ӘДӘБИЯТ

11

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

ӘДӘБИЯТ
11

... язучы һәрвакытта матурлыкка сусап, матурлыкны сагынып яшәргә тиеш. Гыйбрәт алыр, күңелне баетыр, теләкләрне үстерер өчен генә түгел, һәртөрле түбәнлек-ваклыклар, ямьсезлек-әшәкелекләр белән килешмәс өчен, шуларга нәфрәт саклар өчен дә кирәк бу.

Әмирхан Еники

ӘДӘБИЯТ

(XX ЙӨЗНЕҢ 30—90 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА ӘДӘБИЯТ)

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән

Төзәтелгән дүртенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 373.167.1:821.512.145*11
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Ә26

Авторлары:
А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин, Т. Н. Галиуллин,
Ф. Ә. Ганиева, Н. Г. Юзиев

А. Г. Әхмәдуллин редакциясендә

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әдәбият (XX йөзнең 30—90 нчы елларында әдәбият) :
Ә26 татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен д-лек / [А. Г. Әхмәдуллин һ.б. ; А. Г. Әхмәдуллин ред.].— Төзәт. 4 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр, 2011.— 399 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02072-5

УДК 373.167.1:821.512.145*11
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721

ISBN 978-5-298-02072-5

© Татарстан китап нәшрияты,
2011, үзгәрешләр белән

БАШКА ИЛЛӘРДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Мәгълүм булганча, татар халкы күп илләргә-җирләргә таралып урнашкан. Аның дүрттән бере генә бүгенге Татарстанда яши. Калганнары Россиянең төрле өлкәләрендә һәм шәһәрләрендә, дөньяның төрле илләрендә — Америка, Канада, Австралия, Германия, Финляндия һ.б. дәүләтләрдә гомер итә.

Советлар Союзы дигән империя вакытында татар матбугаты, сәнгате һәм иҗатчылар — язучылар, рәссамнар, артистлар үзәге Казанда гына булды. 30 нчы еллардан соң башка урыннарда татарча газета-журналлар чыгару, китаплар басу туктатылды. Мәскәү хакимиятенең сәясәте шундый иде. Башка илләрдәге татарлар СССРдан «тимер пәрдә» белән бөтенләй аерылган хәлдә яшәде. Әмма хәбәрдарлык заманы башлану безгә чит илләрдә барган милли әдәби иҗат процессы белән тулырак танышу мөмкинлеге бирде. Без, ниһаять, күренекле татар әдипләренең 1917 елгы революциядән соң чит илләрдә иҗат иткән әсәрләрен өйрәнә башладык.

Дөрес, бүген бу язучыларның барлык әсәрләре дә табылган, һәм без алар белән кирәк кадәр таныш инде дип әйтеп булмый әле. Бу эш башланды гына. Шулай да без инде башка илләрдәге әдәби иҗат турында, аерым язучылар хакында кайбер мәгълүматларга ия. Соңгы вакытларда Татарстан матбугатында һәм нәшриятларында шактый санда шундый әсәрләр басылды. Без Йосыф Акчура, Хәсән Хәмидулла, Гәүһәр Туганай, Хөсәен Габдуш, Әхнәф Таңгатар, Сания Гыйффәт, Садрый Хәмид кебек язучыларның кайбер әсәрләре белән таныштык. Бөек милләттәшебез Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә нинди эшләр алып барганын, нинди яхшы әсәрләр иҗат иткәнен белдек.

Әдәбиятны яшәтү һәм үстерү өчен матбугат кирәк. Башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез, шуны яхшы аңлап, төрле газета-журналлар чыгарганнар, нәшриятлар оештырып, китаплар бастырганнар. Шундыйлардан, мәсәлән, Төркиядә озак еллар эзлекле рәвештә чыгып килгән «Казан», Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл», Финляндиядә дөнья күргән «Ак юл» журналларын, «Милли байрак» газетасын (Кытай) күрсәтергә була.

Татарлар чит-ят җирләргә төрле сәбәпләр белән барып чыкканнар. Күпчелеге, 1917 елгы афәтләрдән качып, совет сәясәте белән килешмичә, мөһаҗирлеккә мәҗбүр ителгән, һәм аңарчы ук чит ил-

ләргә күчеп киткән гаиләләр дә аз булмаган. Мәсәлән, бүген Финляндиядә көн күрүче татарлар, бу ил әле Россия империясендә булган вакытта ук, ягъни XIX гасыр ахырларында — XX гасыр башларында, монда күчеп килгәннәр. Финляндия мөстәкыйльлек алгач, шунда яшәп калганнар.

XX йөз башында Ерак Көнчыгыш тимер юлы төзелә. Шул ук вакытта Маньчжуриягә дә татарлар күпләп китә. Революцияләр вакытында бу җирләрдә татарлар саны тагын да арта. Монда мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр эшли, газета-журналлар чыга, китаплар басыла, спектакльләр куела.

Чит илләрдә иҗат ителгән әдәби әсәрләрне үзара берләштергән бер тема бар, ул — Туган илне сагыну (ностальгия). Бу хис ватаннарыннан китеп чит илдә олыгайганнарга гына түгел, шунда туып үскән яшьрәк буын вәкилләренә дә хас.

Бик күп кеше әле аңлый алмый
Ватан хисен, Ватан сагышын.
Ватансызлар гына аңлый ала
Ул язмышның авыр каргышын.
«Чит илләрдә яшәү рәхәт»,— диләр,
Чит ил бит үз илең булалмый;
Оясыз кош, иркен очалса да,
Оясына кайтып куналмый,—

дип яза ерак Австралиядә яшәгән Ләйлә Садрый үзенең «Ватансызлык» исемле шигырендә.

Ватансызлыктан газаплану хисе Харбинда яшәп иҗат иткән **Хөсәен Габдушның** (1901—1944) «Алданумы?» исемле хикәясенә дә хас. Әмма монда бу хис милләте белән, аның бөек уллары Г. Тукай, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Кариевлар белән горурлану хисенә төрелгән. Бу каләм иясе күп санлы шигырьләр, хикәяләр («Уртак вөҗдан», «Милли төс» һ.б), пьесалар («Татар телендә беренче телеграф» һ.б.) яза, спектакльләр куюда, төрле әдәби кичәләр оештыруда башлап йөри.

Финляндиягә 1915 елда килеп урнашкан **Хәсән Хәмидулла** (1895—1988), сәүдә эшләреннән тыш, китаплар бастырып таратуны оештыра. Ул актив рәвештә әдәби иҗат белән шөгыльләнә: барлыгы 11 шигырь, 6 хикәя һәм пьесалар җыентыклары, «Тәкъдир каршында» исемле повесть, «Ник алай?» дип аталган автобиографик повесть, «Мөһаҗир бәхете» дигән роман язып бастыра.

Чит илләрдә яшәп тә, милләт язмышын һәм туган телебезне, динебезне саклауны кайгыртудан туктамаган, әдәби иҗаты ярдәмендә халкыбызның гореф-гадәтләрен яшәтергә омтылган мондый язучылар арасында **Гаяз Исхакый** (1878—1954) аерым бер урын тота. Ул үзенең фидакярләрчә актив җәмәгать эшчәнлеге белән дә, язган әсәрләренең саны һәм сыйфаты белән дә әдәбиятыбыз каһарманы булып аерылып тора.

Гаяз Исхакый

(1878—1954)

Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты

Сез, укучылар, бу бөек шәхеснең гомер юлы белән дә, аның беренче чор иҗаты белән дә 10 нчы сыйныфта укыганда танышкан идегез. Аның XX йөз башы татар тормышында, иҗтимагый хәрәкәттә, әдәби процесста нинди күренекле урын билгәнен беләсез.

Гаяз Исхакый иҗтимагый һәм язучылык эшчәнлеген үз иленнән читтә яшәргә мәҗбүр ителгән вакытта да искиткеч фидакярлек белән уңышлы дәвам иттерә. Кытайда, Франциядә, Германиядә, Польшада, бигрәк тә Төркиядә яшәгән 35 елда бу милләтпәрвәр мөһаҗирлектә гомер сөрүче татарларның сәяси һәм рухи атасы булып кала. Милләттәшләрне туплауда, аларга җан азыгы бирүдә какшамас абруен саклый. Аның каләме белән «Өйгә таба», «Татарның кызы» романнары, «Көз» повесте, «Олы бәйрәм», «Тәүбә иткән хатын» хикәяләре, «Локман хәким» исемле фәлсәфи әкияте, «Юлсызлар», «Дулкын эчендә», «Ике ут арасында», «Хәят юлында» драмалары, «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасы, «Җан Баевич» сатирик комедиясе, истәлекләр, тарихи әсәрләр һәм башкалар дөньяга килә.

Гаяз Исхакый бу әсәрләре белән татар совет әдәбиятында булмаган, була да, чагыла да алмаган мәсьәләләрне яктырта. Мәсәлән, Совет хакимиятенең урнашуы вакытындагы вәхшилекләр, дин һәм шәхес иреген кысулар, руслаштыруның аяныч, фаҗигале нәтиҗәләре, татар тарихының кызык һәм кызганыч, онытылуга дучар ителгән сәхифәләре һ. б. кебек «тыелган» темаларны ул зур осталык белән хәл итте һәм тасвирлады. Шундый әсәрләрнең берсе — «Көз» повесте — махсус өйрәнүгә тәкъдим ителә.

«Көз»

Повесть 1923 елда Берлинда языла һәм 1938 елда шунда ук басыла. 1920—1923 елларда Парижда һәм Берлинда язылган 7 әсәрнең берсе ул. Аларның дүртесе 1937—1939 еллар арасында Берлинда басылып чыккан, калганнары кулъязма хәлендә саклана. «Көз» — басылганнарның берсе.

Бер караганда, повестьта вакыйгалар артык куе түгел кебек. Хәлил исемле студент егетнең мирза кызы Гөлсемгә булган көчле, ләкин уңышсыз тәмамланган мәхәббәте, доктор булгач, Нәфисә исемле бай кызын очратуы, яратуы һәм аңа өйләнүе турында. Ләкин шул гади-гадәти вакыйгалар укучыга сюжет ягыннан, композиция төзелеше белән шундый оста һәм нечкә җиткерелә ки, әсәр бер утыруда укыла, фикеренең мөһимлеге һәм татар милләте өчен бүген дә әһәмиятен җуймаган булуы белән нык җәлеп итә һәм сокландыра.

Повестьта вакыйгалар өч өлешкә аерылып тора. Беренчесе — Нәфисәнең үз гаиләсен оештыру тарихы: доктор егеткә булган мәхәббәте, шул мәхәббәте өчен батыр көрәшүе... Боларны ул пароходта очраклы төстә бер каютада туры килгән икенче бер хатынга — Гөлсемгә — үзе сөйли. Икенче өлеш — инде Гөлсемнең җавап төсендә Нәфисәгә үз башыннан кичкәннәрне сөйләве: студент егет белән булган мәхәббәтләре тарихы... Бу ике өлештә сөйләнгән тарихлар контраст рәвешендә, эчке мәгънәләре белән капма-каршы буларак төзелгәннәр, шулай кабул ителәләр дә. Өченче өлештә ханымнар бер үк тукталышта пароходтан төшәләр. Аларны ирләре каршы ала, юл чатына кадәр ике гаилә дә бергә бара. Монда алдагы ике өлешне бергә бәйләгән бер образ бар: сөйләнгән истәлекләрдәге егет — Гөлсем гашыйк булган студент һәм Нәфисәнең ире — бер үк кеше булуы ачыклана. Шуның белән алдагы ике өлештә хикәя ителгәннәрнең йомгагы-нәтиҗәсе бирелә.

Димәк, һәр ике кыз төрле чорда Хәлилнең мәхәббәтенә лаек булган, һәр икесе алдына мәхәббәтләре өчен көрәшү ихтыяҗы килеп баскан. Ләкин монда ике чибәркәй ике төрле эш йөрткән. Әгәр дә мирза кызы сөйгәнен мыскыл итүләренә, үзен егетеннән көчләп аеруларына каршы тора алмаса, язмышы хәл ителгән мизгелләрдә җебеп төшсә, кыюсызланып калса, гади-гадәти татар тәрбиясе алган Нәфисә мәхәббәте өчен көрәштә ныклык һәм батырлык күрсәтә, еш кына инициативаны үз кулына алып, егетен дә үзе артыннан ияртә.

Ничек соң чагыштырмача иркенлектә үскән, рус тәрбиясе алган, белемле Гөлсем, үз ихтыярын эшкә җигеп, үзе теләгәнне булдыра алмый да, шактый ук иске тормышта тәрбияләнгән, мөселман хатын-кызларына хас кысынкылыкта, бигрәк тә этисенең деспотизмын татып үскән Нәфисә үз мәнфәгате өчен көрәшү көченә ия була алган? Ә бит югыйсә повестьның үзендә дә Нәфисә авызыннан әйттерелә: «Бала-чага нинди тирә-юньдә үссә, шуның гадәтен ала...» Ни өчен чагыштырмача иркен рус мохитенә якын булган Гөлсем шулай басынкы тәрбияләнгән? Ә Нәфисәдә рухи ныклык өчен көч кайдан килә?

Әлбәттә, монда һәр ике кызның шәхси сыйфатлары, менәзе-холкындагы үзенчәлекләр зур роль уйный. Автор үзе әйтмешли, «тирә-юнь» дә үз эзен сала. Менә шунда — повестьта уздырылган төп фикернең, татар әдәбияты өчен яңа булган, актуальлеген бүген дә җуймаган идеянең асылы. Моны ачыклау өчен, кызларның тормышына һәм алар яшәгән мохиткә күз ташлыйк.

Мохит һәм дини тәрбиянең мөһимлеге

Гөлсем,— инде әйтелгәнчә, мирза кызы; кече яшьтән үк әнисе үлә; ул ире үлгән тутасы (этисенең сеңлесе) тәрбиясендә кала. Этисе кызының тәрбиясе белән шөгыльләнми. Соңыннан мәгълүм булганча, аның икенче җирдә марҗа сөяркәсе, аннан ике баласы бар икән. Офицер хатыны булган тута кеше кызны рус тәрбиясендә чыныктырырга тырыша, аның һәртөрле татарлыкка дошманлыгы көчле. Уңышларга да ирешә. Шул дәрәҗәгә җитә ки, Гөлсем хәтта иптәшләре арасында «чынлап рус булмавы»ннан хурлана да башлый. Чөнки дини бәйрәмнәр, гадәт буенча, мөселманча үткәрелә, ә бу — кызны башка иптәшләреннән аерып куя. Берара кызый үз асылына кайта язып та кала, һәрхәлдә, аның күңелен алгысыткан хәл булып ала. Бер җәйне аны әбисе янына кайтаралар. Ул шунда ярым мөселман, ярым рус тормышында җәй үткәрә. «Ләкин әллә ничек болар һәммәсе чит булса да, әллә кайчан ишеткән идем, шуның эчендә булган идем кебек бернәрсә сизендем»,— дип искә ала Гөлсем. Утарда, күрше мирзаларда ярым татарча сөйләшү-аралашулар, курай уйнаган малайларның моңнары, әбисенең мөселманча киенеп йөрүе, вакыт-вакыт намаз укуы, бераздан уразага керүләре, үзенең дә ураза тота, күңеле чистара, догалар укуга хирыслана башлавы кызның рухын үзгәртә.

Ләкин арага тагын тутакай килеп керә. Боларны Гөлсем түбәндәгечә сөйли:

«Менә мин шул тормышка ияләшеп кенә беткән идем, тутакай кайтты. Ул: «Бу нинди эш бу?Мондый озын көндә баланы ураза тоттыр, имеш, ул болай да аз канлы, бу тилелеккә мин чыдый алмыйм, әтисенә язам, фәлән»,— диде. Әби белән әйткәләшеп тә алдылар. (...) Минем тормышымның рәте китте. Мин әбием өчен, шундагы кызлар өчен тутакайдан качып сәхәр ашый, азан тыңлый торган булдым. Тутакай өчен әбидән качып көндез чәй эчә торган булдым. Бәйрәмне көттермәенчә, баланы тәмам татарлатып бетерделәр дип куркып, тутакай мине алып китте».

Дөрес, Гөлсем укый торган мәктәптә тагын ике мөселман кызы да укый башлагач, анда мулла китертеп, дин дәресләре дә кертәләр. Шунда кыз татарча укырга-язарга өйрәнә, догалар ятлый. Ләкин болар гына Гөлсемне ике мохит, ике милләт арасында буталып калудан коткармый. Менә шушы тәрбия: үз нәсел-нәсәбенең гореф-гадәтләреннән аерыла бару, икенче тәртипләргә һәм мохиткә кереп бетмәү кызны характерсыз, ихтыярсыз, кыйбласыз итеп формалаштыра. Кыз үз бәхете өчен дә көрәшә алмый. Мөмкин һәм тиеш булганда да тутасы корган киртәләргә каршы чыкмый, кистереп карар кабул итми, бүтәннәр сыбызгысына бии. Нәтиҗәдә олы хисеннән — мәхәббәтеннән коры кала, сөйгәнен югалта, гомерен хәсрәт-кайгыда, җәфада уздырырга мәҗбүр була.

Беренче карашка, Нәфисә — иске тормышлы ата-ана кулында тәрбияләнгән кыз — юаш, карусыз, ихтыярсыз булырга тиеш иде кебек. Ләкин алай түгел. Саф һәм көчле мәхәббәте, сөйгәненә ышанычы аңа иске тәртипләрне җиңеп үтәргә ярдәм итә. Аның мәхәббәте тарихын тыңлагач, Гөлсем: «...шулкадәр иттереп нык тотынырга сезгә кем гакыл бирде?» — дип сорый. «Беркемнән бер киңәш сорамадым, — дип җавап бирә Нәфисә.—Беркем берни өйрәтмәде. Уйлап та тормадым. Күңелем ни кушты, шуны эшләдем, шул барып та чыкты». Үз мохите тәрбиясе, гәрчә кайдадыр, ниндидер якларында кимчелекләре булса да, Нәфисәгә төп гамәлен — күңеле кушканны, үзе дөрес дип тапканны эшләүдә ныклык бирә. Монда аңа динле булуның зур ярдәме тигәнен дә төшенәсең. Шунысы бик мәгънәле: иң кыен, иң хәлиткеч вакытларда кыз Коръәнгә, изге догаларга мөрәҗәгать итә. Менә ничек искә төшерә ул: «Мин кич берлә намаздан соң бик озын Коръән укып

яттым, күңелем бераз басылган кебек булды». Яисә икенче бер урында: «Мин бик һәйбәтләп тәһарәт алып, зур бер ихлас берлә намаз укырга керештем. Егетемне китереп җиткерүе өчен, миңа ярдәме өчен Аллага шөкранам шулкадәр зур иде, мин намазым беткәч тә намазлыктан тора алмадым. Коръән укырга тотындым. Укыдым, укыдым, тагын аз булган кеби булды, тагы укыдым. Әти кайтты, самавыр керде, аш башланды. Мин һаман Коръәннән аерыла алмадым. Әни берничә мәртәбә килеп китте, ул да мине бүләргә базынмады. Догамны кылып, тәмам тынычланып, чәйгә чыктым».

Өченчесендә ул, үзенең бәхетле, тигез тормышы белән Гөлсемнең исерек ир кулындагы газаплы тормышын чагыштырып караганнан соң, дини хисләренә иркенлек бирә:

«Аның күңеле йомшады, ул көзге кояшка каршы чабып бара торган арбаның җиле астында акрын гына Коръән укырга керeште. (...) Үзе аңлап бетмәгән Коръәннең сүзләре, бигрәк шуның көе аның күңеленә әллә нинди бер йомшак җылылык бирде. Аның тамырларына әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык тынычлык таратты. Ул үзе дә сизмәенчә тавышын зурайтканнан-зурайтты. Коръән моңы, көпчәк тавышына кушылып, яңа бер төс алды. Акрын гына исә торган көзге җил ул тавышны алга-артка чәчте, сипте. Нәфисә, үз көенә үзе батып, Коръән артыннан бара торган тирән бер шөкрана берлә, басылганнан-басылып башын иде, бик түбән иттереп башын иде. Шул тормышны биргән Тәңресенә каршы сәҗдә кылмакчы булып буен сонды».

Гөлсемнең динен һәм денен җуйган тутакае һәм этисе фонында, аның әйләнә-тирәсендәге ни рус, ни татар булмаган мирзалар фонында Нәфисәнең дини тәрбиясе нәтиҗәле һәм ышанычлы булып чыга. Исламның көче раслана.

Гомумән, дин әһелләре, дини мохит һәм исламга ышанучылар повестьта җылы итеп сурәтләнгән. Иң әүвәл, хәзрәт акыллы, миһербанлы, дин кагыйдәләрен белеп эш йөртүче, дин юлында нык һәм яшьләр мәнфәгатен аңлый белүче кеше булуы белән хәтердә уелып кала. Бу инде безнең әдәбиятта, бигрәк тә совет әдәбиятында еш сурәтләнгән мөтәгассыйб[1], надан, комсыз мулла образы түгел. Үз иҗатында надан ишан-муллалардан күп көлгән, андыйларны шактый фаш иткән Гаяз Исхакый бу

[1] *Мөтәгассыйб* — киребеткән, фанатик.

әсәрдә халыкның намусын һәм вөҗданын гәүдәләндергән дин әһеле образын тудырган. Яшьләрнең үтенечен үтәп, аларның саф мәхәббәтен һәм изге ниятләрен хуплап, ул Нәфисәнең әти-әнисе янына килә, бигрәк тә киребеткән ата кешене үгетли, кирәк булгач, хәтта тирги дә, ничек булса да аны кызының бәхетенә каршы төшмәскә күндермәкче була. Аның дәлилләре ышанычлы яңгырый:

«Урыс арасында тора торган кеше, үзен үзе саклап, мөселман гаиләсенә катышырга теләве өчен мин тәхсин[1] укыдым,— ди ул.— Нишләр идек, бер маржа тотып: «Хәзрәт, никах укы»,— дип килсә, яисә никахсыз-нисез балалар атасы булып, урыс күбәйтсә». Хуҗаның: «Хәзрәт, сезгә шундый ярты урыслар артыннан олуг башыгызны кече итеп йөрү кирәкмәс иде»,— дигән шелтәсенә ул: «Без — пәйгамбәр галәйһиссәламнең варислары. Кем безгә дин эшендә мохтаҗ, һәммәсенә ярдәм итешү — дини вазифабыз»,— дип җавап бирә. «Олуг башыңызны кече итеп йөрмәңез, хәзрәт» дигәнгә дә нык итеп: «Башымыз шул шулай вакытында кече итә белгәнгә күрә, ул олуг булган»,— дип кистерә. Яшьләрнең ата-ана рөхсәтеннән башка никахлашуын килештермәсә дә, «Ашыгасыз» дисә дә, инде башкача юл булмавын күргәч, ата-ананың бик каршы булуына да карамастан, аларга никах укый. Шул рәвешле, саф хисләрнең татарлар арасында бу чорларда шактый ук нык тамырланган кирелек-үҗәтлекне җиңеп үтүе күрсәтелә, укучыда рухи канәгатьләнү тудыра.

Тагын кайбер үзенчәлекләр

Повестьның сәнгатьчә эшләнешендә тагын да үзенчәлекләр күп. Ике кызның бер үк егеткә гашыйк булу тарихларын автор оста итеп урнаштыра: композицион төзелештә егетнең беренче мәхәббәте тарихы түгел, ә хронологик яктан икенчесе булганы алга чыгарып сөйләнелә. Бердән, укучы һәр ике очракта бер үк егет турында сүз баруын сизмәскә-белмәскә тиеш. Икенчедән, үзенең язмышыннан канәгать булган бәхетле хатынның башлап ачылып китүе мантыйк ягыннан да аклана.

Әдәбиятта еш очрый торган мәхәббәт өчпочмагының автор үзенчәлекле очрагын тапкан. Егетнең мәхәббәте өчен көрәштә

---

[1] *Тәхсин* — яхшы күрү; мактап «яхшы» дип әйтү.

ике кыз үзара тартышка керми, чөнки алар аңарчы бер-берсен белми дә, тартышу өчен нигез дә юк. Бу өчпочмак укучыга бары тик әсәрнең өченче өлешендә генә мәгълүм була. Шуңа кадәр егетләрнең бер үк кеше булуы сизделми, бу укучының да башына килми: моңар сәбәп юк. Ике хатынның бер-берсеннән мөстәкыйль хикәятләрендә аның чын исеме дә аталмый. Аны сөйләүчеләрнең әйтүе мәҗбүри булмаган кебек, укучы да аны кирәксенми.

Автор кешеләрнең портретларын җентекләүгә бөтенләй дә игътибар бирмәгән. Үзәк персонажларның да, ярдәмчеләренең дә — берсенең дә тышкы кыяфәте бирелмәгән. Хикәяләү моңа ихтыяҗ тумаслык итеп алып барылган.

Гомумән, хикәяләүдә исә Гаяз Исхакыйның XX гасыр башында урнашкан стильгә тугрылыгы күренә. Ул тыгыз, экспрессив[1]. Аны А. С. Пушкин прозасындагы («Капитан кызы», «Станция караучысы») стильгә бик тартым дияргә мөмкин.

Ә менә табигать күренешләрен сурәтләүгә язучы иркенлек биргән, зур уңышка ирешкән. Сәнгатьле детальләрнең кулланылышы сокланырлык, һәм аларны бигрәк тә өченче өлештә мул табарга мөмкин. Табигатькә һәм хәрәкәткә караган детальләр кешенең язмышын да, эчке халәтен дә, рухи дөньясын да ача яки аларга тәңгәл килә, яисә капма-каршы итеп китерелә. Бигрәк тә көз образы югары гәүдәләнеш тапкан. Повестьның беренче җөмләләрендә үк игътибарны яулап ала ул:

«Көз иде. Шыбыр-шыбыр ява торган вак ягмур күзгә төртсәң күренмәс караңгы төнгә тагы караңгылык куша, авыр һавага тагы басынкылык бирә иде» һ.б.

Повестьның соңгы өлешендә бу образ тагын калкып чыга. Көзнең төрле манзаралары, сары яфраклары, яфраксыз коры агачлары, җиле-яңгыры — һәммәсе бергә Гөлсемнең язмышы көзгә керүен, Хәлил белән Нәфисәнең дә гаилә тормышы көзгә якынлашуын символлаштыра. Шуның белән бергә, көзгә керүнең дә төрле-төрле булырга мөмкин икәнлеге ассызыклана. Гөлсемнең үзен һаман да сөюе хакындагы сүзләренә Хәлил: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке — миләшчә, алманыкы — алмача!» — дип җавап бирә. Гөлсемнекеннән

---

[1] *Экспрессив* — мәгънәле, тәэсирле.

аермалы буларак, Нәфисәнең тормыш көзе мул һәм тәмле җимешле булуы аңлашыла.

Әсәрдә тел-сурәтләү чараларының байлыгына, урынлы кулланылуына, диалекталь сүзләрнең иркен кертелүенә мисаллар күп.

Кыскасы, «Көз» повесте — Г. Исхакыйның читтә яшәгәндә язылган әсәрләренең мәгънәле, югары сәнгатьле, төгәл эшләнгәннәреннән берсе. Алай гына да түгел, бу — бай мираслы татар әдәбиятындагы иң гүзәл проза үрнәкләреннән берсе.

Сораулар һәм биремнәр

1. Вакытлы матбугаттагы яңа мәгълүматларга таянып, чит илләрдә яшәп иҗат иткән язучылар һәм әсәрләр исемлеген тулыландырыгыз.

2. «Көз» повестеның сюжет сызыгын бәян итегез.

3. Гөлсемгә һәм аның мохитенә нәрсәләр характерлы?

4. Нәфисәдәге рухи ныклыкның чыганаклары нидә?

5. Нәфисә тәрбияләнгән тормышның кайсы яклары искелек дип бәяләнергә хаклы һәм шәхеснең рухи хөрлеген чикли? Ә кайсылары үрнәк булырлык?

6. Мәхәббәтләре төшкән егетне Гөлсем һәм Нәфисә ничек искә алалар? Шул истәлекләрдән һәм әсәрнең соңгы өлешендәге хәлләрдән чыгып, Хәлилгә характеристика бирегез.

7. Гөлсемгә соңгы җавабында Хәлил: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке — миләшчә, алманыкы — алмача!» — дигән сүзләренә нинди мәгънә сала? Шәрехләгез. Әле генә хатирәләргә бирелгән ирнең ике бала анасына «туташ» дип дәшүенә игътибар иттегезме?

8. Ярдәмче образлардан кайсылары җылы хисләр уята, ни өчен? Аларга да, тискәре образларга да бәя бирегез.

9. Повестьның өч кисәктән торуын нигезләгез; һәр өлештәге үзәк ситуацияне табып күрсәтегез.

10. «Көз» повестеның төп фикерен (идеясен) ачыклагыз.

11. «Повестьта пейзаж» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

12. «Мохитнең тәрбияви көче («Көз» повесте мисалында)» дигән темага сочинение язу өчен план төзегез. Дәрестә тикшереп, төзегән планның кайсысы уңышлырак булуын ачыклагыз.

30 НЧЫ ЕЛЛАРДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Чор үзенчәлеге

Ил тормышында, халык язмышында, мәдәнияте үсешендә үзенчәлекле урын тоткан 30 нчы еллар татар әдәбиятының әлегәчә дөрес бәя алганы юк. Элегрәк язылган китапларда, дәреслекләрдә ул чор социализмның беренче баскычын төзү, илне индустриаль адымнарга бастыру, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү, мәдәният өлкәсендә биниһая зур уңышларга ирешү, милләтләр арасында чын дуслык, туганлык, тыгыз хезмәттәшлек урнаштыра башлау дәвере буларак, уңай яктан гына бәяләнеп, алсу, матур төсләрдә генә яктыртылып килде.

Соңгырак басмаларда исә 30 нчы еллар шәхес культы котырынган, вак милләтләргә каршы геноцид алып барылган, миллионлаган акыл ияләрен, зыялыларны физик юк иткән, илне хәерчелектә калдырган караңгы, явыз, соры бер дәвер итеп кенә карала башлады. Бәя бирүдә бер чиктән икенчесенә сикерү өстенлек алды.

Хәлбуки бу унъеллыкны, бигрәк тә шул чор әдәбиятын уңай һәм тискәре яклары, үсеш каршылыклары белән аңлау һәм бәяләү кирәк, һәр дәвер — халык узган тарихи юлның бер буыны.

Әйе, ифрат четерекле, катлаулы булган 30 нчы еллар. Ул чорда бөтен җәмгыятьне аякка бастырган хезмәт дәртен, киләчәккә романтик ышанычны, гомуми күтәренке рухны инкяр итеп булмый. Буш җирләрдә яңа шәһәрләр үсеп чыга. Завод-фабрика морҗалары күтәрелә, илнең куәте ныгый. Хезмәт батырлыгы әдәбиятка үтеп керә, аның эчтәлеген, сурәтләү чараларын тамырдан яңарта. Сүз сәнгате тормышка, төзелешләргә якыная, шулар рухы белән яши. Вакыйгалар эзеннән язылган, көн кадагына суккан очерк һәм хикәяләр, шигырь һәм поэмалар алга чыга.

Үткәнне тоташ кире кагу аша яңаны раслау әдәбиятның үзәк юнәлешенә әверелә.

Ил белән идарә итүче Коммунистлар партиясе әдәбиятның, гомумән, сәнгатьнең халык аңына йогынтысы зур булуны аңлап, аны үз сәясәтенә хезмәт иттерүгә күп көч куя.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» 1932 елгы карары нигезендә язучыларның шул вакытта яшәп килгән оешмалары һәм басмалары таркатыла. «Атака» һәм «Яңалиф» журналлары урынына 1933 елның башыннан Казанда «Совет әдәбияты» журналы чыга башлый.

1934 елның 25—29 июль көннәрендә Казанда татар язучыларының I съезды үткәрелә. Киң җәмәгатьчелек катнашы белән тантаналы төстә уздырылган бу җыенда Г. Ризванов, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Р. Ишморат, К. Тинчурин, Ф. Кәрим һ.б.ның тәфсилле чыгышлары тыңлана.

Милли төбәкләрдә үткән съездларның нәтиҗәсе Мәскәүдә ясала. 1934 елның августында СССР язучыларының I съезды җыела. Татар әдәбияты турында доклад белән Язучылар союзы идарәсе рәисе Кави Нәҗми чыга.

СССР халыклары, бигрәк тә рус әдәбиятының үткәне һәм 1917 елдан соңгы үсеше хакында төп доклад ясауны М. Горький үз өстенә ала. Әдип үзенең чыгышында барлык республикаларның милли әдәбиятлары уртак идея тирәсендә берләшүен, үзара якынаюын, бары тик тел ягыннан гына аерылуларын билгеләп үтә һәм шунда «совет әдәбияты» дигән төшенчәгә нигез сала.

20 нче елларда язучыларны әдәби төркемнәргә, сыйнфый катлауларга бүлеп йөртү, ягъни пролетариат әдипләрен авылдан чыккан язучылардан, бигрәк тә «юлаучылар»дан (иҗатын 1917 елга чаклы башлаган яисә вак буржуа, зыялылар нәселеннән чыккан каләм ияләрен шулай атыйлар) аерып, бүлеп карау гамәлдә иде. Язучылар съездыннан соң бу бүленешнең кирәге калмады. Чөнки алар барысы да «совет язучылары» дигән атамага сыеп беттеләр. Әлбәттә, Г. Исхакый кебек «халык дошманы», Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, С. Рәмиев кебек «буржуа язучылары» ул әдәбиятның тышкы ягында калдылар.

Чынында ил ирешкән матди уңышлар халыкка да, аның юанычы, таянычы булган әдәбиятка да җиңеллек алып килми, алай гына да түгел, якты киләчәк канга буяла. Хәлбуки хосусый милекне юкка чыгару, байлыкны, бөтен көчне хәрби һәм

эре индустриягә баглау, сүздә эшчеләр хакимиятен урнаштыру барышында Сталинның шәхси хөкемдарлыгына юл ачу 30 нчы елларның икенче яртысында коточкыч репрессияләргә китерә, халыкны кол дәрәҗәсенә төшерә.

Башка милли язучылар белән бергә татар каләм ияләре дә дәртләнеп җырлаган Днепрогэс, Метрополитен, Идел-Дон каналы кебек бөек төзелешләр, яла ягып, нахакка кулга алынган кешеләрне җәзалау, «төзәтү» корылмаларына әверелә. Партия үзенчә уйламаучыларны, шикле дип саналган һәркемне рәхимсез җәзалауга керешә. Шәхес язмышын шымчы оешма кешеләре хәл итә.

Сталин режимының авырлыгы бөтен халык җилкәсенә төшә. Берәү дә үзен ирекле, имин дип сизә, тыныч яши алмый. Күршең, танышың, туганың синең сәяси ышанычлыгыңа шик белдерсә, бигрәк тә шикаять язса, язмышың хәл ителгән дип сана, төнге бердә төрмәгә алып китүне, ахыр җәзаны көт тә тор.

Илнең икътисади һәм хәрби куәте үсү дә халыкка мул, рәхәт тормыш алып килми. Төрле сылтаулар белән салымнар елдан-ел арта бара.

Бай һәм олы тарихлы татар халкы аеруча зур югалтулар кичерә. Ун ел эчендә ике тапкыр алфавит алыштыру, матбугатны кысу, татар мәктәпләрен ябу өстенә намуслы, әхлаклы акыл ияләре күпләп юкка чыгарыла. Сталинның канлы балтасы татар әдәбияты муенына иң үткен чагында төште. Г. Ибраһимов, М. Галәү, Җ. Вәлиди, Ф. С.-Казанлы кебек өлкән буын вәкилләре белән беррәттән, Совет хакимиятенә ихлас хезмәт иткән язучылар Ф. Бурнаш, Г. Толымбай, Л. Гыйльми, сугышчан комиссар Ш. Усманов, идеологик ялгышларга, тайпылышларга һәм формализмга каршы армый-талмый көрәшкән марксист-тәнкыйтьчеләр Г. Нигъмәти, Г. Гали белән бергә яшь шагыйрь Г. Мөхәммәтшин һәм башкалар бер гаепсезгә әрәм ителәләр. К. Тинчуринны хәтта совет чынбарлыгын күкләргә чөеп язган «Корыч орчык» (1930), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесалары да коткарып кала алмады. Х. Туфан, И. Салаховлар сөргенгә җибәреләләр. Каһәрле еллар бик күпләрне рухи имгәтә.

Әдәбияттагы бушлыкны производстводан, колхоз кырларыннан килгән, сәләт, зәерлек яклары түбән булган зәвыксыз, уртакул һәвәскәрләр тутыра. Ул елларда совет режимын мактаган, яклаган, сыйнфый көрәшкә, кан коюга чакырган, милләтчелекне фаш иткән, әдәби яктан бик түбән әсәрләр күп

языла, күп басыла. Берәүләр исән-имин калу, икенчеләр тамак туйдыру хакына әхлаксыз, имансыз хакимиятне, «халыклар атасы» Сталинны мактау юлына басарга мәҗбүр булалар. Динсезлек дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма тар идеологик-сәяси кысаларга куып кертелсә дә, татар әдәбияты яшәүдән туктамый.

Искиткеч авыр шартларда, коточкыч басым астында да аның үз йөзен югалтмавының сәбәпләре нинди? Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

Бердән, татар әдәбиятының ерак гасырлардан килгән олы реалистик традицияләре һәм XX гасыр башында күтәрелешенең «алтын чорын» кичерүе бик күп буын язучылар өчен зур таяныч, терәк булды. 30 нчы еллар да бу мирасны читләтеп үтә алмады.

Икенчедән, 1917 ел алдыннан татар әдәбиятында Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Дәрдемәнд, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Камал кебек югары абруйлы каләм осталарының хезмәт итүе, күбесенең 20 — 30 нчы елларда да иҗат эшчәнлегеннән аерылмавы татар сүз сәнгатенә билгеле бер сыйфат дәрәҗәсендә калырга мөмкинлек бирде.

Өченчедән, бу чорда әле татар әдәбияты яшь көчләрне төрле төбәкләрдән үзенә тартып, җыеп тора. Оренбург ягыннан Муса Җәлил килсә, Саратов төбәгеннән — Г. Кутуй, Тамбов тарафларыннан — Һ. Такташ, Башкортстаннан М. Әмир, Ф. Кәримнәр өстәлә.

Проза һәм драматургия үсеше

1905 еллар инкыйлабы уяткан милли аң үсешен бернинди кара көч тә туктата алырлык түгел иде инде. Бу бигрәк тә халык үткән тарихи юлны аңларга омтылышта ачык күренде. М. Җәлил «Алтынчәч» (1935—1941), «Илдар» (1940) кебек героик җирлеккә өстенлек биргән күләмле шигъри әсәрләрен, либреттоларын иҗат итә. Н. Исәнбәт 1939 елда халык легендасына нигезләнеп язылган «Түләк батыр» әсәрен, 1940 елда Борынгы Рим коллары язмышын үзәккә алган «Спартак» трагедиясен төгәлли. Ул шушы елларда «Идегәй» поэмасын китап итеп бастырырга әзерли.

Мәхмүт Галәүнең бу юнәлештәге эшчәнлеге аеруча игътибарга лаеклы. Ул «Болганчык еллар» (икенче исеме «Ил тыныч чакта»), «Мөһаҗирләр» («Ил өреккәндә») кебек әсәрләре белән яңа чор тарихи романына зур өлеш кертә.

«Канлы тамгалар» дигән гомуми исем астындагы бу эпопея, дүрт китаптан торып, халык үткән юлның олы һәм аянычлы хәлләрен үзәккә алырга тиеш була. Ләкин бу матур ният гамәлгә ашып бетми кала. Беренче ике кисәге Мәскәүдә (1931, 1933) рус телендә басылып чыга. Аларның үзәгендә 1877 елда Идел буен аяктан еккан ачлык вакыйгасы, гасырлар буе куркытулар белән яшәүгә дучар ителгән авылның, халык исәбен алуны чираттагы көчләп чукындыру дип кабул итеп, фетнә күтәрүе һәм Төркиягә күченеп китәргә кузгалуы, юлдагы һәм чит җирләрдәге ачы фаҗигасе ята.

М. Галәүнең иҗат планнарын шәхес культы шаукымы өзә.

Аерым кеше язмышын киңрәк җирлектә сурәтләүгә омтылыш милли әдәбиятны эпик киңлеккә алып чыга, халык тормышында урын алган мөһим вакыйга-хәлләрне үзәккә куярга мөмкинлек бирә. Шул юнәлешкә мисал рәвешендә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының икенче басмасын, Ш. Камалның «Матур туганда» романын, Г. Бәшировның «Сиваш», М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестьларын искә төшерергә мөмкин.

Чор таләп иткәнчә, илне саклау темасы алга чыга.

Мирсәй Әмир 30 нчы еллар башында иҗат иткән «Сугыш сере», «Аяк» дигән хикәяләрендә, бигрәк тә «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» повестенда хәрби темага шаян юмор алып керә, үткер, мавыктыргыч сюжет төзүдә гаҗәеп осталык күрсәтә.

«Бер мәхәббәт тарихы» (1933), «Госпитальдә» (1938) хикәяләрендә Афзал Шамов гражданнар сугышы чорын тасвирлый.

Беренче хикәя кызылармеец Нурулланың чибәр кыз Рабигага олы мәхәббәте, әмма аны дошман җибәргән шымчы дип кабул итүе, шул җирлектә туган маҗаралы һәм көлкеле хәлләрне үзәккә ала. Нурулла, сугышта кулын югалтып, аягын имгәтсә дә, һичнигә үкенми, беренче мәхәббәтен —Рабиганы сагынып яши, шуннан күңеленә юаныч таба.

30 нчы елларда иҗат иткән әсәрләрендә А. Шамов кискен эчтәлекне, катлаулы сюжетны мелодраматик һәм лирик буяулар ярдәмендә зур осталык белән сурәтләп бирә. Шул ук вакытта аның канкоеш темасы, сыйнфый көрәш тирәсендә генә әйләнүе иҗат офыгын чикли, бу нәрсә аны кабатлануларга да алып килә.

Гражданнар сугышы чоры вакыйгалары «Сиваш» повестенда колачлы гәүдәләнеш тапты. Анда Г. Бәширов үзе катнаш-

кан һәм яхшы белгән вакыйгаларны, ягъни 1920 елда Сивашны кичеп, Врангельне Кырымнан бәреп чыгаруны үзәккә ала.

Язучы сугышның кырыслыгын, анда кешене һәр адымда үлем көтеп торуын салкын суны гизүче батыр элемтәчеләр, кыю кавалерист Митричев, акыллы, зирәк Данилов, үзе армиягә алынгач туган улын сагынып, шул юксынуыннан тәм табып яшәүче Әхмәди абзый һәм өермәле тарихи вакыйгаларга үз ихтыярыннан башка тартып кертелгән авыл егете Шәмси образлары аша гәүдәләндерә.

Үзәк персонажның фикерләвендә, сүз йөртүендә, кешеләргә бәясендә беркатлылык сакланса да, ул күп нәрсәне, үзенең төрле милләт кешеләре белән туганлыгын, һәр сугышның, хәтта элегесенең дә артык рәхимсез булуын аңлый, сиземли башлый.

Кырыс тирәлек шәхеснең характерын тиз үзгәртә, тиз яңарта.

«Сиваш» повесте рәхимсез чор турындагы иң уңышлы әдәби истәлекләрнең берсе булды.

Гражданнар сугышының кайтавазы драматургиядә дә, поэзиядә дә озак яңгырады. Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләк» (1938), «Ялкын» (1938) пьесалары — шуңа ачык мисал.

Шул ук вакытта яңа чор герое әдәбият ишеген елдан-ел ныграк шакый. Кылычын — чүкечкә, мылтыгын сукага, уракка алыштырган персонажның тышкы кыяфәте генә үзгәреп калмый, аның фикер йөрешендә, дөньяга карашында үзгә, яңа сыйфатлар бөреләнә. Колхоз алдынгысы, производствоны җилкәсендә алып баручы, сыйнфый дошманнар белән аяусыз көрәшүче, түбәннән, буразнадан күтәрелгән зат әдәбиятның тоткасына, умыртка баганасына әйләнә.

Шәриф Камал күпчелек драмаларын шул чорның кискен бәрелешләрен, яңа тормыш төзү авырлыкларын сурәтләүгә багышлый («Козгыннар оясында», 1929; «Таулар», 1931; «Габбас Галин», 1934). Бу әсәрләрдә сыйнфый көрәш, һәркайда дошман эзләү, аны фаш итү өстенлек итсә дә, тынгысыз язучының эшче, интеллигенция вәкилләренең яңа шартларда яшәешен кабатланмас образлар аша күрсәтергә омтылышы игътибарга лаеклы иде.

«Агыйдел» (1935) повестенда Мирсәй Әмир авылның күп еллар дәвамында көйләнгән тормыш итү рәвешен көч кулланып үзгәртүне үзәккә ала. Әсәргә кискен динамизм, кешенең кабатланмас үзенчәлекләрен замана билгеләре аша тасвир-

лау хас. Хәзерге чор күзлегеннән караганда, яшьләрнең мич арасына яшеренеп интим сөйләшүләрне тыңлап йөрүләрен, аларның артык кырыслыгын кабул итмәскә дә мөмкин. Ләкин һәр күренешне үз чорына куеп бәяләү дөресрәк булыр.

Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы (1935) берничә буынны яңа әхлак кагыйдәләре һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгы өчен көрәш рухында тәрбияләде. Зур шәһәргә эләккән авыл кызы Галияне тормыш авыр һәм дәвамлы сынаулар аша үткәрә. Кызның саф, самими хисләрен аяк астына салып таптаган Искәндәрнең керле җанлы, вак кеше икәнлеген тормыш мәктәбе фаш итә. Әмма авырлыклар мәхәббәтнең, хәят дәртенең җиңеп чыгачагына ышанычны киметми. Чыннан да, Галия үзенең эчке һәм тышкы матурлыкларын саклаган хәлдә чыныга, тормыш мәгънәсен киңрәк аңлауга килә.

Галиянең хатлары — һәркайсы төгәлләнгән әдәби бөтенлек. Эпистоляр (хатлар төрендәге) жанр шәхеснең рухи дөньясын, уй-кичерешләрен мөмкин кадәр тулырак, төгәлрәк яктыртуга юл ача.

«Гөлзадә» (1940) драмасында Риза Ишморат искиткеч мөлаем татар хатыны образын тудыра, аның рухи бәйсезлеге өчен көрәшен күркәм итеп сурәтләү югарылыгына күтәрә. Фатих Хөсни «Урманда» (1938) комедиясе белән көлке жанрын яңа шартларда яңартуга омтылыш ясый.

30 нчы елларда татар әдәбиятында зыялылар тормышына багышланган әсәрләр дә күп языла. Фатих Хөснинең «Профессорның трагедиясе» (1932), «Портрет» (1933), Кәрим Тинчуринның «Мәрҗәннәр» (1935—1937) әсәрләре әнә шундыйлар. Аларның нигезендә зыялылар тормышын психологик анализ аша тирән һәм тормышчан итеп сурәтләргә омтылыш ята.

Барысы өчен уртак фикер шул: зыялылар үзләренә инкыйлаб алып килгән бәхетне, шатлыкны авырлык белән кабул итәләр һәм, аның илаһи хакыйкатькә өмет уятуын аңлагач, аңа хезмәткә күчәләр, шул максатта үзләренә куаныч, ләззәт табалар.

Татар язучыларының укыган кешеләр тормышын сурәтләүдә артык туры юлдан барулары, ялгышу, сөрлегүләрне гафу итмәүләре әсәрләренең яңгырашын тарайтса да, аларның матур киләчәккә ихластан ышанып язуларын шик астына алып булмый.

Шәхес культы фаҗигаләре нәтиҗәсендә К. Тинчуринның «Мәрҗәннәр» повесте 1960 елда гына дөнья күрде. Бу әсәрендә автор Сөләйман исемле шәкертнең кан кою, хыянәт итү белән тулы болганчык тормышта үз урынын эзләвен психологик төгәллек белән тасвирлый. Әсәрнең рәвеше үзенчәлекле, һәр «мәрҗән» — үзе бер төгәллекле новелла.

Шул рәвешчә, татар әдәбиятында проза, драма жанры эзләнә, яңара. Ләкин, алга барган саен, сыйнфый көрәш кискенләшә дип, әдәбиятка рәсми идеология көчләп таккан ялган караш жанрлар үсешенә дә кара шәүлә булып төшә. Кешеләрне бер-берсенә каршы кую, сугыштыру, дошманлаштыру өчен уйлап чыгарылган тәгълимат икәнлеген язучылар соңрак аңлый.

Шушы идеологиягә ихлас ышанган байтак язучылар, сыйнфый дошман эзләү юлына чыгып, иҗади үсешләрен чикләделәр. Р. Ильясның «Горизонт» (1934), Х. Госманның «Йосыф» (1937) повестьлары, Г. Иделленең «Дәүләт Бәдриев» (1937) пьесасы шуңа ачык мисаллар.

Тормышның һәр кыйбласында, катламында Совет хакимиятенең дошманнарын эзләү, аларның мәкерле уйларын, күмәк хуҗалыкны юк итү турындагы хыялларын фаш итү, кулакны, аның чит ил контрреволюциясе белән элемтәдә яшәгән күп санлы иярченнәрен, имештер, кояш яктысына тартып чыгару, ахыр чиктә кулга алу, төрмәгә озату бик күп әсәрләрнең, шул исәптән чор классикасы саналган Ш. Камалның «Матур туганда», Ф. Кәримнең «Җиденче мич», М. Әмирнең «Агыйдел», Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман» кебек әсәрләренең дәрәҗәсенә дә кагыла. Ярлы-ябагай арасыннан күтәрелгән персонаж гына һәр очракта җиңүче булып чыга.

Дөрес, бу чор әсәрләренең барысында да диярлек дистәләрчә тормышчан типлар, характерлар, искиткеч оста һәм матур сурәтләү чаралары да табыла. Әмма югарыдан алган күрсәтмә нигезендә фикерләү, алдан хәл ителгәнчә вакыйгалар чишелеше әсәрләрнең яңгырашын чикли.

Шунысы мөһим: бу чорда басылган һәм проза, һәм драма әсәрләрендә ахыр чиктә һәртөрле каршылыкларны, авырлыкларны җиңә килгән, кешелек горурлыгын, вөҗданын һәм халкына тугрылыгын саклаган геройлар югары куелды. Шундыйлардан, әйтик, Г. Бәшировның «Көннәрнең берсендә» (1934), Г. Кутуйның «Вөҗдан газабы» (1939) һ.б. күрсәтергә булыр иде.

Поэзия

30 нчы еллар поэзиясен башлыча Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Салих Баттал, Муса Җәлил, Шәйхи Маннур, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Галим Мөхәммәтшин, Нур Баян, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садри кебек төрле буын һәм юнәлеш вәкилләре иҗат итә. Н. Исәнбәт, Г. Кутуй, К. Нәҗмиләр башка жанрларга күчсәләр дә, шигърияттә өзеклек барлыкка килми. Ул йөзе белән заманга, авылда һәм шәһәрдә җәелеп киткән төзелешләр, яңарышлар ягына борыла. Сүз сәнгате белән тормыш арасында бәйләнешнең яңа төрләре (предприятиеләргә, төзелешләргә, колхозларга барып йөрүләр, шунда турыдан-туры эшкә керү, укучылар белән даими очрашу һ.б.) табыла. Шигъри очерк, репортаж, марш, публицистик җыр кебек һөҗүмчән жанрлар алга чыга. Күмәк әдәби альманахлар, җыентыклар күп басыла («Төзү көннәрендә», 1929; «Төзү баррикадаларында», 1931; «Удар забой», 1931 һ.б.).

Бу төр әсәрләрнең байтагы рифмалы прозаны хәтерләтсә дә, күбесен бүгенге укучыга инде тәкъдим итеп булмаса да, аларда чор сулышы чагыла. Поэзиядә үз йөзләрен тапкан сәләтле шагыйрьләр дә газета мәкаләсен ритмика теленә күчереп аз әсәрләр язмыйлар.

30 нчы елларның җанлы шаһиты С. Баттал «Батый ханга ачык хат» исемле, озак еллар дәвамында тыела килеп, 1993 елда гына дөнья күргән әсәрендә: «Җырлый идек. Без җырлаган даннар архивларда ята бер олау»,— дип яза һәм чорга шундый бәя бирә:

«Сыйнфый дошман» диелде күп дуслар.
Үтте инде, түздек барсына —
Мең тугыз йөз утызынчы еллар
«Революциясе» хакына.

30 нчы еллар поэзиясенең төп җитешсезлеге — җанлы кешене, аның рухи дөньясын исәп-хисап һәм хезмәт лозунглары белән алыштыру, шәхси башлангыч урынына гомумилек, өстән төшкән күрсәтмәләрне тиредән чыгып үтәү, ислам динен, муллаларны, хәлфәләрне һәм, гомумән, зыялы кешеләрне халыкның иң әшәке, кыйналырга тиешле явызлары дәрәҗәсенә төшерү. Сыйнфый дошман эзләүнең «әлифбасы»н Һ. Такташ «Йомшак башлар» (1929) шигырендә биреп калдырган иде.

Шуңа да карамастан, ком арасында энҗе, алтын бөртекләре төсле ялтырап-ялтырап киткән, илаһи тәэсир көчләрен хәзергәчә югалтмаган лирик парчалар туа торды. Х. Туфан «Ак каен» (1933), Ә. Фәйзи «Умырзая» (1933), М. Җәлил «Сагыну» (1936), С. Хәким «Юксыну» (1938) кебек җыр-шигырьләрендә, халык иҗаты өлгеләренә таянып, кеше кичерешен хисси тирәлек, шатлыгы-кайгысы, үпкәләү-сагынуы, тормыш-көнитеш детальләре аша сурәтләүгә ирешәләр. Лириканы «шигырьнең шигърияте» дип, В. Белинский тикмәгә генә атамаган бит.

Ф. Кәрим «Ямьле Дим дулкынлана» (1938), «Кемгә сөйлим серләремне» (1938), «Сүз белән яратам димә...» (1941) кебек моңлы һәм шаян, дәртле һәм сагышлы, салмак һәм омтылышлы лирик шигырьләрендә кеше хисләрен аңларга омтыла, аның йөрәк кичерешләренә тиң сынландыру алымнарын эзли.

«Кояшның алтын нуры» (1939), «Донбасстан узганда» (1939), «Көзге сонетлар» (1939), «Өмет» (1940) кебек әсәрләрендә Ш. Маннурның лирик герое тормыш ямен, табигать матурлыгын аңлый белүче нечкә хисле шәхес буларак ачыла.

Таңда күзен ачкан гөлчәчәкнең
Искиткеч саф алсу йөзендә
Елмаюын күреп яшь баланың,
Чиксез шатлык табам үземдә.

(«Кояшның алтын нуры»)

Ә. Фәйзи «Алмаларның якты кызыллыгы» (1937), «Көймә җыры» (1938), «Кыр казлары» (1940) шикелле нәфис эшләнгән, гүзәл лирик шигырьләрендә кеше белән табигать арасында якынлык эзли, кешегә хас сыйфатларны тирәлеккә күчерә.

30 нчы елларда Х. Туфан төрле юнәлешләрдә эзләнүләр алып бара. Бериш шигырьләрендә ул мәңгелек хакыйкатьләр, яшәеш фәлсәфәсе турында уйлана («Очрашырбыз әле», 1940), кеше белән тарих арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне аңларга омтыла («Узып барышлый», 1939; «Күмелгән эзләр истәлеге», 1939; «Ташкент багларында», 1939), татар поэзиясен киләчәккә тирән ышаныч белән сугарылган шигырьләргә баета.

Кешелек җәмгыятенең тарихи барышын, явызлык белән изгелек, торгынлык белән хәрәкәт арасындагы мәңгелек

көрәшне тарихи шәхес язмышлары аша сурәтләгән «Ант» (1935) поэмасы өчен Х. Туфан формализмда, идеализм фәлсәфәсе алдында баш июдә гаепләнде. Чынлыкта бу поэма 30 нчы елларның иң камил әсәрләреннән берсе иде.

Ә. Фәйзи «Флейталар» (1933), Ф. Кәрим «Тавышлы таң» (1933), Н. Баян «Яңгырлы төн» (1933), С. Баттал «Мөсәллим» (1934), М. Җәлил «Хат ташучы» (1938), С. Хәким «Пар ат» (1939), «Шагыйрьнең балачагы» (1940) кебек поэмаларында чынбарлык үсешенә, кешенең олы күңеленә, андагы рухи киеренкелеккә тиң сурәтлелек чараларын эзлиләр.

Бер үк шагыйрь иҗатында да поэманың мөмкинлекләрен, барыр юлларын киңәйтү юнәлешендә тәҗрибәләр ясала. Әйтик, М. Җәлилнең «Директор һәм Кояш» поэмасы шартлы алымнарга, символларга таянып язылган. Кешегә хас билге, сыйфатларны кояшка күчереп, автор бер совхоз тормышын үзенчәлекле итеп күз алдына бастыруга ирешә.

Биби Кояш торды йокысыннан,
Ефәк болытларга өртелеп,
Һәм, үрелеп күксел таулар аша,
Җиргә сузды озын керфеген.

Бәяне директорга да, ялкау Кәрим белән уңган кыз Җәмиләгә дә Биби Кояш бирә.

«Хат ташучы» — сугыш алдыннан иҗат ителгән, татар кешесенең күңел көрлеген эченә алган иң уңышлы поэмаларның берсе. Биредә Көнчыгыш әдәбияты казанышлары белән татар халык җырларының моңсу һәм дәртле көче кушылып китә.

Шул ук вакытта ул — заманча эчтәлекле әсәр. Алдынгы, эзләнүчән, яңага омтылучан Фәйрүзә белән хат ташучы Тимербулат арасындагы мәхәббәт үзара аңлашылмаучанлыкка нигезләнгән вакыйгага үрелеп үсә. Халыкчан, нәфис матурлыкны шагыйрь тыгыз вакыйгалар белән бизи. Поэма — лирик эпосның ачык үрнәге.

Шигъри жанрларның бу чордагы үсеше хакында сүз йөрткәндә, татар поэзиясендә поэманың гаять бай тарихы булуны да истән чыгармаска, борынгы язма истәлекләребезнең берсе «Кыйссаи Йосыф»ның поэма жанры өчен үрнәк икәнлеген онытмаска кирәк. Соңгы дәверләрдәге татар поэмасы, Көнчыгыш әдәбиятлары белән бәйләнешен югалтмыйча, рус һәм Европа әдәби үзгәлекләрен дә үзенә сеңдерә. Ике башлан-

гычның бергә үрелүе Ә. Фәйзинең «Флейталар» исемле лирик-публицистик поэмасында ачык күренсә, фәлсәфи башлангыч Х. Туфанның «Ант» поэмасында үзәккә алына.

30 нчы елларда эпик поэзия үсешендә кайбер каршылыклар да килеп чыкты. Бер төркем шагыйрьләр иҗат иткән «Бөек Октябрь җыры» (1936) уңышсыз тәҗрибә булды. М. Җәлилнең «Джим» (1935), Ә. Исхакның «Геройның үлеме» (1938) кебек чит ил материалына таянып язылган әсәрләр, колхоз тормышын аллы-гөлле төсләрдә генә тасвирлаган күләмле поэмаларның күбесе чор истәлеге генә булып калды.

Шул рәвешле, 30 нчы еллар әдәбиятында сыйфат үсеше күбрәк эчке омтылыш, эзләнү төсендә бара. Әйтик, 20 нче еллар башы, Ватан сугышы чоры, 60 нчы еллардагы кебек күзгә бәрелеп торган шартлаулы сикерешләр ясалмый. Шул ук вакытта сугыш алды елларында да әдәбият бер урында тукталып калмый, көчен, куәтен, егәрен арттыра барып, чор үзенчәлекләрен язма-басма сүздә калдыру рухы белән яши. Тормыш һәм кеше, табигать һәм тарих, инкыйлаб һәм шәхес язмышы турында уйлану, фикер йөртү, нәтиҗә ясау рәвешендә шактый әсәрләр языла. Тышкы рәвеш белән мавыгу тәҗрибәләре артта калып, сүзнең беренчел мәгънәсенә, эчке егәренә таяну алга чыга.

Киеренке көрәш, эзләнүләр һәм югалтулар аша 30 нчы еллар сүз сәнгатен дәһшәтле 1941—1945 еллардагы бөек көрәш өчен әзерләде.

Сораулар һәм биремнәр

1. 30 нчы елларда илдә барган иҗтимагый-сәяси хәлләргә бәя бирегез. Аларның әдәбият үсешенә йогынтысын аңлатыгыз.

2. Сталин репрессиясенә эләккән татар әдипләренең исемлеген булдырыгыз.

3. Татар әдәбиятының 30 нчы елларда сакланып, яшәп калуы, үсешенең нигезләрен аңлатыгыз.

4. Нинди әсәрләрдә тарихи һәм гражданнар сугышы тематикасы алга чыга?

5. Әхлак, гаилә тормышына багышланган әсәрләрнең уңышын нәрсә белән аңлатасыз?

6. Поэзиядә нинди жанрлар алга чыга? Иң уңышлы поэмаларны, халык җырлары булып киткән әсәрләрне атагыз.

7. 30 нчы елларга әдәбият тарихында нинди урын бирәсез? Гомуми бәягез нинди?

С о ц и а л и с т и к р е а л и з м. Язучыларның Бөтенсоюз съездында (1934 ел), совет әдәбиятының төп иҗат методы буларак, социалистик реализм рәсми рәвештә кабул ителә. Аңа беренче билгеләмәләр бирелә.

Шуннан соң дистәләрчә еллар дәвамында социалистик реализм әдәбият белеменең олы казанышы, сүз сәнгатенең маягы итеп бәяләнде. Аңа багышлап олы-олы хезмәтләр язылды, күп фәнни конференцияләр уздырылды, иҗат методының асылын, мәйданын, чикләрен билгеләргә омтылышлар ясалды.

Хәзер бу төшенчә кискен тәнкыйтьләнә, фаш ителә яисә бөтенләй булмаган кебек читләтеп яки атлап үтелә. Социалистик реализм — марксист галимнәр башында туган бер уйдырма, рәшә генә ул дип санаучылар да бар. Ләкин андый карашлар балаларча беркатлылыктан башка нәрсә түгел. Телибезме, теләмибезме, совет әдәбиятының зур өлеше шул методның кануннарына, таләпләренә таянып иҗат ителгән. Ул — безнең тарихи үткәнебез, XX гасыр әдәбиятының бер үзенчәлеге. Әдәбиятның киләчәге өчен үткәнгә дөрес һәм анык бәя бирү кирәк.

Бөтен совет әдәбиятының иҗат юлы бер һәм уртак булырга тиеш, дигән карар язучылар берлегенә өстән көчләп тагылды. Әдәбият төгәллекле һәм катгый кысаларга кертелде. Иҗатларын 1917 ел борылышына чаклы башлаган язучылар һәм Совет хакимияте алга сөргән сәясәтне хупламаган әсәрләр яңа методның тышында калдырылдылар. Социалистик реализм, әдәбиятны тар кысага салып, аны төп үзенчәлегеннән — шартлылыктан, төрлелектән, эзләнүләр алып барудан мәхрүм итте. Менә шуннан инде матбугатны ике тамчы су кебек бер-берсенә охшаган, соры һәм төссез әсәрләр били башлады. Бу нәрсә бигрәк тә шигърият дөньясында ачык сизелде.

Социалистик реализм тарафдарлары, аның асылын гадиләштерергә тырышучы тәнкыйтьчеләр «әдәбият тормышның күчермәсе, турыдан-туры сыны булырга тиеш» дип раслауга чаклы барып җиттеләр. Бу караш, бер яктан, сүз сәнгатен җир сөрүне, станок гөрләвен, башак сугуны, кибән куюны тәфсилле сурәтләүгә генә хезмәт иттерүгә, көрәк, балта, сука, тимер-томыр, чүкеч кебек эш коралларын әдәби геройлар дәрәҗәсенә күтәрүгә алып килсә, икенче яктан, хыял көченә, кинаяле сөйләмгә, юморга, хәтта киңәйтелгән метафорага бернинди урын калдырмады. (Әйтик, шартлылыкка корылган «Ант» поэмасының Хәсән Туфанны хәтта төрмәгә һәм сөргенгә озатуга нигез булуы — шуның бер дәлиле.)

Әдәбиятта жанр төрлелеге ярлылана, сәнгатьнең башка төрләре белән аралашу, алар ирешкән казанышларны файдалану юкка чыга бара. Бу киртәне бик сәләтле сүз осталары гына атлап чыга яки әйләнеп үтә алды. Әмма һәр тайпылыш, читкә китү бик кыйммәткә төшә. Рус әдәбиятында, мәсәлән, А. Платонов, М. Булгаков, М. Зощенко, А. Ахматова язмышлары — шуның мисалы.

Бер хата, юл биргәч, икенчесен тудыра. Әдәбият социалистик төзелеш темпларының көзгесе, турыдан-туры күчермәсе икән, ул хакта шунда тир түгүче, станок артында басып торучы, кырда иген үстерүче кеше генә дөрес һәм нәкъ булганынча яза ала дигән фикер алга сөрелә. Элеккеге мулла малае, ышанычсыз зыялы, череп таркалган дошман морза баласы яңа чынбарлыкны аңлый да, сурәтли дә алмаячак, янәсе. Менә шундый фикерләргә таянып, әдәбиятка хезмәт алдынгыларын, ударникларны чакыру башлана. Шулай барганда, билгеле, язучы һөнәре мөстәкыйль тармак, иҗат эше булудан туктый. Әдәбият планлы хуҗалык төсмерен ала башлый.

Шуның өстенә язучыга үрнәк-өлге алырлык, бернинди кимчелексез уңай персонаж — коммунист образын сурәтләү, һәр вакыйгага сыйнфый күзлектән карап кына бәя бирү шарты куела. Матурлык хисе тәрбияләү, ләззәт бирү, уйлату, фикер уяту, яратырга өйрәтү кебек мәңгелек сыйфатларын яңа кеше тәрбияләү, социалистик тормыш төзү юлына чыккан ярлы-ябагайны, хәерче затны үстереп, күпертеп сурәтләү, дошман эзләү, әләк, шикаять язу бурычлары алыштыра.

Бу таләпләрнең нигезен илдә Сталин урнаштырган режимга җайлашу, шуның мәнфәгатьләрен генә үтәү бурычы тәшкил итте. Гадәти әдәби шаярулар, ялгышу-эзләнүләр нигезендә тумады социалистик реализм. Ул рәсми сәясәт җимеше булды.

Коммунистлар идеологиясен кабул итмәгән, мөкиббән китеп мактамаган язучыларга һәртөрле ярлыклар тагыла. Гаяз Исхакый халык дошманы дип игълан ителә. Соңрак аның янәшәсенә Совет хакимиятенә турылыклы булып та репрессиягә эләккән язучылар өстәлә. Фатих Әмирхан публицистикасына, Галимҗан Ибраһимов белән Мәҗит Гафуриның 1921 ел ачлыгына реалистик бәя биргән әсәрләренә 90 нчы еллар башына чаклы матбугатта урын булмады. Әсәренә «совет әдәбиятының төп методына җавап бирми» дигән бәяне алу язучы өчен фаҗига, олы кайгы иде. Ягъни социалистик реализм ирекле сулауга, үзенчә уйлап иҗат итүгә каршы

хакимият тарафыннан уйлап табылган һәм көчләп гамәлгә кертелгән бер тәгълимат иде.

Фикер туу мөмкин: социалистик реализм язучыларга өстән тагылып, үзәктән индерелгән, таләпләре катгый һәм кырыс булгач, совет әдәбияты бөтенләй корырга, үләргә яисә укып булмаслык соры, ямьсез, тәмсез бер күренеш булырга тиеш иде кебек. Әмма татар әдәбияты үсеше мисалында да бернәрсәне ачык күрәбез: ул үсә, яңара, хәтта иң авыр 30 нчы елларда да үлмәс әсәрләр тудыра. Бу хәлнең сәбәпләре нинди соң?

Бердән, социалистик реализмның тормышны революцион үсештә, хәрәкәттә сурәтләргә, тарихи үткәнне иңләргә, кешене яңа әхлак рухында тәрбияләргә тиеш дип, язучылар съездында кабул ителгән билгеләмәләрен акыл белән эшкә җиккәндә, барыбер шактый иркен холыклы әсәрләр тудыру мөмкинлеге кала.

Икенчедән, совет режимы хезмәтчеләре иҗат методына куелган таләпләрнең һәр әсәргә нисбәтән үтәлешен аршинга һәм бизмәнгә салып үлчәп, санап утыра алмыйлар. Иң катгый таләп шул: идеологик, сәяси тайпылыш булмасын, советлар илендә яшәгән халыкның дөньяда иң бәхетле, ирекле булуы шик астына алынмасын, милләтчелек баш калкытмасын!

Хыялга бай, сәләтле язучылар әдәбиятка куелган бу кагыйдәләрне үзләренчә аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алдылар. Әйтик, 30 нчы еллар ахырында татар поэзиясендә пейзаж һәм мәхәббәт лирикасы чәчәк ата, халыклашкан җыр, сонет жанрлары мөстәкыйльлеккә ирешә. Шагыйрьнең моңсу шатлыгын, рухи гаҗәпсенүен, йөрәк тайпылышын бирүгә иң кулай булган бу төр шигъриятькә идеологик таләпләр куюы, социалистик реализмның теге яки бу шарты үтәлмәгән дип бәйләнүе кыен шул. Уңышлы үрнәкләрне Х. Туфан, Ә. Фәйзи, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, Ә. Ерикәй, С. Батталлар иҗатыннан күпләп табып булыр иде.

Бу юлда үзенең шартлылыгы, психологик янәшәлекләре, бай һәм җанлы теле белән халык авыз иҗаты язучылар өчен зур таяныч булды, социалистик реализмның шырпыларын әйләнеп үтәргә мөмкинлек бирде.

Безнең әдәбиятта ерак тарих темасына ешрак мөрәҗәгать итүне производство алдынгыларын, җансыз саннарны мактаудан, гражданнар сугышы чирүе батырлыгына сокланудан качуның бер алымы дип бәяләргә мөмкин. М. Галәү,

М. Җәлил, Н. Исәнбәтләр, ерак тарихка юл салып, халыкның үткәнен аңларга тырышалар, шунда милли яшәешнең чыганакларын табалар.

Шулхәтлесе дә бар: милли республикаларда үз әдәбиятларында социалистик реализмның «чисталыгы» өчен көрәш ифрат кискен төс ала. Мәхмүт Галәү романнарын Мәскәү рус телендә чыгара, ә Казанда аларны укучыга тәкъдим итәргә куркалар, язучыны һәртөрле «изм»нарда гаеплиләр һәм ахыр чиктә физик юкка чыгаруга ярдәм итәләр, шуңа җирлек әзерлиләр.

Социалистик реализмны артык тар, вульгарлаштырып кабул итүгә каршы фикерләр дә ишетелеп-ишетелеп китә. Аның чикләрен киңәйтергә, тар, догматик аңлаудан котылырга омтылышлар ясала. 1917 ел борылышыннан соңгы әдәбияттагы төрле-төрле агымнарны күчеш чоры әдәбияты дип атап, яңа методның башка юнәлешләр белән мөнәсәбәтен иркенрәк тәфсилләүгә омтылышлар көчәя. Стиль юнәлешләренең төрлелеге, яңа алымның романтик һәм реалистик канатлары кебек төшенчәләр туа.

Француз галиме Роже Гароди, совет әдәбиятының методын ярлары тәгаен күренмәгән, колачы иксез-чиксезгә җәелгән реализм дип атап, социалистик реализмны үлемнән коткарырга омтылыш ясап карады. Янәсе, бу иҗат методы үзен ниндидер билгеләмәләр, шартлылыклар белән чикләми, ул — иркле, иркен, сыйдырышлы, күпкырлы һәм үсештәге тәгълимат. Совет әдәбиятчылары, аның изге ниятен аңлап бетермичә, философ галимне ревизионизмда гаепләргә ашыктылар.

Ләкин социалистик реализмны берничек тә коткарып булмый иде инде. Ул үзен тудырган, аңа хезмәт иткән хакимият белән бергә тарих киштәсенә кереп ятарга тиеш булды.

Сталин диктатурасы дәверендә аерым алымнарга ябышып яту, стильләр төрлелеген инкяр итү, сурәтлелек чаралары иркенлеген реакцион модернизм галәмәте дип карау социалистик реализмны үле бер төшенчәгә әйләндерде. Аның кагыйдәләрен үтәүне мәҗбүриләштерү, соңгы чиккәчә җиткерү шул алымны үз-үзенә пародия сыманрак әсәрләр тудыруга чаклы китереп куя. Ленинга, Сталинга, партиягә багышланган күп санлы җырлар, шул кешелексез идарәне аклаган, мактаган әсәрләр, сугыштан соңгы матбугатның «конфликтсызлык» теориясенә җайлашып язылган ялтыравык әдәбият — шуның ачык мисалы. Ә чор тәнкыйте шул чиле-пешле язмаларны

күккә чөйде, мәдхия яудырды. Бу төр әсәрләрнең күбесе хәзер замана чүплегендә калды.

Бәхеткә, 30—80 нче еллар әдәбияты иҗат методының тар кысасына гына сыймады. Намуслы, әхлаклы һәм табигый сәләткә ия язучылар, катгый кануннарны әйләнеп үтеп, кеше рухының яңа матурлыкларын ачуны дәвам иттеләр.

Шул рәвешле, бездә социалистик реализм әдәбияты бар, һәм ул — нинди генә, ничек кенә булмасын, безнең мирасыбыз. Аның таләпләренә нигезләнеп язылган әсәрләр арасында гүзәл проза, поэзия, драма үрнәкләре аз түгел. Көнбатышның элек тыелган, хәзер дөньяны тутырган натуралистик, порнографик әсәрләреннән гарык булгач, укучы әлеге әдәбиятның да кадерен белә, күрә башлар, аларның ихласлы, матур үрнәкләренә әйләнеп кайтыр әле.

Татар әдәбияты методның тар үлчәмнәренә генә сыешып бетми. Социалистик реализм әдәбияты белән янәшәдә үк башкачарак сулаган сүз сәнгате дә яшәде, үсте һәм тарихи сынамышта җиңеп чыкты.

Үткәнне яңадан бәяләү — табигый халәт. Әдәбият — дәвамлылык ул. Аның элек яулаган байлыкларын яңача бәяләү, аңлау, күздән кичерү менә шул дәвамлылыкны, көчемлелекне тәэмин итә.

Әдәбият, тормышның үзе төсле үк, бай һәм төрле булуы белән кадерле. Аның көче, кыйммәте шунда.

Сораулар һәм биремнәр

1. Иҗат методлары турындагы мәгълүматыгызны искә төшерегез.

2. Социалистик реализм методына мөнәсәбәтегезне ачыклагыз.

3. Хәзерге чор әдәбиятында нинди иҗат методы өстенлек итә? Үзара фикер алышу, бәхәс рәвешендә шул хакта сөйләшү оештырыгыз.

Нәкый Исәнбәт
(1899—1992)

Иҗатының күптармаклы булуы белән дә, сәнгатьчә казанышларга байлыгы ягыннан да, озак һәм нәтиҗәле яшәве белән дә Нәкый Исәнбәт татар язучылары арасында аерым бер урын били. Драматург һәм шагыйрь, балалар язучысы һәм либреттолар авторы, фольклорчы һәм телче галим, археограф[1] һәм этнограф буларак, ул гаять бай мирас калдырды. Татар әдәбиятына һәм сәнгатенә керткән мөһим өлеше өчен аңа «Татарстанның халык язучысы» дигән олы исем бирелде.

Озын-озак гомер юлы

Нәкый Сираҗетдин улы Закиров (Исәнбәт) 1900 елның 10 гыйнварында (иске стиль белән 1899 елның 29 декабрендә) Башкортстандагы Малаяз авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башта үз авылларында, аннары Уфада «Хәсәния», соңыннан Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә 1917 елга кадәр укый. Инкыйлаблар чорында педагогия курсларын тәмамлый һәм 1920 елгача туган якларындагы Атау, Тазтүбә, Үрге Кыйгы кебек авылларда татар теле һәм әдәбияты укыта. Уфа халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетында укып белемен арттыра. Мәсәгут педагогия курсларында, Уфадагы төрле уку йортларында (мәсәлән, театр училищесында) эшли. 1929 елдан алып Н. Исәнбәт Казанда яши, сәнгать техникумында, химия-технология институтында,

[1] *Археограф* — иске кулъязмалар һәм китаплар җыйнаучы, аларны өйрәнүче белгеч.

кооператив техникумында укыта. 30 нчы елларда көчәйгән алдынгы кешеләрне эзәрлекләүләр җиле аны да бөтереп ала. Ул «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында эшче була, аннары Казаннан ук китеп бара: Әтнәдә мәктәпләр буенча методик кабинет мөдире булып эшли һ.б. 1940 елдан Н. Исәнбәт тулысынча иҗат эшенә бирелә, ягъни профессиональ язучы булып китә.

Йөрәге тибүдән туктаганчы Нәкый Исәнбәт күптармаклы язучылык һәм фәнни эшчәнлеген дәвам итте.

Нәкый Исәнбәт, мәдрәсәдә укыганда ук, шәриктәшләре арасында шигырьләр чыгаруы белән таныла, 15 яшеннән исә язганнарын матбугатта бастыра башлый. Менә аның 12 яшендә язган бер шигыреннән юллар:

Байлар сата, байлар ашый,
Бу малларны эшче ясый,
Арып кайта аксый-аксый,—
Шул кайната каннарымны!
Тагын торып эшкә китә,
Бер ашарлык акча тота,
Акча тагын байга китә,—
Шул кайната каннарымны!

(1912 ел, апрель)

Яшь автор башта күбрәк шигырьләр яза. Аларда кызыл җеп булып бер фикер уза: хезмәтне олылау, аны дөньяның терәге итеп, кешене кеше итә торган нәрсә итеп карау. Бу фикер беркадәр соңрак язылган «Коммуна тимерлегендә» исемле әсәрендә бигрәк тә ачык яңгырый:

Эш кенә тик дөньяларның шаһлыгы,
Эш кенә тик хөрриятнең шатлыгы.
Эш кенә безне богаудан коткара,
Эш кенә тик бар канунны актара...

(1920 ел)

Заманында бу шигырь авторына шөһрәт китерә, аны дәреслекләргә кертәләр, ул кичәләрдә һәм концертларда еш яңгырый. 1925 елда Н. Исәнбәтнең «Чаң» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Моннан соң да язучы шигъриятькә тугрылык саклый, поэмалар, күп санлы лирик парчалар иҗат итә. Аларда гуманистик фикерләрен әйтә, сафлыкны һәм мәхәббәтне зурлый, тормышка һәм табигатькә

соклана. Аерым лирик шигырьләре көйгә салына, халыкның үз җырына әйләнеп китә. Шундыйлардан «Син сазыңны уйнадың», «Илкәем», «Бормалы су», «Уракчы кыз» кебек җырларны атарга мөмкин.

Шагыйрьлек сәләте Н. Исәнбәтнең тезмә юлларда язылган сәхнә әсәрләрендә дә, аерым алганда, «Идегәй» трагедиясендә, «Түләк һәм Сусылу» исемле либреттосында ачык чагыла. Бу соңгысы буенча танылган композитор Нәҗип Җиһанов бик үзенчәлекле опера иҗат итте.

Н. Исәнбәтнең балалар өчен махсус язганнары да үзенә бер сәнгать дөньясын тәшкил итә. Аның «Куян маҗаралары», «Мырауҗан агай хәйләсе», «Ни өчен ни булган яки утыз ялган» дигән h.б. китаплары кечкенә укучылар арасында киң билгеле. Монда тагын язучының балалар фольклоры буенча төзеп чыгарган китапларын да искә алырга кирәк. Кыскасы, ул балалар өчен 100 гә якын әсәрләр иҗат иткән.

Н. Исәнбәтнең иҗат эшчәнлегендә башка халыклар әдәбиятларының иң яхшы әсәрләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгару эше дә лаеклы урын тота. Мондыйлардан А. С. Пушкинның «Полтава», «Бакчасарай фонтаны», «Таш кунак» әсәрләрен, А. С. Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен, В. Шекспирның «Гамлет», «Король Лир» трагедияләрен h.б. күрсәтергә була. Авторның утызга якын фольклор һәм әдәбият буенча гыйльми хезмәт-мәкаләләре, иллеләп әдәби-тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре басылып чыкты.

Н. Исәнбәт гомере буе халык җәүһәрләрен — мәкаль һәм әйтемнәрне, мәзәк һәм табышмакларны, җыр һәм такмазаларны бөртекләп җыеп килә. 20 нче елларда, аркасына биштәр асып, авылдан авылга йөреп башлаган бу эшен галим-язучы соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Фольклор әсәрләре, галим кулына килеп кергәнче, әле эшкәртелмәгән асылташ кыяфәтендә булалар. Исәнбәт эшкәрткәч, алар, күпьяклы кырлары ачылып, әдәбият-сәнгатьнең чын энҗе бөртекләре рәвешенә керәләр. Өч томнан торган шундый капиталь хезмәт — «Татар халык мәкальләре» җыентыгы өчен Н. Исәнбәт Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Ул шулай ук табышмакларны татар фәнендә беренче буларак күп итеп җыеп, фәнни эшкәртеп, бастырып чыгарды.

Драматургиясе

Шуларның һәммәсе өстенә Нәкый Исәнбәт — драматург. 15 яшендә үк ул «Әмирхан хәзрәт» исемле комедия яза. 20 нче елларда язучы сәхнә әдәбияты белән ныклап шөгыльләнә башлый. Уфа һәм Казан сәхнәләрендә зур уңыш казанган «Һиҗрәт»[1] (1923) комедиясеннән соң аның исеме татар театры афишаларында еш күренә. Н. Исәнбәт драматургиясе 30 дан артык сәхнә әсәрләреннән тора, һәм аның үзенә генә хас сыйфат үзенчәлекләре бар.

Н. Исәнбәт — халкыбыз күңеленә ачкыч тапкан язучы. Драматург халык язмышын зур итеп күрә һәм күрсәтә, татарның үсеш тарихындагы сәхифәләрне оста итеп драматик вакыйгаларга күчерә белә. Әгәр дә аның трагедия, драма һәм комедияләрен тематик яктан карап чыксаң, халык тарихының сәнгатьле картинасы күз алдына килеп баса. «Хуҗа Насретдин» комедиясендә, мәсәлән, Болгар чорларында бабаларыбызның чит ил басып алучыларына каршы да, үзләренең булдыксыз һәм ахмак түрәләре белән дә көрәше гәүдәләнә. Бу көрәштә халык коралга һәм тупас көчкә каршы нечкә акылны, үткерлекне, зирәклекне куя һәм җиңеп чыга. Менә җитмеш дистә елдан артык инде комедия сәхнәдән төшми уйнала. Аның мондый уңышын, беренчедән, язучының тарихны, хезмәт иясенең теләк-омтылышларын, фольклорын һәм гади көнкүрешен, ягъни халыкның матди һәм рухи мәдәниятен тирән белеп, табигый төстә чагылдыру осталыгы билгели. Халыкның иреккә сусаганлыгын, әллә кайсы кара заманнарда да азатлык хыялы белән яшәвен «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Хәйләкәр Дәлилә», «Спартак», «Миркәй белән Айсылу» һ.б. әсәрләрдә дә күрергә мөмкин. Әгәр дә борынгырак чорларны чагылдырган мондый пьесаларда автор халык иҗаты әсәрләренә һәм легендалар каһарманнарына таянса, беренче чыганаклар итеп шуларны алса, инде якындагырак вакыйгаларны сурәтләгәндә иҗатына тарихи шәхесләрне дә еш кертә. «Гөлҗамал» драмасында туган халкын наданлыктан алып чыгу өчен үзен аямаган беренче татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның якты образы үзәктә тора. «Мулланур Вахитов» героик драмасында эшче һәм крестьянга сыйнфый азатлык яулап алу юлында тормышын корбан

---

[1] *Һиҗрәт* — күчеп китү.

кылган герой гәүдәләнә. Бөек Ватан сугышының авыр елларын безнең халык намус белән узды, фронтларда һәм тылда батырлык һәм эштә фидакярлек үрнәкләре күрсәтте. Болар «Муса Җәлил», «Мәрьям», «Мәрди белән Нәфисә» исемле сәхнә әсәрләрендә чагылды. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең фашистлар оясындагы тиңдәшсез тартышы җанлы күренешләрдә тасвирлана. Сугыштан соңгы тыныч тормышка автор «Рәйхан», «Гүзәл» кебек пьесаларын багышлады. Күрәбез: халкыбызның тарихи үсеш баскычларындагы әһәмиятле вакыйгалар Н. Исәнбәт драматургиясендә урын алган һәм чагылыш тапкан.

Бу пьесалар халык авыз иҗатында кешенең элек-электән данланып килгән иң гүзәл сыйфатлары — туган илне ярату, азатлыкка омтылу, фидакярлек, туганлык һәм дуслык, шәхесне хөрмәт итү, мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Алардагы геройлар да, халык күңелендә яралып үскән иң матур кешелек билгеләрен һәм тойгыларын үзенә туплаган каһарманнар булып, җанлы һәм кабатланмас кыяфәттә күзалланалар.

Алда әйтелгәннәрдән тагын да бер үзенчәлек килеп чыга. Ул — Н. Исәнбәт драматургиясенең халыкчан нигезләрендә. 30 нчы елларда ук күтәрелгән, М. Горький тарафыннан әйтелгән «Әдәбиятта халык иҗаты белән бәйләнешне көчәйтергә!» дигән чакыруны Н. Исәнбәт хуплап алды һәм зур уңышларга иреште.

Халыкчан эре характер сәхнәдә бара торган вакыйгаларның үзәгендә кайный, аларны теге яки бу якка хәл итә. Н. Исәнбәт драматургиясе шундый образларга ия. Аларның төп сыйфатлары хезмәт иясен яратуга, ватанпәрвәрлеккә барып тоташа. Шуңа күрә дә Хуҗа Насретдин һәм Түләк тә, Җирән чичән, Әбүгалисина һәм Спартак та үзләренә генә хас холык сыйфатларын илне һәм халыкны ярату хисләре ярдәмендә, бәйсезлек һәм ирек өчен көрәштә ачалар. Алар вакыйгалар белән идарә итәләр, вакыйгаларны үзләре тудыралар, Спартак һәм Мулланур Вахитов, Муса Җәлил, Абдулла Алиш һәм Мәрьям кебек, идарә итеп булмастай шартларда, намуслары кушканча яшәп һәм көрәшеп үлә дә беләләр.

Шулай итеп, Н. Исәнбәт драматургиясен, иң әүвәл, халыкчан җирлек, оптимистик идеал, шуңар тугрылык саклап эш йөртүче геройлар, алдынгы карашлы кешеләр билгели. Әмма

бу драматургия тормышта очрый торган кимчелекләргә, кешедәге тискәре якларга да битараф түгел. Анда мондыйларга нәфрәт бөркелә. Сатира һәм көлү мөһим урын били. Язучының беренче пьесаларыннан «Сират» һәм бигрәк тә «Һиҗрәт»тә үк инде гаять үзенчәлекле сатира ярылып ята. Иске җәмгыятьтәге тәртипләрне алыштыру вакыйгаларында драматургның сатира осталыгы торган саен ачыла бара. 20 нче елларның ахырларында иҗат ителгән «Пикуләй Шәрәфи», «Культур Шәңгәрәй», бигрәк тә «Портфель» (сәхнәдә «Портфельле кияү» исеме белән дә уйналды) кебек сатирик комедияләрендә яңа шартларга җайлашырга омтылган мещаннар, кеше исәбенә яшәргә ният иткән авантюрист эшкуарлар һәм бушбугазлар көлкегә алына. Гадел Кутуй, язучының сатирик сәләтенә, гомумән, аның шул еллар иҗатына югары бәя биреп, 1928 елда болай яза: «Хәзерге татар әдәбияты шигъри поэзиягә бай. Сәләтле шагыйрь Нәкый Исәнбәт аңар шактый гүзәл битләр өстәде. Аның «Коммуна тимерлегендә» исемле динамик поэмасы заманның иң яхшы шигыре санала һәм, мөгаен, киләчәктә дә саналыр. Исәнбәт әсәрләре, ничектер, укучының мәхәббәтен тиз яулап алалар, яттан өйрәнеләләр һәм халык җырлары шикелле телдән-телгә күчеп йөриләр.

Исәнбәт тә, Такташ та үз иҗатларын уңышлы рәвештә халык әдәбияты белән бәйлиләр. Исәнбәт соңгы вакытта күбрәк сатирик буларак алга чыкты. Аның «Һиҗрәт» һәм «Культур Шәңгәрәй» пьесалары, «Кисекбаш» дигән зур поэмасы шулай язылган. Ул бик сизгер һәм күзәтүчән, яраксызны тиз күреп ала һәм бөтен материалны шундый канвага утырта ки, язганнарын үлемсез итә».

Мәгълүм булганча, мещанлык һәм тар карашлылык, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәү — һәр җәмгыять шартларында да үзләренә урын алырга тырышкан күренешләр. Алар яңа җирлектә тамыр җибәрергә, икенче рәвеш-кыяфәткә кереп, заманның тышкы төсмерләре белән баерга тырышалар. Шуңа күрә дә аларны фаш итү сәхнә алдында торган бурычларның берсе булып кала. Н. Исәнбәт мещанлыкка каршы, кеше исәбенә яшәргә омтылуга, ваемсызлыкка, намуссызлыкка, хөрәсәнлеккә һ.б. кимчелекләргә каршы көрәш алып бара, сәнгатьчә ачышлар ясый. Баштан ук ачык төс алган фаш итүгә омтылыш сызыгы аның бөтен иҗаты буена

дәвам итә. «Зифа» комедиясе, мәсәлән, 50 нче еллар театрында күренекле вакыйга төсен алды. Образларның җанлы һәм тормышчан булуы, сюжетының төзеклеге һәм кызыклыгы, сурәтләү чараларының байлыгы белән пьеса татар комедиясе тарихында эз калдырды.

Н. Исәнбәтнең иҗат биографиясе — эш һәм хезмәт турында үзе язганнарга тугрылык саклауның мисалы һәм үрнәге. Аның гаять бай һәм күптармаклы әдәби һәм гыйльми мирасы, беренчедән, сарыф ителгән хезмәтенең, куелган көченең күплеге белән сокландыра. Вакытның кадерен шул дәрәҗәдә белүчеләр бик аздыр. Әле 12 яшьлек Нәкый:

Гасыр үтәр, чатанлаган тавык кебек,
Гомер үтәр, су астында балык кебек,
Ун ел үтәр, аучылардан качкан коштай,
Бер ел үтәр, җәя белән аткан уктай...
Тәүлекне әйтә алмам нишләсәм дә,
Аз булыр, яшен яки җил дисәм дә,—

дип язган. Менә шул яшендәй үтә торган тәүлек эченә ул гомере буе мөмкин кадәр күп эш сәгате сыйдыра. Замандашлары әйтүенчә: «70 яшь тулган көнең ничек узды, Нәкый абый?» — дип сорагач, ул: «Мин бүген көнне бәхетле иттем, 16 сәгать эшләдем»,— дип җавап биргән.

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның халык язучысы Н. Исәнбәтнең таланты шундый хезмәттә генә тулы ачыла һәм гаять бай иҗади мирасы менә шундый фидакярлек нәтиҗәсендә генә барлыкка килә алды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Н. Исәнбәт биографиясендәге төп моментларны санап чыгыгыз.

2. Иҗатының күптармаклы булуын мисаллар белән раслагыз.

3. Драматургиясендәге төп әсәрләрне атагыз. Аларның кайсыларын сезнең укыганыгыз бар?

4. Н. Исәнбәт драматургиясендә фольклор нинди урын били?

5. «Зифа» комедиясен өйдә укып килегез. Пьеса кайсы яклары белән сезгә ошады? Андагы кайсы образ кызыклы тоелды, ни өчен? Персонажлар сөйләшендә нинди үзенчәлекләр күрдегез? Болар турында дәрестә фикер алышыгыз. (Бу сораулар буенча кечкенә докладлар әзерләп килергә мөмкин.)

«Идегәй» трагедиясе

(1941)

Нәкый Исәнбәт бу әсәрен 1941 елда, Мәскәүдә булырга тиешле татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтү өчен, махсус яза. Декада Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле булмый кала, ләкин трагедия Казанда уйнала. 1941 елда ул аерым китап булып басыла. Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының 1944 елда Татарстанда идеология эшенең торышына, әдәбиятка һәм сәнгатькә багышланган махсус карарында бу әсәргә «зарарлы» дигән мөһер сугыла, һәм ул куярга да, бастырып чыгаруга да яраксыз табыла. Бары тик илдә үзгәртеп кору дәвере башланып, Татарстан мөстәкыйльлек өчен көрәш юлына чыккач кына әсәр укучыга һәм тамашачыга яңадан кайтарыла.

Трагедия «Идегәй» исемле халык дастанына нигезләнеп язылган. Бу дастан белән сез, укучылар, 8 нче сыйныфта таныштыгыз инде. Игътибар итегез: трагедиядә дастан геройлары белән бергә драматург үзе уйлап чыгарган геройлар да хәрәкәт итә. Ягъни, икенче сүзләр белән әйткәндә, әсәрдәге образлар системасында дастан буенча мәгълүм булган геройлар янында өстәмә персонажлар да бар. Аларны автор әсәрендә уздырган төп фикерен үтемлерәк һәм сәнгатьлерәк итү өчен керткән. Халык авыз иҗатына нигезләнгән, тарихи шәхесләрне сурәтләгән бу әсәрен драматург трагедия жанры кануннары буенча иҗат иткән, һәм ул — татар сәхнә әдәбиятында бу үзенчәлекле жанрның бер үрнәге.

Конфликтка кергән геройлар

«Идегәй» трагедиясе — катлаулы әсәр. Аның катлаулы булуы, иң беренче, жанрына бәйле. Ул драматургия төренең югары формаларыннан берсе булган жанрга карый. Рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский: «Трагедия — драматик поэзиянең[1] иң югары баскычы һәм аның таҗы»,— дигән.

Трагедияне трагедия иткән, ягъни сәнгатьчәлеге ягыннан югары күтәргән яклардан берсе — аның көчле конфликтка

---

[1] «Поэзия» дигән термин астында монда «матур әдәбият» күздә тотыла.

ия булуында. Үзәк геройлар алып барган көрәш кискен, еш кына аяусыз, тәэсирле һәм мавыктыргыч була. Ул еш кына персонажларның үлеме белән, вакыйга фаҗига белән тәмамлана. Шулай булуы табигый да, чөнки үзәк герой (яки геройлар) гаять мөһим мәсьәләне (яки берничә мәсьәләне) хәл итәләр, еш кына үзләре өчен югары булган идеалны раслап үлемгә баралар. Гадәттә, бу идеал кешелекнең гомуми идеалына килеп тоташа, кешелек җәмгыятенең алга омтылышын раслый. Икенче сүзләр белән әйткәндә, трагедиядә гомумкешелек кыйммәтләре раслана, намус, тугрылык, мәрхәмәт, ватанпәрвәрлек, туганлыкның изгелеге кебек сыйфатлар олылана.

Югарыда әйтелгәннәр яссылыгында, әйдәгез, «Идегәй»нең төп конфликтын, шуның белән бәйле үзәк фикерен ачыклыйк.

Көрәш, асылда, Идегәй белән Туктамыш хан, соңрак аның малае Кадыйрбирде арасында бара. Беренче карашка, алар тәхет өчен көрәшәләр кебек. Туктамыш та, аның улы да, хәтта Идегәйнең улы Норадын да, чыннан да, тәхет өчен пычакка пычак киләләр. Ләкин, текәлебрәк карасаң, Идегәй дәүләт төзелеше, аның белән идарә итү тәртипләре, хезмәт иясенең хәлен яхшырту-җиңеләйтү, коллыкны бетерү, гаделсезлекләргә чик кую кебек мөһим мәсьәләләр буенча ханга каршы күтәрелә. Болар әсәр барышында геройның үз авызыннан да, башкалар тарафыннан да кат-кат әйттерелә.

Мәсәлән, башта ук сарай коллары сөйләшүеннән Идегәйнең Кобогыл би исеме астында яшеренеп йөрүен белеп калабыз.

Ә инде Идегәйнең халыкка якынлыгын Болгардан илче булып килгән Янбулат ачыктан-ачык: «Аты юкка ат булган, адашканга юл булган, ялгызга ясак, җәяүлегә таяк булган Идегәй»,— дип әйтеп бирә. Ил карты Килмәт тә аны «күздә тотып торган батырыбыз» дип бәяли.

Идегәйнең төрле уңай белән үзе әйткәннәреннән дә аның тормыш максаты, көрәш мәсләге ачыклана. Гел басып алу, талау турында уйлаган Нугайбигә ул: «Үзең талау өчен түгел, халкыңны таланудан коткару өчен сугышасың син, Нугайби»,— дип әйтә. Үзенең изелгәннәр яклаучысы булуын ассызыклый: «Хурланган, мыскыл ителгән халкым, синең ышанычың мин булдым».

Шулай да Идегәйгә иң тулы бәяләмәне 195 яшьлек җырчы карт Субра бирә. Бу бәяләмәдә дастандагы юллар файдала-

нылган. Ягъни Идегәйдә халык үзе күргән сыйфатлар китерелгән:

Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Ачы сөрән салыр ул,
Алтыннан суккан ак урдаң,
Көмештән суккан ишегең
Бер бәрүдә ачар ул.
Кисмә-кисмә алтының
Кисеп илгә чәчәр ул;
Картайганда аямый,
Сине дә, әй хан, басар ул!
Кол базарың туздырып,
Колдан вәзир куйдырып,
Комга баткан чүлеңне,
Коедан сулар койдырып,
Гөл сәхрасы ясар ул!

Көрәш максаты ачык булса да, Идегәй каршылыклар эчендә яши һәм эш йөртә. Яраннары, дуслары һәм хәтта улы Нурадын да аны һәрвакыт аңлап та бетермиләр. Бигрәк тә Нурадын күп мәшәкатьләр һәм борчулар тудыра. Ахыр чиктә идегәйчеләрнең күчмә халык булган нугайлар белән бәрелеше дә, геройның тәхетне җуюы да, үлеме дә улы аркасында була. Идегәйнең улы белән мөнәсәбәтенең болай катлаулы булуы әдәби образ буларак аны җанландыра, киңәйтә. Чөнки Идегәйдә эчке кичерешләр тудыра, ә баш геройның рухи дөньясын тулы бирү аны тар кысалыктан коткара. Шундый рухи газаплары, кешелекле кичереш-үкенечләре булмаса, Идегәй, батыр сугышчы, акыллы җитәкче генә булып калып, җанлы кеше буларак бер генә яклы чыгар иде. Чөнки җәмгыятьтәге урыныннан, иҗтимагый мәсьәләләр турында борчылуларыннан тыш, һәркемнең үз шәхси тормышы да бар бит әле. Сөекле бердәнбер улы еш кына сәбәпчесе булган бәла-казалар, якты теләк-омтылышына тулысынча ирешә алмыйча, җиңелеп һәлак булуы Идегәйне кабатланмас һәм фаҗигале шәхес итә.

Нурадын да — фаҗигале шәхес. Атасы гәүдәсе өстендә әйткән соңгы сүзләре аның дәһшәтле үкенечен ачып бирә: «Синең адашкан, бәхетсез углың!» — ди ул. Ата белән улы соңга кадәр бер-берсенә теләктәш була алмыйлар. Монда төп рольне, күрәсең, тәрбия уйный торгандыр. Яшьтән кыерсытылып үскән, кайгы-хәсрәтне, үксез-ятим булуны мул татыган, гади халык арасыннан чыккан Идегәй — үзенә бертөрле кеше. Нугайлар арасында кадер-хөрмәттә үскән (алар егетне ханнары итеп таныйлар!), батыр һәм шөһрәтле атаның бердәнбер улы булган Нурадын — бөтенләй башка. Сабырлык, аңларга теләү аңа ят, дуамаллык, тормыш сабагы җитмәү аны бербер артлы хаталар ясарга этәрә. Үзе әйтмешли, адаштыра.

Әтисенең һәрьяклап хаклы булуын ул аңлый, ләкин соңарып аңлый. Тән газапларына түзәрлек чыдам, батыр һәм горур егет сәясәттән читтә, тәхет ыгы-зыгыларыннан тәҗрибәсез булып чыга. Зур көрәшкә әзерлексез булуы аны һәлакәткә китерә.

Идегәй белән көрәштә җиңелгән, тәхетләреннән колак каккан Туктамыш хан белән аның улы Кадыйрбирде дә гомерләрен канлы кылычтан үтеп тәмамлыйлар. Бу яктан алар да — фаҗигале шәхесләр. Әдәби персонаж буларак алар да үзенчәлекле. Рәхимсезлеге, кул астындагыларга, бигрәк тә гади халыкка мөнәсәбәтендә дуамаллыгы белән бергә, Туктамыш менәзенә вакыты белән тәвәккәлсезлек тә хас. Бу җәһәттән аның хатыны Яникә тәвәккәлрәк һәм зирәгрәк. Бигрәк тә Идегәйгә мөнәсәбәттә бу ачык чагыла. Улы Кадыйрбирде дә этисенә караганда тәвәккәлрәк, явызрак һәм кансызрак. Ләкин нинди генә фаҗигале язмышлы кешеләр булмасын, укучы һәм тамашачы аларны тамчы да кызганмый. Дастаннан килә торган халәтләрне сәхнә өчен драматург шулкадәр оста файдаланган ки, бу персонажлар да, Яникә һәм ханның олы кызы Ханәкә дә нәфрәт кенә тудыралар. Иң беренче, иҗтимагый гаделсезлек өчен, ягъни хезмәт иясен, түбән катлауны хаксызга рәнҗетергә сәләтле булулары өчен аларны гафу итеп булмый.

Идегәй һәм аның көрәштәшләре исә, иң әүвәл, рәнҗетелгәннәргә, кыерсытылганнарга карата мәрхәмәтле булулары белән якын. Бу образлар шул яктан олылана, укучыда миһербанлылык, рәхимлелек, хезмәт кешесенә хөрмәт, гаделлеккә соклану хисләре тәрбияли. Кыскасы, трагедия социаль гаделсезлеккә каршы юнәлтелгән. Ул туган илне, туган җирне, гади халыкны яратуны алга сөрә.

Әсәрнең образлары төрле-төрле, бай. Күпчелек персонажның үз йөзе бар. Образлар, асылда, икегә бүленгән: Идегәй яклылар һәм хан тәхете яклылар. Фаҗигале хәлләрне барлыкка китерүдә бер төркем аерата хәлиткеч роль уйный. Бу — Норадын һәм Нугайби, алар тирәсенә тупланучылар, Идегәйнең кара язмышына төп сәбәпчеләр.

Хан ягындагылардан киңәшче Җанбай аерылып тора. Икейөзле, гаять мәкерле һәм акыллы-тапкыр кеше. Четерекле хәлләрдән ул шома чыга белә. Карагыз: ничек итеп Норадынны атасына каршы бастыра ул. Субраны чакыртып, Кобогыл бинең серен ачуда, Норадынны Кадыйрбирде кулына тотып бирүдә дә ул тапкыр эш йөртә.

Хан идарәсенең кешелексезлеген күрсәтүдә хезмәт халкы вәкилләреннән Марук, Янбулат, Чулпан, Килмәт, Аңгысын һ.б. төп рольне уйныйлар. Коллар сату, сарай күренешләре әсәрнең иҗтимагый конфликтын көчәйтәләр.

Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендә үзенчәлекләр

Трагедиянең бөтен төзелеше, һәм эре, һәм вак өлешләре (компонентлары) төп фикерне тулы һәм сәнгатьчә үтемле төстә ачуга ярдәм итә. Иң беренче, үсеш-хәрәкәтнең тыгыз булуын әйтергә кирәк. Моңа автор берничә юл белән ирешә. Хәрәкәтнең җанлы булуы тарихи хәлләрнең күрсәтелүеннән, сәхнәдә зур вакыйгаларның бер-бер артлы алышынып торуыннан килә. Идегәй, Аксак Тимер ягына чыгып, Туктамышка каршы сугыша. Җиңелгән Туктамыш хан, сыену урыны эзләп, Литва короле янына китә, озакламый һәлак була. Нугайлары белән бергәләп, Норадын әтисен тәхеттән бәреп төшерә, үз чиратында, алданып, Кадыйрбирде кулына эләгә, җәзага тарый һ.б. Менә бу зур һәм хәлиткеч вакыйгаларны автор трагедия кысаларына сыйдыруда осталык күрсәткән.

Пәрдәләр өлешләргә (сәхнәләргә, күренешләргә) бүленеп, аларның еш алышынуы да хәрәкәтнең җанлы-тыгыз булуын тәэмин итә, һәр сәхнә (күренеш) эчендә бер яки берничә вакыйга булып уза. Беренче пәрдәне генә алыйк. Зиннәтле сарайда ике күренеш була. Идегәй һәм аның улы Норадын озатуында хан кызы Ханәкә Кырымнан кайтып төшә. Кыска гына күренештә күпме мәгълүмат! Ул гына да түгел, Кобогыл би — Идегәй, ягъни качуда йөрүче кара сөяк икән; Норадынның сарайдагы урынын да, аның хисләрен дә, менәзендәге сыйфат-үзенчәлекләрен дә, Идегәйнең Кырымда ханнар нәселенә нинди зарар салганын да, аңа шунда ханның, аның гаиләсенең мөнәсәбәтен дә белеп калабыз. Ханның Идегәйгә тиешеннән артык игътибарлы булуы хакында Туктамыш белән хатыны арасында бәхәс туа, һәм ул икенче күренеш-сәхнәдә хәл дә ителә. Яникә хаклы булып чыга: Туктамыш хан, үзе дә сизмәстән, Идегәй килеп кергәч, аны каршылап, аягүрә баса.

Хан тәртипләренең гаделсезлеккә корылган булуын сарайдагы күренешләрдән соң ук бирелгән коллар базары ассызыклый. Базар — иҗтимагый тигезсезлекнең иң югары чагылышы. Кеше (кем генә булмасын, нинди генә нәселдән чыкмасын) — дөньядагы иң кадерле зат, дип ышанган һәркем

өчен кол сату, кол алу вәхши бер гадәт төсендә кабул ителә. Күңелдә рәнҗү уяна, бу хәлгә нәфрәт уты кабына, ризасызлык кузгала. Мондый тәртипләрне өнәмәгән Идегәй күңелгә тагын да якыная.

Шулай итеп, трагедиядәге хәрәкәтнең көчен һәм җанлылыгын сәхнә-күренешләр еш алышынып тору да билгеләшә. 5 пәрдәдә барлыгы 12 сәхнә күренеше бар. Шуларның 7 се хан сараенда бара. Калган 5 есе халык тормышын һәм сугыш хәрәкәтләрен гәүдәләндерә: коллар базары, бакчада яшерен очрашу, шәһәр янында сугыш мәйданы, күл буендагы сугыш хәрәкәтләрен чагылдырган 2 күренеш. Бу соңгылары — фаҗигалелек ягыннан иң югары нокта: монда Идегәй дә, Норадын да, Кадыйрбирде дә үтереләләр.

Драматик хәрәкәтнең тыгыз, җанлы булуын персонажлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең тиз арада ачыклануы һәм билгеле бер юнәлештә үсеп-үзгәрүе дә китереп чыгара. Мәсәлән, Янбулат образының үсеш сызыгын алып карыйк. Аның беренче күренүе үк үзенчәлекле: Болгар җирендәге 17 авылдан илче булып килгән сукачы егет хан хозурына җәнҗал белән бәреп керә. Аның хан белән сөйләшүеннән геройның кыютапкырлыгы, тәвәккәллеге, иле-көне алдында җаваплылык сизүе һәм туры сүзле булуы күренеп тора. Кыска гына вакытта да ул шул яклары белән игътибарны җәлеп итә. Алга таба аны күз уңында тотарга мәҗбүр буласың. Вакыйгалар эчендә Янбулатның давыллы, кызыклы язмышы, рухи дөньясы, холкы тулы ачыла. Сөйгән кызының коллыкка дучар ителгәнен белгәч, аның гаҗизлеге, теләсә нинди адымга барырга, хәлиткеч эшләр кылырга сәләтле булуы күренә. Әнә ул кәләшен коткару өчен, ростовщик Саррафтан 400 сум бурычка сорый, сорамый... таләп итә. Аны бер айдан 1000 сум итеп кайтарып бирәсе булачагын, аны кайдан табачагын уйлап та карамый. Идегәйнең ярдәм кулы сузуы аны сокландыра да, гаҗәпләндерә дә. Ә инде коткарылып бетә язган кыз коллар сату белән көн күрүче Шәйхемисрый кулына төшәчәк булгач, шашып китеп, ул аны чәнчеп үтерә. Шундыйерткычлыгы өчен аңа Идегәй, хөкем башлыгы буларак, үлем җәзасы билгеләгәч, аңа нәләт укуы белән егет укучы каршында беркадәр үз бәясен төшерә. Чөнки, ни генә булмасын, кеше канын кою гафу ителә торган гамәл түгел. Дөрес, Идегәйнең бу карары күз буяу өчен генә, Янбулатның газаплары кыска гына вакыт эчендә шатлыкка әйләнә, Идегәйгә нәфрәте ышаныч

һәм бирелгәнлек белән алмашынуы күңелне тынычландырып инандыра. Чулпанның Яникә ханча тарафыннан көчләп кияүгә бирелгәнен ишеткәч, егетнең эчке кичерешләре, кызу канлы холкы тагын бер тапкыр раслана. Шулай итеп, Янбулатның шәхси теләкләре һәм мәхәббәте аның азатлык сугышчысы булып үсеп баруы белән үрелеп бирелә, персонажны җанлы итеп, тормышчан характер төсендә сурәтләргә ярдәм итә. Монда драматург яңадан-яңа буяулар таба, ышандырырлык халәтләр тудыра, Янбулатны кат-кат сынаулар алдына куя. Бу сынауларда егет көрәшче буларак чыныга бара, бер-бер артлы Идегәйнең бөеклегенә, максатының изгелегенә инана.

Шулай итеп, бер шәхес язмышы мисалында гына да авторның драматик хәрәкәт тыгызлыгына ничек ирешүен күрергә мөмкин.

Әдәби әсәрдә сәнгатьлелек деталенең мөһим роль уйнавын беләбез. Мондый детальләрне таба белүдә, дастанда булганнарын сәхнә кануннарына буйсындырып файдалануда Н. Исәнбәт шулай ук зур осталык күрсәтә. Аларның сюжет сызыгында хәлиткеч урын тотканнары бар, кечерәкләре бар. Мәсәлән, Идегәй белән Норадынның арасын бозу нияте белән, Җанбай уйлап тапкан хәйлә Ханәкә тарафыннан эшкә ашырыла: кыз, биленә билбау урап, көмәнле булып күренә, моны Идегәйгә сылтый. Идегәй белән аның төп таянычларыннан берсе булган нугайлар арасында низаг куба, төп максатка зарар килә, тарих фаҗига белән тәмамлана.

Аерым детальләр кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклау, тәэсирлерәк итеп ачу өчен, икенчеләре персонаж менәзенең үзенчәлекләрен күрсәтү өчен хезмәт итәләр. Мисалларга мөрәҗәгать итик. Алда андый бер деталь турында сүз булды инде. Ханча, иренең итәген энә белән тәхеткә беркетеп куеп, аңа сабак бирә.

Норадынның буйсынмас һәм башбаштаграк булуы, сарай тәртипләрен белмәве һәм белгәндә дә аларга буйсынырга теләмәве аның күчмә халыклар арасында тәрбияләнгән булуыннан да килә. Әнә ул ялгышлык белән гаять кыйммәтле вазаны вата. Гүзәл сәнгать әйберен! Ләкин моңа аның исе дә китми. Ялгышына үкенә дә белми. Деталь егетнең менәзен ача башлау өчен бик кулай.

Ләкин шул ук вакытта Норадын — батыр һәм оста сугышчы. Туктамышны җиңеп, башын нәкъ менә ул кисеп алып кайта. Даладагы иркен тормышка өйрәнгән, буйсынмас һәм

башбаштаграк нугай халкы аны үзенең ханы дип таный. Норадын — түзем һәм горур ир дә. Моны аның кадаклар өстеннән яланаяк басып үтеп, пычаклы тәхеткә утырганда йөзен дә чытмавы күрсәтә.

Башка күп детальләрдә бу чорларда яшәгән борынгы бабаларыбызның гореф-гадәтләре, киенүләре, сөйләшү үзенчәлекләре, этнографик бизәкләре һ.б. ачыла.

Трагедиянең үзенчәлекләреннән берсе итеп тагын да персонажларның сөйләм, сүзләр куллану рәвешен, әүвәлге сүз тәгъбирләре-гыйбарәләрнең мул кулланылуын күрсәтергә кирәк. Аларның нигезе дастанга барып тоташа. Дастандагы шигъри юлларны турыдан-туры файдалану белән бергә, драматург, күтәренке стиль тудыру өчен, гади сөйләмгә шигъри элементлар, аерата рифмалаштыру китереп кертә, мәкаль-әйтемнәрне иркен куллана. Бер генә мисал алыйк. Хатыны Яникә белән бәхәсләшкәндә, Туктамыш һаваланып болай ди: «Көтүчедән би булган, түрәм булган Кобогыл өрәге миндәй була алмас! Чыңгыздан булган затыма минем колым тиңә алмас! Ул торганда, мин тормам! Ул торганда, мин торсам, Туктамыш хан мин булмам!»

«Яу юк димә — яр астында, бүре юк димә — бүрек астында», «арыслан белән юлбарыс арасына төштең, тиреңне алдырма», «шагыйрь вакытлы кычкыра белсә генә яхшы. Вакытсыз кычкырган әтәчне суеп ашыйлар», «ялгыз баланың кылыгы яудан яман», «арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар», «кылыч кылычка бәрелгәндә, ике арада күбәләк үлә» кебек әйтемнәр, чагыштырулар әсәрнең телен халыкчан, персонажларның сөйләмен, репликаларын мәгънәле һәм күңелгә якын, үзенчәлекле итә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: халык дастанына нигезләп язылган «Идегәй» трагедиясе белән Н. Исәнбәт халык күңелендә йөрткән изге фикерләрне, халыкчан геройларның образларын сәхнәгә чыгарды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Трагедиянең кыскача эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

2. Анда уздырылган төп фикерне үз сүзләрегез белән әйтеп бирегез.

3. Баш геройларны күрсәтегез. Образларның үзенчәлекле ягын, персонажларның вакыйгалардагы урынын билгеләп, аларга билгеләмә бирегез. Мисал өчен:

а) «Идегәй — рәнҗетелгәннәрне һәм изелгәннәрне яклаучы»;
ә) «Норадынның холкы, хаталары һәм уңай яклары»;
б) «Туктамыш — мәрхәмәтсез һәм гадел булмаган хан»;
в) «Субра — халык чичәне» һ. б.

4. Әсәрдә тартыш нәрсә өчен бара?(Конфликтны билгеләгез.)

5. Трагедиядәге вакыйгаларны үзара охшашлыклары буенча төркемләгез. Гади халык тормышын чагылдырган төркемгә кайсы пәрдәләрне һәм сәхнә күренешләрен кертергә була?

6. Әсәрдән сәнгатьле детальләр һәм образлар табып күрсәтегез, аларның мәгънәсен һәм билгеләмәсен аңлатыгыз.

Трагедия — кискен конфликтка корылган, көчле рухлы геройларга ия булган драматургия әсәре, жанр төре. Аның үзәгендә, гадәттә, гомумкешелек кыйммәтләре һәм югары идеаллар өчен көрәшүче герой яки геройлар образлары тора. Мәсәлән, Ф. Бурнашның «Таһир—Зөһрә» трагедиясендә мәхәббәтләренең җиңүе, шуның белән кешенең хөрлеген раслау өчен үлемгә барган яшьләр үзәккә куелган. «Идегәй»дә халыкның азатлыгы, хәвефсез яшәве, ханның мәрхәмәтсез тәртипләрен юкка чыгару өчен көрәшкә күтәрелгән кеше төп герой итеп алынган.

Көчле һәм кискен конфликтка кергән үзәк герой (яки геройлар) я тарихи-иҗтимагый сәбәпләр, яки характерларының ныклы һәм бербөтен булуы, идеалларына ахыргача бирелгәнлекләре белән үләргә тиеш булалар. Һәлакәтләрен белсәләр дә чигенмиләр. Шуңа күрә дә мондый әсәрләрдә конфликт фаҗигале төсмер йөртә, «трагик конфликт» дип атала. Еш кына геройларның үлеме ниндидер хата адымнарына, ялгышуларына бәйле була. Мәсәлән, Идегәйнең Норадынга һәм Нугайбигә беркатлы ышануы — шундый ялгышларның берсе, трагик хата.

Трагедияләргә гади драма әсәреннән үзгәлекле стиль хас. Еш кына андый әсәрләрдә я югары купшы стиль («Таһир-Зөһрә»), яки күтәренке рухлы стиль («Спартак»), яисә дастаннардан килә торган, поэтик бизәкләр белән баетылган стиль («Идегәй») хас. Олы язмышларны сурәтләгән, ил-халык тормышы белән бәйле мәсьәләләр күтәргән, кешелекнең якты хыялларына тугрылык саклаган геройларны олылаган трагедия әсәрләре укучыга һәм тамашачыга тирән фикерләр алып киләләр, көчле тәэсир ясыйлар.

40—50 НЧЕ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫНДА БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Бу сугышның котылгысыз икәнлеге һәм аның 1941 елның җәйге айларында башланачагы күпләргә мәгълүм иде. Кызганыч, моңа Советлар Союзының югары җитәкчелеге генә ышанмады. Германиянең СССРга һөҗүм итәргә әзерләнүе турындагы хәбәрләр уйдырма төсендә бәяләнде. 1941 елның 22 июнендә иртәнге сәгатьтә фашистлар Германиясенең көтмәгәндә гаять киң фронт белән һөҗүмгә күчүе моның хакыйкать икәнлеген раслады. Дошман, сугышның беренче көннәрендә үк Украина, Белоруссия, Литва, Латвия, Эстонияләрне басып алып, Россия җирләренә ыргылды. Басып алучыларга оешкан төстә нәтиҗәле каршылык күрсәтүгә җитәкчелек итүче үзәк, дөресен әйткәндә, юк иде. Сугыш «театры»нда булган хәрби көчләр җитәкчеләре һәм урыннардагы оешмалар каршылык оештыруны үз җилкәләренә алдылар.

Мондый хәл, әлбәттә, озак дәвам итә алмый иде. Атна-ун көн эчендә СССРның үзәк җитәкчелеге хәл-әхвәлне үз кулына ала алды. Шуннан соң инде 1945 елның августына, ягъни Ерак Көнчыгыштагы җиңүебезгә кадәр, Дәүләт каршылык (оборона) комитеты идарәне нык тотты. Шул ук вакытта тылның киеренке һәм төгәл эшләве дә тәэмин ителде.

Татар халкы бу сугышны азатлык өчен көрәш буларак кабул итте. Татарстаннан ярты миллионнан артык кеше (560 мең) сугышка китте. Шулардан ике йөзгә якыны Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Алар арасында шагыйрь Муса Җәлил, чик буе заставасы командиры Пётр Гаврилов, очучылар Фәрит Фәтхуллин, Михаил Девятаев, Мәгубә Сыртланова, танкист Фатих Шәрипов, артиллерияче Шамил Рәхмәтуллин, сапёр Нәкыйп Сафин, Фәхретдин Заһидуллин һәм башка бик күпләр бар. Дошманның ут нокталарын үз гәүдәләре белән каплаган каһарманнар саны ягыннан да Та-

тарстан уллары дөньяны таң калдырдылар. Газинур Гафиятуллин, Зариф Алимов, Алексей Исаев, Николай Липатов, Филипп Мазилин, Әхмәтгали Мөхәммәдиев, Нух Идрисов, Котдус Габдрахманов, Нургали Акмалетдинов, Сәләхетдин Вәлиуллин, Хафиз Зарипов, Бари Шәвәлиев, Арсентий Карташов, Абдулла Сәлимов, Мансур Вәлиуллин, Әхмәт Мөхәммәтов, Кәрим Исхаков, Әгъләметдин Фәттахов, Сәйфулла Йосыпов, Афанасий Панарин һ. б. Батырлыкның мондый төре аның исеме белән атап йөртелгән Александр Матросовның да татар икәнлеге мәгълүм булды: ул Башкортстан җирендәге Учалы районы Кунакбай авылында туып үскән Шакирҗан Юныс улы Мөхәммәтҗанов булып чыкты. Җиңелгән Германиянең Рейхстагы өстенә беренче булып Җиңү байрагын кадаучы да — татар егете Гази Казыйхан улы Заһитов. Ул Башкортстанның Яңагош авылында 1925 елда туган (1953 елда үлә). Күренекле язучы Илья Эренбург татарларның сугыштагы батырлыкларын бик югары бәяләде: «Алар (татарлар. — *Ф. Г.*) Татарстаннан, Башкортстаннан, Урал һәм Идел буе өлкәләреннән хезмәткә алынганнар — әйбәт солдатлар, тәвәккәл һәм тапкырлар. Сугыш кырында еш ишетергә туры килә: «Бу — татар, сынатмас ул, диләр».

Язучылар сугышның беренче көннәрендә үк фашизмга нәфрәт белән сугарылган әсәрләр бирделәр. Ш. Камал «Без җиңәчәкбез!» дигән публицистик мәкаләсендә болай диде: «Без үзебезнең эшебез хак икәнлеккә нык ышанабыз. Бездә — гаделлек, бездә — хаклык. Бездә — аңлы көч. Әлбәттә, без җиңәрбез!»

Шагыйрьләребезнең әсәрләре дә халыкны сугышка чакыруга, дошманга нәфрәт тәрбияләүгә багышландылар. К. Нәҗми «Фашизмга үлем!», Ә. Исхак «Канга — кан!», М. Җәлил «Тупчы анты» һ.б. шигырьләрен яздылар. Ә. Фәйзинең «Халыклар ярсуы» шигырендәге менә бу юллар ул көннәрдә һәркемне биләп алган уй-теләкләрне чагылдыра:

Каушарга, бер адым чигәргә,
Халыклар, юк безнең хакыбыз,
Җиңәргә, җиңәргә, җиңәргә!
Бу — безнең мөкатдәс антыбыз!

Болар изге сугышка чакыру шигърияте иде. Аннан соң матбугатта озату, аерылышу, сагыш хисләре белән сугарылган әсәрләр күренә башлады. Аларда халык авыз иҗаты

әсәрләренә хас сурәтләү чаралары мул кулланылды, лирик аһәңнәр өстенлек итте. Бу бигрәк тә К. Нәҗминең «Озату» шигырендә күренде. Акбүз атка атланган, кулына кылыч тоткан егет әкият героен хәтерләтә. Вакыйганың таң атканда, Чулпан йолдыз калыкканда баруы исә лиризмны көчәйтә.

Язучылар үзләрен сугышка җибәрүне таләп итә башладылар. Драматург Зәйни Шаһиморатов, аларның уртак омтылышларын чагылдырып, болай дип язды:

Җибәр мине!
Үзем теләп китәм!
Нәфрәт ташый, ярсый, ашкынам!
Ал, военком,
Үзем теләп килдем,
Ал, военком, менә гаризам!

Чынлыкта да язучыларыбызның күбесе сугышка китте.

Ил язмышы хәл ителгән ул көннәрдә алар үзләренең урыны сугыш кырында дип аңладылар. Г. Кутуйның хәрби комиссариатка илткән гаризасында мондый юллар бар: «Дәһшәтле сугыш көннәрендә мин өйдә кала алмыйм. Мине хәрәкәттәге армия сафларына кабул итүегезне үтенәм. Дошманны каләмем һәм штык белән кыйнаячакмын. Чакыруыгызны, өемнән чыкмыйча, һәр көн саен сәгать 12 гә кадәр көтәчәкмен».

Г. Бәширов ул көннәр турында болай искә ала: «Г. Кутуйның язучы буларак популярлыгын, иҗатының халык өчен әһәмиятен исәпкә алып, аңа тылда калу өчен бронь бирелде. Ләкин Кутуй:

— Юк, кала алмыйм. Шундый дәһшәтле сугыш барганда, мин монда ята аламмы соң?! Юк, булмый! — диде.

Кутуй озакламыйча китеп тә барды».

Татар язучыларының утыздан артыгы сугышта һәлак булды. Алар арасында М. Әблиев, А. Алиш, К. Басыйров, Н. Баян, М. Җәлил, М. Гаяз, Р. Ильяс, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, М. Мамин, М. Вәдүт, Х. Рахман, Д. Фәтхи, Х. Мөҗәй, И. Шәфиев һәм башкалар бар.

Кеше үз ана телендә әйтелгәнне йөрәгенә якынрак кабул итә. Көнбатыш илләрендә моңа элек-электән әһәмият бирәләр. Немецлар, татарларга үз карашларын үтемлерәк җиткерү өчен, сугыш вакытында «Идел-Урал», «Хәбәрче» исемле газеталар һәм «Татар әдәбияты» дип аталган журнал чыгаралар. Моңа каршы чара буларак, Мәскәү җитәкчелеге дә татар телендә

фронт газеталары чыгарырга карар бирә. Төрле фронтларда 16 исемдә татар газеталары чыгып килә. Аларда безнең байтак язучыларыбыз эшли: Ш. Мөдәррис, Б. Рәхмәт, А. Шамов, М. Максуд, Г. Галиев, Р. Ишморат, Габделхалик Садри, Г. Әпсәләмов, Г. Насрый, Х. Госман һәм башкалар.

Шагыйрьләребез һәм язучыларыбыз, мөмкинлек биргәнчә, сугыш кырындагы хәлләрне сәнгатьчә күрсәтеп һәм бәяләп барырга тырышалар. Кайнар вакыйгалар эзеннән үк романнар һәм башка зур күләмле әсәрләр язарга вакыт та, җай да юк иде. Шуңа ишарәләп, И. Эренбург болай диде: «Булачак Толстой хәзергә язмый». Ләкин шулай да татар әдәбиятында 1941—1945 еллардагы сугыш турында иң югары сәнгатьчә дәрәҗәдәге әсәрләр нәкъ шул елларда туды. Болай дигәндә, иң беренче, без М. Җәлил һәм Ф. Кәрим иҗатларын күздә тотабыз. Аларның шигъри казанышлары бер татар әдәбияты белән генә дә чикләнми.

Шагыйрьләребез канкойгыч сугышның шигъри елъязмасын тудырдылар. Кайда гына сугышсалар да, алар туган Татарстанны яклауларын яхшы аңладылар. Н. Баян, мәсәлән, 1943 елда болай дип язды:

Шагыйрь күңеле бүген тыныч түгел,
Җырлап алам пуля яуганда,
Мин дошманны илгә җибәрмимен,
Тыныч йөрсен дуслар Казанда.

(«Окопта»)

Туган илне сагыну, аның газизлеген аңлау сугыш мәхшәре эчендә йөрүчеләр күңелендә көчәя бара. Моны Ә. Исхакның 1943 елда язган «Кырда» шигырендә ачык күреп була:

Чыккан идем кырга мин кичә,
Шундый җылы, йомшак җил исә!
Сорадым мин шунда искән җилдән:
— Исәсеңме әллә Туган илдән?..

Илнең газизлеге сугышчы өчен көч чыганагы иде. Моны Г. Кутуй да халыкчан шигырьдә әйтеп бирде:

И Туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

(«Туган ил»)

Җиңүебезгә ышаныч хисе аларның күңелләрендә нык урын алган иде.

Өмет белән алга карыймын да
Бөтен борчулардан бушанам.
Кояш чыгуына ышанган күк,
Җиңәренә илнең ышанам.

(М. Гаяз, «Ватан»)

Балалар һәм Туган ил. Күп кенә шагыйрьләребез бу сүзләрне синоним итеп кулландылар. Балалар иминлеген тәэмин итү илнең киләчәген кайгырту дигән сүз иде.

Мин сугышам синең тормыш өчен,
Синең бәхтең өчен сугышам.
Син уйный тор, бәгърем, иртә-кичен,
Мин кайтырмын тиздән, сау булсам.

(Ш. Маннур, «Балама»)

Татар солдаты бервакытта да милләттәшләре йөзенә кызыллык китерми. Шагыйрьләр бу турыда да горурланып яздылар.

Кышкы кичтә, җилдә, кар-буранда
Ярсып-шашып сугыш шаулады.
Байрак тотып, кинәт калку тауга
Менеп басты татар солдаты.
Торды басып — бомба-миналардан
Көл булса да бөтен тау башы,—
Бабайлардан үлмәс мирас алган
Ашкын җанлы татар солдаты.

(Ш. Мөдәррис, «Эх, шул килеш...»)

Борынгы бабаларыбызның уңай сыйфатлары белән горурлану шагыйрьләребез өчен шулай ук уртак хасият иде. Ш. Маннур тарафыннан язылган «Мәргән батырның иң кече малае Җик Мәргәннән батыр сугышчыларга хат» әсәре моның бер уңышлы гәүдәләнеше булды. Борынгы риваятьләр һәм М. Җәлилнең «Алтынчәч» әсәре буенча безгә бик яхшы таныш бу образ Ш. Маннур тарафыннан замандаш итеп гәүдәләндерелә.

Туган ил — атаң синең,
Ул синнән хезмәт сорар;
Туган ил — анаң синең,
Ул синнән хөрмәт сорар.

Туган ил — балаң синең,
«Сакла!» — дип кулын сузар.
Бирсәң дә син малыңны,
Бирсәң дә син җаныңны,
Бирмә Туган илеңне,
Бирмә Туган җиреңне.

А. Алишның шигъри юллары да шундый ук хисләр белән сугарылган:

Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

(«Ничек килер үлем?»)

Сугыш чоры татар шигърияте, шул рәвешле, халыкның табигый мәнфәгатьләрен, кешеләргә хас булган иң изге, гадәти, шуңа күрә аеруча кадерле булган хис-кичерешләрне чагылдырды. Фронттагы шагыйрьләр өчен намус чакыруы төп идеология булды. Бу исә әсәрләрдә кеше күңеленә якын булган мәүзугларны күтәрү һәм аларны халыкчан, милли рухта ачу мөмкинлекләрен арттырды. 1941—1945 елларда татар шигъриятенең сәнгатьчә югары күтәрелүенә китергән шартларның берсе шул иде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сугышның беренче көннәрендә Советлар Союзында булган хәлне аңлатып бирегез. Сугыш башлану көненең сурәтләнүен сез кайсы әсәрләрдә очраттыгыз? Аларда кешеләрнең үз-үзләрен тотышы ничек гәүдәләндерелгән?

2. Татарларның сугышта күрсәткән батырлыклары турында сөйләгез. И. Эренбургның татарларга карата әйткән фикерен шәрехләгез.

3. Татар язучыларының сугыш вакытындагы эшчәнлекләре белән танышу сездә нинди уй-хисләр кузгатты? Татар әдәбияты сугыш чорында бик күп югалтуларга дучар булды. Ни өчен дип уйлыйсыз?

4. Татар телендә чыккан фронт газеталарының әһәмияте нәрсәдә?

5. 1941—1945 еллар сугышы Татарстаныбыз азатлыгы өчен дә көрәш иде. Шагыйрьләребез иҗатында бу ничек чагылды? «Татар солдатының батыр рухы борынгы бабаларыбыздан килә» дигән фикерне тирәнәйтеп аңлатыгыз.

Сугыш вакытында иҗат ителгән татар әдәбиятындагы проза әсәрләре арасында аеруча хикәя жанры өстенлек алды. Каләм осталары, бер-ике вакыйганы сурәтләп, шушы дәһшәтле көннәрнең катлаулылыгын, драматизмын, гадәттән тыш хәлләр эчендәге кешеләрнең эчке дөньяларын, бер-берләренә мөнәсәбәтен, омтылышларын күрсәтеп бара алдылар. Ул еллардагы барлык хикәяләрнең һәммәсен бергә җыеп укып чыксаң, шуны күрми мөмкин түгел: язучылар сугыш мохитенең барлык өлкәләрен (ут сызыгындагы хәлләрне, разведчикларның хәтәр эшләрен, дошман басып алган җирләрдәге партизаннар хәрәкәтен һәм тылдагы кешеләрнең фидакяр эшләрен) колачларга тырышканнар. Һәм, әйтергә кирәк, алар, нәкъ үз вакытында иҗат ителүләре сәбәпле, кешеләрнең сугыш белән бәйләнешле эшчәнлекләрен һәм хис-тойгыларын чагылдыралар.

Проза әсәрләре иҗат итүдә Ф. Хөсни, Ә. Еники, Ф. Кәрим, Г. Бәширов, А. Шамов, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмов, А. Расих, А. Әхмәт һәм башкалар аеруча өлгерлек күрсәттеләр. Алар тудырган әсәрләрне өч төркемгә аерып карарга мөмкин булыр иде.

Беренчеләрендә безнең ил кешеләренең җиңүебезгә олы ышаныч белән яшәүләре, шушы изге максат өчен бөтен көч-ихтыярларын туплаулары сурәтләнде. Ф. Кәримнең «Язгы төндә», «Разведчик язмалары», И. Газиның «Алар өчәү иде», Г. Әпсәләмовның «Ватан улы», «Үлемнән көчлерәк», «Хәйбулла солдат», Ф. Хөснинең «Хуторда» повесть-хикәяләре шулар рәтенә керә.

Ф. Кәрим әсәрен «Разведчик язмалары» дип атаса да, ул — гади язмалардан гына гыйбарәт түгел, бәлки, чын мәгънәсендә әдәби әсәр. Вакыйгалар авторның үз кичергәннәренә нигезләнә. Сюжет җепләре разведчикларның бик әһәмиятле бурычны үтәүләре тирәсенә туплана. Алар икәү: Акморат исемле төрекмән егете һәм хикәяләүче «мин» — Дим буенда туып үскән татар вәкиле. «Мин» Акморатка зур хөрмәт белән карый. Егетләрнең батырлыгын тасвирлау игътибар үзәгендә торса да, автор илебез кешеләренең ватанпәрвәрлеген күрсәтүне, фашистларның ерткычлыгын ачып бирүне дә үзенең бурычы итеп саный. Шул ук авторның «Язгы төндә» повесте исә сугышчыларның авыр хәл-әхвәлләрне уен-көлке, шуклык белән җиңеләйтергә омтылуларын сурәтләү белән үзенчәлекле. Бу яктан казах егете Турсунбай образы аеруча мөлаем һәм уңышлы иҗат ителгән.

И. Газиның «Алар өчәү иде» әсәренең төп герое — Сөләйманов дигән офицер. Ул үзенең табигате һәм һөнәре буенча һич тә сугыш кешесе түгел. Ил тыныч чакта укытучы булган. Зыялы кешеләргә хас затлы сыйфатларга ия бу ир-егет язмыш тарафыннан үз өстенә йөкләнгән бурычны җиренә җиткереп үти, кыю һәм оештыру сәләтенә дә ия икәнлеген раслый.

Г. Әпсәләмов исә сугыш эчендә йөргән кешеләрне романтик рух белән сурәтләү алымнарын яратып кулланды. Ул тудырган образлар гадәти кешеләр генә түгел. Алар гаять катлаулы хәлләрдә дә югалып калмыйлар, рух көче ягыннан дошманнардан күпкә өстен торалар. «Хәйбулла солдат» хикәясенең героена, бер уйлаганда, исән калырга бөтенләй өмет тә калмаган кебек. Әмма аның рухи һәм җисми көче кыен хәлләрдән исән-сау чыгарга мөмкинлек бирә. «Үлемнән көчлерәк» әсәрендәге Искәндәр турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Башка чарасы калмагач, өстенә ташланган дошман солдатын упкынга өстери һәм аның белән бергә һәлак була.

Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» исемле хыялый повесте исә сугыш чоры прозасында аерым урын тота. Унөч яшьлек малай Рөстәм Асадуллин, җиде төн уртасында абага чәчәген авызына кабып, күренмәс кешегә әверелә һәм немецларга каршы көрәшә башлый, алар өчен куркыныч көчкә әверелә. Әлеге повесть, балалар өчен генә түгел, зурларны да мавыктырырлык итеп, яшүсмерләрнең психологиясен тирәнтен белеп язылган. Ул Г. Кутуйның иҗат кешесе буларак бик кызыклы ягын ачып сала, бездә әлегә нык үсеш алмаган хыялый-маҗаралы әсәрләр тудыруда язучы уңышлы тәҗрибә ясый.

Хикәя һәм повестьларның икенче төркемендә исә фашизмның ерткыч асылын фаш итү максат итеп куела. Г. Кутуйның «Рәссам», Ф. Хөснинең «Рубенс», «Чүлмәк түбәле өйдә», И. Газиның «Кышкы кичтә» әсәрләрендәге вакыйгалар белән танышу укучылар күңелендә фашизмга карата гаять көчле нәфрәт хисләре барлыкка китерә. Димәк, бу үлем алып килүче көчкә каршы бөтен мөмкинлекләр белән көрәшергә кирәк. Шунсыз бүгенгене һәм киләчәкне бәхетле итеп булмый. Г. Кутуй тарафыннан иҗат ителгән хикәянең герое — рәссам Макс Латис. Ул фашистлар яндырган шәһәрдә берүзе кала. Төнлә янгын яктысында «Гитлерга мең нәләт» дигән картина яза. Анда янган балалар тудыру йорты сурәтләнә, ана белән яңа туган бала җимерекләр астында калганнар. Кулына бала тоткан анадан

да изгерәк җан иясе була алмый. Ул — кешелекнең киләчәге. Немец баскыннары кешелекне киләчәгеннән мәхрүм итәләр. Алар — матурлыкның да дошманнары.

Мондый шартларда рәссам пумала урынына кулына пулемёт ала. Чөнки фашизм сәнгать телен аңламый, аның белән корал ярдәмендә генә эш итәргә мөмкин.

Ф. Хөснинең «Рубенс» хикәясе дә фашистларның башка халыклар тарихына, сәнгатенә кимсетеп карауларын күрсәтүгә багышланган. Немецларның биредәге изге әйберләргә хөрмәтсезлек күрсәтүенә нәфрәтләнеп, Бельгиядәге бер шәһәрнең музей хезмәткәре басып алучылардан үч ала, аларны күпләп юк итә.

И. Газиның «Кышкы кичтә» хикәясендә дә тыныч кына яшәп яткан гаиләгә басып алучылар китергән һәлакәт турында бәян ителә. Салкын кыш. Немецлар тылында калган авыл. Фашистлар Мәскәү астындагы җиңелүләреннән соң чигенәләр. Бер өйгә төнгә каршы ефрейтор җитәкчелегендә ике солдат керә. Мич башында карчык авырып ята, бишектә яшь бала йоклый. Фашистлар өй хуҗасы хатынны юк итәләр, үлгән карчыкны да чыгарып ташлыйлар. Бишектә әлегә йоклап ятучы баланың язмышы нинди булыр?..

А. Расихның «Ютазы егете» хикәясендә Бари исемле егет тә фашистлар кылган явызлыкларны күбрәк күргән саен усаллана бара. Чөнки боларны сәламәт акыллы кеше эшли алмый. Алардан котылуның юлы, Бари карашынча, шуннан гыйбарәт: «Фашистны кайда очратсагыз, шунда бетерегез!» Ш. Камал да үзенең иң соңгы әсәре булган «Марат» хикәясендә сугышка китүче егетнең әтисе авызыннан шундый ук фикерләр әйттерә.

Күреп үткәнебезчә, явызлык бары тик үзенә бәрабәр һәм аннан да зуррак усаллык хисләре генә тудыра. Бу хис үз чиратында фашистларга каршы көчле хәрәкәт барлыкка китерә. Җиңүгә булган ышанычның нигезен ватанпәрвәрлек хасил итә. Карап үтелгән әсәрләрдә язучылар шундый нигез фикерне эзлекле үткәрделәр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Язучылар хикәя һәм повестьларда тормышның нинди күренешләрен сурәтләүгә өстенлек бирделәр?

2. Бу чорда аеруча өлгер иҗат иткән язучыларны атагыз.

3. Әлеге елларда иҗат ителгән проза әсәрләрен аларда сурәтләнгән тормыш күренешләре ягыннан ниндирәк төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин?

4. Әсәрләрдә сурәтләнгән безнең кешеләрнең күбесе һөнәрләре буенча сугыш эшеннән бик ерак. Тыныч һөнәр ияләрен кулга корал алырга мәҗбүр иткән сәбәпләр турында сөйләгез.

5. Г. Әпсәләмов сурәтләгән образларның үзенчәлеге нидән гыйбарәт?

6. Ни өчен бу чор хикәяләрендә ана һәм бала образлары еш очрый? Аларны сурәтләп, авторлар нәрсә әйтергә һәм укучыларда нинди хисләр тәрбияләргә теләләр?

7. Ватанпәрвәрлек сугыш чоры кешеләренең гамәлләрен тудыруда гаять әһәмиятле бурыч үтәде. Шуны хикәяләр һәм повестьлар буенча аңлатып бирегез.

Проза әсәрләренең өченче төркеменә кергән хикәяләрдә исә сугыш чоры кешеләренең күңел дөньяларын күрсәтү үзәктә торды. Гадәттән тыш шартларда кешеләрнең бер-берләренә булган карашлары, мөгамәләләре нык үзгәрә, күңелләре сизгеррәк һәм нечкәрәк булып әверелә. Боларны сурәтләү язучыдан да күңел нечкәлеге, кичерү тирәнлеге, геройлары хис иткәнне йөрәге аша уздыра алу сәләтенә ия булуны таләп итә. Психологик тирәнлеккә ирешү мондый әсәрләр иҗат итүченең төп коралы булырга тиеш. Шундый хикәяләрнең күпчелеген Ә. Еники язды. Аның «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз» кебек хикәяләре — кешеләрнең күңел дөньясын яхшы белеп тасвирлауның матур үрнәкләре. Алар арасында «Бер генә сәгатькә» хикәясе сәнгатьчә камил эшләнүе белән аерылып тора.

...Сугыш вакыты. Галимҗан абзый белән Мәрьям апа да улларын моннан ике генә чакрымдагы станциядән сугышка озатканнар. Өй тәрәзәләре әнә шул тимер юл тарафына карап тора. Моңа кадәр Мәрьям апа үтеп йөрүче поездларга игътибар да итмәгән. Хәзер исә аның тәрәзәдән әлеге юлга карап кына утырасы килә. Уллары әйләнеп кайтмасмы? Әдип хикәяләүне әнә шулай башлый.

Шушындый хәл-әхвәлне сурәтләп, психологик җирлек әзерләгәннән соң, вакыйгалар барышы бик кызуланып китә. Көтмәгәндә ананың кече улы Гомәр кайтып керә. Үтеп барышлый гына тукталган. Бер генә сәгатькә. Малаеның кинәт кайтып керүе — үзе дә каушатып җибәрә торган вакыйга. Сугыш

вакытында исән-сау улың алдына килеп бассын әле! Кайсы гына ананың йөрәге кузгалмас бу хәлгә? Күңел, хис киеренкелеген тагын да көчәйтеп җибәрә торган тагын бер сәбәп бар: ул да булса малайның бик аз вакытка — нибары бер генә сәгатькә — өйгә кергәнлеге мәгълүм була. Моны белеп, ананың кулыннан эш төшә, гаҗизләнеп кала. Ә бит ананың улы Сабантуйга түгел, тагын сугыш эченә китә. Исән-сау кайтып, яңадан күрешү насыйп булырмы? Әнә өлкән улы Фатыйхтан ике еллап инде хат-фәлән килми. Шакирының исәнлегеннән дә хәбәр-хәтер юк. Бу хәл ананың күңеленә тагын да хәвеф өсти. «И Ходаем, мунча да кереп өлгермәс микәнни» дигән ананың каушап калуының тирәнлеген күрсәтә.

Улы мунча да керсен, чәй-коймак белән дә ризыклансын, ата-анасы белән иркенләп сөйләшергә дә өлгерсен...

Бер сәгать — алтмыш минут. Ул тиз генә үтеп тә китә. Ана улын әллә күргән, әллә юк. Боларның һәммәсе төштә генә булгандыр сыман. Иртәгесен ул килененнән «Гомәрем ничә чынаяк чәй эчте әле?», «Гомәрем катыкны яратып ашадымы икән?», «Гомәр нәрсә диде әле?» дип сорап-сорап куя. Болар — шушы халәтне кичергән кеше өчен табигый сораулар. Аның хәлендә башкача була да алмый. Башкача булса да, ул дөреслеккә туры килмәс иде. Балаларын өзелеп яратучы, аларның исәнлеге өчен җан атып яшәүче ана турында сүз барганда бу бигрәк тә шулай.

Әлеге көтелмәгән кайтып китү тагын бер кешенең күңелен астын-өскә тузгытып җибәрә. Гомәрнең сөйгән кызын бер генә сәгать эчендә табып өлгерә алмыйлар. Инде ул станциягә килеп җиткәндә, поезд китеп тә барган икән. Галимҗан абзый белән Мәрьям апа аны үзләре белән авылга алып кайтырга телиләр. Әмма кыз кайтмый. Язучы кызның бу вакыттагы халәтен менә болай сурәтли: «Ул беркемгә үпкәләми дә, беркемгә ачуланмый да иде. Хәтта сөйгәне Гомәрне күрми калуының никадәр үкенечле булуы турында да юньләп уйламый иде. Ул бары йөрәге төбеннән күтәрелгән, бөтен тәне буйлап йөргән тиле ярсуны баса алмыйча газаплана. Ахырда ул башын кинәт тезләре өстенә сала һәм һичбер нинди тыелусыз, юка пальтосы аша түгәрәкләнеп, тыгызланып торган иңбашларын калтырата-калтырата елап җибәрә».

Бу хикәядә, күргәнебезчә, сугыш үзе сурәтләнми, ләкин аның барлыгы һәм кешеләр язмышына көчле тәэсир ясавы нык сизелеп тора.

Ә. Еники сугыш чоры кешеләрен сурәтләүгә кайта-кайта мөрәҗәгать итте. 1956 елда, җиңүдән соң унбер ел үткәч, ул үзенең тагын бер талантлы язылган хикәясен бастырды. «Кем җырлады?» дип исемләнгән хикәядә дә, Ә. Еники әсәрләренә хас булганча, атышлар, җимерелүләр һәм гарасатлар юк. Аның каравы сугышның кешеләр язмышына фаҗига алып килүе җанны тетрәндерерлек итеп сурәтләнгән.

...Станциядә ике поезд очраша. Берсе фронтка яңа көчләр алып бара, икенчесе, киресенчә, сугыш эченнән чыгып килә. Сугышка баручы эшелонда, бер вагон ишегенә сөялеп, татар кызы моңлы гына итеп җырлап тора. Тылга кайтучы эшелонның янәшә генә вагонында бер татар егете авыр яраларыннан үлеп бара. Шулвакыт аның колагына каяндыр җыр ишетелә. «Татарча җыр!.. Егет өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы!» Егет, моны үзенең саташуы дип белеп, шул йөрәккә якын моңны ишетә-ишетә җан тәслим кыла. Хикәянең ахырындагы бер җөмлә бу хәлнең аянычлыгын тагын да ныграк көчәйтеп куя. «Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә, чыннан да, бу егетнең сөйгәне Таһирә иде». Биредә көчле үкенү хисе егет белән кыз күңелендә түгел, бәлки, әсәрне укучыда барлыкка килә. Чөнки, әйтелгәнчә, Таһирәнең тавышын ишетүне егет саташуга юрый, кызга килгәндә, ул үзеннән өч-дүрт адымда гына сөйгәне үлеп ятуы турында белми дә. Тик шунысы гаҗәп: кыз, егетенең якында гына булуыннан хәбәре булмаса да, караңгы төндә сагышлана, моңлана. Үзенең җыры, хисләре нәкъ менә шушы мизгелдә үлем газабы кичереп ятучы сөйгәненә кирәк икәнлеген ул йөрәге белән сизенгәндәй итә. Шушы җыр ишетелмәсә, егетнең үлеме тагын да җәфалырак булыр иде сыман. Соңгы сулышларында ул якты хисләр кичереп ала. Моңа әлеге җыр сәбәп була.

Әсәрдә вакыйга бик салмак бара. Аның каравы егет күңелендәге хисләр, аның күз алдына китерүләре, үткәннәрне искә төшерүләре укучыны нык җәлеп итеп тора. Соңгы юлларны укыгач, ул, авыр сулап, «Эх!» дип куйганын сизми дә кала. Шушы халәт аны биләп ала, күңелен борчый. Димәк, язучы үз максатына барып җитә, башкаларның да кеше язмышына битараф калмауларына ирешә.

Кешеләрнең бер-берсен сагынулары арту, сәламәтлекләре турында үзара кайгыртышуның көчәюе, сагыш, сөю хисләренең тирәнлеге аларның күңелен нечкәртеп җибәрде. Шуңа күрә 1918 — 1920 еллардагы гражданнар сугышы вакытында да актив булган нәсер жанры хәзер дә яшәүчәнлеген раслады. Шул ук Ә. Еники «Мәк чәчәге» нәсерен язды. Сугыш һәм чәчәк. Бер караганда алар — бер-берсеннән бик ерак төшенчәләр. Ләкин сугыш китергән фаҗигане чәчәк язмышы аркылы бирү укучыга гаять көчле тәэсир итә. Бомба чокыры төбендә үсеп утырган мәк чәчәге яшәүнең зур көчкә ия булганлыгы турында сөйли. Шул ук вакытта кешеләрнең һәм чәчәкләрнең явыз дошманы булган фашистларга карата нәфрәт хисләрен үстерә. Мәк чәчәгенең безнең солдатка ак юл теләп калуы туган җирнең хәер-фатихасы булып кабул ителә.

Әлбәттә, сугыш чоры нәсерләре дигәндә, хәтердә Г. Кутуйның «Без — сталинградчылар!» һәм «Сагыну» әсәрләре яңара. Аларда туган илен, халкын өзелеп сөюче солдатның уйхисләре, омтылышлары бик көчле чагылган. Идел буендагы шәһәрне азат иткән сугышчы алга таба китә. «Безне яңа сугышлар көтә. Фашистлар тырнагы астында сыкрап яткан калалар һәм авыллар көтәләр. Азатлык кояшы алып барыйк без аларга». «Сагыну» нәсерендә исә сугышчы үзенең Польша җиренә барып җиткәч булган кичерешләрен бәян итә. Чит ил матур булса да, ул аларны шигъри Дим буйларына, борынгы Иделенә алыштыра алмый. Аккош күленең сихри матурлыгы бүтән бер җирдә дә очрамый. «Мин,— ди ул,— ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен Берлинга ашыгам. Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!» Бу сүзләр татар халкының бөек эпосы «Идегәй»дәге мәгълүм шигъри юлларны хәтергә төшерә:

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәзем кылган йорт,
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт.

Идел-йорт — туган халкыбызның, аның борынгы ата-бабаларының изге җире. Г. Кутуй әсәренең лирик герое шул изге

йортны үзе өчен иң мөкатдәс ил итеп саный, шунда әйләнеп кайтуны олы максат итеп күрә.

Сугыш чоры әдәбияты турында сүз алып барганда, Х. Мөҗәйнең «Сугышчы язмалары» дип аталган көндәлекләрен дә искә алу зарур. Аларны сугыш кырыннан репортаж дип атап була.

Полк командиры Хәйретдин Мөҗәй бер үк вакытта шагыйрь һәм язучы да иде. Дахау концлагеренда яндырып үтерелгән бу шәхес — халкыбызның горурлыгы, мәңге хәтеребездә булырга тиешле каһарманы.

Сугыш чоры прозасы, шул рәвешле, әлеге еллар кешеләренең язмышын, эчке дөньяларын шактый бай төсмерләрдә сурәтли алды, укучыларда тормыш таләп иткән хис-кичерешләр тәрбияләүгә иреште.

Сораулар һәм биремнәр

1. Нәрсә ул күңел дөньясы?Сез аны ничек аңлыйсыз?

2. «Бер генә сәгатькә» хикәясенең укучыны җәлеп итә торган төп хасияте нәрсәдә? Әлеге хикәяне вакыйгалар хәрәкәте ягыннан өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Шуларның чикләрен билгеләгез һәм аларның һәрберсендә образларның үз-үзләрен тоту үзенчәлекләрен ачыклагыз.

3. Ә. Еники әсәрләренә хас сыйфатлар «Кем җырлады?» хикәясендә ничек чагыла? Җырның кеше тормышында тоткан урыны турында сөйләшегез.

4. Нәсер жанрының үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Танышып үткән нәсерләрдә гәүдәләнгән төп хисләрне билгеләгез.

5. Г. Кутуйның лирик герое сагынган «ата-баба корган изге йорт» һәм «Идегәй» эпосында әйтелгән «Идел-йорт» төшенчәләре арасында нинди бәйләнеш бар?

6. Х. Мөҗәйнең «Сугышчы язмалары» китабын табып укыгыз.

7. «1941—1945 еллар сугышы һәм татар әдәбияты» дигән әдәби кичә уздырыгыз.

8. Түбәндәге темаларның берсенә сочинение языгыз:

а) «Сугыш чоры шигъриятенең үзенчәлеге»;
ә) «Сугыш чоры хикәя-повестьларында минем яраткан героем»;
б) «Ә. Еники хикәяләрендә күңел дөньясының бирелеше»;
в) «Җыр — ул йөрәкнең йөрәк белән сөйләшүе».

Бу чорның шушындый ук бурычлары драматургия алдында да тора иде. Т. Гыйззәт, М. Әмир, Н. Исәнбәт, Ф. Кәрим, Р. Ишморат кебек авторлар үз әсәрләрендә аларны хәл итәргә

тырыштылар. Драматург Т. Гыйззәт бу мәсьәләдә аеруча өлгер булды. Ул, әле сугыш уты кабынып киткәнче үк, «Таймасовлар» драмасын яза башлады, аны 1941 елның июнь аеның соңгы көннәрендә тәмамлады. Автор халыкны сизгерлеккә, батырлыкка чакыра. Әсәр шунда ук Татар академия театрында куелды да. Г. Кутуй карашынча, ул «кыргый фашизмга каршы татар халкының әче нәфрәте һәм көрәше, театр сәнгате эшчеләренең беренче сугышчан эшләре булып яңгырады».

Бу гаиләнең фамилиясе дә тирән мәгънәле: таймас, тайпылмас, сөрлекмәс, ягъни нык үзәкле кешеләр, ватанпәрвәрләр. Гадәти генә эшче гаиләсенең башлыгы Таһир балаларын үз үрнәгендә илгә тугрылыклы итеп тәрбияләгән. Ил куркыныч алдында калганда, Шәйхаттар, Солтан, Шәүкәт, Марат, Гөлшат — һәммәсе ата йөзенә кызыллык китермиләр. Алар янәшәсендә, кызыл сүзләрне күп сөйләп тә, кирәк вакытта күләгәдә калырга омтылган Искәндәр образы күңел кайтаргыч булып күренә. Ил каһарманы булып танылган Марат янында аның мескенлеге аеруча ачык чагыла.

Шуннан соң Т. Гыйззәт тиз вакыт эчендә «Төнге сигнал» драмасын иҗат итә. Дошман тылында калган украин авылындагы вакыйгалар үзәгендә татар егете Мансур тора. Аны яклап үлемгә барган Антон карт образы соклану тудыра. Ил язмышының кыл өстендә торуы төрле милләтләрне бер максатка берләштерә.

Н. Исәнбәт тә «Мәрьям» драмасында безнең кешеләрнең фидакярләрчә көрәшен чагылдырды. Мәрьям — кыю, батыр рухлы кыз. Җисми яктан юк ителгәндә дә, ул рух көче мәсьәләсендә үзен җәзалаучылардан өстен булып кала. Әсәргә бәя бирүчеләр драманың У. Шекспирча көчле яңгырашын билгеләп үттеләр.

Р. Ишморатның «Дошман лагеренда», М. Әмирнең «Партизан Иван» әсәрләрендә дә безнең кешеләрнең фашизм алдында каушап калмаулары, көчле каршылык оештыру күренешләре тамашачыларны дулкынландырырлык итеп гәүдәләндерелде.

Шул ук вакытта драматурглар тылдагы кешеләрнең намуслы хезмәтен күрсәтүгә дә игътибарлы булдылар. Р. Ишморатның «Кайту», М. Әмирнең «Миңлекамал» драмалары — шуларның иң күренеклеләре. Аларда җиңүне якынайту өчен көчләрен кызганмаган авыл хезмәтчәннәренең тормышчан һәм мөлаем образлары тудырыла. «Кайту»да

(1942) кешенең теләсә нинди хәлләрдә дә җәмгыятьтә тиешле урынын алырга, үзен файдалы шәхес итеп расларга тиешлеге мәсьәләсе күтәрелә. Сугыштан яраланып кайткан Хәмит авылда үзен эшкә яраксыз, файдасыз кеше дип кимсенә. Сугышта танк йөртүче булган егет яшүсмер малайларга-кызларга трактор серләрен өйрәтә ала икән ич. Ул механик булып китә, ягъни хезмәткә керешә. Иленә һәм хатынына булган мәхәббәте аны яңадан сафка кайтара. Кайту сүзенә ике мәгънә салынган: Хәмитнең сугыштан кайтуы һәм тыныч хезмәткә кайтуы әсәрнең фикер үзәген тәшкил итә, шул чор тормышының гыйбрәтле якларын тасвирларга мөмкинлек бирә.

М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасының (1944) сәхнә язмышы тагын да бәхетле булды. Ул барлык татар театрларында зур уңыш белән куелды. Автор сугыш вакыты авылындагы чынбарлыкны бөтен авырлыклары, каршылыклары белән сурәтли. Татар халкының уңганлыгы-булганлыгы, ных холыклы булуы гади авыл хатыны Миңлекамал образында дөрес гәүдәләнгән. Ләкин гади дә түгел ул. Чөнки сугыш чоры күмәк хуҗалыгына рәислек итүне үзең сорап алу өчен куш йөрәкле булырга кирәктер. Үз юлында нинди авырлыклар очрыйсын ул яхшы аңлый, ләкин шундый тәвәккәллеккә бара. Эшләүчеләр — хатын-кыз, бала-чага, карт-коры гына. Атларның да юньлерәкләрен сугышка алып торалар, мал-туарга ашатырга юк. Нәрсә кирәк булса, шул — юк. Җитмәсә, аның эшенә ясалма рәвештә комачау итүчеләр дә бар. Иренең үлгәнлеге турындагы җан тетрәткеч хәбәр дә иң кыен вакытта килеп ирешә.

Ләкин бу хатын, җилкәсенә авырлык баскан саен, ных үзәклерәк була бара. Әсәр аның тормыш сынауларын җиңүен тантана итүе белән тәмамлана. Җитәкче өчен кыен хәлне җиңеп чыгуда бердәнбер дөрес юл — халыкның таза әхлаклы өлешенә таяну. Миңлекамалның көче әнә шунда. М. Әмир моны кызыклы хәл-әхвәлләрдә ышандырырлык итеп күрсәтә алган. Әсәрнең әле дә сәхнәдән төшмәве, гомерле булуы аның сәнгатьчә эшләнешенең тиешле дәрәҗәдә икәнлеген күрсәтә.

М. Әмир «Тормыш җыры» әсәрендә дә (1946) бу теманы дәвам иттерде. Бригадир хатын Фатыйма образы Миңлекамал, Г. Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисәләрнең игезәк туганы кебек кабул ителә. Җиңү әнә шундый фидакяр хатын-кызларның үз-үзләрен аямыйча хезмәт итүләреннән

башка була алмас иде. Татар драматурглары һәм әдипләре бу хакыйкатьне мөмкин кадәр тормышчан итеп ачып салырга тырыштылар.

Сугыштан соңгы елларда һәм бигрәк тә 50 нче елларда халкыбызның яу кырында күрсәткән батырлыгын Габдрахман Әпсәләмов аеруча дәртләнеп сурәтләде. Ул үзе сугышның башыннан ахырынача фронтта булды, батырлыгы өчен хөкүмәт бүләкләре алды. Шуңа күрә үз тәэсирләре эзеннән җиң сызганып иҗат итәргә керешә. 1946 елда ул «Ак төннәр» повестен язды. Аннан соң «Алтын йолдыз» (1948), «Газинур» (1951), «Мәңгелек кеше» (1960) романнарын бастырып чыгарды. Хикәяләрендәге кебек үк, зур күләмле әсәрләрендә дә ул сугышчыларны романтик табигатьле итеп, ягъни гадәттәгедән шактый югары итеп сурәтләде. Алар уйлары һәм гамәлләре белән гадәти кешеләр генә түгел. Бер уйлаганда, Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин — авылдан чыккан гап-гади татар егете. Г. Әпсәләмов сурәтләвендә исә ул — җырга-моңга бай, нәфис телле, балаларын өзелеп яратучы нечкә күңелле ата, шул ук вакытта нык үзәкле, максатка омтылучан шәхес.

«Алтын йолдыз» романында сурәтләнгән Галим, Мөнирә, Наил, Хафиз, Ләлә, Һаҗәр, Ильяс кебек яшьләрне дә гадәти егет-кызлар дип кенә әйтеп булмый. Алар башыннан үткән хәлләр әкият геройларының күргәннәренә бәрабәр. Бу яктан Галим, Ильяс, Ләләләрнең язмышы аеруча маҗаралы.

«Мәңгелек кеше» романының каһарманы Бакый Назимов образы документаль нигезгә таянып иҗат ителгән. Аның тормыштагы прототибы Бакый Назыйров — романда сурәтләнгән Бухенвальд үлем лагере газапларын кичергән кеше. Бу — геройлар китабы. Симагин, Вальтер, Сабир, Мамед кебек образлар да чынбарлыкта булган шәхесләрдән алынып иҗат ителгәннәр. Г. Әпсәләмов бездә документаль-публицистик романның матур үрнәген бирде. «Агыла болыт» (1978) романында исә М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгын күрсәтү белән бергә, аларның намуслы исемен кире кайтару өчен тырышлык куйган Гази Кашшафка да зур урын бирелә (ул романда Мирзаһит исеме белән сурәтләнә). М. Җәлилнең көрәштәше Гарәф Фәхретдинов, әсәрне укып чыккач, язылганнарны хуплап, авторга хат яза. Димәк, бу — язучы хакыйкатькә тугры булып калган дигән сүз.

Сугыш темасын төрле яклап ачу һаман дәвам итә. Бу эшкә Нәби Дәүли зур өлеш кертте: «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» әсәрләрен язды. Хисам Камалов «Безне өйдә көтәләр», «Һәркемнең гомере бер генә»; Әдип Маликов «Яшьлек утравым»; Габдулла Шәрәфи «Сусыз дәрья» әсәрләрен иҗат иттеләр. Сугыш тәмамланганга күп дистә еллар үтсә дә, бу тема һаман да искерми.

Роман төрләре. Роман — эпик төрнең иң күләмле һәм киң колачлы жанры. Ул үз эченә нәсер, хикәя, повестьларның үзенчәлекләрен сыйдыра. Шуңа күрә аны кушылма (синтетик) жанр дип тә йөртәләр. Романда кешене (кешеләрне) башкалар белән бик күп бәйләнешләрдә, элемтәләрдә ачарга мөмкин. Әдәби әсәрнең төп сурәтләү предметы — кеше дигән принцип романда тагын да тулырак тормышка ашырыла. Чөнки роман кешене бөтен гомере буена сурәтләү, хәтта аның нәсел-нәсәбенең берничә тармагын тарихи үсештә күрсәтү мөмкинлеген бирә. Шәхес язмышын милләт, ил язмышы белән катлаулы бәйләнешләрдә күрсәтү ягыннан да роман зур сыйдырышлылыгы белән аерылып тора. Роман цикллары барлыкка килү шуның белән аңлатыла. Г. Ибраһимов өч романнан торган «Хәят дулкыннары» исемле әсәр яза. Ни кызганыч, әмма аның «Безнең көннәр» дип исемләнгән беренче кисәге генә сакланып калган.

И. Газиның «Онытылмас еллар» романы да «Малай чак», «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт», «Канатланыр чак» исемле өч кисәктән тора. Шуңа күрә ул трилогия дип атала.

Романнар тематик яктан да төрле-төрле булалар. Татар әдәбиятында беренче роман саналган З. Бигиевнең «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрләрен детектив романнар дип атый алабыз. Чөнки аларда җинаять һәм җинаятьчеләрне табу хәрәкәте үзәктә тора. (Детектив — «ачып бирү» мәгънәсендәге латин сүзе.) Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» әсәрләре исә — тарихи-сәяси романнар, Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар», «Итил суы ака торур», Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» әсәрләре — тарихи романнар, Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Шәйхи Маннурның «Муса»сын тарихи-биографик романнар дип атыйбыз. Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше»се — документаль-публицистик роман. Тагын фәлсәфи, мажаралы, хыялый (фантастик) һәм башка төрле романнар булырга мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сугыш чоры татар драматурглары үз әсәрләрендә нинди темаларга мөрәҗәгать итәләр?

2. М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасындагы төп образ нинди сыйфатларга ия?

3. Г. Әпсәләмовның әдәби әсәрдә кеше образын тудыруга карата әйткән фикере турында уйланыгыз. Аның бу хактагы карашы әдәби әсәрләрдә ничек тормышка ашырыла? Г. Әпсәләмовның бер әсәре буенча укучылар конференциясе уздырыгыз.

4. «Татар язучыларының романнарында 1941—1945 еллардагы сугышның чагылышы» дигән темага сочинение язу буенча сыйныфта конкурс уздырыгыз.

5. Роман жанры һәм аның төрләре турында сез ниләр беләсез?

Муса Җәлил
(1906—1944)

Шагыйрь Муса Җәлил исеме сезгә үткән сыйныфлардагы әдәбият дәресләре буенча яхшы таныш. Сез аның тормышын һәм иҗатын башлангыч сыйныфларда ук өйрәнә башладыгыз: шигырьләре, балладалары белән таныштыгыз. 8 нче сыйныфта инде шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында тулырак мәгълүматлар алдыгыз. Аерым шигырьләрен дә ятладыгыз.

Муса Җәлил исеме сезгә, мәктәптән тыш та, мәгълүмат алуның төрле тармаклары буенча гел ишетелеп, аның турындагы белемегез баеп тора. Әдипнең тормышы, эшчәнлеге, иҗаты турында күп санлы әдәби әсәрләр, фәнни китаплар язылган. М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең фашистлар белән тиңдәшсез кыю көрәше хакында байтак сәхнә әсәрләре куелган. Шагыйрь сүзләренә язылган җырлар, романслар, опера-дан арияләр радио-телевидениедән даими яңгырап торалар. Рәссамнарның аңа багышланган картиналары белән дә еш очрашасыз. Казан Кремле янындагы мәһабәт Җәлил һәйкәле дә халкыбызның батырлык рухына дан җырлаучы ядкяр булып кабул ителә. Шушыларның барысыннан да Муса Җәлил халкыбызның батыр улы, фидакяр көрәшчесе, әдәбиятыбыз хәзинәсен яңа рухи кыйммәтләр белән баеткан классик әдибе булып күз алдыбызга баса.

20 — 30 нчы еллардагы иҗаты

Тормыш гаять катлаулы. Мәңгелек дип саналган һәйкәлләрне дә урыннарыннан кузгаткан заманнар бар. 80 нче елларның ахырларыннан әнә шундый кискен сәяси-идеологик үзгәрешләр безнең тормышыбызда да башланды, һәм ул әдәбият тарихын аңлатуда да күп сораулар уятты. Заман җилләре корыч пьедесталга баскан Җәлилне дә читләтеп узмады. Социализм дәверен һәм аның рухи җитәкчеләрен мактап җырлаучы коммунист-шагыйрь буларак, аны да тәнкыйть күзлегеннән генә бәяләү кирәклеген күтәреп чыгучылар булды. Шушы ук нигездә аның Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗатын түбәнсетеп, талантын Моабит дәфтәрләренә генә бәйләп ачуны куәтләгән, хәтта аның сугыштагы батырлыгын киләчәк башкача бәяләячәк дигән фикерләр дә ишетелгәләде.

Әлбәттә, һәр заман үткәндә иҗат иткән әдипне үзенчә бәяли. Язучының мирасын яңача укырга омтылу — әдәби процессның табигый бер күренеше. Матбугатта әдәбиятны яңача өйрәнергә кирәклек турындагы фикерләр белән очрашу сездә дә табигый рәвештә сораулар уята торгандыр: Муса Җәлилне данлаган, олылаган, аны Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты кебек иң югары исемнәр белән бүләкләгән СССР дәүләте таркалган чорда, коммунизм идеологиясе кискен тәнкыйтькә очраган заманда шул дәвернең идеяләрен данлаган шагыйрьне ничек бәяләргә? Ул бит бөтен аңлы тормышын социализм идеяләре өчен көрәшкә багышлаган, комсомол, коммунист булган, шул идеяләр хакына гомерен биргән?!

Сораулар җитди һәм катлаулы. Алар әдипнең теге яки бу әсәренә генә түгел, ә бөтен иҗатына, сәнгатьчә фикерләвенең формасына түгел, ә эчтәлегенә, дөньяга карашына барып тоташалар. Бу сораулар табигый рәвештә әдәбият һәм идеология мөнәсәбәтләре мәсьәләләрен кузгата. Без инде үткән дәресләрдә әдәбиятның иҗтимагый аңның бер формасы булуын, әдипнең үзе яшәгән чорның нинди дә булса идеяләрен, фикерләрен яклап-күтәреп чыгуын, шул фикерләрен әсәрләре аша чагылдыруын белеп-күреп узган идек. Әдәбиятның идеология, сәясәт белән якынлыгын, туганлыгын һәм идеология, сәясәт үзгәрү белән бәяләмәләрнең дә үзгәрүен сез татар әдәбияты тарихыннан күп мисаллар белән раслый аласыз. Шундый кискен идеологик үзгәрешләр чорында бәяләмәләрдә бер

чиктән икенчесенә ташланулар да очрый. Мондый хәлләр тәнкыйтьчеләрнең төп акцентны идеологиягә генә юнәлтүләре һәм шундагы принципларны гына төп критерий итеп алулары нәтиҗәсендә килеп чыга. Җәлил иҗатына кискен тәнкыйди карашның тууы да идеология белән матур әдәбиятны бер яссылыкта гына — әдәби иҗатны идеологиянең тәңгәл чагылышы итеп кенә карау белән бәйле. Бу исә әдәбиятны партиялелек принцибы нигезендә үтә гадиләштереп аңлатудан килеп чыга. М. Җәлил коммунизм идеологиясенә хезмәт иткән икән, һәм хәзер ул идеологиянең җитди кимчелекләре ачылган икән, димәк, кайберәүләр фикеренчә, шагыйрь иҗаты да җитди тәнкыйтькә мохтаҗ. Әгәр сүз Җәлилнең сәяси карашлары, ул карашлардагы хәзер күзгә ташланган кимчелекләре турында барса (мәсәлән, дингә кире мөнәсәбәт), мәсьәләне тәнкыйди планда гына да карап булыр иде. Әмма сүз бит М. Җәлилнең сәяси публицистикасы турында түгел, ә аның әдәби иҗаты турында бара. Монда инде мәсьәлә катлаулана төшә.

Әдәби әсәр әдипнең карашларын әдәби сурәтләрнең, алымнарның катлаулы механизмы ярдәмендә ача. Бу сурәтләр, үзара үзгәреп торган мөнәсәбәтләргә кереп, язучы фикерен я турыдан-туры публицистик ачыклыгында, яисә язучы уйлап, әйтеп бетермәгән өстәмә фикерләр рәвешендә, яисә уйлаган, әмма яшертен ымлаулар белән генә сиздергән фикерләре рәвешендә төрлечә ачарга тиеш, һәм ул укучыга да төрле мәгънәдә барып җитәргә мөмкин. Шуңа күрә, язучы иҗатын идеология белән бәйләнештә караганда, әдәбиятның әнә шундый сәнгатьчә үз мөстәкыйльлеге булу үзенчәлеген истән чыгарырга ярамый.

Шагыйрьнең сәяси-идеологик фикерләү дөньясына якынрак килик. Мәсьәләгә тарихи яктан караганда, М. Җәлилнең социализм идеяләренә килеп кушылуы һич тә очраклы булмавы ачык күренә. Социализм идеяләрен аңа беркем дә көчләп такмаган, татар халкының Октябрь инкыйлабына кадәрге изелгән, кыерсытылган, хокуксыз тормышы аны шушы юлга — ирек яулау юлына этәргән. Аларның гаилә тормышыннан ачык билгеле; әтисе Мостафа ярлылыкта, мохтаҗлыкта көн күргән. Күрәсең, шуңадыр да абыйсы Ибраһим, инкыйлаб башлану белән, большевиклар ягына барып кушылган. Муса да абыйсы артыннан калышмаска тырыша. «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләре арасында ул «сул» фикерле шәкерт булып танылa. Оренбургтагы фронт газеталарында 1919 елны

басылып чыккан беренче шигырьләрендә үк («Бәхет», «Ирек бәйрәмендә» һ.б.), ул халыкның азатлык көрәшенә күтәрелүен ихлас күңеленнән хуплый. Ул аны халык өчен, азатлык өчен көрәшү дип билгели. Үз шигъриятенең асылын да, «иң олуг идеалларын да» «халыкка нур чәчеп, ак юлга атлауда», «халкы өчен яшәүдә» күрә. Яшь шагыйрьне шундый идеаллары өчен гаепләү, тәнкыйтьләү урынсыз булыр иде.

Татар халкының азатлыгына омтылу фикере хәзер дә бит шушы рухтарак — «олуг идеал» буларак яңгырый, үткәнне һәм бүгенгене ниндидер бер эчке рухи аваздашлык берләштерә.

М. Җәлил яңа җәмгыять туган халкына тулы бәхет китерер, кешене һәр яктан бәхетле итәр дип чын күңеленнән ышана һәм шул ирекле, матур тормыш өчен аңлы көрәш юлына баса. 1919 елның язында ул комсомолга керә. Шул вакыттан алып комсомолның көндәлек тормышында актив катнаша башлый. Мәскәү дәүләт университетында укыганда, 1929 елны ВКП(б) сафларына алына. Үзенең иҗтимагый эшчәнлегендә дә, әсәрләрендә дә ул коммунизм идеологиясенә тугрылыклы хезмәт итәргә омтыла. Шагыйрь үзенең сәяси карашларын яшерми: әсәрләрендә аның социализм өчен, халкының бәхете өчен көрәшү мотивлары ярылып ята.

Ул,— барыннан да бигрәк, үз чорының шагыйре. Яңа, бәхетле илне — социализмны — бер халыкның да әле төзеп күрсәткәне юк. Халык белән бергә, Җәлил дә дөньяда күрелмәгән шушы олы һәм авыр иҗтимагый тәҗрибәгә — сәяси экспериментка алына. Көрәшче булып та, шагыйрь булып та. Яңа юл салу исә гаять катлаулы булып чыга: тормышта да, әдәбиятта да. Шушы чорның әдәби-эстетик мохите аның иҗатына да тирән эз сала: тәҗрибәләренең яңалыгы белән, тормышның тиз үзгәреп торуы белән, күпмилләтле бердәм социалистик җәмгыять төзү хыялы белән, шул чор сәясәтендәге хаталарның күплеге белән... Шагыйрь дә ул хаталарны читләтеп узмый. Байларга каршы да, чиркәү, мәчетләргә, мулла, попларга каршы да, сыйнфый дошманнарга, кулакларга, чит ил империалистларына каршы да, әдәбияттагы «идеологик бозулар»га каршы да көрәшә. Мәкаләләре белән дә, шигырьләре белән дә. Шул рәвешчә, М. Җәлилнең сәясиидеологик карашларын ачыклау, аның шәхесенә тарихи якын килү иҗатының күп үзенчәлекләрен (нинди темалар-мәсьәләләр күтәрүен, аларны нинди җирлеккә таянып яктыртуын) аңларга һәм аңлатырга ярдәм итә.

Җәлилнең дөнья күргән, басылып чыккан әсәрләрендә революция һәм шул нигездә дөньяны яхшы якка үзгәртү темасы зур урын алып тора. Революцияне төрле елларда язган әсәрләрендә төрлечәрәк сурәтли. 20 нче елларның башларындагы шигырьләрендә инкыйлабны тиңе булмаган олы, мәһабәт күренеш итеп, романтик тасвир чаралары белән гәүдәләндерә. «Кисәк» шигыренең (1922) сурәтләнешенә игътибар итик: сурәтләрнең объектив мәгънәсе автор әйтергә теләгән фикерләрдән аерылып тора. Шагыйрь «коллык шаһын җимергән» инкыйлабка мәдхия укырга тели. Ә сурәтләр мәгънәне башкача ачалар: инкыйлаб — ул дөньядагы тереклекне яндыручы, юкка чыгаручы, җимерүче «ут, ялкын». Икенче метафорасы да шушы рухта: шагыйрь инкыйлабны «канлы җәнҗал» дип билгели. Шул чор инкыйлабларының асылын хәзерге публицистлар да бит җәлилчәрәк аңлаталар.

20 нче елларның урталарында һәм ахырларында инкыйлабны сурәтләүдә шагыйрь иҗатында яңа төсмерләр туа. Шагыйрь хәзер игътибарын инкыйлабның коллыкны җимерү пафосына түгел, ә аны ясаучыларның трагик язмышларына юнәлтә. «Үлем алдыннан» шигырендә үк (1922) шушы мотив күренгән иде. «Авыру комсомолец» поэмасында (1924—1928) әлеге мотив эпик тасвирлауда ачыла. Инкыйлаб шәхесне авыру газапларына дучар иткән канлы бәрелешләр чылбыры сыйфатында күренә. Шагыйрь, әсәрен яза башлаганда, халык батырлыгын күрсәтүне максат итеп ала. Әмма әсәрдәге вакыйгалар логикасы фикерләүне икенче юнәлешкәрәк борып җибәрә. Поэма сюжетындагы драматик вакыйгалар фикерләү үзәген шәхеснең фаҗигале язмышы тирәсенә туплыйлар. Инкыйлабны олылау аның фаҗигале хасиятләрен ачу булып әверелә.

Күрәбез: сәнгатьчә фикерләүдә, образлар системасында хәтта инкыйлаб темасы да ниндидер көтелмәгән идея төсмерләре белән ачылып китә икән. Шагыйрь тормышның авырлыгын да, катлаулылыгын да күргән һәм күрсәткән икән. Бу мисалларда әдипнең сәяси-идеологик карашлары белән аның әсәрләрен тиңләштереп карауның уңышсыз алым булуы да, тышкы тема белән аның эчке темасының аерылу очраклары да, шулай ук әдәби әсәрнең үзалдына мөстәкыйль яши алу сәләте дә ачык чагыла булса кирәк.

Шагыйрьнең сәяси карашлары да үсеп-үзгәреп тора. Бу үсешен аның сәясәткә караган байтак әсәрләрен бастырмый

калдыруы да, 30 нчы елларда чыгарган җыентыкларына элек язылганнарын кертмәве дә раслый.

Үз хаталарын ул үзе үк аңлый, сыйнфый дошман эзләү белән артык мавыгуын үзе үк төшенә башлый. Соңгарак калып булса да...

М. Җәлилнең 30 нчы еллар ахырларындагы дөньяга карашында үзен дә сискәндереп җибәргән яңа бер фикер уяна. Шагыйрь социалистик җәмгыять төзүнең максаты белән аны тормышка ашыручы хакимият, аның үткәргән сәясәте арасында зур аерымлык күрә башлый. Партия һәм хөкүмәт милләтләрнең чәчәк атуы турында сөйли. Шагыйрьне чынлыкта хәлнең башкача килеп чыгуы борчуга сала. Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә татар телендә чыгып килгән газета-журналлар ябылып бетә, Казаннан башка җирләрдә татарча китаплар басу туктала. 20 нче елларда татар мәдәниятенең төрле өлкәләрдә гөрләп яшәвен күргән һәм Мәскәүдәге газета-журнал редакцияләрендә үзе дә эшләгән шагыйрьгә бу хәл бик сәер тоела, күп сораулар уята. Казанга килеп эшкә керергә мәҗбүр ителгәч тә, ул шушы ук яман хәл белән — Сталин сәясәтенең милли рухны кысу күренешләре белән очраша. Үзен Язучылар оешмасы җитәкчесе итеп сайлап куйгач, мондый хәлнең табигый түгеллеген аңлатып, республика җитәкчеләре белән дә сөйләшеп карый. Хәлләр һаман элеккечә дәвам иткәч, иң соңгы чарага тотынырга мәҗбүр була. Үзе үк мактап җырлаган юлбашчының үзенә — Сталинга — 1939 елда татар мәдәниятенең аяныч хәле турында хат юллый. Күп төрле дәлилләр китерелгәннән соң, ул: «Татар әдәбиятындагы мондый хәлгә моннан ары түзеп торырга мөмкин түгел»,— дигән нәтиҗә ясый. Әлеге кисәтү, күрәсең, хакимият җитәкчеләрен дә сискәндереп җибәрә. Чөнки алар тарихта татарларның, түзәр хәлләре калмаганнан соң, ни эшләүләрен яхшы беләләр. Бу хаттан соң Казанда әдипләрнең тормыш хәлләре, гонорар, квартир мәсьәләләре күпмедер дәрәҗәдә рәтләнә. Тел, әдәбият институты да ачыла. Мәскәүдә әдәбият-сәнгать декадасын үткәрү турында карар кабул ителә. Әмма Татарстаннан читтә яшәүче татарларның милли мәдәниятләренең хәле үзгәрешсез кала. Шагыйрь социалистик җәмгыять төзүнең ул ышанып кабул иткән теориясе белән аны гамәли тормышка ашыручы хакимиятнең сәясәте арасындагы аерымлыкның дәвам итүен хәвефләнеп күзәтә. Бу уйланулары аның «Алтынчәч» әсәренең фәлсәфи эчтәлегенә дә, Моабитта иҗат ителгән

кайбер әсәрләренең янгырашына да (мәсәлән, «Бүреләр») билгеле бер эз салалар. М. Җәлилнең иҗатына бары тик сәясәт ноктасыннан гына якын килү шагыйрьнең тормышны сәнгатьчә танып белү дәрәҗәсен бөтен тулылыгында күрсәтә алмый. Чөнки шагыйрьнең дөньяны, тормышны, җәмгыятьне сәнгатьчә кабул итүе аның сәяси карашлары белән генә чикләнми. Ул аның галәмгә һәм табигатькә мөнәсәбәтен дә, халык тарихына, аның милли үзенчәлекләренә, гореф-гадәтләренә, теленә, халык иҗатына, сәнгать төрләренә булган карашларын да, башка милләтләргә мөнәсәбәтен дә үз эченә ала, мәхәббәткә, гаиләгә, бала тәрбияләүгә, дингә мөнәсәбәтен дә сыйдыра. Әдәби әсәрләрендә шагыйрьнең сәяси карашлары фәлсәфи, эстетик карашлары белән тыгыз кушылып китәләр. Әмма аларның үзара бәйләнешләре дә гади түгел. Чорына һәм шул чорда хөкем сөргән әдәби мохиткә карап катлауланырга да мөмкин. Моның шулай икәнлеген М. Җәлилнең иҗат мирасына булган мөнәсәбәт тә раслап тора.

Партиялелек принцибына таянып эш итәргә өйрәтелгән 20—30 нчы еллар тәнкыйте М. Җәлилнең бай һәм күпьяклы иҗатын дөньяга карашының тулылыгында һәм бөтенлегендә күрсәтү белән түгел, ә сәяси-идеологик яссылыгында аңлату белән мавыкты. Гомумән, ул елларның әдәби мохите шуңа нигезләнгән иде. Газеталар, журналлар шагыйрьнең чорга аваздаш әсәрләрен басып чыгардылар, китапларына да сыйнфый көрәш рухын чагылдырган «партияле» әсәрләре генә тупланды. Шуңа да Җәлилне 20 нче елларда еш кына, тематикасына юнәлеш тотып, «комсомол җырчысы» дип атап йөрттеләр. Чынында исә аны бу чорда «яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы» дип атау дөреслеккә ныграк туры килә иде.

М. Җәлилнең әдәби мирасы укучыларына тулылыгы белән, ул үлгәннән соң, 50—70 нче елларда гына билгеле булды. Татарстан китап нәшрияты 1956—1957 елларда аның әсәрләренең өчтомлыгын, 1975—1976 елларда дүрттомлыгын бастырып чыгарды. Бу басмалар М. Җәлилне бөтенләй яңа яктыртылышта ачып җибәрделәр. Шагыйрь иҗат иткән әсәрләрнең бик аз өлеше генә үз вакытында басылып чыккан икән. М. Җәлил шул чор идеологиясенә бәйле шагыйрь-гражданин булып кына түгел, ә үзалдында ирекле шагыйрь булып яшәгән икән. Ул үзен һәм чордашларын борчыган мәсьәләләргә шигъри сүз белән җавап биреп барырга омтылган. Социаль заказ белән генә чикләнмәгән, күңеле һәм йөрәге кушканны шигырь

теленә күчерә барган. Шул чор әдәби мохитендә актив кайнаган әдип буларак, ул матбугатта нинди шигырьләре үтәсен яхшы белгән. Шундыйларын — иҗтимагый-сәяси яңгырашлыларын бастырырга биргән, ә шәхеснең күңел бизәкләренә, моңнарына, аһ-зарына караганнарын үзе өчен аерым дәфтәренә теркәп барган. Мондый дәфтәрләрен ул 20 нче елларда ук алып барган. Аларның күпчелеге мәхәббәт темасына карый. 30 нчы еллардагы дәфтәрен ул «Лирика көндәлеге» дип исемләгән. Биредә дә күпчелек шигырьләр сөю турында.

Мондый әсәрләрнең дөньяга чыгуы Җәлилнең шагыйрь буларак иркле яшәргә омтылышын тагын да ачыграк күзалларга булыша. Алар шагыйрьдә тормыш тулылыгына омтылышның 20 нче еллар иҗатында ук шактый көчле булуын раслыйлар. Шагыйрь мәхәббәт-сөю, кеше күңелендәге моң турында күп әсәрләр язган. Аларның беришендә Хәйям, Сәгъди, Хафиз кебек Шәрык классикларының йогынтысы сизелсә, икенчеләрендә Тукай, Дәрдемәнд традицияләрен дәвам итәргә омтылу күренә.

Характеры белән дә М. Җәлил тормышны тулылыгында кабул итәргә яраткан. Иҗатында да ул шул принцибын тормышка ашырып килгән. Шигъриятенең «Моабит дәфтәрләре»ндә башка тарихи шартларда ачылып киткән шушы хасиятләре буш җирлектә, кинәттән генә тумаган икән. Әдәби мохит, шул чор эстетикасы вакыт-вакыт нык комачауласа да, Җәлил үзенең иҗатын шушы юнәлештә үстерә барган.

Җәлилнең сурәтле фикерләвендә туган яңалыклар аның тормышны тулылыгында кабул итәргә омтылуы белән генә чикләнми. Яңалык әсәр геройларын һәм күренешләрне яңарак принциплар кулланып тасвирлауда да күренде.

Шагыйрь 20 нче еллар поэзиясендә төп игътибарын героеның социаль-сәяси йөзен ачуга юнәлтә иде. Хәзер инде ул социаль сыйфатларны табу белән генә чикләнми. Ул, образның тагы да эченәрәк үтеп, героеның тирәндәрәк яткан рухи тормышын күрсәтергә омтыла.

«Хат ташучы» поэмасында (1938) Тимербулат һәм Фәйрүзә образлары, мәхәббәт хисләре кызыклы халәтләрдә, рухи кичерешләре тулылыгында ачылганга күрә дә җанлы кешеләргә хас сыйфатлары белән күз алдына басалар, шул яклары белән үзләренә тарталар.

Шул ук вакытта әдәбиятны чикләүче норматив кысалар шагыйрьнең сурәтле фикерләвен дә кыршауда тота. М. Җәлил

әлеге характерны бөтен тулылыгында күрсәтә алырдай кискен конфликтларны әсәренә кертә алмый, чынбарлыкта тулып яткан драматик коллизияләрне читтә калдырып, тормышны җиңелләштереп сурәтләргә мәҗбүр була. Шуңа күрә, поэмаларында геройның психологиясенә игътибар артса да, характерны тирәнәйтүче тарихи шартлар әсәргә керми калу нәтиҗәсендә, шагыйрь тормыш дөреслеген тулы күрсәтүгә ирешә алмый. Җиңел коллизияләрне тасвирлап туйгач, әсәрен Сталинга мәдхия уку белән тәмамларга мәҗбүр була.

Сурәтлелекне баетуның юлларын ул фольклордан да, тарихтан да, телдән дә, музыкадан да эзли. Бу эзләнүләр шагыйрьне төрле яктан баеталар. Шушы эзләнүләр җирлегендә иҗатында тарихка һәм фольклорга караган яңа темалар туа («Алтынчәч»), таланты яңа жанрларда ачылып китә (драматик поэма, опера либреттосы), сурәтләү алымнары да төрләнә, стиле байый.

Җәлил шигырьләрендә музыкальлек арта баруы да аның музыка һәм фольклор белән бәйләнешләренең көчәюенә бәйле. Фольклор, музыка белән бәйләнешләренең уңай нәтиҗәсе бигрәк тә «Алтынчәч» драматик поэмасында күренде. Шушы әсәрне нигезгә алып, композитор Нәҗип Җиһанов «Алтынчәч» операсын иҗат итә. Ул татар халкының профессиональ музыка өлкәсендәге олы казанышы буларак кабул ителә. Хәзер дә мәдәният тарихында ул шулай бәяләнә.

«Алтынчәч» поэмасын Җәлил татар һәм башкорт әкиятләренә, легендаларына нигезләп яза. Нигезгә «Җик Мәргән» эпосын һәм «Алтынчәч» әкиятен сала. Башка әкиятләрдән дә файдалана. Халык иҗатындагы фантазия киңлеге, вакыйгаларның масштаблылыгы, образларның символик мәгънә белән дә яктыртылулары шагыйрьне дә халыкта сыналган юллардан атларга этәрә. Әсәрнең төп идеясен шагыйрь үзе болай билгели: «Либреттоның төп идеясе — халыкның үлемсезлеген һәм үзенең бәхете өчен властьның кара көчләренә, ирексезлеккә һәм коллыкка каршы көрәш омтылышын күрсәтү». Аның бу сүзләреннән дә әсәр идеясенең шул чор өчен гаять кыю һәм көтелмәгәнчә яңгыравын күрергә мөмкин. Җәлил үзе дә әсәренең бер үзенчәлеге итеп андагы образларның «әсәрнең эчтәлеген тәшкил иткән философик идеяләрне гәүдәләндерүче гомумиләштерелгән образ-характерлар булып» эшләнүләрен күрсәтә. Тугзак, Җик, Алтынчәч, Кулупай образларында гомумиләштерү аеруча көчле, хәтта алар символик

образлар дәрәҗәсенә күтәреләләр. Кол халыкның — Бураш картның — кызы Алтынчәч символик планда халыкның ирекә омтылу, азатлык идеалын гәүдәләндерә. Хакимият әһелләре халыкның «бәхет кошы»н хан сараеның бизәге итәр өчен тырыша. «Бәхет кошы»на кул сузган кара көчләр белән киеренке көрәш бара, һәм бу көрәш халыкның җиңүе белән тәмамлана.

Әсәрнең эчке темасы киң фәлсәфи мәгънәле, символик яңгырашлы. Ул шул ягы белән шагыйрь иҗат иткән вакытта да халыкның ирекә, мөстәкыйльлеккә сусаган җан авазы булып яңгырады.

Ватан сугышы елларында исә аның эчтәлеге фашизмга каршы көрәш пафосы белән кушылып китте, халыкларның үз ватаннары, «бәхет кошы»н саклау өчен алып барган изге көрәше буларак яңгырады. Операның хәзерге куелышында да бүгенге заман белән кисешкән күп урыннарын табарга була.

Образның шундый ике планлылыгын (конкрет һәм символик) куллану шагыйрьнең үзе өчен дә файдалы тәҗрибә булды. Шуңа да ул сугыш чоры иҗатында бу алымга бик еш мөрәҗәгать итте.

Шул рәвешчә, М. Җәлилнең Ватан сугышына кадәрге иҗатын бер ноктада тукталып калган итеп күзаллау, үз чорының «уңай» тенденцияләрен генә чагылдырган итеп күрергә теләү, шул чор сәясәтенең тәңгәл чагылышы итеп кенә бәяләү дөреслеккә, чынлыкка туры килми. Ул — үз чорының талантлы улы, шагыйрь улы.

Сораулар һәм биремнәр

1. М. Җәлилнең «Тормыш юлым» исемле автобиографик очеркыннан һәм аның турындагы хезмәтләрдән файдаланып, шагыйрьнең кыскача тормыш һәм иҗат елъязмасын төзегез. М. Җәлил турында элекке дәресләрдә үткәннәрне искә төшерегез.

2. Җәлилнең 20—30 нчы еллардагы иҗатын шул чорда хакимлек иткән рәсми идеология һәм хөкүмәт сәясәте белән тәңгәлләштереп карау, шул нигездә әдәби кыйммәтен түбәнсетергә омтылу күренешләре ни өчен дөрес түгел?

3. Шагыйрьнең дөньяга карашының идеологик нигезләре турында сөйләгез. Социализм идеологиясенә килүенең тарихи заруриятен аңлатыгыз. Шул чор идеологиясенең тәэсире аның иҗатында нинди яклары белән чагыла?

4. Шагыйрьнең революцияне сурәтләвендәге үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

5. Шагыйрьнең тормышны тулылыгында кабул итәргә омтылуы нәрсәләрдә күренә? Ни өчен күп әсәрләре үз вакытында басылмый?

6. М. Җәлилнең 30 нчы еллар иҗатында туган яңалыклар нидән гыйбарәт?

7. «М. Җәлил һәм музыка» дигән темага сөйләшү-әңгәмә яки әдәби-музыкаль кичә уздырыгыз.

8. «Алтынчәч» әсәренең жанр үзенчәлекләрен, әсәрнең идея эчтәлеген авторның ничек билгеләве турында сөйләгез. Әсәрнең идея эчтәлеге ни өчен, әсәрнең кайчан сәхнәгә куелуына карап, төрлечә яңгырый? Монда артист, режиссёр һәм авторның ни рәвешле катнашуларын, әсәрнең һәм заманның моңа нинди мөмкинлек бирүен ачарга омтылыгыз.

Сугыш чоры иҗаты

Шагыйрь Бөек Ватан сугышын татар әдәбияты һәм сәнгатенең Мәскәүдә үткәреләчәк декадасына әзерлек алып барган көннәрдә каршылый. Ә «Алтынчәч» операсының премьерасын аңа Казан янындагы хәрби лагерьда хезмәт иткәндә тупчы солдат буларак тыңларга туры килә. 1943 елны Казанда басылып чыккан шигырьләр җыентыгын да үзенең солдат эшчәнлегенә бәйле рәвештә «Тупчы анты» дип атый.

Шагыйрь сугышка кадәр үк дөньяның сәяси картасында туган үзгәрешләрне үткер күзләре белән күзәтеп килде, фашизмның баш калкытуын күреп, хәвефләнүле шигырьләрен язды. Фашизм белән көрәшкә, батырлыкка ул рухи яктан алдан ук әзерләнеп, идея ягыннан чыныгу алып килде. Шуңа күрә сугыш башлану белән үзен солдат итеп хис итте, үзен дә, иҗатын да фашизм белән көрәшкә багышлады. «Әйдә, җырым!» шигырендә ул сугыш башлангач туган рухи халәтен түбәндәгечә билгеләде:

Вакыт җитте...
Хәзер ярты юлда
Куеп торып тыныч эшемне,
Багышларга Ватан сугышына
Үземне һәм каләм көчемне.
Каләмемне салдым юл сумкама,
Автоматым тактым аркама.
Фашистларга каршы пуля һәм җыр
Бил каешымда бергә саклана.

Шул көннәрдән үк ул батырлыкка юл башлый, дөресрәге, 1919 елда башлаган һәм сайлаган төп юлын дәвам итә. Юл-

ның авыр булачагын да, үлем белән тәмамлану ихтималын да белә. Аның күңелен электән үк (20 нче елларда ук) кабул иткән антын — халкына, Ватанына тугрылыклы хезмәт итү антын — ничек итеп яхшырак үтәү мәсьәләсе борчый.

Без шагыйрьнең беренче вазифасын матурлык дөньясын ачуда күрәбез. Хәзер инде шагыйрьгә матурлыкны сугыш дәһшәтләре аша ачу бурычы йөкләнә.

М. Җәлилнең шигърияте матурлыкны сугыш дәһшәтләре аша сынауның төрле этапларын үтә. Солдат-фронтовик лирикасының баштагы чоры чакыру һәм өндәүле публицистик рухының көчлелеге белән аерылып тора. Сугышның беренче айларында язылган шигырьләрендә фикер һәм хис турыдан-туры, ачыктан-ачык өндәү һәм чакыру рәвешендә, публицистик кайнарлык белән ачыла. Ул халыкны изге көрәшкә чакыра, бөтен көчне дошманны җиңү өчен тупларга өнди. Шагыйрь «котырынган этнең безнең корыч сафка таш маңгаен бәреп ярачагына» нык ышана. Сурәтләү чараларының берелешендә дә үзенчәлек бар: тойгыга тәэсир итә, фашистларга каршы нәфрәт хисен ачыктан-ачык кычкырып сөйли торган эпитетлар, метафоралар сайлана. Фашистлар, мәсәлән, «котырган эт», «бирән», «мисез Гитлер» дип аталалар.

Сугыш башлангач ук язылган шигырьләрендә күренгән рухи тетрәнүне һәм публицистик кайнарлыкны тора-бара сабыр акыллылык алыштыра. Туры сызыклы агитацияне сугыш дәһшәтенә эләккән гади солдатның рухи кичерешләренә тирәнрәк керергә омтылышы җиңә бара.

Җәлилнең хатлар рәвешендә язылган шигырьләрендә кичерешләр эчкерсез самимилекләре белән, тирән лирик тойгы булып ачылалар. Шушы самимилек аның шигырьләрен тагы да тәэсирле итә, җылыта, баета. «Хуш, акыллым (Әминәгә истәлек)» шигыре бу яктан аеруча үзенчәлекле.

Хуш, акыллым, әгәр кайталмасам,
Яраланып юлда егылсам,
Йөрәгемдә саклап ялкыныңны,
Акрын-акрын тәнем суынса,
Хуш, акыллым!
Соңгы минутта да
Мин уйлармын синең турында,
Уйлар минем туңган күкрәгемне
Җылытырлар синең куенында.

Үзенең тормыш иптәшенә язган шигъри хатында интим хисләр турында сүз бара. Әмма биредә шунысы үзенчәлекле: интим тойгылар Ватан язмышы белән тыгыз бәйләнештә биреләләр, аларны бер-береннән аерып караву кыен.

Ахыр чиктә синең саф сөюең
Җиңеләйтер үлем газабын;
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җырга язармын,—

ди шагыйрь. Югары патриотик тойгылар, идеяләр бик табигый рәвештә интим сөйләшү темасына әйләнеп китәләр. Шуны ук «Окоптан хат» шигырендә дә ачык күрергә мөмкин. Шигырь сугышчы шагыйрьнең тылдагы дусына җавап хаты рәвешендә язылган. «Каска», «Күпер» шигырьләрендә сугышчы фронт шартларындагы батырлыгы белән ачылса, биредә инде ул тар окопта уйланган, үзе һәм тормыш турында фикер йөрткән хәлдә күренә.

1941 елның декабрендә хәрби-сәяси курсны тәмамлаганнан соң, Җәлил өлкән политрук исеме ала һәм Волхов фронтына җибәрелә. Биредә ул «Отвага» газетасында эшли. «Шушы көннәрдә генә 10 көнлек командировкадан, фронтның алгы сызыгындагы частьларда аерым задание үтәп кайттым,— дип хәбәр итә ул бер хатында.— Бик авыр, хәтәр эш иде... Гел ут астында йөрергә туры килде. Өч көн рәттән диярлек йокламадым. Ләкин бик күп күреп кайттым». «Минем тормыш,— дип яза Җәлил 1942 елның маенда,—хәзер хәрби обстановкада тыгыз эш белән һәм походта уза. Шунлыктан мин хәзергә фронт лирикасы белән генә чикләнәм, ә инде зур әйберләр язарга, исән калсам, җиңүдән соң керешермен. Минемчә, фронт лирикасы да,— бигрәк тә хәзер, кирәкле һәм мөһим жанр».

Җәлил фронт лирикасының «кирәкле һәм мөһим жанр» булуын дөрес билгели. Сугышта шагыйрь сүзе зур көчкә — оештыручы, көрәшкә җитәкләүче көчкә әверелә. Җәлил сугышчыларның героик вакыйгалар белән тулы тормышларын сурәтли («Тел», «Күпер» һ.б.). Фронттан язган соңгы хатларының берсендә үзендә тәмамланып бетмәгән әсәрләре барлыгын («Соңгы патрон турында баллада», «Төш», «Үлем походы») һәм аларны җибәрәчәген хәбәр итә. Әмма фронт хәлләренең үзгәреп китүе һәм шагыйрьнең, көтелмәгән хәлләргә очрап, фашистлар кулына эләгүе сәбәпле, ул әсәрләр җибәрелми һәм дөнья күрми кала.

* * *

1942 елның июненнән Җәлилнең гыйбрәт итеп сөйләрлек кыю һәм тәвәккәл, маҗаралы героик тормышы башлана.

Шагыйрь үзенең тоткынлыктагы тормышын әкияттәге серле йомгак белән чагыштыра:

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда,
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

Язучыларның, галимнәрнең, җәмәгатьчелекнең тырышлыгы белән бу «йомгак»ның байтак серләре ачылды инде.

1945 елның апрелендә совет солдатлары Моабит төрмәсенең ишегалдында Җәлилнең ниндидер китап битенә язып калдырган хатын табалар (шагыйрь анда үзен үлемгә хөкем иткәннәрен хәбәр иткән була). Күрсәтелгән адресы буенча хатны Мәскәүгә, Язучылар союзына — А. Фадеевка җибәрәләр. Шул вакытларда «Правда» газетасы хәбәрчесе Юрий Корольков, төрмә белән танышып йөргәндә, 382 нче камера стенасында түбәндәге язуны күрә: «Без кырык үлем аша үттек, әмма буйсынмадык. Муса Җәлил...» һәм әлеге язу турында Әминә ханым Җәлиловага хәбәр итә. Аннары туган илгә шагыйрьнең шигырьләре кайтып төшә. Җәлил белән бергә көрәшкән, исән калган дуслары-көрәштәшләре табыш бирә... Эзләнү, тикшеренүләр башлана. Төрмәдә бергә утырган һәм шагыйрьнең соңгы айларын, көннәрен күргән хәрби әсир итальян Рениеро Ланфредини белән Бельгия патриоты Андре Тиммерманс та табыла. Фашистлар архивында сакланган документлар да җәлилчеләрнең көрәше турында күп нәрсә сөйли. Хәзер инде Җәлил һәм аның иптәшләренең көрәше турында күп нәрсә ачыкланды.

Җәлилнең Германия үзәгендә — Берлинда — фашистларга хезмәт итәргә ризалык биргән булып, аларны алдалап, фашистларга каршы яшерен фронт (яшерен оешма) оештыруга катнашуы, аның җырлары фашистларның баш очында, чынлап та, «бомба булып ярылуы» мәгълүм.

Фашистларга каршы М. Җәлил ялгыз гына көрәшмәгән. Аның А. Алиш, Г. Курмашев кебек ышанычлы көрәштәш дуслары күп булган.

Җәлил яшерен патриотик оешмага 1943 елның башларыннан катнаша. Аны әсирлеккә эләккән совет офицерлары оештыра. Оешма әсирләр арасында совет пропагандасын тара-

та, фашизмга каршы төрле юллар белән эш алып бара, әсирләрне актив көрәшкә әзерли. Яшерен оешма әгъзалары татар, чуваш, башкорт хәрби әсирләре урнашкан Свинемюнде һәм Крушино лагеренда да, Дрезденда да булганнар. Бельгияле Андре Тиммерманс җәлилчеләрнең Гамбургта да эш алып баруларын сөйли. Яшерен оешма Польшадагы Познань шәһәрендә хәрби заводларда эшләүче совет әсирләре арасында да үз кешеләрен булдырган.

Җәлилчеләрнең бер төркеме үз эшчәнлеген Берлинда җәелдереп җибәрә. Оешманың бер төркеме Польшадагы Радом лагеренда актив эш алып барган. Берлинда басылган листовкалар татар әсирләре арасында таратылган.

Оешманың эше нәтиҗәсез калмый. 1943 елның язында белорус партизаннарына каршы көрәшер өчен җибәрелгән татар әсирләренең бер батальоны баш күтәрә, фашист офицерларын кырып, партизаннарга барып кушыла. Немец журналисты Леон Небенцаль үз тикшеренүләрендә легиондагы башка батальоннарның да фашистлар өчен «иң ышанычсыз булып танылулары» турында яза.

Радомда «артистлар» труппасы хәрәкәт иткән. Концерт вакытларында алар Җәлилнең патриотик җырларын җырлаганнар, шигырьләрен укыганнар. Җәлил шигырьләре әсирләрнең күңел түрләрендә урын алган. Алар, кулдан-кулга, телдән-телгә күчеп, фашистларга каршы нәфрәт хисләрен көчәйткәннәр, әсирләрне гитлерчыларга каршы көрәшкә туплаганнар. Бу чорда язылган шигырьләрне бер шигъри бәйләм итеп карарга мөмкин.

Яшерен оешма 1943 елның 14 августында әсирләрне коралллы восстаниегә күтәрү өчен әзерлек алып бара. Шушы максат белән июль ахырында «Бөркет» (Җәлилнең оешмадагы яшерен кушаматы) Радомга килә. Поляк партизаннары да булышырга булалар. Ләкин гестапо оешманың эзенә төшә, һәм җәлилчеләр восстаниегә берничә көн калганда кулга алыналар.

Төрмәдә тикшерү вакытында да, үлем көткәндә дә, Җәлил үзен батырларча тоткан, тиңдәшсез рухи ныклык күрсәткән. Андре Тиммерманс аның турында: «Мин кабатлап әйтәм: ул бик тыныч һәм батыр кеше, яхшы кеше иде»,— дип сөйли. Төрмә шартларында да ул иҗат эшеннән туктамый, үзенең хисләрен шигырь итеп кәгазь кисәкләренә терки.

1944 елның февралендә Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була. Империя баш хәрби суды аларны,

«дәүләткә каршы җимерү эше» алып барганнары өчен, үлем җәзасына хөкем итә. Үлем карары шул елның 25 августында тормышка ашырыла. Төрмәдәге Италия әсире үзенең көндәлегенә шаһитларның «татарлар елмаеп, батырларча үлделәр» дип сөйләгәннәрен язган.

Немец публицисты Леон Небенцаль 1968 елны Шарлоттенбург округының загс бүлегендә җәлилчеләрнең үлеме турында таныклыклар таба. Анда Плетцензее төрмәсендә 11 җәлилченең гильотинада үтерелүе сәгать һәм минутларына кадәр төгәллек белән теркәлгән. Менә аларның исем-фамилияләре: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Гайнан Курмашев, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Габдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Фоат Сәйфелмөлеков, Әхмәт Әндәшев, Сәлим Бухаров.

1956 елның 2 февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Муса Җәлилгә Бөек Ватан сугышында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Җәлил белән бергә башлары гильотинада киселгән 10 каһарман егет соңлап булса да (1991 елны) I дәрәҗәле Ватан сугышы ордены белән бүләкләнделәр. 1994 елны җәлилчеләрнең батырлыгын тану буенча тагын бер яңалык булды: Казандагы Җәлил һәйкәле янына аның белән бергә һәлак булганнарның барельефлары куелды, исемнәре ташка уелды. Үтерелгәннән соң, нәкъ ярты гасыр үткән көндә — 25 августта — мемориаль ансамбль ачылды.

Бу уңайдан сездә шундый сорауларның тууы бик табигый:

М. Җәлилнең фаҗигале язмышы һәм әсәрләре сугыш тәмамлану белән үк билгеле булса да, хәтта төрмәдә язган шигырьләре 1948 елгы мәктәп дәреслекләрендә урын алса да, ни өчен аның һәм көрәштәшләренең каһарманлыгын тану һәм бәяләү шулай озакка сузыла? Җәлил шигырьләре дәреслекләрдән алына, исән җәлилчеләр совет төрмәләрендә интегә?

Моның иң төп сәбәпләрен шул чордагы дәүләт сәясәтеннән, әсирләргә карата Сталин кулланган сәясәттән һәм аның әсирләргә карата кешелексез, вәхши күрсәтмәләренең (әсир булган өчен генә сәяси гаепле санау) хакимият даирәләрендә тирән тамыр җибәрүеннән, бу карашларның Сталин үлгәннән соң да җәмгыятьтә күпмедер дәрәҗәдә дәвам итүеннән эзләргә кирәк. Моның татар халкына мөнәсәбәтле башка сәбәпләре дә бардыр. Кыскасы, күмәк батырлык үрнәкләре тарихта күп түгел. Җәлил һәм җәлилчеләрнең батырлыгы әнә шундый

сирәк очрый торган батырлыкка тиң. Алар халык батырлыгының символы дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Җәлил, шушы батырлык турында шигъри тел белән дә сөйләп, үлмәс шигырьләр калдырды.

* * *

«Моабит дәфтәрләре» — шартлы исем. Бу исемне Җәлил үзе куймаган. Моабит төрмәсендә дәфтәрләргә теркәлүеннән һәм байтагының төрмәдә иҗат ителүеннән чыгып, җыентык шул исем белән атала башлый.

Шагыйрьнең һәм әсирләрнең фашист тоткынлыгындагы батырлыгы турында иң элек шушы шигырьләр сөйләде.

Дәфтәрләргә теркәлгән шигырьләрнең байтагы, яшерен оешма ачылып, шагыйрь төрмәгә ябылганнан соң — 1943 елның августыннан соң иҗат ителгән.

Туган илгә Җәлилнең ике дәфтәре кайтты. Шигырьләренең язылу тарихлары гаҗәпләндергән кебек, бу ике дәфтәрнең язмышы да гаять гыйбрәтле.

Җәлил фашист тоткынлыгында иҗат иткән шигырьләрнең беренче дәфтәре катлаулы юллар аша Казанга 1946 елны кайтып җитә. Аны Җәлилләр утырган төрмәдән 1944 елның февралендә алып чыгалар. Франциягә аны Габбас Шәрипов алып килә. Франциядәге Ле-пюи лагерендагы татар әсирләре кулына килеп эләккән ул шигырьләр югалмый. Аларны Нигъмәт Терегулов күчереп ала һәм француз партизанкасына сакларга бирә. Алар сугыш тәмамланганчы аңарда саклана. Туган иленә кайткан әсир Нигъмәт Терегулов үзе белән бергә Җәлил, Алиш шигырьләрен дә алып кайта һәм 1946 елда Татарстан Язучылар союзына тапшыра.

Икенче дәфтәр дә катлаулы һәм авыр юл үтә. Анысын фашизмны дошман күрүче Бельгия патриотлары саклап кала. Җәлил бу дәфтәрен үзе белән бер камерада утырып дуслашкан бельгияле Андре Тиммерманска Моабит төрмәсендә, үзен судка җибәрүдән ярты ай гына элек тапшыра. Андре ул шигырьләрне саклый һәм үз әйберләре белән бергә әнисенә — Бельгиягә җибәрә. Әнисе аны улының әманәте итеп сугыш беткәнче саклый. Андрега үз өенә исән-сау кайтырга насыйп була. Камерадаш дустының васыятен үтәп, дәфтәрне 1947 елда Брюссельдагы совет илчелеге аша Мәскәүгә — СССР Язучылар союзына җибәрә.

Шулай итеп, төрле ил, төрле милләт халыкларының ярдәме белән Җәлилнең ике дәфтәргә теркәлгән 94 шигыре туган иленә кайтып җитә.

Җәлилнең тоткынлыкта иҗат иткән әсәрләре, әлбәттә, болар белән генә чикләнми. Ул үзе үк, мәсәлән, бер дәфтәр битенә:

«Әсирлектә һәм тоткынлыкта 1942, IX—1943, XI арасында язганнарым — 125 шигырь һәм поэма. Ләкин кая языйм?— Үзем белән бергә үләләр»,— дип язып куйган. Җәлил, дәфтәрләрдән күренгәнчә, 1942 елның сентябренә кадәр дә, 1943 елның ноябреннән соң да шигырьләр иҗат иткән. Мәсәлән, «Яңа ел теләкләре» шигыре (мәгълүм соңгы шигыре) 1944 елның гыйнварында язылган. Ә бит хөкем карары августта гына үтәлә. Соңгы сигез айда да ул иҗат иткән. Истәлекләрдә Җәлилнең тагын берничә дәфтәре булуы турында фактлар китерелә. Әмма ул дәфтәрләрнең әлегә табылганнары юк.

Җәлил шигырьләрен әсирләр кулдан-кулга күчереп йөрткәннәр, ятлаганнар. Исән-сау калган җәлилчеләр шагыйрьнең кайбер шигырьләрен хәтерләрендә саклап алып кайттылар. Кайбер шигырьләре соңгы елларда да табылды. Шулай да Җәлилнең тоткынлыкта язган аерым әсәрләре билгеле түгел әле. Аларны эзләү дәвам итә.

«Тупчы анты» җыентыгында шагыйрь иле һәм халкы алдында дошманнарга каршы соңгы тамчы канынача, соңгы сулышынача көрәшергә шигъри ант бирсә, «Моабит дәфтәрләре»ндә шушы антның көтелмәгән авыр һәм фаҗигале хәлләрдә ничек үтәлүе турында сөйли.

«Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләр язылу вакытына карап урнаштырылган. Ә менә Тиммерманска тапшырган дәфтәрендә шагыйрь, бу тәртипне сакламыйча, беренче шигырь итеп 1943 елның 26 ноябрендә язылган «Җырларым» шигырен куйган. Һәм хәзер дә ул җыентыкларда беренче урында басыла. Җәлил аны үзенең иҗат программасын тәшкил иткән, бөтен иҗат һәм тормыш юлын йомгаклый торган шигыре итеп санаган. Әйтерсең лә шагыйрь иленә һәм халкына биргән изге анты үтәлү турында соңгы минутларында шигъри рапорт бирә:

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигъремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны токкан килеш языла.

Җәлил шигырьләренең яшәү көче — аларның ил һәм халык тормышына аерылгысыз тоташуларында, «йөрәге һәм хаклык кушканны» җырда ялкын итеп кабызуда.

Шигъремдәге чынлык, ут һәм сөю —
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе,—

ди шагыйрь.

«Моабит дәфтәрләре»нең сәнгатьчә байлыгы — шагыйрь характерының ныклыгында һәм шагыйрьнең рухи байлыгында. Ул шигырьләрдә шагыйрьнең корыч кебек нык характеры, гаҗәеп кешелекле бай рухи дөньясы ачыла.

Җәлил «Кошчык» шигырендә (1942) фашистлар кулына тоткын булып эләккән, «аяк-куллары чәнечкеле чыбык белән бәйләнгән», әмма рухы богауланмаган шагыйрь образын сурәтләде. Шигырьнең беренче строфалары тоткынлыкның физик һәм рухи газаплары белән таныштыра. Бу күренешне шагыйрь ирек һәм коллыкны каршы кую (антитеза), ирек вәкиле кошчыкны әсирләр белән очраштыру, аңа мөрәҗәгать итеп эндәшү кебек төрле поэтик алымнар ярдәмендә ача:

Кояш чыга койма аръягында,
Күрше кырлар нурга коена.
Тик, нигәдер, аның нуры безгә
Тими үткән төсле тоела.

Әсирләр тормышына хас детальләр белән бергә, шагыйрь гомумиләштерүнең шартлы сурәтләү чараларын, символик, аллегорик образларны да мул куллана. Кошчык — әнә шундый символик образ дәрәҗәсенә күтәрелгән сурәт. Ул башта тоткынлыкның хисси конкрет сыйфатын тудырырга ярдәм иткән образ булып күренә. Бу кошка әсир шагыйрь:

Керә күрмә, безнең кан-яшь йотып
Интеккәнне үзең күргәнсең,—

дип эндәшә. Ирекле кошчыкның соңгы кабат килүе шагыйрьдә «мәгъруp җанның соңгы теләген» әйтү ниятен уята. Шигырь реаль планнан шартлы сурәтләүгә күчеп китә. Кошчык образы әкияттәге тылсымлы бер көчкә әверелгән кебек. Ул тот-

кын шагыйрьнең нәфрәт һәм мәхәббәт җырын гәүдәләндергән символик образга әйләнә:

Ук шикелле үткен канатыңнан,
Таң шикелле якты җырыңнан
Таныр сине халкым:
«Бу, дип, аның
Соңгы җыры көрәш кырыннан...»

«Катыйльгә», «Дуска», «Батырлык турында» кебек лирик шигырьләрендә дә (1943) шагыйрьнең көрәш рухы белән сугарылган образы, батырлык фәлсәфәсе ачыла. Бу шигырьләрнең күп юллары хикмәтле сүз, афоризм булып яңгырый.

1942 елның 12 гыйнварында тормыш иптәше Әминәгә җибәргән хатында Җәлил яшәүнең мәгънәсе турында болай дип язган: «Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк: үлгәннән соң да үлмәслек булсын, яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени?! Без үлемнән курыкмыйбыз дип әйтәбез икән, бу без яшәргә теләмибез, безгә һәммәсе барыбер дигән сүз түгел әле. Һич алай түгел. Без тормышны бик яратабыз, яшәргә телибез һәм шуңа күрә дә үлемгә җирәнеп карыйбыз. Әгәр дә синең үлемең кирәк икән (Ватан өчен сугышта) һәм Ватан өчен үзең теләп кабул иткән бу данлы үлем картлык көннәреңә кадәр булган утыз-кырык еллык тыныч хезмәттә үткән гомереңне каплый ала икән, мин иртә һәлак булдым дип кайгырырга һичбер сәбәп юк...»

* * *

Фашистлар үзләренең ерткычлыгы, кансызлыклары белән XX гасыр вәхшиләре булып танылдылар. Сугыш кырында миллионнарча кешеләр һәлак булды, миллионнарча кешеләр концлагерьларда ачлыктан, авырулардан кырылды, бер сәбәпсез үтерелде, крематорийларда яндырылды.

Җәлил шигырьләрендә шушы миллионнарча корбаннарның күңелне тетрәткеч авазлары яңгырый. Шагыйрь шул корбаннар исеменнән дә сөйли, гаепли:

Килер ул көн, халык хөкем итәр,
Карар булыр кискен һәм кыска.
Каным белән язган соңгы җырым,
Бул гаепләү акты фашистка! —

дип яза ул «Хөкем алдыннан» шигырендә (1943).

«Бүреләр» исемле (1943) шигырьнең нигезендә кешеләр үзләренең вәхшилекләре белән хәтта ерткыч хайваннардан да уздыралар дигән фикер ята. Бу фикерне шагыйрь канлы сугыш кырын тасвирлау һәм шунда ике ерткычны — бүреләрне һәм кешеләрне — очраштыру, аларның яралыга мөнәсәбәте аша күрсәтә.

Кан кою күренешенә бүреләрне куеп сурәтләүнең тирән мәгънәсе бар. Бүреләр, кан коючы ерткычлар булсалар да, гадәттә, алар сугыш барган җирдән, ату тавышларыннан качып китәләр.

Ләкин шагыйрьгә, табигатьнең шушы кечкенә төгәллеген саклауга караганда, тормышның зур хакыйкатен ачу әһәмиятлерәк. Шуңа күрә ул бүреләрне сугыш кырына, «меңнәрчә гомерләр киселгән» урынга күчерә, кешеләр «каныннан исереп» йөрүләрен тасвирлый. Шушы күренешләрдә үк кан коюның кешеләр өчен мәгънәсезлеге ачыла, кешеләрнең, «төн буе атышып», бер-берсен һәлак итүләре бүреләрнең ерткыч табигате белән чагыштырыла. Таң белән сугыш кырына кешеләр килә. Алар, яралының яшәргә өметле икәнен күрү белән, егетнең «тәненә кыздырып шомполлар басалар», соңыннан ак каенга асалар. Шагыйрь сугыш кырын һәм бүреләрне параллель сурәтләгән беренче строфаны яңадан тулысы белән кабатлый. Ләкин бу юлы инде чагыштыру бөтенләй икенче мәгънә ала. Беренчесендә кешеләрнең кан коюлары бүреләр белән чагыштырылса, хәзер инде кешеләр бүреләргә караганда да ерткычрак дигән фикер китерелә.

«Вәхшәт» шигырендә дә, фашистларның вәхшәтен хисси яктан тагын да көчлерәк ачу һәм шигырьнең фикерен тирәнәйтү өчен, табигать күренешләренә урын бирелә. Ату-үтерүләрне күргән Җир-ана балалар кебек үкси-үкси яшь түгә, көзге урман нәфрәтеннән шашып шаулый:

> Күк күкрәде кинәт, җил сызгырды,
> Җир елады кысып тешләрен.
> Нинди ачы бу яшь, нинди кайнар!..
> Нишләдең син, Җирем, нишләдең?

Җәлил бу вәхшәтне, гомумән, сугышны тарихның, кешелекнең олы фаҗигасе итеп күрә һәм шигырен шушы вәхшилеккә каршы юнәлгән сугышчан чакыру белән тәмамлый. Бу шагыйрьнең сугышны танып белүдәге һәм сурәтләүдәге яңалыгы булды.

Шигырьдәге эпитетлар да авторның мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. Җәлил, мәсәлән, фашист майорын «бакыр күзле» дип атый. Бу — оста тотып алынган портрет детале. Ул деталь фашистның кансызлыгы турында сөйли, кешелексезлегенә ишарә ясый. «Кургаш болытлар», «моңлы кояш» кебек эпитетлар да сурәтләнгән күренешнең киеренкелегенә туры килә.

Кешелеккә фашизмның нинди вәхшәт китерүен Җәлил әнә шундый сәнгатьчә югарылыкта ачты.

* * *

«Моабит дәфтәрләре»ннән шагыйрьнең мәһабәт образы алга баса. Рухының бөеклеге белән ул халык хыялында туган әкият геройларын хәтерләтә. Шуңа да аны Данко, Прометей, Алып батырларга охшатып сөйлиләр. Әмма Җәлил ул геройлардан үзенең гади җир улы булуы белән аерылып тора. Кылган эшләре, батырлыклары — җир кешесенеке, кичерешләре — җир улыныкы.

Җәлил дөньяның матурлыгын тулылыгы белән, җирнең күркәмлеген сафлыгы белән кабул итә. Шуңа да аның поэзиясенә тормыш тулылыгы хас. Аның поэзиясе тормыш кебек төрле, күп буяулы.

Авыр сынау шартларында Җәлилнең гади җир кешесенә хас сыйфатлары мул булып ачылып китә. Вакыты белән аны ачы сагыш хисләре биләп ала. Вакыты белән күз яшьләре дә күренә. Кайчагында ул ярсу, кайвакытта тыныч, уйчан, сабыр. Кайчагында хәзерге хәленең аянычлы язмышын уйлап әрни, сызлана, кайчагында күңеле киләчәккә омтыла, татлы хыялларга бирелә, сугыштан соңгы тыныч көннәрне күз алдына китерә.

Төрмәнең караңгы, тар таш бүлмәсендә бөтен Җир шарын йөрәгенә сыйдырган нечкә күңелле, кешелекле шагыйрь яши. Үзенең үләсен белеп, дөньяның олылыгын тоеп, киләчәкнең үзе көткәнчә булачагына ышанып яши. Яши генә түгел, көрәшә: шигъри сүзе белән, фәлсәфәсе, хисләре, мәхәббәте белән...

Ватанга мәхәббәт һәм сөйгәненә мәхәббәт аның йөрәгендә бергә яши:

Илдән киттем ил һәм синең өчен,
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алыштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?!

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән», — дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

«Моабит дәфтәрләре» — Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Сугышка кадәрге иҗатында ирешелгән казанышлар биредә тагын да үстерелде, баетылды. Шагыйрьнең сугыш эчендә, кеше, солдат һәм әдип буларак, олы сынау үтүе, зур фаҗига кичерүе, искиткеч шартларда рухи көрәш алып баруы аның сәнгатьчә осталыгын да үткенәйтте, шигъри хисләрен дә яңа биеклеккә күтәрде.

Җәлил Ватаныннан, халкыннан аерылу сагышын, ялыктыргыч бикле тормыш эчендә яшәүдән, ирексезлек, тарлыктан туган рухи газапלануларын тирән кичергән. Ул фашистларның тел белән аңлатып бирә алмаслык вәхшилекләрен үз күзе белән күргән.

Татымадым элек мин һичкайчан
Мондый көчле, мондый әрнешле
Йөрәктәге дәртне һәм нәфрәтне,
Мәхәббәтне, үчне, сагышны! —

(«Авыру сызмалары»,1942)

дип язган шагыйрь. Шушы дәрт һәм нәфрәт, мәхәббәт һәм үч тойгылары «яраланган лачын йөрәктә» шигырь булып туган.

Әмма «Моабит дәфтәрләре»нең әһәмияте Җәлилнең билгесез язмышын ачыклау һәм аның дошман белән көрәштәге каһарманлыгын ачу белән генә чикләнми. Ул шигырьләр гаҗәп зур сәнгатьчә гомумиләштерү көченә ия.

Җәлил шигырьләре халкыбызның рухи дөньясына яңа байлыклар өстәде, әдәбиятыбыз мирасына кыйммәтле хәзинә булып керде һәм шагыйрьгә үлемсезлек алып килде.

Татар әдәбиятына шундый олы байлык биргән шагыйрь 1957 елда Ленин премиясе белән бүләкләнде.

Муса Җәлил татар халкының легендар улы булып танылды. Аның исеме белән шәһәр һәм колхозлар, теплоход һәм аерым коллективлар атала. Сыны һәйкәлләрдә гәүдәләнә, батырлыгы җырларда җырлана. Җәлил хәзер үзе әдәби геройга — поэма, кино, драма, роман, операларның героена әверелде. Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Д. Вәлиев аңа багышлап — пьесалар, ә Ш. Маннур, Г. Әпсәләмов роман-

нар яздылар. Татар язучылары гына түгел, рус, казах, калмык шагыйрьләре дә Җәлил турында поэмалар иҗат итте. Немец язучысы Эрих Мюллер пьеса һәм телевидение өчен сценарий язды, һәм ул Германиядә күрсәтелде. Н. Җиһановның «Җәлил» операсы (Ә. Фәйзи либреттосы) Мәскәүнең Зур театрында да, Чехословакиядә дә уңыш белән барды. «Ленфильм» студиясе «Моабит дәфтәре» исемле кино чыгарды.

Үзенең халыкчан иҗаты, үлемсез шигырьләре белән Муса Җәлил халкыбызның рухи тормышында бүген дә актив катнаша. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

(«Ышанма», 1943)

Җәлил әсәрләрен хәзер дөнья укучылары да белә. «Моабит дәфтәрләре» шагыйрьне әдәбиятның бөтендөнья орбитасына алып чыкты. Шундый тиз вакыт эчендә күп телләргә тәрҗемә ителеп, күп миллионлаган укучыларның мәхәббәтен яулап алган шагыйрьләр бик сирәк.

Җәлилнең һәлак булуына ун ел тулуга багышланган җыелышта азәрбайҗан халык шагыйре Сәмәд Вургун болай диде: «Исемнәрен сулмас иҗат гөлләре белән мәңгеләштереп киткән кешеләрне дөнья һәм дөнья әдәбияты күп белә. Әмма герой-шагыйрь Муса Җәлил кебек исемнәрен сулмас иҗат һәм героик үлем белән мәңгеләштереп киткән шагыйрьләр алай күп түгел. Бөек Байрон, Венгриянең данлыклы халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил — менә алар кемнәр!»

Күренекле француз язучысы Луи Арагон «Совет әдәбиятлары» исемле китабында Муса Җәлилгә аерым бүлек багышлады. Җәлил көрәшенең әһәмиятен Луи Арагон дөнья күләмендә башка халыкларның язмышлары белән тыгыз бәйләп аңлата. «Ул безнең өчен дә, французлар һәм чехлар өчен дә үлде... Муса Җәлил... Сез, Франция диварларында эленгән зур кызыл афишаларны оныткан кешеләр, бу исемне телләрегездә кабатлагыз»,— дип язды һәм татар шагыйренең исемен фашизмга каршы көрәштә һәлак булган француз геройлары белән янәшә куйды.

Бүгенге көрәштә Муса Җәлил дә үзенең шигырьләре белән бер сафта атлый. Ул якты һәм матур тойгылар тәрбияли, кешеләрдәге һәм тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрьнең фронт лирикасына нинди үзенчәлекләр хас?

2. «Моабит дәфтәрләре»нең язылу һәм басылу тарихы турында сөйләгез.

3. «Моабит дәфтәрләре» — Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы» дигән фикерне исбатлагыз.

4. «Моабит дәфтәрләре»нең тематик төрлелеген ачыгыз.

5. «Моабит дәфтәрләре»ндәге жанр төрлелегенә мисаллар китерегез һәм берничә әсәрне чагыштырып (мәсәлән, җыр, публицистик шигырь һәм баллада), жанрга нисбәтән сурәтләү чараларының үзгәрүен-аерымлыгын күрсәтегез.

6. М. Җәлилнең «Батырлык турында», «Кичер, илем» шигырьләрен ятлагыз.

7. «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Җәлил образы» дигән темага язма эш әзерләгез.

8. М. Җәлил иҗатының дөньякүләм әһәмиятен ничек аңлыйсыз?

Фатих Кәрим

(1909—1945)

Фатих Кәрим — татар шигъриятенең сәнгатьчә үсешен яңа, югары дәрәҗәгә күтәреп, гражданлык каһарманлыгы һәм шигъри батырлык күрсәтеп, милләтебезнең һәм аның сүз сәнгатенең йөз аклыгы булырлык мирас калдырып һәлак булган шагыйрь. Ул дөньяда бары тик 36 ел гына яшәде. Шуның дүрт елы төрмәдә, дүрт елы сугышта үткәнен исәпкә алсаң, аның гомере нинди кыска булганлыгын күрәсең. Аның һәлак булганына җитмеш ел була, әмма исеме теллә рдән төшми, киресенчә, еллар үткән саен, күңелләргә якыная бара. Ф. Кәрим — бүгенге укучыларның да замандашы, фикердәше.

Шигъри Дим буеның гүзәл табигате халкыбызның җырларында мактала. «Димдә тудым, Димдә үстем, җиләк җыйдым тугайда...» Бу җырны Ф. Кәрим дә яратып җырлаган. Башкача булуы да мөмкин түгел. Чөнки бу җыр әйтерсең лә аның үзе турында. Ул да, җырда әйтелгәнчә, Дим буендагы Ает авылында туган, шунда үскән, бик күп хәсрәтләр күрергә өлгергән.

Ул шагыйрь җанлы булып ата-ана нигезендә үк ачыла башлый. Үзе искә төшергәнчә, аның әдәбият белән кызыксынуы, әтисе үлгәч, һәр көнне, әнисен елата-елата, аңа «Сак-Сок» бәетен укуы белән башлана. Бәләбәй педагогия техникумында укыганда кулъязма журналда әсәрләрен урнаштыра, 1924 елда Казанга килгәч, балалар матбугатында бастыра. Тора-бара бөтенләй газета-журналларда эшләүгә күчә. «Бала чагымнан ук,— ди ул,— мине хыялый рәвештә мавыктырган әдәбият мәйданына тәвәккәлләп адым ясадым. Шул

еллардан башлап, төрле шартлар эчендә туктаусыз әдәбият өлкәсендә эшлим».

Әйе, ул «төрле шартлар эчендә» иҗат итә. Ул «шартлар»ны өч өлешкә бүлеп карап булыр иде: 1922 елдан 1937 елга кадәр булганын — яшьлек романтикасы белән ашкынып иҗат итү; 1937—1941 еллар арасындагысын — нахак тоткынлык хәленә сыкрап-әрнү; 1941—1945 еллардагысын исә үзенең Ватанын яклап көрәшкән кешенең илһамлы йөрәк авазы дип атап була.

1933—1937 елларда, Татар дәүләт китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегенә җитәкчелек иткән вакытта, ул аеруча канатланып иҗат итә. Ләкин 1937 елда Ф. Кәрим рәсми хакимиятләр тарафыннан эзәрлекләнә башлый. Мулла улы буларак, имеш, ул сыйнфый көрәшкә зыян китергән: үзенең нинди катлам кешесе икәнен яшереп, комсомолга кергән, троцкийчылар белән элемтәдә торган.

Шагыйрь 1938 елның 3 гыйнварыннан тоткынлыкта була. 1939 елның 14 мартында хөкем була, аны ун елга Коми якларындагы төрмәгә җибәрәләр. Язучы К. Нәҗми, генерал Я. Чанышев һәм тагын кайбер башка кешеләр, шагыйрьне азат итүләрен сорап, югары хөкем һәм тикшерү органнарына хатлар юллыйлар. Сугыш башлангач, Ф. Кәрим үзе дә, фронтка җибәрүләрен сорап, гаризалар яза. Ниһаять, 1941 елда, Ф. Кәримне Казанга кайтарып, яңадан хөкем ясыйлар. 3 декабрьдә азат итәләр. Берничә көннән ул инде фронтка җибәрелә.

Ф. Кәрим сугышта гаҗәеп кыюлыклар күрсәтә. Аның (төрмәдән чыккан кешенең) бик тиз офицер дәрәҗәсе алуы — үзе бер могҗиза. Ул разведчик һәм взвод командиры була. Ләкин аңа җиңү шатлыгын кичерергә туры килми. Ф. Кәрим 1945 елның 19 февралендә Көнчыгыш Пруссиядә (Калининград өлкәсе) һәлак була. 1955 елда ул Багратлоновск шәһәренең туганнар каберлегенә күчерелеп (элеккеге Победа бистәсе) күмелә. Кабер өстендәге һәйкәлгә мондый сүзләр язылган: «Лейтенант Фатих Кәрим — татар шагыйре. Немец басып алучылары белән сугышта геройларча һәлак булды».

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Кәримнең тормыш юлын өч өлешкә бүлеп, сөйләп чыгыгыз. Аның шагыйрь булып китүенең сәбәпләрен аңлатыгыз.

2. «Ф. Кәрим — һәм бәхетле, һәм бәхетсез шәхес». Аңа карата ни өчен шулай әйтергә була?

3. Шагыйрьнең абыйсы Ярлы Кәрим дә (Габдулла Кәримов) шигырьләр язган. Аның шигырьләрен дә табып укыгыз.

4. «Дим буе» һәм Димгә багышланган башка җырларны күмәк тыңлауны оештырыгыз, аларны җырларга өйрәнегез. Игътибар итегез: халык үзенең җырларында бу елганы ничек сурәтли, аның образына бәйле рәвештә җырга-моңга үзенең нинди хис-кичерешләрен сала?

5. Дуслык авыр чакта беленер, ди халык. Кыен вакытта Ф. Кәримгә кемнәр ярдәм кулын суза? Сез алар турында ниләр беләсез?

6. Татарстан Республикасының милли музеенда Ф. Кәримгә багышланган экспозицияне карагыз.

7. Ф. Кәримнең иҗатына багышланган шигърият кичәсе үткәрегез.

Шигърият өчен туган кеше

Иҗатының башында ук Ф. Кәрим даһи шагыйрьләребез Г. Тукайны һәм Һ. Такташны үзе өчен өлге итеп карады. 1940 елда язган «Берәүгә» исемле шигырендә ул мондый фикерләр әйтә:

Мин Тукайдан үрнәк алам, дисең,
Бу түбәнлек түгел, һич түгел,
Чөнки Тукай — халык моңнарының
Бакчасында тибрәп үскән гөл.

Ягъни Г. Тукайга йөз тоту — халык иҗатына барып тоташу дигән сүз. Һ. Такташ та — халыкның акыл камиллеген, хис тирәнлеген гәүдәләндергән шагыйрь. Ф. Кәримнең бу ике бөек шәхескә тартылуы — үсәргә, җимешләнергә теләгән агачның кояшка омтылуы белән бер. 1928 елның 12 сентябрендә Һ. Такташка бирелгән фоторәсем артына Ф. Кәрим болай дип яза: «Такташ абый! Без синнән өйрәнәбез, син безнең өчен кыйммәтле».

Һ. Такташ кебек гаҗәеп талантлы шагыйрьдән өйрәнсә дә, Ф. Кәримгә осталык тиз генә килми. Бу, барыннан да элек, шигъриятне ул вакытта илдәге сәяси хәл-әхвәлләргә хезмәт иттерергә теләүдән, шулар белән чикләнүдән килеп чыга. 20 нче елларда ил тормышындагы гадәти генә вакыйгаларга да шигырь багышлап язуны ул үзенә гадәт итә. Мондый нәрсә, телисеңме-теләмисеңме, шигырьдә хәбәр җиткерүнең өстенлек алуына китерә. Нәтиҗәдә образлылык кими, сурәтләү чаралары ярлылана, бертөрлелек барлыкка килә.

Янар таулар көчле,
Җирне тетрәтәләр,
Тик вакытлы: алар сүнәчәк,
Ә мин менә комсомолда
Озак еллар өчен үсәчәк.

(«Безнең һәйкәл»)

Әлеге шигырь язылган 1928 еллар тирәсендә «янар таулар», «тетрәгән җир», «мәңгелек комсомол» кебек сүзтезмәләрдән торган гыйбарәләрне күп кенә шигъри әсәрләрдә табарга мөмкин. Әлбәттә, табигать гарасатлары җәмгыятьнең яңа көчләренә караганда зәгыйфь, куәтсез итеп тасвирлана, ягъни көчләр чагыштырмасы һәрвакыт комсомоллар, юксыллар ягында итеп күрсәтелә.

Шигырь, күңелдәге ихлас хисләр белән өртелгәндә генә, укучыны дулкынландыра, ләззәтләндерә. Ф. Кәрим тора-бара шуны аңлый башлый, һәм 30 нчы елларда аның әсәрләрендә шактый сизелерлек сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. «Көтәм сине» шигыре (1935) солдатка китүче егетнең хисләрен гәүдәләндергән: шул ук ватанпәрвәрлек, ил чиген сакларга ашкыну. Ләкин биредә инде болары шигырьнең бөтен тукымасын каплап тормый. Әсәрдә өртелгән төп хис — сөйгәненнән аерылып китүче егетнең яратуы, шуның табигыйлеге. Нәкъ менә шушы як егетне ягымлы, сөйкемле итә.

Мин сөялгән нарат күрде, ахры,
Килә дигән сыман тирбәлә.
Бәлки, соңгы кабат очрашудыр,
Көтәм сине, син кил, кил бире.

Мондый эзләнүләр Ф. Кәрим иҗатындагы лирик тирәнлекне көчәйтә төшәләр. «Кемгә сөйлим серләремне» җырының (1938) тууы моның ачык мисалы.

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек.
Ялкынланган йөрәгемә
Берәү бик якын кебек.

Ул үзе дә төн йокысыз
Мине уйлыйдыр кебек...
Янып сөймәсәң, яшьлекнең
Яме булмыйдыр кебек.

Чын хисләрне белдергән шигырьне композитор Әнвәр Бакиров күреп ала, аңа матур лирик көй яза. Җырны халык та үз итте.

Ләкин бу еллар иҗатында моңа охшаш зәвыклы шигырьләр аз. Ф. Кәрим әле һаман да шигъри публицистика иркендә кала бирә.

Алда әйтеп үткәнебезчә, 30 нчы еллар ахырь на таба Ф. Кәримгә сәяси гаепләр тагыла. Яшәп килүче җәмгыятькә үзенең тугрылыклылыгын исбат итүдән гаҗиз булып, ул салкын төньякта, муенынннан карга бата-бата, урман кисә. Ләкин шагыйрь җанлы кеше иҗат итми тора алмый ул. Тик аның язганнарында хәзер инде социализмны, партияне, комсомолны мактау юкка чыга. Лирик герой үз мине белән ялгыз кала, «кызыллык» аның янәшәсеннән ераклаша. Бу — аның икенче чор иҗатының, төрмә елларында язганнарының төп сыйфаты. Аның әсәрләрендә тоткынлыкның ачы газабы, рәнҗетелү хисләре өстенлек итә.

Я көн генә була, я төн генә,
Мин яшәгән җирдә ямансу.
Салкынлыктан сөяк әрнесә дә,
Сагыш ялкынында янасың.

Ярып чыгалмаслык чиксез тайга,
Җәй дә монда ике ай гына.
Тын алмыйча тоташ улаган җил
Сала мине кара кайгыга.

Шагыйрь иреккә сусаган. Шуңа күрә хөрлек билгеләре булган кошларны әсәрләренә табигый кертеп сурәтләве дә азатлыкка омтылу хисләрен көчәйтүгә ярдәм итә. Без лирик геройның ак күгәрчен белән сөйләшүенә шаһит булабыз. Икенче бер шигырендә ул кыр казына мөрәҗәгать итә:

Тынчу төрмәдә каршылыйм
Дүртенче язны.
Яз саен сагынып, бу якка
Кайта кыр казы.

Әй кыр казы! Түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан
Язгы ялкында,
Каныма манчып языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Бу шигырьләрдәге хисләр М. Җәлил, А. Алиш тарафыннан фашист тоткынлыгында язылган әсәрләрдә бәян ителгән кичерешләр белән аваздаш. Әйе, Ф. Кәрим өчен «Моабит» Казанда һәм Коми якларында булды. Менә ул Казанга кабат судка кайта. Билгесезлек аның җанын телгәли. Ул, балалары белән хыялында сөйләшеп, болай ди:

Күз нурларым!
Сагынып кайтам сезне,
Белмим, ничек каршы алырлар.
Шигырь өчен туган әткәгезне
Тагын дамы утка салырлар?

Илнең яшәү-яшәмәве хәл ителә торган урында, ягъни фронтта булырга тиешле ир-егет әнә шулай үз язмышы турында кайгырырга мәҗбүр. Язмыш бу юлы аңа мәрхәмәтлелек күрсәтә: ул азат ителә! Тагын берничә көннән яңадан сәфәргә кузгала, ләкин бу юлы сак астында түгел, ә кулына корал тотып!

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Кәрим шигъри остазларын ничек бәяли?

2. Шагыйрь байтак еллар үз йөзен, үз язу рәвешен таба алмый. Моның сәбәпләрен күрсәтегез.

3. 30 нчы елларда ул халык тарафыннан яратып кабул ителгән лирик әсәрләр дә иҗат итә. Аларны атагыз. Әлеге шигырьләр нигезенә салынган хисләрне ачыклагыз.

4. Шигъри публицистика (яки шигырьнең публицистик рухы) дигәндә, без ниләрне күздә тотабыз?

5. 1938 елның башында үзе белән булган фаҗигане Ф. Кәрим бик авыр кичерә. Аның хәсрәтен арттыра торган сәбәп нидән гыйбарәт?

6. 1938—1941 елларда шагыйрь иҗатында сыйфат үзгәреше барлыкка килә. Ул сыйфат үзгәрешләре нәрсәләрдән гыйбарәт? Алар ничек барлыкка килгән дип уйлыйсыз?

7. Ә. Бакировның Ф. Кәрим шигыренә язган «Кемгә сөйлим серләремне» җырын өйрәнегез.

«Үләм икән, үкенечле түгел...»

Сугышка китү шатлык түгел. Әмма Ф. Кәрим моңа чиксез куана. Чөнки ул хәзер ил алдындагы бурычын чын ирләрчә үти ала. Фронтка барып җиткәч, 1942 елның 28 февралендә ул өенә болай дип яза: «Хәзер инде кулга корал тотып Туган ил өчен көрәшәбез. Эш күп, вакыт юк... Тик сәламәтлек кенә булсын. Хәзер Ләйлә «Минем әти фронтта» дигән шигырен күкрәк киереп укысын инде. Әтисе аның фронтта...»

Ф. Кәрим, шул рәвешле, үзенең иң әүвәл кулына корал тотып сугышырга тиешлеген яхшы аңлый. Ләкин шагыйрь каләменең дә үткен корал икәнлегенә инана. Хатларында ул бу турыда гел искәртә. «Вакыт аз, эш күп. Язарга, укырга тик йокыга тиеш булган сәгатьләрне генә файдаланам» (03.12.1942). «Язарга гына вакыт аз. Шулай да мин язмыйча яши алмыйм» (15.02.1943). «Минем язган әйберләрем уңышлы санала икән, моның төп сәбәбе шунда: канымны коеп сугышам, шуның турында шул хис белән язам» (16.06.1943). «Фронт сызыгындагы сугышчының көне ничек үтсә, минем дә көнем шулай үтә. Кайвакытларда шундый янарга-пешәргә туры килә, гимнастёркалар тозланып ката. Шул шартларда табылган вакытны иҗатка багышлыйм» (24.06.1943).

Ирек-азатлык кеше рухына нинди көч-канат бирә! Юкса көн-төн бертуктамый туплар шартлый, пуля ява — җирнең асты өскә килә. Йә яшәү, йә үлем! Икенең берсе. Башка юл юк. Язмыш кыл өстендә. Ф. Кәримдә дә дөньяның башка кайгысы юктыр кебек. Әмма алай түгел икән! Сугыш чоры — аның иҗатының да, шигъри осталыгының да иң югары ноктага күтәрелгән чагы. Фронт биштәреннән аерылмыйча, ул сәнгатьлелек ягыннан теләсә кайсы каләм әһелен көнләштерерлек 150 гә якын шигырь, 8 поэма, 2 повесть, 1 драма әсәре иҗат итте.

Ф. Кәримнең сугыш чоры лирикасы кырыс чынбарлык күренешләренә нигезләнә. Лирик герое — сугыштагы солдат. Бу сугышчы — уйлары чынбарлыктан аерылмаган фәлсәфәче дә. Шигырьләрдә сугышның кешелек өчен — афәт, матурлык, яшьлек өчен фаҗига икәнлеге даими ассызыклана. Яшь нарат төбенә япь-яшь солдатны күмү күренеше, мәсәлән, вәхшәтне тагын да көчәйтеп җибәрә. Ак каен тәлгәшләренең дошман снайперын яшереп торуына да күңел тетрәнә. Сугыш берничек тә табигый була алмый. Шуның өчен сугыш чукмарла-

рын —немец фашистларын — мөмкин кадәр күбрәк юк итү кешелеклелек булып кабул ителә.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!
(«Бездә яздыр»)

Сугышның тагын бер фаҗигасе шунда: ул шагыйрь М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, композитор Ф. Яруллиннарны кулларына үлем коралы — мылтык алырга мәҗбүр итә.

Мин бер шагыйрь — тойгы, хис кешесе,
Яратам мин кошлар сайравын;
Мин — гуманист, сөям дөньяны,
Акмасын, дим, җирдә кеше каны,
Гуманизм — минем байрагым.

Ләкин ул гөнаһсыз сабыйларның, халыкның ирекле булуы хакына, шуларны яклау өчен, илгә басып керүчеләрне юк итәргә тиеш. Шулай итмәгәндә, ил коллыкка дучар булачак. «Иптәш» шигыре шушы теманы дәвам иттерә. Үләр алдыннан канлы башын пулемётка салган ир-егет исән калучы дустын болай дип юата:

Башың түбән имә, әгәр минем
Тыныч үлүемне теләсәң;
Илле фашист
исән йөрер иде әле,
Мин бирегә килеп үлмәсәм.

«Бездә яздыр» шигырендә исә ул тыныч Татарстандагы һәм фашистлар белән сугыш барган урыннардагы язны берберсенә янәшә куеп сурәтли. Туган илебездәге язны ул болайрак күз алдына китерә:

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сандугачлар ярсып сайрыйдыр.

Никадәр матур күренеш күз алдына килеп баса. Ләкин фронтта алай түгел:

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Шагыйрь Туган илне иң мөкатдәс нәрсә итеп карый. Әлеге төшенчәгә үзе өчен кадерле булган барлык кешеләрне, халкын, җир-суларны һәм табигатьне кертә.

Ватанпәрвәр шагыйрьнең күңелен ил гаме биләп алган:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

(«Сөйләр сүзләр...»)

Илне саклап калу өчен сугыш, әлбәттә, корбансыз булмый. Әмма Ф. Кәримнең лирик герое моңа да әзер.

Үләм икән, үкенечле түгел,
Бу үлемнең миңа килүе.
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

Шагыйрь һәм сугышчы Ф. Кәрим өчен иң мөһиме — менә бу шигъри юлларда әйтелгәннәр:

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.

(«Теләк»)

Шагыйрьнең бу изге теләге тормышка ашты. Ф. Кәримнең батырлыгы хәзер җыр булып яңгырый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Кәрим сугышка киткәндә нинди халәт кичерә? Сугышка китүенә куану табигый хәлме? Аңлатыгыз.

2. Ф. Кәрим ни өчен корал тотып сугышу белән генә канәгатьләнеп калмый?

3. Фронттагы сугышчы-шагыйрьнең иҗат итү мөмкинлекләре турында Ф. Кәрим ниләр яза?

4. Ф. Кәримнең фронт лирикасының үзенчәлекләрен билгеләгез.

5. Шагыйрь сугыш барган җирне Татарстан белән ни рәвешле чагыштыра?

6. Үлем — кеше гомеренең бетүе. Ләкин ул мәгънәле яки мәгънәсез булырга мөмкин. Шул турыда үзара фикерләшеп карагыз әле.

7. 1941—1945 еллар сугышы чорында татар шигърияте дөнья күләменә чыкты. Бу казанышта Ф. Кәрим иҗатының әһәмиятен билгеләгез.

8. Ф. Кәримнең «гражданин, шагыйрь, солдат» дип бәяләнүен дәлилләгез.

Поэма һәм балладалары

Сугыш елларында Ф. Кәрим кебек, шулкадәр төрле жанрларда иҗат итеп, шундый да бай әдәби мирас калдырган башка каләм остасын табу кыендыр. Ул үзенә яшәү өчен бирелгән елларның санаулы икәнен әйтерсең лә белә һәм көнелендәгесен тизрәк-тизрәк язып калырга тырыша. Дөресен әйткәндә, бу чынында да нәкъ шулай була. Аның поэма жанрындагы уңышларын күрегез инде: «Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы» исемле сигез поэма һәм «Тимер һәм тимерче» дигән баллада. Болар язу өстәле артында озак-озак еллар утырган каләм әһеле өчен дә бик бай иҗат җимешләре булып саналыр иде. Эш санда гына да түгел, бәлки, ул тудырган әсәрләрнең берсеннән-берсе сәнгатьчә искиткеч камил эшләнгән булуларында.

«Гөлсем» поэмасы (1941—1942) фашистларның канечкеч вәхшилеген һәм безнең ил кешесенең алардан рухи өстенлеген тетрәндергеч күренешләрдә ача. Татар кешесенең матурлыгы, физик камиллеге, акыл үткерлеге күптән расланган. Донбасс шахтёры хатыны Гөлсем дә үзенең эчке һәм тышкы матурлыгы белән сурәтләнгән. Аның озын толымы — милли күркәмлегенең аерылмас билгесе. Сабый баласын өзелеп сөюе, зенитчы ирен сагынып өзгәләнүе аның эчке матурлыгын тагын да затлы итә. Әмма матурлык белән янәшә бу җирдә фашист дигән ерткычлар да бар. Алар, гомерләрен озайту өчен, баланың канын актык тамчысына кадәр суыртып алалар һәм сабыйның тәнен дә үзләренең яраланган урыннарына күчереп утырту өчен кискәлиләр. Тап-таза йөргән баласының әнә шулай үтерелүенә шаһит булу — ана өчен күтәрә алмаслык газап, кайгы-хәсрәт. Фашист аның матур чәч толымын да кисеп ташлый. Бу инде — мөселман хатын-кызын мәсхәрәләүнең явыз төре. Нәфрәтнең дә бер чиге була, ул хис дошман белән көрәштә хатын-кызны да арысландай көчле итә. Гөлсемнең

киселгән чәч толымы белән фашист офицерын буып үтерүе күптән көтелгән финал булып кабул ителә. Бу кадәр чиктән ашкан явызлыклар өчен бирелгән җәза шуңа бәрабәр булырга тиеш. Матурлык билгесе булган чәч толымы тиешле шартларда җәза коралы булып та әверелә ала.

Бу толымы хәзер көч аңа,
Җиңүенә Гөлсем ышанып
Селки-селки буа дошманын,—
Улы, улы өчен үч ала.

Поэма партизаннарның авылны фашистлардан азат итүләре белән тәгәлләнә.

Ф. Кәрим,— вакыйгалар чынлыгыннан тыш, кешеләрнең эчке халәтен бик нечкә төсмерләр белән сурәтләп бирүнең дә остасы.

«Тимер һәм тимерче» балладасында (1942) тасвирланган вакыйга укучыны сугыш кырына алып китә. Ихтимал, бу — сугышның гадәти бер күренешедер. Саттар исемле илле яшьлек солдат немец танкы белән очраша һәм шушы тартышта җиңеп чыга. Бер карасаң, көчләр бөтенләй тигез түгел. Фашист тимергә төренгән, бронялы танк эчендә утыра, кулында җен кебек көчле машина, көпшәсеннән ут яудырып бара. Татар солдаты Саттар исә шушы тимер тавына ялгызы каршы чыга. Дөрес, ул сугышка кадәр авылда тимерче булып эшләгән. Ләкин, тимерче булса да, аның тәне тимердән түгел бит.

Автор Саттарның тимерче булуын очраклы гына ассызыкламый. Бу аның тыныч тормыштагы һөнәре генә түгел, бәлки рух ныклыгын, ихтыяр көчен дә күрсәтә. Тагын шунысы мөһим: тимерче буларак, ул тимер тавы — танкның «йомшак» якларын да белә булыр. Тимерче Саттар белән танк күзгә-күз, капма-каршы калалар. Әлбәттә, Саттар бу тирәлектә берданбер солдат түгел. Бар аның иптәшләре. Әмма танкка иң якыны ул. Димәк, аның язмышын хәл итү бу очракта Саттар өстенә төшә.

Танк килә — кара тәреле,
Улап килә Саттар янына;
Тимерчеме тимер тавына,
Таумы тимерчегә бәрелер?

Бик киеренке халәт барлыкка килә. Хәзер кем кемне мәсьәләсе хәл ителә. Якында гына яткан берәү түзми, артка таба йөгерә. Ләкин Саттар андый куркаклардан түгел. Дөрес, Сат-

тарда да курку бар. Тик «бераү» дигән кешенең «куркуы» белән Саттар «куркуы» арасында җир белән күк аермасы.

Яшереп булмый, курка тимерче:
«Ычкынмасын кулдан бу «үлем»,
Үзем үлсәм, бәхил бул, илем»,—
Дип тимерче җыйный бар көчен.

Ул үлем алып килүче фашист танкының, кулдан ычкынып, алга үтеп китүеннән курка. Шулай да автор аны гадәттән тыш кеше итеп сурәтләү юлыннан китми, чөнки Саттар мәңгелек суы эчкән кеше түгел. Ул үзенең үлү мөмкинлеге турында да уйлап ала, рух ныклыгын җыя, туплый. Игътибар итегез: ул хәтәр мизгелдә илгә мөрәҗәгать итә, бәхиллекне иленнән сорый. Баллада героеның тимерче булуының әсәр тукымасы өчен тагын бер әһәмияте бар: ул, сугыш кораллары рәвешендәге тимерләрне эретеп, халыкларга иксез-чиксез хәсрәтләр китерүче илбасарларның үзләрен авызлыкларга яраклы әйберләр ясар.

Танк ватыкларын сандалга
Салыр бу көн безнең тимерче,
Чүкеч үтә йөртеп бар көчен,
Богау ясар һәрбер вандалга.

Шулай итеп, шагыйрь үзе сурәтләгәннәргә бик уңышлы нәтиҗә ясый, нәкъ кирәк урында нокта куя.

* * *

Ф. Кәрим иҗатына гомуми бәя биреп, шуны әйтергә кирәк: ул, үзе кулланган жанрларның тулы мөмкинлеген файдаланып, сугыш кырындагы кешенең кичерешләрен, башыннан үткәннәрен килер буыннарга ихлас дөреслек белән сурәтләп калдыра алды. Үзе дә бу сугышта катнашкан шагыйрь һәм язучы Н. Дәүли әйткәнчә, «Фатих Кәрим безгә рядовой солдат турында олы сүз әйтте. Ә ул солдат туган илен ярата белгән, халыкка үз мөнәсәбәтен йөрәк түрендә йөрткән, туган җир өчен дошманнарга каршы көрәштә башын салган кеше иде. Фатих Кәрим үзе дә — шундый солдат» һәм, әлбәттә, олы шагыйрь.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Кәримнең сугыш вакытында аеруча күп иҗат итүен сез ничек аңлатыр идегез?

2. «Гөлсем» поэмасының үзәк герое нинди сыйфатларга ия?

3. Поэмаларында кешенең психологик халәтен шагыйрь ничек итеп сурәтли?

4. Поэма һәм баллада жанрлары арасында нинди аерма бар? Ф. Кәрим әсәрләрен укып аңлатыгыз.

5. «Тимер һәм тимерче» балладасында Саттарның тимерче һөнәренә ия кеше булуының әһәмияте нидә дип уйлыйсыз?

6. «Шулай үлде Ватан улы» яки «Окопларда язган җырларымны хөрмәт белән дуслар укырлар» дигән темага әдәби-музыкаль кичә әзерләгез.

Лирик шигырь. Лирика — грек сүзе, «лира исемле музыка коралына кушылып җырлаучы» дигән мәгънәне аңлата. Әдәбиятның билгеле булган өч төре бар: лирика, эпос һәм драма. Лирик әсәр дип кешенең эчке уйлары, кичерешләре гәүдәләнгән әсәрне атыйлар. Ул хисләр чәчмә юл белән дә бирелергә мөмкин. Ләкин күпчелек очракта лирик әсәрләр тезмә (шигъри) рәвештә языла. Шуңа күрә, лирика дигәндә, без шунда ук шигырьне күз алдына китерәбез.

Ләкин теләсә кайсы тезмә әсәрне лирик шигырь дип әйтеп булмый. Лирик шигырьнең үзәгендә хис, кичереш торырга тиеш. Анда эпостагы кебек вакыйгалы сюжет булмый, бәлки, эмоциональлек, ягъни хиссилек аеруча көчле бирелә. Лирик шигырь яза торган шагыйрь нечкә, нәфис күңелле, кичергәннәрен башкаларга да «йоктыра» алырлык итеп әйтеп бирә белү сәләтенә ия була.

Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,
Соңгы кабат күрим акканын,
Бәлки, бик тиз бире кайтмамын,
Сакланыр ул бары күңелдә.

Ф. Кәримнең бу строфасында сугышка китүче кешенең уй-хисләре тирән һәм матур итеп әйтелгән. Алар әсәрне укыган һәркемгә аңлаешлы. Бигрәк тә шуңа охшаш хәлләрдә булган кешеләр аңарда үзләре кичергәннәргә тәңгәл төсмерләрне табалар. Шулай булгач, лирик әсәр дә гомумиләштерү сыйфатларына ия була икән.

Ил тамыры белән без тип-тигез,
Сөт чишмәсе белән без игез —
Сөт тамыры корган халык китә,
Без яшибез әле, китмибез!

(Р. Харис)

Бу инде — уйланып укуны, мәгънәгә төшенү өчен күпмедер көч куюны таләп итә торган фәлсәфи лирик шигырь.

Лирик шигырь аеруча мәхәббәт темасына күп языла. Татар әдәбияты мәхәббәт шигъриятенә бик бай.

Без яратмый, җирдә кем яратсын,
Чиге бармы матур хисләрнең?
Шашып сөя алсам яшәп булыр,
Мәхәббәтем сүнсә нишләрмен?

(К. Сибгатуллин)

Күңел тулы якты тойгыларым
Ташып чыга бөтен дөньяга.
Хисләр яңа, чәчәк атып килгән
Мәхәббәт тә, дуслар, өр-яңа.

(Ф. Сафин)

Ә табигать матурлыгына сокланып язылган шигырьләр? Алар да кеше күңеленә көчле тәэсир итәләр.

Ак каеннар яшел яулык япкан,
Шомыртларым инде бөредә.
Беркая да китмим туган яктан,
Гомерем язы үткән бирердә.

(К. Булатова)

Көзне күзләп барам әле,
Яңгыр үтеп китте яңа.
Хәзер менә юеш җиргә
Бурап-бурап яфрак ява.

(Р. Зәйдулла)

Кешенең төрле халәте (шатлыгы, кайгысы, соклануы, горурлануы, кимсенүе һ.б.) шулай ук лирик шигырьләрдә чагылыш таба.

Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп:
Сулган гөлгә,
Сүнгән көлгә,
Моңсу таңнарга,
Үкси-үкси,
Яулык селкеп
Калган ярларга,—
Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп,
Соңгы тапкыр күргәндәй итеп.

(И. Юзеев)

Кеше, шул исәптән шагыйрь, җәмгыять белән бихисап җепләр ярдәмендә бәйләнгән. Шагыйрь җәмгыятьтәге бик күп кадерле нәрсәләрне күңеленә якын итеп яши, ләкин шул ук вакытта аңа ошап бетмәгән, аның уенча үзгәртергә кирәкле яклар да була. Ул аерым бер милләтнең, катламның, төркемнең мәнфәгатьләрен яклый. Г.Тукайның, мәсәлән, татар халкының «мескен булып торган өч йөз елда» изелеп яшәвенә йөрәге әрни. Кайбер даирәләрнең «әгәр монда ошамаса, әнә Төркиягә китегез!» дип кычкыруларына каршы ул «Китмибез!» исемле шигырен яза. Безнең ата-бабадан, ягъни борынгыдан килгән туган җиребез шушында, без тегендә-монда күчеп йөрүче килмешәк түгел, бары тик туган илебездә генә бәхетле була алабыз дигән фикер әйтә. Димәк, шагыйрь татар җәмгыятенең мәнфәгатьләрен кайгырта. Моны шагыйрьнең гражданлыгы дибез. Ул үзе гражданин булып торган җәмгыятькә битараф түгел, ил, халык язмышы — аның шәхси язмышы. Р. Харис, бөек остазыбыз Г. Тукайның шушы шигырен хуплап, шулай ук «Китмибез!» шигырен язды.

«Китмибез!» — дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Һәр күңелдә, мең мәгънәле булып,
«Китмибез»е яши яңгырап.

М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, Г. Кутуй, С. Хәким, Н. Арсланов, С. Сөләйманова һәм башка бик күп шагыйрьләребезнең иҗатларында гражданлык мотивлары көчле яңгырый. Алар һәрберсе үз халкының, чорының гаме белән яшәүче, иҗат итүче шәхесләр иде. М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» җыентыгы, Ф. Кәримнең фронт лирикасы — гражданлык шигъриятенең бөек үрнәкләре.

Поэма. Шигъриятебезнең бай тарихы бар. Дини эчтәлекле һәм лирик шигырьләр иҗат итүнең тарихы мең елдан артыкка китә. Шигъри осталык үскән саен, шагыйрьләр зур күләмле тезмә әсәрләр дә иҗат итә башлаганнар. Й. Баласагунлының «Котадгу белек», К. Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», С. Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур», Г. Кандалыйның «Сахибҗәмал» кебек әсәрләрен искә төшерү генә дә моның шулай икәнлегенә дәлил булып тора. XX йөздә исә Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»,

М. Гафуриның «Эшче», Ш. Бабичның «Газазил», Н. Исәнбәтнең «Түләк» (драматик поэма), С. Кудашның «Хат», Ә. Фәйзинең «Флейталар», Һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе», Х. Туфанның «Ант», М. Җәлилнең «Хат ташучы», Ф. Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун», С. Хәкимнең «Шагыйрьнең бала чагы», И. Юзеевнең «Таныш моңнар», Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш», Р. Харисның «Ат иярләү» һәм башка бик күп поэмалар иҗат иттелде. Күрәбез: никадәр байлык һәм төрлелек.

Искә алынган һәр поэманың үзенә бер аерым эчтәлеге генә түгел, бәлки сурәтләү рәвеше, ягъни кабатланмас формасы бар. Әйтик, Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Г.Кандалыйның «Сахибҗәмал», С. Хәкимнең «Шагыйрьнең бала чагы» кебекләрендә төп урынны лирик уйланулар алып тора. Димәк, аларны лирик поэма дип атыйбыз. К. Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», С. Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрләрендә нык оештырылган сюжет бар, аларда сурәтләнгән образлар бер-берләрен яраталар, бәхетләренә киртә булып торучы көчләр белән көрәшәләр, шул рәвешле, сюжетны алып баруга әһәмиятле өлеш кертәләр. Шул ук вакытта әлеге персонажлар, кешегә хас булганча, шатланалар, кайгыралар, сагышланалар, хәсрәтләнәләр, кыскасы, хислеуйлы кеше итеп сурәтләнәләр. Шуңа күрә бу әсәрләрне лироэпик поэмалар дип билгелибез. Аларда, күргәнебезчә, бер үк вакытта лирикага хас хис тирәнлеге, эпоска хас вакыйгалар бар. Алар лириклык һәм эпиклык кушылмасы булып торалар. Поэмаларда вакыйгалар, хисләр үстерелеше шигырьгә караганда шактый дәвамлы була, ләкин, гадәттә, бер сызык буенча бара. Бу яктан аларны чәчмә әсәр булган повесть жанры белән тиңләштереп булыр иде. Мәсәлән, «Хат ташучы» поэмасында М. Җәлил әсәрнең буеннан-буена Фәйрүзә белән Тимербулат арасындагы мөнәсәбәтләр турында сүз алып бара. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә вакыйгалар күптармаклы. Хөсрәү, Ширин, Фәрһад, Шируя образлары, сурәтләнгән тагын башка образлар һәрберсе аерым-аерым сюжет сызыкларын тәшкил итәләр. Автор аларны гомуми (уртак) сюжет җебенә үреп алып бара. Бу әсәрнең жанрын хәтта шигъри роман дип билгеләргә мөмкин. Бездә тагын да шигъри романнар бар. С. Баттал «Чирмешән буйларында», Ә. Давыдов «Йокысыз төннән соң», Р. Харис «Исемсезләр» дигән шигъри романнар яздылар.

Инде нәтиҗә ясыйк: поэма (грекча: иҗат итәм) дип шигъри рәвештә язылган һәм аеруча мөһим вакыйгалардан торган, сюжеты хис-кичерешләргә төреп сурәтләнгән әсәрне атыйлар.

Баллада итальянча «бию» дигән мәгънәне аңлата. Урта гасырларда Көнбатыш Европа халыкларында күмәк биеп җырлый торган уенны аңлаткан. Ул вакытта баллада сюжетсыз лирик шигырь рәвешендә булган. Гасырлар үткән саен, баллада сюжетлы шигъри әсәр рәвешен ала. Аның үзәгенә бәхетсез мәхәббәт, тарихи легенда вакыйгалары куела башлый. Алар кечкенә генә драматик әсәрләрне хәтерләтәләр. Гадәттә, бу вакыйга бик киеренке була. Аның геройлары гаделлекне, кешелеклелекне яклыйлар. Шуңа күрә алар көрәш романтикасы белән яналар. Дөрес, кайбер шагыйрьләр иҗат иткән балладаларда күңел әрнү, сагыш белән тулы образлар да сурәтләнде. Димәк, баллада романтик рухлы әсәр буларак аерылып тора. Романтик шартлылыкны үз итү — аның төп билгеләреннән берсе.

Балладаларның тагын бер үзенчәлеге шунда: аларда экияти сурәтләү алымнары да иркен кулланыла. Җансыз табигать предметлары һәм җәмгыять күренешләре, кош-кортлар, җәнлекләр, хайваннарны кешеләргә хас булган сыйфатлар белән сурәтләү дә балладада гадәти хәл.

Менә бу сыйфатлар Ф. Кәримнең «Тимер һәм тимерче», М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», «Ана бәйрәме» балладаларына да хас.

ЯҢА СЫЙФАТ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕНӘ КҮЧЕШ ЧОРЫНДА (1945—1970 ЕЛЛАР)

Халыкныкы халыкка кайта

Кешелек тарихындагы иң зур канкоешларның берсе — Икенче бөтендөнья сугышы — безнең җиңү, Берлинны алу, Рейхстаг өстенә кызыл әләм кадау белән тәмамланды.

Дошманны үз оясында тар-мар итү, азат тормыш шатлыгы җимерелгән шәһәрләрне, юкка чыгарылган авылларны торгызуда, илне кабат аякка бастыруда таяныч булды. Һәркемгә өстәмә көч, куәт биреп торды. Сугыш авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп алып чыккан халык туачак бәхетле көннәр сөенече белән яшәде. «Бүген миңа кыен, авыр, хәерчелек эзәрлекли, ачлык артымнан калмый, әмма иртәгә рәхәтрәк, матуррак яшәрмен» дигән өмет уты хезмәткә рухландырды, киләчәккә ышанычны җылытып торды.

«Совет кешесе» дигән кушаматлы адәм баласының, чынлыкта авыр тормыш михнәте, җәбер-җәфа белән тартыша-тартыша, киләчәк язмышы, олы сәясәт турында уйларга вакыты да калмый.

Дөньяда барган үзгәрешләрнең асыл сәбәбен аңламаган, хәбәрдар булмаган халык Европаның һәм Азиянең кайбер илләрендә коммунистик режимнар урнаштырып, социалистик лагерь төзүне дә уңай кабул итте, хуплады.

Үзен «Халыклар атасы» дип санаган Сталин үлгәннән соң да, партия илне элеккечә куркыту, өркетү белән тотуын дәвам итә. Көтелгән, вәгъдә ителгән хөррият һаман да халыкка ирешми.

Әдәбиятның үсешенә социалистик реализм юнәлеш биреп, чынында иҗат ирегең чикләп килә.

Торгынлык елларында әдәбиятта җайлашу, икейөзлелек, ике яклы әхлак, ваемсызлык һәм битарафлык алга чыга.

Үз фикерле, кыю каләмле сүз осталарын чикләү, әдәбиятның «сафлыгы» өчен көрәш озак дәвам итте.

Ил җитәкчеләрен, партияне, бәхетле, шатлыклы, мул тормышны мактап җырлаган әсәрләр рәсми хуплана килде. Соңрак «конфликтсызлык» дип аталган бу күренешнең төбендә тормышны берьяклы, купшы һәм ал төсләрдә генә сурәтләү бурычы ятты. Сугыштан соңгы әдәбият «фаҗига» төшенчәсен әйләнеп үтәргә тырышты. Яшәешнең әлеге кыйбласына кагылсалар да, язучылар аны берьяклы, күтәренке рухта сурәтләделәр.

Сугыш фаҗигасен тирәнтен ачу, сагыш, әрнү, рәнҗү, юксыну кебек «вак-төяк» кичерешләрне, кешенең рухи эзләнүләрен сурәтләү совет әдәбияты өчен чит-ят күренеш буларак бәяләнде.

Милли әдәбиятларда милләтчелеккә, формализмга каршы көрәш ямьсез төс алды.

Вакытлы матбугатта тәнкыйтьче Хәсән Хәйри белән күренекле язучы Әхмәт Фәйзи арасындагы бәхәс — шул чор әдәби тормышының ачык бер үрнәге. «Сугышчан поэзия өчен» (1948), «Поэзиядәге формализмга каршы» (1948) кебек исемнәреннән үк төп юнәлешләре анык чагылган мәкаләләрендә Х. Хәйри шартлы алымнарга, символик образларга, лиризмга, төрлелек ирегенә каршы чыга. Ул Ә. Фәйзинең «Эзләр», «Флейталар», «Кара таш ник дәшми?», «Тышта яз» кебек шигъри әсәрләрендә совет әдәбиятына ят, чит мавыгулар, шәклилек[1] шаукымы чагылыш таба.

«Бер тәнкыйть уңае белән» дигән мәкаләсендә (1948) Ә. Фәйзи үз иҗат юнәлешен, символик, шартлы сурәтләүләрнең әдәбиятта яшәргә хакы барлыгын яклап чыга.

Чор тәнкыйте әдәбиятка ярдәм итәрлек, юнәлеш бирерлек дәрәҗәдә тормый әле. Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Хатип Госман кебек галимнәр күбрәк әдәбият тарихын тикшерү белән мәшгульләр. Яңа буын тәнкыйтьчеләре үсеп җитә алмаган иде әле. Шулай да әдәби тормыш акрынлап яхшы якка үзгәрә килә.

1952 елда «Чаян» журналы яңадан чыга башлау сатира белән юморның үсеп китүенә этәргеч бирде. Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Габдулла Шамуков, Салих Баттал, Зәки Нури, Зыя Мансур, әдәбиятка соңрак килгән Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Фаил Шәфигуллинның иҗатларында көлү жанры

[1] *Шәклилек* — формализм.

тормышның бөтен катламнарына үтеп керә. Мәсәл, бигрәк тә аның кыска төре, тернәкләнеп, яңа сыйфат югарылыгында үсеп китә.

1954 елда, нәкъ егерме елдан соң, Мәскәүдә язучыларның икенче съезды җыела. Тантаналы күтәренкелек рухы белән үткән бу җыеннан соң милли республикалардан Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Давид Көгелтинов, Мостай Кәрим кебек бер төркем язучыларны аерып алып, данга күмү галәмәте башлана. Бу партия сәясәте өчен кирәк.

Татар әдәбияты тормышында әһәмиятен бәяләп бетергесез олы вакыйга булды: 50 нче еллар уртасында Хәсән Туфан белән Муса Җәлил иҗатлары бер-бер артлы халыкка кайтты. Аларның мирасы, гомуми әдәби халәткә уңай тәэсир итеп, купшылыкка, сорылыкка, төссезлеккә каршы көрәштә терәк һәм бигрәк тә сыйфат дәрәҗәсе үлчәме бирәмлеге булды, әдәбиятка яңа үсеш чорын башлап җибәрергә җирлек әзерләде. Нәкъ шушы дәвердә 30 нчы елларда шәхес культы корбаны булган язучыларның әсәрләре дә басылып чыга һәм өйрәнелә башлады.

Бөек җиңү рухында

Байтак еллар дәвамында Ватан сугышы, дөньяны фашизм коллыгыннан коткару темасы әдәбиятның төп үсеш юнәлешен билгеләде. Бу — табигый. Татар халкы батырлар саны ягыннан да, корбан булган улларының исәбе буенча да СССРда яшәүче милләтләр арасында беренче урыннарда тора.

Әдәбият галиме Нил Юзиев бик хаклы язганча, фронт татар язучылары өчен чыныгу, өлгерү «университеты» булды. Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Шәрәф Мөдәррис, Зыя Мансур, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Хисам Камалов, Әдип Маликов, Зәки Нури, Нури Арсланов, Мәхмүт Хөсәеннәр, сугыш сынауларын үтеп, тыныч тормышка кайттылар.

Сугыш гарасаты әле байтак еллар дәвамында әдәбиятның рухы, бәгыре, үзәге булып калса да, аны күрү, аңлау дәрәҗәсе һәм тасвирлау рәвеше үзгәрә. Чакыру, өндәү, нәгъләтләү рухын үтеп киткән фаҗиганең мәгънәсен, нәтиҗәсен фәлсәфи тирәнлек белән иңләргә омтылыш алыштыра. Биредә берничә тармак ачык төсмерләнә.

Бер яктан, мәңгелеккә чит-ят җирләрдә ятып калган якыннарны, дусларны, туганнарны сагынып, юксынып язылган әсәрләр йөрәктә бөреләнә: З. Мансур «Кайта алмый калган солдат бәете» (1945), Ә. Фәйзи «Ач тәрәзәң» (1945), «Ана турында җыр» (1951), С. Хәким «Көткән идем» (1946) шигырьләрен, Ш. Галиев «Әткәйгә хат» (1957) поэмасын яза.

Әллә инде Җиңү шатлыгыннан,
Әллә яшьли күпне күргәнгә,
Тел очыма, әткәй, шигырь килә,
Иген арасында йөргәндә,—

дип, яшь шагыйрь сугышта һәлак булган әтисенең якты истәлегенә мөрәҗәгать итә.

Поэмага хисси моң, самими җылылык хас.

«Сары капкалы йорт» (1958) балладасында С. Хәким сугышта югалган авылдашы Сәләхи образын калкытып куя. Аның ядкяре булып, сары капкалы йорты, яшел күзле кызлары һәм хуҗасын сагынып моңаючы гармуны гына калган.

Әсәр психологик анализның тирәнлеге, нечкә күзәтүләргә байлыгы белән баллада үсешендә аерым урын били.

Сугышны реалистик төгәллек белән сурәтләгән әсәрләр арасында Х. Камаловның «Яну» поэмасы аерылып тора. Татар сугышчысы Заһид әхлакый өлгергәнлеге, җиңүгә ышанычы белән үзенә җәлеп итә.

Г. Әпсәләмов «Ак төннәр» повестенда (1946) сугышчы батырлыгының эчке мәгънәсен ачарга омтылыш ясый.

«Газинур» (1951) романы — тарихи шәхескә багышланган әсәр. Александр Матросов кебек үк, күкрәге белән дошман утын каплаган татар кешесенең үзен корбан итүен хәзер төрлечә бәяләргә мөмкин. Г. Әпсәләмов татар егетенең холкы, характеры, гомумән, каһарманлыкның нигезләре турында җитди уйлана. Шәхесне романтик биеклеккә күтәреп сурәтли.

Икенче юнәлешне язучыларның үз башларыннан узган, күргән, ишеткән аянычлы һәм фаҗигале хәлләрне, кеше рухының бөеклеген тасвир үзәгенә алган әсәрләр тәшкил итә.

Бу юлда С. Хәкимнең «Дала җыры» (1948), «Курск дугасы» (1948) һәм шул ук теманың яңача дәвамы булган «Дуга» поэмасы (1968) игътибарга лаеклы.

Сугышка багышланган тыгыз эчтәлекле хикәяләре белән Ә.Еники сугыш вакыйгаларына, андагы фаҗигале хәлләргә лирик җылылык алып керә («Тауларга карап», 1948; «Кем җырлады?», 1957).

«Без әле очрашырбыз» (1947) әсәрендә Ибраһим Гази сугышны бөтен каршылыклары белән кабул иткән Закир Дәүләтшин образын тудыруга ирешә.

Н. Дәүлинең «Яр буенда шаулый наратлар» (1946), Ш. Мөдәрриснең «Үлемсезлек» (1959) әсәрләрендә үтеп киткән вакыйгаларга тарихи күзлектән килеп бәя бирүгә омтылыш ясала.

Әсирлек хурлыгын кичергән Н. Дәүли башыннан үткәннәрне «Яшәү белән үлем арасында» (1958), «Җимерелгән бастион» (1965) исемле ярым документаль, ярым әдәби китапларында фашизмның ерткычлыгын фаш итеп, совет кешеләренең әхлакый һәм акыл бөеклеген, туган илләренә бирелгәнлекләрен үзенчә тасвирлый.

Бериш әсәрләрнең нигезендә тормышта булган хәлләр ятса, икенчеләрендә хыял эшчәнлеге, югары, күтәренке рух алгы нәүбәткә чыга. Ә. Фәйзинең «Күтәрелә кояш» исемле (1945) романтик һәм шартлы поэмасы — шул стильнең ачык мисалы.

Кояш җиңү шатлыгын, көрәш дәртен символлаштыручы уңай образ булса, халык әкиятләреннән алынган Юха елан кыргый явызлыкны, дошман көчне гәүдәләндерә. Яхшылык белән начарлык арасындагы киеренке тартышта беренчесе җиңеп чыга.

Бу әсәре белән Ә. Фәйзи шартлы-символик һәм гомуми сурәтләрнең яшәргә хакы барлыгын раслады.

Ш. Маннурның «Казан кызы» поэмасында (1946) сугыш темасын алга чыгаруның өченче тармагы ачык чагыла. Ул — кичәге сугышчының өенә, тыныч тормышка кайтуын, үткәннең фаҗигале вакыйгаларын искә алу аша киләчәккә хыялларын тасвирлау.

Ш. Маннур поэмасының үзәк герое — Казан кызы Дилбәр. Шагыйрь аның сугышта күрсәткән батырлыкларын үзәккә ала, аны тәрбияләп, кешелек сыйфатларын үстергән тирәлекне, гаилә тормышын, эчке дөньясын ачуга әһәмият бирә.

Чор тәнкыйте авторны әхлак мәсьәләләре белән мавыгуда гаепләсә дә («Совет әдәбияты».— 1946.— № 11.— 57 б.), тулаем алганда, татар хатын-кызының мөлаем образын тудыруы белән поэма әдәбият тарихында үз урынын тапты.

Табигый ки, тыныч тормышка, тыл язмышына багышланган әсәрләргә дә сугыш күләгәсе төшә. Малайлык һәм яшьлек еллары дәһшәтле чорга туры килгән, сугыш корымына

буялган буын иҗатында әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән яңа бер жанр туа. Аларда чорның кырыс дөреслеген, хакыйкатьне эзләү үз башларыннан узган хәлләр, вакыйгалар җирлегендә ачыла. Әсәргә хыял белән тулыландырылган, баетылган шәхси биография ургылып килеп керә. Мәсәлән, Эдуард Касыймовның «Гомер ике килми» (1962—1963), Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» (1964—1966), Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» (1966), Барлас Камаловның «Яшьлек эзләре» (1968), Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» (1968) повестьларын атарга мөмкин. Үзәкләрендә яткан фаҗигале һәм көлкеле хәлләр, ачыктан-ачык сөйләшү, шәхси башлангыч, сугыш чоры михнәтләренә баш бирмәгән яшьлек матурлыгы, тел-бизәк алымнарының сафлыгы, яңачалыгы әсәрләргә ышандыру көче бөрки. Алар — сугыштан соңгы прозаның мөһим казанышы.

Әдәбиятта тарихилык рухы көчәю, олы язмышлы шәхесләргә игътибар үсү тематиканы төрләндерергә омтылышның бер чагылышы булды.

Ә. Фәйзинең Тукай исемен мәңгеләштерү юлындагы кыю иҗади эшчәнлеге аерым игътибарга лаеклы. 1943 елда ул «Тукай» тарихи драмасын бастырып чыгара, 50 нче еллар дәвамында бөек шагыйрь шәхесенә багышланган роман өстендә эшли. Әсәр Тукайның балалык, яшьлек елларын эченә алып тәмамланмыйча кала. Шул хәлендә дә ул күп телләргә тәрҗемә ителеп укыла, татар әдәбиятын бизи торган әсәрләр рәтендә яши.

Ә. Фәйзинең иң соңгы әсәре дә Казанда Тукай һәйкәлен ачуга багышланган:

Белмим, кайсы таулар
күкрәгеннән
Һәйкәлеңнең ташы, тимере,—
Тик син үзең халык
йөрәгеннән.
Халык мәхәббәте — синең
исемең.
Халык гомере — синең
гомерең!
(«Габдулла Тукайга»)

Язучыларны Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгы рухландыра. Ә. Фәйзинең «Шагыйрь» (1947), Г. Хуҗиның «Безнең Муса» (1954—1957), Н. Дәүлинең «Берлинда окоп» (1956)

поэмалары, Р. Ишморатның «Үлмәс җыр» (1955), Н. Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (1956) трагедияләре, Г. Әпсәләмовның «Агыла болыт» (1956), Ш. Маннурның «Муса» (1959—1964) романнары шагыйрьнең бөеклеген, физик һәм рухи куәтен, иҗади батырлыгының сүнмәс-сүрелмәс дәртен укучыга ирештерүдә зур өлеш керттеләр. Үзәктә халык рухын аерым кеше язмышы аша тасвирлауга омтылыш ята. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы алдагы елларда да әдәбиятка якты нур сирпеп, сүз осталарын иҗатка рухландырып тора (Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләмов һ.б.).

Торгынлык елларында Ленин образы һәм эшчәнлеге белән мавыгу көчәеп китә. Ленин эшчәнлегеннән тулысынча хәбәрдар булмаган язучыларга аның үтәлмәгән вәгъдәләре һаман да тирән йогынты ясый.

С. Хәким Ленинны олылауга багышланган поэмалар яза. «Ленин фәрманы белән» (1957), «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» (1961), «Баһавиның моңы» (1963), «Язы-гыз, Җир уллары» (1963) һ.б. Ә. Фәйзи, Р. Ишморат, Ш. Мөдәррис, М. Ногман, Ә. Давыдовлар иҗатында да бу тематика зур урын ала.

Тарих истәлеге булып калган әлеге әсәрләрдә 1917 ел борылышын оештыручы инкыйлабчы татар халкын бәхет һәм мәгърифәт юлына алып чыккан, аңа зур изгелекләр эшләгән кеше буларак бәяләнә.

Безнең халык күпләп яши торган төбәкләрне Татарстанга кертмәү, 1921 елгы ачлык вакытында бар икмәкне кырып-себереп «үзәккә» озату, зыялыларны юкка чыгару кебек фаҗигаләрнең күбесе Ленин фәрманы буенча эшләнүе мәгълүм булмый әле ул чор язучыларына.

Тыныч тормышны сурәтләү юлында

Сугыш эзләрен, рухын акрынлап тыныч тормыш гөрелтесе күмә. Әдәбиятка замана җиле, яңа чынбарлык рухы үтеп кереп, анда яңа юнәлешләр, агымнар төсмерләнә.

Сүз осталарының игътибары янәдән авыл, колхоз тормышына, илне тукландыручы, халыкның әхлагын, гореф-гадәтен, динен, телен саклаучы игенче язмышына юнәлә.

Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Ш. Маннур, С. Баттал, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис кебек өлкән буын язучылары иҗа-

тында авыл һәм табигать, хезмәт һәм тереклек мәсьәләләре күпьяклы һәм эзлекле яктыртыла.

С. Хәкимнең «Бакчачылар» (1951) поэмасында вакыйгалар сугыш чорында бара. Әмма үзәктә шул ук колхоз хезмәте ята. Алма бакчасын саклап калу өчен көрәш барышында ачылган Сәлим карт, Зөһрә, фронт якларыннан күчеп килгән Марина образлары 50 нче еллар кешеләренә якын. Поэмада кеше күңелен сурәтләү чаралары төрләнә, лиризм тормышны күпьяклы итеп күрсәтү алымы буларак үстерелә.

С. Батталның «Олы юл буйлап» (1949—1951) поэмасы — чорның уңышлы әсәрләреннән берсе. Ул 1953 елда «Новый мир» исемле үзәк журналда русча басылып чыга һәм уңай бәя ала.

Сәфәр, фронтта бер кулын, бер аягын югалтып, туган авылына кайта һәм типтереп, колхоз милкен әрәм-шәрәм итеп яткан колхоз рәисе Фазылга каршы көрәш башлый, аны гына түгел, «фазылщина»ны фаш итә.

Шагыйрь коллектив белән шәхес арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, кеше аңында сакланган искелек калдыклары белән тартышуны әхлак, мәхәббәт сафлыгы өчен көрәш фонында ача.

Ә. Давыдов — 50—60 нчы елларда иң күп иҗат иткән язучыларның берсе. Ул колхоз тормышына багышланган поэмаларын укучыга бер-бер артлы ирештерә тора: «Алтын көз» (1949), «Ферма кызы» (1952), «Уяну» (1958—1960), «Су юлы» (1960) һ.б. Авылдагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне беркадәр бизәп, шомартып сурәтләсә дә, әсәрләре шул дәвер рухындагы иҗат җимешләре булса да, Ә. Давыдов вакыйга-хәлләргә үз бәясен бирә, шигъри телне проза, гади сөйләм алымнары белән баетырга омтыла.

Авторның вафатыннан соң архивыннан «Йокысыз төннән соң» исемле шигъри романы табыла. Авторның эчке каршылыклары чагылган бу әсәр 1972 елда аерым китап булып басылып чыкты.

Нәкъ шул чорда татар авылының авыр һәм катлаулы язмышын үзәккә алган, аның үзенә генә хас матурлыгына сокланып язылган икенче шигъри роман — С. Батталның «Чирмешән якларында» (1934—1970) әсәре төгәлләнә.

Икесендә дә авыл кешесенең тарих җилләренә йөзен куеп, ачы тәҗрибәсе аша олы дөньяда үз урынын эзләве, рухи сафлык өчен көрәшүе турында сүз бара. Ә. Давыдов әсәрендә

кискен, киеренке ритмнар, сөйләшү алымнары өстенлек итсә, С. Баттал романында халык җырлары рухына, мәкаль-әйтем акылына йөз тотыла. Әлеге шигъри романнар — татар әдәбиятының казанышлары.

60—70 нче елларда авылны һәм кешене, тирәлекне һәм әхлакны саклауга багышланган чәчмә әсәрләр күп язылды. Аларны шартлы рәвештә «авыл прозасы», «лирик проза» дип тә төркемлиләр.

Вакыт сынавын үтеп, тормышчан көчләрен, сәнгатьчә матурлыкларын хәзергәчә югалтмаган күп әсәрләрне атап үтәргә мөмкин. Алар — Рафаил Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» (1957), «Йолдызым» (1962), «Тамчылар ни сөйли» (1965), Аяз Гыйләҗевнең «Урталыкта» (1969), «Язгы кәрваннар» (1972), «Җомга көн кич белән...» (1979), Мәхмүт Хәсәновның «Саф җилләр» (1961—1963), Фатих Хөснинең «Утызынчы ел» (1958—1962), Нурихан Фәттахның «Бала күңеле далада» (1962), Атилла Расихның «Язгы авазлар» (1956), «Ике буйдак» (1963), Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Икмәк кадере» (1968), «Чоңгыллар» (1973), Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте» (1969—1972), Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» (1975), Мөхәммәт Мәһдиевнең «Каз канатлары» (1975), «Кеше китә — җыры кала» (1978) һ.б.

Һәркайсы аерым сөйләшүгә лаеклы бу әсәрләрдә авыл кешесенең XX гасыр дәвамында яхшырак яшәү өчен көрәше, изгелек белән начарлык арасында барган мәңгелек тартыш бай сурәтлелек чаралары, сүз тылсымы ярдәмендә күз алдына бастырыла.

Нәкъ менә шул әсәрләрдә татар әдәби теле үсешенең яңа үренә күтәрелә. Мин Шабай, Газиз Мөхәммәтшин, Фаил Шәфигуллиннар иҗатында хикәя нык камилләшә. Шулай да прозаның әйдәп баручы көче, төп жанры булып җыйнак күләмле, эчке егәрле повесть урнаша.

Чор рухын эзләгәндә

Халык тормышына якынлыгы, фәлсәфи өлгергәнлеге, сәнгатьчә нәфислеге белән укучыны сокландырган әсәрләрнең үзәгендә киң мәгънәсендә заманчалык төшенчәсе ята. С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы», Ә. Давыдовның «Себер трактында квартал», Х. Камаловның «Әлмәт эскизлары», Р. Мингалимовның «Күз карасы», Зөлфәтнең «39 нчы квартал» кебек

әсәрләрен кабат укып чыгыйк. Барысы өчен уртак сыйфат — хезмәт кешесен олылау, шәхеснең көченә, кодрәтенә ышану.

Сугышта һәлак булган ирен — Ярулласын — тыныч тормышта алыштырган, кем өчендер яшәүне үзе өчен яшәүгә тиңләгән, татар көенә, моңына гашыйк, әхлагына тугрылыклы Халидә (С. Хәким, «Үрләр аша...») рухи өлгергәнлеге, хакыйкатьнең җиңүенә ышанычы белән күңелдә кала.

Татарстанда нефть табылу, аны күпләп чыгару өчен көрәш, ахыр чиктә туган җиребезнең кара алтын чыгаручы олы үзәккә әверелүе әдәбият үсешендә мәгълүм эз калдырды. Дөрес, бу вакыйганың эченә кермичә, тышкы ягын гына үзәккә алган бик күп ялтыравык шигырьләр, җырлар, очерклар, вакыт сынавын үтә алмыйча, әдәбияттан төшеп калды.

Эшчеләр сыйныфының яңа катламы турында күләмле әсәрләр 50 нче елларның урталарында күренә башлый (И. Гази «Гади кешеләр», Ш. Маннур «Җир әнкәнең сылу кызы» һ.б.). Ш. Маннур шигъри повестенда әкият алымы, җир асты маен сылу кызга тиңләү хезмәтне яңачарак тасвирларга мөмкинлек бирә.

Нефть чыгару белән бәйле рәвештә туган яңалык-үзгәрешләр, авыл белән шәһәр арасында туа килгән каршылыклар Гариф Ахуновның «Хәзинә» (1963), «Хуҗалар» (1968), Шамил Бикчуринның «Каты токым» (1972), «Тирән катлам» (1981), Мәхмүт Хәсәновның «Шөгеровлар» (1980) кебек романнарында шактый төгәл чагылыш тапты. Аеруча уңыш казанып, күп телләргә тәрҗемә ителгәне «Хәзинә» романы булды. Ул — эшчеләр тормышын үзәккә алган әсәрләр арасында үзенә бер үр, татар нефтенең яшьлегенә мәдхия булып калды.

Әмма татар әдәбиятында бу юнәлеш авыл тормышын, игенче язмышын үзәккә алган, табигатьне саклау өчен көрәшкә чыккан әсәрләрдәге сәнгатьчә югарылыкка күтәрелә алмады.

50—60 нчы елларда зур күләмле, вакыйга-хәлләрне иркенләп, тәфсилләп хикәяләп биргән, сюжетның буеннан-буена ачыла килгән геройлы олы әсәрләр күп языла.

Ибраһим Гази егерме ел дәвамында татар халкы тормышының бер тарихи дәверен иңләгән «Онытылмас еллар» (1946—1966) эпопеясын иҗат итә. Язучы төп игътибарын 1917 ел вакыйгаларының татар авылына, төрле катлам кешеләр язмышына алып килгән уңай һәм тискәре күренешләрен ачуга, сыйнфый көрәшнең кырыслыгын күрсәтүгә юнәлтә. Әсәрнең

теле искиткеч төгәл, анык, шул ук вакытта образлы һәм бай булуы белән аерылып тора.

Мирсәй Әмир «Ялантау кешеләре» (1953), «Саф күңел» (1959) исемле бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән, киң панорамалы романнарында безнең чорга якынрак килә. Үзәктә 1941—1945 еллар сугышы вакыйгалары, тылда яшәгән кешеләрнең фидакяр хезмәте, шул авырлыкларны җиңү барышында шәхеснең рухи үсүе тора. Артык вак хәл-әхвәлләрне сурәтләү, озынлык үзен сиздерсә дә, М. Әмир романнары үз укучысын тапты.

Ләкин бу чорда да әдәбиятның үсеше тигез генә бармады. «Халыклар дуслыгы» дигән ясалма тәгълимат милләтләрне көчләп берләштерү сәясәтенә алып чыкты.

Татар тормышына багышланган һәр әсәрдә диярлек башка милләт вәкилләре урын алырга тиеш иде. Кави Нәҗминең Сталин бүләге алган «Язгы җилләр» исемле (1948) революция вакыйгаларына багышланган тарихи әсәрендә, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» (1948), «Сүнмәс утлар» (1958) романнарында бу юнәлеш аеруча калку чагылыш тапты.

Бик күп әсәрләрдә персонажлар һаман да шул артта калган һәм алдынгы, ялкау һәм тырыш, комсыз һәм намуслы кешеләрдән тора. Алар арасында туган ясалма каршылык соңгыларының җиңүе белән тәмамлана. Әлеге китаплар, татар халкы өчен иҗат ителүдән бигрәк, Мәскәүдә русча яңгырау өчен языла лар. Тәрҗемәченең эшен җиңеләйтү максаты әдәби телне ярлыландыруга, сорылыкка, бертөслелеккә алып килә. Бай татар теле тылсымлы, сыгылмалы көчен югалта. Төссез, алынма сүзләр күбәя. Язучылар арасында да хакимият куштаннары туа. Торгынлык елларында алар дан, шөһрәткә күмелә.

Әдәбият дин белән көрәшкә тартыла. Милли рухка каршы сугыш татар мәктәбен һәм динне тәмам юкка чыгару рәвешен алды. Чөнки рухи пакьлек, гореф-гадәт, халыкның кабатланмас үзенчәлекләре, әхлагы дини мохиттә ныграк саклана. Телнең терәге — милли мәктәп.

Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» исемле күләмле язмасы (1967) динне «фаш итүгә» багышланган иң түбән әсәрләрнең берсе булды.

Әлбәттә, торгынлык елларында иҗат иткән барлык татар язучылары да җайлашу, хакимияткә, партиягә ләббәйкә җырлау юлына төшмәде. Татар әдәбиятында мондый фикерләү

белән килешмәгән, шәхес иреген яклаган, тормышны әзер калыплар ярдәмендә генә сурәтләүдән баш тарткан юнәлеш тә яшәде һәм җиңеп чыкты.

Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» (1962), Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге» (1955), «Рәшә» (1965), Салих Батталның «Сигезенчесе кем?» (1965), Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» (1965), «Бер ананың биш улы» (1976), Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» (1976) кебек әсәрләрендә тормыш бөтен катлаулылыгында сурәтләнә. Мирвәли образында А. Гыйләҗев сталинчылыкның, көчләп күмәк хуҗалыкка кушуның күпме кеше язмышын ачы хәсрәт ярларына алып килүен фәлсәфи тирәнлек һәм психологик нечкәлек белән сурәтләп бирә.

Ә. Еники үзенең күләмнәре белән җыйнак повестьларында бүген дә заманча яңгыраган мәсьәләләрне калкытып куя: ялган матурлык һәм комсызлык, тышкы ялтырау һәм рухи ярлылык, гамьсезлек һәм шәфкатьлелек. Бу төр әсәрләрдә купшылык, ясалма кәпәренү кими бара, тормышчан, уйланучан проза алга чыга, нык, төгәл сүз үз урынына кайта.

Сатираның югары таләпләренә җавап биреп, Х. Сарьянның «Нокталы өтер» (1976), А.Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» (1979—1980) әсәрләре дөнья күрә. Чәчрәп торган юмор, усал сатира, нечкә төрттерү сарказм белән кушылып, тормышыбызда очрап торган күләгәле яклар яктыга тартып чыгарыла.

Алдарак 60—70 нче еллар прозасының бер үзенчәлеген без тарихи-шәхси башлангычка игътибар үсү, халык һәм әдәбият узган юлларны яңача бәяләргә, аңларга омтылудан гыйбарәт дигән идек.

Өлкән һәм урта буын язучылары XX гасырны үз шәхси тәҗрибәләре, тормышлары аша иңләргә омтылалар. Ф. Хөсни «Минем тәрәзәләрем» (1963) исемле язмаларында үзе яшәгән чорга бәя бирә. Күз алдыннан гыйбрәтле язмышлар, сөенечле һәм көенечле хәлләр уза. Повесть бай һәм нәфис теле белән җәлеп итә.

«Туган ягым — яшел бишек» (1967), «Җидегән чишмә» (1977) әсәрләрендә Г. Бәширов кешенең рухи бөеклегенең серләрен аңларга омтыла. Нинди генә авыр шартларда яшәмәсен, татар авылы үзенең гореф-гадәтләрен, әхлагын, аң-белемгә омтылышын сакларга тырыша. Саф һәм югары рухлы кешеләр турында ул сәнгатьчә матур итеп, яратып, сокланып яза. Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» (1973) әсәре татар

әдәбиятының күренекле вәкилләрен искә алуы белән үзенчәлекле.

М. Әмир өч кисәктән торган истәлекләрен («Без бәләкәй чакларда», «Үсә төшкәч», «Казан») 1973—1982 елларда бастырып чыгара. Башкортстан табигатенең матурлыгын, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын үз башыннан, күңеленнән узган хәлләргә төреп сурәтли.

Автобиографик әсәрләр арасында С. Батталның «Баштан үткәннәр» (1972) повесте татар укучысын очучылар даирәсенә алып керүе белән аерылып тора. Атаклы очучы В. Чкалов белән беррәттән, Г. Ибраһимов, А. Фадеев образлары белән дә танышып үтәбез.

Урта буын язучыларыннан Г. Ахунов «Йолдызлар калка» (1977) повестенда документаль жанрга мөрәҗәгать итә. Биредә инде укучы 60—70 нче еллар әдәби процессы, шул чорда иҗат иткән И. Гази, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, Г. Кашшаф кебек күренекле шәхесләр белән таныша.

70 нче елларда чал тарих сәхифәләренә игътибар арта, чын мәгънәсендәге тарихи әсәрләр иҗат ителә башлый. Безнең тарих сезнең кулда, ди, сугыш кырына килеп чыккан XIII гасыр татар шагыйре Кол Гали С. Хәкимнең «Дуга» поэмасында.

Г. Афзал тарихның изгелеген яклап чаң суга, мәкальәйтем, хикмәтле сүз йолаларына таянып, олы хакыйкатьне берничә юлга сыйдыра:

Әшәке кешеләр була,
Әшәке халык булмый.
Әшәке тарихчы була,
Әшәке тарих булмый.

Киң катлам укучы өчен чыгарылган тарихи әсбапларда, дәреслекләрдә татар тарихы берьяклы яктыртылды, рәсми сәясәт яулап алган, җиңгән халык җырын көйләде. Болгар чоры, Казан ханлыгы турында без әле яңа гына, СССР таркалганнан соң гына, уйлау, фикер әйтү һәм язу хокукы алдык.

Н. Исәнбәт, А. Расих, Н. Фәттах, М. Хәбибуллин, М. Госманов, Т. Миңнуллин, И. Юзеев кебек төрле жанрларда эшләүче каләм ияләре ком барханнары, яндырылган, җимерелгән кала хәрабәләре астында калган тарихны укучыга ирештерү рухы белән яшиләр.

М. Галәүдән соң өзелеп торган тарихи роман иҗат итү юлына беренчеләрдән булып «Итил суы ака торур» (1970) әсәре белән Нурихан Фәттах чыкты. 1973 елда ул «Кол Гали» драмасын иҗат итте, 1977 елда киң колачлы, төрки халыкларның бик борынгы тарихына юл алган «Сызгыра торган уклар» исемле романының беренче кисәген тәмамлады.

Әлеге әсәрләр янына Туфан Миңнуллинның «Канкай угылы Бәхтияр» (1974) тарихи драмасы һәм Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» (1984) романы өстәлде.

Бу әсәрләр татар халкының олы тарихын яңабаштан барлау, өйрәнү һәм яктырту эшенә нигез салдылар.

Табигый ки, татар әдәбиятының эчтәлеге, юнәлеше, сәнгатьле куәте аерым юнәлешләргә генә сыеп бетми. Кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм табигать, мәхәббәт һәм нәфрәт, хәтер ярлары һәм киләчәк кебек мәңгелек борчуларны үзәккә алган әсәрләр күп языла бу чорда.

Әхлак һәм гаилә мәсьәләләренә аеруча драматургия сизгерлек үрнәге күрсәтә. Н. Исәнбәт «Рәйхан» (1949), «Гүзәл» (1950), «Зифа» (1954) пьесаларында татар хатын-кызлары образлары галереясын иҗат итә.

Ә. Фәйзи дә каләмдәшеннән калышмый. «Отышлы кияү» (1947), «Күршеләр» (1956), «Сәйдә апа» (1955) кебек комедияләрендә, озак еллар сәхнә тоткан «Рәүфә» (1957) исемле психологик драмасында татар тормышының, гореф-гадәтенең, үзгәрә барган рухи даирәсенең бик күп якларын калкытып куя.

Шул мираска таянып, алдагы елларда Гамир Насрый, Хәй Вахит, Юныс Әминев, Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Рөстәм Мингалим, Ризван Хәмид кебек сәхнә сәнгатенең серләренә тирәнтен төшенгән оста драматурглар үсеп чыкты.

Һәр чорда әдәбиятка яңа, сәләтле көчләр өстәлә тора: Р. Төхфәтуллин, Ә. Баянов, Ш. Галиев, И. Юзеев, Х. Сарьян, С. Сөләйманова, М. Хәсәнов, Н. Мадьяров, М. Шабаев, М. Маликова, М. Юныс, Ф. Яруллин, Г. Зәйнашева кебек исемнәр белән теләсә кайсы әдәбият горурлана алыр иде.

Кешенең эчке дөньясына, шатлыгына-кайгысына, сөенеченә-көенеченә игътибар арту шигырь китапларының, шигъри бәйләмнәрнең исемнәрендә үк күренә: С. Хәким «Суд залында», Ә. Давыдов «Кеше бәхете», Г. Афзал «Вөҗдан сүзе»,

Ш. Галиев «Сөенечләрем, көенечләрем» һ.б. Үзәктә — кеше белән җәмгыять, кеше белән табигать арасындагы катлаулы бәйләнешләрне яңача, самими һәм гадәти итеп тасвирлауга омтылыш ята.

Тормышның яңа адымнары акрынлап әдәбиятка үтеп керә. Чорга хас илаһиятне эзләү рухы иҗатка яңа килгән буынны алдагы елларда үзенчәлекле ачышлар юлына алып чыга.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен 50—60 нчы еллар әдәбиятында сугыш темасы үзәктә кала? Аны яктыртуда нинди сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә?

2. Авыл тормышын тасвирлаган һәм табигатьне саклау темасына багышланган иң яхшы әсәрләрне атагыз.

3. Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Х. Сарьян кебек язучыларның тормышны тәнкыйди күзлектән чыгып сурәтләгән әсәрләрен санагыз, бәя бирегез.

4. Татар тарихына багышланган нинди әсәрләрне беләсез? Тарихи роман гадәти проза әсәреннән нинди сыйфатлары белән аерылып тора?

5. Үзәктә язучыларның үз шәхси биографияләре яткан әсәрләрне атагыз. Аларның үзенчәлекләрен күрсәтегез.

Гомәр Бәширов
(1901—1999)

Татар прозасын халыкчан рух белән сугарылган, сәнгатьчә югары роман, повесть һәм хикәяләр белән баеткан Г. Бәширов иҗат юлын «Канлы бармаклар» хикәясе белән 1931 елда башлап җибәрә. Шуннан соң «Сиваш», «Намус», «Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә», «Сарут» кебек әдәбиятыбызның горурлыгы, мактанычы булган әсәрләр язылa. Татар халык язучысы Гомәр Бәширов иҗатында әдәбиятыбызның соңгы алтмыш еллык үсеш юлы, аның халык язмышына якыная баруы, әхлакый-фәлсәфи көче һәм сәнгатьчә камиллеге чагылыш тапты.

«Намус» романына гомуми бәя

Сугыш чорында языла башлап, 1947 елда төгәлләнгән, икенче елны «Совет әдәбияты» журналында һәм аерым китап булып басылып чыккан «Намус» романы Г. Бәшировка язучылык шөһрәте алып килгән бәхетле язмышлы әсәр булды.

1951 елда романга Дәүләт премиясе (ул вакытта Сталин исеме белән йөри) бирелә. «Намус» немец, кытай, поляк, венгр, вьетнам, украин, казах, үзбәк һ.б. бик күп телләргә тәрҗемә ителә, матбугатта югары бәя ала.

Әсәрнең уңышын премиягә генә кайтарып калдыру берьяклы булыр иде. Чөнки «Халыклар атасы» исемендәге бүләккә лаек булган әсәрләрнең байтагы тарихи чор истәлеге булып калды. Ә «Намус» бүген дә укыла, күңелдә, йөрәктә яши.

Ни өчен ул күтәп алынган, вакыт сынавын үтәрлек әсәр булды соң? Хәтер канатында шул чорга кайтып карыйк.

40 нчы еллар әдәбиятында сугыш темасы өстенлек итә. Фронтның үзен, совет солдатының батырлыгын, дошманнан өстенлеген тасвирлаган әсәрләр вакыйга киеренкелеге, төрлелеге белән җәлеп итә. Дары, кан исе, фаҗига, романтик батырлык, разведчик кыюлыгы ул тәүге карашка «Намус»ның беренче битләрендә тасвирланган орлык чүпләп утыру эше генә түгел кебек.

Тыл тормышы белән укучыны шаккатыру, сискәндерү, ышандыру бик кыен. Бу төр әсәрләрнең күбесе тонык, төссез чыга.

Чынлыкта исә ил язмышының хәтәр борылышларында кешенең характеры, туып үскән җиренә тугрылыгы сугыш кырында да, бодай басуында да бер үк дәрәҗәдә сынала. Фашизмны тар-мар итүгә керткән өлешне кулына мылтык тотып дошман өстенә ташлануга, окоп тормышына гына кайтарып калдыру — берьяклы дигән карашны уздыра Г. Бәширов «Намус» романында. 1941 елның декабрь суыкларында герман армиясенең «билен сындырган» сугышчыны тукландырасы, җылы киемнәргә төрәсе дә бар иде әле.

Сугыш илнең һәр почмагына явыз шәүләсен ташлый. Элек таза, гаярь ирләр алып барган тормыш авырлыгы карт-коры һәм хатын-кыз җилкәсенә төшә. Г. Бәширов гади бер татар авылы тормышына сугыш алып килгән фаҗигане, кешеләр язмышындагы үзгәрешләрне тирән рух, бай, сурәтле тел белән тасвирлап бирүгә ирешә. Гадәти тормышта ул олылыкны, бөтен илне борчыган вакыйга-хәлләрне күреп ала.

Совет халкының әле чын-чынлап яшәгәне дә юк. 1921 елгы ачлык, гражданнар сугышы калдырган яралары төзәлер-төзәлмәс, авылның уңган кешеләре — кулаклар һәм зыялылар белән көрәш башлана, намуслы һәм акыллы кешеләрнең күбесе кырыла яисә төрмәләргә, Колымага озатыла; Хәсән күле, Фин кампанияләре килеп чыга.

Икенче Бөек Ватан сугышы — халык өчен янә бер җитди сынау. Г.Бәширов романы шул хакта.

«Намус» күп еллар дәвамында социалистик реализм казанышы буларак бәяләнә килде. Әмма әлеге иҗат методы юкка чыкты, ә роман яши, тыйнак, күзгә бәрелеп тормаган матурлыгының яңа сыйфатларын ача килә. Янәдән сорауны кабатлыйк:

Романның тәэсир көче нәрсәдә? Нинди сыйфатлары белән ул хәзерге укучының рухи дөньясына үтеп керә?

Әсәр турында язган М. Әмир, С. Хәким, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Ф. Хатипов, Ф. Миңнуллин кебек әдипләр язучының сугыш фаҗигасен сурәтләү осталыгына, татар авылы тормышын аерым шәхес язмышы аша сәнгатьчә матур тел белән күрсәтә белү көченә игътибар иттеләр. Алар хаклы.

Г. Бәширов әсәре фикергә, тормыш һәм яшәеш турында уйлануларга бай. Биредә чорның, тыл яшәешенең бик күп яклары үзәккә алына, яңача тасвирлана.

Нәфисә

«Намус»ның төп ачышы — Нәфисә образы. Вакыйга агышы, шәхесләр язмышы ахыр чиктә шул мөлаем хатын образына барып тоташа. Аның белән һәр очрашу күңелдә матур һәм изге хисләр уята.

Нәфисә буш урында туган образ түгел. Татар әдәбиятында ягымлы, рухи бай, үрнәк-өлге булырдай хатын-кыз образлары күп. Алар татар әдәбиятының йөзек кашы, шатлыгы, сөенече була килделәр. Г. Кандалыйның Сахибҗәмалы, Ф. Әмирханның Хәяты, Ш. Камалның Газизәсе, М. Фәйзинең Галиябануы, Г. Исхакыйның Зөләйхасы, Г. Кутуйның Галиясе, М. Җәлилнең Фәйрүзәсе кебек мәшһүр образлар янына Нәфисә өстәлде.

Язучы гадәти авыл бригадирын яратып, аның төсен, битен, буен-сынын, ашыкмыйча, нечкә һәм төгәл итеп тасвирлый. Немец телендә романның «Нәфисә» дип аталуы тикмәгә генә түгел. Ул татар хатын-кызларына хас тыйнаклык, сабырлык, язмыш басымына тешне кысып түзә алу, сөя һәм сөелә белү кебек бик күп сыйфатларны үзенә җыеп алган.

Шуңа да ул күңелдә олы һәм шул ук вакытта җирдә нык басып торган, шатлыгы һәм кайгысы, сөенече һәм көенече, табышлары һәм югалтулары белән саф һәм ихлас шәхес булып хәтердә кала.

Әкият батырлары төсле үзенә көчне һәм ышанычны туган җирдән, дус кызларының теләктәшлегеннән алып, Нәфисә күз алдында үсә. Аның хезмәт сөюе, җиңүгә ышанычы соңгыларына күчә, аларга дәрт һәм куәт өсти.

Нәфисәнең югары уңыш алуга юнәлгән ихтыяры, ашлык карагы Сәйфине фаш итүе, Зиннәтнең бәйләнүен горур кире кагуы характерының ныгый баруын күрсәтә.

Дөрес, урыны белән Нәфисәне беркадәр үстерү, күтәрү, идеаллаштыру, тормыш авырлыкларын җиңел ерып чыгуы сизелә. Биредә язучының, чор таләбенә җавап биреп, һәрьяктан килгән үрнәк-өлге шәхес тудыруга омтылышы чагыла.

Әдәби әсәр, идеологик максатларга буйсынганда, сәнгать җимеше буларак һәркайчан оттыра.

Әмма Нәфисә үзен «әзер калыпка салырга» рөхсәт бирми. Аның беренче мәхәббәтенең уңышсызлыкка очравы, Сәйфи каракны үз вакытында күреп алмавы, ире үлеп, берничә ай үтүгә янәдән гашыйк булуы аны нечкә җанлы, тулы канлы кешеләр белән бер рәткә куя. Ул — табигый хис кешесе. Шул ук вакытта уртак кайгы, ил алдында, бригадасы каршында җаваплылык хисе аны тарихи шәхесләр дәрәҗәсенә күтәрә.

Нәфисә образын төрле яклап ачуга автор зур көч куя. Бер яктан, аны төскә-биткә матур, бик күп күркәм сыйфатларга ия хатын-кыз итеп, М. Әмир романга кереш сүздә язганча, җан хәрәкәте аша тасвирласа, икенчедән, Нәфисәне тирәлек, мохит белән берлектә күрсәтү юнәлешендә эзләнә, диалог, эчке монолог, үзалдына уйлану, бәя бирү алымнарына мөрәҗәгать итә. Психологик анализ ысулларын тирәнәйтә, баета.

Тормыш — Нәфисә өчен намус белән яшәү. Күптәннән сынала килгән, ата-бабалардан иң зур бүләк буларак калган әхлак кагыйдәләре — аның өчен язылмаган кануннар. Ул фронттагы ире Солтанга хыянәт иткән Әпипәне дә, кешелегенә кагылган, нахакка рәнҗеткән көнче каенанасын да гафу итми.

Нәфисә ялгыз кыя төсле җирдә берүзе басып тормый. Аны тормышка гашыйк, кулы эшкә ятышып торган Мәүлиха, көчле, уңган Зәйнәпбану, хискә бай, шигъри җанлы, «нечкә тойгылы, сабыйларча саф һәм йомшак күңелле» Карлыгач, үзе теләп фронтка киткән, максатына ирешә белүчән Гөлзәбәр, мәхәббәткә сусап яшәгән, шуңар да нәфесен тыя алмаган Әпипә образлары тулыландыра, баета. Аларның берише нечкә күңелле, тиз рәнҗүчән, икенчесе кызу канлы, өченчесе каты бәгырьле, үзе турында күбрәк кайгыртучан. Шулар белән һәртөрле мөнәсәбәтләрдә Нәфисә холкының төрле яклары өскә калка, тулырак ачыла.

Геройларын Г. Бәширов ашыкмыйча, салмак алым белән, тәфсилләп тасвирлый. Тынгысыз колхоз рәисе Тимергали, төпле сүзле, әмма үз фикеренә, партиягә ихластан ышанып яшәүче парторг Айсылу, шашкынлы мәхәббәткә лаеклы, туган

тел турында иң матур сүзләрне әйткән, гомерлек романтик Хәйдәр образлары күңелдә кала.

Һәр характерның эчке яшәешен хәлләр, мохит аша уйлану, үзара аралашу ярдәмендә ачарга омтыла язучы. Күбрәк тормышның матур якларын сурәтләсә дә, уңай шәхесләр белән беррәттән, тискәре адәми затларга да урын бирә. Нәфисәнең беренче, язгы чәчәк төсле саф мәхәббәтен рәт җеткән чибәр музыкант Зиннәтне автор кабул итми. Элеккеге колхоз рәисе, алдакчы, комсыз һәм әйтерсең лә шул комсызлыгы кулын корыткан Сәйфи, ил өстендә фашизмның кара шәүләсе асылынып торганда бакчасын киңәйтеп калу хәстәрен күргән Бикбулат карт образлары аша кешенең канына сеңгән саранлык, башкалар исәбенә баеп калырга омтылу югары әхлак күзлегеннән тәнкыйтькә юлыга. Вак җанлы кешеләрне сурәтләгәндә, автор күпертү, арттыру алымнарына да мөрәҗәгать итә. Шулай да үзе кабул итмәгән кешеләрне үтә кара буяуларда сурәтләү юлына басмый язучы. «Сәйфи чибәр генә киенеп йөри торган күркәм чырайлы кеше иде». Әмма Мәүлиха түтигә аның күзләре «бик хәйләкәр дә, оятсыз да кебек» күренәләр.

«Намус» романында Г. Бәшировның язучы буларак осталыгы үсүе дә ачык күренә. М. Әмир фикеренчә, бу әсәрендә ул «үзенең бай күңел хәзинәсендә булган бөтен буяуларын эшкә куша».

Табигать күренешләрен, бер-берсенә һич кенә дә охшамаган төрле язмышлы кешеләрне җанлы итеп күз алдына бастыруда аңа сөйләм телен, халык иҗаты байлыкларын — җырларын, мәкаль-әйтемнәрен, канатлы гыйбарәләрен — яхшы белү, урынлы файдалану ярдәм итә.

Мәсәлән, Мәүлиха түти, Әпипә белән бәхәсләшеп, Нәфисәнең төп сыйфатын бер җөмләгә сыйдыра: «Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар».

Мишәр хатыны Әпипәнең холкы, характеры шулай ук ике юлга сыя: «Акылы кушканча түгел, күңеле кушканча гына йөри торган бәндәләр дә була бит».

Романның иркен һәм сыйдырышлы композициясе, үткән белән хәзергене якынлаштырып, бер үремтәдә сурәтләргә мөмкинлек бирә. Булачак райком секретаре Мансуровның әтиәнисен кемнәрнең ничек үтерүләре, яралы Җәүдәтне аякка

бастырган ак сакаллы, әкияттән иңгән мөлаем карт («карт» дип әйткәндә, күз алдына шул шәхес килеп баса) белән очрашу вакыйгаларын искә төшерү персонажларның хәзерге халәтен, дөньяга карашларын аңлауга хезмәт итә. Язучы рухи дөньяны үсештә, хәрәкәттә күрсәтергә омтыла.

Романга замана бәясе

Бүгенге көн югарылыгыннан килеп хөкем йөрткәндә, моннан биш дистә еллап элек язылган әсәрнең искечәрәк яңгыраган урыннары булу табигый. Аерым алганда, тормышны кайбер хәлләрдә берьяклы бизәп, матурлап сурәтләү ачык ярылып ята.

Шул чор калыбы идеаль герой төшенчәсе Нәфисәне артык кырыс итеп сурәтләүгә алып килә. Аңа вакыты белән кешелекле моң, җылылык, шәфкатьлелек (әйтик, Әпипәгә мөнәсәбәттә) җитенкерәми.

«Сәнгать халыкка хезмәт итә» кебек артык гомуми, дөрес сүзләрне кабатлаудан тәм тапкан райком секретаре Мансуров — әзер өлгегә куып кертелгән образ. Аның Хәйдәр белән коммунизм һәм яңа кеше турындагы фәлсәфи әңгәмәләре, кулакларның барчасын «тотып атарга... илдән сөрергә» чакырулар романның әһәмиятен киметәләр. Хәер, авылдагы партия оешмасы секретаре Айсылу да җитәкчесеннән әллә ни ерак китми.

Шул чор рухындагы үгет-нәсыйхәтчелек, һәрнәрсәне ваклыклары белән сурәтләү, кайбер үзара сөйләшүләрнең яңалык алып килмәве романның сәнгатьчә яңгырашына зарар китерми калмый.

Тәфсилле ваклык, үгет-нәсыйхәт янәшәсендә үк урын алган саннар, йөкләмә үтәлү турындагы рапортлар авыр укыла. Үзара ярышны, колхоз системасын артык күтәрү ышандырып җиткерми. Сугышның авырлыгы ахыр чиктә аерым кешеләр, болай да ачлы-туклы яшәгән хатын-кыз җилкәсенә төшә. Чәчүлеккә орлык җитми икән, рәхим итеп, өеңнән кырыпсеберeп кил! Хезмәтеңә тигән икмәкне дә Сөмбел шикелле үсмерләрдән җыелышта кычкыртып алалар. Оялтып, әрләп, кызыл сүз сөйләп, намусына кагылып, үзен хәерче калдырып, икмәкне кире дәүләт амбарына кайтаралар. Бу очракта язучы яхшы ният белән, әмма үзе дә сизмәстән, Совет хакимиятенең

шәхесне изүен, талавын, өзлексез киеренке халәттә тотуын күрсәтә.

Шул ук вакытта «Намус» халыкның көчен, тормышка, яшәүгә мәхәббәтен үзәккә алуы, тирән лиризмы һәм бай әдәби теле белән һаман да заманча яңгырый.

Г. Бәширов «Намус» романында тукталып калмады. «Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә», «И язмыш, язмыш», «Сарут» кебек әсәрләрендә ул «Намус»та бөреләнгән үрентеләрне, юнәлешләрне дәвам иттерә, үстерә. Ул һәрвакыт хәрәкәттә, эзләнүдә, һаман да яшьләрчә дәрт, омтылыш, ният һәм иҗади рух белән яшәде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Тәнкыйть Г. Бәшировның «Намус» романын сугыштан соң иҗат ителгән иң уңышлы әсәрләрдән саный. Шул фикер белән килешәсезме? Әсәрнең тәэсир көче нидән гыйбарәт?

2. Г. Бәшировның тыл тормышын тасвирлаудагы яңачалыгы турында нәрсә әйтә аласыз?

3. Романның исеме сезгә ошыймы? Тәрҗемәче ни өчен немец телендә романны «Нәфисә» дип атаган?

4. Нәфисәнең шәхес буларак үсеше нинди вакыйгаларда ачык төсмерләнә?

5. Үзләренчә яшәргә омтылган Сәйфи, Әпипә образларына карашыгыз нинди? Әпипәнең тел үзенчәлекләренә игътибар итегез.

6. Хәзерге көн югарылыгыннан торып, әсәрнең кимчелекләрен, йомшак якларын ничек бәялисез?

7. «Намус» романы һәм бүгенге тормыш» дигән темага сочинение языгыз.



Хәсән Туфан
(1900—1981)

Шагыйрь Хәсән Туфан XX гасыр башланганда дөньяга килә. 20 нче елларның урталарында инде талантлы шагыйрь булып танылa. Тукай, Такташларның шигъри эстафетасын дәвам итеп, ул 20—30 нчы елларда шигъриятне яңа рухи кыйммәтләр белән баета. 30 нчы елларның ахырында аны язмыш көтелмәгән хәвефле сынаулар алдына куя. Үзенең җырчысы итеп таныган дәүләт, аның сәяси даирәләре шагыйрьне «халык дошманы» дигән кара тамга белән тамгалыйлар. Әмма милли шигъриятебез бәхетенә, татар халкы бәхетенә ул исән кала.

Иҗатының тормышчан-биографик нигезләре

«Шагыйрьнең үзе турында белергә теләсәгез, аның шигырьләрен укыгыз» дигән мәгълүм гыйбарә бар. Шушы ук фикерне куәтләп, Туфан үзе дә түбәндәгечә язды:

Ничек икән синең йөрәк?— дисең,
Ничек икән гомер көннәрең?—
Кулыңдагы китабымда, чордаш,
Шигырьләрдә минем йөрәгем.

Әмма шагыйрь йөрәген тулырак аңлар өчен, аның биографиясен, ул кичергән әһәмиятле вакыйгаларны, ул яшәгән урыннарны, аның тормыш юлы кагылып үткән төбәкләрне дә белергә кирәк. Чөнки шигырьдә һәр сүз, һәр детальнең әһәмияте бар. Шагыйрьгә генә хас шундый биографик моментлар,

географик атамалар Туфан әсәрләрендә дә әледән-әле очрый тора. Аның әсәрләрендә Татарстан, Урал, Себер кебек исемнәр һәм шул якларның табигатенә, көнкүрешенә караган сурәтләүләр, күренешләр байтак. Олыгая башлагач, бу исемнәргә караганда да ешрак телгә алынган тагын бер исем бар. Ул — шагыйрь туган авыл. Бу авыл элекке Казан губернасы Аксубай волостена кергән һәм Иске Кармәт дип атап йөртелгән. Хәсән Туфан шушы авылда 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән 9 декабрендә) крестьян гаиләсендә унынчы бала булып дөньяга килгән. Соңрак аның поэзиясендә Кармәт иске авыл булып түгел, ә шагыйрьнең балачак һәм яшьлек истәлекләрен саклаган, имәннәре, каеннары, таллары, чәчәкләре белән күңеленә сеңгән матур як булып, Себердә, Уралда йөреп чыныккан гайрәтле рухлы «Геркулес кебек ирләр»нең Туган иле булып күз алдына китерелә.

Шагыйрь үз иҗатында туган ягының тарихи-социаль үзенчәлекләренә нык таяна. Ирек сөюче борынгы бабаларыбыз Кармәт якларына алпавыт изүеннән качып килеп, урманда яңа җирләр арчып утырганнар. Әмма урман эченә кереп урнашсалар да, каен, усаклар гына аларны һәртөрле изелүләрдән саклап кала алмаган; алар бөлгенлектә, ярлылыкта яшәргә дучар ителгәннәр. Өстәвенә аларны көчләп чукындырырга маташканнар. Алар, үз диннәрен, гореф-гадәтләрен, телләрен саклау өчен, көрәшләрен дәвам иткәннәр. Әлеге рухи изелүдән Хәсәннәр гаиләсе дә читтә калмаган.

Кармәт офыклары — кечкенә Хәсән танып белгән беренче шигъри офыклар ул. Автобиографик язмасында шагыйрь соңыннан аларны түбәндәгечә искә ала:

«Әни минем, гәрчә язу белмәсә дә, халыкның бер баласы буларак, ифрат шигъри җанлы кеше иде. Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә иң әүвәл әнием өйрәтте мине. Белеп, максат итеп түгелдер, әлбәттә, тумыштан ук үтә нечкә күңелле, хискә бай кеше булгандыр. Тормышның безне чолгап алган ямьсез якларын ул минем күздән яшерергә тырышкан, күңел күземне табигатьтәге ямьлелекләргә юнәлтергә теләгән, күрәсең. Ул мине ишегалдына яки бәрәңге бакчасына алып чыга да дөньяны күрсәтеп йөри, кайткан яки киткән киек казлар, торналар белән генә түгел, куаклар, таллар, җилләр, йолдызлар белән дә сөйләшә башлый иде. Йолдызларны танырга, табарга өйрәтә, аларның исемнәрен әкиятләргә кушып сөйли иде. Әни миндә «Бар нәрсәнең дә җаны бар икән, чишмәләр

генә түгел, җилләр дә, яфраклар да, йолдызлар да сөйләшә икән» дигән иман тудырды. Мин, ул замандагы һәрбер авыл баласы кебек, һәртөрле мифларга — шүрәлеләр, бичуралар, убырлар, җеннәр барлыгына ышанып үстем. Бу җәһәттән без — Кармәт малайлары — борынгы Эллада һәм Мисыр балаларыннан, шәт, аз гына да калышмаганбыздыр».

Хәсәннең әтисе күп һөнәрләргә ия кеше булган. Улын да сәгать төзәтү, пыяла кую, иген игү, печән чабу, тимерчелек кебек һөнәрләргә өйрәтә. Бүтән авылларга мич чыгарырга барганда, улын да ияртә. Шундый йөрүләрдән Хәсән, үзе әйткәнчә, «арып түгел, ә баеп, әллә никадәр яңа җыр отып, табышмаклар, мәкальләр, яңа сүзләр отып кайта».

Авылдагы тормышның авырлыгы ир-егетләрне Урал заводларына, Себергә, Лена буендагы Бодайбо алтын шахталарына куа. Читкә киткән авылдашлары, туган абыйлары, авылга кайтып киткәндә, үзләре белән чит җирләрнең дә җырларын, хәбәрләрен алып кайталар. Кечкенә Хәсән шуларны да тыңлап үсә, ишеткән җыр-әкиятләрне күңеленә сеңдерә бара. Шул рәвешчә, аның күңел офыклары да әкренләп киңәя.

Керәшенлеген, христианлыгын ташлаган татарларга үч итеп, патша хөкүмәте Кармәт авылында мәктәп ачарга рөхсәт итми. Шунлыктан Хәсән укырга-язарга әтисеннән һәм үзлегеннән өйрәнә. Авылда мәктәп 1905 елгы революциядән соң гына ачыла. Хәсән күрше чуваш авылындагы мәктәптә бер ел русча да укый.

* * *

Шагыйрь күңелендә тирән эз калдырган төбәкләрнең тагын берсе — мәгърур Урал. Ул Уралның «белем мәгарәләре»нә керә, шахтёр булып җир астына төшә, эшче булып заводларында чыныга. Тормыш «университетларын» ул шунда үтә.

1914 елның язында Хәсән Тобол губернасының Ахман авылында яңа җир алган шахтёр абыйлары янына китә һәм абыйлары белән бергә җир астында бакыр мәгъдәне чыгару эшенә керешә. Эшләп-эшләп тә тернәкләнә алмаган абыйлары: «Үзебездән булмады инде... энебезне — кечебезне — җыйнаулашып укырга җибәреп карыйкмы әллә?»— дип киңәшеп, Хәсәнне шул ук елны Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Булачак шагыйрь үз чорының алдынгы уку йортыннан исәпләнгән «Галия»дә азатлык һәм мәгърифәт идеаллары белән янган шартларга килеп эләгә, төрле яклардан

җыелган татар, башкорт, казах укучылары арасында белемен тирәнәйтә. Ул «Галия»дә Галимҗан Ибраһимовтан әдәбият дәресләре тыңлый, аңардан иҗат эшенә илһамландырган сүзләр ишетә, шул ук мәдрәсәдә укыган Шәехзадә Бабич оештырган түгәрәккә йөреп, шигырь серләренә өйрәнә. Әдәби кичәләрдә Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй кебек шагыйрьләрнең чыгышларын ишетә. Сәйфи Кудаш һәм казах шагыйре Баимбәт Майлин белән бер сыйныфта укый һәм дуслаша. Фикер азатлыгына һәм иҗатка омтылу атмосферасында Хәсән үзе дә беренче өйрәнчек шигъри тәҗрибәләрен сынап карый. «Йолдызлар» исемле парчасы мәдрәсәдәге кульязма «Парлак» журналында авторы әйтелмичә генә басылып та чыга.

«Галия»дә ике ел укыганнан соң, Туфан, белем алуын дәвам иттерү өчен акча табарга дип, Уралдагы Лысьва заводына эшкә керә. Анда ул слесарь, токарь булып эшли. «Яраттым мин заводны. Бигрәк тә аның кичләрен, мартен мичләренең, вулканнарны хәтерләтеп, күкләрне кызарткан төннәрен, цехларның металлар музыкасы кебек булып гөрләп, күкрәп торуларын яраттым»,— дип искә ала шагыйрь бу чорны. Ул шунда, большевиклар яклы эшчеләр арасында, башта Февраль инкыйлабын, аннары Октябрь инкыйлабын каршылый. 1918—1923 елларда Урал һәм Себер мәктәпләрендә укыта. Үзлегеннән укып белемен тирәнәйтү белән шөгыльләнә, халык авыз иҗатын өйрәнә. Эшчеләр белән аралашу, алар арасында яшәү аңа киләчәк иҗаты өчен дә бай тормыш материалы тупларга ярдәм итә.

Күңелендәге хисләрен әдәбият аша әйтергә теләү тойгысы, Такташның бу елларда көчле яңгыраган шигъри авазы аны Казанга тарта. 1924 елны ул Казанга килә һәм шунда төпләнеп кала. Башта Бишбалта бистәсендә балалар укыта, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә, радиокомитетта эшли. Казан шәһәре шагыйрь өчен Кармәте, Уралы шикелле үк якын булып китә. Биредә ул Такташ, Кутуй, Җәлил, Нигъмәти кебек якын дуслар таба, үзенең олы мәхәббәтен — артистка Луиза Салигаскарованы очрата һәм аның белән тормыш корып җибәрә. Казанда аның чын-чынлап әдәби иҗат эшчәнлеге башлана, шигъри таланты ачыла. 1924 елдан аның әсәрләре газета-журналларда еш басыла башлый.

Урал һәм Татарстаннан башка географик төбәкләр дә шагыйрь иҗатында байтак очрый: Җаек даласы, Кара-Ком чүле,

Ташкент арыклары, Себер урманнары һәм далалары... Болары да — шагыйрь биографиясе һәм язмышы белән бәйле урыннар. Озын юлның бер өлешен ул үз теләге белән, үз ихтыяры белән сәяхәтче шагыйрь булып үтә. Романтик ашкынулы, тынгысыз күңеле аны сәяхәткә, яңа җирләр, яңа кешеләр, яңа юллар күрергә чакырып тора. Эзләнүчән рухы аңа, Казанга килеп урнашкач та, бөтенләе белән төпләнеп яшәргә ирек бирми: ул ике ел рәттән (1925—1926 елларны) берәр айга үзе эшләгән завод цехларына барып кайта. Шушы сәяхәт нәтиҗәсендә «Урал эскизлары» (1926) исемле атаклы шигырьләр бәйләме һәм поэмалары туа, һәм әлеге цикл Туфанны тиз арада талантлы шагыйрь итеп таныта.

Туфанның 20 нче еллардагы поэмалары «Башлана башлады» (1927), «Ике чор арасында» (1927), «Бибиевләр» (1927) башлыча Урал эшчеләре тормышы белән бәйле. Шагыйрь үзе белгән тормыш материалына мөрәҗәгать итә, үзе күргән вакыйгаларга нигезләнә. Мәсәлән, шагыйрьнең үз тормыш тәҗрибәсенә таянып язуы «Башлана башлады» поэмасында ачык сизелеп тора. Әсәрдәге вакыйгалар 1917 елда, Февраль инкыйлабы белән Октябрь кораллы кузгалышына кадәрге вакыт аралыгында, Урал заводларының берсендә бара. Истәлекләреннән мәгълүм булганча, Туфан да Февраль һәм Октябрь инкыйлабларын Уралда, Лысьва металлургия заводында большевиклар яклы эшче егет буларак каршылый. Поэмада сурәтләнгән Минап, Хабул кебек образларның тормышта прототиплары булуын шагыйрь үзе үк билгеләп үтә. Минап образына өлге итеп, ул иң олы абыйсын ала. Хабул образына үрнәк — Лысьва заводында эшләгән бер зимагур металлург. Шагыйрьнең тормыштагы шундый кешеләргә таянуы, үз күз алдында булып узган тарихи-революцион вакыйгаларга нигезләнүе әдәбиятка яңа тормыш материалын алып керергә, революцион күренешләрне һәм кызыклы язмышлы кешеләрне җанлы итеп тасвирларга ярдәм иткән.

«Язуын язам, ләкин нәрсәдер җитми, һаман нәрсәдер эзләнәм. Шул эзләнүләр мине 1928 ел язында тормыш эченә сәяхәткә алып китте. Сәяхәтем мине Идел буйларыннан башлап көньякка, бабайлар эзе калган якларга таба алып китте. Әбинең ир туганнары, чукындырылудан качып китеп, шул якта гомер иткәннәр. Бу хәлләр «Узып барышлый» дигән шигыремдә чагыла. Кояшка да якынрак якларда — Кавказ һәм Урта Азия республикаларында — халыкларның яңа тор-

мышлары эчендә ике ел буе җаяүләп йөрдем. Яшәрлек акча кирәк булганда, канал казу, таш юллар салу кебек эшләргә тукталгалап уздым.

Сәяхәттә йөргәндә, төрле төрки халыкларның гади вәкилләре белән очрашып, язылмаган фольклорларын өйрәндем. Ашугларны, багшыларны, акыннарны, манасчыларны тыңладым».

Шагыйрь үзе хаклы рәвештә әлеге ил гизүләрен «тормыш эченә сәяхәт» дип атый. «Тормышның үзенә юнәлү» шагыйрьгә ифрат күп нәрсә бирә. Барысыннан да бигрәк, тормыш белән поэзия арасындагы бәйләнешне ачыграк күрергә ярдәм итә. Шагыйрьнең төп эзләнүе дә шушы юнәлештә бара. Ул яңа тормыш төзелүнең җанлы күренешләре белән очраша. Укучыларның үсүен дә, зәвыкларының яңара баруын да күрә. Аңарда шигырьнең яңа чорда тагы да яңарырга тиешлеге турында фикер уяна:

Без, «җыр бу» дип,
Тезмә тоттырдык,
Тезмә — башка, җыр — башка.
Тезмәләрдән битәр тере шигырь —
Җыр сорыйлар бездән чордашлар,—

дигән нәтиҗәгә килә шагыйрь. Лирикасыз калган әдәбиятны оркестрсыз гаскәр белән чагыштыра. Тормыш эченә юнәлү, шул рәвешчә, шагыйрьнең поэзиядә «тере шигырь», «җан тарихы»н ачкан лирик шигырь өчен көрәш башлавына этәргеч бирә. Шушы сәяхәттән соң Туфан поэзиясендә лирик агымның һәм халыкчан образлылыкның көчәеп китүе һич тә очраклы түгел. Әлеге тенденция «Ак каен» (1933), «Озату» (1933) кебек шигырьләрендә аеруча ачык күренде. Әлбәттә, Урта Азиягә һәм Кавказга сәяхәтнең шагыйрь иҗатын яңа темалар, яңа хисләр һәм образлы детальләр белән баетуын да әйтергә кирәк.

Туфан гомере буе ил гизүдән, юл йөрүдән туктамый. Үзе туктаса, заман туктатмый. Бу исә аның тормышының авыр, фаҗигале яклары белән бәйле. Ил күләмендә барган репрессия афәте Хәсән Туфанны да читләтеп үтми. Баштарак ул «Ант» поэмасында җибәргән, хата дип бәяләнгән сурәтләүләре өчен матбугатта тәнкыйтьләнә. Вульгар социологик рухтагы тәнкыйть, ул хаталарны күпертә-күпертә, аңа сәяси гаепләр ташлый. 1937 елны аны Язучылар союзыннан чыгаралар.

1940 елны ул кулга алына һәм Казан төрмәсенә ябыла. Шагыйрь илгә һәм халыкка хыянәт итүдә, контрреволюцион оешма эшендә катнашуда, милләтчелектә, япон шпионы булуда гаепләнә. 1942 елның 7 мартында суд аны атып үтерүгә хөкем итә. Мәсхәрәле һәм хурлыклы үлемен көтеп утырганда да, ул иҗат эшеннән туктамый. Ниһаять, үлем карарын унъеллык төрмә белән алыштыралар. Ул төрмәдә сугыш кирәк-яраклары җитештерүче бригадада эшли, тырышлыгы өчен бригадир дәрәҗәсенә күтәрелә. Мордовиядәге металлургия заводының корыч кою цехында да эшләргә туры килә. Яшереп шигырьләр язуын биредә дә дәвам итә. Үзенең шундый вакытларда фронтта булмыйча, гаепсезгә төрмәдә утыруын ул бик авыр кичерә. СССР Верховный Советы Президиумына язган үтенечендә аның шундый сүзләре теркәлгән: «Илбасарларга каршы аяусыз көрәшкә күтәрелгән халкыңнан читтә булудан да авыррак җәзаның булуы мөмкин түгел һәм юк та.

Халкыбыз һәм партия алдында минем бер бөртек гаебем дә юк. Бөек халыкның иң яхшы уллары! Сездән мине сугышның иң канкойгыч урынына җибәрүегезне, яки миңа үлемнән берничек тә котылып булмый торган эш кушуыгызны, гранаталарга уралып, самурайларның сугышчан машинасы астына ташлану, я булмаса торпеданың руль тотучысы булып, дошман корабленең йөрәгенә барып бәрелеп шартлау, яки шуңа охшаш бүтән берәр максатка юнәлешле бурыч бирүегезне һәм шуның белән күпләрнең тормышын саклап калуны тапшыруыгызны сорыйм... Элеккеге партиясез шагыйрьгә үземнең Ватаныма кабатланмас тугрылыгымны исбатлап күрсәтеп, сезнең кан туганыгыз булып тормыштан китү мөмкинлеген бирсәгез иде...»

Мондый эчтәлектәге хатларны шагыйрь, төрмәдән төрле юллар белән чыгарып, Мәскәүгә җибәрткән. Ләкин аның ирекле үлем бәрабәренә Ватанга тугрылыгын исбатлау турындагы үтенечләре нәтиҗәсез кала. 1950 елның ноябрендә 10 елга хөкем ителү вакытын тутыра. Инде азатлыкка чыгам, дип уйлый. Әмма хыялы тормышка ашмый: аны мәңгелеккә Себергә сөргенгә җибәрәләр.

Аңа Новосибирск өлкәсенең Устарка районында Покровка дигән рус авылында көн күрергә рөхсәт ителә. Биредә ул совхозда көтүче булып эшли, мал карый, кешеләргә сәгатьләр төзәтә. Тора-бара, җир казып, үз куышын корып җибәрә.

Биредә дә ул җан дусты Поэзиядән аерылмый — тоткын шагыйрьнең кичерешләре сурәтләнгән шигырьләр иҗат итә.

Х. Туфанның тоткынлык дәвере 16 елга сузыла. Сталин үлеп, аның сәясәтендәге җитди хаталары ачылганнан соң гына, шагыйрьгә ирекка чыгарга мөмкинлек туа. 1956 елның җәендә ул Казанга кайтып төшә.

Ул өенә кайтканда, аның улы да, хатыны да үлгән була инде, аны тик кызы һәм язучы дуслары гына каршы ала.

Шагыйрь үзен сәяси аклау мәсьәләсен күтәрә.

Татарстан прокуратурасы 1957 елның маенда шагыйрьгә ташланган барлык гаепләрнең нигезсез булуын раслый. СССР Югары судының хәрби коллегиясе шул ук елның август аенда аның тулысынча акланганлыгын хәбәр итә.

1956 елдан Х. Туфан тормышында яңа бер чор башлана. Бу чоры да аның заман рухы белән яшәве, илһамланып иҗат итүе, хисләренең кайнарлыгы һәм киеренкелеге белән үзенчәлекле.

Соңгы көннәренә кадәр ул иҗат эшен дәвам итә.

Сурәтле фикерләвенең үсеше һәм үзенчәлекләре

Хәсән Туфанның иҗаты әдәбиятыбызның җанлы тарихы булып озак елларга сузыла. «Шагыйрьләр, әдипләр күңеле киеренке кыллы арфаны хәтерләтә. Тормыш аның тере, җанлы, сизгер кылларына бармак очы белән генә, аз гына кагылса да яңгырый башлый ул»,— дип язган иде шагыйрь үзе. Бу чагыштыру шагыйрьнең үзенә карата бик тә туры килә. Тормыш дулкыннарына, заман җилләренә һәрчак игътибарлы һәм үтә сизгер бу арфа ярты гасырдан артык ил һәм халык тормышындагы зур үзгәрешләрне көйләп, сөйләп, яңгырап торды.

Шуңа да аның шигырьләрен укып, заман үзгәрешләрен тоярга, татар поэзиясенең идея-тематик һәм сәнгатьчә үсү юлларын да күзалларга, шагыйрьнең үзенең үсүен-үзгәрүен дә күз алдына китерергә мөмкин.

Заман гел үзгәреп тора. Чор белән бергә шагыйрьнең матурлыкны аңлавы һәм аңлатуы да үзгәрә. Бу үзгәрешләрнең нигезен, әлбәттә, шагыйрь шәхесе, аның дөньяга, тормышка мөнәсәбәте, карашы тәшкил итә. Аның әдәби-эстетик карашларына исә әдәби мохит, чорның сәяси-идеологик атмосферасы нык йогынты ясый.

Әдәбиятчылар шул нигездә Х. Туфан иҗатын өч зур чорга бүлеп өйрәнәләр:

1) 20—30 нчы еллар (1924—1940) — шигырьләре, поэмалары белән күренекле татар совет шагыйре булып танылган чоры;

2) 40—50 нче еллар (1940—1956) — сәяси гаепләнеп, әдәби процесстан көчләп читләштерелгән чоры;

3) 60—70 нче еллар (1956—1981) — сәяси тоткынлыктан котылып, иҗатын тулы хокуклы шагыйрь булып дәвам иткән чоры.

* * *

20—30 нчы еллар тәнкыйте (Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти) Туфан иҗатын татар әдәбиятының олы казанышы төсендә кабул итә. Тәнкыйтькә шагыйрьнең гыйсъянчылыктан, ясалмалыктан качып, «уйлар тавына» — фикер шигърияте на омтылуы, яңа тормыш күренешләрен, бигрәк тә Урал эшчеләре тормышын, табигыйлеге һәм реаль төсмерләре белән сурәтләве, җанлы характерлар иҗат итүе ошый.

Х. Туфанның сурәтле фикерләвендәге үзенчәлекләр аның 20 нче еллардагы әсәрләрендә үк ачык сиземләнәләр. Бу үзенчәлекләр нидән гыйбарәт?

1. Чынбарлыкның җанлы сулышына актив мөнәсәбәт күрсәтү, иҗтимагый тормыштагы, халык күңелендәге яңалыкларга игътибарлы булу, ул яңалыкларны сизгер тою.

2. Бу чорда ук ул игътибар үзәгенә халык язмышын сурәтләүне куя, үткәндәге авыр, михнәтле тормыштан котылып, ирекле дөнья, бәхетле ил төзүгә көчүне күтәренке күңел белән рухланып җырлый («Татарстанда», «Еллар итәгендә», «Зәңгәр бүре»).

3. Әсәрләренә шигъри фикернең дәвамлы, теземле ачылуы да хас. Ул рухи халәтнең бер мизгелен чагылдыру белән генә чикләнми, ә берничә кичерешне дәвамлы итеп сурәтли. Бу үзенчәлек шигырьләр бәйләме иҗат итүгә китерә («Урал эскизлары» циклы). Шигъри бәйләм үзе төрле лирик шигырьләрдән тора. Аларны бер шигъри фикер — лирик геройның Уралга, аның эшче кешеләренә мөнәсәбәте, бер үк вакытка һәм җирлеккә таянуы, Уралга булган сәяхәте берләштерә.

4. Халык авыз иҗатының афористик фикерләвенә якынлык. Аның әсәрләрендә хикмәтле сүзләргә, мәкаль-әйтемнәргә охшаш гыйбарәләр еш очрый. «Аягүрә үлеп булыр микән?» шигыреннән (1926) мисаллар китерик:

Читен ләкин чирләп,
Тик пролог көе үлүләр.

Эх, уй да озын, дуслар,
Юл да озын, гомер кыскарак.

Тиргәү — мильләп булса,
Баштан сыйпау — миллиметрлап.

5. Сурәтләрне, символларны яңарту. Х. Туфан көтелмәгән метафоралар, чагыштырулар таба алуы, яңа символик мәгънәле образлар иҗат итүе белән дә укучыларның игътибарын үзенә тарта.

Кыңгыр яткан Урал челем тарта,
Челем сабы — озын таш торба.

(«Еллар итәгендә»)

Уйда винт йомшаса,
Нинди ачкыч белән борырга?

(«Урал эскизлары»)

Киң дөньяга сыймас зур гомерләр
Сыендылар
Маузер артына.

(«Соңгы сарай янында»)

Туфан таланты, еллар үтү белән, тагы да чыныга. Сурәтле фикерләвенең хасиятләре тагы да тәэсирлерәк, үзенчәлеклерәк рәвеш ала бара. «Ак каен» шигырендә (1933) үк инде шагыйрьнең сәнгатьчә гадилеккә, халыкчанлыкка омтылуы ачык төсмерләнә. Шагыйрь иҗатындагы бу яңа сыйфатлар бигрәк тә 30 нчы елларның урталарыннан сурәтле фикерләвенең төп хасиятләреннән берсе булып әверелә.

Халык үзе — тере классик:
Моңы, җыры, үлмәс теле белән,—

дип яза ул, 1936 елда иҗатының юнәлешен билгеләп, «алтын телле халкы» белән горурланып.

Халыкның сурәтле фикерләвендәге традицион детальләрне шагыйрь мул куллана башлый. Фикер салмаклыгын, «уйлар көләчлеге»н хисләр киеренкелеге, акылның тырышып хакыйкать эзләве алыштыра.

Әдипнең эзләнүләрен, табышларын хуплыйсы урында, Сталин репрессияләре дулкынына ияреп, тәнкыйть Х. Туфан иҗатыннан дошман идеологиясенә хас сыйфатлар, фикерләр эзләү белән шөгыльләнә башлый. Хакимият кубызына биегән тәнкыйть чираттагы һөҗүм өчен нигез итеп «Ант» поэмасын (1935) сайлап ала. Шагыйрьнең Язучылар оешмасыннан куылуы да аның «шәхес культы»ның чираттагы корбаны булачагын искәртеп куя.

* * *

Әдәби хәрәкәттән, әдәби процесстан сәяси тоткын сыйфатында көчләп читләштерелгән шагыйрьне хакимият бөтенләе белән әдәбиятның үзеннән аерырга тырыша. Исеме дәреслекләрдән сызыла, китапханәләрдәге китаплары яндырыла. Төрмәләрдә иҗат эше катгый тыела. Шундый кыенлыкларга карамастан, ул шигырьләр язуын дәвам итә. Сакчы-күзәтүчеләрдән яшеренеп, юка папирос кәгазьләренә күңелендәге уй-хисләрен терки, аларны сохари кисәкләре эчендә яшереп саклый. Байтак әсәрләре югала, юкка чыгарыла. Сөргенгә Себергә җибәрелгәч кенә, иҗат өчен иркенлек ачыла. Әмма ул анда да хакимият өчен сәяси ышанычсыз кеше булып кала, үзе өчен генә иҗат итә: шигырьләре басылмый. Тоткынлыкта язган шигырьләрен ул, сәяси аклангач кына, матбугатка чыгара алды. Шигырьләрен укучылар югалган Туфанның исән-сау яшәвенә куанып, шатланып каршы алдылар. Тәнкыйть тә аларны шигъриятебезнең алтын хәзинәсен тулыландырган кыйммәтле рухи байлык буларак кабул итте.

Укучыларны да, тәнкыйтьне дә шагыйрьнең кеше күңеленең поэзиядә моңача яктыртылмаган тирәнлекләренә үтеп керүе, гадәти булмаган авыр шартларга эләккән шәхеснең драматик кичерешләрен сәнгатьчә нәфислек белән гәүдәләндерүе үзенә тартты.

Х. Туфанның кара көчләр белән рухи көрәше М. Җәлил кичергән фаҗигаләрдән дә катлаулырак шартларда бара. Әйтик, М. Җәлил дошманнар кулында — фашист төрмәсендә тоткын булуын ачык белә. Ул үлемгә аңлы рәвештә бара: аның тормыш фәлсәфәсе шундый. Х.Туфанны исә дошманнары түгел, ә үзе бөтен күңеле белән ышанып, бирелеп хезмәт итеп килгән дәүләтнең хакимияте — Совет власте оешмалары — сәяси җинаятьче сыйфатында хөкем итә.

Тормышны тирән ярату, иленә һәм халкына булган ышанычы, җан дусты булган поэзиясеннән аерылмавы, эзсез югалган гаепсез тоткыннарның җан авазларын башкаларга да ишеттерергә теләве аның гомерен һәм шигырьләрен могҗиза белән саклап кала.

Төрмәнең тимер челтәрләрен үтеп чыккан шигырьләре поэзиябездә яңа бер дөнья ачты. Алар тоталитар дәүләтнең кара көчләре белән көрәштә Туфан шигырьләренең көчле рухи корал булып хезмәт итүләрен сөйләделәр. Алар шигърияте-безнең алдынгы традицияләрен тагы да үстерделәр, баеттылар. М. Җәлил, Ф. Кәримдә генә түгел, Х. Туфанда да татар халкының вөҗданы, татар шагыйренең намусы, татар шигыренең көче сыналды. Үзенең тоткынлыктагы гомер юлын, иҗатын йомгаклау рәвешендә ул «зирәк, кыю, чая» иленә 1956 елны түбәндәгечә мөрәҗәгать итте:

Һәр эшне мин
Башкардым тик бары
Синең өчен кирәккә күрә.
Кирәк төштә утка-суга кердем,
Бата-чума һәм яна-көя.

Тоткынлыкта шагыйрьнең дөньяга карашында да, сурәтле фикерләвендә дә үзгәрешләр туа. Сәяси карашларында ул Ленин тәгълиматына тугрылык саклый. Шул ук вакытта төрмә «университетлары»н узу аңа социалистик җәмгыять кичергән «авыру» күренешләрне күрергә, халыкны бәхеткә илтә торган җәмгыять төзүнең Ленинча теориясе белән аның Сталинча корылышы арасында зур аерма ятуын төшенергә ярдәм итә. Аның төрмәдә, сөргендә иҗат ителгән шигырьләрендә җәмгыятьнең әнә шундый моңача укучы күзеннән яшереп сакланган хасиятләре ачыла.

Җәмгыятьнең авыру халәтен шагыйрь Сталинның шәхес культы фаш ителгәнче үк сиземли һәм аңлый. Әлбәттә, төрмә шартларында ул бу турыда ачыктан-ачык яза алмый. Шуңа да ул әдәбиятта Эзоп дәвереннән үк (Эзоп — б.э.к. VI гасырда яшәгән борынгы грек мәсәлчесе) кулланылып килгән, Эзоп теле дип аталган алымга мөрәҗәгать итә.

Эзоп теле дигәндә, әдәбиятта әйтергә теләгән фикерне ишарәләп, ымлап, яшереп язуны күздә тоталар.

Сурәтләүләрнең шундый могҗизалы көче бар: яңа контекстта һәм яңа текстта алар икенче бер мәгънәдә дә ачылып

китә алалар. Төрмә халәте шагыйрьне шигырьнең әлеге тылсымлы хасиятенә еш мөрәҗәгать итәргә этәрә. Сурәтләрнең шундый яңа мәгънә төсмерләре белән ачылуы «Каеннар сары иде» (1942), «Авырган минутларда» (1942), «Хәят» (1942) кебек шигырьләрендә үк күренде.

«Хәят» шигырен шагыйрь үзен үлемгә хөкем иткәч яза. Хәят — гарәп теленнән кергән алынма сүз. Ул «яшәеш, тереклек, тормыш» дигәнне аңлата. Хатын-кызлар исеме буларак та татар халкында киң таралган. Биредә аны шагыйрь хатын-кыз исеме кебек баш хәрефтән язган. Укучы аны текстта Хәят исемле хатын-кыз белән аерылуы уңаеннан иҗат ителгән икән дип кабул итә. Ә шагыйрьнең биографиясе белән контекстта (тыгыз бәйләнештә) караганда аның мәгънәсе башкачарак ачыла. Үлем көтеп утыручы шагыйрьнең газаплы уйлары, аның соңгы сәламе, тормыш белән саубуллашуы икән бу шигырь:

Син китәсең, Хәят, еракка,
Мин дә, мин дә бөтен көчемне
Шушы юлга бирдем түгелме?!
Бер искә ал, уйла шул хакта,
Бу көннәрдән ерак-еракта.

«Каеннар сары иде» беренче карашка сугыш чорының кырыс авырлыгын тасвирлаган шигырь булып күренә. Әмма шигырь детальләренә, аларның эчке мәгънәләренә игътибар юнәлтсәк, чор һәм шагыйрь язмышы белән контекстта карасак, шигырь юлларының яңа мәгънә төсмерләре белән ачылып китүен күрербез. Әтисез калган сабыйның йөзләре сарылануы, күзенең зәңгәрлеген күз яшьләренең юуы шул чорның ул вакытта әйтергә ярамаган олы фаҗигасе, халыкның йөрәк ярасы булып ачыла. Табигать тә шушы фикер-хисне тулыландырып, иҗтимагый тормышка ишарәли:

Көз иде... Җирнең шушындый
Күңелсез чагы иде.
Астралар, гөлләр — кыраулы,
Каеннар сары иде.

Сары каеннар, кырау тигән гөлләр табигатьнең көзге халәтен генә түгел, җәмгыятьнең дә кыраулы көзенә ишарә ясыйлар.

«Авырган минутларда» шигырендә дә табигать күренешләрен күчерелмә мәгънәдә сурәтләү дәвам итә. Гөлләргә

төшкән кырау, кышка ерак булса да бик иртә сибелә башлаган яфраклар шул ук «социаль накаллы» кичерешкә барып тоташалар. Шагыйрь үзенең яшерен язуының иҗтимагый фонын ачыклый торган детальләр кертүне дә кирәк саный. Тоткын шагыйрь төшендә илләреннән хаксызга сөрелгән әдипләрне — Овидий Назонны, Назыйм Хикмәтне, Герцен-Искәндәрне күрә, болар шагыйрьнең фаҗигале язмышын иҗтимагый-сәяси яктыртылышта кабул итәргә булышалар.

Шул рәвешчә, олы иҗтимагый-сәяси фаҗига турыдан-туры публицистик фикерләү алымы белән түгел, ә күчерелмә мәгънәдәге сурәтләр аша ачыла.

Күңел тирәнлекләрендәге моң, сагыш аның башка шигырьләрендә дә (мәсәлән, «Иртәләр җитте исә», 1944) зур осталык белән тасвирланды. «Кырда ике ак канат ята» шигырендә (1953) сурәтләнгән канлы күренешләр дә табигатьтә очрый торган гадәти күренешләрне генә күз алдына бастыру белән чикләнми:

Ята кырда ике ак канат...
Алар күккә
Җилкенми инде:
Төлке тагы иснәнә җилне,
Мыегындагы каннарны ялап...
Ята җирдә
Ике ак канат.

Шигырьдә әлеге күренеш белән шагыйрьнең үз язмышы арасында охшашлык, якынлык булуы шигырьнең бөтен төзелешеннән күренеп тора. Кырда яткан ике ак канат, мыегындагы каннарны ялаган төлке шигырьдә икенче мәгънәне дә аңлаталар, иҗтимагый тормыш хәлләренә ишарә ясыйлар. Элегрәк Х. Туфан барлык вәхшилекләрне фашистларга сылтап, үз язмышын шуңа мөнәсәбәттә карауны укучының үзенә калдыра иде. Бу юлы инде бикле йозакка ачкычны үзе үк күрсәтеп бирә:

Моңаясың, аккош, далада.
Безнең язмыш, бәлки, берүктер,
Син дә, бәлки, минем кебектер —
Эндәшептер җуйган балаңа,
Моңаясың, аккош, далада.
Моңланасың... аккош... далада...

Далада моңланучы, баласын җуйган аккош сурәте, шул рәвешчә, шул чор тарихының канлы, кешелексез күренешләрен

шагыйрь язмышына бәйләнешле рәвештә (ул да бит баласын җуйган!) тирән итеп гомумиләштерә.

* * *

Х. Туфан иҗатының өченче чоры шагыйрьнең 1956 елны, ирек алып, Казанга кайтуыннан башлана.

Сөргенлек кысасыннан котылу аның рухын да, шигъри телен дә үзгәртә. Ул канатланып, дәртләнеп, олы дөньяның бөтен шатлык-борчуларын йөрәгенә сыйдырырга омтылып иҗат итә башлый:

Кил әле, кил,
Үбим үзеңне бер!
Яратам мин сине, Җир шарым!
Кочагыма минем сыймасаң да,
Җаныма бит сыясың, җаным!

Сурәтле фикерләвендә, шигырь аһәңендә үзгәреш исә берничә ел алданрак туа. Аны 1953 ел белән — Сталин культының илдә фаш ителү вакыты белән билгеләргә мөмкин. Аның шул елны иҗат ителгән «Ә җир барыбер әйләнә!» исемле публицистик шигыре яңа чорның тууын хәбәр итте.

Бүрегең яна, бүрегең, инквизитор,
Нахак каннар яна бүрегеңдә! —

дип эндәшә ул вәхшәт иясенә. Аны турыдан-туры «егерменче гасыр формасына җайлаштырган маска кигән инквизитор» дип атый. Шушы вакытлардан аның әсәрләрендә публицистик аһәң тулы тавыш белән яңгырый башлый. Эзоп теле арткырак планга күчә. Әмма ул тирән мәгънәле, олы гомумиләштерүләргә ия булган символик сурәтләрне куллануын ташламый. Халыкчан традицион сурәтләүне яңа мәгънәви төсмерләр белән баетуын дәвам итә.

Х. Туфан — җир тормышын йөрәгенә үтә якын кабул итүче шагыйрь. Прогресска комачаулаган һәртөрле күренешкә, ул сәясәткә яки әхлакка карыймы, үзенең публицистик рухлы шигырьләре белән җавап биреп бара, салкын дөньяның җылынуы өчен көрәшүен дәвам итә:

Йөрәк минем тына белмәде,
Моннан соң да тынмас, иншалла.
Җил-давыллар белән очрашып,
Киеренкелек өстәр илһамга.

(«Тугызынчы дулкын»)

Сурәтле фикерләвендәге үзгәреш яңа темаларның тууында да күренә. 60—70 нче еллар поэзиясендә киң яңгыраш тапкан шундый темаларның берсе — ул милләт һәм тел язмышы. Бу тема аның иҗатында үзен һәм җәмгыятьне һәрчак борчып торган бик тә әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып күтәрелә.

Туфанда татар халкының үткәндәге тарихы белән кызыксыну тоткынлык чорындагы шигырьләрендә үк очрый иде («Халыклар капкасы янында», «Каплан-Кырда», 1947). Үзен ул скиф, һун, хәзәрләрнең «кандаш баласы» дип атый. Каплан-Кырда сөякләре яткан бабаларын онытмаска чакыра:

Каплан-Кырда сөякләр ята...
Без аларны онытачакмыни?!
Без бу юлдан борылачакмыни!

Тоткында чакта да туган теленә багышлап шигырьләр иҗат итә:

Бу дөньяның төсен, ямен, зәүкын
Кем аркылы, ничек белдем мин?
Бишектә үк мине өйрәтүчем,
Туган телем — бәгърем, син ул, син!

(«Туган тел»)

Иреккә чыккан шагыйрь халык язмышы темасына игътибарын тагы да ныграк юнәлтә. Бигрәк тә аны милли рухның кысылуы, туган телнең аяныч язмышы, яшь буынның үз телләрен онытулары борчый. Ул Коммунистлар партиясенең милли телләрне берләштерү, бер-берсен йоттыруы аша, аларны югалтуга илтә торган сәясәтенә каршы чыга. «Алмаз» шигырендә (1953), үзенең фикерен цензура аша җиңелрәк үткәрү өчен, эзоп телен файдалана. Шул чор сәясәтенә каршы калкан итеп Ленинны куя. Татар теленең царизм чорында, «чабаталы» чакта да, «халыклар төрмәсе»ндә яшәгән чагында да югалмавын дәлил итеп китерә:

«Чыра яктысында югалмады,
Ильич яктысында югалмас!»
«Туган телебез булган бу алмаз!»

Иҗтимагый-тарихи контекстта, ягъни тарихи чорларны чагыштырып бәйләнештә күрсәткәнгә дә алмаз символының мәгънәсе тирән булып ачылып китә. Телләрне бетерергә юл тоткан сәясәтнең нигезсезлеге ачык күренә.

Татар теленең авыр язмышы, аның көндәлек тормышта, мәктәпләрдә, дәүләттә әһәмияте кими баруы, милли рухның

кысылуы унаеннан ул күп шигырьләр яза («Ләлә белән күбәләк», «Килдеңме син Ильич каршына?», «Хөлли Мәймуновичның калорияләр һәм колоритлар турындагы фәлсәфәсе» һ.б.). Аларның күпчелеге, үз вакытында цензура иләгеп үтә алмыйча, шагыйрь архивында гына ятып кала. Басылмаган шундый шигырьләре «Гүзәл гамь» (1990) җыентыгында беренче тапкыр дөнья күрделәр.

Сурәтле фикерләвендә туган үзгәрешләр фәлсәфи фикерләвенең җанлануында да күренә. Мондый шигырьләре үзләре бер шигъри юнәлеш-тармак төзиләр, аерым бер цикл буларак төркемләнәләр. «Һиндстанны эзлим», «Сөйли торган материя», «Битараф ай», «Сүз кушасы килә талларга» кебек шигырьләрендә шагыйрьнең фәлсәфи-лирик фикерләү табигате аеруча тулы чагылды.

Менә «Битараф ай» шигыре. Ай сурәте халык җырларында еш очрый. Аларда ул, нигездә, мәхәббәт тойгыларына бәйләнештә, моңсулык һәм сагыш хисен сынландыру өчен кулланыла. «Битараф ай» шигырендә ул яңа мәгънә ала. Шигырьдә ай һәртөрле битарафлыкның, шул исәптән иҗтимагый-сәяси битарафлыкның, символы дәрәҗәсенә күтәрелә:

Сугышлар да җирдә,
Концлагерь да —
Әйтерсең лә берни булмаган:
Варфоломей төнендәге сыман,
Битараф ай тыныч, тын һаман.
Нур сибә ай
Куйга һәм бүрегә...
Гүя бар да тигез-яхшылар,
Моабитларда асып үтерелгәннәр
Гүя инде терелеп кайттылар.

Шагыйрь, җирдә барган көрәшнең тарихи һәм социаль масштабын югалтмый күрсәтү өчен, тирән мәгънәле, күп сыйдырышлы детальләр белән эш итә, хәтта төрле тарихи чорларны бергә янәшә куя (Варфоломей төне, Моабитларда асып үтерелгәннәрне искә алу). Әмма шагыйрьнең максаты айның җиргә битараф каравын — куйга да, бүрегә дә тигез яктыртуын әйтүдә генә түгел. Шигырь җирдәге канлы сугышлар өчен, вакытсыз өзелгән гомерләр өчен тирән әрнү белән сугарылган. Шагыйрь җирдәге сугышның кеше өчен табигый булмавын сөйли, шундый газаплар, фаҗигаләр кабат җирдә кабатланмасын өчен, кешеләрне уяу булырга өнди.

...Кинәт ай болытлар арасына чума. Утлар сүнә. Дөньяда — караңгылык һәм тынлык. Кемдер әкрен генә, куркып кына, Европаның ишеген кага. Юк, тынлык булса да, дөнья тыныч түгел. Ай һәрнәрсәгә битараф булса да, дөньяга мондый битарафлык ят. Дөресрәге, дөньяны тынычлыкта һәм ваемсызлыкта калдырмый торган көч бар. Нинди көч соң ул?

Зиндан әлифбасын хәтерләтеп,
Кем ул шакый?
Сиңа кем кирәк?
«Мин, — ди ул, — мин — Ана йөрәге, мин —
Балаларым эзләгән йөрәк...»
Улларының исемнәрен атый:
«Тельман, Фучик, Мусам, Абдуллам...
Сездә, бәлки,
Берәр хәбәр бардыр?—
Сәлам бардыр алар ягыннан?»

Югалган балаларын Европадан, канлы сугышлар узган иллрдән эзләп йөргән Ана йөрәге... Көтелмәгән, әмма ныклы реаль нигезгә таянып уйлап табылган оригиналь яңа образ бу. Караңгы төндә дә үзенә тынгылык тапмыйча, кешеләргә тынгылык бирмичә, балаларын эзләп йөргән кешелекле Ана йөрәге! Бу символик образ шундый тирән мәгънәсе белән укучыны ваемсыз калдырмый, аны тетрәндерә, сискәндерә. Шушы күренештән соң килгән юлларда айның битарафлыгына — кешелекнең үткән фаҗигаләрен оныту мөмкинлегенә, шуларны онытырга чакыручыларга көчле протест яңгырый:

Ә ай дәшми:
Куйлар һәм бүреләр
Гүя тигез-яхшылар инде,
Концлагерьлар төбенә күмелгәннәр
Гүя терелеп кайттылар инде.

Шагыйрь кулланган образлар, традицион сурәтләр, яңа символика укучыларны бүгенге кешенең интеллектуаль дөньясына алып керә, тормыш турында, табигать һәм кеше мөнәсәбәте турында, җир һәм кеше язмышы турында уйландыра.

Мин — бу кырлар, сулар, җилләрдәге
Атомнарның иске туганы;
Материя мин, җаным,
Аның бары
Сөйли, җырлый, сагына торганы.

Бу юллар — «Сөйли торган материя» шигыреннән. Кайлар-гадыр барган юлчы, үз итеп, якын итеп, юл читендә уйга талып утырган миләүшәгә эндәшә һәм, аның белән тирән якынлыкны тоеп, әнә шундый зур мәсьәләләр турында әңгәмә алып бара. Туфан лирикасында кеше, ягъни материянең «сөйли, җырлый, сагына торганы» катлаулы кичерешләре белән ачыла. Лирик геройның йөрәге менә шул һәр кешегә хас сагынусөю хисләрендә яна.

Киләчәктә
Кирәк булмас, бәлки,
Бу юксыну, сагыну-сөюләр;
Күңелдәге гүзәл һәйкәлләрне
Искә алып башны июләр?!

Лирик герой бермәлне үзендә уянып куйган шундый фикер белән үзе үк бәхәскә керә: юк, йөрәк әрнүләрдән, сагынусөюләрдән башка яши алмый. XX гасыр уртасына килеп җиткән бөек мәхәббәтне «һичкем, һични, һичбер һәлакәт» җиңә алмаячак:

Кешенең син, ахры, һәрбер хисен
Киләчәккә алып барырсың!
Анда да син шулай сөя торган,
Сагына торган булып калырсың!

Туфан поэзиясендә кешеләр әнә шундый яна-көя торган сыйфатлары белән күз алдына китерелә. Шагыйрь ут эчендә исән калган мәхәббәтне, мәхәббәтләренә турылыклы булган ир-егетләрне, хатын-кызларны олылый («Иртәләр җитте исә», «Ромашкалар», «Сиңа» һ.б.). Мәхәббәт темасы шагыйрьнең олыгайгач язган шигырьләрендә яшьлек чорына караганда да тирәнрәк итеп, күңелләрне кузгатырлык фаҗигасе һәм кешелекле сафлыгы, сәнгатьчә матурлыгы белән сурәтләнә. «Сиңа», «Ромашкалар», «Кайсыгызның кулы җылы?», «Тамчылар ни диләр?», «Тургай нигә дәшми?», «Әйткән идең», «Карамый калалмадым шул» шигырьләре мәхәббәт лирикасының энҗеләре булып саналырга хаклы.

Мәхәббәт-сөю шигырьләренең беришe кеше күңелендәге шатлыклы, күтәренке, якты кичерешләрне сурәтли. Гайре шигырьләре исә фаҗигале аһәң белән өртелгән. Аларның мәгънәсе Х. Туфанның шәхси тормышы белән бәйләнештә караганда тагы да тәэсирлерәк булып ачылып китә.

Туфан кулга алынгач, аның хатыны актриса Луизаны эштән куалар. Ул, төрмәдәге иренә ярдәм итәр өчен, бала-

ларын яшәтер өчен, госпитальгә барып, донор булып канын тапшырып торырга мәҗбүр була. Шул акчаларга, сохарилар әзерләп, иренә посылкалар җибәрә. Ачы хакыйкатьне шагыйрь, сөргеннән өенә кайтканнан соң гына, ридикюльдә сакланган белешмәләргә карап төшенә:

Посылкалар белән ярдәм иттең:
— Без бит илдә... өйдә бит, — дидең.
Ә ул ярдәм
Каныңа алыштырган
Паёкларың икән бит синең...
Алдарсың дип уйлый идеммени? —
Ә син мине алдагансың ич:
Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син
Җаның белән ялгагансың ич!

Шагыйрьнең бәхетсез язмышлы мәхәббәтен шул чор иҗтимагый тормышы белән контекстта караганда гаилә фаҗигасе олы социаль-тарихи яңгыраш ала. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә (1956) ул нәкъ әнә шундый хасият белән чор фаҗигасе, җәмгыятьнең сәяси нигезе тудырган афәт булып гомумиләштерелә, шундый яралы йөрәкле кешеләрне күз алдына бастырып тетрәндерә:

Кайсыгызның кулы җылы?
Бәйлисе бар йөрәкне!

Шагыйрьнең «тышы гына салкын, ә йөрәге җылы дөньяны» күрәсе, шундый җәмгыятьтә кешеләрне яшәтәсе, бәхетле итәсе килә.

* * *

Сезнең «Туфан шигыре» яки «Туфан — шагыйрьләр шагыйре» дигән гыйбарәләрне очратканыгыз, ишеткәнегез бардыр. Алар шигырь төзелешенең Туфанга гына хас үзенчәлекләре булуына ишарәлиләр, аның үз мәктәбен тудырган талантлы шигырь остасы булуын раслыйлар.

Әлбәттә, ул мондый осталыкка җиңел генә ирешмәде. Сәгъди, Хәйям, Хафиз кебек атаклы шәрык классикларының, Есенин, Блок, Маяковский кебек рус шагыйрьләренең, Тукай, Такташ, Бабич кебек татар әдипләренең, гомумән, дөнья поэзиясенең тәҗрибәләрен өйрәнде.

Х. Туфан татарның шигырь төзелешендә күп яңалыклар ачты, рифмалашуның һәм строфалар төзүнең яңа өлгеләрен

тапты. Төрмәдә иҗат ителгән «Иртәләр җитте исә» шигырен без лирик эчтәлеге һәм символик сурәтләре ягыннан искә алып үткән идек инде. Әлеге шигырь строфа өлгесе ягыннан да татар поэзиясе өчен яңалык ачты:

Иртәләр җитте исә,
Аклысын кия ярың:
Юлларда күзе аның...
Ә юлда — җилләр исә,
Иртәләр җитте исә...

Шигырь шушы строфа белән башланып китә. Бу биш юлда рухи халәтнең төп хасиятләре ачыла башлый, кичерешләрнең гомуми күренеше күз алдына баса. Шигырьнең башка строфаларында инде шагыйрь кичерешләрнең эченәрәк керә. Моның өчен ул шул ук шигырь юлларын файдалана. Беренче строфаның икенче юлын яңа строфаның беренче юлы итеп ала, аны да алка итеп, бишенче юл итеп кабатлый. Өченче строфаны беренче строфаның өченче юлыннан башлый да бишенче юлында кабатлап куя. Дүртенче, бишенче строфалар да шул ук алым белән төзеләләр. Күп нокталарны да хис-тойгыны сүзсез ачучы шигъри чара итеп куллана. Строфаның шушындый яңа өлгесе хис-тойгыларның төгәл һәм нәфис дулкыннарын, кичереш мизгелләрен тудырырга ярдәм итә.

«Тынма, давыл!» шигырендә (1951) ул авазлар кабатлануының, авазлар аһәңлегенең, якынлыгының башка өлгеләренә мөрәҗәгать итә:

Өстә — дулкын, астан — упкын
Куллар сала салыма.
Сукма, дулкын, упма, упкын:
Кайтыйм ярым янына.

Беренче юлны бишенче юл итеп, яки беренче строфаны шигырьнең соңгы строфасы итеп кабатлау да Туфанга хас алымнардан санала. Мондый кабатлаулар (аваз, сүз, юл, строфа) кичереш дулкыннарын үстереп, баетып, нечкә психологик төсмерләре белән сурәтләргә, рәсемләргә булышалар.

* * *

Хәсән Туфан — татар поэзиясенең горурлыгы. Аны рус шагыйре М. Дудинның «уникаль талантка ия шагыйрь» дип атавында тирән хаклык бар. Аның шигырьләре хәзер дә, Мостай Кәрим сүзләре белән әйтсәк, «халык рухының илчесе»

буларак дөнья буйлап сәяхәт итә. Тукай эстафетасын лаеклы дәвам итүе белән ул халыкка якын, кадерле.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кечкенә Хәсәннең матурлыкны тою хисләре ничек тәрбияләнә? Х. Туфанда поэзиягә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләгән чыганакларны ачыклагыз, әдәбиятка килү юлын сөйләгез.
2. Уралда ул нинди «тормыш мәктәпләре» үтә? Иҗатында алар ни рәвешле, нинди әсәрләрендә чагыла?
3. Урта Азиягә һәм Кавказдагы республикаларга сәяхәте аның иҗатына нинди йогынты ясый?
4. Шагыйрьнең сәяси тоткынлыгы нинди шартларда һәм кайларда үтә? Сәяси тоткын булуы шәхси язмышына һәм иҗатына нинди йогынты ясый?
5. Иҗаты нинди чорларга бүлеп өйрәнелә?
6. Шагыйрьнең 20—30 нчы еллар иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?
7. Тоткынлык чоры шигырьләренең үзенчәлекләрен ачыгыз. Шагыйрь ни өчен эзоп телен файдалана? «Иртәләр җитте исә» шигырендә шагыйрьнең халык иҗатындагы төсләр символикасын ничек куллануын, нинди яңа мәгънә төсмерләре белән ачуын мөстәкыйль анализлагыз.
8. Туфанның өченче чор иҗатына хас үзенчәлекләрне ачыгыз. Шагыйрьнең фәлсәфи-лирик, публицистик шигырьләрендә нинди темалар, мәсьәләләр күтәрелә?
9. Мәхәббәт лирикасының үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?
10. «Х. Туфан шигырьләре — музыкада» дигән темага әңгәмә оештырыгыз.

Әмирхан Еники
(1909—2000)

«Кеше гомере чикле һәм ул «кояш баюга» таба, бары шул якка таба гына бара. Табигатьнең бу законын үзгәртеп булмый, аны бары тик кичереп, аның турында уйланып кына була. Шулай да серле, сихри бер дөньяның — әдәбиятның шундый хасияте бар: анда үткәнгә юллар бар, кабат-кабат кайтып карарга мөмкинлек бар, үлемсезлек бар». Гомеренең үтеп баруына моңланып, шушы сүзләрне язган Әмирхан ага Еникинең иҗаты — менә шундый үлемсез, классик иҗат.

Аның тормыш юлы турында мәгълүмат 7 нче сыйныф дәреслегендә, Татарстан язучылары турындагы библиография белешмәсендә бирелгән. Әдип, үзенең гомер юлына әйләнеп карап, тормышның кадерле мизгелләрен, кыйммәтләрен барлап, «Соңгы китап» дигән документаль-биографик әсәрен дә язды. Әмма әле нокта куелмады, язучы өзлексез уйланды, үзенә хас булганча иплэп кенә, сабырлык белән нәтиҗәләр ясады. Иң мөһиме, ул безне дә уйландыра; бу зур иҗатның замандашлары булган һәм аннан соңгы менә инде ничәнче буын укучылар гыйбрәтләр ала, үзе өчен нәтиҗәләр ясый.

Әмирхан Еникинең әдәбият белән танышлыгы 20—30 нчы елларда башлана. Ләкин бу чорны әле чын мәгънәсендә язучылык эшчәнлеге чоры дип әйтеп булмый. Бу чор әле — Такташ, Кутуй, Туфан, Нәҗмиләрнең иҗатына, әдәбиятта кайнап яшәүләренә соклану; катлаулы һәм хәтәр каршылыклы бу елларның сизгер шаһиты, күпмедер дәрәҗәдә «корбаны» да булып, туктаусыз эш урынын алыштырып, «күчмә» тормыш белән яшәү чоры. Шулай да бер закончалык, өзелмәгән бер җеп, язмыш булып сиземләнеп торган сукмаклар бар: белем

алу, укыту эше, сәнгать белән бәйле хезмәт. Өстәвенә «тормыш мәктәбе» биргән сабаклар ни тора!

Әмирхан Еникинең сугыш елларында язылган беренче хикәяләре үк диңгез төбендә озак ятып, энҗе бөртегенә әйләнгән хәзинә кебек балкып китте.

Ватан сугышы чоры әдәбиятын шул чор белән үтеп киткән, мираска гына калган әдәбият дип уйларга гадәтләнгәнбез. Бигрәк тә аның прозасы турында сөйләгәндә сугыштагы батырлыкны яки тылдагы шул чор авырлыкларын сурәтләгән әсәрләр дип нәтиҗә ясыйбыз. Әмирхан Еникинең хикәяләре бу тема кысаларына сыймый, үзенчәлекле бер агым тәшкил итә.

«Бала» хикәясе 1941 елда языла, сугыш чоры прозасын, шул исәптән Ә. Еники иҗатын да башлап җибәрә, юл сала. Хәер, әсәр үзе дә юл образын тасвирлаудан башлана. «Юл ат, арба, машина эзләре белән тулы... Бу юл — бүгенге мәхшәрнең бердәнбер телсез шаһиты. Ике туганның бер үк эзгә басканын бары ул гына белә. Ә шулай да ул бу сәгатьтә нинди мәкерле тыныч һәм нинди буш». «Юл», «сәгать», «тыныч» сүзләрен күңелгә салып куйыйк, алдагы әсәрләрдә алар гел кабатланып торачаклар һәм күп мәгънәле образларга әйләнәчәкләр.

Хикәя алгы позициягә, ут эченә баручы бер ротаның кызылармеецы Зариф турында. Урманның алдаучан тынлыгы, җылы кояшлы иртә аның уйларын туган авылына, өенә, гаиләсе янына алып китә. Шулай онытылып уйланып барганда, һава тревогасы була, рота урман юлының ике ягына сибелә. Самолёт ераклашкач, Зариф урыныннан кузгала. «Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды... Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенде, һәм аңарда кузгалган беренче теләк — баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды. Беренче хәрәкәте аның, ротасы артыннан китү өчен, юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды».

Бу хәрәкәт күп нәрсә турында сөйли. Зарифның ротасыннан аерылып калырга һич хакы юк. Ләкин ул баланы ялгызын урман эчендә, сугыш гарасатында калдырып та китә алмый. Нәкъ шушы урында конфликт башлана. Зариф, сугыш

тудырган законга буйсынып (рөхсәтсез-нисез аерылып калганы өчен аны җәза көтә), салкын акыл белән эш итәргә тиешме, әллә үзенең дә нәкъ шул яшьтәге Фәридәсе булган эти кеше буларак, һәм гомумән кеше буларак, йөрәге кушканны эшләргә тиешме? Үз күңелегез, хисләрегезгә колак салыгыз әле — сез нишләр идегез?

Зариф, әйләнгеч юлдан булса да, тимер юл станциясенә чыга, баланың әнисе шунда була, һәм Зариф ана белән баланың кавышу бәхетенә соклану тулы бер караш кына ташлый да ротасы артыннан йөгерә. Бәхетенә (ә бәлки, рота командиры акыллы кеше булгандыр, бер солдатының артта калганын абайлап, көтеп алырга уйлагандыр? Яки, сугышка керер алдыннан, солдатларын ял иттереп аласы килгәндер?!), рота ялга туктаган була, ул үзе белән булган хәлне сөйләп бирә. Командиры каты шелтә бирер дип куркып торган Зарифка: «Сез зур изгелек эшләгәнсез, рәхмәт сезгә!» — ди.

Конфликт менә шулай хәл ителә. Ләкин бу әле турыдан-туры вакыйга катламына бәйле каршылык кына. Ул да әһәмиятле, әлбәттә. Юкса Зариф алдына ике мәсьәлә килеп баскан иде, ул берсенә дә зыян китермичә, икесен дә уңай хәл итә алды. Бер җөмлә белән, алгы сызыкка, ут эченә барышлый, Зариф адашып калган баланы коткарды, әнисенең кулына илтеп бирде — моны әсәрнең төп максаты дип нәтиҗә ясыйбыз. Әмма 2—3 битлек хикәядә тагын бер фикер катламы, тагын бер биеклек бар әле.

Беренче җөмләдән үк аңлашылганча, вакыйга сугыш хәлләренә, алай гына да түгел, алгы позициягә баручы рота, аның бер солдатына бәйле рәвештә тасвирлана. Гадәтләнгән әдәби канун буенча, сугыш икән, димәк, батырлык, дошман белән йөзгә-йөз килеп көрәшү, үлем, җиңү сурәтләнергә тиеш кебек. Язучы сугыш турында сөйләүнең бик үзенчәлекле ягын сайлап ала: сугышны ул вакыйга итеп түгел, ә кешенең халәте — үзен тоюы, каршылыклы кичерешләре рәвешендә гәүдәләндерә, фикер йөртә, уйлана. Зариф шактый четерекле, кыен бер хәлдән чыгарга тиеш. Солдат бурычы, солдат намусы, кеше табигате, кешелеклелек сыйфаты бәрелешкән хәлдә кала ул. Без дә еш кына шундый киеренке хәлиткеч мизгелләргә юлыгабыз, ахырдан үкенәбез яки канәгатьлек хисен кичерәбез. Бу хикәядә нәкъ менә шундый кичереш дулкыны әһәмиятле, кыйммәтле. Димәк, әсәр рухи батырлык, салкын акылдан өстен булган олы җанлылык турында да

икән. Зариф моны тыйнак кына, башкача булдыра алмаганга күрә, бернинди зурлау көтмичә, бик табигый итеп эшли. Мәсәлән, кояш яктырта, җылыта икән, шуның өчен кояш бит инде ул! Кеше дә шулай — яхшылыкны, изгелекне күңел кушуы буенча, нииндидер исәп-хисапларга бәйләмичә эшли. Иң зур хакыйкатьләрнең берсе шулдыр инде: үзең тоеп, үзең белеп кешеләргә, табигатькә, дөньяга яхшылык эшләү. Шәфкатьле, мәрхәмәтле булуыңны тою иң беренче чиратта үзеңә канәгатьлек бирә, күңел тынычлыгы тудыра.

Үзеннән-үзе соралып торган менә шушы нәтиҗәне хикәя ахырында автор фәлсәфи дәрәҗәдә һәм образлы итеп йомгаклап куя. «Бу чын сугыш кыры иде. Биредә үлем никадәр әрсез, рәхимсез булса, тереклек шулкадәр үз-үзенә ышанучан, бирешмәс, мәгърур була белә. Биредә кеше бер алмаз бөртегенә әйләнә. Ул, күзгә күренмәс дәрәҗәдә кечкенә булуына карамастан, олы алмазның бөтен сыйфатларын үзендә саклый. Ул каты... һәм нурлар чагылдыра.

Зариф снаряд шартлавыннан йөгергән һава дулкынының йөзенә бәрелүен сизә. Ул колагы төбеннән чинап, сызгырып үткән һәр пуля турында уйлана; гүя ул пуля тисә, бары тик чеметеп кенә алыр кебек.

Чыннан да, Зариф, беренче мәртәбә сугышка керүенә карамастан, үзендә аңлавы читен булган бер тынычлык тоя иде. Күңелендә аның кояшлы иртә тынычлыгы, хыялы исә шул иртәнең нурлы матурлыгы белән тулы иде. Менә ул ирексездән муенын сыпырып куйды. Гүя шунда баланың кул җылысы йогып калган иде».

«Аңлавы читен» дисә дә, язучы кыска гына хикәядә зур фәлсәфи сорауга җавап бирә алган. Кеше күңеле, аның халәте гел үзгәреп тора, күп вакытта көтелмәгәнчә үзгәреп куя. Менә шул көтелмәгән үзгәреш мизгелләрен сурәтли алу зур сизгерлек һәм осталык сорый. Беренче мәртәбә ут эченә кергәндә, кеше, табигый буларак, курку хисе кичерергә тиеш. Ә Зарифның күңелендә тынычлык. Каян килә ул хис, сәбәбе нәрсә аның? Кояшлы иртәдән, табигатьнең хозур матурлыгыннан гына түгел бит инде. Хикмәт шунда: Зариф җиңү шатлыгын кичерде, шул мәхшәрдә бер тәртип-гаделлек тойды. Аның кулыннан килә, аңа да бәйле икән зур җиңү. Сугыш дигән коточкыч дәһшәт каршында көчсез түгелдер ул. Менә шул хис (акыл белән аңлаган фикер үк тә түгел әле) Зарифның күңелен тынычландырды, рухын ныгытты.

Тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик: хикәядә кызчыкның исеме юк, аны автор да әйтми. Зариф та кыздан сорамый, югыйсә ничек киенгәне, таныш булмаган кешедән башта ничек ятсынганы, ахырдан тынычланып, ачык итеп сөйләшүе җентеклəп тасвирланган. Кызчык бик ачык күз алдына килə, шулай да «бала» дип кенә әйтелә. Хикәя дә шулай исемләнгән. Әйтерсең лә автор ике якны кара-каршы куя: коточкыч дәһшәтле сугыш һәм адашып калган бала — табигатьнең иң матур, ярдәмгә, яклауга мохтаҗ өлеше. Сугыш мәрхәмәтсез, ул ана белән баланы һәлакәт чигенә китереп куя. Бу хикәя менә шул турыда әрнеп сөйли.

Беренче хикәядәге үзенчәлекләрне Әмирхан Еники башка әсәрләрендә дә дәвам итә. «Ана һәм кыз» хикәясе шулай ук табигатьне тасвирлау белән башлана. Җәй башының шифалы яңгыры, иртәнге яшь кояш, бәбкә үләннәре өстендәге, энҗе бөртекләре шикелле, нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы... һәм авыру ана. «Ана күптәннән каты авыру, һәм ул бу урынга инде яңадан тормаска ятканлыгын яхшы белә. Ләкин тыныч җан белән үлемне көткән бу авыру анада соңгы сулышыннан аерылу минутын кичектерү теләге бик көчле: ул улын көтә. Бердәнбер улының фронттан кайтуын, менә шул кечкенә ишектән иелә төшеп керүен, елмаеп янына килүен, «Әни!» дип дәшүен күрергә тели иде. Бу гади сагыну гына түгел, бу үзеннән соң каласы тормышның дәвамын күрергә тырышу, һәр тамчы каны белән йөрәге аша үткән ана мәхәббәтен соңгы тапкыр актыгына кадәр улына бирү теләге иде».

Бу хикәядә кеше гомеренең икенче чиге — гомеренең соңына якынлашып килгән ана тасвирлана. Аны бу дөнья белән улын күрәчәгенә, аның исән-сау әйләнеп кайтачагына ышаныч кына бәйләп тора. Һәм сугыш менә шул җепне дә өзә: улының үлгән хәбәре килә. Бу хәбәр киләсе көнне иртән шифалы яңгыр явып үтте. «Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек. Өй эчендә нурлы тынлык...»

Өй эчендә — тынлык, ана җанында — өмет, тынычлык, табигатьтә яшәрү. Ана, чыннан да, кызы Рәхиләнең, улы Хәсәннең тату булып, бер-берсенә шәфкатьле булып яшәячәкләренә ышана, аның күңеле шуңа күрә тыныч. Авыру ананың хәле дә шуңа күрә фаҗига итеп түгел, ә нурга төреп сурәтләнә. Менә ул кул эше алып тәрәзә янына утырган кызына җайлап, ашыкмыйча гына васыятен әйтә. «Хәсәнемне күргәч, мин күп тор-

мам... Исемә төшкәндә кайбер сүзләремне әйтеп каласым килә. Инде минем беренче васыятем шул, кызым: Хәсән балам бервакытта да апаларын-сеңелләрен онытмасын, мине якын күргән кебек, аларны якын итсен... Кулыңнан килгән ярдәмеңнән ташламасын. Бигрәк тә сине туган анасы кебек күрсен, синең күрсәткән хезмәтләреңне бервакытта да онытмасын». Дөнья яралганнан бирле, аналар нәкъ шундый васыять әйтәләрдер, бу — балаларына иң изге догадыр.

Рәхилә әнисенең васыятен шулай ук сабырлык белән, тыныч күңел белән тыңлый. «Хәсән — туган җанлы бала, әни... Ул тарафтан тыныч бул»,— ди. Ана белән кыз «менә исән-сау кайтыр... эшли башлар...» дип Хәсәнне көтәләр. Рәхилә дә бит энесе укысын дип тырышты, кечкенә вакыттан ук ул аны карап үстерде, үзенең алдагы тормышын да энесе белән бәйләп күз алдына китерә иде. Почта таратучы китергән конверт Рәхиләнең менә шул өметләрен кисте. Бу хәбәрне анага ничек әйтергә? «Өйгә, ана янына керү аның өчен шундый шомлы, шундый авыр газаплы иде, әйтерсең ул хәзер менә баштүбән тирән бер бушлыкка егылырга тиеш... башына килгән беренче уй «Ник элек әни үлеп, соңыннан бу хәбәр килмәде? Ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды». Сугыш тормышның гадел тәртибен җимерә; улының кайтуын да күреп, үзен кадерләп тәрбияләгән кызы кулында тынычлап җан бирәсе, дөнья белән табигый халәттә саубуллашасы анага үлемнән дә яман газап — баласын югалту газабы килә.

Рәхиләгә «үзе һәм әнисе шундый кызганыч, шундый бәхетсезләр, шундый ялгыз-бәхетсезләр» булып тоела. Бу тау кебек газапны күтәрү аңа аеруча авыр, чөнки ул ананы уйлый, үлем хәбәрен аңа әйтми. Васыятен әйтеп куйгач, ана сабый бала тынычлыгы белән йоклый, үз үлеме аны куркытмый, улының үлемен ул әле белми. Рәхилә кайгысы бик зур булса да елый алмый. «Кулы тойган җир, аркасыннан сөйгән кояш, күзләренә караган чәчәкләр тыныч булырга кушалар, сүзсез, бары үзләренең шушында, аның әйләнәсендә булулары белән юаталар. Чыннан да, Рәхилә салкын-тыныч. Тик чигәсендә аның әле үзе күреп өлгермәгән ике бөртек чал чәче елтырый».

Бу хикәядә дә вакыйганы бер җөмлә белән атап әйтеп була: авыру анага һәм аның кызына кайгы — үлем хәбәре килә. Бу әсәрдә Ә. Еники кайгы тетрәткән күңелнең кичерешләрен, кешене яшәткән өметне, сабырлык-түземлекне тасвирлый. Су-

гыш чорының ачлык-ялангачлыгы, алга баскан авырлыгы менә шундый рухи газаплар янында кечерәеп кала кебек. Шулай да кеше йөрәге чыдам, кеше җаны олы, түзем. Тормышның зур мәгънәсе шунда дип нәтиҗә ясыйбыз.

Гомумән, ялгызлык — гаҗәеп катлаулы төшенчә. Аны кирәк — кирәкми, яхшы — яман дип кенә бәяләп тә булмый. Шуңа күрәдер инде зур әдип Әмирхан Еники бу турыда кайта-кайта уйлана, бу сорау аның әсәреннән әсәренә күчә, күпмәгънәле һәм хәл ителмәгән, гел безне борчып торган мәсьәләгә әйләнә.

Чынлап та, кешегә ялгыз гына калып уйланырга, ял итәргә дә кирәк. Шул ук вакытта ялгызлык фаҗигагә дә әйләнергә мөмкин. Очрагына, кешесенә, шартларына карап, бу халәт бик күп төрле кичерешләр дулкынын тудыра. Бер караганда табигый да булган, һәркемгә күпмедер дәрәҗәдә таныш та булган ялгызлык турында язучы көтелмәгән яклардан килеп уйлана.

«Ялгыз каз» хикәясе бик мөлаем юмор белән язылган, хикәянең герое да — каз. Нигә әсәренә автор мондый образны сайлаган? Нинди ялгызлык турында сүз бара? Немецлардан азат ителгән авылда безнең солдатлар бер каз күреп гаҗәпләнәләр. «Әгәр безнең солдатлар Калинин урманнарында тәвә кошын очратсалар, бу кадәр гаҗәпләнмәсләр иде: меңләгән авылларны фашистлар коллыгыннан азат итеп, безнең беренче тере каз күрүебез иде». Күп авылларда нәселләре дә калмаган, сирәк очрый торган, могҗизага әйләнгән каз турында сүз бара. Ул повар Иван белән дуслашып китә, аңа ияреп «эшкә бара, эштән кайта», үзе туктаусыз сөйләнә, нәрсәдәндер зарлана яки дәртле тавыш белән күкрәк кага. Беркөнне каз, дустына иярмичә, өй ишеге төбендә ялгыз басып кала, чөнки ул өйдән үзенә бик таныш тавышлар ишетеп ала. Менә Маша, алъяпкычына салып, тавык астыннан чебиләр алып чыга. «Ләкин каз ни күзе белән күрсен, яшел чирәмдә тавык чебиләре түгел, ә каз бәбкәләре иде. Бу күренештән ала каз тәмам таңга калды. Ул, бәбкәләргә карап, бөтен барлыгы белән йотылган, һич айный алмаслык булып сихерләнгән иде. Бичараның йөрәгендә бу могҗизалы күренештән нинди хисләр уянды икән? Әгәр каз кеше кебек булса иде, һичшиксез, бу минутта аның ике күзеннән сөенеч яшьләре мөлдерәп агып киткән булыр иде».

Кечкенә генә бу хикәядә фәлсәфи фикер-нәтиҗә бар: ана каз бәбкәләрен ияртеп су буена төшеп киткәч, табигатьнең

кечкенә бер хатасы төзәтелгән кебек була. «Шулай итеп, немецлар явыннан япа-ялгыз торып калган ала каз семьялы булып алды... Киләсе язда инде аңа бер көтү бәбкәле, тигез бәхетле тормыш килер». Табигать җан ияләрен шулай итеп яраткан: кешеләр дә, тереклек тә үзенең дөньясында — нәселе, гаиләсе белән яшәгәндә генә бәхетле була, чын мохиттә, хәтта ул кешеләр арасында булса да, җан иясе ялгыз. бәхетсез. Табигатьнең гармониясе — гаделлеге шуннан гыйбарәт бит.

Бу фикерне «Мәк чәчәге» нәсере дә раслап тора. Нәсер — татар әдәбиятының аз иҗат ителә торган, әмма оркестрдагы арфа кебек гаҗәеп яңгырашлы булган жанры. Нәсердәге лирик образ тормышның һәм табигатьнең ваклыклардан өстен торган бер хакыйкате булып гәүдәләнә. «Киң авызлы тирән бомба чокырының төбендә үсеп утырган ялгыз мәк чәчәге чокыр кырыена килеп туктаган узгынчы бер солдатка карап сүз башлады». Нәсер мәк чәчәгенең шул монологыннан тора. «Бик күптән инде кеше заты күргәнем юк, һаман ялгызым, һаман ялгызым!» Мәк чәчәгенең хәле — ялгызлыкның символы. Нәсернең бер авазы — шул ялгызлык. Әсәр шул зарланудан гына торса, анда матурлык булмас иде. Мәк чәчәгендә гаҗәеп акыл, ныклык, тормышны ярату бар. Әсәрнең сәнгать көче, кешелеклелеге шунда. «Торган җирем никадәр буш, җансыз булса да, ерак түгел тере сулышлы тормыш барын сизеп торам... Сез тагын бу юләр тормышыннан зарлана дип уйлый күрмәгез! Һич юк! Мин бит тере! Ничек мин тере булуымнан зарланыйм, ди!.. Әйе, әйе, мин ышанам, мин тормышның бетмәве, чәчәкләрнең кешеләрдән бервакытта да аерылмавы белән бәхетлемен, мин ялгызлыгымнан һич тә зарланмыйм!» Бу сүзләрне кешегә мөрәҗәгать итеп, нәкъ менә мәк чәчәгенең әйтүе, чынлап та, тереклек авазы булып яшәүгә — тере булуга мәдхия булып яңгырый.

Әмирхан Еникинең сугыш елларында язылган хикәяләре турындагы уйлануларга йомгак ясыйк. Аларда иң ачык сизелеп торган үзенчәлек шунда: сугыш күренешләрен тасвирлау максат итеп куелмый. Язучы сугыш белән очрашкан кешене, тереклекне тасвирлый, сугышның ни дәрәҗәдә кайгы-хәсрәт булуын гәүдәләндерә.

Туган илне дошман-илбасарлардан азат итүгә мисал булара к язылган әсәрләр дә күп бездә. Сугыш чоры әдәбияты алдына шундый максат куелган: патриотизм, интернационализм идеяләренә хезмәт итү — әдәбиятның төп бурычы дип

билгеләнгән чор иде бу. Ә. Еники, бу бурычны турыдан-туры мәгънәсендә генә аңлап, шул чорны гына күздә тотмыйча, югарырак дәрәҗәгә күтәрелде. Әйтерсең ул 1941—1945 еллардагы сугыш турында гына түгел, гомумиләштерелгән күренеш турында сөйли. Хикәяләрендә «Ура» кычкырып һөҗүмгә барулар юк, пулялар да сызгырмый, шулай да яшәү һәм үлем турында, сугыш һәм тереклек турында төрле халәтләр мисалында уйланулар, ачышлар бар. Сугыш шартларында кеше үзен ничек хис итә, ниләр кичерә, нинди халәттә яши. Сугыш елларында да тормыш дәвам итте бит, тормыш — яшәү булган икән, аның матурлыгы, кыйммәтләре, мәгънәсе дә булган дигән сүз. Хикәяләр менә шул турыда сөйләп тора, шуңа күрә алар бүгенге көн укучысы өчен дә кызыклы, алардагы фикерләр әһәмиятле.

Сугыштан соңгы чор иҗатында да Ә. Еники сугыш алып килгән котылгысыз фаҗигаләр, югалтулар булып дәвам иткән күренешләр, хәлләр турында яза. Шуларның берсе — ялгызлык. 1957 елда язылган хикәясе нәкъ шулай дип атала да. Ирен, баласын, туганнарын сугыш елларында югалткан Тамара Сергеевна озак еллар туган шәһәре Ленинградтан читтә, «Бөреле» совхозында яши. Чын мәгънәсендә интеллигент булган бу ханым рухи сыйфатлары, тәрбиясе белән үзенә һич тиң булмаган егет белән тора башлый. Ләкин бу тормыш аны һич кенә дә ялгызлыктан коткармый, киресенчә, Тамара Сергеевна газаплы кимсенү хисләрен кичерә. Нәрсә эшләргә тиеш иде ул? Петя Котовның үзенә тиң түгеллеген күрә, белә торып тормышын аның белән бәйләмәскә идеме? Әллә үзенә иптәш табарга өметләнеп, аны үз дәрәҗәсенә күтәрергә тырышып карап дөрес эшләдеме ул? Әсәрдә бу сорауга җавап бирелми, андый максат куелмый да, мөгаен. Шундый четерекле, һәркем үзе хәл итәргә тиешле мәсьәлә бу. Нәкъ үзенә хас итагатьлелек, саклык-сабырлык белән Ә. Еники әйтерсең үз-алдына уйлана. Хәер, ул укучы алдына да күп сораулар куеп калдыра. Игътибар итсәгез, әсәрдә күп урынны сорау җөмләләр алып тора.

«Тауларга карап» хикәясе (1948) — үзенчә бер мәгънәгә ия булган, шулай ук кеше язмышы турындагы әсәр. Локман карт белән Шәмсенур әбинең бердәнбер уллары Тимерҗан үсеп егет булганда, беренче герман сугышы башлана. Солдатка каралыр вакыты җитмәсә дә, Тимерҗанны сугышка алырлар дигән уй Локман карт күңеленә талпан булып ябыша. Кечкенә өметенең дә сүнә баруын аңлап, ул Тимерҗанны өйләндерергә

була. «Яшьләрнең бәхетле көннәре бик санаулы булды, давыл аларны читләтеп узарга теләмәде, һәркайсы эчтән тынып көтеп, һәркайсының йөрәген өшетеп торган рәхимсез сугыш кара канатын, ниһаять, алар өстенә дә җәйде... Ә карт, учына төшкән утлы күмерне тота да, ташлый алмаган шикелле, «Кемгә кирәк бу сугыш, кемгә генә кирәк бу канкоеш?» дигән сораудан котыла алмый йөрде». Сугыш Тимерҗанны да, аның үлеме кайгысын күтәрә алмаган Зәйтүнәсен дә йотты. Алардан Батырҗан торып калды. Локман карт күз карасыдай саклап үстергән оныгын да сугыш көтеп торган икән. «...Сугыш турында йөрәгендә ятканны әйтер өчен, гади кеше сүзләре генә җитми аңа, бик көчсез алар, чөнки бу һичкем теләмәгән сугышның башлануы аның өчен җир түгел, кояш тетрәвеннән дә яманрак булган иде». Чөнки Батырҗаннан берәү дә калмады, нәсел өзелде, киләчәк калмады. Картлык өчен иң куркыныч хәл — ялгызлык килде. Менә шундый хәлдә — фани дөнья белән һәртөрле алыш-бирешләре беткәндәй тоелган хәлдә яшиләр карт белән карчык. Шулай сүлпән-сабыр гына, моңсу-тыныч кына яшәп ятканда, яшь кенә бер хатын, җыйнаклап төрелгән биләү күтәреп, Локман карт өенә килеп керә. Сания бу өйгә тормышның дәвамын — Батырҗанның улы Газизҗанны алып кайта. Язмыш әйтерсең лә рәхимсезлегеннән үзе туеп, ахырда бер гаделлек эшләргә була. «Ерактан, бик ерактан ак читле күгелҗем болытлар акрын гына йөзеп киләләр һәм аларның күләгәләре йомры тау түбәләре өстеннән тын гына шуып үтәләр... Әйе, күләгәләр шуып үтә, тормыш бетми, һаман дәвам итә». Кеше гомерләре бер-берсенә ялганып дәвам иткәндә генә тормыш та дәвам итә. Кеше дә тау кадәр кайгылар күтәрә. Кешегә тау кадәр сабырлыклар кирәк бу дөньяда яшәргә.

Менә шундый биеклектә нәтиҗәләр ясала, укучы күңеле дә олыгая төшә. Әмирхан Еникинең иҗатына фәлсәфилек хас дигәндә, без шул сәнгать югарылыгын күздә тотабыз.

Мәгълүм бер хакыйкать бар: фәндә дә, сәнгатьтә дә иң әһәмиятлесе — сораулар кую, мәсьәләләрне ачыклау. Һәрбер очракта аларга җавап табылмаска яки табылган җавап дөрес, тулы һәм бертөрле генә булмаска да мөмкин. Ләкин алга куелган сорау фикерне кузгата, уйланырга, эзләнергә мәҗбүр итә. Өстәвенә җаваплары беркайчан да тулысынча табылып бетә алмаган мәңгелек мәсьәләләр дә бар бит әле. Шуларны һәркем үзе чишәргә тиеш була, һәм кеше гомеренең нәтиҗәсе үзенә

юлны, яшәү рәвешен, максатларыңны дөрес сайлый белүдән тора.

Әмирхан Еники, әсәреннән әсәренә күчеп, шул турыда уйлана: нинди сәбәпләр кешене бәхетле яки бәхетсез итә; кайчан кеше үзеннән һәм тормыштан канәгать була яки җан тынычлыгын югалта, үзенең рухи дөньясында кеше үзе хуҗа була аламы, әллә ул шул чор шартларына, җәмгыятьнең нинди булуына бәйлеме?

Җиңү белән рухланып, большевиклар партиясе җитәкчелегендә тайпылышсыз рәвештә коммунизмга барабыз дип ихлас ышанып яшәгән сугыштан соңгы елларда Ә. Еники «Саз чәчәге» повестен (1955) язды. Күп еллардан бирле партия эшендә эшләп йөргән, райкомның икенче секретаре булган Шакир Мостафинны конференциядә кабат үз урынына сайламыйлар. Коммунистларның ышанычын югалту — җитәкче кеше өчен яман хәл. Ләкин «тау ишелә башласа, аны ничек туктатасың?» Әсәр әнә шул сорау белән башлана. Нинди тау, нинди ишелү турында сүз бара, бу кадәр җимерелеп төшүнең сәбәпләре нинди соң? Һәм, повестьның исеменнән күренгәнчә, нинди саз чәчәге турында сүз барачак?

Хатыны Мәрьям һәм кызы авариягә очрап һәлак булганнан соң, Шакир Мостафин моннан өч ел элек үзе сорап икенче районга күчеп килә. Үзен беренче секретарь итеп куймаганнарына хәтере калып, шактый кәефе бозылса да, бу кимсенүләргә кул селтәп, артык ватылмыйча, тынычрак җан белән эшкә керешә. Вакыт үтү белән, ялгызлык үзен сиздерә башлый, ул бу ятим, моңсу тормыштан котылырга — өйләнергә була. Менә ул саклык кассасында эшләүче Наҗия исемле кызны очрата. «Барысыннан элек, Наҗия тулаш шәһәрчә нәфис кыз иде. Аннан үзен бик сөйкемле итеп тота да белә... Бөтен килеш-килбәтеннән, тотыш-кыланышыннан, шулай ук шактый фасонча киенгән өс-башыннан аның җитеш тормышта, оста кулда пешеп җитешкән кыз булуы әллә каян күзгә бәрелеп тора иде».

Наҗиянең әти-әнисе,— чыннан да, ни җитте кешеләр түгел, Байгузиннар дип яхшы исәптә йөргән төпле һәм ныклы бер оя бу. Әтисе Идият абзый озак еллар база директоры булып эшли, әнисе Майпәрвәз ханым — гаять үткер, акыллы һәм уңганлыгы белән райүзәктә дан алган хатын. Аның уңганлыгы аш-суга, өй җыештыруга оста булуда гына түгел әле, аның «ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын» дип башлана

торган тулы бер үз «фәлсәфәсе» бар. Нәҗияне дә ул ир дигән бәндәне ничек сихерләүнең серләренә төшендереп, бернинди оят киртәләренә сыймаган киңәшләрен тыңларга мәҗбүр итә. Бу сүзләрне баштарак хурланып һәм чирканып тыңлаган Нәҗия тора-бара үзе үк аларга күнегә башлый, алай гына да түгел, әнисенең шул «политикасы»н яшәү кагыйдәсе итеп ала. Саф күңелле кыз, ир белән торуны шактый мәкерле исәпләргә корып, иренең эше, абруе турында түгел, ә аннан ничек файдалану турында гына уйлап яши башлый. Әйтерсең лә ул — күрер күзгә матур, нәфис чәчәк — тамырлары белән сазлыкта утырган, сазлык һавасын сулап агуланган чәчәк булып чыга. Мостафинга моның мәгънәсен табигать күренеше дә раслап тора, «юлдан сул якта, сазлыкка әйләнгән бер кечкенә уйсулыкта, күче белән сары чәчәкләр үсеп утыра. Ялгыз, үзләренә бер гаилә булып үсеп утырган бу озын сабаклы һәм бармак бите хәтле кечкенә чәчәкләрнең сары төсе искиткеч ачык, якты иде. Эретеп тамызган гәрәбә тамчысыдай янып торалар иде алар». Халыкта аларны ачык төсенә карап кына түгел, бик зәһәр булганнары өчен «ут чәчәк» дип тә йөртәләр икән. «Менә син аны тотып иснәсәң — төчкертә ул, капсаң — авызны уттай яндыра, ышкысаң — тәнне боза. Алама нәрсә, шуңа күрә мал да ашамый аны».

Әсәрдә менә шундый хәтәр бер дөнья тасвирлана. Нигә хәтәр, нигә куркыныч бу фәлсәфә, бу яшәү рәвеше? Беренче карашка, кешеләрнең әйбәт, тук, тыныч яшәргә омтылулары табигый. Ләкин бөтен хикмәт шунда: кем хисабына, нинди хак түләп?!

Майпәрвәз ханымның кыйбласы, «иманы»,— мәсәлән, заман үзгәрешләренә яраклашып, бары тик үз исәбен генә алга куеп, башкалар җилкәсенә басып өскә үрмәләү. Ул ирен дә «яратмаган да, яратырга тырышып та карамаган. Аңа бары Идиятнең җилкәсе кирәк булган. Шул җилкәгә атланып алгач, Майпәрвәз тезгенне тота белгән инде. Бәхетеннән, Идиятебез тезгенне тиз сизә торган шактый йомшак башлы мәхлук булып чыккан». Менә шулай да яшәп була, әйтергә кирәк, шактый чибәр генә, көйле генә тормыш корып яшәп була. Шулай да күңелгә кызыклы бер сорау килә: менә бу «акшарлы битенә елмаю каткан» Майпәрвәз ханым бердәнбер кызын нәкъ үзе дигәнчә яшәтүгә ирешә — Нәҗия дә ире белән шактый оста-мәкерле идарә итәргә өйрәнеп җитә. Ә бу ояда тагын ир бала да булса яки бердәнбер балалары кыз түгел, ә ир бала булса, Майпәрвәз ханым нинди каенана булыр иде дә улына нинди сабаклар бирер иде икән?

Повестьта төп сурәтләү объекты Шакир Мостафин бит әле. Аның белән нинди хәл була? Өйләнгәннән соң, Шакирның гаилә тормышы шактый көйләнеп китә: ул — кадерле кияү, янында — уңган, чибәр Нәҗиясе. Мул-уңайлы тормышның нәтиҗәләре Мостафинның эшендә дә бары тик уңай яктан гына күренергә тиеш кебек. Ләкин нигәдер «әнә күпме укылмаган журнал өелде; икешәр-өчәр бите генә укылып ташланган күпме китап җыелды. Күңелле эш түгел иде бу. Юк-юк та, аның моңа эче пошып куя иде». Әмма янында бала кебек үпкәләргә торган, үзенә игътибар таләп итеп торган Нәҗия булганда, эшләнмәгән эшләр, үтәлмәгән бурычлар икенче планга чигенә бара. Шулай «көйләнеп» китә бу җылы, җыйнак, тыныч, аулак тормыш.

Мостафин эшен бетерер-бетермәс кайтып китәргә дә гадәтләнә, гел Нәҗиясен генә уйлап йөри. Ә шулай да тынычлыгын җуя бара. Шундый вакытта ул бөтен акылы, рухы белән Мәрьямен юксына, аңа хатын гына түгел, дус, сердәшче һәм бик акыллы киңәшче булган Мәрьям булсын иде янында. Ире аптырауга төшкәндә, аңа иң кирәкле киңәшне бирә белгән, аның җаны-рухы, хезмәте-намусы турында кайгыртып торган хатыны исән булсын иде. Аның Мәрьяме, чынлап та, күзгә бәрелми торган тыйнак, сабыр һәм түзем кыр чәчәге булгандыр. Менә ул күзләрне камаштырырлык гүзәл белән яши. Тик нәрсәдер югалта бара.

Иң беренче чиратта ул күңел сизгерлеген югалта, дөресрәге, шуның белән килешә бара. Чынлап та, ул үзенә кул селтәп, Майпәрвәзләр дөньясына чумып йотыла бара. Менә аның алдына җайлап кына өй салу мәсьәләсен куялар. Бер караганда, кешенең үзенә өй салып керүе тырышлык, уңганлыкның мисалы кебек. Үз көче белән, хәләл хезмәт куеп башкарылганда бу, чыннан да, шулай. Ләкин хикмәт шунда: өй салуның башлануы гына Мостафинның хезмәтенә зыян китермәслек, аның дәрәҗәсенә күләгә төшермәслек була. Ә дәвамы һәм ахыры шактый гыйбрәтле булып чыга. Беренчедән, кызу эш өстендә колхозлардан чакырып китерелгән дүрт балта остасы сала аның өен. Икенчедән, мәшәкатьсез генә күренгән эш шактый катлаулы булып чыга, Мостафинның исеме, дәрәҗәле урыны шул өен салуга хезмәт итә башлый. Хуҗа үзе дә күп вакытын, әле тегесен, әле монысын эшләп, осталар тирәсендә үткәрә башлый. Ниһаять, өй салынып бетә, ләкин ул инде, нигәдер, Мостафинга шатлык та, канәгатьлек тә китерми. «Бик әшәке

иде аның рухи хәле. Оят та иде аңа, авыр да иде. Кемнәрдер алдында гаепле дә кебек иде».

Авылларда йөргәндә, хатын-кызларның нинди авырлыкларга чыдап, күпме фидакярлек күрсәтүләрен ул үз күзләре белән күреп йөри. Ми кайнарлык эсседә аларның чәй эчәргә шикәрләре дә юк. «Ә бит аның өендә ике эшсез хатын, аналы-кызлы, потлап варенье кайнаталар, янып-көеп печән чапкан, урак урган апайларга дигән шикәр нииндидер хәрәм юллар белән аның үз өстәленә килә. Ул тик күрмәмешкә, белмәмешкә салына. Я, оятсызлык түгелме инде бу? Һәм менә шушы үзенең җаваплы исеменә, тоткан урынына һич ярамаган хәлне бик яхшы аңлау һәм шул хәл белән килешеп яшәү аның төп бәхетсезлеге иде».

Шушы халәттә интегеп яшәү, үзенең намусы югала баруын тою — Мостафинның эчке фаҗигасе. Ул, җинаятьче дип аталып, хөкемгә тартылмаса да, үзен югалтты, җан тынычлыгын югалтты. Тагын да яманы шул: ул үзен газаплаган бу каршылыктан чыгарга тырышып та карамады, чөнки ул «ут чәчәге»нә кызыгып сазлыкка-баткаклыкка керде һәм шунда батып калды, шул хәленә ияләште, рухы белән кол хәленә төште. Соңгы вакытта ул агач эшләре артеле председателе булып тора, йортын һәм терлекләрен үзе карый, «һәр көнне эштән кайткач ул, иске телогрейкасын кия дә тизрәк шулар янына чыга, башы кирәксез уйлардан буш, күңеле йокыга талгандай тыныч». Менә шулай Майпәрвәз сазлыгы тагын бер корбанын йота.

Әсәрдә тасвирланган гыйбрәтле язмыш турында уйланып, нәтиҗәләр ясыйбыз. Тормышта һәркемнең үзе сайлап алган, теләгән һәм омтылган максатлары, яшәү биеклеге була. Биеклек дигәндә, дәрәҗәле урын гына күздә тотылмый, әлбәттә. Мостафин гап-гади колхозчылар каршында басып торганда үзен гаепле итеп сизә икән (һәм ул, чынлап та, гаепле), бу инде — кеше җанының ваклануы, рухи түбәнлек, җимерелү дигән сүз. Элек Мостафин сәләтле, намуслы җитәкче иде, башкалар язмышын кайгыртырлык, зур эшләргә акылы-тәҗрибәсе җитәрлек кеше иде. Ул үзе аңлап, күрә торып шул биеклекне югалтты, тауның ишелүе дигәндә, Ә.Еники, мөгаен, шуны күздә тота.

Тагын шунысы әһәмиятле: 50 нче елларда барган бер вакыйга мисалында кайсы чор өчен дә бик мөһим булган, гомуми яшәү рәвешенә, кешенең рухи хәленә кагылган мәсьәлә

күтәрелә. Бүгенге көндә ул хәтта үткенрәк тә булып, һәркемнең хәленә кагыла торган мәсьәләгә әйләнде. Җәмгыятьнең хәле беренче чиратта аның белән кемнәр, ничек идарә итүгә бәйле. Әгәр җитәкчеләр үз өсләренә алган бурычны үтәргә сәләтсез булып чыксалар яки, аннан да яманрагы, аңлы рәвештә үз урыннары, дәрәҗәләре биргән мөмкинлекләрдән явызларча файдалансалар, җәмгыятьнең үсешендә, иҗтимагый тормышта фаҗигаләр башлана. Җәмгыять тормышындагы шушы катлаулы процессның бер чагылышын без Мостафин язмышы мисалында күрәбез. Дөрес, ул — явыз җинаятьче булудан бигрәк, шул җинаятьчел фәлсәфәнең, психологиянең корбаны. Әмма фикерне дәвам иттерсәк, бүгенге көнгә килеп җиткән бәйләнешләрне җиңел табып була. Алай гына да түгел, Ә. Еники 50 нче елларда күтәргән бу мәсьәләне 80 нче елларда башка язучылар тагын да кискенрәк итеп куйдылар: Ринат Мөхәммәдиев «Кенәри — читлек кошы», Аяз Гыйләҗев «Балта кем кулында?» дигән әсәрләрен яздылар. Аларда инде нәкъ безнең заман, бүгенге җәмгыятькә ясалган яралар, фаҗигаләр тасвирлана.

Әмирхан Еникине иҗтимагый вакыйгалар түгел, кеше язмышы, аның рухи дөньясы — күңел дөньясы күбрәк кызыксындыра. Аның геройларын да уңай яки кире герой дип кенә бәяләп булмый, хәтта язучы үзе дә аларга кискен хөкем чыгарырга ашыкмый кебек. Һәрхәлдә, ул аларның хәлен аңлап, кичерешләрен, битараф булмыйча, геройлары өчен үзе дә борчылып тасвирлый. Дөрес, бик гадел, намуслы рәвештә сәбәпләрне дә ачык күрсәтеп, анализлап бирә. Кешеләр язмышында, кабатланмас үзенчәлекләр белән бергә, уртак яклар да була. Бигрәк тә заман нинди, тормыш кай якка таба үзгәрә дигән сорауларга җавап эзләгәндә, уртак сыйфатлар, сәбәпләр ачыла.

Язучы өчен иң кызыклысы, әлбәттә, кеше табигате, аның характеры, психологиясе. Ә. Еники һәр әсәрендә үзәккә бер язмышны куеп анализлый. Без дә ул язмышларны, характерларны үзара чагыштырабыз, үзебез өчен дә гыйбрәтләр алып уйланабыз. Мостафин, мәсәлән, акылы белән аңлап, күңеле белән тойса да, йомшак характерлы булуы аркасында, шундый хәлдә калды, каршылыклы хәлдән чыга алмады. Чәчәктәй нәфис Наҗиясе белән ул кешеләр алдында горур һәм бәхетле булыр кебек иде, әмма шул ук вакытта берни белми, белергә дә теләми, берни уйламый торган җилбәзәк хатын белән адәм көлкесенә калу, тирән бәхетсезлеккә төшү ихтималын да сизеп

яшәде. Таудан түбән тәгәрәү җиңелрәк, аның өчен тырышлык кирәкми, үз хәлең белән килешү, ризалашу җитә. Ләкин ул килешү — чигенү, үз көчсезлегеңне тану дигән сүз. Мостафин, хәтта борчылу чиген дә үтеп, битараф рәвештә, йокымсырап яши башлый. Бу дәрәҗәгә төшкән кеше кемдә дә теләктәшлек уятмый инде. Без моннан гыйбрәтләр генә алабыз.

60 нчы еллар татар әдәбиятына вакыйга булып килеп кергән, бәхәсләр һәм каршылыклы фикерләр уяткан әсәр — «Рәшә» повесте булды. Ни өчен бәхәслеме? Чөнки совет әдәбиятының төп герое тик уңай герой гына булырга тиеш дигән карашка күнеккән идек. Әмирхан Еники, менә шул мәҗбүриятькә буйсынмыйча, җәмгыять үзе тудырган типны мәйданга чыгарды. Бу әсәр уңай һәм кире геройлар конфликты турында түгел, ә катлаулы, каршылыклы күңел дөньясы, кешенең шактый яшерен дә, серле дә булган эчке дөньясы турында. Бәхеткә омтылып та бәхетсезлеккә дучар булган язмыш турында. Ә. Еники Зөфәр Сабитов язмышын гына түгел, шундый язмышларны тудырган җирлекне дә анализлый.

Иҗат үзенчәлегенә хас булганча, әдип-рәссам Зөфәр турында да аны беркем күрмәгәнчә, аңламаганча, читтән карап түгел, аның күңел түренә үтеп, иң яшерен уйларын, теләкләрен сиземләп яза. Күп очракта ул үзе Зөфәр булып сөйли, тормышны һәм кешеләрне дә Зөфәр булып күрә, бәяли. Башка чор. Характер да бүтән. Әмма «Саз чәчәге»ндәге Шакир Мостафинныкыдай гаять гыйбрәтле һәм уйландыра торган язмыш. Автор аның нәтиҗәсен алдан ук искәртеп тә куя кебек — әсәрнең исеме бик мәгънәле. Рәшә ул — табигать күренеше, коры далада алдалап уйнаклаган эссе шәүлә; матур җемелдәп, ымсындырып торган, әмма барып җитүгә бушлыкка әйләнә торган һава дулкыны.

Әсәрнең башлануы да хикмәтле — тугызынчы май таңында, Җиңү көнендә Зөфәр төш күрә. Буш, тын, чиксез дала буйлап каядыр бара, имеш. Аны берөзлексез кояш яндыракөйдерә. Очы-кырые күренмәгән үлек даланы үтеп чыгуга, ул нindидер могҗизалы дөньяга барып җитәчәк һәм бәхетен дә шунда табачак. Берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә ялгызы гына чыгып китүе дә шуның өчен, имеш.

Менә шулай, киләчәгенә бара торган юлга да Зөфәр ялгызы гына чыга. Аның үзе өчен генә корып куйган фәлсәфәсе бар: бәхетле булу өчен, башкалардан өстен, көчле булырга кирәк. Бик ачык күз алдына китергән, төшендәге зәңгәр күл кебек

үзенә чакырып торган киләчәге, шул киләчәккә алып барачак яшерен юлы бар. Ныклы исәп-хисапка корылган, беркем белмәгән һәм белергә дә тиеш булмаган планнары бар. Иң башта ул бу сугыштан, көн саен меңнәрчә адәм баласын йотып торган бу гарасаттан котылып калырга тиеш. Нәкъ шул максат белән ул хәрби заводның тәэминат бүлегенә урнаша, һәр адымын үлчәп атлый, сүзен уйлап сөйли, завод өчен, чынлап та, кирәкле кешегә әйләнә. Сугыш елларын шулай исән-имин үткәреп җибәрә. Дөрес, ул кешеләрнең аны сәламләү түгел, бөтенләй күрмәмешкә салышуларын, астыртын бер дошманлык белән артыннан карап калуларын сизеп-тоеп яши. Тап-таза яшь кешегә кайгы-хәсрәткә баткан, ачлыктан, салкыннан интеккән кешеләр арасында көн итүе җиңел булмый. Ләкин аның фәлсәфәсе нык: исән калу факты үзе генә дә (нинди хисапка булса да) кешегә «Бәхетлемен!» дип әйтергә хокук бирәчәк. «Исән калган баш ничек яшәр — ә ул моның серен белә инде: бәхет — үзең теләгәнчә яшәү, бәхет — матди һәм рухи бәйсезлек ул. Бәс, шулай икән, Зөфәр дә киләчәк тормышын үзе теләгәнчә бәйсез, иркен, мул итеп корып җибәрергә тиеш».

Игътибар итегез әле: бу теләк-омтылыш бүген кемгә дә булса «чит» яки «сер»ме соң? Киресенчә, без шушы хакта ачыктан-ачык сөйлибез, аны уртак максат итеп куябыз. Күрәсең, бөтен хикмәт тә максатларның, күңелләрнең ачык, бәхетшатлыкларның уртак булуындадыр. Зур хакыйкать шулдыр. Әсәрдә рухи бергәлекнең нинди зур көч икәнлегенә бик матур дәлил дә бар. «Юньләп исемнәре дә билгеле булмаган, болай карап торырга йолкыш кына күренгән дүрт артист халыкны нишләтте? Гаҗәеп бит бу, гаҗәеп! Халык гүя ач булуын, ялангач булуын, нинди авыр михнәттә яшәвен онытты; елады, көлде ул, һәм, иң гаҗәбе, тирән рухи бер канәгатьләнү алып, гүя эчләренә тагы да зур сабырлык, чыдамлык, батырлык җыеп таралды ул!» Ягылмаган, ярым караңгы клубта Рәшидә җырлаган халык җырлары «зур халыкның гүя барлык йөрәк зарын, саф вөҗданын, авыр хезмәтен, кара бәхетен, якты өметен, кырларны-яланнарны, тауларны-урманнарны, сандугач-былбылларны — барысын бергә җыйган, бергә үргән, бер киң дәрьяга әверелдергән иде».

Чынлап та, халык язмышы — шундый каршылыклы дөнья, әмма бербөтен дөнья. Шуннан аерылып, үзең генә югары күтәрелеп, ялгызың гына бәхетле булып булмыйдыр. Бүгенге көннең миллионнар, миллиардлар белән эш йөртә торган эш-

куарлары бар. Матди байлык белән акылын җуймаганнары, аңын томаламаганнары бер фикерне кабатлыйлар: үзеңне чын мәгънәсендә бәхетле итеп тою өчен, үз әйләнә-тирәңдәге кешеләрнең дә бәхетле булуы кирәк, диләр.

Икенче яктан караганда, кешенең үз шәхси тормышы, үз дөньясы, үз бәхете дә булырга тиеш, кешенең шуңа омтылырга хакы бар бит әле. Шуңа күрәдер Ә. Еники Зөфәрне халыкка, җәмгыятькә каршы куеп, җинаятьче итеп түгел, ә үзенең максатларына тайпылмыйча бара торган, көчле ихтыярлы, акыллы кеше итеп тасвирлый. Характер сыйфатларын аерым гына санап чыксак, әнә шундый уңай персонаж күз алдына килә. Һәрхәлдә, Зөфәр — бәхетле булырга лаек, бәхеткә омтылган һәм, күп тырышлыклар куеп, үзе теләгән бәхетенә барып җиткән кеше. Шулай да нигә канәгатьлек, җан тынычлыгы, шатлык-куаныч китермәде соң әле аңа бу бәхете?

Беренчедән, ул һаман да, сугыш беткәч тә, кешеләрдән куркып-сакланып, булган байлыгын да кеше күзеннән яшереп яшәргә мәҗбүр. Сизә бит ул: күршеләре дә, хезмәттәшләре дә аңа кырын карыйлар. Кемне өйгә кертергә, кунакка чакырырга, кем белән аралашырга — барысын да кат-кат уйларга тиеш ул. «Исәп белән торырга кирәк... Әйе, бары тик исәп белән, исәп белән, исәп белән, кадалып киткере!» Әсәр ахырында Зөфәр әнә шундый халәттә кала. Рәшә булып кала аның бәхет дигәне! Җанны яндыра-көйдерә торган исәп-хисап колына әйләнде Зөфәр, ә нинди акыллы, көчле кеше иде ул. Күрәсең, акылның да, нинди максатка хезмәт итүгә карап, төрлесе була.

Зөфәрнең менә шул бик ныклы исәп-хисапка корылган акылы ялгышты; аның тормышын матурлык белән тутырачак, бәхетен бөтенәйтәчәк Рәшидәгә булган мәхәббәтен дә шул исәп-хисаплар аркасында корбан итте, үзен шуңа мәҗбүр итеп ялгышты. Үзен аңларлык, теләктәш булырлык кешеләрдән читләшә торгач, ул әйтерсең төшендә күргән ялангач далага килеп чыкты. Югыйсә Зөфәр ничек ярата иде. «Шушындый гүзәл, ак хыяллы, нечкә, пакь җанлы бер хатынның якын, ышанычлы кешесе булу аны ничектер үз күз алдында үстереп җибәрә, күңелен әйбәт бер горурлык белән тутыра иде. Алай гына да түгел, бүтән бервакытта да татырга туры килмәгән, бары чын матурлыктан, якты уйлардан гына килергә мөмкин булган аеруча тирән, олы бер бәхет кичергән кебек тә була иде ул».

Менә шундый бриллиант кисәгедәй нур чәчеп торган, матур хыяллары булган Рәшидә аннан баш тартты. Югыйсә бит Зөфәр, болай өстән караганда, әйбәт кеше иде, кирәксә, үзен гел уңай яктан гына күрсәтә дә белә иде. Шуның белән бергә, ул гаять сак кеше дә иде, аңа үзенең уй-теләкләрен күңеле булганчы ачыласы килгән чакларда да йомык-бикле булып калды. «Акыл искиткеч уяу аңарда!» Менә шул салкын акыл ахыр чиктә аңа артистка Рәшидәгә өйләнү дөрес булмас, «Юк инде, артистка белән башың бәйләнә күрмәсен!» дип аның күңелен бикләп куя. Дөрес, ул Рәшидәгә, аны югалта баруын сизгәч, өйләнергә тәкъдимен әйтә, ләкин Зөфәрнең ике төрле дөнья белән яшәвеннән, аны аңлый алмаудан гаҗиз булган Рәшидә аның бу канатсыз бәхетеннән баш тарта. Ул иркен дөньядагы хөр бәхеткә, ак хыяллар һәм зәңгәр биеклекләр белән үлчәнә торган бәхеткә генә табына. «Әйе, гыйбрәт бу... Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар — шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!»

Менә нинди катлаулы икән ул бәхетне аңлау. Зөфәр һич икеләнүсез, бик төгәл исәп белән барды бәхетенә. Тик бәхетле була алмаячак ул. Бик дәрәҗәле, төшемле эш урыны да, Зөфәренә «Хуҗам!» дигәндәй күндәмлек белән генә карап торган Гамбәр туташ та аны бәхетле итмәячәк. Зөфәр — акыллы кеше, аңлый ул моны.

Әсәрнең көче шунда: бу язмыш турында, аның сәбәпләре-нәтиҗәләре турында кабат-кабат уйланасың. Нәкъ Такташ әйткәнчә, акыл белән йөрәк сугышканда, кайсы хаклы икәнен ялгышмыйча, хаталанмыйча билгеләү гаҗәеп авыр мәсьәлә икән. Бернәрсә ачык: дөнья исәп-хисапка гына корылса, күңелдә бушлык хасил була, төзәтеп булмаслык хаталар ясала икән. Табигатьтә дә, кеше җанында-рухында да гармония булса гына, матурлык, иминлек саклана, акыл белән йөрәкнең килешеп яшәве — бәхетле булуның төп шарты. Хак шулай бу.

Бирем

Әмирхан Еники иҗатына карата сез үзегез нинди сораулар һәм биремнәр билгели алыр идегез? Ягез, кем нинди темаларны аерып күрсәтә ала?

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҮЗГӘРЕШЛӘР ЧОРЫ АЛДЫННАН

Матур әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре, гадәттә, берьюлы, кинәт кенә барлыкка килми. Яңалык еш кына күнегелгән тормышта, ягъни иске эчендә туа, шунда үсә-җитлегә. Татар әдәбиятының бүгенге үзгәреш һәм яңарыш елларында ирешкән уңышлары да берьюлы, әзерлексез генә була алмас иде. Совет җәмгыятендәге хәлләрнең асылын ачкан тормыш дөреслегенә ирешү юлы аерым язучылар өчен 60—70 нче елларда ук башланды. Сез моны алдагы бүлекләрдә, бигрәк тә Х. Туфан яки Ә. Еники кебек сүз осталары әсәрләрен өйрәнгәндә күрдегез.

Яман шәхес культы фаш ителгән, ягъни тоталитар системага беренче удар ясалган 1956 елдан соң илдә беркадәр демократик иркенлекләр хасил булды. Бу чорда татар әдәбиятында да җанлану башланды. 20—30 нчы елларда «халык дошманнары» дип тамгаланып, моңарчы тыелуда яткан бер төркем язучыларның әсәрләре укучыларга кайтарылды. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов кебек дистәләрчә талант ияләре иҗат иткән хәзинә әдәбиятны һәм сәнгатьне баетты. Төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә исән калганнар, туган илләренә кайтып, иркенәеп яңадан иҗат эшенә керештеләр (Х. Туфан, И. Салахов, С. Рәфыйков, М. Бөдәйли, А. Гыйләҗев, Г. Тавлин һ.б.).

Шул елларда әдәбиятыбызга бер зур төркем яшь талантлар килде. Алга таба әдәбиятыбызны үстереп алып китү нәкъ менә шуларга насыйп булды. Бүген аларны Н. Исәнбәтләргә, Г. Бәширов һәм Г. Әпсәләмов, И. Гази һәм М. Әмирләргә алмашка килгән буын дип атау гадәткә керде. Бу буынны Гариф Ахунов һәм Нурихан Фәттах, Хәй Вахит һәм Аяз Гыйләҗев, Гамил Афзал һәм Мәхмүт Хәсәнов, Шәүкәт Галиев һәм Илдар

Юзеев, Хисам Камалов һәм Әдип Маликов, Әхсән Баянов һәм Туфан Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Миргазиян Юныс һ.б. кебек бер-берсенә һич тә охшамаган, үзенчәлекле каләм ияләре тәшкил итә. Алар әдәбиятка яңа фикерләр, өр-яңа образлар һәм тормыш сурәтләре алып килделәр.

Иң мөһиме: бу язучылар иҗатында кешегә, шәхескә игътибар артты. Кешенең эчке дөньясы, аның җирдәге һәм тормыштагы урыны, яшәвенең мәгънәсе кебек катлаулы темалар торган саен күбрәк яктыртыла башлады.

Ә әдәбиятның төп вазифасы кешене сурәтләү икәнлеген инде сез яхшы беләсез. Бу эш әдәбият яшәешенең буеннан-буена төрләнә һәм байый, тирәнәя һәм тәэсирлерәк була бара. Моны югарыда исемнәре аталган язучылар иҗаты да ачык раслый.

Өлкән буын әдипләре Г. Ибраһимов һәм Ш. Камаллар да, аларга алмашка килгән К. Нәҗми һәм Ш. Усманов, Г. Бәширов һәм И. Газилар да кеше характерын тасвирлаганда, аның эчке кичерешләренә шулай ук игътибар иттеләр. Әмма алар кешене, иң беренче, аерым катлау яки төркем вәкиле буларак сурәтләделәр, еш кына сыйныф билгеләмәләреннән чыгып эш йөрттеләр. Шуңа да алар күп вакытта шәхси мәнфәгатьләрен коллектив мәнфәгатьләренә буйсындырган геройны якын күрделәр.

Иҗатлары 60 нчы еллар тирәсеннән башланган буын вәкилләре дә кешене шул яссылыкта сурәтләүне дәвам иттеләр. Ләкин тора-бара аларның иҗатларында шәхеснең характер билгеләрен аның эчке дөньясыннан эзләү гамәле алга чыкты. Әдәбиятта Совет хакимияте тарафыннан кыерсытылган һәм рәнҗетелгән кешеләр, Ватан сугышы афәтләре нәтиҗәсендә җәфаланган, ялгыз калган хатыннар, карт-карчыклар, ятимнәр, олыгайган кызлар образлары күбәйде, аларның һәркем өчен аңлаешлы кайгы-хәсрәтләрен гәүдәләндерү җанланды. Әдәбият тормыш дөреслегенә тагын да ныграк якынайды. Болар барлык жанрлар һәм жанр төрләре өчен хас. Моны без түбәндәге иң характерлы мисалларда, 60—90 нчы елларның иң яхшы әсәрләрендә карап үтәрбез.

ПРОЗА

Гариф Ахунов
(1925—2000)

Кешеләргә әйтәсе сүзләре китапларга күчкәнче, Гариф Ахуновка башта күп борылышлы тормыш юлы үтәргә туры килә. Әтисез калуы күңеленә тирән яра булып уела; беренче укытучылары, остазлары аны эш яратырга, тырыш булырга, гаделлеккә өйрәтәләр; туган авылы Кечкенә Өчиле күренешләре рәсем булып ясала; беренче шигырьләре языла. Саный китсәң, болар барысы да — балачак, мәктәп еллары. Аннан соң — Арча педагогия училищесы, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге...

Данлыклы Казан арты төбәге, әдәбият өчен аның гаять шифалы һавасы һәм булдыклы, киң күңелле кешеләре Гариф Ахунов иҗатының нигезе булалар. Хезмәт сөю сыйфаты аның эстетик карашларының нигезендә ята, яшәү ямен-мәгънәсен ул шунда күрә. Ул көндәлек тормышта да, иҗатында да авырлыклардан зарланып түгел, аларны тырышлык белән җиңеп, яшьлектәге хыял-омтылышларына хыянәт итмичә, күңел көрлеге һәм көләчлеге белән үзенең тормышын һәм иҗат дөньясын матурлап яши.

Оештыру сәләте, өлгерлеге һәм тынгысызлыгы Гариф Ахуновны әдәбият тормышының киң мәйданына чыгара: университетны тәмамлагач, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында эшли; 1956—1968 елларда Әлмәттә яши, анда Язучылар берлеге бүлеген оештыра; аннан соң Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре, озак еллар бу берлекнең рәисе булып эшли. «Казан утлары» журналы редакторы булган елларда шулай ук әдәби процессның үзәгендә кайнап яши. Татарстан язучыларының башка милли

әдәбиятлар белән җанлы бәйләнешләрен урнаштыруда роле зур була.

Гариф Ахуновның «Яшьлек яме» повесте белән башланган иҗаты күп санлы хикәя һәм повестьлары, әдәбиятыбызда күренекле урын алган «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнары белән танылды. «Хәзинә» романы һәм «Чикләвек төше» повесте өчен ул 1973 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1993 елда әдипкә «Татарстан Республикасының халык язучысы» исеме бирелде. 1998 елның февралендә Гариф Ахунов Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы әгъзасы итеп сайланды.

«Идел кызы» романы — ике китаптан торган, гаять катлаулы чор һәм язмышларны чагылдырган әсәр. Габбас мулланың бай һәм каршылыклы рухи дөньясы 70 нче еллар әдәбиятының бер ачышы булды. Татар халкының күренекле бер вәкиле булган Ардуанов Мирсәеткә багышланган тарихи-документаль повесть — «Ардуан батыр»ны язуы да очраклы түгел иде: Гариф Ахуновны көчле рухлы, иҗтимагый тормышта югалып калмый торган, үз язмышларына хуҗа булып яши торган кешеләр кызыксындыра. Язучының һәр героенда күпмедер дәрәҗәдә ул үзе дә чагылмыйча калмый, һәрхәлдә, язучы үзенә аңлаешлы булган, үзе сокланган кешеләр турында рухланып, теләктәш булып яза.

«Хәзинә»

(1963)

Гариф Ахунов иҗатында аеруча күренекле урын тоткан әсәр — «Хәзинә» романы. Бу әсәрен ул Әлмәттә яшәгән чорда, Татарстанда нефтьнең яңа, зур катламнары ачылган һәм үзләштерелгән елларда, шул нефть мәйданының үзәгендә торып, кешеләре белән якын аралашып, аларны күңел аша үткәреп язды. Бер җөмләгә җыеп, роман нефтьчеләр тормышы, хезмәте турында дип әйтергә була.

Әдәбият тормышта булган үзгәрешләрне, яңалыкларны тасвирлап тора. Бу — әдәбиятның бер максаты, шуңа күрә яңа темага багышланган әсәргә аеруча игътибар итәбез. Ләкин әдәби әсәрнең кыйммәтен тасвирлаган вакыйгалар, тормыш күренешләре генә билгеләми. Иң әһәмиятлесе: бу материал авторга ни өчен кирәк, бу вакыйгалар мисалында язучы нинди сорау, мәсьәләләр турында уйлана, ягъни нинди проблема куя һәм безне ни өчен уйга салырга тели. Әсәрне озын гомерле

иткән сәбәп — проблеманың зур, катлаулы булуында, аның бүгенге көнгә дә килеп җиткән һәм безне киләчәгебез өчен кирәкле юнәлештә уйландырырлык булуында.

«Хәзинә» романы — ике китаптан торган зур әсәрнең беренче кисәге. Вакыйгалар салмак кына башлана, дөресрәге, төп вакыйгаларга кадәр автор укучысын кешеләр белән таныштыра, җирлек әзерли.

...Иске Кәлимәт авылында Көбәшләр нигезендә яшәгән кешеләрнең иң өлкәне, иң борынгысы — төп йортта берүзе торып калган Йөзлекәй карчык үлеп китә. Ил буйлап сибелгән балалар, җыелып, әүлия кебек күргән бу карчыкны кадерләп күмәләр. «Йөзлекәй карчык безнең татар авылларында сирәк очрый торган озын гомерле һәм хәсрәт-кайгыны батыр күтәрә алган чыдам кешеләрнең берсе иде». Ул үләсе көнне үзе кебек үк борынгы чишмә янына төшә, дөньяларның матурлыгына сокланып, чишмәдә битен юа, үткән гомере турында уйланып утыра, һәм шул чишмә буенда, табигатьнең үзенә кайтып киткәндәй итеп, җан бирә. Аның олы улы Шәвәли гаиләсе дә кайчандыр Кәлимәтнең күренекле кешеләре булганнар, әмма ул нигез дә инде тузып-искереп бара, иң яманы — балалары аның дөньясын кабул итмичә таралышып беттеләр. «Тормышы да көйсез түгел иде, балалар үсеп җиткәч кенә көйсезгә китте. Фәйрүзәсе белән Арыслангалие ата нигезен үз итмәделәр. Быел унынчыны бетергән Мәрзиясе дә йортка күңел салмый. Телендә гел шәһәр. Төпчеге Габделхәй кайчан карама кармак күтәргән, су буенда. Йөрәкләре үлгән. Мүк баскан йөрәкләрен!.. Бер-бер артлы йортны ташлап чыккан балалары өчен, көн саен туза, җимерелә барган хуҗалыгы өчен борчылу, кайры корты кебек, йөрәген кимерә башлады».

Бер гаиләдә генә туган, бер нигезнең генә таркалуына караган конфликт түгел бу, мәсьәлә зуррак һәм катлаулырак. Нефть үзенә яңа җирләр даулый, иген басуларына, кешеләрнең бәрәңге бакчаларына бораулау вышкалары утыртып куялар. Дөрес, акча түлиләр, яңа җир бирәләр, әмма кешенең — нәселнең гомер иткән җирен-нигезен таркаталар бит. Әнә Шәвәлинең балалары да нефть эшенә китеп беттеләр. Ничек туктата ала ул ташкын булып килгән бу яңарышны, үзгәрешне?! Әсәр чишеп булмый торган шушы каршылыкны тасвирлау белән башлана. Бу әле 50 нче еллар — Татарстан данын бөтен илгә, бөтен дөньяга шаулаткан ачышлар чоры, авыллар яңа шәһәрләргә әйләнгән, беренче асфальт юллар түшәлгән, әллә нинди

хыяллар белән рухланып яшәгән чор, бу яңарыштан бары уңайлык, бик нык алга китү, уңыш-җиңүләр генә килер дип уйланган еллар.

Тик менә Йөзлекәй карчык кына башкача уйлый иде: «Дөрес булса, җир астыннан май тапканнар, ди... Үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең әле. Һәммәкәй төшне тишеп, җир мае суыртасылар, ди... Чишмә суларын былчыратып, үләннәрне корытып бетермәсәләр ярарые». Карт-карчыкларның искелеге, артталыгы, аңсызлыгы дип кенә кабул ителгән бу шикләнүләр нәкъ шулай булып чыкты. Уңдырышлы туфраклар, җирнең өсте актарылып, тау-тау кызыл балчык өелде, йөзләгән машиналар җиргә, аркылыга-буйлыга, тирән җәрәхәтләр ясады. Бүген без менә шундый аяныч нәтиҗәләрне күрәбез.

Мәсьәләнең бөтен катлаулылыгы да шунда: нефть, бер яктан, Татарстанны күтәрде дә шул. Менә бүген ягулык торган саен кыйммәтрәк була бара. Җир астындагы бу хәзинәне алдынгы ысуллар белән, ягъни чишмәләрне агуламыйча, җирне рәнҗетмичә, газны әрәм итмичә, һаваны бозмыйча, табигатькә хилафлык кылмыйча гына алырга мөмкин иде бит.

Мәсьәләнең бүгенге көнгә турыдан-туры мөнәсәбәте бар: ярты гасыр вакыт үтте, без гыйбрәт алдыкмы, алга киттекме, хуҗаларча эш итәргә өйрәндекме? Иң аянычлысы: ачы тәҗрибәдән сабак ала белмәдек, ялгышларны төзәтмәдек, ваемсыз булдык.

Әсәрнең икенче бүлеге әүвәлгерәк чордан — Идел-Урал буйларында җир мае эзләү тарихыннан башланып китә. Тарих — бик кызыклы төшенчә, аның законнары бер кеше гомере белән генә үлчәнә алмый, бер кеше күңеленә генә сыеп бетми. Җир мае Кәлиматтә табылганчы өч гасырлык эзләнүләрдә әллә никадәр акыл көче сарыф ителгән, тау чаклы язма мирас җыелган. Җир мае, үзе артыннан ияртеп, кешеләрне дә туган йортларыннан читкә алып киткән, әллә кайларга тараткан.

Көбәшнекеләр күршесенә — үз нигезләренә — нефть чыгаруның тәҗрибәле остасы Лотфулла Дияров гаиләсе әйләнеп кайта. Бу ике гаилә шул дәрәҗәдә төрле холыклы, төрле язмышлы, әмма алар күршеләр генә түгел, шактый киеренке хис-кичерешләрдән соң туганлашып та китәләр; бу ике нәселне тормышны дәвам иттерүчеләр — балалар, гаиләләрнең бөтенлеге, иминлеге берләштерә. Фәйрүзә белән Булат образлары әсәрдә табигый, шул ук вакытта гадәти үк булмаган шәхесләр итеп тасвирланганнар; аларга карата күңелдә җылы

хис уяна, бәхетле була күрсеннәр дигән теләк туа. «Тансыгы сәке йөзлегенә ябышып, үрмәләп йөрер хәлгә җиткәч, Фәйрүзә колхоз эшенә чыкты: ат җигеп көлтә кертте, станцага задание бодае ташыды, өч җәпле агач сәнәк белән кырда эскерт куйды. Бер селтәнүдә мунча түбәсе хәтле итеп күтәреп алган салам чүмәләсенә хәтта күпне күргән авыл картлары да тел шартлатып тордылар:

— Җеннәре эшләтәдер бу дуамалны!»

Иске Кәлимәт янында яңа шәһәр төзелә башлагач, Фәйрүзә шундый ук тәвәккәллек белән яңа һөнәр үзләштерә, оператор булып китә. Эштә дә, тормышта да ирләрчә батыр, беркадәр тупасрак та күренгән Фәйрүзә чынлыкта — нечкә күңелле, кешеләрне кызгана торган шәфкатьле кеше. Йөзлекәй карчык ялгыз калгач, Фәйрүзә аның янына күченеп килә, аны тәрбияләп тора. Йортны ташлап чыгып киткәне өчен, әти-әнисе аны баласы дип санамасалар да, ул авыру әнисенә дә, карт әтисенә дә мәрхәмәтле булып кала.

«Хәзинә» романының төп вакыйгалары Кәлимәт авылында туып үскән һәм шунда нефть чыгаруның осталары булып җиткән Арслан Гобәйдуллин һәм Кәрим Тимбиков образларына бәйле.

Арслан — Бөек Ватан сугышында катнашкан, партизаннар белән утлар-сулар кичкән, разведкада чыныккан кеше. Автор аның баһадирларныкыдай көчле, алыпныкыдай зур гәүдәсенә ярашып торган сабырлыгын, тыныч характерын сокланып тасвирлый. Арсланның беренче эчкерсез мәхәббәте, яшьлекнең иң матур мизгелләре безне дә дулкынландыра. «Керфек очлары югары таба бөгелеп, күзләре сагыш бөркеп торган сылу кыз булып үсеп килә иде Мөнәвәрә, һәм бу озын керфекләр бер сирпелеп китсәләр, тирә-якта җил кузгалыр төсле тоела иде». Кәлимәт мәктәбендә икәү бергә укып йөргән чакта уяна хисләр. «Мөнәвәрә — Арслан» дип ике сүз чигелгән кулъяулык шаһит була бу хисләрнең нәфислегенә. «Дөньяда уналты ел гомер кичереп, ул беренче мәртәбә каушап калуын тойды, куллары дерелдәвен, күз аллары әлҗе-мөлҗе килүен сизде. Бу шул микәнни инде? Кешеләрне йокысыз калдырган, газапларга дучар иткән хиснең башлануы шушы микәнни?.. Ничәмә еллар узган инде ул көннәргә. Ничәмә көз салкын яңгырлары белән юып ташларга теләгән ул истәлекне, ничәмә кыш аяусыз бураннары белән күмеп китмәкче булган — булдыра алмаган».

Арслан күңелендә әнә шундый газаплы мәхәббәт яши. Мөнәвәрәне оныта алмый ул. Донбасста берәр ел эшләгәч, Кәлиматкә кайтырга, матур итеп киенеп кайтырга, Мөнәвәрәгә яулыкның чәчәклесен, күз явын ала торганын бүләк итәргә хыялланган, күңеленә беркетеп куйган иде ул. Әмма сугыш аны урманнар эченә, партизан учаклары янына алып кереп китте. Сугыш беткәннән соң, ике ел армия хезмәтен үтте. Кәлиматкә ул, киң күкрәкле партизан-солдат булып, дөнья күргән кеше булып кайтты. Яшьләрнең аңа багышлап җырлаган җырлары аның күңелен айкап алды: Мөнәвәрә кияүгә чыккан иде. Үпкәләргә хакы бар идеме аның?Алар бит вәгъдә бирешмәделәр, алар бер-берсен яратулары турында хәтта телдән дә әйтмәделәр. Кияүгә чыккан икән, бәхетле булсын!

Әмма йөрәк барыбер сыкрый, хисләрне салкын-сабыр акыл гына җиңә алмый икән. Арслан күңелендә бу хисләр Мөнәвәрәне күргән саен кабынып китә. Мөнәвәрәнең Кәрим белән бәхетле түгел икәнен белү бу сагышны тагын да көчәйтә. Менә шундый сүнми-сүрелми һәм хәл итеп тә булмый торган каршылыклар да бар әле дөньяда — кеше күңеле дигән гаҗәеп серле дөньяда.

Арслан күңеленә тагын бер сагыш килеп урала: Кәлимәт үзгәрә. «Машина Кәлимәт юлына борылгач, Арслан кара кучкыл булып, туктаусыз машина астына кереп барган асфальттан күзен алмады. Каршыга унар тонналы гигант машиналар очрап, үкереп-үкереп уздылар. Аларга әрдәнәләп төялгән корыч торбалар, машина кисәкләре, өем-өем тимерләр, берберләренә бәрелеп, чыңлап, бу якларда башланган зур тормыш турында үз телләрендә хәбәр әйтеп киттеләр». Аны утыртып кайткан шофер егет: «Биш елда йорт кына түгел, шәһәр салып була!» — ди. Әйтәсе дә юк, тизлек заманы, машиналар заманы. Әнә басуларны да трактор табаннары ермачлап, актарып бетергән. Кәлиматкә сугыштан соң беренче мәртәбә кайтканда да ул күңеленә юаныч эзләп су буена төшкән иде, «йөрәген үткен пәке белән сызып алгандай булды: шомырт куаклары тапталган, сынып, гарипләнеп беткән. Исән калганнарының да ботаклары, уттан чыккан кисәү кебек, кап-кара булып торалар, аларга куе кара деге сыланган иде...

Кешеләр, еллар узгач, бәлки, монда икенче бер матурлык ясарлар. Ул инде чын табигый матурлык булмас, газоннар, декоратив агачлар рәвешендәге геометрик матурлык булыр. Ләкин ничек кенә булмасын, кадерле әйберең югалту, гәрчә

алар урынына башкасы, матуррагы килә торган булса да, барыбер авыр икән...»

Бу шулай ук — бер хакыйкать, чишелми торган конфликт. Тормышның зур тизлек белән алга баруы, күз алдында яңа шәһәрләр калкып чыгу, әлбәттә, сокландыра, аеруча яшьләрне һәм шул яңарышны үз куллары белән тудырган кешеләрне рухландыра. Ләкин яңарыш янында ук югалтулар да тора. Читтән караганда хәзер искелек булып, гузган һәм югалырга тиеш кебек күренгән нәрсәләр кешеләргә гомер буена юаныч биргән, кемнәрнеңдер яшәү максаты булган.

Нәкъ менә шуңа күрә дә кырыс табигатьле, хатыны Мәгыйшәгә, үзенең балаларына карата да шактый мәрхәмәтсез күренгән Шәвәли картның кичерешләре табигый һәм аңлаешлы, аның сүзләрендә дә кире кагып булмаслык дөреслек бар: «Замана хәзер яшьләрнеке!.. Без үләсе, яшьләргә каласы дөнья. Гомер-гомергә шулай килгән... Көч куймадым, тир түкмәдем дип зарланыр хәлем юк. Көч куйдым, ташның авырын күтәрдем. Әмма ләкин хәзинәне таба алмадым...

Менә хәзерге заман яшьләре аның хәйләсен дә белделәр, ташын күтәреп, хәзинәсен дә чыгара башладылар. Тик менә минем күңелемә бер сорау галәмәте һич кенә дә тынгы бирмичә кыймылдап тора: ул хәзинә, ягъни мәсәлән, безгә нәрсә бирәчәк соң?» Арслан аңа нефть алып киләчәк яңалыкларны ышандырырлык итеп санап чыга. Бу ягы белән ризалашса да, Шәвәли картның картлык көнендә балаларын үз янында яшәтәсе, алар белән горурланасы, нигезенә аларны хуҗа итеп калдырасы килә. Аның бу теләге — гомеренең, куйган тырышлыкларының нәтиҗәсен күрәсе килүе — бик табигый. Өлкән улы белән кызы аның бу хыялын аңламыйлар, Арслан: «Нәрсә син, әти?! Нишлим мин йорт белән, миңа казённый квартир да бетмәгән», — ди; өйләнеп, уңайлы квартирда, йорт мәшәкатьләреннән азат булып яши. Бу сөйләшү вакытында әле мәктәп укучысы гына булган кече малае Габделхәй, Мәскәүдә укып кайтканнан соң, абыйсын шаккатырып, әтисен чиксез куандырып, нигезгә төпләнә һәм инде Арсланнар буынына — Татарстанның беренче буын нефтьчеләренә алмашка киләчәк буын вәкиле булып, шундый сүзләр әйтә: «...мин төп йортка ял итәр өчен генә кайтмыйм. Кайтсам, Кәлиматтә үз йортымны салып, бакча үстереп, үзем теләгәнчә яшәр өчен кайтам... Кемдер минем тормышымны бәхетле итәр, кемдер миңа рәхәтлек алып килер дип ышанмыйм. Бәхетне мин

үз кулларым белән табарга, үз тормышымны үзем корырга тиеш».

Бик озак еллар совет кешеләрен чын бәхет бары тик җәмгыять хакына үз шәхси тормышыңны корбан итеп, үзеңне тулысынча шул максатка буйсындырып яшәгәндә генә була ала дип тәрбияләделәр. Бу фикернең үзендә хаклык бар, әлбәттә, кешеләргә файда китереп, үз көчеңне тоеп, җәмгыять тормышының алгы сафында бару кешене шәхес итеп тәрбияли, үзеңә таләпчән булырга, туктаусыз алга барырга дәртләндереп-рухландырып тора. Кайсы чорда да шундый иҗтимагый актив, җаваплылыкны үзе теләп үз җилкәләренә алучылар кирәк. Җәмгыятьнең йөзен шулар билгели, чорның, заманның геройлары дип без шундый кешеләрне — башкаларның үзенә ышануларын тоеп яшәгән, танылган шәхесләрне атыйбыз, алардан үрнәк алабыз. Киләчәккә өмет-ышаныч утын шундый кешеләр кабыза һәм шундый кайнар йөрәкле, көчле ихтыярлы кешеләр саклый. «Хәзинә» романының күп геройлары — Арслан Гобәйдуллин, Лотфулла һәм Булат Дияров, Кәрим Тимбиков — шундый кешеләр.

Ләкин хикмәт шунда: безгә социалистик җәмгыять бары тик шундый кешеләрдән генә, бары тик шул дәрәҗәдәге фидакярлектән генә торырга тиеш дип тукып килделәр. Ниһаять, 80 нче елларның йомшак җилләре иркенләп сулыш алырга, үзебез теләгәнчә уйларга, сөйләргә һәм яшәргә мөмкинлек бирде. Бүгенге тормышта туган мондый яңарышны күңелләрдә җыелып килгән хисләр, уй-фикерләр күптән башлап җибәргән икән. Элекке чорларда ук кешеләр рухи хөрлеккә, мөстәкыйльлеккә омтылып яшәгәннәр. Игътибар итегез: «Хәзинә» һәм аның дәвамы булган «Хуҗалар» 1958—1973 елларда язылганнар. Романнарның төп герое Арслан энесенең фикерләрен берничек тә кабул итә алмый, үз йортында, үз рәхәтең өчен генә яшәүне ул күз алдына да китерә алмый: «Синең кебек тәти егетләр күп килде инде монда, берсе дә дөньяның агышын үзгәртә алмады...» — ди. Шулай да ул энесенең бәйсезлеген, үзенә нык ышанып яшәвен тоя, үзеннән соң килгән буынның яшьлеккә хас булганча күктә йөзеп, хыял дөньясында гына яшәмичә, җирдә үзләре теләгәнчә, кемдер кушканча гына түгел, үзләренә хуҗа булып яшәргә җыенганнарын һәм шулай яшәргә сәләтле икәннәрен танымыйча да кала алмый: «Беренче тапкыр ул сүзләренең көчсез һәм буш булуын, җавапсыз калмас өчен генә әйтелгәнен аңлап тынды. Аның энесенә әйтерлек саллы дәлиле юк иде».

Әдәби әсәрләр тормышның кайсы якка үзгәрә баруын дистә еллар алдан сиземләп, талант көче белән тоеп язылып килделәр. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романында Йөзлекәй карчык, Шәвәли карт сүзләрендәге борчылу, икеләнүләренең хаклы икәнлеген «Хуҗалар» романында Габделхәй, Саша, Тансык кебек яшьләр исбатлый башлыйлар.

Сюжет җебенең менә шушы конфликтка — җәмгыять тормышына килгән яңалык белән кешенең үз шәхси тормышын, үз дөньясын төзергә омтылыш арасындагы каршылыкка корылган өлеше турында нәтиҗә ясап әйтсәк, ягъни аны әсәрнең идеясе дип билгеләргә теләсәк, бер кызыклы фикер туа: без нигәдер каршылыклы күренешләрнең әле бер ягын, әле икенче ягын гына күреп яшибез кебек. Я уңай, я тискәре генә булырга тиеш, янәсе. Социалистик җәмгыять дигән төшенчәне дә без җитмеш ел буена барлык кешеләрнең гомуми максатка, уртак идеалларга хезмәт итүе дип аңлап, шуңа ышанып яшәп килдек. Ә хәзер, Советлар Союзы таркалу белән икенче чиккә ташланып, бу уртак идеаллар да җимерелде, юкка чыкты дип яши башладык. Чагыштырып, ашыкмыйча фикер йөртеп карыйк әле, каршылыкларның табигый күренеш икәнлеген ачык аңлап була.

Гомерен яраткан һөнәренә багышлап, шуның белән бик хаклы рәвештә горурланып яшәгән Лотфулла ага Дияров; үзенең намусы кушканча, үзе инанганча хезмәт иткән Нәҗип Корбанов; эш мәнфәгатьләрен кайгыртканда кешеләрне дә яратып, дәрәҗәсенә, хезмәт урынына карап түгел, аларны куйган хезмәтенә карап хөрмәт итә белгән Митрофан Зозуля; бик коры-кырыс характерлы, максатына барганда чама чиген дә узып китә торган җитәкче Кожанов — чын мәгънәсендә җәмгыятькә хезмәт итүчеләр. Аларны үз һөнәрләренә бирелгәнлек, үз эшләренең осталары булу берләштерә. Бүген дә ул шулай: без социалистик җәмгыятькә мөнәсәбәтебезне үзгәрткән чорда да югары дәрәҗәдәге профессионализм — иң кирәкле сыйфатларның берсе. Ләкин шундый кешеләр белән янәшә үзенең төп бурычы — иренең язмышын уртаклашып, мәшәкатьле тормышын җиңеләйтеп, балалар тәрбияләп яшәү дип санаган гаҗәеп сөйкемле Тәүфика апа да, үзе теләгәнчә яшәргә ихтыяр көче, кыюлыгы җитмәгән, әмма табигате, күңел байлыгы белән гүзәл булган Мөнәвәрә дә, юл йөрү романтикасы белән яшәүче, һаман үз урынын эзләп йөрүче Атнабай да яши. Аларның да үз хаклары, үз дөреслекләре бар. Алар

тормышка төрлечә карыйлар, матурлык һәм кыйммәтләрне үзләренчә бәялиләр, тормышның кызыклы, мавыктыргыч булуы да, байлыгы да шушы төрлелектә. Мондый төр каршылыкны без табигый кабул итәбез, романда бу геройлар автор тарафыннан бердәй ихтирам белән тасвирланганнар.

Шул ук вакытта романда бары бер якның җиңүе, бер якның хаклы икәнлеген раслау белән генә хәл ителә ала торган кискен конфликт та бар. Ул Кәрим Тимбиков образы белән бәйле һәм романда тасвирланган чор — 50 нче еллар өчен гаять хас булган конфликт.

Кәрим башта Лотфулла Дияров бригадасында эшли; сәләтле бу егетне мастер итеп күтәрәләр, һәм ул, үзенә бригада туплап, алны-ялны белмичә, атналар буе буровойдан кайтып кермичә эшли башлый. «Беренче вахтаны тыенкы гына озатып җибәреп, икенчесен каршылады. Арыган кешеләр өйләренә киттеләр. Алар, кайту белән, кайнар аш ашыйлар, кайнар чәй эчәләр, чишенеп бер рәхәтләнеп йоклыйлар инде. Ә ул, алардан битәр арыган, алардан да күбрәк дулкынланган кеше, мастер дигән исеме булганга күрә, буровойда калды... Бирешергә ярамый иде. Юк, ярамый, ярамый. Ул бит мастер, аңа кешеләр язмышы тапшырылган». Мондый җаваплылык хисе кешене матурлый, аның тормышын мәгънәле итә, авырлыкны җиңәрлек көч бирә.

Кәримне зур рекордларга әзерләгән, гадел булмаган рәвештә башка бригадалар өлешенә кереп, аңа алар хисабына уңай шартлар тудырып килгән кеше — трест җитәкчесе Николай Николаевич Кожанов. Аңа дан кирәк, трестның данын бөтен илгә шаулатырга кирәк. «Кирәк» дигән сүз урынлы да түгел, бәлки кызыгу, мавыгу дип әйтү дөресрәк булыр. Беренче карашка гына гөнаһсыз күренгән бу теләк гаделлекне боза, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ямьсезли, күңелләргә кара яга. Бу үзгәрешне күреп торган Лотфулла агай, Митрофан Зозуля Кожановны кисәтеп тә карыйлар, ләкин бер якка гына салулап кереп киткән хәрәкәтне туктата алмыйлар. Кәрим үзен чикләнмәгән хокуклар белән файдаланырга лаек дип санап ялгыша, бер-бер артлы ялгышлар ясый. Иң яманы — Кәримнең кеше буларак үзгәрүендә, шуны сиземләмәвендә, үз вакытында туктый алмавында. Буровойда үзен хуҗа дип санап, ул берәү белән дә исәпләшми башлый, нәтиҗәдә Арсланның аягы яралана, тыелган алымнар белән бораулау нәтиҗәсендә коточкыч авария килеп чыга, Кәрим үзе дә һәлак була.

Нефть — җир мае, ягъни күп байлык бирә торган хәзинә генә түгел ул. «Кара алтын» дигән матур исем белән аталса да, аның әле башка төрле һәм бик мәкерле яклары да бар икән. Нефть — ул зур техника, меңнәрчә метр тирәнлекләргә төшеп бораулау дигән сүз. Шундый куәтле көчләр белән идарә итү өчен сабырлык, акыл, белем кирәк. Җирдән аерылып кинәт күтәрелеп китү Кәримнең башын әйләндерә һәм ул, эчке әзерлеге, зиһен ныклыгы җитмәгәнгә күрә, шул «биеклек»тән җимерелеп төшә.

Бу конфликт Арслан белән Кәрим арасындагы шәхси мөнәсәбәтләргә генә сыешып калмый. Бу — нәкъ менә социалистик системаның бүген без ачык күреп, аңлап кире каккан сыйфаты да, «Хәзинә» исеме нәкъ шушы конфликт белән бәйләнештә яңа мәгънәләре белән ачылып китә. Беренчедән, хәзинә, әлбәттә, җир астындагы кешеләрдән яшеренеп яткан байлык. Икенчедән, тормышта барлыкка килгән яңарыш, үсеш. Өченчедән, Татарстан өчен яңа ачышлар ясаучы белгечләр, фән тармакларын үстерүче кешеләр, аларның яшәү принциплары, характерлары, психологиясе. Нефть, шул рәвешле, кешеләрнең ныклыгын һәрьяклап сыный торган, үзенә аерым катлаулы бер дөнья булып күз алдына килеп баса.

Сораулар һәм биремнәр

1. Халык язучысы Гариф Ахунов «Хәзинә» романында нинди идея-эстетик максатлар куя?

2. Әсәрнең әдәби сәнгатьлелек дәрәҗәсен ничегрәк билгеләр идегез?

3. Язучы тудырган нинди образлар сезнең күңелгә нык кереп калды? Аларның тәэсир итү көче нидән гыйбарәт?

4. Хезмәттә шәхси һәм күмәклек мәнфәгатьләренә сезнең карашыгыз нинди?

5. Кешенең шәхси иреге мәсьәләсе хакында бәхәс үткәрегез. Бу теманың татар әдәбиятында ничек тасвирлануына мисаллар китерегез.

6. Гариф Ахуновның иҗат колачы киң булу аның нинди сыйфатларына бәйле дип карыйсыз? «Әдип һәм заман» дигән темага үз фикерләрегезне дәлилләп күрсәтегез.

Әдәбият теориясе. Әдәбият тормыш-чынбарлыкны сурәтләү ярдәмендә тасвирлый. Иң кечкенә күләмле әсәрдән, әйтик, берничә юллык шигырьдән башлап, зур-зур күләмле роман-

нарны кабат искә төшереп карыйк: күп гасырлар буена баргән вакыйгалар, чиксез күп кешеләр язмышлары тупланган аларда. Бер әсәрне укып чыгу әллә ничә кеше гомере кадәр тормыш гыйлеме бирә, безне рухи сыйфатлар турында уйландыра, үрнәк һәм гыйбрәтләр ярдәмендә тәрбияли, яхшы белән яманны аерырга өйрәтә. Тормыштагы кебек үк, чын сәнгать әсәрендә дә яхшылык белән явызлык бер йомгак булып үрелгән, бер төен булып бәйләнгән. Шуны аңлап, бу төеннәрне чишәргә, фаҗигаләрсез, мөмкин кадәр аз югалтулар белән каршылыкларны хәл итәргә өйрәнү — сәнгать әсәре бирә торган тәрбия. Үзара тыгыз бәйләнгән сыйфат-максатларның икенчесе — әдәбият безне дулкынландыра, уйланырга мәҗбүр итә.

Әдәбиятны һәр чор, һәр җәмгыять үзенчә аңлатып, үзенә яраклаштырып тудыра. Язучылар күмәкләшеп иҗат итмиләр, һәрберсенең үз «иҗат лабораториясе» бар. Әмма алар, берберсен тулыландырып, бер-берсен дәвам итеп язалар. Берсе күтәргән проблеманы, әгәр ул әһәмиятле, кызыклы булса, җыйнаулашып күтәреп алалар. Мәсәлән, Ватан сугышы чоры әдәбияты бу яктан бик характерлы — максат бер: басып алучыларга каршы изге көрәшкә халыкны туплау, һәр кешенең җанына барып җитәрлек сүзләр табу, туган илнең бөеклеге, кадере турында сөйләү.

Әдәбиятның иҗтимагый вазифасы дигәндә, без конкрет вакыйгалар һәм кеше язмышлары, характерлары мисалында җәмгыятьнең төп сыйфатлары гәүдәләнешен күздә тотабыз. Мәсәлән, Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы язылган чор социалистик җәмгыять, зур максатлар белән рухланып, зур эшләр башкарырга сәләтле, гомуми идеалларга ихлас ышанып яшәүче кешеләрне тудырган заман булды. Ләкин бер үк вакытта шушы гомуми максатлар хакына кешенең үз хокуклары, кичерешләре дә корбан ителгән, характерлары имгәтелгән чор да иде дигән нәтиҗәгә киләбез. Чор кешеләрнең яшәү шартлары, бәхетле яки бәхетсез булулары белән билгеләнә, мондый катлаулы һәм каршылыклы язмышлар картинасын аерым бер әсәр генә тудырып бетерә алмый, шуңа күрә чор әдәбиятының уртак максаты һәм нәтиҗәләре турында сүз бара.

Нурихан Фәттах

(1928—2004)

«Яшәү өчен, исән калу өчен кеше бертуктаусыз көрәш алып барган. Ачлык белән дә, табигать китергән бәла-казалар белән дә көрәшергә туры килгән аңа. Тик шулай да күбесенчә кеше бер-берсенә каршы көрәшкән... Ни генә булмасын, беркайчан да җирдә оҗмах булмаган.

Ләкин шулай да, бер-берсенә дошманлык тойгысына караганда, яшәргә омтылыш кешедә һәрвакыт көчлерәк булган».

Зур сәнгать әсәрләре бу хакыйкатьне раслап, исбатлап тора.

60 нчы елларда әдәбиятта яңа омтылышлар, ачышлар, зур мәйданнарны яулап алулар башланды. Иҗат көчләре үз алларында торган киртәләрне үтеп чыккан язгы ташкынны хәтерләттеләр. Аларның фикерләре, карашлары, чынбарлыкка мөнәсәбәтләре рәсми идеология кысаларын җимерә башлады. Нәкъ менә шул чорда рәсми тарих фәненең декларацияләренә, дистә еллар буе калыпланып килгән өйрәтмәләренә каршы чыккан, тарихи дөреслекне үҗәт бер сабырлык һәм иҗади дәрт белән өйрәнергә керешкән язучы Нурихан Фәттах булды.

«Төрки халыклар тарихын башлыча төрки булмаган галимнәр язган һәм яза. Безгә карата булган дошманлык тойгысы аларның канына сеңгән. Әле булса алар безнең ата-бабаларыбызның батырлыгын, бөеклеген оныта алмыйлар һәм бүген — без инде бик нык түбәнәйтелгән, артта калырга мәҗбүр ителгән бер вакытта, безнең хәзерге халәтне ата-бабалар чорына күчереп, тумыштан ук безне бернинди иҗатка сәләтсез кыргыйлар итеп күрсәтергә тырышалар»,— дип язды

ул, кайнарланып. Бәлки, нәкъ шул кайнарлыгы, рәсми фикерләргә ябышып ятучы үз галимнәребезгә дә үпкә белдерүе зур дулкынны кузгаткандыр: ниһаять, хәзер инде без СССР тарихын, Татарстан тарихын түгел, ә зур фән булып формалашып килүче татар халкы тарихын өйрәнәбез, бүгенге чынбарлыкка актив мөнәсәбәт белдерәбез. Халкыбыз тарихына, күңел күзе һәм акыл җитәрлек ерак гасырларга мөрәҗәгать итәбез, кызыксынабыз икән, бу — милли аңыбыз уяну, үзебезнең шәхси горурлыгыбызны тою дигән сүз.

8 нче сыйныфта Нурихан Фәттахның тормыш һәм иҗат юлы белән таныша башлаган һәм аның «Итил суы ака торур» дигән тарихи романын өйрәнгән идек. Һәр иҗат кешесенә хас булганча, аның тормыш юлын әсәрләреннән аерып кую мөмкин түгел. Нурихан Фәттах үзенчәлекле шәхес, күп язучылардан аермалы буларак, көндәлек тормыш ваклыкларында, җыелыш-утырышларда, юбилей-бәйрәмнәрендә дә катнашырга, күңел күтәреп йөрергә бик яратмый; мәгарәгә кереп бикләнгән Әбүгалисина кебек, үз иҗат дөньясында, китаплар дәрьясында яшәргә тырыша; фәндә дә һәм әдәбиятта-сәнгатьтә дә күренгәләп ала торган ялтыравык фикерләр, модаларга исе китмичә, акыл иясенә хас тынычлык белән яза бирә. Дәлилле итеп, кире кагып булмаслык дөреслеккә — тарихның үзенә таянып яза.

«Итил суы ака торур» романына нигез итеп, ул X гасыр башында — 922 елда — Багдадтан Идел буе болгарларына килгән илчелек вәкиле Ибне Фадланның юлъязмаларын файдалана. Берничә гасырга сузылган Болгар чорының бер дәверен, Болгарның дәүләт булып оешып җитүен, рәсми рәвештә яңа бердәм дин — ислам динен кабул итү фактын үзәккә куеп тасвирлый. Дөрес, без романның беренче өлешен — акбүреләр ыруына, аның язмышына бәйле өлешен генә анализлаган идек. Төп образ булган — тарихи шәхес Алмыш хан, аңа бәйле вакыйгалар белән сез, анализлауны дәвам итеп, мөстәкыйль рәвештә танышырга тиеш идегез. Хәер, әдәби әсәргә бәйләп, «тиеш» сүзен куллану урынлы да түгел, чөнки һәр әдәби әсәр шундый бер дөнья ки, анда укучы үзе кунак (кызыксынып танышып йөри), үзе хуҗа (нәтиҗәләр ясый, мөнәсәбәтен белдерә).

«Сызгыра торган уклар»

(1977—1985)

Менә без Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» дигән зур тарихи романын өйрәнә башлыйбыз. Зур дип әйтү әсәрнең һәр ягына карый: ул — ике китаптан торган күләмле әсәр; 1977—1985 еллар дәвамында язылa; моңа кадәр бер язучы да үтеп керә алмаган ерак тарих — безнең эрага кадәрге III гасыр гәүдәләнә. Роман, үз жанрына хас булганча, күптармаклы һәм гаҗәеп мавыктыргыч вакыйгалар хәрәкәтенә корылган. Гадәттән тыш язмышлар, хыялны уята торган гореф-гадәтләр, рухны ныгыта торган кырыс та, романтик та заман, яшәү рәвеше, тормыш кануннары — әсәр искиткеч хәзинәне үзенә җыйган сихри, серле дөнья булып балкып тора. Аның эчтәлеген дә бер тында сөйләп чыгу мөмкин түгел, сюжет җепләре күз камаштырырлык бизәкләр, борылышлар ясый.

Иң башта романның җирлеген, нигез ташларын тәшкил иткән тарихи җирлеккә күзәтү ясыйк. Беренчедән, автор өйрәнгән чыганаклар бик кызыклы. Ул романның Татарстан китап нәшриятында 1991 елда чыккан икенче басмасында «Сөннәр турында тарихи белешмә» бирә, бик җентекләп тарихи документларга күзәтү ясый, аңлаешлы, эзлекле итеп төрки тарихына кагылган мәгълүматларны сөйләп чыга. «Күчмә халыкларның тарихы бик еракка һәм тирәнгә сузыла. Вакыт һәм территория ягыннан күчмәләр тарихын колачлап бетерерлек түгел. Ерак Көнчыгыштан алып Дунайгача булган иксез-чиксез җирләрдә төрле чорда, төрле төбәктә төрле кабиләләрнең дәүләтләре, дәүләт берләшмәләре булган. Алар бер, ике, өч йөз еллар яшәгәннәр дә, күршеләре белән сугышта җиңелеп, тарих арбасыннан төшеп калганнар. Ләкин шул ук вакытта берәүләр урынына икенчеләре күтәрелеп чыккан. Шул рәвешчә, даланың төрле ягында әле бер исемдәге, әле икенче исемдәге дәүләтләр, берләшмәләр хакимлек иткән».

Нурихан Фәттах шул күчмә дәүләтләрнең берсе булган сөннәр тормышын, сөн тарихын язарга була, эзләнүләр аны Борынгы Кытай елъязмачыларының хезмәтләренә китереп чыгара, һәм ул үзара тыгыз бәйләнгән, янәшә яшәгән ике халык, ике дәүләт тарихын чагыштырып өйрәнеп чыга. Дөрес, сөннәр турындагы мәгълүматлар тулы да, объектив та түгел. Язучыга өстәмә чыганаклар өйрәнергә, чагыштырып нәтиҗәләр ясарга, уйланырга кирәк була. Шулай да Кытай чыганакларында

китерелгән тарихи фактлар бик кызыклы: «Сөннәр Борынгы Кытай дәүләте барлыкка килгәндә үк булганнар, күршеләре белән аралашып, шактый актив һәм шау-шулы тормыш алып барганнар; тарихи истәлекләрдә сөннәрнең сугышчан, горур, мөстәкыйль һәм башбирмәс халык булуы турында әйтелә; аларны биш император да үзләренең хезмәтчеләре итә алмаган, өч династиягә нигез салучылар да йөгәнли алмаган; чын мәгънәсендә Урта җир дәүләтенә тиң көчле көндәшләр һәм дөньяның өч ягында алар кебек башка беркем юк».

«Сызгыра торган уклар» романында язучы хыялы уйлап тапкан түгел, ә тарихта үзләре турында шундый истәлекләр калдырган сөннәр — бүгенге төркиләрнең, шул исәптән татарларның да, борынгы бабалары турында сүз бара. Сюжет та реаль шәхес — сөннәр патшасы Тоумань һәм аның улы белән булган хәлләргә нигезләнгән. «Тарихи белешмә»дә автор ул тарихи вакыйганы сөйләп тә чыга. Тик ул исемнәрне һәм вакыйгаларның тарихи исбатланып бетмәгән яки әсәрнең сәнгатьчә логикасына туры килмәгән урыннарын, борылышларын үзгәртә.

Тарихи чыганаклар никадәр әһәмиятле булсалар да, алар әле аерым фактлардан гына торалар. Күптән үткән һәм күз алдына китерүе дә кыен булган тормышны җанлы итеп, кешеләре, йорт-җирләре, хисапсыз күп мал-мөлкәте, әйберләре белән тасвирлау өчен гаять зур осталык, хыял көче кирәк. Әсәрнең әһәмияте, кыйммәте һәм матурлыгы турында нәтиҗәләр ясаганчы, беркадәр уйланып, аның серен аңларга тырышып карыйк.

Романның вакыйгалар катламына игътибар итик. Күп санлы персонажлар язмышына бәйле рәвештә алар күп эпизодларга бүленеп, әле берсенә, әле икенчесенә күчеп тасвирланалар. Шулай да төп сюжет сызыгы ике кеше: Сөн дәүләтенең патшасы — Туман тархан һәм аның тәхеткә утырачак улы — тәгин углан Албуга язмышларына һәм аларның үзара мөнәсәбәтләренә бәйле. Бу мөнәсәбәтләрнең теге яки бу якка үзгәреп торуы, ни өчен, нинди сәбәпләр һәм кемнәр йогынтысында үзгәрүе, ничек хәл ителүе әсәрнең эчтәлеген тәшкил итә. Төп проблема да шушы мөнәсәбәтләр, язмышларда гәүдәләнә һәм әсәрнең төп геройлары да алар — аталы-уллы ике кеше.

Романны укып чыккач, гаҗәпләнеп уйга каласың: халык җырларыннан, әкиятләреннән башлап, бик күп әдәби

әсәрләрдә, башка сәнгать әсәрләрендә тормышның тоткасы, дәвамлылыгы, гаделлеге һәм иминлеге шушы күчешкә, ата белән бала (иң беренче чиратта ир бала) мөнәсәбәтләренә бәйләп аңлатыла. Бу — тормышның, яшәешнең төп закончалыкларыннан берсе булган күренештер, шуңа күрә иң кулай сәнгать чарасыдыр да. «Атадан бала яшь калса...», җилкәләргә тигез төшәргә тиешле авырлык балага кала. Халык моны гап-гади итеп гомер буе җырлап яши. Элек тә шулай булган, хәзер дә. Әмма бу хәлнең мең-миллион төрле вариантлары бар. Тарихта да, тормышның гадәти барышында да, сәнгатьтә дә (мәсәлән, Шекспирның Гамлетыннан башлап).

Җир Кояш тирәсендә бер әйләнеп чыккан саен, тормыш үзгәрә тора, хәтта аннан да кызурак тизлек белән үзгәрә. Безнең эрага кадәрге мең еллар белән генә түгел, дистә еллар, берничә еллар белән бу үзгәрешләрнең адымнарын, тизлеген санап торабыз. Ә менә бу иң гади һәм иң катлаулы бәйләнеш — ата белән бала мөнәсәбәте — Җирнең әйләнү законы кебек кабатлана да тора: һәр тарихта, һәр халыкта, һәр гаиләдә. Бүген дә шулай.

«Сызгыра торган уклар» романында бу мөнәсәбәткә бөтен сөн халкының язмышы бәйләп тасвирлана, хәтта сөннәрнеке генә түгел, алар яу чапкан чиннар язмышына да барып кагыла.

Роман Албуганың әтисе Туман тархан урдасына килүе, сөенечле хәбәр алып килүе белән башлана: Атсыз (исемсез) күлне боз тоткан. «Атсыз күлдә беренче тапкыр боз күренүне сөннәр изгегә юрыйлар иде. Күлне боз тоту ул көз бетеп кыш башлануны белдерә иде. Кыш башлану белән исә бер үк төрле көндәлек тормышта күптән көтелгән үзгәрешләр, күңелле һәм тынгысыз мәшәкатьләр башланачак иде. Урдадан бер-ике чакрым ераклыкта урнашкан Атсыз күлне боз тоту белән, барыннан да элек, Сөн иленең башы Туман тархан беренче ауга чыгачак. Аннан соң корбан, җыен, мал-туарны барлау, сугым сугу башлана. Кыш буена эш җитәрлек сөн иренә! Шуңа күрә дә күлне боз тоту турында хәбәр алып килгән беренче кешегә тархан үз кулы белән бүләк бирә. Шуңа күрә дә ике бите уттай янып торган яшь тәгин углан шулай таң тишегеннән капка төбенә килеп җиткән, шуңа күрә дә ул куанычыннан нишләргә белми елмая иде».

Автор борынгылыкка хас салмаклык белән, ашыкмыйча, сүзләрне кабатлап, фикер җебен чигеп сөйли, сүзнең мәгънәсен үткәзеп, тәмен белеп сөйли. Без дә укыганда ашыкмыйбыз,

җөмләне берьюлы «кабып йотмыйбыз», һәр сүзне берәмләп «чүплибез», шулай укудан ләззәт алабыз.

Албуга тархан улы булса да, әтисе янына алай тиз генә, җиңел генә кереп китә алмый. Тәртип король сарайларындагыдан болайрак куелган. Иң башта кояш чыкканын көтәргә кирәк: тархан кояш чыккач кына торачак, шуннан алда аның йокысын бүләргә ярамый, әнә никадәр сакчылар урда әйләнәсендә дә, сарай әйләнәсендә дә аның тынычлыгын саклап торалар. Тагын бернәрсә игътибарны тарта: Кояшның җирдәге углы — Сөн иленең патшасы бөек тархан — һәр көн җир өстенә җәелгән ак йомшак киезгә ялан аяклары белән басып, югары үрләп килгән изге яктылыкка «Кояш әткәем, Кояш әнкәем!» дип эндәшеп, «Мине изгелегеңнән ташлама» дип дога кыла. Бу һәр көн шулай, елның кайсы вакыты булса да. Бу — изге бер йола, бозарга ярамый торган кагыйдә. Ирексездән сокланып куясың: үзенең күңелен Кояш белән бәйләп кую, Кояш мине саклый, мин аннан көч алам дип ышану, чынлап та, кеше рухын кояшка якынайтадыр.

Албуга Туман тарханның Ак өенә байтак җир үтеп бара. Урданы әйләндереп алган биек коймадан башлап, урда күренеше шулай ук җентекләп тасвирлана. Без дә, юлчыларга ияреп, көннең ничек ачыкланып килүен, өч божра булып, билгеле бер тәртиптә, һәрберсе үз урынын белеп, билгеле бер ераклыкта урнашкан төрле зурлыктагы киез өйләрне «күреп» барабыз. Безгә таныш булмаган, ләкин, ничектер, безнеке дә булган бу дөнья, яшәү рәвеше, күренешләр, әйберләр белән очрашу дулкынландыра. Инде югалды, мин күреп өлгергәнче үк юкка чыкты дип уйлаган моңлы бер матурлык, кадерле әйбер белән очрашкан кебек хис туа. Әле генә укыган күренешне тагын кире кайтып укыйсы, хәтердә калдырасы, ул күренеш янында озаккарак тукталасы килә.

Ниһаять, Албуганы, бер генә кагыйдәне дә бозмыйча, һәркем үти торган, үтәргә тиеш булган тәртип белән әтисе янына, ул торган йортка алып керәләр. «Ата кеше улын ике куллап, яратып күкрәгенә кысты, шуннан соң ул үз кулы белән углына кымыз бирде дә бүлдермичә аның эчкәнен карап торды». Икесенең дә һәр хәрәкәтендә — бер-берсен ярату, Албуганың әтисен тархан итеп олылау, аңа буйсынырга, аңа сыенырга әзер тору. Менә шундый табигый, һәр ата һәм бала арасында кабатланып торган мәңгелек җылылык, бары шушы ике кеше арасында гына була ала торган ярату.

Зур юллар — бер адымнан, зур фаҗигаләр бик юктан башлана. Албуганың кол кыз — тарханның яраткан кырнагы — Табылдыкка сокланып, «киек күргән аучы кебек сагаеп» карап торуын шәйләгәч, тархан кинәт кенә өлкән углына карата көнләшү һәм дошманлык хисен тоеп ала. Шулай итеп, хәвефле хәл туа. Ләкин ауда Албуга, искиткеч кыюлык һәм өлгерлек күрсәтеп, әтисен үлемнән коткарып калгач, чатнап куйган күңел үз урынына утыра, тархан, олы җанлылык күрсәтеп, улына кыз бүләк итә. Ләкин Табылдыкны түгел, ә Чин ягыннан качаклар тарханга бүләккә дип алып килгән гүзәл чин кызын. Әмма үзе, кызның гүзәллеген күреп, тынычлыгын югалта, ничек тә аны кире алу турында уйлый башлый. Кеше күңеленең, хәтта ул Олы тархан булса да, әнә нинди серле почмаклары, чоңгыллары бар. Никадәр кырыс, нык һәм никадәр зәгыйфь, көчсез була кеше. Үзеңне җиңү дип шул көчсезлегеңне үз вакытында аңлый белүне, күңелеңне кояшлы якка бора алуны әйтәбездер инде.

Шул хәлдән соң вакыйгалар шактый зур тизлек белән хәрәкәт итә башлый, чөнки әлеге кызлар мәсьәләсенә хәйлә-мәкергә осталыкта тиңе булмаган Исәнтәй һәм тарханның әнисе Ана-кам катнашып китә. Һәрберсенең үз исәбе, үз планы бар; икесе дә тарханга бик оста «капкыннар» куялар, гаҗәп оста итеп аның йомшак якларыннан файдаланалар. Тархан күргән куркыныч төшне дә Албуганың әнисе Күрекле бикәгә гомер буе дошманлык саклаган Ана-кам үзенә файдалы итеп юрый.

Ата белән углан арасына, шулай итеп, мәкер, хыянәт, алдан уйлап корылган хәйләләр килеп керә. Туман тарханның шуларны аңларга — акылы, тоярга сизгерлеге җитми. Ил башлыгы дәүләтен дә, Сөн иленә янаган куркынычны да, урдасындагы зур эшләрне дә ташлап, күңел ачуга бирелә. Чиннарның яшерен шымчысы булган, урыны ишек төбендә, дәрәҗәсе кол хәлендә йөргән Исәнтәй Туман тарханның иң якын кешесенә, киңәшчесенә әйләнә. Шулай итеп, Олы тархан — ил башы — тычкан тәбесенә эләккән юлбарыс хәлендә кала. Иң зур хатасын да Исәнтәй киңәше буенча эшли: әзерлексез килеш чиннарга каршы яу чаба, бу юлы үзе генә түгел, бөтен гаскәре белән чиннар корган тозакка килеп эләгә. Аз гына гаскәре белән үлемнән чак качып котыла, үзенең иксез-чиксез даласына кайтып егыла. Ләкин тыныч, аулак җирдә төн уздыру да Туман тархан өчен зур газапка әйләнә. «Янында кеше булганда ул үзен тынычрак сизде, һәм шулчакны, боздай кат-

кан күңелен җылытып, татлы истәлекләр, чибәр кызлар күз алдына килде. Шул ук вакытта ул алардан тизрәк арынырга тырышты. Шул чибәр кызлар аркасында шушы хәлгә төште түгелме соң ул? Юк, моннан соң аларны уйларга да ярамый. Кызлары да, башкалары да кирәкми. Дөмексен барысы да! Кайдадыр таулар артында, далада үзен куа килгән чиннардан гына түгел, кайчагында ул хәтта үз кешеләреннән дә — һәрбер теләген үтәргә әзер торган барлык якын кешеләреннән дә курка, шикләнә башлагандай булды. Курку, шикләнү генә түгел, ул алардан оялды да, ахрысы, бөтен илен-көнен, байлыгын туздырып, барысын да дошман аягы астына ташлап китүе өчен, үзенең менә монда башын саклап качып-яшеренеп ятуы өчен оялды һәм хурланды, ахрысы».

Туман тарханда Сөн иленең элекке куәтен кире кайтарырлык көч тә, теләк тә калмый. Әйтерсең гаепсез улына карата эшләгән явызлыклары өчен, ата да, Олы тархан да була белмәве, шуңа акылы, ныклыгы җитмәве өчен, Тәңресе аны — җирдәге улын җәзалый. Тархан, чынлап та, элекке дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Хәер, күпмедер вакыт үткәч, ул үз урдасын торгыза, ләкин гүзәл һәм мәкерле чин кызын үзе янына тәхеткә утырта, аннан туган яшь баланы тәгин углан дип игълан итә; баштагы ялгышын тагын кабатлап, хыянәт белән тугрылыкны, чын ихлас ярату белән ялагайлыкны, икейөзлелекне аера белмичә яши бирә. Аның урынына дәүләт белән куркак, булдыксыз кешеләр, мәкерле шымчы Исәнтәй идарә итә. Дәүләт өчен шуннан да зуррак фаҗига булуы мөмкин түгел. Тарих бу сабакны төрле чорда, төрле шәхесләр һәм дәүләтләр мисалында кабатлап тора. Бу очракта без ерак тарихны гына түгел, якындагы соңгы йөз елны, үзебезнең XX гасырны һәм бүгенге көн тарихын-вакыйгаларын да күздә тотабыз.

Нурихан Фәттах шушы киң мәгънәдәге тарихны яза, бүгенге көнне дә күздә тотып, күчмә төркиләр чорыннан бүгенге көнгә килеп җиткән, югалмаган һәм югалмаячак сыйфатлар турында яза. Идарә итү теләге, баш булырга, хуҗа булырга хыяллану, тәхеткә һәм дан-дәрәҗәгә омтылу кеше табигатенә хас сыйфат, күрәсең. Дәүләтләр оешканнан алып кешелек тарихы нинди генә тарханнар, каганнар, ханнар, патшалар, корольләрне күрмәде! Тарих белән, чынлап та, шәхесләр идарә итә, аларның акылы, холкы, теләк-максатларына карап тормыш һәм Җир йөзе үзгәреп тора. Нурихан Фәттах шул турыда яза.

«Кайвакыт патшалар, ханнар, корольләр аеруча комсыз һәм кансыз булганнар. Бер кешенең мәгънәсез боерыгына буйсынып, илләр белән илләр сугышкан, халыклар белән халыклар сугышкан. Кешеләр чебен урынына кырылган. Авыллар, шәһәрләр җир белән тигезләнгән...

Юкка-барга бер-берсенә яу чапкан борынгы кабилә кешеләре белән чагыштырганда, бүгенге кеше аңлырак та, белемлерәк тә. Бүгенге кешенең академияләре, институтлары бар, галимнәре, инженерлары бар. Ләкин шул ук вакытта галимнәр, инженерлар уйлап тапкан үтерү, җимерү кораллары да бар. Хәзерге «уклар» белән, ясалма «ми» куелган хәзерге «ташлар» белән авылларны, шәһәрләрне генә түгел, бөтен илләрне, дәүләтләрне җир белән тигезләргә була. Бүгенге көндә ыру-кабиләләр язмышы гына түгел, барлык халыкларның, барлык тереклекнең язмышы кыл өстендә тора».

* * *

Тархан үзенең өлкән бичәсе Күрекле бикәне дә, өлкән улы Албуганы да читкә сөрә. «Кем аркасында? Билгеле, гүзәл чин кырнагы аркасында! Шулай да акылсыз бу тархан. Сөн илендә аңа әллә кыз беткәнме?! Әрнеп-ачынып, агай-эне шулай уйлады.

Күрекле бикәнең йөрәген, бавырын ачу һәм хурлану тойгысы талады... Туман тарханның өлкән бичәсе, шулай итеп, урда өчен кинәт юкка чыкты. Үлде. Тере килеш үлде».

Яклаучысыз калган Күрекле бикә үзенең туып үскән җирләренә, иксез-чиксез даланың бер читенә үзенең авылы, балалары белән күченеп бара. Озак баралар алар. Күчмә халык өчен табигый яшәү рәвеше дә, нинди хәлдә калуларын уйлап, билгесез киләчәк өчен борчылу да, ыруы, балалары исән булганга куану да бар бу озын юлда. «Ул әле монда — җирдә, кешеләр, терлекләр арасында. Ул бары күченеп кенә бара. Моңарчы да гомер буена күченеп йөргән кебек, хәзер дә ул әнә каядыр күченеп бара. Яшь, чибәр бичәләрен, гүзәл кырнакларын гына якын күрә торган тарханнан үч алачак әле ул бер заман! Юк, җиңел генә төшеп калмаячак әле ул арбадан.

Аның улы — Тучибәк тәгин углан. Ул — Тәңре улы! Аның хокукын тартып алырга беркемнең көченнән килмәячәк. Исән генә булсын аның олы колыны!»

Акыллы, горур Күрекле бикә — чын мәгънәсендә улына киңәшче, таяныч була алырлык кеше. Романда аның тормы-

шы шактый тулы тасвирланган. Албуга аякка басканчы, күңеле, рухы ныгып, ир булып җиткәнче, алар бергә киңәшеп һәм килешеп яшиләр. Туган якларына алып киткән юл аларны урда тормышыннан аера, алар үз дөньяларын корып, үз мәшәкать-борчулары белән көн күрә башлыйлар. Шулай итеп, катлы-катлы гаилә, туганлык мөнәсәбәтләре йомгагыннан торган зур оядан бер кисәк кителеп төшә. Тархан гаиләсенең, урдасының гына түгел, дәүләтнең дә язгы боз кебек кителә башлавы иде бу. Хәер, «гаилә» төшенчәсе бүгенге мәгънәгә туры да килми. Ыруның көче йола нигезендә ыру башының ишле гаиләсе — берничә хатыны, күп балалары булуга да караган, шуның белән дә үлчәнгән. Бүген дә әле без көчле нәсел, ишле гаилә дигәндә туганнар, балалар санын, аларның татулыгын, ярдәмчеллеген һәм бер-берсенә терәк булуын күздә тотабыз.

Күчмәләр чорында бу татулык аеруча әһәмиятле роль уйнаган, чөнки тәхетнең ныклыгы, тормышның иминлеге бик күп яктан шуңа бәйле булган. Бүгенге көн кешесе өчен гадәти булмаган яшәү рәвешен шул чор кануннары тудырган, андагы мөнәсәбәтләрнең гаделлеген, табигыйлеген йола саклап торган. Йолага исә барысы да буйсынган, чөнки ул ата-бабадан килә, Тәңредән килә. Бу, хәзергечә әйтсәк, эчке сәясәткә шәхси мәнфәгатьләр дә буйсындырылган. Шуңа күрә мөнәсәбәтләрне бүгенге көн күзлегеннән чыгып кына бәяләү мөмкин түгел, алар шул чордагы тормыш барышына нинди йогынты ясый, нәтиҗәләре нинди — мәсьәләне шул хәл итә. Туман тархан дүрт хатынына, балаларына карата гадел булса, хатыннар арасында ызгыш чыкмас, урдада иминлек яшәр, ил белән идарә итүченең төп игътибары да зур, иң кирәкле эшләргә юнәлгән булыр иде. Аның өлкән хатыны тарханның дәрәҗәсен, хезмәтен олылап, аның тынычлыгын саклап яши, иренә ярдәмче, акыллы киңәшче була. Зур, иң мөһим мәсьәләләр — дәүләт белән идарә итү кадәр җаваплылыкны вак хисләре белән бутаганга күрә, Олы тархан буталып бетә дә инде. Шуңа күрә ул хыянәт һәм интригалар корбаны булып кала, язмышының югарыдан түбәнгә тәгәрәве аның вакытсыз үлеменә дә сәбәп була.

«Сызгыра торган уклар»ның икенче өлеше Албуга һәм аңа турыдан-туры бәйләнгән кешеләр язмышын тасвирлаудан гыйбарәт. Ул тархан улы булса да, чынлыкта аңа ата кеше бирергә тиешле тәрбияне, җылылыкны һәм ныклыкны тарханга гомер буе тугры хезмәт иткән, тархан урдасындагы каравыл

агасы Туңгак бирә. Балачактан ук ул Албуганы ат менәргә, кылыч, сөңге тотарга, һәр сөн ире үзләштерергә тиешле булган сугыш һөнәренә өйрәтә. Әмма Туңгак алыпның иң зирәк һәм алдан, бик күп алдан күреп, уйлап эшләгән эше — Албуганы көчле сугышчы гына түгел, барыннан да бигрәк, акыллы, гаДел ил башлыгы булырга әзерләү. Туңгак алыпның үзен дә көченнән, акылыннан куркып, кыйнап-имгәтеп ташладылар. Ул да әнә Күрекле бикә белән бергә читкә куылып, күчеп бара, аның да йөрәген аяк астына салып таптадылар. Менә шундый кыерсытылган, чиксез тугрылыкны, үзенә күрсәткән хезмәтне бәяли белмәгән игелексез тарханга ачу-нәфрәтле кешеләр түбәнсетелгән, кимсетелгән хәлдә урдадан куылып, юлда баралар. Әмма бу — түбәнгә төшү түгел, бу — чыныгу, көч туплау, акыл-зиһен җыю юлы. Ул әле үргә таба, тәхеткә таба борылачак, гаделлекнең җиңүенә алып киләчәк.

Шулай да җиңел түгел үзеңә кешеләрне буйсындыру, алар белән идарә итү. Әнә Албугага бирелгән сакчы ирләр — төрле ыруДан, төрле холыклы кешеләр. Арада яшь ягыннан олылар, гәүдәгә көчлеләр, сугышларда катнашкан алыплар да бар. Ничек берләштерергә аларны, нәрсә берләштерәчәк аларны? Албуга бу турыда туктаусыз уйлана. Аның егетләренә әйткән сүзләре шул аңлашуның беренче, кыю-тәвәккәл адымы була. Ул Куян ыруының изге саналган агасын — ырубашы саналган куянны — укка алган, үзен өстен куярга маташкан башбаштак ирнең кылыч белән башын кисә. Үзенә кул күтәргән икенче егетне сакчыларыннан аяп кала да, барысына да мөрәҗәгать итә: «Ирләрем-җегетләрем, мине тыңлагыз! Мин ил башы тархан түгел. Әмма шуны онытмагыз: мин — Тәңре улы!.. Шулай булгач, сезнең өчен мин тархан кебек. Минем сүзем, минем теләгем — сезнең өчен боерык. Күктә кояш балкып торганда, мин ант итеп әйтәм: минем җегетләрем арасында, миңа буйсынган барлык ирләр арасында моннан соң башбаштаклар, качаклар, телләшүчеләр булмаячак! Мин, Тәңре углы Албуга, буйсынмаган, телләшкән теләсә кемнең башын чаптырырга боерачакмын. Тотнаксыз, тәртипсез Төпсәнең үлеме сезгә шул турыда искәртеп торсын!»

Албуганың хаклылыгын да, хаклыкны кайвакыт әнә шулай кырыс, рәхимсез рәвештә якларга туры килә икәнлеген дә егетләр танымыйча булдыра алмыйлар. «Сезнең язмыш белән минем язмыш уртак. Мин туңсам туңарсыз, миңа җылы булса, сезгә дә җылы булыр. Мин ачыксам ачыгырсыз, мин тук бул-

сам, сез дә тук булырсыз. Мин кайда гына булсам да, мин кем генә булсам да, сез миңа мәңге тугрылыклы булырсызмы?» Чынлап та, бер үк язмышка тарган кешеләрне менә шундый гаделлек, авырлыкны бердәй бүлешкән бердәмлек кенә коткарачак. Алар шуңа күрә икеләнмичә бер-берсенә ант бирешәләр һәм ул антларына тугры калалар.

Яшь угланның баш чабу кебек кансызлыгын белгәч, Күрекле бикә борчыла: ана кеше буларак та, улы тәхеткә утырырга тиешле кеше дип санаган бикә буларак та. Туман тархан кебек ерткыч булмасмы аның улы? Бу икеләнүләрдә дөреслек тә бар. Әмма Туңгак алып хаклырак: «Баш чабарга мин өйрәттем аны, бикә, — диде Туңгак алып, тыныч кына. — Баш бирми торган, буйсынмый торган ирләрне! Йолага, түрәгә каршы килүче, тәртип бозучы ирләрне бернинди кызганусыз юк итәргә мин өйрәттем. Киләчәктә тархан буласы, ил башы буласы кешенең күңеле йомшак, кулы каты булырга тиеш дип мин тукыдым аңа, бикә! Илдәге бар башбаштаклык, бар бозыклык тарханның үзеннән башлана. Бәкләр, аксөякләр, каралар — барысы да тарханнан, үзен Тәңре углы дип атаган кешедән үрнәк алалар, аның яман якларын да, яхшы якларын да кабатлыйлар... Мин дә аның кеше үтерүче булуын теләмим. Шулай да Төпсәнең башын чабып ул дөрес эшләгән! Ул аны бүтәннәргә сабак булсын өчен эшләгән!»

Романның башында сөенче хәбәр алып килгән яшь егетне шушы Туңгак алып каршы алган, тархан янына Ак өйгә озатып куйган иде. Менә тагын иң авыр хәлдә калганда, михнәтле юлда алар янәшә баралар. Албуганың киләчәге өчен борчылган Күрекле бикә белән Туңгак алыпта акыл, тәҗрибә, изге теләк бар. «Туңгак алып күз алдында үзгәреп китте. Аның ябык, ачулы чыраенда дәрт һәм омтылыш барлыкка килде. — Миндә, бикә, тау-ташларны актарып ташлардай ярсу бар, көч-куәт бар! Миндә, бикә, бер бөртекне мең бөртеккә әйләндерә алырдай өстенлек бар!»

Чынлап та, Туңгак алып романда гаҗәеп үзенчәлекле роль уйный. Ул Албугага иң куркыныч серне ача, тарханга биргән антын бозып, Албуганы сагалап торган дүрт үлем — урданың дүрт почмагына күмелгән курчаклар турында әйтә. (Күчмәләренең ышануы буенча, кешенең үзенә охшаган, ул үзе дип уйлаган курчакны җиргә күмсәң, ул кешегә, һичшиксез, үлем киләчәк. Димәк, тархан, улын читкә сөргәндә үк, аның үләчәгенә исәп тоткан булган.) Антын бозган кеше бу дөньяда

яши алмый дип ышансалар да, соң дәрәҗәдә имгәнгән алыпны бикә белән Албуга тархан кешеләреннән яшерәләр, имче карчык аны дәвалап, үлемнән алып кала. Сызгыра торган укларны — Албугага җиңү алып киләчәк дәһшәтле коралны да — нәкъ менә Туңгак алып уйлап таба.

Алар күп хәлләрдән соң Албуга белән очрашалар. Туңгак алып аның гаскәр башлыгы, иң акыллы, тәҗрибәле киңәшчесе, гаять оста ярдәмчесе дә булып яши. Күңелләре бер-берсенә тартылган бу горур, матур кешеләр бер-берсенә «әти», «улым» дип дәшәләр. Бу — аларның иң кадерле, яшерен серләре. Күрекле бикә, үзенә яңа оя корып, аерым бер гаилә, тормыш белән яши башлый, ә Туңгак алып, нәкъ аталарча, иң кирәк вакытта Албугага акылы һәм осталыгы белән ярдәм итеп тора. Аның зирәк акылы һәм тәҗрибәсе, улының барыр юлын яктыртып, аны ялгышлардан, бәла-казалардан саклап тора.

Туңгак алыпның үзен, дөресрәге, аның рухын сәламәтләндергән, яшәүгә теләк, киләчәккә өмет уяткан шактый серле тагын бер шәхес, бер язмыш бар әле. Бу — кеше аягы басмаслык ерак таулар арасында, урманда яшәүче Хучи исемле имче карт. Ул — Чин иленнән качып килгән, борынгы галимнәрнең белемен үзләштергән, һәр үләннең шифасын, тере җан иясенең телен аңлый белә торган хикмәтле кеше. Гыйлемнең нинди кодрәтле көч икәнлеген аңлаган, тойган бу кешеләрне язмыш дөнья чите дип уйларлык Яман саз тирәсендәге аулак урман аланында очраштыра. Шунда алар, куыш корып, табигать биргән байлык белән тукланып яшиләр. Туңгак алыпны Хучи яшәгән аланга китереп куйганда, ул хәрәкәтсез, җансыз-рухсыз бер гәүдә иде. Янында аны карап-тәрбияләп торган Табылдыктан да кыенсынып, әрнеп уйлана гына иде. Аның, билгеле, әз генә дә үләсе килмәде. Кайчагында аның бик нык яшисе һәм озак итеп, шаулатып-гөрләтеп яшисе килде. Аннан да бигрәк, үзеннән соң яшәячәк кешеләргә нинди дә булса мәңгелек истәлек калдырасы килде. Бар дөньяны таң калдырасы килде. Ләкин ничек итеп? Әлегә ул моны белмәде. Ул бары бу дөньяда үзенең ничектер бәхетсез, өлешсез булуын гына белде. Беркайчан да аның мондый тигезсезлек, өлешсезлек белән килешәсе килмәде.

«Әйе, әллә ничек булды аның тормышы. Күпме дан яулап, данлы була алмады, күпме хатын сөеп, янында бер баласы, якыны калмады. Беркем дә аңа «әти» дип эндәшми, беркем

дә аны «ирем» дип яратмый. Булдыра алган кадәр барысы да аның әле канын, әле җелеген суырды. Кирәге беткәч, менә ташлап калдырдылар. Колның язмышы, күрәсең, шулай булырга тиештер дә. Ләкин ул тархан өчен, бикә өчен генә кол булды. Үзе өчен, үзенең ирләре-сугышчылары өчен ул беркайчан да кол булмады. Тәңре кешене яратканда кол итеп яратмый. Туганда алар барысы да сабый булып туа. Сабыйларның һәркайсы тигез. Бары язмыш кына кешеләрне төрлечә бүлгәли, тарката, или. Язмыш көчлерәкме, әллә Тәңреме? Менә эш нәрсәдә!.. Җирдәге барлык кеше Ата улы, Ана улы икән, нишләп әле ул — кеше — ниндидер явыз язмышка буйсынырга тиеш?!

Әйе, беркайчан да аның буйсынасы килмәде. Үзенең буйсынмавын күрсәтмәкче булып, ул теләсә нинди аксөяктән, язмыштан көчлерәк, акыллырак булырга тырышты».

Игътибар итегез: бу — мәңгелек фәлсәфә. Кешеләр гомер буе әнә шулай бәйсезлеккә-хөрлеккә омтылган, үз горурлыгын саклаган. Безгә дә бик таныш кичерешләр, борчулар бит болар. Җәмгыять хәзер колларга һәм аксөякләргә бүленмәгән, әмма кеше җаны — рухының нинди генә хәлдәгеләре, дәрәҗәдәгеләре юк?! Бүген без үзебездәге курку хисе, коллык психологиясе белән көрәшәбез, шуңа күрә романда тасвирланган язмышлар безне дулкынландыра, без үзебезне, чынлап та, шул язмышларның дәвамчысы, бүгенге көнебезне шул дәверләрнең, зур тарихның бер өлеше итеп тоябыз.

Гаҗәп хәл: үзен Тәңре улы, Кояш улы дип санаган тарханның көче тәхеткә генә тотынып торган икән, шәхес зурлыгы да тәхет биргән дәрәҗә генә булган икән. Кол Туңгак алып һәм туган иленнән качарга мәҗбүр булган Хучи яшәү көчен борынгыдан килгән акылдан, акыл ияләренең язып һәм әйтеп калдырган хикмәтле сүзләреннән, гади халыкның көндәлек тормышта бөртекләп җыйган тәҗрибәсеннән алалар. Табигать үзе, урман-сулар, һәр агач һәм таш, һәр тереклек иясе аларга көч биреп тора. Романда бу шулкадәр ачык, җанлы итеп тасвирланган, бу язмышлар, олы җанлы кешеләр шуңа күрә ихлас соклану уята. Шәхеснең зурлыгы дәрәҗәдә, алтын-көмешкә күмелгән тәхеттә, мал-мөлкәттә түгел, җирдә нык басып торуда, тормышта кирәкле, файдалы булып яшим дигән горурлыкта, рухның сафлыгында, ышанычның ныклыгында икәненә тагын бер кат ышанасың. Имче карт, антын бозган кешенең кул-аягы корыша, күзе сукырая, теле корый, антын

бозган кеше озак яши алмый, кайчан да булса ул барыбер корып-кибеп үләчәк, дип ышанып яши. Әмма ул шул хәлдәге кешегә дә ярдәм итә ала. «Аңа мин ярдәм итә алам. Мин — имче, күрәзәче. Минем белмәгән нәрсәм юк», — ди ул, тыйнак кына, эчке бер горурлык белән. Чыннан да, аның дәвалау ысулы да, дарулары да — гаҗәеп бер могҗиза, ышану һәм ышандыру көче бар аларда. «Иң элек без җир иясенә атап корбан бирербез... Шуннан соң без синең хәзерге исемеңне утта яндырырбыз. Ут-анага корбан бирербез. Сиңа яңа исем кушарбыз. Шуннан соң синең тәнеңә: битеңә, маңгаеңа, кулларыңа, аякларыңа... бөтен җиреңә бизәкләр, сурәтләр төшерербез. Монысы кыен булачак. Шуңа түзсәң — исән каласың, түзмәсәң — үпкәләштән түгел. Антын бозган Туңгак үләр, аның урынына яңа кеше туар». Туңгак алып, чынлап та, яңадан тугандай булып көн итә, кол язмышын җиңеп, талантлы гаскәр башы, акыллы, гадел тарханның уң кулы булып яши.

* * *

Нурихан Фәттах безнең ерак бабаларыбыз булган сөннәр тарихын гына түгел, алар күршесендә яшәгән, әмма яшәү рәвешләре, мәдәниятләре белән бөтенләй башка дөнья булып яшәгән чиннар (борынгы Кытай) тормышын да кызыклы итеп күз алдына китерә. Шул рәвешчә, тарихи мәйдан, офыклар тагын да киңәя. Әмма игътибарны тарта торган, бер урынга җыеп алгач, аеруча рәхимсезлеге белән ачылып китә торган мәсьәлә бар: бу — идарә итүче образы, тираннар тарихы. Халыклар, илләр язмышында кайчан да, кайсысында да тирән эз калдыра торган тарих.

Һәр илнең, чорның патшасы дәрәҗәне үзенчә аңлаган, үзенең бөеклеген үзенчә күргән, исбатлаган. Чин патшасы Шихуанди кырык елга якын тәхеттә утыра. Ул тәхеткә утыруга, теге дөньяда да җирдәгечә яшәргә өметләнеп, үзе өчен күз күрмәгән, колак ишетмәгән кабер казыта башлый. Зур тауның эче алынып, тау астында теге дөнья корылырга тиеш була. Утыз елдан артык вакыт эчендә җир казу эше беркайчан да тукталып тормый. «Ишелеп, җимерелеп төшкән таш астында кешеләр үлде. Көянтәләп күтәрелгән ташның авырлыгына түзә алмыйча, башкаларның аягы астына егылып кешеләр үлде. Кансыз багларның — күзәтчеләрнең — камчысыннан

кешеләр үлде. Ачлыктан, хәлсезлектән, авырудан, ялгыш басканнан, ялгыш ишеткәннән, ялгыш сөйләшкәннән, каршы эндәшкәннән йөзәрләп, меңәрләп кешеләр үлде».

Үзеннән, үзенең ялагайларыннан башка барлык кешеләрне җинаятьчеләр дип санаган патша әнә шулай йөзәрләп, меңәрләп үлгән кешеләр урынына ун меңләп, йөз меңләп таза кешеләрне куып китерә тора, аларны тагын исәннәр алыштыра. Бер патша өчен, аңар кабер казу өчен. Кеше аңы кабул итә алмаслык бу кыргый рәхимсезлек иң борынгы культура илендә эшләнә. Ни өчен культура дибез, кайда соң ул? Ул менә шушы күз күрмәгән эшне башкаручы кешеләрнең осталыгында, эш ысулларында, сәләтләрендә, талантларында. Бары тик чикләнмәгән хакимият кенә кешенең хыял-теләкләрен шул дәрәҗәдә гарипләндерә ала, бөтен бер халыкның галимнәренең, акыл ияләренең, һөнәрчеләренең талант көчен берүзенә хезмәт иттерә ала. Әнә бит дистәләрчә елларга сузылган, тау кадәр дип кенә бәяләп бетереп булмаган эш башкарыла, хезмәт куела: «Кабернең кырыйларына, бернинди су һәм юеш үтмәслек итеп, кургаш катыштырып эретелгән җиз койдылар. Гөмбәз сыман биек түшәм тигезләп шомартылды. Түшәмне буяп, анда кояш һәм болытлар ясап, тышкы дөньядагы күк йөзен сурәтләделәр. Болындай идән өстенә, берничә мәртәбә кечерәйтеп, Чин җиренең тауларын, үзәннәрен, елгаларын, күлләрен-диңгезләрен ясадылар. Елгаларга, күлләргә-диңгезләргә терекөмеш тутырылды. Терекөмешне бер савыттан икенче савытка күчә торган, үзеннән-үзе ага торган итеп тутырдылар. Үзәктәге гөмбәз сыман кабер-төрбәдән як-якка сузылган озын юлларга, куышларга бөек патшаның кечерәйтеп ясалган барлык сарайлары утыртып куелды. Алтын-көмештән, җиздән-бакырдан, кургаштан, тимердән һәм затлы ташлардан ясалган затлы әйберләр, сыннар, чүлмәк, савыт-саба, сирәк очрый торган кыйммәтле бик күп нәрсәләр куелды».

Менә шулай итеп, җир астына чын мәгънәсендә никадәр байлык, хезмәт күмеп куела. Никадәрле кеше гомерләре сарыф ителә, кеше сөякләреннән таулар өелерлек була. Акыл, мәгънә чиген үтеп киткән максат — бер кешенең холкы һәм халык язмышы. Коты очып үлемнән курыккан Шихуанди, ялганчы-хәйләкәр күрәзәчеләрнең океан уртасындагы утрауда терек суы бар икән дигән сүзләренә ышанып, тагын никадәр кеше гомерен суга сала. Ахырда үзе юлга чыга һәм үлемен дә шул сәяхәттә таба.

Игътибар итегез: тарханның колы Туңгак алыпның да үләсе килми, аның да җирдә үз эзен мәңгеләштереп калдырасы килә. Әмма никадәр аерма. Бер үк сүзләрнең мәгънәләре никадәр бер-берсеннән ерак, капма-каршы була ала. Иң югары дәрәҗәдәге кешелеклелек белән иң түбән, соң чиктәге кешелексезлек арасында да бер үк тереклек иясе — кеше басып тора. Чин патшаларының чиксез мәкерлелеген, кансызлыгын автор шундый итеп тасвирлый, ул тираннарны җанлы кеше рәвешендә кабул итеп булмый башлый. Тәхеттә утырган кешенең үз акылын комсызлык, курку, көнчелек кебек түбән, вак хисләр күмеп киткән булса, аның әйләнә-тирәсен мәкерле, хәйләкәр, ялагай кешеләр чорнап ала. Бу тарихта да шулай булган, хәзер дә, безнең күз алдында да шулай ук.

Тормышның мәңгелек белән тоташкан агымнары, үзгәрми торган сыйфатлары да бар. Үрнәкләр һәм гыйбрәтләр алырлык тарихи байлык, төрле язмышлар, характерлар җыелган бу романда. Әйтерсең ерак чорларда калган кешеләр безгә үзләренең хис-кичерешләрен, кайнар җаннарын васыять итеп тапшырып калдырганнар, ничәмә-ничә буыннар аларны үзләре, язмышлары аша үткәреп, безгә китереп җиткергәннәр.

* * *

«Сызгыра торган уклар» романының гаҗәеп күптармаклы, күп борылышлы вакыйгалар катламы, ырулар арасындагы көрәш һәм каршылыклы мөнәсәбәтләр, күчмә тормышның үзе кебек үк туктаусыз үзгәрешләр әсәрдә бер кеше — Албуга язмышына килеп бәйләнә.

Урдадан куылып, үзләренә билгеләнгән кышлауга барып җиткәнче үк, ул тарханның хыянәте турында ишетә. Ул дүрт үлемне, үлемнән куркуын җиңәргә тиеш, аның өчен яшәү бары шул җиңүләр аша гына була ала. «Төшлектәге таза, яшь кояшның түбәдәге айның, йолдызларның кинәт җиргә төшеп үлеп-кырылып бетүләре башка сыймас нәрсә булган кебек, аның да — яшь, таза Тучибәк угланның да — үлеме башка сыймас нәрсә булмас идемени? Инде шулай да берәрсе аның юлына үлем тозагы корып куйган икән, барлык җаны-тәне белән, барлык тырышлыгы белән, барлык осталыгы белән ул әлеге тозакны юк итәргә тиеш түгелмени?

Тиеш!

Кортларның-бөҗәкләрнең, ташларның-агачларның яшисе килгән кебек, Туман тарханның, Котлуг бәкнең...— барлык

башка җан ияләренең яшисе килгән кебек, аның да яшисе килә. Ул яшәргә тиеш. Бер көн эчендә Кояш Җирне әйләнеп чыккан кебек, ул да үзенә тиешле гомерне яшәргә, үз төшлегенә, үз биеклегенә күтәрелергә тиеш...

Ләкин дала киң, далада юллар күп — ат юллары, арба юллары, тычкан юллары... Шуларның кайсысыннан китәргә? Кирәк юлны сайлаганда ялгышмаммы, Туңгак алып? Бутамаммы арба юлы белән тычкан юлын?»

Туңгак алыптан аерылгач, Албуга шулай уйлана; сорауларга җавап табарга аның әле тәҗрибәсе, тормыш белеме җитмәсә дә, ул бернәрсәне яхшы аңлый: әнисе, энеләре, туганнары, аңа бирелгән каралар, аларның гаиләләре — барысы да аны үзләренең башы, яклаучысы дип белә. Менә шул ышанычны акларга тиеш ул. Кемдер кушып, мәҗбүр итеп түгел, үзе аңлап һәм теләп алган шушы җаваплылык хисе аның буыннарын ныгыта, аңа акыл һәм тәвәккәллек бирә. Өлкәннәрнең киңәшен тыңлый белә, кирәк чакта уйлап бетереп үз сүзен әйтә, ничек тә татулык-бердәмлекне сакларга тырыша Албуга.

Аңа иң башта үзен, ыруын сакларлык ир-егетләрдән торган, тәртипне таныган, бер йодрыкка тупланган гаскәр кирәк. Моңа кадәр сөн ире тумыштан сугышчы булып туа, өйрәнеп торырга кирәкми дип уйлаган ирләрне-егетләрне ул һәр көн сугыш осталыгына өйрәтә. Байык су буена — үз җирләренә килеп йорт коргач, авыл булып урнашкач, урман кешеләре белән дуслык урнаштыра, корал һәм тормыш өчен кирәкле башка әйберләрне ясау хәстәренә керешә. Албуга чын хуҗаларча тырышлык, уңганлык белән көндәлек тормышын корып җибәрә, әмма ул бер генә көн дә үзенең һәм үз кешеләренең киләчәге турында уйламыйча, шул турыда кайгыртмыйча, аңа әзерләнмичә калмый. Аның ыру җитәкчесе буларак зирәклеге дә шунда: ул, язмышына буйсынып, аның килгәнен ваемсыз гына көтеп ятмый. Ирләрен-егетләрен үз сүзенә, хаклы икәнлегенә сабырлык, ныклык белән ышандыра бара, тәртипкә күнектерә. «Безнең бүгенге көнебез караңгы, киләчәгебез якты. Минем киләчәк — сезнең кулда, сезнең киләчәк — минем кулда. Якты киләчәкне яулап алу өчен, миңа көчле куллар, кыю йөрәкләр кирәк. Алар — сез!» Теләктәш булган ышанычлы кешеләр шулай туплана бара.

Туман тархан чиннарга каршы сугыш башлаганда, Албуга аның гаскәренә әнә шулай өйрәтелгән, бер сүздән аны аңлый торган сугышчылары белән килеп кушыла. Сугыш эпизодла-

ры романда күреп торгандагыдай ачыклык белән, кораллар, киемнәр, сугыш барышы белән тулы тасвирланган. Нәкъ шул күренешләрдә, вакыйгаларда сугышның никадәр кеше табигатенә ят, аны ярсыта, ерткычка әйләндерә торган рәхимсез көч икәнлеге дә ачык чагыла.

Нурихан Фәттах иҗат иткән тарихи романнарның безне әсир итә торган көче дә шунда: аларда үткән гасырларның илаһилыгы, бөеклеге, романтикасы шул чорның кыргыйлыгы, кешеләрнең кырыслыгы, күчмә тормышның безгә ят булган яшәү тәртипләре белән бергә үрелгән. Аерып булмаслык каршылыклар: күкләргә ашарлык көчле дә, даланың ягымлы җиледәй, хәтфә үләнедәй нәфис тә хисләр һәм дала бүреседәй кыргыйлык рәхимсезлек белән катнашкан.

Сораулар һәм биремнәр

1. Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Нурихан Фәттахның татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы, ачышлары нидән гыйбарәт? Аның тормышы һәм иҗаты турында сөйләгез.

2. 8 нче сыйныфта өйрәнгән «Итил суы ака торур» әсәрен искә төшерегез. Анда кайсы чор, нинди вакыйгалар тасвирланган иде? Ике роман арасында нинди уртаклык һәм аермалар күрәсез?

3. «Сызгыра торган уклар» романындагы конфликтларны билгеләгез. Ул каршылыклар кемнәр арасында, сәбәпләре нинди һәм алар ничек хәл ителәләр? Кайсылары бүгенге көн өчен дә хас дип уйлыйсыз?

4. Романдагы персонажларның кайсылары төп вакыйгаларда катнаша, хәлиткеч роль уйный, һәм алар нинди сыйфатлары белән аерылып торалар? Кайсы геройлар сездә соклану һәм теләктәшлек хисе уятты, ни өчен?

5. Әсәрнең теленә игътибар итегез. Нинди үзенчәлекләре бар, безнең бүгенге сөйләм теленә, башка әдәби әсәрләрнең теленә охшаганмы? Үзегезгә ошаган өлешне ятлагыз.

6. Татар әдәбиятындагы нинди тарихи романнарны беләсез, кайсыларын укыганыгыз бар? Тарихи романнар укучыга нинди сыйфатлар үсти дип саныйсыз?

Тарихилык — иҗат принципларының берсе һәм әһәмиятлесе. Ул язучыдан һәрбер чорны һәм психологик күренешне эзлекле төстә, бар тарихи аныклыгында тасвирлауны таләп итә. Бу таләп бигрәк тә үткән тарихи чорларга багышланган әсәрләр өчен әһәмиятле. Тарихилык принцибына тугры булган язучы үз әсәрендә тормыш һәм кешеләрне, үзләре яшәгән

шартларның нәтиҗәсе төсендә, шуның белән бергә, үзләренә хас барлык үзенчәлекле сыйфатлары белән тасвирлый.

Тарихилык тулырак, ачыграк чагылган һәм кулланылган жанр — тарихи роман жанры. Без өйрәнгән «Сызгыра торган уклар» романы мисалында бу алымның төрле яклары турында сүз кузгаткан идек. Тарихи документларга нигезләнгән булу, ерак бер чорда яшәгән кешеләрнең язмышларын, хис-кичерешләрен без бүген күреп торгандай ачыклык белән, бербөтен дөнья итеп тасвирлап бирү; аерым кешеләрне берләштергән җирлекне — яшәү һәм идарә итү формаларын, җәмгыятьнең төрле катламнарга бүленгән булуын, дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне анализлап нәтиҗәләр ясау — бу романга хас сыйфатлар.

Тарихи дөреслеккә, документлар, фактларга нигезләнгән булу — тарихилык принцибының бер шарты. Шундый ук дәрәҗәдә аның әһәмиятле икенче сыйфаты да бар: ул — уйланмалылык, уйлап табылган күренешләр, образлар җыелмасы. Язучы, тарих кыйпылчыкларын хыял көче белән тулыландырып, җанлы, бөтенлекле дөнья тудыра, иҗат итә.

Тагын бер мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк: тарихилык, иҗат принцибы буларак, бүгенге көн турындагы әсәрләргә дә хас. Аерма шунда: тарихи әсәрләрдә ул төп принцип итеп алына, барлык яклары тулысынча гәүдәләнә. Ә башка төр жанрларда тарихилык бүгенге көн вакыйгалары һәм күренешләре өчен нигез яки фон итеп бирелә, тарихи чор икенчерәк планда кала, шуңа күрә алгы планга вакыт агымының бүгенге катламы чыга. Шулай да тарихилык күздә тоткан максат — үткән, бүгенге һәм киләчәк заманнарның тыгыз бәйләнешен күрсәтү, тормышның өзлексез агымын, хәрәкәтен тасвирлау — зур күләмле һәр әсәрдә саклана. Чөнки тормышның көче — аның хәрәкәтендә, бер чорның икенчесенә ялганып баруында; мәңгелек проблемалар — кыйммәтле сыйфатлар, яшәү закончалыкларында. Тарихилык принцибын шуңа күрә чиксез бай тормыш-чынбарлыкны әдәби әсәрдә бирү алымы, сәнгать чарасы дибез.

Аяз Гыйләҗев
(1928—2002)

«Шәхсән минем үземне «гыйбрәтле» геройлар ныграк кызыксындыра. Мин шундый кешеләрне яратам: үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәт һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр... Уйлана һәм уйландыра торган кешеләр!.. Бу сыйфатларга ия булган кешеләрне гомер юлымда күп очраттым мин, алар минем күңелемне нык баеттылар. Ясалмалылыктан, төче буяулардан, ярашудан качарга өйрәттеләр».

Бу сүзләрне әйткән әдип үзе дә — гаять гыйбрәтле язмыш кичергән, кешеләрне аңлый һәм ярата белә торган олы җанлы шәхес. Ул сокланган кешеләр аның әсәрләренә герой булып күчкән, күңел сизгерлеге һәм иманының ныклыгы аны заман ваклыкларына яраклашудан саклап торган. Аяз Гыйләҗев өчен бердәй кызыклы булган ике өлкә, ике сурәтләү мәйданы бар. Бу — кеше характерлары һәм үзе яшәгән чор. Чиксез бай булган шушы материалны аның талант көче үзенә буйсындырган, әйтерсең ул, көчле ихтыярлы режиссёр булып, тормыш вакыйгалары белән идарә итә, алардан үзе теләгән вариантлар төзи.

Бүген без татар әдәбиятының тарихына һәм бүгенгесенә яңача карарга, аны яңача аңлатырга һәм бәяләргә кирәк дигән фикерне еш кабатлыйбыз. Нәрсәдән гыйбарәт ул яңача караш?Мөгаен, иң беренче чиратта, авторның үз алдына куйган максатын дөрес аңлап, әсәрне игътибар белән укый белүдә; нәтиҗәләрне дә бүген намусыбыз кушканча, икейөзләнмичә ясаудадыр. Икенчедән, әдәбиятның сәнгать дөньясы икәнлеген, аның үз кануннары, үз алымнары, үз мәгънәви чаралары булуын, әдәбият ул тормышны турыдан-туры кабатлау түгел

икәнлеген истә тотып сөйләшергә тиешбездер. Шулай уйласак, күп әсәрләр көтелмәгән яки моңарчы әйтелмәгән яклары, мәгънәләре белән ачылып китәрләр.

Аяз Гыйләҗев иҗаты — татар әдәбиятының олы юлыннан барган иҗтимагый яңгырашлы иҗат. Әмма ул, тормышның ямен, яшәү көчен, кеше рухы-җанының бөеклеген туктаусыз тасвирлап торган хәлдә дә, җәмгыятьнең кеше язмышларын көлгә әйләндерә торган рәхимсезлеген, шәфкатьсезлеген дә гәүдәләндереп бирә.

«Өч аршын җир» әсәрендәге Мирвәлине, мәсәлән, этисе җыйган малны бирмәс өчен, нигезен һәм авылдашларын рәнҗетеп качып китте, гомере читтә үтте, үзен генә түгел, хатыны Шәмсегаянны да бәхетсез итте дип кенә аңлатып килдек. Ләкин бит игътибар белән укысак, Мирвәлидән шул адымны ясаткан гаделсезлек тә кычкырып тора. «Мине җылы түшәгемнән тартып торгызып, салкын урамга куып чыгарырга кемнең хакы бар иде? Кулак малае булып тууыма мин гаеплеме?! Кулакның хезмәтчесе идем ич мин! Унбер яшьтән мин аңа бил бөктем! Ярый, байлыкны алырга да карар кылсыннар, ди... Тик нигә мине чакырмадылар алар? Нигә?

Аның ятларга бөгелергә теләмәгән горур, кире башында усал уйлар кайнады: киңәшмичә, сорашмыйча эшләгәннәр! Кеше түгелме әллә Мирвәли?! Кайсы почмакка гына барып төртелмәсен, аның йөрәге, горурлыгы бәрелеп сызлады: аның үзеннән — хуҗадан башка барын да ничек хәл иткәннәр?!»

Хаклы бит Мирвәли: аның үз шәхесен, хокукларын якларга омтылуын, кешеләр белән аңлашырга әзер торуын күрми мөмкин түгел. Аның гомер буе газапланып яшәвенә, «Дөнья нигә болай көйсез яратылган? Кайда, нинди ялгышлык эшләдем?» дип өзгәләнүенә битараф калу мөмкин түгел. Кешеләрне шундый фаҗигаләргә салган чор, җәмгыять турында уйланмый калып булмый.

Яки тагын бер мисал. «Язгы кәрваннар» әсәрендә җитмеш биш кеше, чана тартып, алтмыш биш чакрымдагы элеваторга чәчүлек орлык алырга баралар. Чаналарга өс-башлары талан-ган, йолкынган, ашарларына да булмаган хәлсез кешеләр җигелә. Бик зарури идеме бу газаплы юл? Сугыш чоры, аның законнары кырыс дип аңлата килдек. Менә ул «закон» — көзен интегеп бер якка, алты чакрымдагы элеваторга ташыганнар иде, язгы юл өзегендә бөтенләй икенче яктан, алтмыш биш

чакрымнан алып кайталар. Юлда йөрәге авыру Сабирәттәй үлә. Кайтып җиткәндә, каршыларына Югары авыл кәрваны очрый, болар — шул ук юлны нәкъ кире юнәлештә кабатлаучылар, якындагыны тагын да еракка ташучылар.

— Безне шулай әрле-бирле йөрткән бәндәләрнең кулы корысын! Тамакларыннан аш үтмәсен! — дип рәнҗиләр кәрванчылар. Берни белән дә аклап булмый торган бу рәхимсезлек җәмгыятьнең сыйфаты, идарә итүнең ысулы иде.

Аяз Гыйләҗев әнә шулай кеше күңеленең байлыгы, матурлыгы, рухының ныклыгы-чыдамлыгы турындагы әсәрләрендә кеше гомеренә «куелган» бәяне дә бик ачык һәм аңлаешлы итеп чагылдырып килде. «Балта кем кулында?» романында бәя куючылар белән йөзгә-йөз очраштырды, чорның үзенә хас рәхимсезлек белән бүгенге көн образын иҗат итте, аның төп, асыл сыйфатларын фаш итте.

Сәнгатьлелек дәрәҗәсен билгели торган бер үлчәм — ни турында язу, нинди ачышлар ясау булса, икенче хәлиткеч билге — ничек, нинди алымнар белән тасвирлау. Бу инде — язучыны рәссам дәрәҗәсенә күтәрә торган осталык мәсьәләсе. Халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең таланты яңадан-яңа инешләрне кушып аккан елга кебек көчәя-куәтләнә бара. Аеруча 70—80 нче еллар мул уңышлы еллар булды. Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Җомга көн, кич белән...» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары да шул чорда языл ды. Һәм бу әсәрләр мәгънәви фикер, каршылыклы мөнәсәбәтләре белән генә түгел, төзелешләре һәм образлар системасы белән дә сәнгать ачышы иделәр. Шуларның берсен — «Әтәч менгән читәнгә» әсәрен анализлап карыйк.

«Әтәч менгән читәнгә»

(1979—1980)

Иң башта әсәрнең төзелешенә-композициясенә игътибар итик. 120 битле җыйнак кына әсәр 11 бүлектән тора. (Кайберләре йолдызчыклар белән тагын да ваграк өлешләргә бүленгән.) Гадәттә, зур һәм катлаулы вакыйгаларны тоташ агым итеп тасвирлап булмаганда, иң әһәмиятле, кирәкле эпизодларны гына сайлап алалар да аерым бүлекләр итеп тезеп, билгеле бер тәртиптә урнаштырып чыгалар. Ягъни һәр бүлек нинди дә булса кечерәк вакыйга, эш-хәрәкәттән тора, шулай итеп, бер-берсенә бәйләнгән вакыйгалар чылбыры төзелә.

Бу әсәрдә исә вак өлешләргә бүленеш принцибы вакыйгага түгел, ә геройларының әсәргә кертелү тәртибенә буйсындырылган.

«Әтәч менгән читәнгә» әсәре нәкъ шулай, исемендә әйтелгәнчә башлана: «Ниһаять, әтәч тәвәккәлләде: ишегалдын иңләп, канатларын җилпеде, мәгърур башын кыегайтып, күккә карады һәм, мә сиңа, читән казыгына очып та кунды.

Өстән караганда дөнья бик киң һәм тавыклар бик вак булып күренделәр. Югарыга карады, кояш та тары бөртегеннән әллә ни зур түгел иде...»

Беренче бүлектә Гәрәйхан кушаматлы әтәч һәм каравылчы Хәйретдин агай белән танышабыз. Икенче бүлеккә әтәчне читән башыннан бәреп төшергән Зәйтүн һәм әтәч хуҗасы Әнәс исемле малайлар килеп керә. Өченче бүлектә Зәйтүннең бик зәһәр апасы Фирүзәне күрәбез, аның тирән «кайгысы» белән танышабыз. Дүртенче бүлек укытучы Җәмил Камалов, бишенче бүлек аны кулга ияләштерү кебек олы максат белән башы әйләнгән Вәзиләгә багышлана һәм башкалар. Ахырга кадәр диярлек шул рәвешчә әле бер герой, әле икенчесе алга чыга. Тагын шунысы кызыклы: ул геройларны «сәхнәгә» автор «җитәкләп» алып чыга, аларның кем булулары, әсәргә нинди уңай белән килеп керүләре, шөгыльләре һәм яшәү максатлары, бер-берсенә мөнәсәбәтләре белән таныштыра.

Повестьның бик ачык сизелеп торган икенче үзенчәлеге автор сөйләменә, хикәяләү рәвешенә бәйле. Ул гел укучысына мөрәҗәгать итеп сөйли, әйтерсең аның күз алдында кызыклы бер эксперимент-тәҗрибә үткәрә, аның барышын һәм сәбәпнәтиҗәләрен анализлап, аңлатып бара. Укый башлауга ук, авторның күзгә бәрелеп торган ирониясенә, геройларын үчекләгәндәй сөйләү тонына, манерасына игътибар итәсең. Шуңа күрә аның үткен теленә эләккән күренешләр, хәлләр, яшәү рәвешләре, принциплар һәм, әлбәттә, геройлар аеруча игътибарны тарта, истә кала. Ул бик күп нәрсәләрне «колагыннан тартып чыгарып», укучысы алдына тезеп куя. Әйтерсең безнең бүгенге ыгы-зыгылы, «бәйдән ычкынган» көнебезне «Мең дә бер вак-төяк» кибетенә әйләндереп куя, әйтерсең бүгенге чорыбызның бер моделен төзи. Аның әле бер деталең, әле икенчесен алга чыгара, нинди дә сыйфатларны махсус арттыра, көчәйтә, зурайткыч пыяла аша тасвирлый. Шуңа күрә бу әсәргә карата «тормышта алай булмый» дигән мөнәсәбәт тумый, киресенчә, без шул ирония дулкынына ияреп

китәбез һәм «әле болай гына да булмый» дигән нәтиҗәгә киләбез. Авторның позициясе, дөньяга карашы, геройларына эстетик мөнәсәбәте — аларны бәяләве — безне дә әсир итә, әсәр чынбарлыкның үзенә караганда да көчлерәк тәэсир ясый.

«Әтәч менгән читәнгә» әсәре чын тормышның бер моделе кебек төзелгән. Авторның теле, хикәяләү алымнары: тезеп, санап бару вакыйгалар тизлегенә тәңгәл килә; чагыштырулар, каршы һәм янәшә куюлар, тиз һәм кискен үзгәрешләрне кыска һәм җыйнак кына итеп сөйләп бару спорт ярышын тасвирлагандагы репортаж стилен хәтерләтә. Бер яки ике-өч сүздән торган кыска җөмләләр, өндәү һәм сорау җөмләләр (күбесе риторик, ягъни җавабы мәгълүм яки җавап көттерми торган сораулар) озын-озын җөмләләр белән аралаша. «Язгы кәрваннар»дагы сандугач һәм тургайлар теле белән сурәтләү юк, лирик яңгыраш, махсус тел бизәкләре дә бик кирәк кадәр генә. Персонажлар сөйләме шактый тупас, авторның сөйләме дә кырыс, усал. Өстәвенә ул әле сөйләмен заманчалаштырып, «бюрократлаштырып» та җибәрә: «Нәни географик белешмә», «Кыскача гына белешмә» (гаилә составы турында) һәм «Нәни генә фәнни белешмә»ләр биреп куя.

Авторның яратып куллана торган башлам җөмләсе бар: «Өч ел дисәм күп, ике генә ел үтте дисәм азрак булыр» яки «Ел дисәм аз, ике ел узды дисәм күбрәк булыр» h.б. Ул хәтта минутларны да шул чамасы белән үлчи. Шунда ук хәтердә әкиятләрнең «борын-борын заманда...», «ай китте, ел китте — энә буе җир китте» дигән сүзләре яңгырый башлый.

Бу үзенчәлекләр барысы бергә пародия жанрын тудыра. Үзенчәлекле, аерым осталык сорый торган, үз законнары булган бу жанр безнең әдәбиятта сирәк иҗат ителә. Повестьның кыйммәте, фикер-нәтиҗәләрдән тыш, шуның белән дә билгеләнә әле.

Инде әсәрнең сюжет үзенчәлекләренә игътибар итик, ягъни вакыйга хәрәкәтен, нәрсә, нинди процесс тасвирланганлыгын күзәтеп чыгыйк. Гәрәйханның читәннән егылып төшүе кошкортлар дөньясында гаять көчле ыгы-зыгы кузгата: «Китте кытаклау, купты тавыш, кузгалды ыгы-зыгы, әкәмәт! Моңа күрше-тирә әтәчләре дә игътибар иттеләр: муеннарын сузып күкне күзәттеләр — тилгәннәр эскадрильясы очып килгәнме әллә?! Уңнан да, сулдан да йомылып әтәчләр чаба башлады. «Бүгеннән Югары очта беренчелек миндә!» — дип шауладылар

алар, бер-берсенең күзен чукып алырга әзер торып. Түшләр киерелде, бугазлар бушады. Китте шикләнү, китте юраулар, фараз кылулар, күрәзәлек, табышмак чишүләр, талаш көчәйде, шулар һәммәсе күршедән күршегә, йорттан йортка күчеп, авылның бөтен кош-кортлары пыр туздымы...»

Бу кереш вакыйга һәм мәсәл геройларын хәтерләткән кош-кортлар дөньясы, операның кереш музыкасы кебек, укучының хис дулкынын көйләп куя, без шуңа охшашлы ыгы-зыгы турында сүз барачагын тоеп алабыз.

Кош-кортлар хоры авылның кап уртасындагы пожар каланчасына менеп йоклаган Хәйретдин агайны йокысыннан уята, һәм ул, кош-корт юкка котырынмый ул дип, чаң кагып куя. «Хәйретдин агай да, Гәрәйхан кушаматлы усал әтәч кебек, безнең алдагы күңелле әңгәмәләребездә мәгълүм бер урын тотканга, аның турында да аз-маз сөйләмичә узып китеп булмас» дип, автор аның тормышын хикәяләп бирә. Кеше гомеренә язган кайгы-хәсрәтнең барысын да кичергән Хәйретдин агайның «үзе дә, гадәтләре дә авылча гади түгел иде, кайгы-шатлыгын уртак итәргә бер чакта да ашыкмады, килгән сагышны үзенә сеңдерде, аз сүзле, сабыр холыклы була калды». Әдәплелеге, акчага-малга кызыкмавы, чисталык-пөхтәлек яратуы белән дә аерылып торган, Язкилдедә үз йорты да калмаган Хәйретдин агай бөтен авылны кинәндереп яши. Аның кулы белмәгән эш юк, һөнәрләрен, кешеләргә эшләгән яхшылыкларын санап кына чыгу өчен дә, авторга берничә бит кирәк булган.

Әмма хәзер менә шул һөнәрләрнең кирәге бетеп бара торган авылда әйбер аз гына туздымы исә чыгарып ташлыйлар, ватылды исә чүплеккә ыргыталар. Нинди матурлыктан мәхрүм булып бара замана. Дөрес, азаплы-михнәтле тормыш җиңеләя бара кебек, әмма үз кулың, үз хезмәтең биргән канәгатьлек, үз осталыгың-уңганлыгың белән көйләмәгән тормыш чын тормыш түгел инде ул.

Әсәрнең сюжеты вакыйгаларның реальлегенә, аларның эчке, тирән мәгънәләренә түгел, ә вакыйгаларның хәрәкәтенә, аларның тышкы рәвешләренә корылган. Өстәвенә, тау башыннан тәгәрәтеп җибәрелгән таш кебек, вакыйгаларның тизлеге дә арта бара. Аяз Гыйләҗев кызыклы алым куллана — әсәрдә ике төрле вакыт үлчәме бар: бер көн һәм үткәне-бүгенгесе белән күз алдына килгән мөнәсәбәтләр тарихы. Ни өчен ике төрле вакыт катламы кирәк булган язучыга? Бер көн эчендә

булган вакыйгалар алга таба хәрәкәт итәләр, аларны автор хәтта бер урында җыеп санап та чыга, һәм алар — шактый озын гомернең, ниндидер тырышлык һәм омтылышларның ачык, бәхәссез, логик нәтиҗәләре. «Бүгенге көндә Язкилдедең Югары очында, Сәләхетдиннәр йортында, хәлләр менә шундыйрак — хәлләр, турысын әйтергә кирәк, шәптән түгел. Зәйтүн белән Әнәс читән сүтә-сүтә сугышканнар. Фирүзә белән Җәмил абыйсы ызгышканнар. Зөфәр дигән егет аламасы, мөгаен генә, Вәзилә апасын сатып дошман лагерена чыккан. Җәмил белән Вәзилә арасына, үткен пычак булып, Сәкинә килеп кергән!»

Бер көн эчендә барган вакыйгаларның барысының да эчтәлеге бер үк: ызгыш-талаш, сугыш. Автор аларны йомгаклап, түгәрәкләп куя: әтәчләр сугышы белән башланган көн, ике семья башлыгының сугышып, берсенең имгәнүе белән тәмамлана. Автор башта ук «безнең кызыклы әңгәмә» дип кисәткән иде, уку барышында шул «кызыклылык»ның мәгънәсе ачыла бара. Куанып көләрлек, адәм хуры булганга мәсхәрәләп көләрлек һәм, иң әһәмиятлесе, гыйбрәт алырлык кызыклар да була Язкилде авылында бер көн эчендә.

Әсәрдә кулланылган сәнгать алымы да кызыклы — Сабантуйда көрәшкә башта малайларны чыгаралар, аннан яшүсмерләр, егетләр, соңыннан гына мәйданга чын көрәшчеләр чыга. Монда да шул ук тәртип, түбән дәрәҗәдән югарыга таба үсеш: әтәч читәннән егылып төшә, «син атып төшердең аны» дип, гаиләдәге иң кече буын — беренче сыйныфта укучылар сугыша. «Сезнеке-безнеке» дип мактанышу-үртәшү китә, чөнки аларны, «берәүгә дә баш бирмә, җиңелгәнне җиңгә бөтерәләр» дип, әткәләре-әнкәләре катгый боерык биреп өйрәтеп торалар. Бу ызгышка мәктәпкә консультациягә бармыйча борылып кайткан Фирүзә (8 нче сыйныф укучысы) килеп кушыла. Аның үз хәсрәте баштан ашкан: бу язда аның битен бетчә баса, күзгә күренеп үзгәрә Сәләхетдиннең чибәр кызы. Җитмәсә, аны укытучы Җәмил абыйсы мыскыл итеп кайтарган. Җәмил дә мәктәпкә тренировкага ашыга иде, Сәрвәрбикә әби аркасында гына Вәзилә янында тоткарланды. Вәзиләнең исә Җәмил белән бәйләнешле зур планы бар: ул шәһәргә күчеп китәргә тиеш. Үзен яратып йөргән егетне кыз авылдан биздерергә тырыша. Ләкин Җәмил авылны ярата, күңеле авылны яраткан яшь, сөйкемле кызга — Сәкинәгә тартыла. Шуңа күрә Вәзиләнең генеральный планы җимерелү алдын-

да. Өстәвенә энесе Зөфәр дә аңа «хыянәт» иткән. Зөфәрнең дә хәле җиңел түгел, апасыннан куркып, өйгә кайта алмыйча йөри. Аның Җәмил кебек спортчы буласы, гомумән, аңа охшыйсы килә, өйдәгеләр генә ирек бирми. Абыйсы Хәйдәр кайтып керсә, Зөфәрне яклар иде дә, бәлки, тик ул да һаман күренми әле. Хәйдәр исә бүген шулай ук зур эшләр белән мәшгуль: бай кәләш эзләп йөри. Әнисе Гөлбикәне утыртып, кәләш күзләп кайтып килгәндә, аларның чия төсле «Москвич»ын Мидхәтнең сары лимон төсле «Жигули»е узып китә. Күзләренә ак-кара күренмәс дәрәҗәгә җиткән егетләр ярыша торгач, машиналары җимерелә, Гөлбикәнең кулы сына. Җитмәсә, йорт хуҗалары Сәләхетдин белән Мирфатыйх та сугышып кул сындыралар.

Менә шундый хәлләргә төшә ике күрше. Нәрсә була соң аларга, дошманлыкның сәбәпләре нидә?

Бу сорауларга җавапны без күршеләрнең үткән көннәрен тасвирлаган бүлекләрдә табабыз. Автор укучысын икенче вакыт катламына күчереп куя. «Нинди матур чаклар бар иде! Ничаклы гөнаһсыз, эчкерсез бәйләнышлар яши иде Сәләхетдин белән Мирфатыйхлар арасында». Юри дә, күңел өчен дә, кирәктә дә, кирәкмәстә дә йомышка йөриләр иде; барлык эшләре уртак булды, эш җитми иде тату күршеләргә; ризыкларын бүлешәләр иде алар: өреле ашлар, угыз коймаклары. Мунчадан соң да ирләр чәй генә эчә иде; дару-дәва дигәндә дә бергә сулыйлар иде: үләннәр, кура җиләге, андыз тамырлары; читән эт биеклеге генә, чебиләр өчен генә иде, кош-корт, мал-туар да бик тату иде; бүләкләр дә бик тыйнак, кечкенә, әмма «юк кына әйбер дә олы бүләк, чөнки һәммәсендә хөрмәт билгесе, эчкерсезлек үрнәге, дуслыкны ныгыта торган җылы ишарәләр була иде».

Менә шулай ике йорт арасында какшамас татулык хөкем сөрә. Ишле бала-чагалы ике йорт арасында бернинди яшерен сер, гайбәт, көнчелек юк. Күршелекнең язылмаган, ләкин гасырлар буе сакланып килгән законнары шулар иде. Халкыбызның борынгыдан җыелып килгән шул рухи хәзинәсе кешеләрнең тормышын ямьләп, җанын җылытып тора иде.

Берзаман Сәләхетдин бишекле мотоцикл сатып ала. Гаиләләре белән төялеп, Сабан туена төшәләр. Киңәшсез-нисез, кинәт булгангадыр, күршеләр шаккаталар, Мирфатыйх хатыны Гөлмәрьямнең күзе шуларда гына була. Икенче көнне үк ул кибеттән көзгеле шкаф сатып ала, ә Сәләхетдин Гөлбикәсе

шкафның ике көзгелесен алып кайтып утырта, һәм... шуннан китә ярыша-узыша йортка әйбер ташу.

Әле генә түр башында татулык, хөрмәт иде, үзләре иде. Хәзер исә өй эче берсеннән-берсе кыйммәт әйберләр белән тула, әйбер арткан саен көнчелек тә арта; әйберләр затлырак була барган саен, кешеләрнең үз кадерләре кими. Әйберләр белән кешеләрнең урыннары алышына, кеше әйбер колына әйләнә. «Көнчелек» дигән сүз кергән арага тиз арада дошманлык та кереп оялады. Сәләхетдин белән Мирфатыйх кан дошманнарга әйләнделәр». Тату дөнья чәлпәрәмә килеп җимерелә, һәрнәрсәгә бәя куела башлый, яшәүнең-тормышның кыйммәте кеше җаныннан, җылы мөнәсәбәтләрдән җансыз әйберләргә күчә. Тотылмаган, файдаланылмаган җиһазлар өй хуҗаларының үзләренә — кешеләргә урынны тарайталар, кысрыклыйлар, әйтерсең аларның иманнарын суыралар.

Чынлап та, бүгенге көндә йогышлы чиргә әйләнгән бу процессны Аяз Гыйләҗев әнә шулай ике күрше йортына җыеп, вакытны да, пружина кебек, бер көнгә кысып тасвирлый. Игътибар итсәк, аның бу әсәрендә ярдәмче персонажлар юк диярлек, барысы да бик әһәмиятле рольләрне уйный, чылбырның боҗралары кебек бердәй кирәклеләр, мәгънәлеләр. Аларны автор ике ояга — гаиләгә җыя, һәм ике гаиләдә дә яшьтәш балалар үсә.

Әсәрнең конфликты бик үзенчәлекле. Каршылыкка кергән геройларның, гадәттә, берсе уңай сыйфатларга ия була, икенчесе кире роль уйный. Биредә хәл башкача — ике күрше дә, хатыннары, балалары да көнчелек, усаллык корбаннарына әйләнәләр. Әйбәт, саф күңелле кешеләрне көнчелек дигән явыз көч сихерли, таш күңеллегә әверелдерә. Матур хисләр, теләкләр белән яшәүче Җәмил белән Зөфәр генә бу чиргә бирешмиләр, әмма алар гына нәрсәнедер үзгәртер дип әйтеп булмый.

Шулай да әсәрдә бу дошманлыкка нокта куела: һәлакәт чигенә җиткән күршеләр кинәт тукталып калалар, агулы сөремнән айнып китәләр. Әсәр башында Гәрәйхан кушаматлы гайрәтле әтәч янәшәсендә күренгән Хәйретдин агай авырып китә һәм үзен яңа зиратка күмәргә васыять әйтә. Ә халыкта шундый ышану яши: янәсе, яңа зиратка беренче булып күмелгән кеше үз артыннан туганнарын да ияртә икән. Икесе дә Хәйретдин агайның туганы икәнен исләренә төшергән Сәләхетдин белән Мирфатыйх, ниһаять, аңнарына киләләр, үзара да туган икәнлекләренә акыллары барып җитә.

Хәйретдин агай әсәрдә тирән мәгънәле роль уйный, конфликтның бер ягына автор шул хикмәтле картны куя. Әйтерсең ул пожар каланчасында гына түгел, кешелекле мөнәсәбәтләр сагында да тора. «Язкилдедә гел яхшы кешеләр генә яши дип ышана иде Хәйретдин агай. Талашларны да очраклы хәл, чәкәләшеп алуларның да төп сәбәпчесе бары тик шул каһәр суккан зәмзәм суы дип кенә белә иде. Ә монда Мирфатыйх белән Сәләхетдин дошманлаша». Һәр халыкның яхшы гореф-гадәтләре, кунакчыллыгы, тәмле теле, хатын-кызларның буй җитмәс сафлыгы, горурлыгы, батырлыгы сакланганда гына, тормыш дәвам итә дигән ышаныч белән, үзе дә гомере буе тормышны матурлап яшәгән Хәйретдин агай уйга кала. Кая бара бу тормыш — зиратлар ишелә, су буенда кеше башлары аунап ята. Кешеләр чишмә суы урынына аракы эчәләр, хәтер, акыл зәгыйфьләнә. Кош-корт юкка тузынмый ул, кешеләр азына. «Нәсел башын, олыларны хәтерләгәндә, аның сүрән йөзе азга гына ачылып китә дә, уй җебе бүгенгә, бүгенге кешеләргә, борынгыдан догалы, аш-сулы йорт-нигезнең бүгенге хуҗаларына әйләнеп кайткач, чыраендагы саран яктылык югала. Кешеләр кыска гына арада танымаслык булып үзгәрделәр». Язкилдедә шушы хәвефне сизеп борчылучы кеше — бер Хәйретдин агай. Гомер-гомергә беркемгә авыр сүз әйтмәгән, тәмле телле, әүлия күңелле карт бүгенге көн кешеләренә карап, әрнеп уйлана. Аның чаң сугуы да күңелләрне уятырга теләве, кешеләрне акылларына килергә чакыруы кебек кабул ителә.

Әмма әсәр никадәр ирония, сарказм белән язылса да, аның ахыры хәерлегә таба борылган. Шулай тормыш турында ничек кенә итеп сөйләсәк тә, аны кешеләр кора, төзи яки җимерә.

Ул җимерелүләрдән кешене мәрхәмәтле җаннар, олы акыл гына саклап кала ала. Яшәү өчен фидакярлек, гомер буена җитәрлек сабырлык кирәк, заман чирләренә бирешмәслек акыл кирәк. Тормышның гадел тәртибе бар — акыл, тәҗрибә туплаган өлкән буын үзеннән соң килүчеләрне акылсызлык, тәүфыйксызлык упкынына төшермичә саклап тора. Яшьрәкләр шуны аңламаса, алар уң яктан үзләренә терәк булып торган таянычларын югалталар, чынбарлык каршында киңәшчесез калалар.

Бу хакыйкать Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә якты бер моң булып яши. Ул мәрхәмәтле ил картларын, нарасый күңелле карчыкларны гаҗәеп бер күңел сизгерлеге белән тасвирлый. Алар кеше гомеренең бер чиген икенче дөнья белән тоташ-

тыручы изге җаннар булып күз алдына киләләр. Кырыс та, нечкә күңелле дә булган әдип-рәссамның халык рухын аңлавы, тоюы аның «Җомга көн, кич белән...», «Яра» повестьларында чын сәнгать дәрәҗәсендә чагылды. Игътибар итегез әле: ул, кеше гомере турында уйланганда, аны кыска, чикле, тиз үтүчән дигән үкенечле хис белән түгел, чиксезлекнең бер өлеше, дәвамлылыкның бер күчеше рәвешендә тасвирлый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Аяз Гыйләҗев иҗатының зурлыгын, әһәмиятен билгели торган әсәрләрен әйтегез. Кайсыларын укыганыгыз бар?

2. 8 нче сыйныфта өйрәнгән «Язгы кәрваннар» повестен искә төшерегез. Ул әсәрнең кайсы яклары сезгә аеруча тәэсир итте, кайсы геройларның кичерешләре сезгә якын, таныш?

3. «Әтәч менгән читәнгә» повестенда тасвирланган төп һәм ярдәмче вакыйгаларны сөйләп бирегез.

4. Бу әсәрдә нәрсәләр чагыштырылган, охшатылган яки каршы куелган, нинди сыйфатлар арттырылган, көчәйтелгән? Мондый алымнарны автор ни өчен кулланган, алар әсәргә нинди яңгыраш бирә, нинди максатка хезмәт итә?

5. Әсәрдәге «ярыш»ны, геройларның характер сыйфатларын, яшәү максатларын үзегезнең әйләнә-тирәгездәге тормыш белән чагыштырып карагыз. Нинди фикерләр, нәтиҗәләр әйтә алыр идегез?

6. Татарстан Республикасының халык язучысы Аяз Гыйләҗев иҗаты башка язучылардан нинди сыйфатлары белән аерылып тора, ул кайсы чор, нинди вакыйгалар, нинди кешеләр турында язарга ярата? Аның үзен ниндирәк шәхес итеп күз алдына китерәсез?

Мөхәммәт Мәһдиев

(1930—1995)

Тәнкыйтьче, галим, Татарстан Республикасының халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев әдәбиятка «Без — кырык беренче ел балалары» (1968) повесте белән кинәт килеп керде, авыл укытучылары тормышына багышланган «Фронтовиклар» (1972) романы белән үзен инде җитди иҗтимагый-фәлсәфи, әхлакый мәсьәләләрне калкытып куярга өлгергән язучы итеп танытты.

Алдагы елларда «Каз канатлары» (1975), «Кеше китә — җыры кала» (1978), «Торналар төшкән җирдә» (1979), «Мәңгелек яз» (1982), «Бәхилләшү» (1987) кебек һәркайсы үзенчә яңгырашлы, халыкчан рухлы, камил телле әсәрләре дөнья күрә.

М. Мәһдиев иҗаты турында әдәби тәнкыйтьтә фикер әйтелә тора. Фәрваз Миңнуллин аны яшьлеген сагынучы, туган авылының үткәненә гашыйк язучы дип атый. Рафаэль Мостафинга аның иҗатына хас җылы лиризм, табигыйлек һәм тормышка якынлык ошый. Ринат Мөхәммәдиевне язучының күпчелек әсәрләренең үзәгендә яткан табигатькә дусларча, хуҗаларча мөгамәлә, аерым кеше белән олы дөнья күренешләре, шәхес белән чишмә, күбәләк, арыш серкәсе, сандугачлар арасында тирән якынлык, эчке уртаклык таба белүе сокландыра. «Күпчелек замандашлары кебек, ул да күбрәк сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы колхоз тормышы, авыл кешеләре турында яза. Ләкин аларның берсенә дә охшамаган, берсенә дә иярми, берсен дә кабатламый»,— дип яза әдәбият белгече Ф. Миңнуллин.

Чыннан да, аның иҗатында сугыш алды, афәт чоры һәм 50—60 нчы еллар татар авылы тормышы киң колачлы, кабатланмас шәхес язмышлары аша тасвирлана. Ул халык тормышын, көнкүрешен яхшы белә, аны сәнгатьчә төгәл, ачык күренешләр, детальләр аша тасвирлый.

«Кеше китә — җыры кала» повестенда иҗатының бу сыйфатлары аеруча ачык чагыла.

«Яшьлекне сагыну» исемле мәкаләсендә Ф. Миңнуллин әсәргә югары бәя бирә. «Кеше китә — җыры кала» — киң колачлы вакыйгаларны, драматик эпизодларны үз эченә алган, олы һәм катлаулы язмышлы характерларга, кызыклы образларга бай булган, гаҗәеп дәрәҗәдә халыкчан рухлы, олы хисле, зур, төзек, җыйнак һәм бөтен әсәр»,— дип яза ул.

М. Мәһдиев үзен әдәбиятка алып кергән юнәлешенә турылыклы кала, 30—60 нчы еллардагы татар авылы язмышына, чордашларының авыр, ләкин беркайчан да югалып калмый торган олы рухларына мәхәббәтен яшермичә яза, шуларга мәдхия яудыра.

Кара Чыршы авылы һәм аның кешеләре

«Кеше китә — җыры кала» әсәренең үзәгендә — Кара Чыршы исемле, табигатьнең матур бер җиренә кереп оялаган гадәти татар авылы. Аның тормышында, язмышында бөтен ил кичергән олы һәм кечкенә, шатлыклы һәм фаҗигале вакыйгалар чагыла, һәммәсе аерым кеше язмышы аша уза. М. Мәһдиев «югалган» вакытны эзләми, аны төрле буын кешеләрен якынлаштыручы, бәйләүче ачык һәм төгәл берәмлек дип кабул итә. Персонажлары табигый җирлектә, гаилә эчендә, күршеләре, авылдашлары, җитәкчеләре белән мөнәсәбәттә һәм хезмәттә ачылалар. Көндәлек эштән башка, геройларының яшәешен күз алдына китереп булмый. Авыл кешесенең тормышы җиңел түгел. Әмма яшәешенең эчке матурлыгы, яме бар. Язучы тормышның кырыс реализмы белән романтик күтәренкелекне үреп алып китүгә ирешә.

Колхоз тормышын читләтеп үтә алмый язучы. Соңгы елларда халыкка заманында көчләп тагылган бу хуҗалыкларны хурлау, юкка чыгару рухы модага кереп китте. М. Мәһдиев колхозларның яхшы якларын да күрә һәм сурәтли алган.

Сугыш алды авылы кешеләре бер-берсенә ярдәм итешеп, барыннан канәгать булып, язмышларын колхоз белән бәйләп,

матур итеп тормыш коруга омтылганнар. Идарә итүче режимның, хакимиятне кулына алып, халыкның алдынгы өлешен юкка чыгаруда Тимерхан, Шәяхмәт, Васфикамалларның бер гаебе дә юк. Алар иген үстерә, бала тәрбияли, табигатьне, халкын, туган телен яратып яши.

М. Мәһдиев, 20—50 нче елларның сыйнфыйлыкка нигезләнгән әдәбияты әдипләреннән аермалы буларак, кешеләрне байга — ярлыга, укымышлыга — наданга бүлми. Аның кыйбласы — кешелеклелек. Адәм баласы үз башына төшкән шатлыкны да, кайгыны да, бәхетне дә, көенечне дә кабул итә белергә, һәр очракта дәрәҗәсенә, җанына тап төшермәскә тиеш.

Һәр кешенең үз язмышы бар, ди язучы. Шул фикерен төгәл, ачык, хәтердә калырлык вакыйга-хәлләр аша күңелгә, йөрәккә сеңдерә килә. Шуның өстенә уртак кайгы — сугыш хәсрәте өстәлә. Ирләрне сугышка, күбесен үлемгә озату вакыйгасын язучы искиткеч зур осталык белән, мәңгегә күңелдә сакланырлык итеп, фаҗиганең олылыгын искәртеп язган.

«...Тальян, шөлдер тавышына эт заты чыдый алмый. Койрыкларын җиргә терәп утыралар да, капка төбеннән китмичә генә, күккә карап елыйлар. Бу тавыш күңелләргә шом сала. Нәрсәдер бар, дөньяның кай төшендәдер гаделсезлек бар... Эт күңеле сизгер, ул зрәгә генә алай шыңшымый... Чыннан да, бу сугыш дигәннәре әллә нинди куркыныч нәрсә икән! Хатын-кыз елаша башлады, атлар тыпырчынды...»

Шау-шулы, ыгы-зыгылы тормышны тәфсилләп сурәтли М. Мәһдиев. Сугышка озату, туй күренешләре, күп кешеле җыелышлар, базар мәйданы аеруча осталык белән тасвирлана. Бу өлешләрдә күпертү, сүз уйнату өстенлек итә. Әмма шул чуарлыкта да һәр кеше үз тавышы, үз тамгасы белән яши.

Әйтик, ил өстенә килгән фаҗига — 1941—1945 еллар сугышы — кешеләрне кыл икегә бүлә. Берәүләр, илбасарларны шәхси дошманнары күреп, фронтка ыргылалар, Шәяхмәт карт кебек өлкән буын, хатын-кыз, бала-чага «җаннарын фида кылып тырышалар», сугышчыларга азык-төлек, җылы киемнәр озаталар. Алары — күпчелек, һәр кеше үзенә бәяне гамәли эше буенча ала.

Тәне, теше, күзе таза, Казан арты базарын тоткан ат карагы гаярь Заһри, Хәбирә карчык биргән черек гөмбә суын колагына салып, тәмәке төнәтмәсен эчеп, үз тизәген ашауга кадәр барып җитеп, сугыштан кала. Авылдашлары аның ялганын гафу итмиләр, вак-төяктә дә аркылы киләләр, фаш итәләр.

«Шул көннән башлап, халык белән Заһри арасында ниндидер салкын сугыш башлана, мөмкин кадәр аның белән очрашмаска, сәламләшмәскә тырышалар».

Заһри үзен генә түгел, малае Әхмәтзарифны да, метрикасындагы яшен кечерәйтеп, сугыштан алып кала.

Үлем атлы ачы галәмәт адәм балаларын тигезли. Заһри да, күпме тырышса да, башкалардан озаграк яши алмый.

Унсигезенче елда авыл халкы тарафыннан комбед (ярлылар комитеты) рәисе итеп сайланган, совет эшенә ихлас бирелгән изге җан Шәяхмәт икенче улын артык иркә үстерә. Нургали кулына яшьли акча керә, авызына затлы папирос, конфет менә, зоотехник курсларын ошатмый һәм ахыр чиктә, ФЗОдан качып, үзе әйтмешли, ерткыч җәнлек хәлендә урманда яши.

Язучы беренче рәткә Шәяхмәтнең эчке кичерешләрен чыгара, куе буяуларга мөрәҗәгать итә. «Шул төн эчендә Шәяхмәт ун еллыгын картайды. Йөзенә сары коелды. Яңак сөякләре очлаеп калды».

Бу кайгы ил хәсрәтенә охшамаган, «үзенә бертөрле, эчтән кимерә, төн йокысын качыра торган хәсрәт иде».

Шәяхмәттә барлыкка килгән тышкы үзгәрешләрне бәян иткәннән соң, автор туры сөйләм алымнарына мөрәҗәгать итә. Сүзне кайгы-хәсрәткә төшкән картның үзенә бирә:

«— Менә, билләһи, картаймыш көнебездә адәм рисвае итте бит, урамга чыгарлыгыбыз калмады, нәселебез череде,— дип өзгәләнеп, урыныннан торды да ишек янындагы чөйгә элгән кызыл башлы сөлгегә туры барып битен каплады».

Ата өчен иң яманы — баланың гайре табигый тәртибе, кешеләр, авылдашлары каршында хурлану, гарьләнү. Бу — мең еллар дәвамында сынала, чарлана килгән халык әхлагының чагылышы.

Нургали, Рәмзия исемле читтән килгән кызны әрәм итеп, тегесе туачак баласы белән бергә үлеп, ата-ана башына кайгы-хәсрәтне болай да аз китермәгән була. Инде бу хәтлесе генә җитмәгән тагы.

«...Табигать ул көнне көне буе дулады. Ул нәрсәгәдер риза түгел. Кешеләрдән нәрсәдер сорый кебек».

Бу авыр хәлләрнең шаһиты — җир дерелди, яшен чытырдый, тәрәзә пыялалары зыңгылдый, агач ботаклары сына. Тирәлекнең котырынуы юкка түгел, Нургалидән Рәмзия каберенә баруны, зиратта баш очындагы ак ташны кочаклап

гафу үтенүне, сафлануны, чистарынуны, агарынуны таләп итә. Нургали шулай эшли дә.

Әмма язмыш аны барыбер гафу итми. Ул сугышка китеп, батырлыклар күрсәтеп, күрше Атҗабар станциясендә поезд астына эләгеп һәлак була. Атасы күз алдында соңгы сулышын ала.

Бу олы фаҗиганең тирәнлеген янәдән табигать ачып сала. «Кинәт... күк йөзендәге кояш дерелдәп китте. Менә ул икегә бүленде, аннан ул кисәкләр тагын балаладылар. Күк йөзе вак кояш белән тулды».

М. Шолоховның «Тын Дон» романында, иң яраткан кешесе Григорий Мелехов кулында җан биргәндә, Аксиньяга кояш чем-кара бер түгәрәк булып күренә. М. Мәһдиев әсәрендә дә шундый әдәби алым — катлаулы метафора кулланыла.

М. Мәһдиев күптөрле яшәү ысулларын үзәккә ала. Бер үк туфрак, бер үк авыл, суны да бер коедан эчкән кешеләрнең холыклары, язмышлары төрле-төрле, кабатланмас.

Элегрәк әдәби әсәрнең кыйммәте коммунист образының эшләнеше белән бәяләнә иде. Аның булуы һәм сюжет сызыгын әйдәп баруы мәҗбүри шарт булып торды.

«Кеше китә — җыры кала» әсәрендә дә ике коммунист хәрәкәт итә: берсе — колхоз рәисе, фронтовик Тимерхан, икенчесе — мишәр хатыны Улибаева.

Тимерхан өстән кушканны гына үтәп яшәргә өйрәнгән, «кызыл авыз» коммунист түгел. Шуңа да аны халык ярата, тыңлый, сүзен аяк астына салмый. Ул халык мәнфәгатьләре белән яши. Фронтта чирканчык алган, тәнендә яра йөрткән шәхес, халыктан эш таләп иткәнче, аны ашатырга кирәклекне аңлый һәм колхозчыларга аванс өләшә. Әлбәттә, аны райком бюросына чакырып, иманын укыталар. Шуннан вакыйгалар куерып китә.

Бюро әгъзасы, район прокуроры Улибаеваны башбирмәс Тимерхан колхозына вәкил, дөресрәге, шымчы, күзәтүче итеп җибәрәләр. Ул ифрат явыз, каты бәгырьле, хатын-кызга хас сыйфатларын югалткан гыйфрит кебегрәк сурәтләнә әсәрнең башында. Тимерханны туктаусыз әзәрлекли, усал кигәвен төсле бәйләнә, дүрт йөз грамм арыш урлаган алтмыш бер яшьлек карчыкны төрмәгә озата.

Аның өзлексез тәмәке тартуы, авыз тутырып сүгенүе авыл халкында бу хатынга карата күрәлмаудан, нәфрәттән башка хис уята алмый.

Мәгәр ул шәхес шактый катлаулы, үзенчәлекле. Аның сугыш чоры тудырган тышкы катылыгы, явызлыгы астында олы җаны яшеренгән икән. Ире сугышта үлгән, дүрт баласы әнисе белән ачлы-туклы яши. Ул үз кайгысын берәүгә дә ачмый. Шул ук вакытта Улибаева башкаларга сабак булсын дип үзе утырткан карчыкны төрмәдән коткарып йөри.

Язучы, бу каршылыклы образны тудырып, тормыш һәм кеше без уйлаганнан катлаулырак һәм әзер калыпларга сыеп бетми дигән фикерне әйтергә тели. Ул Улибаеваның үз-үзен тотышында, холкында «кырыс дөреслек» бар дигән фикергә килә.

М. Мәһдиев мәңгелек темаларның берсен — мәхәббәт маҗараларын читләтеп үтми. Ул бу хисне, романтик шагыйрьләрдән аермалы буларак, күпертеп, томанлы күкләргә чөеп сурәтләми, олы тойгыны тормышның табигый дәвамы, кеше яшәешенең бер чагылышы буларак аңларга тырыша. Мәхәббәт бар. Әмма авыл кешесенә хатын-кыз нәселне дәвам иттерү, йортны алып бару өчен кирәк. Шәяхмәт карт та, аның олы улы Хәкимулла да бу мәсьәләне авыр хәл итәләр. Үз башыннан күпне кичергән Шәяхмәт улына өйләнүгә саграк килергә киңәш бирә. «Безнең нигез өйләнү мәсьәләсендә болай да кыңгыраулы булып чыкты»,— ди ул.

Миңлебикә турында хыялланып та, Хәкимулла, икенче бер чибәрне — Васфикамалны урлап кайтса да, бу хәлдән фаҗига ясап, мөгез чыгарып тормый. Кулы-аягы исән, күзләре чая ялкын, эшкә уңган хатын белән рәхәтләнеп яшәп китә. Хәйләкәр, усал, шырпы теленә дә «дару» табыла хатынның.

Шул ук вакытта язучы бу изге тойгыны гадиләштерү, гади көнкүреш вакыйгалары белән чикләнми. Милиционер Нәбиуллин Васфикамалның саф мәхәббәтеннән ат карагы Заһри кызы булганы өчен баш тарткан икән. Кыз, яраткан кешесенең шәһәрдән хатын алып кайтканын белгәч, бик гарьләнә, әрни. Аның тирән кичереше турында сөйләми автор. Психологик күзәтү алымына мөрәҗәгать итә: «Васфикамал сыек май кыздырган табасын, ялгыш әйләндереп, чуен плитә өстенә аударды. Кухняны зәңгәр май исе басты... Васфикамалның кайнар мәхәббәте, башка беркемгә карата да, беркайчан да уянмаячак кайнар хисләре плитә өстендәге сыек май белән бергә чыжлап яндылар».

* * *

Башыннан ахырына чаклы эзлекле вакыйга агышына, бер яки берничә кеше язмышын тасвир үзәгенә алган әсәрләргә күнеккән укучы «Кеше китә — җыры кала» повестенда төгәлләнгән сюжет тапмас.

М. Мәһдиев мәзәк, кызык хәлләр ярата, берсе артыннан икенчесен тезеп бара. Һәр күңелле һәм аянычлы хәлдә эчке мәгънә, сәбәплелек бәйләнеше эзли. Аның бу юнәлештәге кыюлыгын инкяр итеп булмый. Әдәбиятның көче, яме, киләчәге — төрлелектә.

Ул һәр вакыйганы, язмышны аерым бүлекчәгә чыгара, аңа, эчтәлектән чыгып, исем бирә. «Тартмалы композиция» дип аталган бу алым дөнья әдәбиятында күптәннән мәгълүм, ул урта гасыр итальян, француз, испан әдәбиятларында киң тарала. Әлеге ысул язучыга иркенлек бирә, вакыйга канвасына ябышып ятудан коткара.

Поэзиядә бер үзәк кичереш тирәсенә җыелган, бер-берсенә тартылып торган лирик шигырьләрне бәйләмгә туплау гамәле кабул ителгән. Мисал рәвешендә А. Блокның «Стихи о Прекрасной Даме», Х. Туфанның «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...», С. Хәкимнең «Суд залында» бәйләмнәрен алырга мөмкин. Бу уртаклык әдәбиятның төрле жанрлары арасында эчке якынлык яшәве турында сөйли. Шуңа күрә «Кеше китә — җыры кала» повесте көлкеле һәм фаҗигале, сөенечле һәм көенечле вакыйгалар тезмәсеннән, табигать фасылларын гаҗәеп бай, сыгылмалы, ямьле һәм тәмле тел белән сурәтләүдән торган, әмма төгәл композициясез әсәр дип фараз кылу дөрес булмас.

Бер яктан, илдә, дөньяда барган иҗтимагый хәлләр эзлекле сурәтләнә: 30 нчы еллар ахыры авыл тормышы, сугыш михнәте, аның тылга алып килгән салкын кырыслыгы, фронт хәлләре, игенченең михнәт эчендә бәхетле киләчәк турындагы хыяллар белән яшәве...

Икенчедән, әсәрдә бер кешене икенчесе, өченчесе алыштыра, сүзгә дүртенчесе кушылып китә, бишенчесе ата сүзе — мәкаль кыстыра... Яр буендагы чуерташлар төсле гаҗәеп бай һәм төрле аның кешеләр токымы. Повестьның беренче җөмләләре үк Шәяхмәт һәм аның улы Хәкимулланың өйләнү, тормыш кору юлындагы әкәмәт һәм сәер хәлләрен искә алудан башланып китә. «Бәхетеңне сыер сөзсә — көтү көткән

акчаңны да ала алмассың, диләр. Өйләнүнең бәла-казасы Шәяхмәт агайның нигезеннән килә». Нәсел хуҗасы үзе дә, улы Хәкимулла, оныгы Нариман да, нигез корып җибәргәнче, шактый мәшәкатьләр күрәләр, күрше-күлән алдында көлкегә калып бетәләр. Ахырдан нык һәм киләчәкле гаиләләр корып җибәрәләр.

Өйләнү күренешләре үзенчәлекле бердәмлек төзи. Һәр гаилә язмышы — башкалар белән тыгыз бәйләнгән, әмма үзенә бер мөстәкыйль җимеш тутәле.

Җитлеккән әдәби әсәр чорны, аның мең дә бер тармаклы хәлләрен хикәяләү белән генә чикләнми, язучының үз рухи дөньясын, холкын, уй-кичерешләрен дә эченә ала. Иҗатчы белән аның каләме тудырган геройлар арасындагы якынлык «Кеше китә — җыры кала» әсәрендә аеруча нык сизелә. М. Мәһдиев үз геройларына битараф түгел, ул аларның уңышларына сөенә, ялгышларына көенә. Тормыш буйлап кулга-кул тотынып, җилкәгә-җилкә терәп бергә атлый.

Ат кешнәве, эт елавы, арышның серкәгә утыруы, яфрак лепердәве, Сабан бәйрәме турында язсынмы, кешенең олы дөньядагы урыны турында уйлансынмы,— һәммәсе артында язучының шәхси кабул итүен күрәсең, нечкә күңелен сизәсең. Үзәктә — кеше җаны. Ул аның һәр борылышына игътибарлы.

Табигать белән кеше — М. Мәһдиев өчен аерылгысыз төшенчәләр. Тирәлек тормышында ул кешеләргә хас чалымнарны күрә. «Арыш басуы иртәгә кияү куенына керергә тиешле җиткән кыз кебек дулкынлана, тигезсез сулый, үзенең яшьлеге белән саубуллаша».

Өлкән буын бу матурлыкны үзенчә күрә. «Җылы, сөремле кич. Кайдадыр яңгыр ява булса кирәк, йомшак кына гөрелдәү ишетелеп ала. Мондый вакытта киләчәккә план кору уңай». Шәяхмәт, шул матурлыкка сокланып, рухланып, «ни ултара, ни пултара» булып «галахлыкта» йөргән улына киңәшләрен бирә.

Табигать сурәтләре кеше күңеленә, холкына, рәвешенә якын, шуңа үрелеп үсә. Шуның өстенә этләр сугыш афәтен кешеләр төсле кабул итә, кара туры ат та «хәвеф сизә».

Язучы һәр персонажының холкын, фигылен, мәсләген, үсеш дәрәҗәсен ачып бирердәй тел бизәкләрен эзли. Германиядә әсирлектә булганы өчен Улибаева тарафыннан «немец шпионы» дип мәсхәрә ителгән Шәйхи хәлфә «борчак сибәргә», чуар итеп сөйләргә, табигать сынамышларын кабатларга ярата.

Имче-томчы Хәбирә карчык надан кешеләрне алдап үз көнен күрә, ялганын яшерер өчен, томанлы, кинаяле сөйләмгә мөрәҗәгать итә. «Үлмәсә, әле дә исән буласы икән, исән булса Гарәбстанда җимешлектә йөрүе күренә»,— дип, сугыштагы малае турында юрауны сорап кергән Фәхернисаны шомартып чыгарып җибәрә. Кызмача Хисмәт, авылдашлары белән саубуллашканда да, үлеме алдыннан Гитлерны әрләгәндә дә, фикерен «едва ли» белән хуплап бара. Башкача була алмый, нәкъ шулай сөйләргә тиештер бу кешеләр дигән фикергә киләсең.

Кызып, кабынып китүчән, усал телле кешеләрне яратып тасвирлый М. Мәһдиев. Әйтик, ике явызның берсе, уңган, чибәр, теленә шайтан төкергән Васфикамалга җылы мөнәсәбәтен яшерми язучы. Кешеләрнең тышкы кыяфәтенә ул бик игътибарлы: «икенче бер чөгендер борынлы кеше кызыл башлы шырпы сата», «кызыл битле», «йөзләре чөгендердәй кып-кызыл» кебек бизәкләрдә шәхси мөнәсәбәт ачык сизелә. Болары авторның яратмаган кешеләре булыр.

Фикер иркенлеге, көчәнмичә язу шул сыйфатлардан килә. М. Мәһдиев иҗатына гомуми бәя биреп, Гариф Ахунов болай дип язган иде: «Сугыш һәм сугыштан соңгы авыл татар әдәбиятында 50—60 нчы елларда да күп сурәтләнгән иде, ләкин аны берәү дә М. Мәһдиев ачкан катламнарда ача алмады. Мәһдиев сугыш чорын хәзерге чор биеклегеннән чыгып язды, төрле-төрле катламнарны кеше хәтере дигән бик шәп җилем белән бербөтен итеп җыйды... Гомере буена туган авылына тугры булу Мәһдиевне әдәбиятның зур юлына алып чыкты».

Сораулар һәм биремнәр

1. Мөхәммәт Мәһдиев иҗатына гомуми бәя бирегез. Әсәрләренең төп сыйфатларын билгеләгез.

2. Халыкның тоталитар системага буйсынуын автор ничек аңлата? Колхозларга карата бәя төрлелеге кайларда күренә?

3. Аерым гаилә белән тарихи вакыйгалар арасындагы бәйләнешләр Шәяхмәт карт гаиләсе язмышында ни рәвешле ачыла?

4. Татар авылы кешеләре башына төшкән фаҗигаләр очраклымы? Аларның үзләренә генә бәйлеме?

5. Тормышларын башлап кына җибәргән Нариман белән Зөлфиянең киләчәген ничек күз алдына китерәсез?



ПОЭЗИЯ

Әхсән Баянов
(1927)

Әхсән Баянов — татар укучысына таныш һәм якын исемнәрнең берсе. Ул — дистәдән артык шигырь китабы чыгарган, «Яшьлегемне эзлим», «Ут һәм су», «Таш китап», «Тау ягы повесте», «Аязучан болытлы һава», «Тавыш — табигать бүләге», «Аргы як» кебек проза әсәрләре, «Һәйкәл», «Алтын каш-бау» шигъри драмаларын иҗат иткән, әдәби җәмәгатьчелек арасында яңалык эзләүче буларак танылган, Татарстанның халык шагыйре.

Аның «Еллар тавышын тыңлыйм» (1962), «Мәңге зәңгәр күгебез» (1966), «Сез аңларсыз мине» (1971), «Язмыштан узмыш» (1975), «Елларга сәяхәт» (1977), «Аязучан болытлы һава» (1981), «Таш китап» (1984) кебек җыентыкларын укучы җылы каршы алды. Бу әсәрләре белән Ә. Баянов үзен киң колачлы, романтик омтылышны аек фикер, фәлсәфи эчтәлек белән кушып алып барырга сәләтле, үзенчәлекле сүз остасы итеп раслады.

Проза һәм драма әсәрләрендә дә Ә. Баянов дөньяны һәм кешене күбрәк шагыйрь буларак кабул итә һәм сурәтли. «Яшьлегемне эзлим» — шагыйрь каләме белән язылган проза әсәре»,— дип билгеләп үтүе белән тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин хаклы иде.

Ә. Баяновның 1959 елда «Диңгез шавы» җыентыгы белән башланып киткән иҗат юлы әлегә чын-чынлап өйрәнелмәгән. Иҗат биографиясе дә тәфсилле итеп язылмаган.

Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов 1927 елда Башкортстандагы җырга-көйгә бай Илеш районының Әшмән авылында туа. Күрше Ишкарда җидееллыкны тәмамлагач, колхозда эшли.

Район мәдәният йортында сәнгать бүлеге җитәкчесе була. Әдәбиятка мәхәббәте аны, читтән торып урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Тулысы белән язучылык хезмәтенә күчкәнче, ул күп еллар дәвамында журналист һөнәре белән шөгыльләнә, «Казан утлары» журналында җаваплы эшләр башкара.

Катып калган, искергән, җөйләре сүтелгән йолаларга беренче әдәби тәҗрибәләреннән үк каршы чыккан, заманча уйларга һәм язарга омтылган сүз остасының татар әдәбиятында тәгаен үз урыны бар.

Ә. Баянов — татар шигъриятендә салмак агышлы, тирән фикерле, уйланып нәтиҗә ясауга өстенлек биргән юнәлеш тарафдары. Хисләрнең салмак агышы, эчкәртен яшәве әле салкынлык, битарафлык дигән сүз түгел. Шагыйрь чордашының рухи эзләнүләрен бөтен нечкәлекләре, төрле-төрле төсмерләре белән ачу юнәлешендә хәрәкәт итә.

«Сез аңларсыз мине» поэмасы басылып чыккач, тәнкыйтьтә Ә. Баянов тар, субъектив кичерешләре белән артык мавыга, әрнү, сыктау, сызлану кебек хисләрне үзәккә алырга ярата дигәнрәк фикерләр дә әйтелде. Тормышта бит кайгы-хәсрәте дә, авырлыгы да булып тора, барысы да кеше башыннан йөри. Шагыйрь явыз хакимияткә, фашизмга, бозык әхлаклы шәхесләргә карата үзенең нәфрәтен белдерә. Шул ук вакытта яшьлеге авыр сугыш елларына һәм аннан соңгы михнәтле елларга туры килгән яшүсмер тормышның матур яклары, күңелдә якты, җылы эз калдырган сәхифәләре, шулар кабызган өмет белән яши.

«Дәрья эчендә янып», «Безнең күгебез», «Мин — диңгез», «Йолдызлар коелды», «Гомер — биек тау бугай ул», «Көзге урман», «Икмәк», «Төнге бәхәс» кебек шатлык һәм кайгы, табигать күрке һәм тормыш низаглары турында уйланулар рәвешендә язылган шигырьләренә замана нурлары сирпелә, тормышчан рух иңә. «Кимә, бәгърем, кара күлмәк, Син ки һаман Кояш нурларыннан тукылган кызыл-сары күлмәк»,— ди ул «Кимә кара күлмәк» шигырендә.

Ә. Баянов шигъри сүзнең кадерен белгән, рухи әзерлекле укучыны күздә тотып иҗат итә. Аның остазлары — Һ. Һейне, М. Лермонтов, Г. Лорка, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләр.

Төрле әдәби жанрларда көч сынавы, теленең иркенлеге, фикер белән хиснең бердәмлегенә омтылуы, иҗади тынгысызлыгы белән ул Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ә. Давыдов кебек язучылар-

га якын тора, шигъри драмаларында исә Һ.Такташ, М. Җәлил, Н. Исәнбәтләр тәҗрибәсенә таяна. Бу яктан караганда, «Алтын кашбау» (1987) трагедиясе шагыйрьнең зур уңышы булды.

Хыял канатларында ерак тарихка юл алып, Ә. Баянов чәчәк атып утырган Болгар иленең Бату чирүләре тарафыннан җимерелү, хәрабә хәленә китерелү вакыйгасын үзәккә ала. Авыр сынау чорында кешеләр икегә бүленә. Галим, шагыйрь, фикер иясе Баян, Алсылу кебекләр дошманга каршы дәррәү күтәрелә: алар я җиңә, я үлә... Үз мәнфәгатьләре белән генә яшәгән, илен, халкын сату исәбенә булса да гомерен озынайту турында гына кайгырткан Балтамар, Изух кебек бәндәләр дошман ягына авыша, үз халкын кыса, изә, җәзалый. Балтамарны агулап үтергән Алсылуның хөкеме заманча яңгырый: «Җыен хәшәрәтне өскә алып чыккан Дәүләт үзе чыгачактыр юкка».

Әхсән Баяновның шигырьләренә кыскалык, фикер төгәллеге, сурәтле янәшәлекләр һәм ритмик төрлелек хас. «Уйладым да кабат», «Элегия», «Сөйгән җирем», «Агып бара...», «Тыйнак кеше турында баллада» кебек әсәрләрендә ул рухи дөньяны сурәтләү алымнарын һаман саен камилләштерә бара. Озак еллар дәвамында эзләнүләрен бер юнәлештә үстерүе аның омтылышлы, максатлы һәм үзенчәлекле шагыйрь булуы турында сөйли.

Тирә-юньдә, кеше күңелендә барлыкка килгән үзгәрешләрне рухы, йөрәге, шәхси кайгысы итеп сурәтли белгән шагыйрьнең тормыш тәҗрибәсе үсә баруы, шәхес буларак өлгерүе «Сәяхәтнамә»дә ачык күренә. Хәзер шуны укып, аңлатып карыйк.

«Сәяхәтнамә»

(1969)

Ә. Баянов бу әсәре белән, табигатьне, авылны һәм халык әхлагын, гореф-гадәтләрен яклап аваз салып, җәмәгатьчелекне сискәндереп җибәрде. Ул, беренчеләрдән булып, яңа шәһәрләр, ясалма диңгезләр төзүнең, тирәлекне пычратуның киләчәк өчен нинди куркыныч алып килүен искәртте, шигъри йөрәге белән шул афәтләргә каршы күтәрелде.

Татарстан җирендә бу чорда ифрат зур үзгәрешләр хасил булды. Татар нефте илне туйдыра, кешене галәмгә алып чыга, «Канатларын җилпеп бөркеттәй, краннарын изәп биеклеккә, Түбән Кама шәһәре балкый», аның белән ярышка Чаллы кала-

сы чыга. Юлына ясалма буа күтәртеп, күпер салынган Чулман елгасы үләнле болыннарны, кара урманнарны, уңдырышлы җирләрне мәңгегә үз астында, су эчендә калдыра. Сандугач, кәккүк тавышларын машина гүләве алыштыра. Хәйләкәр төлке дә йомшак якаларда, затлы бүрекләрдә генә «яши».

Вакыт һәм җил — сугыш кебек,
Чакырылмаган яулар кебек,
Афәт кебек, бәла кебек.
Койма ватып, капка җимереп,
Җитәкләшеп өч исерек:
Җил, гамьсезлек, өметсезлек
Йөри тилереп өйдән өйгә.
Авыл туза бөтенләйгә.

Адәм баласы үзенә янаган афәтне сизми әле. Кичәге игенче бик теләп эшче вазифасын үти башлый. Яшеллеккә күмелеп, гөрләп утырган авыллар юкка чыга. Сала егете, каланың бизәкле утларына, мич якмыйча җылынган торагына, краннан аккан суына кызыгып, салкын чишмәсен, сандугачлы әрәмәсен ташлап китә. Туган җиренә урлагән һәлакәтне сизми, ул — ваемсыз, гамьсез.

Ава койма, ава читән.
Ир төзәтми: «Тиздән китәм».
Авыл күчә, сүзләр оча:
— Без бу җирдә вакытлыча.

Күнегелгән тормыш, гасырлар чатында туган йолалар югала, җырлар онытыла, ана теленең хаҗәте калмый.

«Җырлагыз, кошлар, таныш миңа шундый матур сезнең телегез»,— дип, шагыйрь кошларга мөрәҗәгать итә. Кошлар җыры, ана теле кебек үк, күңелгә, җанга, йөрәккә якын. Әмма шау-шулы калаларда аларның икесенә дә урын юк.

Кешегә, аның яшәешенә гайре табигый көчләрне адәм баласы үзе тудыра, үзе хәрәкәткә китерә. Көндәлек вак-төяк борчылулары, тамак туйдыру мәшәкатьләре белән мавыгып, ул табигатьнең юкка чыгу һәлакәтен шәйләми, тиешле бәясен бирми.

Гаеп аерым шәхестә генә дә түгел. Җитмеш ел дәвамында Совет хакимияте һәр яңа буынны тирәлекнең дошманнары итеп тәрбияләде, мул, рәхәт тормышка табигатьне ерткычларча талау исәбенә ирешеп була дип ышандырырга тырышты, табигатьне «авызлыклаган» кешеләрнең түшләренә орденнар,

медальләр такты. Казылма байлыкларга, уңдырышлы җиргә иң бай илдән Россия хәерчеләр рәтенә төште.

Табигатьнең зарын, моңын шагыйрь йөрәге тизрәк, җиңелрәк аңлый.

Күренми шул монда җәнлек эзе,
Кәккүк тавышлары ишетелми.
Болын буйлап, ерак урманнарга
Кача тынлык, җәнлек шикелле.

Шул юл белән барып, искерде, кечерәйде дип, үзебезне анда кунак итеп кенә санасак, Җирне дә ташлап китәргә генә кала. Ничәмә буынны куенына сеңдергән, халык өчен яшәеш, рухи ныклык чыганагы булган Татар җире — шагыйрь өчен изге төшенчә.

Шуннан килеп, ул табигатьне, тормышны сакларга өндәп чаң суга.

Чаң кагам мин:
— Бар халыклар!
Барлык теләк-гадәтләрне
Буйсындырып бары акылга,
Кул бирегез бер-берегезгә
Җир хакына, яшәү хакына!

Тарихның усал җилләренә бирешмәгән мәрхәмәтле туган туфракны саклау, яклау кирәклеген бер Әхсән Баянов кына калкытып куймый, әлбәттә. Бу афәт бик күпләрне борчый. Яшәешне саклап калу өчен көрәштән бер генә язучы да читтә кала алмый. Шагыйрь заманның иң тынгысыз урыннарында йөрергә тиеш.

«Сәяхәтнамә» шикелле үк уңышлы әсәрләрнең берсе Илдар Юзеевнең «Карурман» (1976) поэмасы булды. Үзәктә үткәнне санга сукмау, ваемсызлык, нигилизм алып килгән рухи гариплек темасы ята. Егет бабасының телендә, күңелендә яшәгән карурманнар сагышыннан көлә, үткәненнән кискен баш тартып, йолдызларга юл ала.

Ә мин әйттем: «Киләчәккә барам,
Тукталырга вакытым юк әле.
Сезнең җирле микрохисегездән
Безнең уйлар бик-бик югары».

Хискә, тойгыга бай, кайнар хисле, тынгысыз уйлы табигать баласы — бабасы — үзенең оныгын күрмичә, «Санду-

гачлар... Чишмә... Карурман...» дип өзгәләнеп үлеп китә. Оныгына васыятен әйтеп калдыра: «Кайтсын... астан өскә карасын...»

Замана баласы, кирелеген-үҗәтлеген, икеләнү-шикләнүләрен җиңеп, бабасын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә, җылы туфракка тезләнә.

«Сәяхәтнамә» белән «Карурман» әсәрләре, тышкы дөньяда туган тискәре күренешләргә җавап, җан әрнүе буларак туып, кешене саклап калу өчен көрәшкә чыгалар.

Гүзәл табигатьнең дошманы — кеше үзе дигән фикер якынлаштыра ике әсәрне.

«Сәяхәтнамә»дә дә, төнге Кама, Табигать-Анадагы матурлыкны «бер югалтсаң булмый табып» дип, баланы искәртә. Әмма ул ваемсыз, үзсүзле, кире, киләчәк турында уйламый.

Хаклы да син, ана, тик хаксыз да...
Һәм еракта балаң, еракта.
Мин дә менә синнән ары китәм,
Үзәннәр һәм ярлар буйлата.

Илдар Юзеевнең лирик герое да билгесезлеккә ашкына.

Карурманнан атың чыккан чакта,
Йолдызларга, бабам, карарсың.
Оныгыңны җирдән эзләмә син,
Галәм юлларында табарсың.

Ахыр чиктә, егетләрнең икесе дә туып үскән җирләренең кадерен белү, табигатьне саклаучылар, яклаучылар дәрәҗәсенә күтәрелә. «Күпме генә биек менсәм дә мин, юк, егылмам хәзер, ышанам»,— ди «Карурман» герое.

«Сәяхәтнамә» — шартлылыкка корылган әсәр. Тынлыкны, акрын кыштырдауны эзләп, шагыйрь күпне күргән, чал тарих шаһиты Кама елгасына мөрәҗәгать итә, ыгы-зыгыдан чатнаган башына, җанына таяныч эзләп, Табигать-Ана янына килә. Табигать шавы аңа бишек җырыдай рәхәт һәм якын.

Шигъри шартлылык алымы үстерелеп киңәйтелә бара. Су төбеннән сәер тавышлар килә. Аннан туган авылы, туфрагы, чирәме, беренче мәхәббәте кебек изге төшенчәләр аңа эндәшә, үткәнен онытмаска чакыра.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Сәяхәтнамә» әсәре татар әдәбиятына нинди яңалык алып килде? Шул хакта уйланыгыз.

2. Су астыннан килгән тавышларны, Табигать-Ана, урманнар, өйләр белән сөйләшүне ничек аңлыйсыз? Нәрсә ул әдәби шартлылык?

3. Ни өчен шагыйрь «яфрак хәтле кулы»ның «тын ярдагы яшерен ояга...» сузылуын борчылып искә ала?

4. Ә. Баянов әсәре белән И. Юзеевнең «Карурман»ы арасында нинди якынлык һәм аерма күрәсез?

5. Өлкән буыннар һәм яшьләр арасында каршылык бармы? «Ике буын — ике әхлак» дигән төшенчәләрне кулланып буламы? (Ике әсәр буенча фикер йөртегез.)

6. Туып үскән, яшәгән ягыгызда табигать үзгәрәме? Аны саклау ихтыяҗы бармы?

7. «Тау ягы повесте»н мөстәкыйль рәвештә укып чыгыгыз.

Илдар Юзеев
(1933—2004)

Татарстан Республикасының халык шагыйре Илдар Юзеев иҗат юнәлеше, омтылышлы рухы, сурәтле фикерләү үзенчәлекләре белән чордаш каләмдәшләреннән нык аерылып тора. Аның шигырь-поэмаларына, драмаларына яшьлек дәрте, эчкерсезлек, мөлаем лиризм һәм самимилек хас. Замандашларының менәзе ныгу, дөньяга карашы турында шагыйрь борчылып, дулкынланып, кирәк икән, әсәренеп яза.

Тәнкыйть И. Юзеевне бертавыштан «яшьлек һәм романтика», «матурлык һәм батырлык» җырчысы, Такташ шигъри мәктәбен үзенчә дәвам иттерүче шагыйрь дип бәяләде.

Ул «Таныш моңнар» поэмасы (1955) белән үзенә игътибарны җәлеп итте һәм тиз арада әдәбиятта үз урынын тапты, укучының яраткан шагыйре булып китте. Әлеге әсәрендә ачык төсмерләнгән кичереш һәм фикер бердәмлегенә, чынбарлык алып килгән катлаулы мәсьәләләрне лирик моңга, җырга, көйгә үреп хәл итүгә омтылу бөтен иҗатына хас.

Алдагы елларда аның поэзиясе иҗтимагый эчтәлек ала, кеше рухының бөеклеген, татар тарихының олылыгын ачуга, явызлыкка, мәкергә, ялганга, битарафлыкка каршы көрәш рухы белән тулылана, байый. «Әнкәй» (1959), «Язылмаган поэма» (1964), «Өчәү чыктык ерак юлга...» (1965), «Тынлык белән сөйләшү» (1966), «Соңгы сынау» («Соңгы төн», 1968), «Канкай углы Бәхтияр» (1970), «Таш диварлар авазы» (1973), «Өзелмәс кыллар» (1977), «Мәхәббәт китабы» (1979), «Очты дөнья читлегеннән» (1980), «Мәңгелек белән очрашу» (1982) кебек лирик тарихи, драматик поэмаларында, замандашлары белән беррәттән, гомерләрен халык бәхете өчен көрәшкә ба-

гышлаган Бәхтияр Канкаев, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәйретдин Мөҗәйләр эшчәнлеген, батырлыгын, бөеклеген ачуга зур өлеш кертә.

Илдар Юзеев шигырьләренә хас төгәллек, пөхтәлек, тирән моң һәм ачык фикер композиторларны иҗатка рухландырды. Аның «Яшь наратлар» (Җ. Фәйзи көе), «Кайтам инде» (С. Садыйкова), «Серле чәчәк» (М. Яруллин), «Мәтрүшкәләр» (Алмаз Гыйләҗев), «Кыр казлары артыннан» (М. Имашев), «Сине уйлап янам» (С. Ибраһимов) кебек җырлары тыңлаучының күңеленә, рухына хуш килде.

Шуның өстенә И. Юзеев — чорыбызның танылган драматургы. Аның «Янар чәчәк», «Бөркетләр кыяга оялый», «Кыр казлары артыннан», «Бәхетемнән узып барышлый», «Онытылмас бәет», «Гомернең алты сәгате» кебек җырлы комедияләре һәм драмалары Татарстанның, илебезнең бик күп театрларында уңыш белән бара. Аларның үзәгендә яткан тормышчан башлангыч заман һәм кеше арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр-карашлар бәрелеше, хис тирәнлеге, табигать матурлыгы һәм бай тел бизәкләре аша ачыла.

Әдәбиятның тарихи үткәнне, фәлсәфи-иҗтимагый мәсьәләләрне, киләчәкне сурәтләү юлындагы мөмкинлекләрен киңәйтергә омтылып, И. Юзеев ифрат көчле шартлы алымнарга, символик образларга, шигъри трагедия жанрына мөрәҗәгать итә. Кыскасы, иҗади эзләнүләрен төрле юнәлешләрдә алып бара.

И. Юзеев әсәрләренең үзәгендә ашкынулы, ярсулы, ярты юлда туктап кала алмый торган көчле шәхес тора. Аның кайнар хисләре, теләк-ниятләре сине яндырып үтә. Мисал рәвешендә «Шундый безнең егетләр», «Светлана», «Ике малай китә армиягә», «Егет күңеле далада», «Буран» кебек шигырьләрен атап була. «Табигатем минем ерганактай, шау-шуларга, алга омтыла»,— ди шагыйрь үзе турында.

Иҗатының шул сыйфатына С. Хәким югары бәя бирә. «Илдарның иҗаты башыннан ахырына чаклы яшьлек турында: аның чордашларыннан бу теманың стихиясенә кереп, тәмам үзенең романтикасына әйләндергән башка бер шагыйрь дә юк. Ул, картайганчы, яшьлектән айный алмый торган шагыйрь булып калачак». Чыннан да, ул яшьләрнең рухи эзләнүләре, мәхәббәт сагышлары, ләззәт-шатлыклары турында дәртләнеп, күңел кыңгырауларын тибрәндерерлек итеп яза.

И. Юзеев — лирик-романтик табигатьле шагыйрь. Ул поэмаларында гына түгел, хәтта драматик әсәрләрендә дә тормышны шигъри чаралар ярдәмендә иңли.

Шул ук вакытта шагыйрь, дилбегәне тулысынча «лирик стихия» кулына тапшырып, вакыйга агышыннан, кешене мохит, хәлләр эчендә тасвирлаудан баш тартмый. Яшьлек һәм мәхәббәт, тормыш һәм әхлак темаларын үзәккә алган «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасы — шуңа ачык дәлил.

Бер караганда, үзәктә — гадәти эчтәлек. Фазылҗан, Нур һәм сөйләүче зат ямьле табигать кочагында «бергә шаулап», «яшел чирәмнәрдә аунап», дус, фикердәш булып үсәләр һәм «тормыш көймәсенә ишкәк тотып» бергә керәләр.

Өч дус... Өч язмыш... Бәхет таңы, сөеләчәк һәм сөячәк ярлар шатлыгы әле алда.

Гомернең чәчәк ату, җитлегү, олы тормышка аяк басу чоры — яшьлек — И. Юзеев өчен кеше яшәешенең иң гүзәл, җаваплы һәм четерекле чоры. Бу гадәти халәт түгел. Сюжет өлгесе итеп шагыйрь хәтәр сынау, әхлакый борылыш вакытын ала һәм аны, соң чиккәчә үстереп, хәтергә сеңеп калырлык итеп, хәрәкәттә, үсештә сурәтли.

Сезнең алда ике юл бар,
теләсә кайсын сайлагыз
үзегез,— ди кәккүк! —
Алда әле борылмалар бик күп, кәк-күк!
Я түзегез,
я китегез
кирегә,
хәл итегез
үзегез, — ди кәккүк! — Кәк-күк!

Зәңгәр күк гөмбәзе астында урыныңны табып, үзеңне раслаганчы, син тормыш сынавын үтәргә, үз юлыңны тынгы белми эзләргә тиеш. Юл — поэмада үзәк образ. Биредә ул гадәти кулланышта түгел, ә киң мәгънәдә алынган. Күп юллы, күп сукмаклы тормышта, яшәештә үз кыйблаңны табу һәм раслау хакында сүз бара биредә.

Америка язучысы Э. Хемингуэй: «Беркайчан да югалмый торган нәрсәне табарга кирәк»,— дигән. «Югалмый торган нәрсә» — олы тормышта үз юлыңны табу һәм кешеләргә файдалы булудыр ул, бәлки.

Кешегә гомер бер генә бирелә, ике тапкыр яшәп булмый дип, Фазылҗан җиңел язмышны сайлый. Аның яраткан җы-

ры да шул рухта: «Әйттер, типтер, сиптер, әйдә, без җирдә кунак кына!»

Кара бөдрә чәчле Фазылҗан — моңлы, көйле, Такташның Мокамае төсле, һәр эшкә сәләтле егет. Әмма тормыш — көймә, гел ишеп тормасаң туктап кала икән.

«Әйттер-типтер» көе белән чыгып югалган Фазылҗан җинаятьчелек юлына баса һәм ахырда рәшәткә эченә килеп эләгә. Лирик герой аны соңгы мәртәбә суд залында күрә.

Фазылҗанның яшьлек дуслары кырыс язмыш реализмын, эзләнүләр һәм табышлар юлын сайлыйлар. Нур зур корабның капитаны булып китә. Сөйләүче шигырь диңгезенә юл ала, үзен шунда раслый. Авырлыкларга тешне кысып түзеп, бу ике дус үз юлларын табалар. Фазылҗан үзен югалта.

«Быргы кычкыртып, гармун тартып кына сәфәргә чыккан өч яшүсмернең язмышы җиңелләрдән булып чыкмый. Өч яшүсмер, өч төрле язмыш... Уен һәм көлкедән генә тормый икән тормыш дигәннәре. Әнә шул җитди, тормышчан проблемалары белән уйландыра әлеге әсәр»,— дип яза Р. Мөхәммәдиев И. Юзеевнең «Мәхәббәт китабы» (1982) исемле җыентыгына кереш сүздә.

Шагыйрь әхлакый эзләнүләр, ачы югалтулар, авыр юллар илткән киләчәк турында җитди итеп яза.

Шигъри әсәр вакыйга-хәлләрне эзгә-эз бәян кылуны, сөйләп бирүне өнәми. Өч егетнең кыяфәтләре, алдагы көннәрдәге язмышлары әсәрнең тышында кала. Язучыны, вакыйгалар җебеннән бигрәк, шәхеснең рухи дөньясы, аның киеренке әхлакый эзләнүләре, давыллы-яшенле, җилле-яңгырлы каршылыкларның чишелеше борчый, уйландыра.

«Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасының шигъри яңачалыгы

Шагыйрь хәтер канатында яшьлегенә әйләнеп кайта, «су өстендә чалкан яткан чакларын» искә төшереп, гомер йомгагын сүтә башлый. Аның фикерен бик күп язмышлар шаһиты кәккүк раслап бара.

> Көймә килә, көймә килә,
> өчегез дә уникедә,— ди кәккүк!

Яшьлек — гомер диңгезенең чишмәсе. Шуңа күрә «балачакны искә төшергәндә, дәрәҗәләр-ниләр онытыла».

Шул рәвешле, әсәрнең үзәгендә истәлек-хатирәләр, балалык еллары сәхифәләрен яңарту ята. Бу алым шагыйрьгә табигатьтән, тирәлектән кичереш тирәнлеген ачардай сурәтләрне «эшкә җигәргә», үстерергә мөмкинлек бирә.

Беренче рәттә матди дөньядан алынган кәккүк, көймә, урман («Урман арасы, безгә ерак әле барасы»), гомер агышын хәтерләткән чабыш атлары кебек образлар тора. Алар туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә ачылган, эчке дөньяны, тормышта үз урыныңны эзләү һәм табу авырлыгын раслауга, күрсәтүгә буйсыналар.

Кәккүк үз югарылыгыннан яшьләрне гел күзәтеп, искәртеп, киңәшен биреп, әйтеп тора. Ул — үсмерләргә теләктәш, аларга яхшылык теләүче, дуслык кадерен белергә чакыручы итагатьле изге җан. Кәккүк гомерне заяга, бушка исраф итүгә каршы.

«Фазылҗан,— ди кәккүк.—
Көймәдә кит, дусларыңны ташлама,— ди кәккүк,—
ташлама,
гомер юлы әнә шулай башлана,— ди кәккүк,—
башлана».

Игътибар итегез: кәккүк биредә нәкъ кеше төсле сөйли, киңәшен бирә. Икенче урында шагыйрь, урман, әрәмә кошына мөрәҗәгать итеп, фикеренең дөреслеген яисә ялгышлыгын раслауны сорый, үтенә.

Кай юллардан барыйк икән,
әллә туктап калыйк микән, әйт әле, кәккүк!

Кәккүкне шулай «үстерү», мөстәкыйль әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрү тикмәгә түгел. Татар халкының бик борынгы чордан килгән ышанулары буенча, кәккүк — кеше гомеренең дәвамлылыгын әйтеп бирүче, күрәзәче кош. Җәйнең билгеле бер вакытында аның кычкыруын санап, кешенең калган гомерен әйтеп бирергә тырышканнар бабайлар.

Кәккүк яшьләргә хәтта әкият-вәгазен дә әйтеп сала:

Егет бәхет эзләп киткән, ди,
ике юл чатына җиткән, ди,
баганага такта кагылган,
ә тактага болай язылган:
«Уңга китсәң — авыр, әмма
бәхет ишеген ачар,— ди икән,—
сулга китсәң — җиңел, әмма
бәхет синнән качар»,— ди икән.

Матди тирәлектән алынган, авторның фикерен, теләген, ниятен укучыга җиткерүдә зур әһәмияткә ия образның икенчесе — көймә.

Татар халкының «Көймә генә килә генә» исемле шаян рухлы, шук табигатьле җыры һәркемгә таныш. Н. Арслановның «Көймәдә» шигырендә бу образ — аңлашу, йөрәк серләрен ачу чарасы. Ул — мәхәббәт арадашчысы.

И. Юзеев көймәнең мәгънәви яңгырашын киңәйтә. «Көймә килә, өчегез дә уникедә,— ди кәккүк!» җөмләсе белән килеп кергән көймә сурәте киңәя, үсә бара, «тормыш көймәсе» дигән фәлсәфи мәгънә ала. Көймә гомер диңгезенә алып чыга.

Җиде көн, җиде төн дигәндә,
алланып таң атып килгәндә,
ниһаять, күренде киң Идел!

Көймә, ишкәк — олы юлга алып чыгучы ярдәмчеләр. Әсәрнең бетемендә шагыйрь янәдән шуларны искә ала.

«...Өчәү чыктык ерак юлга,
өчебез.
Ишкәк тотып нәни кулга
өчебез».

Икенче рәттә рухи дөнья белән бәйле җыр, көй, моң, уй кебек сурәтләр килә. Шулар белән янәшәдә үк татар халык җырларының нигез образлары — болытлы көн, караңгы төн тезелеп китә. Әкият серлелеге, атын яр буенда туктаткан Төн кешесе образлары поэмага үзенә бер ямьле, гаҗәеп матур яңа дөнья рухы бөркиләр. Әсәр «Кара урман» кебек озын һәм моңлы, шомлы һәм гаҗәеп якын җырга охшап тора. Шагыйрь халык җырын тирәнтен сиземли, әхлакый, фәлсәфи кыйтгаларны халык йөрәгендә туган кичерешкә үреп алып бара. «Бер дә генәй нужа күрмәенчә, ир булалмый ата баласы...», «Урман арасы, безгә әле ерак барасы», «Иш, дускай! Бирешә торган малай түгел без, дускай!» кебек шагыйрь үзе иҗат иткән, әмма халык җырлары рухы, стиленең тәэсире сизелеп торган юллар яшьлек ярсуын, хис муллыгын, олуг дөньяда үз юлыңны эзләү һәм табуның авыр михнәтен ачуга хезмәт итәләр.

Матди һәм рухи дөньядан алып үстерелгән сурәтләр поэмага җылылык кына түгел, ышандыру көче дә бирәләр.

Поэма белән танышканда, ике, өч, җиде кебек саннарның еш очравына, киң кулланышына игътибар иткәнсездер. Татар

халык ышануларында, әкиятләрендә бу саннар — бик мөхтәрәм, абруйлы билгеләр. Җирнең җиде хикмәте, җиде юл чаты, җиде көн, җиде төн кебек гыйбарәләр җырларда еш очраса, тылсымлы, маҗаралы әкиятләрдә патшаның өч малае, үсеп, дошманга каршы чыкканда, алларында өч юл торыр.

Аларның берсе сандугачлы-бакчалы, җиңел бәхет вәгъдә итә, икенчесе — билгесез, томанлы, ә өченчесе — михнәтле һәм авыр. Дөрес юлны табуда баланың акыл сәләте, зиһене һәм алдан күрүчәнлеге чагылыр. Михнәтсезен сайлаганы коры чыбык төсле янып юкка чыгар, авыр язмыштан курыкмаганы ахырда бәхетле, файдалы кеше булып китәр.

И. Юзеев халык иҗатында үскән, сакланган әхлак кагыйдәләрен үзәккә ала. Шуңа күрә поэма тукымасында бу саннарның әледән-әле очравы, гомумән, җыр, көй, әкият рухының өстенлек итүе табигый.

«Бер-ике-өч!», «Өчәү чыктык ерак юлга...», «Өч ел бардык», «Җиде көн, җиде төн дигәндә» кебек юллар поэманың эчтәлеген, мәгънәсен ачуга ярдәм итәләр.

Шигъри камиллек, нәфис яңгыраш, сурәтлелек байлыгы аша Илдар Юзеев яшьлек, матурлык, туган җиренә мәхәббәт кебек олы төшенчәләрне укучы күңеленә шигъри дулкында сеңдерә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Поэманың үзенчәлеген билгеләгез, эчтәлеген сөйләгез.

2. Фазылҗанның ялгышы нидән гыйбарәт? Яшьлек дуслары аңа нинди ярдәм күрсәтәләр?

3. Шагыйрь фикерләрен, хисләрен укучыга нинди образлар ярдәмендә ирештерә?

4. Нәрсә ул җанландыру һәм шартлылык? Кәккүккә йөкләтелгән мәгънәләрдән чыгып аңлатыгыз.

5. Кәккүк, көймә образлары белән бәйле җырларны искә төшереп, җырлап карагыз.

6. И. Юзеев иҗатыннан «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасына якын әсәрләрне табыгыз һәм чагыштырулар ясагыз.

7. «Мәңгелек белән очрашу» әсәрен укып анализлагыз.

8. Поэма нигезендә әдәби кичә уздырыгыз.



ДРАМАТУРГИЯ

Туфан Миңнуллин

(1935)

70 нче еллардан алып соңгы көннәргә кадәрге татар драматурглары исемлеге Туфан Миңнуллин белән башланып китә. Менә дүрт дистә елдан артык инде ул милли сәхнәне тота, аны яңадан-яңа образлар белән баета. Ягъни милли театрны темалар яңалыгы, сәнгатьчә чаралар байлыгы ягыннан үстерә. Бу яктан ул әдәбиятыбызда Г. Исхакый һәм Г. Камал, К. Тинчурин һәм Н. Исәнбәтләр традицияләрен уңышлы дәвам итә.

Әдәби иҗат юлы

Язучының бала чагы дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Бу чор фидакярлек, түземлек, батырлык ягыннан олыларны гына түгел, балаларны да сынады. Авыр хезмәт белән дә, ачлык һәм ялангачлык белән дә...

Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 елның 25 августында хәзерге Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында дөньяга килә. Улында әдәби зәвык тәрбияләүдә әтисенең тәэсире зур була. Чыгышы белән ул — Казан кешесе, заманында Гафур Коләхмәтовтан белем алган. Алар укыган мәктәпкә Тукайның килүе, яхшы укучыларга китаплар өләшүе кебек истәлекләрен улына кат-кат сөйли. Габдулла агай, гомумән, кызыклы шәхес була, аның тормыш юлы да катлаулы һәм кызыклы: дары заводы эшчесе Габдулла Миңнуллин 20 нче елларда авылга китә, авыл Советы секретаре булып эшли. Ул анда беренче мәртәбә радио керткән, велосипед алып кайткан.

Беркадәр вакыт колхоз рәисе булып эшләгән. Габдулла агай үгет-нәсыйхәтле шигырьләр язган, экиятләр чыгарган. Малаена шул елларда дөнья шаулаткан шагыйрь исемен кушуы да аның әдәбиятка гашыйк булуын күрсәтә.

Башлангыч белемне авылларында алгач, Туфан күрше Олы Салтык авылында җидееллык, Олы Карамалыда (язучы Ибраһим Гази авылы) унъеллык мәктәптә укый. Стена газеталары чыгаруда бик теләп катнаша, аларда өйрәнчек шигырьләрен бастыра.

Белемгә омтылыш һәм әдәбиятка мәхәббәт Т. Миңнуллинны Казан университетына алып килә. Әмма сугыштан соңгы авыр еллар, гаиләгә ярдәм итү кирәклеге яшь егетнең тормыш юлына үзгәрешләр кертә: ул туган авылына кайта, төрле эшләрдә эшли. 1956 елда университетка кабат килә, ләкин, күп тә үтми, Мәскәүгә, театр училищесына укырга китеп бара.

Т. Миңнуллинның әдәби иҗат белән чынлап торып шөгыльләнә башлавы да Мәскәүдә укыган елларга туры килә. Дөрес, ул язганнарын бастырырга ашыкмый, «Насыйбулла боткасы» дигән һәм башка шундый кулдан тегеп эшләнгән «китаплар чыгару» белән чикләнә. Шулай да инде киләчәк өчен шактый «мая» туплана, мәсәлән, «Азат» исемле соңыннан аерым китап булып басылып чыккан экият-пьесасы шул елларда ук язылган.

Щепкин исемендәге театр училищесының 1961 елгы чыгарылышы яшьләре (бүгенге танылган сәхнә осталары Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Наил Дунаев, Гөлсем Исәнгулова һ.б.) белән бергә, Т. Миңнуллин да Казанга кайта. 1964 елга кадәр Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли. Әмма яшьтән үк тынгылык бирмәгән, студентлык елларында инде төн йокыларын качырган «язучылык җене» аңа уен сәнгате белән чын-чынлап шөгыльләнергә ирек бирми: журналистикага күчеп, «Чаян» журналында, Казан телевидениесендә эшли. Аның юмористик сәләте ачылып китә, шактый санда көлкеле хикәяләр һәм «уклы-камчылы» фельетоннар яза, кече күләмле сәхнә әсәрләре иҗат итә.

Шулай итеп, беренче карашка Т. Миңнуллин — әдәбият һәм театр мохите тәрбияләп үстергән талант. Театр училищесында уку (соңрак ул Мәскәүдә Югары әдәби курслар да тәмамлый) һәм Г. Камал театрында эшләү еллары, аннары телевидение һәм «Чаян»да эшләү чоры аны әдәбиятның авыр

төрләреннән булган драматургияне үзләштерү өчен әзерлиләр. Ул сәхнә сәнгате серләренә төшенә, аның үзенчәлекләрен, тамашачы белән бәйләнеш булдыру өчен нәрсәләр кирәген белергә өйрәнә. Әмма бу талантның ачылып китүендә, мул җимешләр бирә башлавында тормыш, аны яхшы өйрәнү, кешеләрне белү, аңлый алу — төп сәбәпчеләрдән берсе. Т. Миңнуллинның беренче пьесаларына ук заманны һәм кешеләрне аңлау, көн сорауларына, заман агышына сизгерлек хас. Боларын исә иҗат кешесендә тормыш үзе булдыра һәм үстерә.

Чыннан да, үз-үзен белә башлаганнан алып Мәскәүгә укырга киткәнче, булачак язучы авыл һәм аның кешеләре тормышы белән яши. Ә авыл аңа бик күпне бирә. Авыр сугыш еллары, сугыштан соңгы хәерче һәм мәшәкатьле дәвер крестьян алдына күптөрле мәсьәләләр куйды, аларны хәл итәргә, авырлыкларны җиңә белергә өйрәтте. Крестьян (ә сугыш елларында аның төп өлешен хатын-кызлар һәм яшүсмерләр тәшкил итте) төп бурычын намус белән үтәде: фронтны азык-төлек белән, чимал белән тәэмин итте. Икмәк үстерүдә, мал-туар асрауда, хуҗалык алып баруда ул елларда әллә кайчангы бабайлар ысуллары киредән кайтты. Бу чор баласы буларак, Туфан, «уфалла» арбасына җигелеп, урманнан утын да ташыды. Сыер җигеп, анысы да булмаганда, кул белән тартып, иске сука белән җир сукалауны да, чабагач белән ашлык сугуны да күреп һәм үзе кичереп үсте. Шуның белән бергә, тормышны танып белергә, яшәү өчен көрәшергә, гомумән, иртә уйлый белергә, олы була белергә өйрәнде.

Боларның һәммәсе яшь Туфан күңелендә җуелмас эз калдыра. Болар — драматург әсәрләренең тормышчанлык нигезләрен тәэмин итешкән башлангыч чишмәләр. Менә ни өчен аның иң беренче пьесаларына ук, алда әйтелгәнчә, заманга сизгерлек һәм авыл тормышын, аның кешеләрен яхшы белү, аларны ярату хас. Шулар һәм, әлбәттә, табигый талант Т. Миңнуллинга әдәби өйрәнү чорын чагыштырмача тиз узарга мөмкинлек бирәләр. Кече күләмле пьесалар, шаян-көлкеле хикәяләр, театрда уйналган, соңыннан аерым китап булып басылган «Азат» һәм «Айга сәяхәт» исемле әкият-пьесалар, «Безнең авыл кешеләре» дип аталган пьеса яшь авторның кыска вакытлы өйрәнчеклек чорын тәшкил итә. 1968 елда аның ике пьесасының берьюлы — берсе Академия театрында, икенчесе Күчмә драма һәм комедия театрында — сәхнәгә чыгуы милли әдәбиятыбыз һәм театрлар тормышында күңелле сюрприз бул-

ды. Алар сәнгатьчәлек ягыннан җитлеккән, ныклы кул белән язылган, мөһим һәм кабатланмаган фикерле әсәрләр иде.

Язучы үз буыны укучылары аңына төрлечә үтеп керә. Кайберәүләр өчен ул дистә еллар белән исәпләнә; андыйлар әсәрдән әсәргә, китаптан китапка күңелгә «сеңә»,— укучы бу авторның үзе өчен кай арада, ничек итеп кирәк була башлавын сизми дә кала. Ә кемдер беренче әсәре белән үк замандашы өчен кирәкле юлдашка әверелә: укучы андый автор күтәреп чыккан сорауларны һәм белдергән теләкләрне, ул алга сөргән ышаныч һәм юанычны, аның күңелен биләгән эчке сыкрану һәм нәфрәтне тиз күреп ала. Аларның нәкъ менә үзен дә биләгән сорауларга, кайгы һәм шатлыкларга, омтылыш һәм эчке газапларга тәңгәл килүен аңлый. Бу яктан Т. Миңнуллин бәхетле. «Миләүшәнең туган көне» драмасын һәм «Нигез ташлары» комедиясен карап, 1969 елда басылган «Бәхетле кияү» дигән берәр пәрдәле пьесалар җыентыгын укып, укучы һәм тамашачы аны берьюлы үз итте, яратты. Болар артында чын рәссам, үткен күзле тапкыр комедиограф торганын әдәби тәнкыйть тә, укучы да тиз аңлап алды.

Шуннан соң узган еллар эчендә Т. Миңнуллинның иҗат йөзе тәмам формалашып җитте, иҗат принциплары ачыкланды. Ул халыкның үз драматургына әйләнде. Хәзер бу иҗат иллеләп тулы күләмле пьесалардан, егермедән артык кыска күләмле сәхнә әсәрләреннән, повесть, күп санлы хикәя һәм юморескалар, публицистик мәкаләләрдән, әдәбият-сәнгать турындагы, яшәү мәгънәсе һәм тормыш турындагы уйланулардан торган язмалардан гыйбарәт. Бу саннар талант көче турында да, кызыксыну киңлеге хакында да сөйли.

Туфан Миңнуллин — язучы буларак кына түгел, гомумән, кеше буларак та кызыклы, үзенчәлекле шәхес. Көр тавышлы, ачык чырайлы, һәрчак оптимист, шаян һәм тапкыр, урынына карап җитди һәм кырыс, таләпчән бу кеше гел игътибар үзәгендә, абруйлы. Аның Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләве, СССР Югары Советы депутаты булып торуы, бүген Татарстан халык депутаты булуы да шул хакта сөйли. Аңа фикер үткерлеге, җорлык, мәсьәләнең асылын тиз тотып ала белү, һәр очрак өчен тормышчан фактлар, халыкчан мәзәкләр, гыйбрәтле хәлләр һәм урынлы гыйбарәләр китерә белү хас, шулар аны кызыклы әңгәмәдәш тә, акыллы җитәкче дә ясый. Шәхес буларак аңа хас сыйфатлар әсәрләрендә дә үзенчәлекле төстә чагыла.

Иҗатының үзенчәлекләре

Алда әйтелгәнчә, бүгенгә кадәр Т. Миңнуллин гаять зур иҗади мирас тудырды. Аның күпчелеген драматургия әсәрләре алып тора. Язганнарының күплеге драматургның иҗат активлыгы турында сөйли. Бу драматургия тематика һәм проблематика ягыннан да, сәнгатьчә эшләнеш буенча да күптармаклы һәм бай. Жанрлар өлкәсендә дә, образлар системасы җәһәтеннән дә бу шулай. Анда бер-берсенә охшамаган йөзләрчә образлар, бер дә кабатланмый торган ситуация-хәлләр бар. Жанр үзенчәлекләре белән дә әсәрләр төрле-төрле: тарихи-биографик, фәлсәфи-романтик драмалар, комедияләрнең һәм психологик драмаларның төрләре, водевиль һәм әкият-пьесалар, трагедиягә тартым пьесалар, балаларга аталган әсәрләр... Алар арасында сәнгатьчә эшләнеше белән саф реалистик стильдәге пьесалар да, романтик пафос белән сугарылганнары да, шартлы һәм фантастика элементлары кертелгән әсәрләр дә бар.

Бу иҗатта темалар һәм проблемалар күптөрле. Шулай да аларны бер үзенчәлек берләштерә: аларның күпчелеге безнең көннәргә багышланган. Бүген бара торган хәлләр, бүген тормышыбызда туа торган, хәл итүне сорый торган мәсьәләләр... Т. Миңнуллин — чын мәгънәсендә бүгенге көн язучысы.

Драматург сәхнә өчен кызыклы материалны тормышның төрле өлкәләреннән табып ала, яңадан-яңа фикерләр күтәрә. Шул төрлелек арасында да берничә юнәлешне күрсәтергә мөмкин. Ягъни тема төрлелегенә һәм сәнгатьчәлек ягыннан бай булуга да карамастан, Т. Миңнуллин драматургиясендә аерым «оя»-юнәлешләр аерылып тора. Аларда рәссамлык көче һәм иҗат эшчәнлегенең киң колачы күренә.

Беренче юнәлеш. Кешенең кеше буларак аякка басуын, рухи ныгуын, ягъни шәхеснең формалашуын күрсәтү иҗатының буеннан-буена килә. Бу темага караган әсәрләр («Миләүшәнең туган көне», «Китәр юлың еракмы?», «Адәм баласына ял кирәк», «Монда тудык, монда үстек», «Әзләдем, бәгърем, сине» һ. б.) тулы бер стиль һәм фикер юнәлеше тәшкил итә. Гади, гадәти көндәлек хәлләрне, еш кына гаилә эчендәге вакыйгаларны сурәтләү ярдәмендә, драматург бүгенге яшәешнең катлаулы булуын, аерым кеше язмышының халык язмышы белән аерылгысыз бәйләнешен, кеше рухы нинди байлык һәм көч тәшкил итүен чагыл-

дыра. Кеше белән җәмгыять арасындагы, аерым шәхесләр, төрле һөнәр вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең асылы нидән гыйбарәт? Бүгенге шартларда нинди әхлак принциплары өстенлек итә, итәргә тиеш һәм итәчәк? Әхлакый-этик нормаларның нигезе кайдан килә, никадәр тормышчан һәм тотрыклы? Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның дустанә булуы нәрсәләрдән оеша? Менә шул һәм шундый башка сорауларга җавап эзләү бер омтылыш төсен ала. Бүгенге кешенең, замандашыбызның әхлакый йөзе нинди? Нинди булырга тиеш? Т. Миңнуллинның дөньяны, яшәешне аңлавында һәм күзаллавында нигез ташы булып әнә шул ята.

Оешып килүче язмыш, шәхеснең формалашу юлы, үзенчәлекле характерда ачык чагылган гражданлык намусы... Болар, драматургның беренче әсәрләрендә үк башланып, һаман саен тәэсирлерәк һәм мәгънәлерәк гәүдәләнеш таба бара. Мәсәлән, шул җәһәттән «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Хушыгыз!» драмаларыннан торган трилогия әһәмияте. Персонажлары бер үк булуы белән генә түгел, куелган мәсьәләләре ягыннан да алар бер-берсенең дәвамын тәшкил итәләр. Игътибар үзәгендә кешенең тормышта үз урынын ничек итеп дөрес билгеләргә тиешлеге мәсьәләсе тора. Ул «Миләүшәнең туган көне» драмасындагы кичә студент дуслар булган, бүген мөстәкыйль тормышка аяк баскан иҗат яшьләре өчен бик җитди һәм катлаулы. Инде гомер юлларының уртасына җитеп килгән шул ук геройлар «Дуслар җыелган җирдә» пьесасында (1978) бу мәсьәләнең әле дә хәл ителеп бетмәгәнен, үзләре өчен мөһим икәнен күреп аптырашта калалар, тирән кичерешләргә төшәләр. Ә инде трилогиянең соңгы кисәге булган «Хушыгыз!» драмасында (1992) без яшәгән җәмгыятьнең кешелексезлеге, аерата сәнгать кешесенә битарафлыгы, хәтта рәхимсезлеге күрсәтелә. Бу шартларда тәрбияләнгән кешеләрдәге кимчелекләр ачып салына. Шуның белән бергә, шартларның авырлыгына карамастан кешене кеше итә торган, матурлый торган сыйфатларның да яшәү нык-лыгы, саклануы чагылдырыла.

Үз тормышыңны мәгънәле итеп, халыкка файдалы итеп кору җиңел эш түгел шул. Тормыш һәр буын алдына үзенең катлаулылыкларын куеп тора. Гадел һәм дөрес итеп яшәү кагыйдәләрен кеше бөтен гомере буена үзләштерә килә. Ләкин кистереп кенә «үзләштердем» дип әйтә алмый. Яшь вакытларында ук Шәһит кебек карьерист иптәшләренә каршы чык-

кан, аның яшәү фәлсәфәсенең череклеген фаш иткән Нурислам, Фәһим, Рәфисләр («Миләүшәнең туган көне») олыгайган көннәрендә үзләренең дә тиешенчә актив тормыш белән яшәми башлауларын, мещанлык баткагына кереп баруларын төшенеп алалар («Дуслар җыелган җирдә»). Ә бит инде аерым уңышларга да ирешелгән: берсе — рәссам, икенчесе — композитор, өченчесе — галим... Уңайлы фатирларда яшиләр, очрашканда затлы эчемлекләр генә эчәләр... Ләкин шуңар да карамастан ниндидер күңел китеклеге бар: үз-үзеңнән дә, дусларыңнан да риза булып бетмәү, олы, мәгънәле тормышның янәшәңнән узып баруын сиземләүдән туган канәгатьсезлек... Бу канәгатьсезлек гомернең соңгы баскычында иң югары ноктасына җитә («Хушыгыз!»).

Т. Миңнуллин драматургиясендәге **икенче юнәлешне** инде менәзе формалашкан, ныгыган шәхесләр образларын үзәккә куйган пьесалар тәшкил итә. Мондый геройлар — иҗтимагый тормышта үз урыннарын тапкан, үз вазифасын һәм бурычларын яхшы аңлаган кешеләр. «Ир-егетләр», «Үзебез сайлаган язмыш», «Йөрәк янар өчен бирелгән», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр», «Без китәбез, сез каласыз», «Әниләр һәм бәбиләр» кебек әсәрләрдә вакыйгалар үзәгендә шундый персонажлар тора.

Мәгълүм булганча, уңай герой әдәбиятның тәэсир итү, тәрбияви көчен арттыра. Әдәбиятның поэзия һәм проза төрләрендә герой образы сәхнә өчен язылган әсәрләрдәге кебек конкретлык алмаска да мөмкин. Димәк, драматургия өчен герой образының анык булуы, тормышчан көнкүреш билгеләренә һәм җанлы характер сыйфатларына ия булуы мөһим.

Бу юнәлешкә мисал итеп «Үзебез сайлаган язмыш» драмасын (1972) китерергә мөмкин. Пьеса мәгариф өлкәсендә эшләүчеләргә тирән хөрмәт белән сугарылган. Бер үк вакытта анда шул чорда мәктәпләрдә чәчәк аткан кимчелекләр дә кире кагыла.

Үзәккә яшәү принциплары ачык аңлаешлы булган, дөреслек хакына көрәш башлаган герой куелган. Мәктәпнең яңа, яшь директоры Илгиз Туктаров ныклы гына тамыр җибәреп өлгергән иске тәртипләргә каршы сугыш ача. Ләкин күнегелгән гадәтләр һәм искелек, күз буяу шактый көчле, аларны тырышып яклаучылар бар. Мәсәлән, завуч Мөнирә кебекләргә шулай эшләве дә, яшәве дә җиңел, күнегелгән. Укытуның сыйфаты түбән булса да, өлгереш процентын югары итеп кур-

сәткәнгә күрә, мәктәп моңарчы районда алдынгылар рәтендә йөргән. Ә моның, мәктәпне тәмамлап, аттестат алганнарга, ләкин чынлыкта надан калганнарга никадәр кыйммәткә төшүе турында берәү дә уйлап карамаган. Әнә яхшы укучылар рәтендә йөргән, аттестатында гел «биш»ләр булган кичәге бер укучы аттестатын кире җибәргән: укытучыларына ышанып, ул югары уку йортына имтихан тоткан. Ләкин беләм дип йөргән фәненнән түбән билге алган. Аның кичәге укытучыларына, алар биргән белемнәргә ышанычы какшаган. Яңа директор мондый ялганнарга чик куярга тели. Аны баштарак хәтта Нариман кебек намуслы һәм тәҗрибәле карт укытучы да аңламый. Искелек яклылар көрәштә җиңәләр кебек: яшь директорны моннан күчеп китәргә мәҗбүр итәләр. Шулай да әхлакый җиңү аның ягында, һәм ул үзенең уңай нәтиҗәләрен дә бирә башлый: Фасил кебек һәрвакыт битарафлык ягын каерган укытучылар йокыларыннан уяна. Искелеккә һөҗүм ясала. Шәйхаттаров кебек бик тә үзенчәлекле җитәкче, башаягы белән эшкә чумган колхоз рәисе дә Туктаровтагы намуслылыкны һәм гаделлек көчен күреп ала, аны яклый, эшенә кире кайтару өчен тырыша башлый. Көрәшнең эчтәлеге тагын да зурая, аның иҗтимагый әһәмияте арта.

«Үзебез сайлаган язмыш» пьесасы өчен Т. Миңнуллин яшьләрнең Муса Җәлил исемендәге бүләгенә лаек булды.

Драматург сынмас-сыгылмас рухлы һәм нык иманлы геройлар образларын иҗат итү юнәлешендәге эзләнүләрендә яңадан-яңа уңышларга ирешә. Мондый әсәрләренең күренеклеләреннән берсе «Ай булмаса, йолдыз бар» исемле мелодрамасы булды.

Авторның пьеса персонажы төсендә вакыйгаларга үзе катнашып китүе, әсәрдәге башка персонажлар белән аралашуы, алым буларак, сәхнә әдәбияты тарихында күптәннән очрый. Т. Миңнуллин бу әсәрендә шул алымга мөрәҗәгать итә. Персонажлаштырылган автор монда үзенең әдәби герое белән тартыш алып бара. Ул пьесасын мелодрама итеп яза башлаган икән, моның өчен геройларның күз яше мул булып агуы, кайгы-хәсрәт күп булуы, ләкин алмашка, һичшиксез, шатлык һәм бәхетле финал килүе кирәк. Ләкин гаҗәп хәл туа: драманың үзәк персонажы Мәдинә Сафина автор теләгенә буйсынмый, авырлыклар алдында сыгылып төшми, күз яшен күрсәтми. Әдәби героеның үзсүзлегенә үртәлгән автор аның алдына авыр сынауларны бер-бер артлы куя тора: яраткан

һәм нык ышанган иренең хыянәте дисеңме, бердәнбере булган кызының һәлакәтеме, соңыннан үзенең дә энисе кебек үк сукыраюы дисеңме — берсе дә калмый. Ләкин Мәдинә бирешми. «Зуррак кайгыларга түзгән, кеше булып калган кешеләрне беләм мин,— ди ул.— Минем юлымда сез миңа кайгы китергән кешеләрне, көтелмәгән бәхетсезлекләр очраттырдыгыз. Әмма белегез: кеше кешеләр арасында яши. Берәүсе этеп екса, унысы тартып торгыза. Кешедәге көч ул үзе уйлаганнан күбрәк».

Автор бәхәсне оттыра, кешедәге рухи көчнең зурлыгын таный. Ихтыяр көче сынмый торган кешеләрнең тормыштагы урынын күреп соклана, бу хатынның ныклыгы алдында баш ия. Шул рәвешчә, Мәдинә үз язмышына үзе хуҗа була алган кешеләрнең җыелма образы төсендә гәүдәләнә.

1977 елда язылган бу әсәре өчен Т. Миңнуллинга Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Драма русчага тәрҗемә ителеп, «Театр» журналында басылып чыкты (Мәскәү, 1979, 6 нчы сан), башка халыклар театрларында уйнау өчен тәкъдим ителде.

Т. Миңнуллин драматургиясендәге тематик «оя»-юнәлешләрдән тагын берсен тарихка һәм тарихи шәхесләр образларына мөрәҗәгать итү дип билгеләргә мөмкин. «Канкай углы Бәхтияр» драмасында крестьяннар юлбашчысы Емельян Пугачевның полковникларыннан берсе булган тарихи шәхес образы үзәктә тора. Ат урлау кебек начар гадәтне үзенә кәсеп иткән кешенең тормышы «Ат карагы» драмасында гәүдәләнә. Инкыйлаби күчешләр чорында бернинди хакимиятне дә танымаган, баш бирмәгән Сибгат ахыр чиктә үзенчә итеп кешенең рухи хөрлеге өчен көрәшә, ләкин җиңелә. Татарның сөекле шагыйре һәм каһарманы Муса Җәлил, аның көрәштәшләре «Моңлы бер җыр» исемле драмада гәүдәләндереләләр. Бу геройларның соңгы сәгатьләрендә кичергәннәре, дошманнарының фәлсәфәләрен кире кагулары, үлсәләр дә, әхлакый җиңүләре үзенчәлекле төстә, шартлы алымнар белән сурәтләнә. «Без китәбез, сез каласыз» драмасының үзәгендә бөек Тукай тора. Мәгърур шагыйрь, буйсынмас, ныклы ихтыярлы шәхес! Миһербанлы, кече җанлы кеше!

Т. Миңнуллин художестволы детальләр белән оста эш йөртә, аларны таба белә. Шул аның тарихи драмаларына да хас. Мисал итеп «Канкай углы Бәхтияр» драмасыннан бер күренеш алыйк. Емельян Пугачёв алдында горур Бәхтияр ба-

сып тора, түбәтәен салмаган. «Ни өчен патша алдында баш киемеңне салмыйсың?!» дигән шелтәгә ул: «Татарның түбәтәе башы белән бергә генә салына»,— дип, ярым шаяртып җавап бирә. Чөнки үз алдында чын патша утыруына ул нык кына шикләнә. Бу кем, ни өчен үзен патша дип тәкъдим итә — Алла белсен! Ә инде бераздан батыр ир үзе үк түбәтәен йолкып ала, крестьяннарның житәкчесе каршында түбәнчелек белән баш ора. Чөнки ул хәзер Пугачёвның ни өчен һәм кемнәр хакына көрәшүен аңлый башлаган. Пугачёв башлаган көрәшкә бирелгәнен ул шундый гади, шул ук вакытта мәгънәле төстә аңлатып бирә.

Баш турындагы шул ук деталь тагын бер кабатлана. «Моңлы бер җыр» драмасында ул. Батыр җәлилчеләрнең берсе Абдулла Батталов, маңгайга чиертеш уйнаганда, «И башыңны!» дигәнгә: «Юк инде, башны имибез. Башны без ике очракта гына иябез: сөзәргә уңай булсын өчен һәм кисәргә җайлы булсын өчен. Менә сезгә маңгай — рәхәтләнегез»,— дип җавап бирә.

Кешенең рухи байлыгын, менәзендәге үзенчәлекләрне чагылдыра торган мондый детальләр Т. Миңнуллин пьесаларын уку өчен дә, сәхнәдән карау өчен дә җанлы, кызыклы итәләр, персонажларны тулырак сурәтләргә ярдәмләшәләр. Мондый табышлар Т. Миңнуллин драматургиясендә бик күп.

Сораулар һәм биремнәр

1. Т. Миңнуллин драматургиясенә кергән әсәрләрне санагыз. Аларның кайсыларын сезнең укыганыгыз яки сәхнәдә күргәнегез бар?

2. Бу драматургиянең үзенчәлекләрен сез нәрсәләрдә күрәсез?

3. Андагы темаларны һәм проблемаларны санагыз. Жанрлар ягыннан төрлелекне раслагыз.

4. Психологик драма дигән жанр формасына Т. Миңнуллинның кайсы әсәрләрен кертер идегез? Мондый жанр төренә нинди үзенчәлекләр хас?

5. «Дуслар җыелган җирдә» пьесасын өйдә укыгыз. Анда Нурислам сөйләгән пәриләр турындагы риваятькә нинди мәгънә салынган? Ягъни Нурислам ни өчен сөйли аны, сез ничек уйлыйсыз?

6. Бу драматургиядәге тарихи темаларга караган әсәрләрне атап күрсәтегез. Алар арасыннан кайсылары тарихи шәхесләргә багышланган, ягъни тарихи-биографик пьесалар дип әйтә алабыз?

7. Драматургның үзегезгә таныш булган пьесасыннан художестволы детальгә мисаллар табыгыз. Алар нинди роль уйныйлар, яки аларга нинди мәгънә салынган?

«Әлдермештән Әлмәндәр»
(1976)

Туфан Миңнуллин драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре, андагы «оя»-юнәлешләр турында алда сүз булды. Аны дәвам итәргә мөмкин. Чөнки әле язучының комедияләре, әсәрләрендәге образлар системасындагы кайбер яклар, пьесаларының характеры, стиле, сәнгатьчә алымнары хакында тиешенчә әйтелмәде.

Бу иҗатның ачык билгесе, үзенчәлеге шунда: автор язганда фәлсәфи-психологик драмадан шаян, көлкеле тамашага җиңел күчеп китә белә. Заман турында, яшәү хакында җитди уйланулардан салмак тарихи агышка иркен күчә. Кыскасы, драматург каләме бай сәнгатьчә чаралар белән эш йөртә.

Аның бигрәк тә беренче чорда иҗат иткән пьесаларында чынлык нык саклана. Вакыйга-халәтләр, аларның алышынуы, аларда катнашучы геройлар, аларның үзара мөнәсәбәтләре чынбарлыктагыча, гадәти тормыштагыча. Дөрес, автор кайбер сәхнә шартлылыкларыннан да белеп файдалана. Әмма алар чынлык иллюзиясен бозмый.

Ләкин драматургка сюжет-композиция төзүдә дә, образларны сурәтләүдә дә башка төрле чара-алымнар да ят түгел. Киресенчә, сюжет-композициядә фантастика һәм шартлылык элементларына нигезләнгән, образлар системасында шартлы-метафорик персонажларга мөрәҗәгать иткән пьесалары авторны күбрәк таныттылар. Алар сәнгатьчәлекне яулап алуда яңа биеклек булдылар. Тормышның реаль агышына тәңгәл килеп бетмәсәләр дә, алар шулай ук чынбарлыкны дөрес һәм тирән, ышандырырлык итеп чагылдыруга хезмәт итәләр. Хәтта художестволылык ягыннан тәэсирлерәк тә булалар. Шундый әсәрләрнең күренеклеләреннән берсе — «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы.

Моңсу комедия. Аның үзәк геройлары

Татар драматургиясе комедияләргә бай. Шулай да үзенең идея-эстетик йөкләмәсе белән тулы бер вакыйга булырлык комик һәм сатирик типлар әллә ни күп тә түгел. Комедиянең төп билгеләмәсе һәм асыл бурычы — кимчелекләрне фаш итү һәм алардан көлү. Шуңа күрә булган кадәрләренең дә күпчелегендә типлар сатирик һәм комик яссылыкта хәл ителә.

Ә эре, уңай характерны үзәккә куйган комедияләр аз туа һәм бүгенге көндә дә бармак белән генә санарлык. Мәсәлән, Хуҗа Насретдин образы — шундыйлардан. Көлкеле вакыйгаларны әйдәп бара алган, халкыбызның рухи ныклыгын һәм акыл үткерлеген үзендә туплап чагылдыра алган герой образы, ләкин үткән заманныкы түгел, ә безнең көннәрнең уңай герое образы да сәхнәбезгә бик кирәк иде. Ниһаять, Әлмәндәр карт образы туды.

...Күк канцеляриясендә Әлдермеш авылында бер картның инде 91 яшен яшәп ятуы мәгълүм була. Ә бит язмыш буенча андагы кешеләр 90 яшьтән дә артык яшәргә тиеш түгел. Тиз арада хәлне төзәтергә дип, әҗәлләрдән берәве шул авылга командировкага җибәрелә.

Әҗәл боерыкны үтәргә, Әлмәндәр картны теге дөньяга алып китәргә тиеш. Ләкин тегесенең әле яшәп туйганы юк, җир җимертеп йөри, хәтта тагын бер мәртәбә өйләнергә дә исәбе бар. Кыскасы, Әлмәндәр белән Әҗәл арасында көлкеле дә, бер үк вакытта фаҗигале дә тартыш башлана. Карт Әҗәлне каткат алдый. Шулай булса да, әлбәттә инде, Әҗәл җиңә. Ләкин ул Җир кешесенең яшәү өчен шулкадәр тырышуын, аңардагы ныклыкны, хөрлекне, тәҗрибә байлыгын күреп соклана, корбанын хәтта кызгана, аңа кызыга да башлый. Шулай да югары әмергә буйсынырга тиеш була, картны теге дөньяга алып китә...

Әлмәндәр — чын халыкчан характер. Иң беренче, үлемгә реаль мөнәсәбәте белән. Ул җор телле, әле дә тапкыр акыллы. Күп хәлләрне башыннан кичергән, ил һәм халык язмышы өчен иң җаваплы чорларда вакыйгаларның үзәгендә кайнаган, шулар аны халык менбәре дәрәҗәсенә күтәрә. Бер караганда, инде бу картка фани дөнья мәшәкатьләреннән читтә яшәргә дә мөмкин, ул лаеклы ялда. Ләкин характеры андый түгел, ул әле дә авыл тормышының үзәгендә булырга тырыша. Карт зур тормыш тәҗрибәсенә ия, хезмәт иясе халыкның уңай әхлак-тәрбия сыйфатларын үзендә туплаган. Шуның белән ул әле дә бүтәннәрнең яшәешенә уңай тәэсир ясый. Авылның өлкәннәре дә, Илсур кебек кечкенәләре дә аңар тартыла. Әлмәндәр бүгенге яшьләрнең омтылышларын да, дөньяга карашларын һәм үз-үзләрен тотышларын да аңлап кабул итә, аларга теләктәшлек белдерә. Тормыштагы уңайны күрү белән бергә, ул кимчелекләрне дә дөрес тоеп-аңлап яши. Аларны фаш итәргә тырыша, аларга каршы үзенчә көрәшә, яисә үз тирәсендәгеләрне көрәшкә рухландыра.

Әлмәндәрнең күркәм холык сыйфатлары сәхнәдә кылган эшләре белән аклана бара. Үзе таяна торган югары әхлак-этика кагыйдәләрен, гүзәл гадәт-йолаларны ул эш белән исбат итә килгән һәм әле дә исбат итә. Зур һәм кечкенә мәсьәләләрне ул кешеләргә файдалылыгы ноктасыннан торып бәяли. Шуңа күрә аның гайре табигый бер теләге дә (инде яшен яшәгән, ашын ашаган карт кешенең яңадан өйләнергә җыенуы) җир өстеннән, якын кешеләреннән, яраткан шөгыль-һөнәрләреннән, авылыннан аерылып китәргә һич кенә дә риза булмавы төсендә кабул ителә, хәерхаһлык белән көлү генә уята. Бу — кешелекнең гомуми сыйфаты, яшәүгә булган тыелгысыз омтылышының һәм хөрлегенең чагылышы. Шулай итеп, халыкның алдынгы сыйфатларын, иң күркәм гореф-гадәтләрен үзендә җыйган бу аксакалны драматург заман рухын сизгер тоеп яшәүче кеше итеп гәүдәләндерә.

Комедиядә Әлмәндәргә каршы Әҗәл куелган. Зур көч, дәһшәтле көч. Беренче карашка аның вазифасы — кешенең гомерен кисү, ягъни ул — явыз көч. Ләкин монда да без Т. Миңнуллин драматургиясенә, аның образлар системасына хас тагын бер үзенчәлекне күрәбез. Ул уңай белән каршылыкка кергән тискәре көчне һәм образны да гел кара буяулар белән генә сурәтләми, һәркемдә ул нинди дә булса яктылыклар да күрә. Инде якты ягы булмаса, андый кешенең эш-хәрәкәтен, аның начарлыгын аз гына булса да аклый торган башка сәбәпләр табып күрсәтә белә. Әҗәл образы белән дә эш шулай тора. Автор аны берьяклы гына итеп, гел явыз итеп сурәтләми. Каядыр Әҗәл беркатлы да, хәтта аңа кызгану хисе дә ят түгел. Әлмәндәрнең тапкыр-хәйләкәрлеге аның өчен кызык булып та китә. Адәм балалары эшләгәннәрне эшләп тә карыйсы килә аның: әнә ул картка алачык салыша, әче бал эчеп карый, исерә... Болар әдәбиятта һәм сәнгатьтә моңарчы сурәтләнгән Әҗәл-үлемнең традицион образын үзенчәлекле итәләр, баеталар.

Аллегория һәм шартлылык

Татар драматургиясендә, үзәк фикерне тулырак ачу өчен, аллегорик образларга мөрәҗәгать итү күптәннән килә. Аны беренче мәртәбә уңышлы итеп Гафур Коләхмәтов куллана.

Сез, укучылар, аның «Ике фикер» драмасы белән үткән уку елында танышкан идегез. Андагы аллегорик Кызыл һәм Кара фикерләр көрәшен хәтерлисездер. Әсәрнең татар әдә-

биятына пролетар идеология кертүдә башлангыч булуын беләсез. Аллегорик образларга мөрәҗәгать итүе белән, язучы драма поэтикасына зур яңалык кертә.

Кызыл һәм Кара фикерләр үзара нинди генә кискен бәхәсбәрелешне дә төп герой Даутка бәйле мөнәсәбәттә уздыралар, аннан аерылып китмиләр. Китә дә алмыйлар, чөнки алар — Даутның фикерләре — бары тик персонажлаштырылганнар гына. Шартлы метафорик форманың бурычы шундый.

Т. Миңнуллин исә бу алымның яңа мөмкинлекләрен ачты. Әҗәл вакыт-вакыт үзбашка «яши» башлый. Ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, үзара тарткалашучы Әлмәндәр белән Әҗәлнең, һәрберсе мөстәкыйль рәвештә кузаллансалар да, нигезләре бер. Нигә икәне аңлашыла. Чөнки Әҗәл шул ук Әлмәндәр картның үз табигатенә бәйле, бары тик персонажлаштырылган гына. Билгеле бер вакытка (яшькә) җиткәч, һәркем үлә. Димәк, һәркемнең әҗәле — үзенеке, нindidер гомуми әҗәл юк. Без шуны, укучы һәм тамашачы буларак, яхшы төшенәбез. Шулай була торып та, Әлмәндәрнең үз әҗәле белән көрәше чынлык яссылыгында кабул ителә. Шартлылык — әдәбиятта нинди сихерле көч ул!

Әҗәл уйланма образ булса да, аның вазифасы бик реаль: ул картның яшәвенә чик куярга тиеш. Реалистик һәм аллегорик образларның үзара мөнәсәбәте җентекле эшләнгән. Автор Әҗәлнең һәрвакыт реаль җирлеккә һәм конкрет кешегә бәйле булуын нечкә генә сызыклар, детальләр ярдәмендә сиздереп тора. Шулай да Әҗәл һич тә Әлмәндәрнең үз атрибутына әверелми. Алда әйтелгәнчә, вакыт-вакыт ул эчке мәгънәсе, яшәеш рәвеше һәм перспективасы белән асыл нигезе Әлмәндәрдән аерылып-аерылып та китә. Менә, түбәндәгечә сөйләгәндә, ул инде мөстәкыйль персонаж булып гәүдәләнә: «Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү — зур бәхет ул. Сез, кешеләр, шуңа бәхетлеләр. Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин — җимерүче».

Шулай итеп, үзенең үлемсезлегеннән һәм вазифасыннан туйган вакытында ул мөстәкыйль эчтәлек ала, монда ул — реаль персонаж. Мондый урыннар бик оста эшләнгән. Картның үз үлеме белән көрәшенә яңа төсмер һәм мәгънә бизәкләре өстәлә. Шуңа күрә дә шартлылык җитди теманың тормышчан фәлсәфи эчтәлеген һәм мәгънәсен тулырак, шулай да укучыга һәм тамашачыга авыр тәэсир ясамаслык төстә ачарга ярдәм итә.

Моңсу көлүне тудыруда өстәмә чаралар

Комедиячел конфликт ярдәмендә җиңелчәлек һәм шаянлык рухы тудырып, драматург әсәренең нигезендә яткан, бик җитди булган үлем темасын кабул итүне ансатлаштыра. Моңар ул комедиянең төзелеше ярдәмендә дә, ярдәмче образлар белән дә ирешә. Мәсәлән, вакыйгаларның шаян, кызыклы башлануына прологта ук нигез салына. Интермедиядә шул рух дәвам иттерелә. Ә инде эпилог күңелле итеп яшәүдән ямь таба торган Әлмәндәрнең характерын тагын бер кат күрсәтә.

Шаянлык рухын тудыруда андагы геройлардан Газраил һәм Фәрештәнең дә роле зур. Оста кертелгән көлке хәлләр һәм шаян репликалар ярдәмендә автор яшәү һәм үлем мәсьәләсенең вакыйгаларны фаҗига яссылыгына тартып кертү мөмкинлеген юкка чыгара бара. Мисал өчен Газраилнең «окаянный» сүзен бозып әйтүен, Фәрештәнең аны төзәтеп куюын яисә Әҗәлнең Әлмәндәр сүзләре белән сөйләшә башлавы һ.б. урыннарны алырга була.

Яисә менә тагын бер күренеш. Монысының реаль җирлеге бик көчле. Үзенә әҗәл җиле кагылгач, Әлмәндәр алышынып китә. Ул яшьлеген, сөйгәне, хатыны Йөзембикәне күз алдына китереп саташа. Үлем алдыннан була торган саташу бит инде бу — аны картның килене Өммия дә шулай кабул итә. Димәк, авыр һәм кызганыч халәт. Ләкин монда да драматург каләме шаянлык, җорлык белән тулы сәхнә күренеше тудыра. Яшьлек рухы, мәхәббәт романтикасы, бер-берсенә хөрмәт белән сугарылган матур күренеш. Нәтиҗәдә дөнья белән хушлашучы кешене — яратып өлгергән героебызны кызгану хисе артка чигә.

Әлмәндәр төрле менәзле кешеләр арасында яши. Алар белән аралашканда, аның үз холкы да тулырак ачыла, башкаларның да холык сыйфатлары билгеләнә. Шунысын да исәпкә алыйк: пролог, эпилог һәм интермедиядән башка, барлык күренешләр дә Әлмәндәр катнашында бара. Ул сәхнәдән бер дә чыгып тормый. Аның аралашкан кешеләре яшьләре белән дә, тормыш тәҗрибәләре һәм максатлары, холык-фигыльләре белән дә төрле-төрле. Авыр сугыш юлларын үтеп, яраланып кайткан улы Искәндәр — инде 70 яшьлек авыру карт белән Әлмәндәр, яратып һәм кызганып, аның хәленә кереп, җитди сөйләшә. Дөрес, аның шелтәләп: «Чирләшкә! Япь-яшь башыңнан... Җитмеш яшендә чирләп ята»,— дигән сүзләре елмаю уята.

Ләкин бу сүзләр артында «Яшәү өчен көрәшергә, авыруга бирешмәскә тырышырга кирәк!» дигән мәгънә ятуы, җитди мәгънә салынган булуы ачык аңлашыла.

Килене Өммия белән картның диалогларында җитдилек һәм наянлык, үзсүзлелек һәм хөрмәт итешү аралашып килә. Өммия аның сәер-әкәмәт кыланышларыннан шактый ук туйган, шуңа күрә еш кына бәхәскә дә керә. Ләкин, ни генә булмасын, ул каенатасын санлый. Тегесе да аны хөрмәт итә. Картның хатын-кызга хөрмәтле карашы таныш карчыгы Хәмдебануга мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла.

Ә менә Мансур һәм Гөлфирә кебек яшьләр, кечкенә Илсур белән аралашканда, картның мөнәсәбәте дә үзгә. Монда ул — шаян, котыртып-үчекләп сөйләшергә ярата торган кеше. Юк, ул яшьләрне санга сукмый түгел. Киресенчә, аларны тиң күрә, аңлый, аларның яшьлек сыйфатларын хөрмәт итә. Шаяртып һәм төрттереп сөйләшүе артында да аның һәркемне шәхес итеп, олылап каравы ята.

Аңлашылса кирәк ки, ярдәмче образлар Әлмәндәрне төрле яклап тулы ачу өчен хезмәт итәләр. Картның дөньяны һәм тормышны яратуын, яшәүнең мәгънәсен таба белүен күрсәтүгә ярдәмләшәләр. Бу яктан күрше авыл карты Евстигней образы шулай ук мөһим роль уйный. Әлмәндәрнең дуслыкны бәяли белүен күрсәтә. Бу ике картны берләштергән сыйфатлар уенга яңа мәгънәләр өсти: хезмәтне ярату, авыр чакларда бер-беренә эчкерсез ярдәм итәргә әзер тору, башка милләт кешесен хөрмәт итү, ихласлык, миһербанлылык. Иң җаваплы моментта Әлмәндәр дусты янына «качып китә»; монда инде, әлбәттә, үлемнән качып котылу исәбеннән бигрәк, «знакомы» белән соңгы тапкыр күрешү-саубуллашу теләге беренче урында тора. Әлмәндәр кинәт юкка чыккач, Евстигней, инде үзе дә олы яшьтәге кеше, иренми, аны эзләп ерак юлга чыга.

Боларның аралашуын җентекләп сурәтләгәндә, автор тагын да бер максатны күздә тоткан, билгеле. Ул да булса, әсәрдәге көләчлек рухын арттыру. Чыннан да, Әлмәндәрнең «знакомы» белән русчаны ватып-җимереп сөйләшүе, рус сүзләрен үзенчә борыпбозып куюы күңелле көлү тудыра. Евстигней үз чиратында кордашына хөрмәт йөзеннән, ватып-җимереп булса да, татарча сөйләшергә тырыша. Ахириләрнең җылы һәм мөлаем мөнәсәбәтен оста сурәтләү бөтен текстка күңелле рух һәм матур мәгънә бирә.

Шулай итеп, комедия алынган мәсьәләсенең җитдилеге белән аерылып тора. Шуның белән бергә, ул төрле кәеф төс-

меренә (настроениегә) бай, мул бизәкле. Монда җиңел, уйнак юмор да, җитди көлү һәм сатирик үткерлек тә, лиризм һәм драматизм да, хәтта фаҗига дә үзара аралашып килә, үзенә бер яңа сыйфат тудыра. Моңсулыкның һәм якты оптимизмның үрелгән кушылмасы — әсәрнең иң көчле якларыннан берсе. Ул теманы дөрес хәл итү өчен, тамашачының һәм укучының кәефен төшерми генә, аны мөһим сора лар белән җәлеп итү өчен кирәк. Пьесада төрле жанр үзенчәлекләренең, әдәби-драматик төрләрнең, сәхнә алымнарының үзара керешеп китүен, комедия төренең күп чаралар белән баетылуын күрәбез. Шулар һәммәсе бергә, иң мөһиме, тормыш һәм үлем фәлсәфәсен реаль аңларга ярдәмләшүче Әлмәндәр образы бу әсәрне 70—80 нче еллар драматургиясенең генә түгел, гомумән, татар сәхнә әдәбиятының иң яхшы пьесалары рәтенә кертеп карарга мөмкинлек бирә.

1980 елны шушы пьеса буенча куелган спектакль өчен Т. Миңнуллинга, режиссер Марсель Сәлимҗановка һәм төп рольдә уйнаган Шәүкәт Биктимеровка Россия Федерациясенең Станиславский исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Спектакль берничә мәртәбә Мәскәү үзәк телевидениесеннән күрсәтелде. Болар татар театр сәнгате яулап алган зур уңышларны чагылдыралар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Комедиянең конфликтын билгеләгез. Әдәби әсәрдә конфликт турында алдагы сыйныфларда белгәннәрегезне искә төшереп, мондагы бәрелеш-көрәшнең үзенчәлекләрен ачыклап күрсәтегез.

2. Әлмәндәр образына характеристика бирегез. Аның менәзенә хас нинди сыйфатларны аерып күрсәтергә була?

3. «Әҗәл — шартлы-аллегорик образ» дигән темага әзерләнеп, бәхәс-сөйләшү уздырыгыз.

4. Ярдәмче персонажларның кайсылары сезгә бигрәк тә ошады? Ни өчен?

5. Комедиянең композициясендә сез нинди үзенчәлекләр күрәсез? Башка сыйныфларда өйрәнгән комедияләрнең сюжетларында очрамаган нинди өлешләрне (компонентларны) аерып күрсәтә аласыз? Алар ни өчен кертелгән?

6. Комедиянең шартлы алымга корылган булуын сез нидә күрәсез? Үз сүзләрегез белән аңлатып бирегез.

7. Түбәндәге ике теманың берсенә сочинение языгыз:

а) «Әлмәндәр — ил карты»;

ә) «Шартлы алымнарның һәм образларның әдәби әсәрдәге роле» («Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясе мисалында).

Сез сюжет белән 9 нчы сыйныфта ук таныштыгыз инде. Анда мәҗбүри өлешләр (элементлар: экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация ноктасы, чишелеш) булуын да беләсез.

Кайбер әсәрләрдә, сюжетның бу мәҗбүри элементларыннан тыш, пролог һәм эпилог та була.

П р о л о г т а (грекча: кереш сүз) әсәрдә барачак вакыйгалардан алда булган берәр вакыйга сурәтләнә. Ул төп өлештәге вакыйгалар белән турыдан-туры бәйләнмәгән дә булырга мөмкин, ләкин төп хәрәкәткә этәргеч биргән яки аның эчке мәгънәсен чагылдыруга ишарә ясаган моментны эченә ала. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә пролог шундый. Үзенең вазифасы белән пролог экспозициягә якын тора, шуңа күрә аны экспозициянең үзенчәлекле бер рәвеше дип карарга мөмкин.

Пролог дип борынгы грек трагедияләрендә авторның тамашачыларга мөрәҗәгатен атаганнар.

Э п и л о г («соңгы сүз» дигән грек сүзеннән) — әсәрдәге азакка нәтиҗә. Борынгы грек драмаларында авторның гомуми фикерен яки пьесаның характерын аңлаткан соңгы йомгаклау сүзен шулай атаганнар. Ул — чишелешнең бер формасы. Ягъни анда чишелештә сурәтләнгән персонажларның менәзендәге үсеш юнәлеше ачылып җитмәгән һәм аларның киләчәк язмышы җитәрлек ачыкланып бетмәгән урыннар ачыла һәм ачыклана. Моның мисалы — Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестендагы эпилог, ул «автордан» дип исемләнгән.

И н т е р м е д и я («ике арадагы» дигән латин сүзеннән) — ике пәрдә яки сәхнә күренешләре арасындагы зур булмаган күренеш. Ул, гадәттә, комик характерда була. «Әлдермештән Әлмәндәр»дә ул I һәм II пәрдәләр арасында.

А л л е г о р и я («читләтеп» һәм «сөйлим» дигән грек сүзләреннән) — абстракт төшенчәне яки фикерне алыштыручы предметны яки чынбарлык күренешен конкрет сурәтләү. Мәсәлән, күгәрчен тынычлыкның аллегорик гәүдәләнеше төсендә кабул ителә. Елан һәм савыт — медицина, дәва аллегориясе.

ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Матур әдәбият — җәмгыять тарихының, кешелек тәрәккыятенең көзгесе, дип әйтәбез. Сүз сәнгатенең бу сыйфаты соңгы елларда тагын да бер кат расланды. Матур әдәбият, шул җөмләдән татар әдәбияты, илдә бара торган инкыйлаби үзгәрешләрне чагылдыруга җиң сызганып кереште дип әйтергә ныклы нигезебез бар.

Ил тормышында, Советлар Союзы дип аталган зур империядә башланган үзгәртеп корулар, иң беренче, икътисади тормышка тәэсир итте. 1917 елгы инкыйлаблардан соң 70 ел дәвамында һәрнәрсәне коллективка буйсындырырга омтылу, күмәклекне генә тану, шәхеснең теләк-омтылышларын артка куеп эш йөртү өстенлек иткән иде. Сыйнфый көрәшне зурлау һәм мактау, совет кешесе, үзе турында уйлаудан бигрәк, башкалар хакында кайгырта дип раслау һәм шуны таләп итү, байлыкның кешене аздыру, бозу куәтен генә күреп, аңа һәрчак каршы чыгу әдәбиятта да киң урын алды. Аның берьяклы гына үсешен китереп чыгарды. Нәтиҗәдә җиргә хуҗа калмады, кешенең хезмәткә күңеле суынды, завод-фабрикаларда һәм колхозларда хуҗасызлык, табигатькә вәхшиләрчә мөнәсәбәт һ.б. кимчелекләр чәчәк ата башлады. Җәмгыять акрынлап-акрынлап таркалу, әхлаксызлык баткагына төшә барды.

Матур әдәбият боларны бөтенләй күрмәде дип әйтү дөрес булмас иде. Ул аерым кимчелекләргә игътибар итте, тегеләйме-болаймы аларны сурәтләде, кире какты. Бигрәк тә җәмгыятьтәге әхлаксызлыкның арта баруы аны борчыды. Бер генә мисал алыйк.

Совет мәктәбендә бигрәк тә соңгы дәвердә кимчелекле тәртипләр урнашты. Формализм чәчәк атты. Укытуда теориягә генә басым ясалды, нәтиҗәдә мәктәптән тормыш итү өчен аз әзерлекле кешеләр чыкты. Совет системасында нык пропа-

гандаланган ярыш гарип төстә мәктәпкә дә үтеп керде. Район мәгариф бүлекләре, мәктәп җитәкчеләре ярышта 100 процентлы өлгереш артыннан кудылар. Ә бу, асылда, күз буяуга китерә, укучыга начар билге тиеш булганда да уңайны куюю таләп итеде иде. Шуның аркасында урта мәктәп аттестатын ярым надан, хиссез һәм рухсыз яшьләр дә алып чыкты.

Без алда Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» исемле драмасы уңае белән мондый тәртипләрне фаш итүне билгеләп үткән идек инде. Шундый ук, заманына күрә кыюлык күрсәтеп, мәктәптәге гарип тәртипләргә, караңгылыкка каршы чыгуны Аяз Гыйләҗевнең «Җиргә тапшырылган серләр» драмасында да (1976) күрергә мөмкин. Драматург монда мәктәптәге катып калганлыкка, укучыларны бертөсле уйларга (дөресрәге, уйламаска), кеше өчен кайгырмаска, һәрнәрсәгә битарафлыкка өйрәтүгә ризасызлык белдереп фаш итә. Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» драмасы да (1972) бу теманы хәл итүдә беркадәр яңалык рухы белән сугарылган иде.

Әлбәттә, кайбер язучылар җәмгыятьне артка сөйри, тарката торган мондый тәртипләрне күрсәләр дә, аерым очракларда чаң суксалар да, совет илләрындагы гариплекләр матур әдәбиятта киң яктыртыла алмады. Моңар идеологик система юл куймады. Коммунистлар партиясенең илдәге бөтен хакимиятне үз кулларында тоткан җитәкчеләре төрле-төрле чаралар ярдәмендә, шул җөмләдән физик көч кулланып та, әдәбият-сәнгать әһелләренең иҗатын чикләп-буып тордылар. Татар әдәбияты тормышны чын мәгънәсендә тулы һәм дөрес итеп чагылдыру юлына 1985 елдан башланган үзгәртеп корулар чорында гына аяк басты.

Матур әдәбиятның яңалыкка борылышы, иң беренче, кешегә, аны сурәтләүгә мөнәсәбәттә күренә. Совет илләрында рәсми сәясәткә буйсынган язучылар кешене җәмгыятьнең кечкенә бер шөребе, коллектив ихтыярына буйсынган бер берәмлек итеп кенә карадылар. Күпчелек очракта шулай тасвирладылар да. Хәзер әдәбиятта кеше, аерым шәхес, аның мәнфәгатьләре алга чыгарыла башлады. Ни өчен? Чөнки кеше — дөньяда тормыш итү үзәге, һәркем — кабатланмас меңәзе, үзенчәлекле холык сыйфатлары белән дөньяда берәү генә. Кеше үлсә, бер дөнья юкка чыга, дип әйтергә була. Җан иясе фани дөньяда бер генә яши. Шуңа да аның бүгенгесе, бүгенге яшәеше, бүгенге өмет-омтылышлары кадерле. Бүгенге

яшәешне иртәгегә күчереп булмый. Кешене киләчәккә өмет яшәтә, ләкин, киләчәк өчен дип, ул бүгенгедән баш тарта да, бүгенгегә төкереп карый да алмый. Менә ни өчен әдәбиятта кеше, аның уй-фикерләре, кичерешләре, өмет-хыяллары алга чыгарыла, кешенең шәхси мәнфәгатьләре беренчелекне ала. Бүгенге матур әдәбият мәсьәләне менә шулай аңлап хәл итүгә күчә бара.

Моның белән, билгеле инде, кеше бары тик үзе өчен генә яши дә, ул шулай сурәтләнергә, язучы шуны якларга тиеш дигән фикер уздырылмый. Кеше дигән җан иясенең бөеклеге дә шунда: ул һәрвакыт башкаларның да мәнфәгатьләрен күздә тотып эш йөртә. Шуның белән ул табигатьтәге башка җан ияләреннән өстен, шуның өчен аңа акыл бирелгән, рух иңдерелгән. Аның өчен күршеләренең, туганнарының, авылдашларының, якташларының иминлеге, тормышлары бөтен булуы үзенең һәм гаиләсенең иминлеге кебек үк кадерле һәм мөһим. Ул милләттәшләренең тынычлыгы һәм матур киләчәге өчен дә кайгырта. Үз халкының, Ватанының хөр булуы, бөек булуы өчен җан ата. Ул — ватанпәрвәр.

Әдәбиятта һәм сәнгатьтә кешене, аның тормыштагы урынын һәм билгеләмәсен шулай аңлап сурәтләү торган саен күбрәк урын били бара. Шуларга бәйле төстә хәзерге әдәбиятыбызда берничә тема бик мөһим, актуаль төс алды.

Соңгы елларда **милли бәйсезлек темасына** шактый әсәрләр язылды. Бу мөһим мәсьәләнең шулай алга чыгарылуына сәбәп бар. Төп сәбәп — 1552 елга, ягъни Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан Казанның басып алынуына кадәр үз дәүләтчелеге булган халыкның XX йөзгә кадәр һәм аннан соң да колониаль изелү шартларында, ә инкыйлаблардан соң ярым изелү хәлендә яшәве. Гомер-гомергә яшәп килгән үз туган җирләреннән, урман-суларыннан мәхрүм итү, көчләп чукындыру ярдәмендә үз диненнән, ахыр чиктә үз милләтеннән тәмам аеру, мәчет-мәдрәсәләрне ябу, Совет чорында аларның эшен тыю, милли мәктәпне, туган телне туктаусыз чикләүгә бару, милли гадәт-йолаларны бетерү, алардан ваз кичтерү, руслаштыру сәясәтен торган саен көчәйтү һәм тормышка ашыру һ.б. — болар барысы да татар милләтенең бетүенә, халык буларак юкка чыгуына китерә иде. Үзгәртеп корулар чорына килеп кергәч, татар халкына, күптәнге хыялы булган милли бәйсезлеккә ирешү, үз дәүләтен булдыру өчен, кайбер мөмкинлекләр ачылды, шуның өчен көрәш башланды. Бу хәл әдәбиятта да чагы-

лыш тапты. Язучылар Совет хакимияте вакытында тыелган темаларга: тарихи үткәнебез, килеп чыгышыбыз (этногенез), дәүләтебез һәм бәйсезлегебез өчен көрәш мәүзугларына иркен мөрәҗәгать итә башладылар. Мөстәкыйльлек өчен көрәшкә зур көч куйган милли каһарманнар соңгы еллар әдәбиятында үзәк персонажларга әверелде. Шундый әсәрләрдән Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романын һәм «Шәҗәрә» дигән китабын, М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» һәм «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Р. Батулланың «Сөембикә кыйссасы», Җ. Рәхимовның «Батырша», Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романнарын, Р. Харисның «Ант суы», Ә. Рәшитнең «Колшәриф», Г. Рәхимнең «Аяз көнне яшен», З. Мансуровның «Балкыш» һ.б. поэмаларын, дистәләгән хикәяләрне, сәхнә әсәрләрен күрсәтергә була. Алар укучыларга, тарихыбызны дөрес чагылдырып, халкыбыз узган авыр, фаҗигале, әмма данлы юлны тасвирлыйлар.

Социализм теориясен тормышка ашыруда ялгышлар җибәргән Коммунистлар партиясе, иң беренче, аның җитәкчеләре диктаторлык иткән Совет дәүләте шартларында күп кенә закон бозулар булды, кешелексезлек, имансызлык хөкем сөрде. Аерым сыйныфлар, шул исәптән крестьяннар, чамасыз җәбер күрде, мәрхәмәтсез эксплуатацияләнде. Милләтләр кимсетелде, шәхес иреге кысылды. Боларны һәм башка төрле кимчелекләрне, гаделсезлекләрне гаепләп язган әсәрләр үз илебездә бастырылмады, чит илләрдә басылганнары укучыларга җиткерелмәде. Законсызлыкларны күреп-аңлап та, алар турында яза алмаган әдипләр, демократия заманына кергәч тә, эчләрендә җыелган нәфрәтне һәм протестны әсәрләренә күчерә башладылар. Бигрәк тә Сталин культы чорындагы, соңыннан «торгынлык чоры» дип аталган 70—80 нче еллардагы башбаштаклыкларны фаш итә башладылар. Язылып та, вакытында басыла алмаган әсәрләрдән Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы, Г. Исхакыйның эмиграциядә язылган әсәрләре дөнья күрде. А. Гыйләҗев «Йәгез, бер дога!», Мәхмүт Хәсәнов «Язгы аҗаган», Г. Ахунов «Идел кызы», М. Мәһдиев «Бәхилләшү», Н. Фәттах «Кичү», Р. Мөхәммәдиев «Кенәри — читлек кошы», Ф. Садриев «Шаһзаманов эше», Ф. Сафин «Саташып аткан таң», Ф. Латыйфи «Ишелеп төшкән бәхет» һ.б. роман-повестьлар, Р. Хәмид, Р. Батулла, Р. Мингалим, З. Хәким, Д. Салихов һ.б. — пьесалар, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миңнуллин, Р. Әхмәтҗанов, З. Мансуров,

Ә. Рәшитов, М. Әгъләмов, Ә. Баян, Зөлфәт кебек шагыйрьләр поэмалар иҗат иттеләр. **«Совет чорын фаш итү»** дип атарга мөмкин булган бу тема бүген актуальләшә бара. Язучылар мондый шартларның аерым кеше рухына җимергеч тәэсирен сурәтләүдә һәм фикерләү, һәм сәнгатьлелек ягыннан тирәнәя баралар.

Хәзерге әдәбиятта үзәк урынны алган тагын бер өлкәне табигатькә, әйләнә-тирәгә төпле, миһербанлы, сакчыл мөнәсәбәт мәүзугы дип, экология темасы дип атарга мөмкин. Әлбәттә, бу темага багышланган әсәрләрдә дә кеше, аның рухи дөньясы үзәктә тора. Ләкин психологик кичерешләр мохиткә, табигатькә мөнәсәбәттән туа. Нефтькә бай һәм зур-зур заводларга ия булган Татарстан ахыргача уйлап бетерелмәгән корылышлар, җир маен мәгънәсез төстә суыртуу, урман-суларга вәхшиләрчә мөнәсәбәт нәтиҗәсендә афәт зонасына әверелде. Язучылар бу хәлгә күптәннән чаң сугалар. Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романыннан башланган бу юнәлеш көчәя бара. Бу темага язылган дистәләрчә әсәрләр арасыннан Р. Мөхәммәдиевнең «Ак кыялар турында хыял» повестен, Ә. Гаффарның «Олы юлның тузаны» романын, А. Гыйләҗевнең «Хушыгыз, тургайлар!», И. Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә» пьесаларын һ.б.ны күрсәтергә була.

Үзгәртеп кору, базар мөнәсәбәтләренә күчү, хосусый милекчелекне көчәйтү чорына кергәндә, **кеше күңелендә барган давыллы кичерешләргә, рухи ориентир эзләүләргә** дә язучылар иҗатларында торган саен күбрәк урын бирәләр. Рухи гариплек арта барганда, ансат юл белән байлык туплау чире көчәйгәндә, кеше, бигрәк тә яшьләр, кайсы кыйблага табынырга тиеш? Әхлаксызлык киң җәелгән, миһербансызлык көчәйгән вакытта, ни-нәрсәләр күңелне саф, вөҗданны пакь сакларга ярдәм итәчәк? Бу сорауларга җавапны күпчелек язучы татар халкының гореф-гадәтләреннән табарга өнди. Кеше рухының ныклыгын, күңел байлыгын, хисләр төрлелеген шуларга бәйләп, шуларга мөнәсәбәттә күрә. Мәсәлән, моның мәгънәле һәм тәэсирле чагылышын Ф. Садриевнең «Таң җиле», Мәдинә Маликованың «Фидая» исемле романнарында күрергә мөмкин.

Әлбәттә, хәзерге әдәбиятта күтәрелгән мәсьәләләр даирәсе югарыда аталганнар белән генә чикләнми. **Үткән мираска һәм дингә мөнәсәбәт, җәмгыятьнең һәм милләтнең үсешендә атааналың роле, алга бару тулы булсын өчен, мәгърифәтнең, әдәбият-сәнгатьнең мөһимлеге, милләтләр арасында дөрес**

мөнәсәбәт урнаштыру юллары, туган телебезне, мәдәниятебезне үстерү ысуллары һ.б. дистәләгән мәсьәләләр язучыларның акылын һәм күңелен бимазалый. Бимазалый, борчый икән, димәк, бүген булмаса иртәгә роман һәм повестьларга, пьеса һәм поэмаларга, хикәя һәм шигырьләргә күчеп, укучының да күңелен кузгата дигән сүз. Татар әдәбияты бүген шул юлда көч туплый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Тарих дәресләрендә алган белемнәрегезне кулланып, илдә 1985 елдан башланган үзгәртеп коруларның асылын аңлатыгыз.

2. Соңгы елларда илдә барган вакыйгалар әдәбиятта ничек чагыла? Бер-ике мисал ярдәмендә раслагыз.

3. Хәзерге әдәбиятта нинди темалар аеруча актуаль? Шулар арасыннан сез кайсын әһәмияте ягыннан беренче урынга куяр идегез? Ни өчен?

4. Бүгенге әдәбиятта шәхескә игътибар арта бара дигәндә, нәрсәне күз алдында тотабыз? Совет елларында да әдәбиятта кеше образы үзәктә торды бит. Аерма нидә?

5. Югарыда аталган әсәрләрнең кайсыларын укыганыгыз яки сәхнәдә (телевизордан) күргәнегез бар? Укыган әсәрегезнең кыскача эчтәлеген иптәшләрегезгә сөйләп бирегез.

ШИГЪРИЯТ ОФЫКЛАРЫ

Шигърияттә дәвамлылык, кабатлану, элгәрләр ачкан юлга тугрылык рухы көчле булса да, һәр дәвер анының үсешенә үз чалымнарын, үз бизәк-билгеләрен алып керә. Яңа чор иҗаты — эчтәлеге, бирелеш рәвеше, фикерләү үзенчәлеге җәһәтеннәнме — кайсы ягы белән дә башкалардан аерылып тора.

60 нчы елларда, мәсәлән, шау-шулы эстрада поэзиясе алга чыкты, шигырь сәхнәгә менде, метафора, куе һәм төсле чагыштыру, шашкын хислелек, зиһен ташкынын чагылдыруга омтылыш көчәйде. Поэма, күләме буенча кыскарып, чор һәм олы дөнья мәшәкатьләрен гомумирәк рухта сурәтләү юлын алды. Сатира, юмор тернәкләнде.

70 нче елларда шигърият, образлылык хасиятен, романтик дәртен, эчке егәрен саклаган хәлдә, үз ярларына кайтып төште, тынычланды, фикер белән хис бердәмлеген ныгытты. Халык иҗаты байлыкларына игътибар үсте.

80 нче елларда төзелешләр, нефть чыгаручылар, галәмгә очучылар турында язылган шигырь-җырлар, поэмалар азайды, кешенең гадәти мәшәкатьләренә, уй-тойгыларына якынаюның яңа чараларын эзләү дәвам итте. Авылны, табигатьне, тирәлекне саклау мәсьәләләре төп юнәлешләрнең берсе булып калыкты.

Тик әлеге унъеллыкта татар поэзиясе ике олы язучысын, халык киләчәге белән яшәгән намуслы шәхесләрен югалтты: Хәсән Туфан (1981), Сибгат Хәким (1986)...

Элеккеге СССРда соңгы чорда барган үзгәреш-яңарышларның шаһиты була алмасалар да, хәзерге шигъри эзләнүләрнең юнәлешен, мәйданын, сурәтле фикерләү үсешен алар иҗатыннан башка күзаллавы кыен. Өлкәннәрнең акыллы һәм моңсу, тирән һәм нәфис лирикасы, олыларга хас булганча, башыннан ахырынача кешеләргә мәхәббәт белән сугарылган, шәхес бәхете өчен көрәш белән рухланган. Халык тормышын тирәнтен тою нәтиҗәсендә, Х. Туфан белән С. Хәким иң гүзәл әсәрләрендә

иҗат юлларын милләт язмышы белән кушу бәхетенә ирештеләр, үзләреннән соң килүчеләр өчен максатлылык үрнәге булып калдылар.

Кешенең кайгы-хәсрәтен, әзләнү-үкенүен, гади шатлыклар өчен фаҗигале көрәшен тасвирлау юлына сугыштан соңгы татар поэзиясен Х. Туфан алып чыкты. Соңрак аңа үз тавышы, үз моңы белән С. Хәким һәм яңа буын килеп кушылды.

Татар шагыйрьләре остазларының якты истәлегенә дистәләрчә мәдхияләрен, элегияләрен багышладылар: Кадыйр Сибгатуллин «Туфан белән сөйләшү», «Туфаннар», Гәрәй Рәхим «Хәсән Туфан елмаюы», Роберт Әхмәтҗанов «Сибгат ага Хәкимгә элегия», Әмир Мәхмүдов «Мәңгелек моң кебек» һ.б. Үзәктә — югалтуны тирәнтен кичерү, сагыш, юксыну, элгәрләр сызган юлга тугрылыклы калуда вәгъдәләр...

Газинур Морат Туфан фаҗигасен дүрт юлга сыйдыра алган.

«Мә, партия, мине»,— диеп
Язган да... көткән хәбәр...
Башлары Себер китәсен
Алдан белгән пәйгамбәр.

(«Туфан»)

Харрас Әюпов Туфанны романтик биеклеккә, олы Вакыт хәтеренә күтәреп тасвирлый.

Еллар аша,
Ут-давыллар аша
Калка Туфан...
Уралларны кичеп...
Төрмәләрне ватып калкып чыга —
Дертләп китә Вакыт әллә ничек...

(«Калка Туфан»)

Хәзерге поэзиянең төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт соң? Аңа нинди сыйфатлар, яңа тамга-билгеләр хас?

Табигый ки, төрле юнәлешләрдә барган үзгәрешләрнең барысына да тукталу мөмкин түгел.

Поэзиянең халык яшәешендә, Татарстан язмышында тоткан урыны елдан-ел арта бара дибез икән, бу хәлнең мәгълүм сәбәпләре, ышанычлы нигезләре бар.

Социализм дип аталган ясалма иҗтимагый үсеш баскычының җимерелеп төшүе, аның артыннан СССРның юкка чыгуы һәр аерым кешегә, бигрәк тә шагыйрьгә, тәэсир итмичә кала алмады.

90 нчы еллар башында сәяси, икътисади үзгәрешләр, борылышлар йогынтысында татар халкының ачы язмышы турында уйланып, борчылып язылган, тарихи аң белән сугарылган шигырь-поэмалар күбрәк күренә башлады. Поэзия, милләт азатлыгын, татар телен, халыкның динен, гореф-гадәтләрен, меңәр еллар дәвамында камилләшә, чарлана килгән әхлак кагыйдәләрен саклау өчен, көрәш юлына чыкты.

Гамил Афзал, Рәшит Әхмәтҗанов, Фәнис Яруллин, Рөстәм Мингалим, Әхмәт Рәшитов, Харрас Әюпов, Кадыйр Сибгатуллин, Зөлфәт, Әхмәт Гадел, Мөдәррис Әгъләмов, Лена Шагыйрьҗан кебек кыю фикерле шагыйрьләр нәкъ шул юнәлештә татар поэзиясенең йөзенә кызыллык китермәстәй әсәрләрен укучыга ирештерделәр. Алар иҗатында халык рухын сәнгать чаралары, күркәм сурәтләр белән күрсәтү юлында татар поэзиясе шактый алга китте.

Язарга азык биргән уртак иҗтимагый тормыш шигъри мәйданда күңелсез бертөслелек тудырмый. Шәүкәт Галиевнең уйчан, мәгънәле реалистик поэзиясен Равил Фәйзуллин белән Ренат Харисның шартлы алымнарга бай, дәртле, көтелмәгән борылышлы шигырьләре тулыландыра. Рәшит Әхмәтҗановның итагатьле, тыйнак чишмәсе агышына Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Рәдиф Гаташның романтик күтәренке, үткән белән киләчәкне иңләргә омтылган авазы килеп кушыла. Поэзиягә хатын-кызның уйлану рәвешен, шатлыгын-кайгысын, рухи матурлыгын алып кергән Клара Булатова, Энҗе Мөэминова, Салисә Гәрәева, Нурия Измайлова, Флёра Гыйззәтуллина иҗатларын Зиннур Мансуров, Марсель Галиев һ.б.ның әхлакый-фәлсәфи эзләнүләре төрләндерә, баета...

Илдә барган игелекле үзгәрешләрнең уңай тәэсирендә соңгы елларда татар поэзиясенең әлегәчә укучыга таныш булмаган үрнәкләре басылып чыкты.

Х. Туфанның, үзе исән чакта матбугатта күренмичә, төрле кулъязмаларда, шәхси архивларда чәчелеп-сибелеп яткан шигырьләре «Гүзәл гамь» (1990) исемле җыентыкка керде. Бу китабында ул сәяси яктан җитлеккән шәхес, татар халкының башка милләтләр арасында тигез хокуклы булуын теләп, шуны таләп итеп янып-көеп йөрүче көрәшче буларак күз алдына баса. «Татар» дигән сүзне ишетү белән...», «Мәңгелек син...», «Әгәр берәр шваль расист...», «Иман», «Гасыр үтәр кебек» шигырьләре шуңа дәлил. Ул халыкның холкы, характеры турында җитди уйлануларын калдыра.

Синең дә, и татар,
Сыйфатың, саның бар,
Холкыңда, йоланда
Соклангыч ягың бар:
Синең төп сыйфатың —
Батырлык, кыюлык.
Синең бу гадәтең
Байрагың булырлык!

(«И татар»)

Тормыш үзе биргән гадәтеңне
Кем танымый аны, кем белми:
Я җиңелә татар, я җиңә ул,
Ә бирелми әмма, бирелми.

(«Ил»)

Ф. Кәримнең 1941—1945 еллар сугышы алдыннан Казан төрмәсендә утырганда язылган шигырьләре ачыну, әрнү, нахакка иза чигүне һәм рәнҗегән җанның йөрәк кичерешләрен һәм ахырда гаделлеккә ышануын чагылдыралар («Карбыз кебек»).

М. Гафуриның 1921 ел ачлыгына багышланган, озак еллар матбугат битләрендә күренмәгән «Кеше ашаучылар» поэмасы киң җәмәгатьчелеккә килеп җитте. Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан йомшак әсәр булса да, ул большевиклар хакимиятенең Урта Идел буенда яшәүче халыкны коточкыч ачлыкка дучар итүен ачып салды.

1944 елда партиянең Үзәк Комитеты карары нигезендә тыелган «Идегәй» дастанының кабат кайтуы демократиянең шифалы җиңүе булды.

Дастан — татар халкының сәнгатьчә даһилеген, теленең камиллеген үзенә туплаган иҗат җимеше. Анда җыр мирасының, мәкаль-әйтем, хикмәтле сүз хәзинәсенең гүзәл үрнәкләре тупланган.

«Идегәй» сәяси максаттан чыгып каһәрләнмәгән, изелмәгән булса, ул татар поэзиясенең үсешенә күп уңай тәэсир ясаган булыр иде.

Бу урында С. Батталның, 1963 елда язылып та, 1994 елда гына («Идел», 1994, 2 нче сан) дөнья күргән «Батый ханга ачык хат» әсәрен искә алып үтү урынлы булыр.

Шагыйрь татар тарихын бозып аңлатуга каршы чыга («Каны белән купсын җирдән үкчәң! Син татармы, димәк, син — Батый»), милләтләрне санга сукмау, сыту, юкка чыгару сәя-

сәтен алга сөргән шәхес культын, шул ук юлны дәвам иткән Хрущёв чорын фаш итә.

Чордашымның кайсын өстен куйыйм?
Бик күренеп тора тыштан ук:
Чиста канлы татар булмаган күк,
Чиста канлы сыңар рус та юк.
Сугышып һәм суешып яшәгәндә,
Кемдер әйтеп куйган шуңа бит:
«Урысларны суеп, карынын ярсаң,
Аннан татар килеп чыга»,— дип.

Фикер артык туры, тупас әйтелсә дә, халыклар арасындагы тарихи мөнәсәбәтләрне дөрес һәм объектив аңлатырга чакыруы белән шагыйрь хаклы иде.

Татар поэзиясендә барган эзләнүләр рухы 60—80 нче елларда «икенче яшьлеген» кичергән **Нури Арсланов** (1911—1990) иҗатында ачык гәүдәләнеш тапты.

Ул поэзиягә дәһшәтле сугыш чорында килә, 50 нче елларда татар әдәбиятын күләмле эпик поэмалары белән баета.

Алдагы елларда аның иҗатында фәлсәфи-лирик башлангыч тирәнәя, ныгый. Дөньяда һәр күренешнең, табигатьнең, фикернең үз кыйммәте, үз урыны бар, ди шагыйрь. Шулар арасында шәхес аеруча игътибарга лаеклы.

Әйе, шундый чакларым бар:
Давылланып чатнавым бар.
Табылмасын табар кебек,
Көндез чыра якканым бар.
Давылдан соң тынгы көтеп,
Кабат давыл тапканым бар.

(«Давыл»)

Табигать белән кеше мәңгелек: «Кеше — гаҗәеп зур җан, табигатьтә мәңге яши, мәңге эзләнә» («Була күрсен иде»).

Н. Арсланов шәхес кичерешләре турында саклык һәм нәзакәтлелек белән яза. Шигырьләре пөхтә, җыйнак, композицияләре уйланылган («Үзгәреш», «Син генә», «Уйлата», «Кайтам» h.б.).

Н. Арсланов яшәү белән үлем кебек төшенчәләр турында, шаярып-көлеп, шул ук вакытта фәлсәфи моң белән уйлана.

Хәят белеп тора,
Картлар үлеп тора,
Яшьләр күреп тора,
Язмыш көлеп тора...

(«Язмыштан узмыш юк»)

Нечкә хисле, үз җырына, моңына тугрылыклы лирик геройның характерына романтика да, кискенлек тә чит түгел: «Казан, Казан», «Җир яңгырый», «Котлау сезгә».

Шагыйрь, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәримнәр сызган юлны дәвам итеп, сәяси лирика үсешенә дә өлеш кертә. «Ябып булмый», «Өмет өзмә», «Кояшына карап» шигырьләрендә Н. Арсланов йөрәк хисләрен Җир шарының кайнар нокталарына юнәлтә, башка халыклар фаҗигасен үз кайгысыдай кабул итә.

Лирикасының тагын бер үрнәк булырдай сыйфаты — кыскалык, төгәлләнгән фикерне тар мәйданга сыйдыра алу осталыгы. Шагыйрь мәкаль-әйтем, хикмәтле сүз хәзинәләренә таяна.

Ир гайрәтне тәвәккәлдән ала:
Я башын сала, я батыр кала.

(«Ир гайрәтне...»)

Күзгә сөрмә итәр идем,
Туфрагың табалмадым.

(«Тузмый икән»)

Татар теленең эчке көчен, байлыгын тирәнтен аңлап, шәхеснең рухи дөньясы кебек үк, нәфисләү чараларының бай һәм төрле булуы турында туктаусыз кайгыртып, Н. Арсланов халык иҗаты казанышларына, экият сюжетына һәм Көнчыгыш әдәбиятлары казанышларына килеп чыга. Ул борынгы Шәрык классигы Гомәр Хәйям робагыйларын тәрҗемә итеп, аерым китап итеп бастырды.

Әдәбият ишеген 50 нче еллар ахырында, 60 нчы сәнәләрдә шакыган буын — хәзерге татар поэзиясенең әйдәп баручы көче. Аларның иҗади яшьлеге «Хрущёв җепшеклеге» дип аталган, үсеш өчен җайлырак, иплерәк вакытка туры килде. Алар замана биргән шартлардан тиешенчә файдалана, поэзиядә үз сүзләрен әйтә, йөрәкләрен, хисси дөньяларын ача алдылар.

Шунысы да бар: 80—90 нчы еллар аралыгында буыннар арасындагы аерма югала бара. Уртак максатлар уй-тойгыларны, фикерләү төрләрен ничектер якынлаштырып җибәрде. Һәркайсы үз шигъри йөзен саклаган хәлдә, аларны Татарстан язмышы, тарихи дөреслек тантанасы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр сафлыгы, шәфкатьлелек, туган илеңә, якыннарыңа тугрылык кебек әхлакый-фәлсәфи төшенчәләр борчый.

Г. Афзал «Үрләрдә иманнар шаулый» (1981), Ш. Галиев «Исәнме, дус!» (1985), «Серләрем бар» (2002), Ә. Баянов «Ак канатлар» (1983), И. Юзеев «Мәңгелек белән очрашу» (1985), Роберт Әхмәтҗанов «Хәтер елгасы» (1980), Рәшит Әхмәтҗанов «Моңлану» (1990), Р. Фәйзуллин «Сайланма әсәрләр» (1992, 1993), Р. Мингалим «Шигырьләр һәм поэмалар» (1987), Г. Рәхим «Үз җиремдә үз җырым» (1986), Р. Гатауллин «Гомер уртасыннан хатлар» (1984), М. Әгъләмов «Киләчәккә кайту» (1987), «Мин әйттем» (1991), М. Галиев «Су буеннан әнкәй кайтып килә» (1992), Ә. Гадел «Рух бәйрәме» (2002), Ф. Яруллин «Күңел яктысы» (2003), З. Мансуров «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» (2003) кебек җыентыкларында вөҗдан, намус, ышаныч, сафлык кебек изге әйберләр турында уйланалар.

Гамил Афзал (1921—2003) олы тарихны халык хыяллары югарылыгыннан килеп бәяли, туган иле аңа фаҗигале һәм бөек үткәне белән газиз.

Еракларлан килде ул, гасырлар түреннән,
Риваятьләр, җырлар аһәңенә төренгән.
Елаган-көлгән,
Жиңгән-җиңелгән,
Алтын өмет дигән рухым минем.

(«Рухым»)

1957 елда басылып чыккан «Кар сулары» исемле беренче җыентыгыннан алып, Г. Афзал чынбарлыкның ямена тап төшерүче кешеләрне үткен сатира ярдәмендә камчылауны, кояш яктысына тартып чыгаруны язучылык максаты итеп калкытып куя.

Аның үткен каләме тудырган «Тәнкыйть сүзе», «Әсмабикә җаным, ахирәт», «Тотып җибәр, апаем», «Шәрифулла күршем белән», «Өф-өф итеп», «Ярый, карчык», «Әгәр мин директор булсам» кебек халыкчан юмор һәм ачы телле тәнкыйть белән сугарылган шигырьләреннән башка, хәзерге сатирик поэзияне күз алдына китерүе кыен. Алар — халык телендә, күп еллар дәвамында эстрада түрендә.

Г. Афзал сатирасы хаклыкны ялганнан аеруда — арадашчы, яшәешнең авырлыкларын җиңүдә — ярдәмче, кайгыда — юаныч, шатлыкта — сердәш, көрәштә — киңәшче. Г. Афзал каләме тудырган типларның төп үзенчәлеге — тышкы күренеше белән асылы арасындагы каршылык.

«Минем хатын түрә булган» шигыренең герое Габдрахман абзый үзе турында гаять югары фикердә яши. Ләкин гаҗәп

хәл. Танау Сафура мөдир булып ала, хатыны үсә, ә ул Әптери булып кала бирә. Аның күңеле әрни, кимсенә, рәнҗи.

Хатын — баш, значит, ә син аңа,
Габдрахман иптәш, муенмы?
Уенмы!

«Мыек борам» шигырендә дә, кеше күрмәгәндә «гайрәт белән мыек борам» дип, һәрнәрсәгә битараф кешене мактаган булып фаш итә шагыйрь.

Г. Афзал иҗади гомере буена эчтәлеккә бәрабәр шигъри калыплар, сүз байлыкларына үтеп керү алымнарын яңарту, кешенең катлаулы рухи дөньясына үтүнең яңа юлларын эзләвен дәвам итте.

Шәүкәт Галиев (1928—2011) — нечкә хисле, тормышчан нигезле лирик, чәчрәп торган шаян телле юморист һәм дөньякүләм танылган балалар язучысы.

Шагыйрь дөньяны һәм шәхес кичерешләрен каршылыклары белән кабул итә, иҗат ялкыны белән яшәгән кешене күтәрә, үстерә. Аның «Таң шатлыгы», «Хәтимә апа», «Нюра», «Атам исеме, балам исеме белән...» шигырьләре, дүрт һәм сигез юллы парчалары кеше хисләренә сизгер булулары, нечкә психологик күзәтүләре белән күңелдә кала. Менә бер мисал:

Ерак планетаның вәкилләре
Килеп җиргә төшсә, фаразан,
«Ничек аңлашырбыз?»— диеп инде,
Галимнәр баш ватып караган.
Төшенерләр иде дуслык ымын,
Бер-берсенә кулын сузганда!
Аңаргача, җирдә яшәүчеләр,
Аңлашалсак иде үзара!

Ш. Галиев — Тукай мирасына, халык иҗаты казанышларына турылыклы шагыйрьләрнең берсе. Аның лирик герое эчке серләрен, «мең кешенең мең тавышына» якын күңел тирбәлешләрен, шәхси тәҗрибәсен укучысына ышанып сөйли, аны көрәшкә, бәхәскә чакыра («Җиргә якын...», «Киткән чакта...», «Сугышларда калган...», «Чаң турында баллада» һ. б.). «Дошманнарга рәхмәт», «Сәер кеше» кебек шигырьләрендә, шаяртկан булып, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең пакьлеге, күркәмлеге өчен көрәшә.

Ш. Галиевнең «Шомырт чәчәкләре ак кына» (Х. Вәлиуллин көе), «Кыңгыраулы мәктәп еллары» (Р. Хәсәнов көе), «Шалт, Мөхәммәтҗан» (Р. Хәсәнов көе), «Юл җыры» (Ш. Мәҗитов

көе), «Ник яңара сагышлар?» (Ф. Әхмәдиев көе), «Бар икән күрәселәр» (Х. Вәлиуллин көе) кебек моңсу һәм дәртле, җитди һәм шаян җырлары халык телендә, халык күңелендә яши.

Балалар поэзиясенең бүгенге уңышлары Ш. Галиев исеменнән аерылгысыз. Ул нәниләрнең дөньяны аңларга омтылышын, холкын, характерын белеп, сиземләп эш итә. Аның геройлары ихлас күңелле, самими, эчкерсез, хыялга бай, кирәк вакытта хәйләкәр («Камырша», «Физзарядка ясый куян», «Магнитофон онытмый», «Борау», «Пәрәмәч»). Аның Шәвәлие, Камыршасы балалар дөньясында җыелма образлар булып киттеләр.

Халык иҗатына, сөйләм теленә таянып, Ш. Галиев балалар поэзиясенең сәнгатьчә фикерләү мөмкинлекләрен баетты, үстерде, Роберт Миңнуллиннар буынына юл ачты.

Хәзерге поэзиядә уйлану рухы, анализ, шәхеснең туктаусыз үзгәрә килгән рухи дөньясына игътибар үсә. Фикернең бәясен, кадерен, сүзнең тәмен, урынын белеп, тормыш һәм кеше турында җитди уйланып язылган сабыр холыклы, әмма тирән эчке янулы, үз артыннан ияртеп китәрдәй кешелекле хисле шигырьләр арта бара.

Кеше иҗат миссиясен
Үтәр өчен туа.
Аның ничек үтәлүен
Вакыт карап тора,—

дип яза яңа чор татар поэзиясенә нигез салучыларның берсе С. Баттал.

Роберт Миңнуллин «Вакыт» шигырендә бу төшенчәнең мәгънәсе безнең заманда бик нык үзгәрүе, «гасыр белән сәгать» арасындагы юлның кыскара баруы турында уйлана.

Тыгызлана Вакыт —
Тора-бара нишләр?
Бер елга да җитми
Бер гасырлык эшләр.

Шагыйрьләр галәмнең, яшәешнең, рухи дөньяның барча яклары бер-берсенә тыгыз бәйләнгән дигән иманга киләләр, шул камиллекне аңларга тырышалар. «Мин Геракл кебек бик борынгы, Компьютер кебек өр-яңа»,— дип яза Г. Рәхим «Автохарактеристика» шигырендә. Үзәктә үткән белән хәзерге арасындагы бердәмлеккә ышаныч ята. Алдагы юллар фикергә ачыклык кертә: «Яфрак, бөҗәк, диңгез ничек килсә,— Шулай килдем мин бу дөньяга».

Без — Кояштан, Кояш яктысыннан,
Без — Кояштан, Кояш нурыннан,—

дип яза Х. Әюпов «Без Кояштан...» шигырендә.

Сабан туена багышланган шигъри бәйләмгә кергән «Галиҗәнап», «Көрәшче» шигырьләрендә Фәнис Яруллин кешене иң гадәти яшәеш күренешләрендә ала, гадилектә бөеклек, табигыйлектә олылык күрә.

Хәзерге поэзия турында сүз чыкканда, шагыйрьләр иҗтимагый гаделлек, тулы хакыйкать өчен көрәшкә үзләреннән өлеш кертәләрме дигән сорауның тууы табигый.

Күпчелек татар язучылары хәрәкәт һәм эзләнү заманы килеп җитүне, иҗат кешеләре өчен яңа мөмкинлекләр ачуны дөрес сиземлиләр, халыкның бәйсезлек өчен көрәшенә юнәлеш бирү, ярдәм итү рухы белән яшиләр. М. Шабаев «Ачыктан-ачык», Н. Арсланов «Гласность» турында», Г. Рәхим «Бөек халык», К. Сибгатуллин «Хөкемдар», К. Латыйп «Юл бирегез, гамьсезләр», Р. Харис «Үзгәрәбез» кебек шигырьләрендә тормышта барган яңачалыкны күңел, йөрәк һәм хис хакыйкате дәрәҗәсенә күтәрү турында уйланалар.

«Гаделлеккә сусап алҗыган Кеше җаны өчен көрәш бара. Кеше җаны тора үзәктә»,— дип яза К. Булатова «Соң булса да...» шигырендә.

Кайбер шигырьләрдә азатлык өчен көрәш темасы Сталин тиранлыгы, аның корбаннары турында уйлануларга алып чыга (Н. Арсланов «Каршыма», М. Әгъләмов «Остаз»).

И. Юзеевнең «Сез кабызган утлар», Р. Гатауллинның «Гасыр уртасыннан хатлар», Р. Мингалимнең «Ике авыл арасы», Г. Садәнең «Көмеш йөзек», Р. Зәйдулланың «Күпер», Р. Шәриповның «Фатыйма мәхәббәте» кебек әсәрләре җәмгыятьнең рухи үсешен, әхлакый эзләнүләр киңлеген чагылдырган поэмалар булдылар.

Поэзиядә оратория (Р. Харис «Кеше»), либретто (Г. Рәхим «Каһәрләнгән мәхәббәт», «Аяз көнне яшен»), шигъри драма (И. Юзеев «Мәңгелек белән очрашу»), сонет (М. Хөсәен, Р. Зәйдулла) кебек жанрлар тернәкләнә.

Рәдиф Гатауллинның «Лирик шаярулар» бәйләменә хас юмор хисе тормыш муллыгын, кешенең гадәти табышларын, шатлыгын шигъри дулкында кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Роберт Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Р. Фәйзуллин, Р. Зәйдулла иҗатларында кыска шигырь яңа мөмкинлекләрен ача бара.

Әхмәт Гадел дә тар мәйданда төгәлләнгән фикер әйтү рухы белән эзләнүләр юлына чыга.

Акыл —
күз кабагы яшермәгән
тынгысыз күз.

(«Акыл»)

Корал алсаң, илне саклыйм дип тот,
Каләм алсаң, җирне аклыйм дип тот.

(«Яшьләргә бер киңәш»)

Хәзерге поэзиядә олы язмышлы тарихи шәхесләргә игътибар үсү шулай ук табигый. Үткәнен зурламаган, аның белән горурланмаган халыкның киләчәге юк. Бәхтияр Канкаев, Акмулла, Тукай, Сәйдәш, Кариев, Җәлил, Кәрим, Туфан кебек татар милләтенең мәгърур уллары эшчәнлегенең мәгънәсе безнең көннәр рухына якынлыгын аңлауга омтылыш көчәя. С. Хәким 1971 елда «Тукай дәфтәреннән» шигъри бәйләмен, «Кырыгынчы бүлмә» поэмасын төгәлли.

...Тукай тормышының соңгы көннәрен уздырган «Болгар» кунакханәсенең кырыгынчы бүлмәсе. Йозаксыз, ачкычсыз, кысан, суык, әмма дусларга, фикердәшләргә бай бүлмә. Хөррият рухы белән сулаган шигъри бүлмә татар халкының шатлыгын, кайгысын үзенә иңдерә.

С. Хәким поэмасы басылып чыкканны гына көткәндәй, И. Юзеев белән М. Әгъләмов яңа чор татар поэзиясенә нигез салучының үз чоры өчен кыю шәхес, халык бәхете өчен көрәшче булуын яңача яктырткан «Очты дөнья читлегеннән...», «Тукай хатлары» исемле поэмаларын язып чыктылар.

Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш», Р. Харисның «Җәлилчеләр», З. Мансуровның фашизм крематориенда яндырылган өлкән офицер, шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй истәлегенә багышланган «Балкыш» поэмалары хәзерге поэзиянең мөһим казанышлары рәтенә бастылар.

Шагыйрьләр, остазларының тормыш юлы турында төкмичәчми сөйләүгә, иҗатларын тулы яктыртуга дәгъва итмичә, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә үз бәяләрен бирәләр, шәхси кичерешләрен ачалар.

Татар халкының олы һәм фаҗигале, үкенечле һәм героик тарихында «ак таплар», өйрәнелмичә, ачыкланмыйча калган серле битләр җитәрлек.

Кыска гына вакыт эчендә берничә тарихи поэма укучыга барып җитте. «Ант суы»нда Р. Харис Борынгы Русь һәм Болгар дәүләтләре арасында мең ел элек булган үзара килешүгә кул кую вакыйгасына үзәккә халык дастанын — «Идегәй» поэмасын — нигез-өлге итеп алса, Г. Рәхимнең «Аяз көнне яшен», Ә. Баяновның «Алтын кашбау» әсәрләренең нигезендә халык тарихының аянычлы бер чоры — Бөек Болгар дәүләтенең монголлар тарафыннан туздырылуы ята.

«Алтын кашбау» шигъри трагедиясе — тыгыз һәм хәрәкәтчән сюжеты, үткәнне бүгенге биеклектән килеп бәяләве, шигъри яңгырашы белән татар поэзиясенең казанышы саналырга лаеклы әсәр.

Үргә басып, өркеп кешни Вакыт, —
Унөченче гасыр уртасы.
Йорт-диварлар тетелеп, эри металл,
Дөрләп яна нигез — чор ташы.

«Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр» поэмаларында Ә. Рәшитов Казан ханлыгы чорының өч олы шәхесе турында уйлана. Беренче әсәрдә ул ярым тарихи, ярым легендар Казан ханбикәсе Сөембикәнең кешелекле, тормышчан, җанлы образын тудыруга ирешкән.

Ник диеп елыйсыз, әбиләр?
Абыйлар, кайгыгыз ни икән?
Батырлар, ник боек сез болай?
Тик бер сүз җавапка:
— Сөембикә...
Рәхимле, шәфкатьле, сөекле
Сөембикә бар иде ул илдә.
...Бу иңрәү-сыкрану ишетеп
Моңайган шикелле Идел дә.

Шул рәвешле, шигърияттә сәяси, икътисади мәсьәләләр бергә үрелеп үсә. Дөрес, илдә барган үзгәрешләрне, эчке агымнарны, күңел, җан җылысы белән баетып, табигый агымда шигырьгә күчерү җиңел түгел, аның өчен вакыт һәм өлгереп җиткән сүз осталары булу кирәк.

Әйтик, Татарстанның бәйсезлеге, тулы хокуклы ил булырга омтылышы турында шигырьләр күп языла, күп басыла. Әмма акыл, теләк буенча гына туган шигырьләр озак яши алмый. Бу төр тезмәләрнең күпчелегенә фикер яңалыгы, ышандыру көче һәм кичереш тирәнлеге җитенкерәми.

Рәшит Әхмәтҗанов — татар милли шигъриятенең нурлы баганаларыннан берсе. Р. Фәйзуллин аны «замана давылларын җанына яшергән ир-егет» дип атый. Ә җаны аның ифрат пөхтә, җыйнак, эчкерсез шигырьләрендә, «Бишташ», «Аучылар кибетендә» кебек поэмаларында ачыла.

«Адашкан болыт» (1990) китабында Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) — тормыш һәм олы дөнья, тарих турында җитди фикер йөртүче җитлеккән шагыйрь. «Игенче» («Сөргеннән качкан кулак»), «Итек», «Өн», «Сөембикәнең хушлашу догасы», «Имансызлар» шигырьләрендә халык язмышы, шәхес культы шаукымы турында уйланса, авыр тойгылары белән уртаклашса, «Ат йокысы», «Атлар чаба», «Ат карагы», «Ике ат турында баллада» кебек әсәрләрендә кешене янәдән табигать кочагына, бала чагына алып кайту рухы белән яши. Зәвыгы нечкәрә, чигештәге матур бизәкләре, энҗе гәүһәрләре арта бара.

Хәзерге татар поэзиясендә хатын-кыз шагыйрәләр авазы шактый көчле яңгырый.

И. Юзеев төзеп чыгарган «Кызлар җыры» (1977) китабы гына да хатын-кыз шагыйрәләр салган юлны, изге йолаларны дәвам иттерерлек үзенчәлекле тавышлар, көчләр барлыгын күрсәтә.

Җыр кайчан туа, дисезме?—
Кош тоткан чакта туа;
Йөрәгеңне уа-уа
Ут йоткан чакта туа,—

дип яза Энҗе Гыйрфанова.

Аның уйлануларын Флёра Гыйззәтуллина «Кемнәр җыр башлар?» шигырендә дәвам иттерә.

Туган җирне олылау — татар поэзиясенең йөрәк түрендә туган олы хис. Үзләренә җан, илһам биргән, шатлыкта да, кайгыда да таяныч, өмет йолдызы булган, туып үскән төбәккә, Г. Тукай, Һ. Такташ, Х. Туфан, С. Хәкимнәр истәлегенә шагыйрәләребез иң гүзәл шигырьләрен юллыйлар. «Актанышым» әсәрендә Роза Хәлиуллина туган якны олылап чыга.

Шулай да хатын-кыз шагыйрьләр иҗатына фикерләү киңлеге, хис тыгызлыгы, сүзнең эчке егәрен ачу җитенкерәми. Араларында Саҗидә Сөләйманова кебек олы шәхеснең булмавы үзен сиздерә.

Татар әдәбиятына элек-электән ак, пакь, инсафлы шәхесләр хезмәт итте, аның абруен шулар күтәрде. Акъегетнең (Рөстәм Фәйзуллин) «Төнге сулар» китабы (1990) шундый уйлар ту-

дыра. Шагыйрь мәхәббәтен дә, нәфрәтен дә ачык һәм төгәл әйтеп бирү юлын сайлаган. «Зиратта», «Мәҗүси шомлык», «Олыгаю», «Көнбагыш бага кояшка», «Тамчылар» бәйләме шундый хисләр уята.

Гасыр тузаннары тузмый,
хәтер йокласа...
Акыллылар алга бара
Үткәне аша...

(«Тамчылар»)

Татар поэзиясендә әйдәп баручы шагыйрьләрнең берсе булган Харрас Әюпов «Сабыр савытлары» (1992) китабында урын алган «Авыл җаны», «Көй эзләү», «Су хәтере», «Көзге» кебек кыска, әмма тыгыз эчтәлекле поэмаларында, күңел байлыгын, фикер иркенчелеген эченә алган лирик шигырьләрендә рухи дөньяга игътибарлы, тормыш киеренкелеген фәлсәфи уйларга төреп, төгәл һәм ягымлы итеп ачып сала.

Шәһәрнең кысрыклавына түзә алмаган «авыл җаны» әнкәсе кыяфәтендә яши.

...Үз-үземә урын табалмыймын —
Кая куйыйм сине, авыл җаны?!

(«Авыл җаны»)

Шагыйрь йөрәге ыгы-зыгылы тормышта тынычлык, рухына таяныч таба алмый. Сәбәбе ачык.

Сиңа шатлык каян килсен, Казан,
Сатлыклардан булган бәхетең?!

(«Су хәтере»)

Шигърият чишмәсе саекмаса да, әдәбиятның бу авыр һәм катлаулы, миһербанлы һәм шәфкатьле төренә яңа көчләр берән-сәрән генә килә.

Чувашстаннан Ркаил Зәйдулла, Рөстәм Сүлти, Башкортстаннан Ләис Зөлкарнәй, Татарстаннан Газинур Моратов, Ләбиб Лерон кебек урта буын шагыйрьләрнең соңгы еллардагы актив эшчәнлеге татар поэзиясенең киләчәгенә өмет уята.

Газинур Моратның «Оча җырлар» (1991) җыентыгына кергән «Кош хокукы», «Черек күл», «Фидаилләр кирәк», «Тәүбә» шигырьләре, «Атом-кирмән» поэмасы хис-тойгыларының яңалыгы, тирәнлеге, ихласлыгы һәм сурәтләү чараларының заманчалыгы белән җәлеп итәләр.

Буталчык, болгавыр заманда да шагыйрь дөреслекнең, изгелекнең ахыр килеп җиңәчәгенә тирәнтен ышаныч белән яши.

Һәр уйның килә
Яхшы буласы —
Мәҗүси булып
кабат туасы.
Һәр җанның килә
Изге буласы...
(*«Мәҗүси уй»*)

Шагыйрь ил тарихы, халык язмышы турында әрнеп, борчылып яза.

Ркаил Зәйдулла шигырьләрендә иҗтимагый күренешләр шагыйрьнең шәхси тормышы һәм кичерешләре җирлегендә тирән мәгънәле шигъри юлларда, тәэсирле һәм яңача сурәтләү чаралары ярдәмендә ачылалар. «Урыс кышын озату» (1993) җыентыгында ул тормышка мөнәсәбәтен аныклаган, җитлеккән шагыйрь буларак чыгыш ясый. Хәсән Туфанга багышланган «Койрыклы йолдыз» поэмасы — заманча фикерләү үрнәге. Олы шагыйрь язмышы турында уйланулар аша ул татар халкының тарихын иңли.

«Матәм» әсәрендә Әфганстанда һәлак булган корбаннарга шигъри һәйкәл куеп, зирәклек, акыллылык үрнәкләрен Болгар иле, Казан дәүләте биргән шәхесләр эшчәнлегендә таба. Халкының язмышы өчен күңеле әрни, йөрәгенә кан сава.

Үз язмышын башка халыкларга
Тапшырган да
татар — мескен кавем,
Тыңлап ята хәзер хуҗаларның
Үз исеменә матәм уйнатуын.

Гаделлек һәм матурлыкның ахырда җиңеп чыгасына ышана шагыйрь («Литва», «Һәйкәлләр», «Утлы көпчәк», «Сабакташ»).

Рөстәм Сүлти — урта буын шагыйрьләреннән. «Мин — шигырьдән» (1992) җыентыгының үз аһәңе, моңы бар. Фикер поэзиясе агышларын ул кайнар, дәртле хисләре, яшьлек рухы белән җылыта. «Соңгы кәрван», «Тетрәү», «Сорау», «Туган туфрак», «Соңгы учак» кебек шигырьләрендә ул фәлсәфи лирика юлына чыга, шактый төгәллеккә, сәнгатьчә камиллеккә ирешә.

«Тәрәзә» поэмасы һәм «Кый-гак-к» балладасы — тормышның төрле кыйтгаларын, тарих яссылыкларын колачларга мөмкинлеге булуга дәлил.

Тораташтай Тарих инде миннән
Ут сорамый. Уеннардан уймак.
Үткәндәге шат-шәүкәтен сагынып,
— Сак,— дип дәштем...
Җавап килде:
— Кый-гак-к!

(«Кый-гак-к»)

Поэзия туктаусыз яшь көчләр, яңа авазлар, аһәңнәр өстәлеп торганда гына яши, үсә ала. Шигърияткә соңгы елларда килгән каләм ияләре арасында үзенчәлекле шәхесләр аз түгел. Шәүкәт Гаделша, Сөләйман, Фәүзия Солтан, Фәйрүзә Мөслимова, Рәмис Аймәт, Луиза Янсуар, Марат Закир, Ленар Шәех кебек иҗади йөзләре, шигъри индивидуальлекләре ачыла килгән шагыйрьләр татар поэзиясенең киләчәгенә өмет уяталар.

Хәзерге поэзиянең абруен күтәрү өчен, халык тормышын, халык тарихын шәхси кичерешләредәй сурәтләү юлында кыюлык сорала.

Шигъриятнең үлемсез үрнәкләре үз халкының тормышын белгән, рухи ихтыяҗларын йөрәге белән тоеп яшәгән, шуларны яңача ачып биргән сүз осталары иҗатында туа.

Төрле буын һәм юнәлеш шагыйрьләре бердәмлеген тәшкил иткән хәзерге татар поэзиясе андый исемнәргә дә, халык күңелендә үз урынын алырга лаеклы әсәрләргә дә бай.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәзерге татар поэзиясенә нинди үзенчәлекләр хас? Ул алдагы унъеллыклардан кайсы яклары белән аерылып тора?

2. Элегрәк иҗат ителеп тә, соңгы елларда гына дөнья күргән әсәрләрне атагыз. Тыелуның сәбәпләрен ачыклагыз.

3. Тарихи темага игътибар артты, дидек. Ни өчен?

4. Соңгы елларда поэма жанрында кемнәр актив эшли?

5. Сүзләре 80—90 нчы елларда иҗат ителгән яраткан җырларыгызны атагыз.

6. Хәзерге татар поэзиясенә багышлап, шигърият кичәсе уздырыгыз.



Равил Фәйзуллин

(1943)

Бала өчен әти — Тәңре, Алла кебек изге һәм газиз кеше. Ана — күңелнең, җанның иң нечкә кылы, изге угы, чишмә башы, якыннарның якыны. Чөнки алар сине дөньяга китерә, күкрәк сөте белән яшәү тереклеге бирә, беренче адымыңны атларга, тәүге сүзеңне әйтергә өйрәтә, олы һәм мәшәкатьле дөньяга алып керә. Калганы үзеңнән тора.

Матур әдәбиятта ата-ана турында йөрәк түрендә, җанда бөреләнгән гүзәл җырлар, саф хисле шигырьләр, күләмле әсәрләр бик күп иҗат ителгән. Изге җаннар турында яңа сүз әйтеп булмас төсле тоелырга да мөмкин.

Юк, алар хакында рәхмәтле сүзләрнең барысы да кәгазьгә төшмәгән икән әле. Татар шагыйре Р. Фәйзуллин «Минем әти» (1964), «Менә без дә үсеп җиттек, әни!» (1968) шигырьләрендә әти-әнисен үзенчә бәяли, үзгәчә иркәли, олылый алган.

Әтисен күкләргә чөеп мактамый шагыйрь. Киресенчә, ул аның иң гади һәм гадәти бер кеше булуын искәртә: философ та, галим дә түгел, сугышта яраланып кайтса да, герой булмаган икән аның әтисе. Кыскасы, шагыйрь атасын аллалар, фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәреп кую юлына басмый. Аны җир кешесе итеп тасвирлый.

Шигырьнең үзәгендә капма-каршы кую (антитеза) алымы ята. Әтисен тәнкыйтьләгән булып, дикъкатьне шул якка юнәлтә дә нәтиҗәсен ясый. Шагыйрьнең әтисе, җырчы булмаса да, «бишек силәсен, зыңлап торганын ясарга өйрәнгән», рәссам булмаса да, улына «салават күперен чыкта да күрә белергә өйрәткән», кирәк чакта йомры сүзләрен дә таба белгән икән. Чынлыкта аның әтисе яшәү, тормыш итү өчен кирәкле

бөтен һөнәрләрне белгән һәм улына тапшыра алган. Аның атасы хезмәт сөюендә, «сугышта алган җөен» яшерүендә, тыйнаклыгында һәм өлкәннәрчә кырыслыгында бөек шәхес, туачак буыннар өчен үрнәк кеше буларак күз алдында кала.

Р. Фәйзуллин әтисен күңелдә, хәтердә калдырырлык, кабатланмас һәм шул ук вакытта җыелма образ итеп тудыруга ирешкән. Һәркем аны үзенә якын кешесе белән янәшә куя, чагыштыра ала. Шигырьнең соңгы юллары горур һәм тантаналы яңгырый: «Син бары әти, әти». Шундый әтиең булу шатлык, бәхет ул, ди шагыйрь.

«Менә без дә үсеп җиттек, әни!» шигырендә җылы, ягымлы лирик аһәң өстенлек итә.

Әтисе турындагы шигырьне язганда, Р. Фәйзуллинга бары егерме бер яшь иде. Хәзер инде ул — фани дөньяда җиде дистәләп ел яшәгән кеше, күп дистәләгән китап авторы, Татарстанның халык шагыйре, озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире. Артык ягымлы, сентименталь булудан, тымызык, моңсу хистән дә курыкмый.

Менә без дә үсеп җиттек, әни!
Син әллә ни үзгәрмәгәнсең,
элеккедәй мөлаемсың.
Күзләр гел шул,
яшьләр генә менә...

Әсәрнең нигезендә гомер агышы турында уйлану ята. Кайтып караганда, тирәлектә үзгәрешләр сизелми, «кыр казлары, элеккечә» шагыйрь үскән йортның түбәсеннән каңгылдашып узалар, Сабантуйлары «нәкъ искечә, тау башында үтә икән». Бала үсә, ана олыгая. Килер бер көн, инде аның да оныклары, күтәрелеп җитеп, җылы сәламнәрен иңдерер. Шигырьнең соңгы юллары күңелгә кеше гомеренең кыскалыгы турындагы, җанны тетрәткән, йөрәкне телгәләгән авыр хисләрне алып керә: «Бар да әйбәт, әни. Моңсу гына менә».

Дөньялыкта башкарган эш, үстергән буын, игелек кала. Дәвамлылык яши. Кешелекнең яшәү көче шунда.

Хәзерге татар шигърияте ананы олылауга зур өлеш кертте: Р. Миңнуллин «Әти төсле», «Әнкәмнең догалары», М. Галиев «Су буеннан әнкәй кайтып килә», Р. Вәлиев «Нигә, әни, нигә картаясың?» һ.б. Бу җыр хәзинәбездә татар халкын милләт буларак саклап калган анага рәхмәт хисләре ташый.

Р. Фәйзуллин дөньяга яңача, заманча карашы белән укучыны сискәндереп җибәргән «Нюанслар иле» исемле шигырь-

ләр көлтәсе белән килеп керде әдәбиятка. Язгы ташкын төсле бәреп керде.

Нигездә бер, ике, өч юлдан торган бу парчаларда салмак һәм тигез агыш, рифма, эчке тәңгәллек, ярашу кебек, татар поэзиясенең күнегелгән сыйфатларын сөйләм теле, хисси борылыш, халәт, көтелмәгән сынландырулар, янәшәлекләр алыштыра.

Кесә тулы елан мөгезе!
(«Яшь чак»)

Каршы төшсә дус дуска:
«Тел — озын, гомер — кыска!»
(«Искәртү»)

Кызлар күптән йоклый,
Кефир шешәсендә гөлләр
таңны көтә.
(«Тулай торакта»)

Һәркайсы мөстәкыйль фикерне, тормыш фәлсәфәсен, зиһен очкынын күзәтүне эченә алган бу шигырьләр тәнкыйтьтә бәхәс уятты.

Берәүләр аны татар поэзиясенең шигырь калыпларын җимерүдә, күркәм казанышларына кизәнүдә гаепләргә ашыкса, икенчеләре, өч юллы шигырь халык җырларында күптәннән яши, иркен ритмлы иҗек мәкаль-әйтемнәргә барып чыга, ирекле, ак шигырь үрнәкләре татар поэзиясе өчен чит-ят күренеш түгел дип, яшь шагыйрьнең кыю эзләнүләрен яклап чыкты.

Бәхәсләр ялкыны акрынлап тынды. Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләре һәм тынгысыз эзләнүләр рухы калды. Тар мәйданда кичерешне үсештә ачу, фикерне җәеп җибәрү мөмкинлеге чикләнгән булса да, кыска шигырь фәлсәфи мөһерне, хикмәтне эченә ала һәм укучыга нәтиҗәне үзенә ясарга, зиһенен эшкә җигәргә җай тудыра, урын калдыра.

Р. Фәйзуллинга танылу иртә килә: яшьли М. Җәлил, Г. Тукай исемендәге бүләкләргә лаек була, С. Хәким, Ф. Хөсни, М. Мәһдиев, М. Кәрим, Г. Ахунов кебек танылган сүз осталарының җылы сүзен вакытында ишетә.

Хәзер Р. Фәйзуллин — татар поэзиясенең горурлыгы, аның алгы сафында атлаучы җитлеккән шагыйрьләрнең берсе.

Аның иҗаты ифрат киң тармаклы. Шагыйрь Тарих — Заман — Вакыт кебек мәңгелек төшенчәләр турында уйлана, аларның эчке мәгънәсенә, фәлсәфәсенә үтеп керергә омтыла. Кеше — бу дөньяда олы Вакытның кунагы.

«Бу юлларны сагынырбыз әле!
Тик кайтылмас бүтән менә...»
Әйе, сагынырбыз. Вакыт — Алла,
Ә без бары кеше генә.

(«Бу юлларны сагынырбыз әле...»)

Шуңар да кеше Вакыт эчендә югалып калмаска, үз юлын, тормыш мәсләген эзләргә, таба белергә тиеш.

Бөтен өмет, бөтен ышаныч —
үзем өчен үзем генә белгән
Вакыт эчендәге Вакыт.

Әгәр дә кеше, чор сулышын, дәртен, таләбен тоя алмыйча, замана «арбасыннан» төшеп калса, кемне гаепләргә соң? Шагыйрьнең җавабы ачык:

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.

Мәңгелек җиһанда үзен шәхес буларак раслый, саклый алган, изелсә изелгән, әмма бөгелмәгән кешеләр бар икән.

Ә бит бар кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданын саклаган.

(«Җаныңның ваклыгын...»)

М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй кебек үлемнәре аша үлемсезлек югарылыгына күтәрелгән бөтен һәм күркәм шәхесләр шагыйрьгә аеруча газиз һәм якын. Шул ук вакытта, «мәңгелекнең рәшәсендә тибрәлер» өчен, сугыш кырында үлеп калу мәҗбүри түгел, ди шагыйрь.

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
Бердәнбер юл түгел тормышта...

(«Үлемнәре белән үлемсезлек...»)

Р. Фәйзуллин үткәннең бөекләрен хөрмәт итә, аларга табына. Шул ук вакытта аңа бүгенге тормышны алып баручы гади кешеләр дә якын.

«Ветеран җыры», «Кояш бер әйләнгән арада...», «Кер чайкыйлар кызлар...», «Минем әти» шигырьләрендә ул гадәти һөнәрле кешеләргә, гомумән, тереклеккә дан җырлый.

Аның бөтен иҗаты — укучы белән әңгәмә, кешелек язмышы турында уйлану, күңелен биләгән уй-хисләре белән уртаклашу. Тирән фикер бәйләнеше еш кына ирекле ритмиканы сайлый.

Р. Фәйзуллин туып үскән җирен үзенчә олылый.

Беләм, кояш астында бар
шундый шифалы яклар:
кадасаң чыбык Җиренә —
яшьнәп чыга яфраклар!
Минем дә бар үзем өчен
шундый як — Туган ягым!
Дога иңгән һәр төшеннән
чишмәләр чыга аның!

(«Туган ягым»)

Шигърияттә заманча фикерләүне алга сөреп, чордашына төбәп, аның фикер, зиһен эшчәнлеген күздә тотып иҗат итсә дә, Р. Фәйзуллин халыкның җыр лирикасын да читләтеп үтми. Киресенчә, иҗатының җитлеккән чорында ул эзлекле һәм төгәл калыпка салынган шигырьгә өстенлек бирә башлады. Күп кенә лирик шигырьләренең җыр булып китүе табигый: «Аккошлар» (Ф. Әхмәтов көе), «Мин сине ничек яраттым» (С. Садыйкова көе), «Менә без дә үсеп җиттек, әни!» (Л. Хәйретдинова көе), «Синең өчен яшим» (Р. Абдуллин көе), «Тимим күңелемә» (Р. Яхин көе), «Якты моң» (Ш. Шәрифуллин көе) һ.б.

Мәхәббәт лирикасында да ул олы хисләр, кешелеклелек тарафдары булып кала. Бөтен иҗатына эчке бер илаһи яктылык сирпеп торган бу тойгы Р. Фәйзуллин иҗатын яңа баскычка күтәрә. Хәзерге татар поэзиясендә мәхәббәт турында шулчаклы тирән итеп, үз йөрәк кичерешләре белән җылытып, олылап сурәтләгән шагыйрьләр күп түгел.

Иҗатында бер-бер артлы «Мәхәббәт күзсез була, ди...», «Син — теләп алган сагышым...», «Мәхәббәттә күпме яндык», «Сөйдем аны, шаштым!» кебек тирән лирик аһәңле, моңлы һәм дәртле, йомшак һәм кырыс шигырьләр дөньяга килә.

Лирик геройның мәхәббәте шашкын, ярсу, фаҗигале, сагышлы булырга мөмкин. Ләкин ул бервакытта да ялган хис булмас.

Аның шигырьләре «холыклы», тирән кичерешле.

Сөйдем аны,
Шаштым!
Җаным
күкләргә күкрәп менде!
Әйттеләр: бигрәк сүрән,
басынкы бала инде...
Берзаман: «Гашыйк икән!» — дип,
Илгә сүз чыккан иде.
...Ә мин инде ул вакытта
аны оныткан идем.

(«Сөйдем аны, шаштым!»)

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы катлаулана, төрләнә бара, каршылыклы хисләре авыр, күңелсез, әмма тормышчан күренешләрне дә читләтеп үтми.

Чакырдың да,
үзең киткәнсең...
Синең тәрәз каршысында
басып торам.
Буп-буш урам.

(«Чакырдың да...»)

Р. Фәйзуллин шигырьләрен төгәл һәм нечкә күзәтүдән, сыйдырышлы детальдән башка күз алдына китерүе кыен.

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!
Уйларны да, керләр кебек,
ак иткәнче, пакь иткәнче,
ах, чайкарга иде!

Гадәти бер тормыш күренеше белән башланып киткән «Кер чайкыйлар кызлар...» шигыре мөнәсәбәтләрнең сафлыгы, кешеләргә сөенеч, шатлык өләшү ихтыяҗы турында уйлануларга алып чыга, кер чисталыгы белән кеше яшәеше, үзара мөнәсәбәтләр арасында ассоциатив элемтә, күчеш туа.

Р. Фәйзуллин поэмага сирәк мөрәҗәгать итә. 60 нчы елларда бу жанрның ике лирик-публицистик үрнәген биргәннән соң («Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр»), 80 нче еллар башында гына кабат күләмле әсәргә алына. Татар халкының күренекле композиторы, яңа гасыр музыкасына нигез салучы Салих Сәйдәшев образына мөрәҗәгать итүе көтелмәгән бер яңалык булды.

«Сәйдәш» поэмасы (1980) — бу тарихи, олы һәм фаҗигале язмышлы шәхесне бөтен каршылыклары, ачышлары, сөенеч-көенечләре белән шигърияттә ачуга омтылуның беренче зур тәҗрибәсе.

Поэмада ике юнәлеш ачык төсмерләнә. Шагыйрь Сәйдәшнең тормыш юлын, биографиясен, шәхес һәм композитор булып үсү чорларын тәфсилле сурәтли. Иҗат кешесе язмышында барысы да әһәмияткә ия. Әмма поэманың иң көчле яңгыраш алган урыннары — татар җыры, татар моңы турында уйланулар. Чөнки «халыкларның җаны ул — җыр...» «Җыр язмышы — халык язмышы ул, ил язмышы белән беррәттән». Шагыйрь татар җырының яңгырашын, мәгънәсен, фәлсәфи эчтәлеген бәгырьләрне кискән моңга, зарлануга, елаусыктауга кайтарып калдыру белән килешми: «Юк, безнең җырлар —киңрәк, тирәнрәк! Ничек тоташ хәсрәттән торсын хезмәт дәрте тулы бу йөрәк».

Халык җыры турында уйланып, аның көченә, аһәңенә югары бәя биреп, Сәйдәш иҗатына шәхси мөнәсәбәтен ачыклауга күчә.

> Сәйдәш иҗатыннан эзләсәң дә
> Таба алмассың көйләр бер көнлек.
> Халык рухы кебек сәламәт ул,
> Юк аларда шыңшу, мескенлек.

«Әй дуслар, дуслар, дуслар» бүлеге тулысы белән иҗат кешесенең җәмгыятьтә тоткан урыны, аның язмышы турында уйлануларга багышланган.

> «Дус» сүзе бар. Бер иҗекле генә...
> Ә мәгънәсе — чиксез һәм тирән.

Бу төшенчә икмәк, туфрак кебек үк изге, әмма кешелек тарихында «дус» исеме белән сату итүләр, алдаулар, мәкерләр күп булган.

Сәйдәш тирәсендә дә, чын дуслардан бигрәк, олы шәхес кырында кул җылытучылар, аның талантын «интеллектуальный закуска» дәрәҗәсенә төшерүчеләр аз булмаган. Ялган «Дуслар... Уендашлар... Шешәдәшләр...» һәрчак булган һәм булачаклар, ди шагыйрь.

Әмма замана җилләренә, хәйләгә, битарафлыкка бирешми, сатылмый торган көч бар дөньяда.

Девальвацияләр ала алмаслык
байлыклар бар җирдә — бәхәссез!
Җан бәйрәме — сөю бәһасез!
Чын җыр бәһасе, талант бәһасе!

Тирән фәлсәфи фикер, гражданлык пафосы, горурлык хисе — «Сәйдәш» поэмасының төп сыйфатлары.

Соңгы вакыттагы шигырьләрендә дә Р. Фәйзуллин тормыш һәм табигать күренешләренә, яшәеш һәм рухи дөнья чагылышларына игътибарлы. Һәр күренештә, чуерташларны сугып ут чыгарган кебек, шигърият орлыгы күреп ала. Аны кешеләр күңеленә чәчә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Р. Фәйзуллин шигырьләренең уңышы нәрсәдә?

а) Шагыйрьнең, ил, чор вакыйгаларын йөрәге аша уздырып, халкын борчыган мәшәкатьләрнең үзәгендә булырга тырышуындамы?

ә) Ялкынлы фикерен, язгы су төсле, ярларына сыеша алмыйча ыргылган кичерешләрен тормышчан күзәтү белән куша алуындамы?

б) Бер караганда әһәмиятсез, вак-төяк күренгән төшенчәләрдә олы мәгънә, моң таба белүендәме?

2. Татар шагыйрьләренең батырлыгына биргән бәясе кайсы ягы белән үзенчәлекле?

3. «Сәйдәш» поэмасында биография сөйләүгә урын күбрәк бирелмәгәнме?

4. Р. Фәйзуллин сүзләренә язылган кайсы җырларны яратасыз? Аларның халык җырларыннан аермасын һәм уртаклыгын күрсәтеп бирегез.

5. Р. Фәйзуллин иҗаты турында шигърият кичәсе үткәрегез.

Ренат Харис
(1941)

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис әдәбиятка 60 нчы еллар башында Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Мингалим, Р. Гатауллиннар белән бер дулкында килә. «Хрущёв җепшеклеге» дип аталган бу дәвердә әдәбиятка, сәнгатькә беркадәр ирек бирелә, күп еллар дәвамында изелеп, кысылып яшәгән шигъри сүз, азатлык җилләренә битен куеп, халык күңеленә, рухына якыная төшә. Язучы фикерен өздереп, кичерешен ирекле калыпка салып бирү мөмкинлеген ала.

«Ренат Харисның миңа беренче чоры якын,— дип яза күренекле шагыйрь Сибгат Хәким.— Хисләр сафрак, хисләр кабатланмаган, образлар таушалмаган, шигырь табигый, кыскарак та, бөтенрәк тә. Фикерләр формага ятып тора».

Иҗатының бу үзенчәлекләре 1968 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыккан «Җир һәм кеше», ә 1969 елда «Кайтаваз» исемле беренче китапларында ачык чагылыш таба. Алдагы елларда да шагыйрь үсешендә тукталып калмый, эзләнү-уйлануларын дәвам итә, шигъри бәйләм, шигъри роман («Исемсезләр»), поэма, җыр жанрлары үсешенә мөһим өлеш кертә.

Р. Харисның татар поэзиясенә алып килгән яңалыгы нидән гыйбарәт соң? Нинди сыйфат үзенчәлекләре белән ул замандашларыннан аерылып тора?

Аның иҗаты өчен кешенең фикерләү рәвешенә, уйлану дөньясына үтеп керүгә омтылыш хас. Ул — шартлаулы, көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре.

Лирик герое — көчле, нык ихтыярлы шәхес (аның каләме тудырган Идегәй, Мулланур Вахитов, Муса Җәлил, Фатих Кәрим кебек тарихи шәхесләр образлары — шуңа мисал).

Рухи дөньяны да шагыйрь моң, сагыш ярдәмендә сурәтләми; ихтыярлы чагыштырулар, көтелмәгән борылышлар, ачык һәм төгәл, вакыты белән катлаулы чагыштырулар — аның төп «ярдәмчеләре».

Сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу — Р. Харисның фикерләү үзенчәлеге. Шул алымнар ярдәмендә шагыйрь кешенең рухи халәтен ача, шәхеснең чынбарлык белән мөнәсәбәте катлаулы һәм каршылыклы булуын күрсәтә.

Шигъриятенең бу сыйфатлары «Дөньям кызыксындырса...», «Яфрак», «Көтелмәгән көн», «Чын җылы чак җитте исә» кебек шигъри бәйләмнәрендә ачык төсмерләнә.

Туып үскән җир, аның үткәне һәм киләчәге Р. Харис поэзиясенең үзәгендә тора. Туган ил — аның өчен иң олы һәм туры хаким, бөек һәм гали хакыйкать.

Татарстан «дастан» сүзе белән рифмалашуга сорап тора икән. Дастан — халык тарихының шигъри язмасы.

Алып батырлар турындагы дастаннарның хәзер дәвамы бармы?

Дәвамы аның Татарстан...
Татарстан — яңа дастан!

Кеше белән табигать арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында шагыйрь күп яза: «Коела яшел яфрак», «Яфракларың гәрәбә...», «Корылык», «Яктылык төшә», «Ике ата каз», «Алтын төрән», «Зураеп бата», «Көзге төн» һ.б.

Табигать,— яшәү һәм матурлык чыганагы буларак, кеше өчен мәңгелек үрнәк. Мәсәлән, «Өянке» шигырендә тормышка омтылыштан да өстен хис юк, ул үлемнән, вәхшилектән өстен дигән фикер уздырыла.

«Сабантуй», «Чулпы», «Ак сөлге», «Йола» шигырьләрендә ул татар халкының милли йолалары, кабатланмас үзенчәлекләре турында уйлана, һәр күренештә эчке мәгънә таба.

Һәр яңа гаилә оешу
Йоланы яңадан яңарта.
Күрәсең, халыклар өмете
Һаман да яшидер аңарда.

(«Йола»)

Син бит үзең дә халкымның
Күңеле төсле —
Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.

(«Ак сөлге»)

Г. Тукай, Дәрдемәнд, Ф. Кәрим, М. Җәлил кебек олы шәхесләргә — татар поэзиясенең якты йолдызларына багышланган шигъри бәйләмнәр Р. Харис иҗатында аерым урын тота. Ул остазларының рухи матурлыгын, үлемсезлекләренең нигезен ачып бирү рухы белән яши.

Халкыбызның батыр улы һәм дәртле шагыйре Фатих Кәрим истәлегенә багышланган «Синең йөрәгең тибә...» бәйләме һәрьяктан үзенчәлекле. Автор өлкән каләмдәшенең иҗатына тулы бәя бирүгә дә, холкын-характерын ачуга да дәгъва итми. Ул үзен борчыган мәңгелек сорауларга җавап эзли. Фатих Кәримне каһарманлыкка һәм үлемсезлеккә алып килгән илаһи көчнең серен, чыганагын аңларга омтыла.

Җәлил үлде...
Син...
Мулланур...
Үлде Шамил Усманов...
Беләм, беләм —
Үлеп була,
Үлемнән өстен калып.

(«Фатих Кәрим...»)

Үлемне идеаллаштыру юк биредә. Киресенчә, әрнү, сызлану хисләре ята үзәктә.

Үз тәнеңдә яра ярамыни?
Сызлануы бары үзеңә.
Кеше ярасыннан гомер буе
Сызлануга ничек түзәргә?

(«Өченче ядрә»)

Ике тапкыр яралы Фатих Кәримне кеше сызлануы, ил ярасы аңар өченче ядрәне әзерләгән атакага күтәрә дә инде. Шагыйрь халыкны олы улларыннан мәхрүм иткән иҗтимагый явызлыкка кискен каршы чыга.

Тукай әсәренә нәзыйрә буларак язылган «Китмибез» шигыре сәяси эчтәлекне лирик аһәң аша ачуы белән үзенчәлекле.

«Китмибез!» — дип әйткән шагыйрь китте.
Ләкин китте ләйсән яңгырга,
Һәр күңелдә, мең мәгънәле булып,
«Китмибез»е яши яңгырап.

Поэма жанры үсешенә дә Р. Харис зур өлеш кертте. «Җитмеш икенче ел икмәге» әсәре белән ул үзенең олы жанрда эшләрлек көче барлыгын раслады. Биредә шагыйрь, тормышчан нигезне — 1972 елгы корылыкны алып, шартлы алымнарга таянып, бөртекнең явыз дошманнарын эзләргә чыга. Табигать кешегә «ачык чырай» күрсәтергә ашыкмый. Ул үзен хезмәте белән акларга һәм расларга тиеш.

Алдагы елларда «Рәссам», «Ат иярләү», «Ант суы», «Чехов базары», «Идегәй» поэмаларын, М. Җәлил исемендәге бүләккә лаек булган «Кеше» ораториясен иҗат итә. Һәр олы әсәре — кабатланмас.

Кешенең иң олы байлыгы — Җир,
Җирнең иң олы байлыгы — Кеше.
(«Кеше» ораториясе)

Гомуми символик мәгънәгә ия Кешедә шагыйрь халыкның иң матур сыйфатларын, иң изге хыялларын күрә. Шигъри җанын вәхшилек сарае өстендә әләм итеп күтәргән Мусаларны үрнәк-өлге итеп ала.

1983 елда Р. Харис «Ат иярләү» исемле әсәрен укучыга ирештерде. Поэманың төп шигъри алымы — шартлылык. Кәрам, үзе барасы урынга, сугышка атны озата. Юлдан качып кайткан атына Кәрам әчке серләрен ача, улының Украина җирендә ятып калуын хәбәр итә. Аның күз яше атына күчә: «Адәм җаны, хайван җаны аңлашырлык тел таптылар».

Нәкъ халык әкиятләрендәгечә, ат кешечә сөйли башлый һәм, туган ягына тарткан хисләре, ни рәвешле сугыш афәтеннән котылып калуы турында куе төсле буяуларда бәян итә. Шуннан кинәт кискен күчеш ясала.

Сугышның иң авыр йөген
тартыйм тыныч юллар буйлап
монда гына...
Синең кебек...

Шартлы әдәби алымның асыл мәгънәсе, юнәлешле эчтәлеге соңгы ике юлда ачыла да куя. Ат Кәрамның сугыштан качып калуына ишарә ясый.

Игътибар кешенең зиһен эшчәнлегенә, ат сүзләре тудырган үзгәрешне сурәтләүгә юнәлтелә: «Ә йөрәге чәйнәлгәндә, кеше бик тиз аңга килә», «Ә йөрәге өтелгәндә, кеше җавапны нык эзли», «Йөрәгеннән кан сауганда, кеше җавапны тиз таба».

Кабатлау алымы рухи дөньяда барган кискен үзгәрешне күзалларга булыша.

Кәрам бу вакыйгага, борылышка үзенчә бәя бирә. Аның күңелендә өермәле хисләр дулкыны уяна.

Малы иясенә охшар,
дип әйткәннәр борынгылар.
Димәк, мин дә аңа охшаш.
Бу ат, димәк, ат кына түгел,
бу ат,— димәк, минем күңел...

Иленә, намусына хыянәтен аңлаудан, үз хатасын танудан «ул оят төсле» кызара, «аптырау төсле» агара. Ачуын чыгару нияте белән, ерткычларча һәм явыз рәвештә атын кыйный. Дөресе: ул үзен җәзалый һәм, кинәт катгый карарга килеп, сугышка китә, батырлыклар эшли, җиңүче булып кайта.

Бу — поэманың вакыйга канвасы. Чынлыкта, «Ат иярләү»,— сугыш чорын тасвирлаудан бигрәк, һәр дәвердә үзенчә, яңача яңгыраган, кешедә шәхесне табуга һәм раслауга багышланган әсәр. Поэма, олы галәмнең җил-давылларыннан читтәрәк торып, ышыкта калу хәстәрен күргән куркак җаннарга каршы, шуларны фаш итүгә юнәлтелгән. Кәрам асылын яшерергә, кабык астында тотарга, үзен төрле сылтаулар белән акларга тырыша. Янәсе, аңа инде 51 яшь, малае сугышта, үзе колхоз өчен кирәкле кеше һ. б.

Үтә шартлы алым ярдәмендә шагыйрь туң йөрәккә барып җитә, Кәрамда кешелек сыйфатларын уята.

Шагыйрь күпертү-градация алымына киң таяна. Менә Кәрам урынына аның атын фронтка озату күренеше:

...Шул чагында күзеннән
ак томан агып чыкты,
ул җәелде, куерды,
вокзалны күмеп китте,
бугазына төелде,
күзләрне ачыттырды...

Р. Харис — сүзгә саран шагыйрь. Ул укучыга фәлсәфи фикер, чыгарган нәтиҗәсе, ясаган йомгагы белән мөрәҗәгать

итә. Еш кына тулы бер язмышны, характерны берничә юлга сыйдыра ала.

Табып ләззәт уенда һәм куенда,
Калды ул гомер елгасы буенда.
Тарих ансыз китте...

(«Табып ләззәт...»)

Яз көне
Кибән-кибән болыт
Җиргә сеңгән.
Көз көне
Җирдә шытып чыккан
Болыт-болыт кибән.

(«Кибән»)

Р. Харис яшьлегендә табылган алымнарыннан, шартлылыктан, катлаулы чагыштырулардан баш тартмый. «Бирсен дә...», «Ачыш», «Нинди сүзләр», «Шагыйрь», «Баскыч», «Юмартлык» кебек соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрендә ул шәхес фикеренең, аңының катламнарына, хисси байлыкларына тирәнрәк үтеп керү алымнарын эзләвен дәвам итә.

Р. Харис поэзиясе — кешелек тәҗрибәсенең яңа якларын ачуы, тормыш ямен җырлавы, остазларының табышларын үзенчә яңгыратуы, эзләнүләренең кыюлыгы белән хәзерге татар әдәбиятында үзенчәлекле күренеш.

Сораулар һәм биремнәр

1. Р. Харис поэзиясенең төп сыйфатлары нидән гыйбарәт?

2. Иҗатка бер чорда килгән шагыйрьләрдән ул нинди сыйфатлары белән аерылып тора?

3. Р. Харисның тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләрен атагыз. Фатих Кәрим батырлыгын ул ничек бәяли?

4. Р. Харисның поэмаларын атагыз. «Ат иярләү» әсәренә бәя бирегез.

5. «Ул оят төсле» кызара», «аптырау төсле» агара» тезмәләрен аңлатыгыз. Биредә нинди сурәтләү чаралары кулланылган?

6. Р. Фәйзуллин белән Р. Харисның кыска шигырьләрен чагыштырып, уртаклыкны һәм аерманы күрсәтегез.

7. Ренат Хариска кайчан һәм нинди әсәрләре өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде? Кайсы елда ул «Татарстанның халык шагыйре» дигән исемне алды?



Мөдәррис Әгъләмов
(1946—2006)

Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан,
Ак яулыклы татар карчыгының
Яргаланып беткән кулларыннан.

Яралганмын әнкәм көлтә итеп
Бәйләр өчен җыйган учмалардан,
Көлтәләрдән учма булып кына
Безгә килеп җиткән кыйссалардан.

«Мин табышмак чишәм» исемле әлеге шигырендә Мөдәррис Әгъләмов үзенә тормыш, кодрәт, көч биргән, тапкырлыкка өйрәткән төшенчәләр турында уйлана. Кара туфрак, тыйнак, эшчән татар карчыгы, халык иҗаты әсәрләре — аның өчен яшәү һәм илһам чыганагы. Шул ук вакытта кешелекнең һәр яңа буыны тормыш дип аталган озын чылбырның бер боҗрасы, бер буыны икән: «Хәзер инде дөнья, чишәр өчен, Үз алдыма табышмаклар куйган».

Тарих белән киләчәкнең, үткән белән хәзергенең якынлыгын сиземләү, чорлар һәм аралар бәйләнешен тоеп, үз урынын билгеләргә омтылу — М. Әгъләмов поэзиясе алдында торган изге бурычларның иң мөһиме.

Мөдәррис Әгъләмов 1946 елда Татарстан Республикасының Зәй районы Биш Субашы авылында колхозчы гаиләсендә туа. Тукай районында укытучы, Чаллы шәһәр халык театрында режиссёр ярдәмчесе булып эшли.

Әдәби иҗат белән мәктәптә укыганда ук мавыгып китә. 1970 елда «Кыңгырау» исемле беренче китабы дөнья күрә.

Укучының игътибарын М. Әгъләмов «Еракка китеп кара» исемле шигырьләр бәйләме белән җәлеп итте. Х. Туфан, С. Хәким кебек олы шагыйрьләрнең уңай бәясенә лаек булды.

Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен,
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен,
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара! —

ди шагыйрь.

Яшь шагыйрь тыйнак кына үз тавышы, үз моңы, нечкә хисләрне аңлый-сиземли торган йөрәге белән килеп керә чал тарихлы татар поэзиясенә. Һәркем үз җыры белән яшәргә тиеш, ди ул.

— Кем җырлый анда?— Тимерче бугай.
— Кем җырлый анда?— Игенче бугай.
— Кем әйтте моны?— Ә бу мин генә.
— Син үз җырыңны җырлап кил менә.

(«Эзләүчеләргә»)

М. Әгъләмов лирикасы елдан-ел катлаулана, заман кешесенең рухи бөтенлеген, эчке дөньясын киңрәк чагылдыру юнәлешендә үсә бара. Шәхес күңелен нечкә сиземли һәм сурәтли белүе, табигый матурлыкны аңлавы, халыкчанлыгы «Урман яна», «Зарланабыз», «Буйга да үскәнсең», «Яшәү», «Белмим, туганым», «Китә алмыйм», «Авыл зиратында көз» кебек шигырьләрендә, «Чичәннәр» бәйләмендә анык күренә. Кеше кичерешенең бер мизгелен, яшәешенең бер күренешен тасвирлау аша шагыйрь тормыш фәлсәфәсен ачып сала, туган ил, милләт язмышы турында җитди уйланулар юлына чыга.

Каеннар иле син, Болгарым,—
Ярый ла китерде юлларым,
Үкенеч икән бит, үкенеч
Зиярәт кылмаган елларым.

(«Каеннар илендә»)

М. Әгъләмов иҗаты турында язган тәнкыйтьчеләр аның төп сыйфатлары итеп хислелекне, моңлылыкны һәм татар шигыренең классик алымнарын иркен куллана белүен саныйлар.

Чыннан да, ул — әдәбиятыбызның Тукай исеме белән бәйле реалистик йолаларына, халык иҗаты кыйммәтләренә якын

юлдан атлаучы шагыйрь. Матурлык, төгәллек билгесе булып, иҗатында «кырыс» классик шигырь өстенлек итә. Сәхнә шөһрәте аны үзенә тартмады, «интеллектуаль шагыйрь» дигән исем өчен дә көрәшмәде, табигыйлеккә таянып, рухи матурлыкның яңа якларын, үзгә кыйблаларын ачуга иреште.

Шагыйрь халык мәзәкләреннән, сөйләкләреннән килә торган үткенлек, җор сөйләм, сүзнең күчерелмә мәгънәсен уйнату алымнарын да яратып үстерә.

Карт:
— Буйга да үскәнсең, улым,
Ходайдан бәхет сора!
Егет:
— Бәхетме, бабай?
Ул бары
Ике өй аша тора!

М. Әгъләмов тормышның гадәти күздән «яшеренгән» ваклыкларын, әйләнә-тирә күренешләрен, җисемле сурәтләрне күңеленә сеңдерә һәм аларга уй-хисләре, фикер-кичерешләре аша юл ала.

Иҗатының бу сыйфаты «Акмулла арбасы», «Тукайдан хатлар» һәм «Онытма, Европа!» поэмаларында ачык чагылыш таба. Бу әсәрләрнең үзәгендә ачы язмышлы кеше образлары тора.

Беренче әсәр татар, башкорт, казах халыкларының уртак рухи байлыгы булган шагыйрь Акмуллага багышланган. Кешеләргә белем бирү, агарту хыялы белән авылдан авылга йөргән бу изге җанны, сүз остасын явызлар далада үтерәләр. Бар байлыгы, йорты-җире — бер арбасы.

Гадәти түгел Акмулла арбасы. Ул — хикмәтле.

...Үз арбасы, юл арбасы булган,
Өч бүлектән торган ул арба.

Бер бүлектә үткен балта: «Аның белән азмы тәрәзәләр уелган». Икенче бүлектә дала киңлекләренә аң-белем өстәүче татар китаплары кереп оялаган. Өченче бүлектә «үзе утырып йөргән».

Менә шундый гадәти күзаллаулар ярдәмендә М. Әгъләмов шагыйрь Акмулланың катлаулы, бунтарь холкын ачу юлына чыга. Аның җыры төрмә-таш капчыкка да сыймаган, аның шигыре халыкка ышаныч, өмет алып барган.

Ул яктылык илткән даладагы
Халыкларга
Кара елларда.

Аны сөекле улы итеп яраткан, яклаучысы буларак кабул иткән халык Акмулла үлеменә бәет чыгара. М. Әгъләмов шуннан «Акмулла тикле намны ничек үтермәк кирәк...» дигән юлларны башлам итеп ала да акын-чичән шагыйрьнең варислары — Тукай, Җәлилләр язмышы турында уйлануга күчә. Акмулла батырлыгы тарихта эзсез югалмаган.

Башланмаган яңа гасыр әнә
Киләчәккә дәшеп торганда,
Йөзләп шагыйрь чыккан өч урынлы
Шул арбага яулык болгарга!

Татар әдәбиятында Тукайга багышлап шигырь-поэма иҗат итмәгән, аңа үзенең самими хисен, хөрмәтен юлламаган татар шагыйре юктыр. «Тукай хатлары» поэмасында М. Әгъләмов, берәүне дә кабатламыйча, остазы турында яңа сүз әйтүгә ирешкән.

Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Гыйльметдин Шәрәф, Габдулла Кариев, апасы Сажидә кебек фикердәшләренә, туганнарына, дусларына, нәширләренә язган шәхси хатларны укый шагыйрь. Тукай бөтенләй яңа, үзгә яклары, әрнүле һәм дәртле, ачулы һәм гафу итүчән йөрәге белән ачылып китә.

Тукай хатларыннан алынган өзекләр поэманың фикер сөрешен һәм сәнгатьчә яңачалыгын билгели. Һәр бүлеккә эпиграф итеп бер хаттан өзек алына, һәм ул өзек Тукай язмышы, халыкның рухи дөньясы, поэзиянең бүгенге торышы турындагы уйлануларының рухын билгели.

Дүртенче том кулда... Егерме хат.
Иҗат түгел, бары хат кына...
Күк капусы ачылгандай, алда
Көрәшче һәм шагыйрь яктыра.

М. Әгъләмовка Тукай исемен йөрткән Дәүләт бүләге бирелү шулай ук табигый.

«Онытма, Европа!» — публицистик поэма үрнәге. М. Әгъләмов сугыш һәм тынычлык, яшәү һәм үлем кебек олы төшенчәләр белән эш итә. Фикерен укучыга ачык һәм төгәл итеп җиткерүгә ирешә.

Татар халкының бик күп батыр уллары Европаны фашизм коллыгыннан азат итү юлында һәлак булдылар, һәм дөнья зыялылары аларның якты истәлекләренә рәхмәтле булырга тиеш дигән фикерне уздыра шагыйрь әлеге әсәрендә.

Дөнья картасында Татарстанның үз урыны бар. Аның яртысы Азиядә, яртысы Европада урнашкан: «Димәк, Европа, минем өемнең яртысы Азиядә, яртысы синдә». Икесе өчен дә татар халкы күп тапкыр утларга керде. Далада гөл булып үскән үлгәннәр безне шул хакта кисәтә:

Европа, сак бул, — үлем элмәге!
Халыклар өстендә үлем элмәге.

Шагыйрь фашистлар яндырган француз авылы Орадур, чех авылы Лидице, Америка сугыш чукмарлары юк иткән Вьетнам авылы Сонгми фаҗигаләрен йөрәге аша уздыра. Явызлыкны гафу итми. Ник дисәң, анда үтерелгәннәр — шагыйрьнең сеңлесе, авылдашы Шәйхи карт, чал чәчле Шәрифә карчыклар икән.

Үтерелгән бу кыз бала —
Ул минем сеңлем:
Итек эзләре йөзендә
(кешелек йөзендә);
Яшәүгә өмет күзендә
(кешелек күзендә).

Бу шартлы алым шагыйрьгә халыклар башына төшкән кайгы-хәсрәтне күңелгә, йөрәккә сеңдерергә, явызлыкка нәфрәт уятырга мөмкинлек бирә.

М. Әгъләмов фәлсәфи уйлану рухын нечкә күзәтүләр, анык һәм төгәл чагыштырулар белән кушып алып баруга ирешә. «Өмет кебек ап-ак дулкын», «Күзем гүя учак утларын чайкый», «...күмер мичтән сикермәсен һич тә...», «Чал чәч бөртеге әйтерсең бер инеш» кебек нәфис чагыштырулар, шигъри орлыклар әсәрнең яңгырашын киңәйтә. Төп нәтиҗәсен ул соңгы юлларга күчерә.

Күз яше җитәр,
Үлемнәр җитәр,—
Байрак итеп өскә
Вөҗданыңны күтәр!

М. Әгъләмов шигъри сүзенә таләпчәнлекне арттыра бара, артык каударланмыйча, каушамыйча гына, тарих белән за-

ман, табигать белән сәнгать арасында якынлык эзләвен, милли бизәкләрне үзенчә үстерү, баету юнәлешендә уйлануларын дәвам итә.

Төртелмичә йөгер, каләм,
Сөйлә якын туганнарга:
Ни ул әрни безнең җанда,
Ни уй туа безнең анда?
(«Йөгер, каләм»)

Сораулар һәм биремнәр

1. «Еракка китеп кара» шигъри бәйләмен укыгыз. Мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Акмулла кем ул? Аның шигырьләренә нинди үзенчәлекләр хас?

3. Г. Тукай хат алышкан, исемнәре М. Әгъләмов поэмасында аталган шәхесләр кемнәр?

4. Европа нәрсә турында онытмаска, тарихи үсештән үзе өчен нинди нәтиҗә ясарга тиеш?

5. М. Әгъләмов шигырьләренә нинди сыйфатлар хас? Ни өчен аны халыкчан шагыйрь дип атыйлар?

ПРОЗА ЖАНРЫНЫҢ ҮСЕШЕ

XX гасырның соңгы чиреге халкыбыз тарихында гаять катлаулы, аның бүгенге, бигрәк тә киләчәктәге язмышын хәл итүдә аеруча әһәмиятле вакыйгалар булуы белән аерылып тора. 80 нче еллар уртасында идеология кысалары йомшара төшү язучыларга күңелләрендә йөргән темаларны күтәрү мөмкинлеген бирде. Моңа кадәр язучының бер генә бурычы-вазифасы бар иде: ул коммунистик системаны хупларга, шушы мохиттә яшәгән кешене бары тик бәхетле итеп кенә сурәтләргә тиеш иде. Башкача уйларга һәм язарга җөрьәт итү яшәп килгән җәмгыятькә яла ягу һәм илгә хыянәт итү дип каралды. Мондый шартларда язучы карамагындагы тема, өслүб мөмкинлекләре әллә ни бай була алмады. Шуңа күрә алар бер-берләрен, хәтта үз-үзләрен кабатларга да мәҗбүр булдылар. Бу — әдәбиятны ярлыландыруга китерде.

80 нче еллардан башлап, иҗтимагый фикердә кайбер үзгәрешләрнең пәйда булуына язучылар сизгерлек күрсәттеләр. Моңа кадәр нык үскән социализм дип йөртелгән җәмгыять, бактың исә, әле очы-кырые күренмәгән камилләштерүләргә мохтаҗ икән. 80 нче еллар дәвамында Әфганстанда сугыш алып бару шулай ук илебез халыклары алдында Совет җәмгыятенең абруе төшә баруга китерде. Икътисад өлкәсендә бер урында таптану барлыкка килде. Җитәкчеләр күбрәк үз мәнфәгатьләрен кайгырта башладылар. Гади кешеләр дә җәмгыятьтә шәхес иреге булырга тиешлегенә төшенә бардылар. Бу исә күмәклеккә омтылу психологиясеннән шәхесне күтәрү юнәлешенә борылуга китерде. Җәмгыятьтә әхлакый кыйммәтләр нык үзгәрде, коммунизм идеалларына ышанмау, аңа хыял итеп карау барлыкка килде. Әхлак кануннары гомумкешелек кыйммәтләренә, милли яшәү рәвешенә һәм дин тәгълиматына нигезләнергә тиешлеге ачыклана барды. Милләтләр, шул исәптән татарлар да, үз асылларына кайтырга

омтыла башладылар. Бу исә тарихи үткәннәрне дөрес фәнни бәяләүне таләп итте. Шул ук вакытта 1917 елдан соңгы Совет чорындагы хәл-әхвәлләрне дә яңача күздән кичерү һәм бәяләү ихтыяҗы туды. Милләтләрне торгызу иң мөһим максат булып әверелде.

Мондый шартларда язучыларның күпчелеге үзләреннән нинди әсәрләр көтелүен яхшы аңлады һәм әдәбият ярдәмендә халыкка хакыйкатьне җиткерергә теләде. Халык иң әүвәл үткәндәге хәлләрне төгәл белергә тиеш иде. Менә ни өчен бу елларда әсәрләрне документлар белән расланган мәгълүматларга һәм чынбарлыкта булган вакыйгаларга нигезләнеп язу өстенлек алды. Язучы хыялы белән тудырылган әсәрләрдә дә, үткәндәге хәлләрне гомумиләштергәндә, тормышчанлыкка тугрылык сакланды.

Әсәрләрдә үткән чорлардагы нинди генә катлаулы вакыйгалар һәм күренешләр сурәтләнмәсен, язучыны иң кызыксындырганы — җәмгыять һәм кеше, җәмгыять һәм әхлак мөнәсәбәте. Шушы ук мәсьәләләр, бүгенге тормышны чагылдырганда да, үзәккә куела. Шуннан башка әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән кешенең рухи дөньясын ачу, моңача гәүдәләндерелмәгән холык-фигыльле кеше образын тудыру мөмкин түгел.

Кеше җиргә яшәү өчен туа. Бу — аның хокукы. Кемнәрдер аңа шушы төп хокукын тормышка ашырырга комачаулык итә икән, дәүләт кешене якларга бурычлы. Тик бер шарты бар: кеше намуслы, җәмгыять тарафыннан куелган таләпләрне төгәл үтәп яшәүне үзенә кагыйдә итеп алырга тиеш. Ягъни, омтылышына, сәләтенә карап, һөнәр сайласын, аны гадел, җиренә җиткереп башкарсын, кешеләр белән тату, матур мөгамәләдә булсын, башкаларга игелек кылсын, аларның да яшәүгә булган төп хокукын бозарга җөрьәт итмәсен. Менә шушындый үзара хөрмәткә корылган мөнәсәбәт җәмгыять белән кешене бер-беренә якынлаштыра, алар арасындагы бәйләнешләрне матур, үзара ярашлы итә. Аларның бер-берсенә булган ышанычы шушы мөнәсәбәтләрнең нигезен тәшкил итә. Җәмгыять кеше өчен барлыкка килә, димәк, шәхес анда үзен рәхәт, иркен хис итәргә тиеш.

1917 елга кадәрге патша Россиясе җәмгыяте кешегә мондый шартларны тудыра алмады. Андый бурычны куймады да ул. Азчылык милләтләрнең иң гади, гадәти хокуклары да исәпкә алынмады. Аларны руслаштыру, христианлаштыру, кешелек хокукларын таптау дәүләт сәясәте итеп куелды. Рус

милләтенең үз эчендәге ярлы катламнары да бу җәмгыятьтә нык изелүгә дучар ителде. Шуңа күрә большевикларның патша хакимиятенә каршы көрәшен хезмәт ияләре һәм азчылык милләтләр хуплап күтәреп алдылар, бу бурычны тормышка ашыруга барлык мөмкинлекләрен бирделәр. «Ил төкерсә — күл була» дигәндәй, бөтен «мир» белән тотынгач, хакимият әллә кая бара алмады, патша тәхеттән ваз кичте. Илдә демократик инкыйлаб җиңеп чыкты. Ләкин большевиклар хакимлекне җәмгыятьнең башка катламнары һәм фиркаләре белән бүлешергә теләмәделәр. Алар В. Ленин җитәкчелегендә социалистик инкыйлаб ясадылар, ил белән җитәкчелекне үз кулларына гына алдылар. Аларга каршы кораллы көрәшкә күтәрелү дә нәтиҗәсез булды. Чөнки ил халкының күпчелеге большевиклар вәгъдә иткән бәхетле тормышка ышана иде. Димәк, шушы ышанычны файдаланып (җитәкче өчен иң зур нәрсә — халык ышанычы), большевикларга, чыннан да, кеше тигез, кимсетелүсез, иркен яши торган җәмгыять төзергә кирәк иде. Чынлыкта алай булмады. Большевиклар хакимияте патша Россиясенең үз халкына булган сәясәтен мирас итеп алды, аны тагын да нечкәртелгән рәвештә, ялган юллар ярдәмендә алып барды. Руслаштыру сәясәте моңарчы күрелмәгән төс алды. Моның өчен төрки һәм башка халыкларның язулары рус графикасына күчерелде. Тугандаш халыкларның бер-берләре белән рухи кыйммәтләр алмашу мөмкинлекләре чикләнде. Милли телләр әкренләп эш даирәсеннән, тора-бара мәктәпләрдән, урта һәм югары уку йортларыннан кысрыклап чыгарылды. Ягъни кеше, рус телен белмәсә, кайда да булса хезмәт итү мөмкинлегеннән мәхрүм ителде. Нәтиҗәдә кайбер милләтләр (коми, мордва, мари һ.б.) үз телләрен бөтенләйгә югалту чигенә килеп җиттеләр. Татарларның да миллионнан артыгы рус телен төп аралашу теле дип саный башлады.

Боларга нигезне В. Ленин салды. Ул болай дип язды: «Тормыш һәм эш шартлары буенча рус телен белүгә мохтаҗ кешеләр аны таяксыз да өйрәнерләр». Димәк, аныңча, рус булмаган халыкларның тормыш һәм эш шартларын шундый итеп корырга кирәк, кеше, рус телен белмәгән очракта, бик кыен хәлдә калсын, әлбәттә инде, тиз арада аны өйрәнергә мәҗбүр булсын.

Яки менә сүз иреге дигән мәсьәләне алыйк. Һәркемнең үз уйларын әдәп таләп иткән рәвештә теләсә кайда әйтә алу

мөмкинлеге җәмгыять тарафыннан шулай ук хупланырга тиеш. Совет хакимиятенең беренче елларында ул шуңа якынрак була да. Әмма тора-бара сүз әйтү, үз фикереңне җиткерү иң куркыныч бер гамәлгә әверелә. Бик кирәк булганда да, кеше үз фикерен әйтүдән тыелып калырга мәҗбүр була. Ә инде дәшми калу мөмкин булмаса, сүзен алдан бик нык уйлап, хәтта язып әйтә. Чөнки фикереңнинди дә булса башка мәгънә аңлата күрмәсен. Безнең илдә инде 30 нчы еллар ахырына таба кәгазьдән карап кына сөйләү гомуми бер күренеш булып әверелә. Г. Бәширов та бервакыт моны искәртеп болай диде: «1937—1938 елларга кадәрге җыелышларда кәгазьгә карап сөйләү гадәте юк иде».

1980—1990 еллар язучылары үз әсәрләрендә бу хәлләрнең төрле якларын сурәтләргә тырыштылар. Чынбарлыкны сурәтләү — алар иҗатының уртак сыйфаты. Бу мәсьәләдә Гариф Ахуновның (1925—2000) «Идел кызы» романы (1979) кызыксыну белән каршы алынды. Аның тормыш чынлыгына тугрылыклы булуын Фатих Хөсни хәтта «авторның батырлыгы» дип атады. Татар кызы Нуриянең, аның әтисе Габбас мулланың һәм алар даирәсенең Совет хакимияте елларындагы язмышы куркыныч төш кебек тоела. Ни өчен бу кешеләр шундый авыр сынауларга дучар ителәләр? Бәлки, алар тирә-юньдәгеләр өчен бик зыянлы кешеләрдер? Юк, һич юк! Сәбәп — бер, алар — мулла, абыстай һәм, гомумән, зыялы кешеләр. Кешеләргә белем, тәрбия бирүчеләр. Шундый затлы кешеләрне эзәрлекләгән җәмгыятьне, әлбәттә, табигый дип әйтеп булмый.

XIX гасырның соңгы көннәре. Бер буранлы таңда романның төп герое булачак Нурия дөньяга килә. Бу — Нуриянең тормышы давыллы елларга туры килүенә ишарә. Зыялы гына булып көн күреп, балалар үстереп, гадәти генә яшәргә дип дөньяга килгән Нуриягә инкыйлаб башка язмыш әзерли. Заман шаукымы Кама буенда тын гына яшәп яткан Зартугай авылына да килеп җитә.

Инкыйлаб һәм шәхес язмышы мәсьәләсе үзәккә куелган бу әсәрдә мулла кызы Нуриянең төп образ итеп алынуы аның җәмгыять тарафыннан кыерсытылуын күрсәтү өчен отышлы килеп чыккан. Кызның зыялы һәм җитешле гаиләдән чыгуы аның тормыш чынбарлыгы белән бәрелешен тагын да үткенләндереп җибәрә, укучының аның язмышы белән кызыксынуын арттыра төшә.

Нуриянең башыннан үткәннәрен, аларның катлаулылыгын күрсәтүгә язучы зур урын бирә. Кызның дин сабагына йөрүе, Алабугада рус мәктәбендә укуы, Казанда рабфакка керүе, үзен укудан чыгармасыннар өчен, мулла һәм абыстай булган әти-әниләреннән ваз кичәргә мәҗбүр ителүе, тагын һәм тагын бик күп башка кыерсытылуларга дучар ителүе укучыны битараф калдыра алмый. Шулай да «Идел кызы» романының беренче кисәгендә укучыны аеруча кызыксындырган, борчыган тагын бер кеше образы бар. Ул — Габбас мулла. Ул шушы беренче кисәктә яши һәм тормышын шунда чикли.

Крестьяннан мулла булган, мәхәлләсендәге өстен хәленә һаман да күнегеп җитә алмаган, куллары гади эшне сагынып торган бу кешегә инкыйлабтан соң авылда кешечә мөнәсәбәт калмый. Аның беркемгә дә зыян китергәне, кемне дә булса җәберләгәне дә юк. Киресенчә, ул авыл халкының балаларын укыта, аң-белем һәм дин-шәригать кушкан тәрбия бирә. Хәтта муллалыгын ташлап, гади крестьян булып та яшәп карый.

Габбас мулла — үзендә күп кенә каршылыклар туплаган кеше. Бу образ Г. Ахуновның кеше холкын тудырудагы осталыгын күрсәтә. Мулла хатынына йортка кереп, урта хәлле катламнан байлар даирәсенә килеп кергән, ләкин алар арасында үз кеше булып җитә алмаган Габбас эчке газап кичереп яши. Инкыйлаб тарафдарлары да аны үз күрмиләр. Болар бөтенесе аны җәмгыятьтән читләштерә, үзен артык кеше итеп сизүгә китерә. Артык нәрсәнең тәкъдире — кадерсезләнеп юкка чыгу. Габбас фаҗига юлына атларга мәҗбүр. Әсәрнең беренче кисәге, шулай итеп, Габбасның һәлакәткә килү юлы дип бәяләнә ала.

Габбас мулла кискен сыйнфый көрәш көннәрендә урталыкта калган булса, хәлиткеч бәрелешләрнең ике башында торучылар да автор тарафыннан шактый җентекле сурәтләнгәннәр. Большевиклар яклы Мулланур Вахитов, аның тарафдары Шәяхмәт Айдаров — бу көрәшнең бер ягында. Солтан кебек яшьләр дә алар юлын сайлаганнар. Кечкенәдән әти-әнисенең мал-мөлкәтле кешеләр тарафыннан түбәнсетелеп килүе Солтанны Азин дивизиясенә китерә, гади авыл малаеның гыйбрәтле язмышын укучы кызыксынып күзәтә.

Таминдар Тураев, Сөләйман хәзрәт, Динислам Бохараевлар, киресенчә, җәмгыятьтәге үз өстенлекләрен саклап калу өчен, бөтен мөмкинлекләрен кулланып эш итәләр, ләкин халык ташкынына каршы тора алмыйлар.

Язучы әсәрдә вакыйгалар бара торган географияне шактый киңәйтә. Зартугай авылыннан алып Мәскәүгә кадәр булган арадагы фаҗигале хәлләр, бер үк ил гражданнарының үзара кан коешулары укучыны тетрәндерә.

«Идел кызы» өч кисәктән торырга тиеш дип уйланылган. 1985 елда автор аның икенче кисәген дә тәгәлләде. Бусында Нурия Уразаеваның Ватан сугышы алды һәм сугыш елларындагы тормышы сурәтләнә. Нурия инде бу вакытта табибә, фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия булган. Ул намуслы, эшчән, кыю һәм гаиләсен өзелеп яратучы акыллы хатын буларак күзаллана. Тормыш өермәләре аны шәһәрдән авылга, аннан тагын икенче җирләргә куып йөртә. Шушы кыенлыкларны үтә-үтә, ул, кеше буларак, тагын да чыныга, ныгый төшә. Әнә шулай укучы бу образның үсешен бөртекләп күзәтә ала. Дөрес, укучы аны белгечлеге буенча, ягъни табибә буларак, һөнәре даирәсендә күрергә тели. Аның җилкәсенә нинди генә авырлыклар төшсә дә, ахыр чиктә Нуриянең җиңәчәгенә укучы ышана, шулай итеп, бу хатынның язмышы өчен әллә ни борчылмый. Ничектер шулай килеп чыга: укучыны, Нуриядән бигрәк, Солтан, Чишмәбай образларының язмышы дулкынландыра.

Әсәр Солтанның, яла ягылып, фиркадән чыгарылуы белән башланып китә. Аны 30 нчы елларда колхозлашу вакытында, чамадан тыш мавыгып, рөхсәт ителмәгән алымнар белән эш иткән дип гаеплиләр. Сыйнфый дошман булган мулла кызына өйләнгәнлеге дә гаеп итеп куела. Вакыйгаларның буеннан-буена Солтан үзенең фирка билетын яңадан кайтару гаме белән яши, ләкин моңа ирешә алмыйча һәлак була. Шушы фаҗигагә кадәр укучы романны мавыгып укый, аннан соң игътибар акрынлап сүрелә.

Шунысы гыйбрәтле: райкомның беренче секретаре булган Шәяхмәт, үзенең бертуган энесенең язмышын җиңеләйтү өчен, берни дә эшләми, бу хәлне читтән күзәтүче булып кала. «Мин нишли алам?» Ул инде шулай дип акланырга күнегеп беткән. Энесенең туры сүзле, күңелендә алдашу-ялганлашу булмаганын белеп тора, әмма салкын битарафлык саклый. Әйе, бу еллар җитәкче урыннардагы кешеләрнең иң изге нәрсәләрен — кыерсытылганнарның хәленә керү сәләтләрен гарипләндерде. Бу галәмәт Совет хакимиятенең иң югары дәрәҗәдәге җитәкчелегеннән башланды. СССР Югары Советы Президиумы рәисе М. Калининның хатынын да төрмәгә яба-

лар. Лəкин «Бөтенсоюз старостасы», хəлəл җефетен яклап, бер сүз дə əйтə алмый, ул иң элек үзе өчен курка. Бу — кешенең əхлакый яктан иң түбəн дəрəҗəгə төшүе иде. Шуңа охшаш хəлгə тарыган Шəяхмəткə абыйсы əшче Мөхəммəтша болай ди: «Җир йөзендə йөз ел куян булып яшəгəнче, бер ел арыслан булып яшəвең əйбəтрəк». Шəяхмəтне шушылай сурəтлəп, Г. Ахунов дөреслеккə тугры кала, ягъни фирка җитəкчелəренең югары оешмаларга карап эш итəргə күнегеп баруларын дөрес итеп ачып сала. Алай гына да түгел, гади кешелəр дə, үзлəренə тимəсəлəр, башкаларны рəнҗеткəнне дəшми-тынмый күзəтеп торуны кагыйдəгə əверелдерəлəр. Бу бигрəк тə Каюм-Чишмəбай образына мөнəсəбəттə ачык күренə.

Үзеннəн бертуктаусыз чишмə суы сыман игелеклелек ташып торган Каюм исемле бу кешене халык, яратып, Чишмəбай дип атый. Ул байтак еллар чит җирлəрдə каңгырап йөрергə мəҗбүр ителгəн. Ихтимал, бүтəн берəүнең авылга кайтып төплəнүе күзгə артык ташланмас та иде. Чишмəбайның кайтуын исə күрми, сизми мөмкин түгел. Авылда аның кулы белəн ат абзарлары күтəрелеп килə, башка терлек-туар каралтылары үсеп чыга, тегермəнгə җан керə, чишмə янында, гүзəллек һəйкəле булып, гаҗəп матур йорт пəйдə була. Каюм-Чишмəбай өзелеп ярата да белə. Габбас муллага икенче хатын булып килгəн Хəнифəне сөю хислəрен гомере буе йөрəгендə йөртə. Ике дистə елдан соң əйлəнеп кайткач, атасыз калган өч баласы булуына карамастан, Хəнифə белəн гаилəле була. Шамил исемле малайның тууы аларның бəхетен тулыландырып, түгəрəклəп куя. Чишмəбай — чын мəгънəсендə талантлы һəм булдыклы кеше. Ул җирне матурларга, үзен һəм башкаларны бəхетле итəргə, балаларының куанычын күреп яшəргə тели. Əмма əшəке кешелəр аның бу бəхетен күпсенəлəр. Сөйкемле Каюм-Чишмəбай əлəк корбаны була. Шушындый изге күңелле кешегə беркем дə ярдəм кулын сузмый. Аны аклап, үзлəренең караласылары килми. Укучы Чишмəбай белəн ялачы Бүре Бадулы арасындагы конфликт ни рəвешле чишелер икəн дип көтə, кызыксына.

Роман сəнгатьчə эшлəнеше белəн игътибарны җəлеп итə. Г. Ахунов татар əдəбияты классикларыннан килə торган сурəтлəү чараларын баетып җибəрə. Язучы сүзнең нəфис яңгырашына нык тоемлы. Сүз остасы менə ничек яза: «Бер генə кош та күкене уздыра алмый икəн бит. Сандугачның тавышы бер аланга җитə, урман күгəрченнəре баш очында гөрли, бөркет

булып бөркетнең каркылдавы күп булса бер кварталга ишетелә торгандыр. Ә күке, бәләкәй генә кошчык, урманны бөтенләе белән кочаклап, барлык аваз-өннәрне үзенә буйсындыра, кеше булып кешене — табигатьтәге иң бөек затны тынып калырга, Җир йөзендә күпме яшәргә икәне хакында уйланырга мәҗбүр итә». Язучы җәйге урманны күз алдына китерә дә бастыра, шул ук вакытта табигать турындагы уйлануларын укучылар белән бүлешә, аларга да әйләнә-тирәгә игътибарлы булу үрнәген бирә.

Бу романда Г. Ахунов большевиклар хакимияте елларының кешегә тәэсирен күрсәтә, кешенең яшәү рәвешендә, психологиясендә үзгәрешләр барлыкка килүен оста сурәтләп бирә.

Сораулар һәм биремнәр

1. 80—90 нчы елларда язучыларның иҗат итү мөмкинлекләре арту нинди вакыйгалар белән бәйләнгән?

2. Җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте мәсьәләсен сез ничек аңлыйсыз? Үзебезнең үткән тормыштагы хәлләрне искә төшереп, шуны ничек бәялисез?

3. Большевиклар хакимият өчен көрәштә ни өчен җиңеп чыгалар? Халыкның аларга булган өмете акланамы?

4. Инкыйлаб һәм шәхес язмышы мәсьәләсе Г. Ахуновның «Идел кызы» романында ничек сурәтләнә?

5. Нуриянең әтисенә булган мөнәсәбәтен сез ничек аңлыйсыз? Сезнең бу очракта әлеге кызга булган карашыгыз нинди?

6. Габбас мулла образына үз карашыгызны дәлилләгез.

7. 20 нче елларда кеше психологиясендә нинди үзгәрешләр барлыкка килә?

8. Каюм-Чишмәбай образының сурәтләнешенә нигезләнеп, 20—30 нчы елларда гади кеше язмышы турында уйларыгызны уртаклашыгыз.

9. Г. Ахуновның сурәтләү чараларын, тел үзенчәлекләрен билгеләгез.

Мәхмүт Хәсәновның (1927—1990) **«Язгы аҗаган» романын** (1985) «Идел кызы» белән янәшә куеп карау югарыда әйтелгәннәрне тагын да дәлилле төшәргә мөмкинлек бирә. «Язгы аҗаган» тормыш күренешләренең тагын да катлаулылыгы, сюжет җепләренең күптармаклы булуы белән аерылып тора. «Мәхмүт Хәсәнов,— диде Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев,— моңарчы татар әдәбиятында булмаган ха-

рактердагы әсәр иҗат иткән. Без моңарчы я бозып күрсәткән, яисә күрмәмешкә салышып үтәргә маташкан гаделсезлекләр монда чишелеш тапкан».

Әсәрнең тагын бер үзенчәлеге шунда: ул хатирәләр рәвешендә язылган. Искә төшерүләр табигый рәвештә бүгенге вакыйгалар белән үрелеп бара. 1922 елдан башлап алып кителгән вакыйгалар тезмәсе 1957 елда өзелеп кала. Димәк, биредә утыз биш ел эчендә кешеләр кичергән язмыш гәүдәләнә.

Республика газетасы хәбәрчесе Фәйзи вакыйгаларны үзәккә туплаган хикәяләүче вазифасын үти. Ул үзе туып үскән Салаяз авылы якларына бары җиде көнгә генә эш белән кайткан. Үзенә кече яшьтән үк таныш булган кешеләр белән очрашу, алар сөйләгән сүзләрне ишетү аның хәтерендә чәбәләнеп беткән вакыйгаларның бер җепкә тезелүенә китерә. Әсәрдә сурәтләнгән төрле искә төшерүләр, хикәяләүченең тәфтишле фикерләве белән бергә кушылып, кызыклы әдәби әсәр тукымасы барлыкка китерәләр һәм гыйбрәтле язмышларны күрсәтеп бирергә ярдәм итәләр. Утыз биш ел эчендә бик күпләр кичергән хәл-әхвәлләр җиде көн эчендә (әсәр җиде бүлектән тора, алар көннәр белән биреләләр) искә төшерүләргә сыеп бетәләр.

Әсәр бик хәтәр вакыйга белән башланып китә — Хаҗи исемле кеше үтерелә, аның хатыны Зәйтүнә бу тетрәндергеч хәл тәэсирендә баласын вакытсыз таба. Ана Гази, Таҗи, Һади исемле балалары белән тол кала. Хикәяләүчене иң кызыксындырган кешеләр — менә шушы бертуган Зәкиевләр. Дөрес, хикәяләүче Фәйзи бу туганнарның кичерәкләре турында артык хафаланмый. Таҗи салкын акыллы, коры исәп-хисапка корылган фәлсәфәсе белән фирканең район күләмендәге җитәкчесе булып җитлегә, тикшерү органнарында урнашып ала. Аның өчен изге нәрсәләр юк. Эш урыны буенча күтәрелү юлында, яратып өйләнгән хатынын аерып, үзенә карьерага юл ярырга ярдәм итәрдәй кешеләр белән туганлашу кебек адымнарга бара торган бу бәндә үзе хакында чирканыч хисләр тудыра.

Әтисе һәлак булган көнне туган Һади исә, киресенчә, Таҗи абыйсының кодрәтле баҗалары ярдәменнән баш тарта. Үз бәхетен бары тик намуслы хезмәт, тырышлык ярдәмендә табу максаты белән яши, күңеленә ятмаган адымнар ясамый. Хезмәт юлыннан гаделсез юл белән күтәрелүне намусы кабул итми. Шундый булганы өчен, «җайсыз кеше» дигән исем казана.

Романда төп игътибар олы малай Газига юнәлә. Әсәр аның якты дөнья белән саубуллашуын сурәтләп тәгалләнә. Гази биредә иң әһәмиятле образ булып әверелә.

Ул кече яшьтән үк иҗтимагый тормышта кайнап үсә. Әтиләрен авылда большевиклар сәясәтен үткәрүдәге тырышлыгы өчен һәлак иткәннәр. Олы малай буларак, Гази этисенең нинди кеше икәнлеген күреп, аңлабрак калырга да өлгергән. Аның хәтерендә этисе үрнәк алырлык шәхес булып калган. Менә ни өчен Гази яшьтән үк комсомолның җигелеп эшләүче бер көрәшчесе булып китә. Аннан рабфакта, медицина институтында уку. Сугыш. Анда хирург булу. Әсирлек. Газаплар, интектерүләр. Илгә кайткач, әсирлек дигән яман күләгәнең үзе артыннан тагылып йөрүе, ул кичергән рәнҗү хисләре — болар һәммәсе бергә аның өчен бик авыр хәлләр тезмәсен тәшкил итә.

Газиның берничә мөһим мәсьәләне хәл итәсе бар: сугыш башлану сәбәпле өзелгән укуын тәмамлап, табиблык дипломы алу; әсирлектә дә илгә тугры булганлыгын расларлык шаһитлар табу; сөйгәне Гөлүсә язмышын белү, аны күрү бәхетенә ирешү.

Гази — аянычлы язмыш кешесе. Максатларына ирешүдә укучы аңа теләктәш. Димәк, Гази язмышы өчен ул борчыла, дулкынлана. Бу инде — язучының уңышы дигән сүз. Әсәр ахырында икенче һәм өченче мәсьәләләрнең хәл ителүенә укучы ихласлык белән куана.

М. Хәсәнов бу әсәрендә, әлеге туганнар язмышын күрсәтү юлы белән, ил тарихына күз ташлый, большевиклар сәясәтенең кешеләрне нинди авыр хәлләргә дучар итүен ачып сала. Романда, җепкә тезелгән мәрҗән-муенса кебек, күп кенә вакыйгаларны бергә теркәп, туплап торган тагын бер образ бар. Ул — Иргали. Аның исеме дә тирән мәгънәле. Ир — «чынчыннан таяныч булырдай кеше» дигән төшенчәне белдерсә, гали — «бөек, олы, югары дәрәҗәле» мәгънәсенә ия.

Иргали укучы күз алдында шулай ук гаять катлаулы юл үтә. Без аны башта гражданнар сугышыннан кайткан кызылармеец буларак күрәбез. Ләкин аны авылда бер-бер артлы күңелсезлекләр көтә. Ул сугышып йөргәндә, әнисе ачтан үлгән, хатыны белән кызы да чак исән калганнар. Өйдә бер валчык икмәк юк. Аптыраган Иргали ярлылар комитетына килә, әмма аңа биредә дә җылы сүз әйтмиләр. Фиркасез солдатка авыл коммунистлары да таяныч була алмый.

Иргалинең эчке инануы — кешелеклелек. Ул әнә сугышта ак офицер Клячкинны да үлемнән саклап калган. Акланмаган кан түгү — аның өчен аңлашылмый торган нәрсә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр аек акылга корылган җәмгыятьтә Иргали кебекләр бик югары бәяләнер иде. Ләкин 20 нче еллар башында безнең илдә башкача уйлыйлар һәм бүтән кагыйдәләр буенча эш итәләр иде шул. Шуңа күрә, яхшылыкка яхшылык иткән Клячкиннарның булышлыгына таянып, үз кул көче белән тормышын рәтләгән Иргали күмәк хуҗалык төзүчеләрнең сыйнфый дошманы булып әверелә. Үзе кан коеп яулап алышкан яңа җәмгыять аны кирәкмәгән кеше итеп саный. Чөнки Иргали авылның иң ялкау кешесе Хәләфләр төзегән күмәк хуҗалыкка керергә атлыгып тормый. Әлбәттә, мондый кешенең ул вакытлардагы сыйнфый көрәш көннәрендә «чит зат» булып исәпләнүе табигый иде. Нахак бәла тагып, Себергә җибәрелгән Иргалинең гаепсез икәнлеген авыл халкы да белеп тора, Советның авылдагы җитәкчесе дә күңеле белән аның ягында. Әмма «сыйнфый дошман»га кем ярдәм итә алсын?

Иргали — халык вәкиле. Хезмәт кешесендә була торган сәламәт тән, төпле акыл, эштән тәм, ләззәт таба белү — аңа хас затлы сыйфатлар. Себер урманнары уртасында тормышны казык кагудан башлаганда да, ул үзенең кешелеклелеге белән аерылып тора. Көчле рухлы, төпле акыллы кеше үзе дә куылып китерелгәннәрнең таянычына әверелә. Аның уңай сыйфатлары табигый сайланыш чорында тагын да калку булып әверелә.

Гази да, Иргали дә — үзләрендә бары тик уңай сыйфатлар гына туплаган, чын мәгънәсендә ил таянычы булырдай кешеләр. Шуңа күрә алар, кемнәргәдер җайлашып, бүген тегеләй, иртәгә болай булып йөри алмыйлар. Мондый кешеләрнең башын төрле ялганнар белән бутап булмый. Гази белән Иргалине халык түгел, бәлки рәсми хакимият читкә тибәрә. Хаксыз рәнҗетелгән мондый шәхесләрнең якты исеме соңлап булса да торгызылды. Үзләренең вак җаннарын саклап калу бәрабәренә җылы урыннарында икейөзлеләнеп утырган бәндәләр халык хәтерендә кара эшләре белән генә калырлар.

Сораулар һәм биремнәр

1. М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

2. «Зәкиевләр гаиләсе язмышында ил язмышы чагыла» дигән фикерне дәлилләргә тырышыгыз.

3. Бертуган Гази, Таҗи һәм Һадиларны, шәхес буларак, нинди сыйфатлар аерып тора?

4. Иргали образын сурәтләп, автор ул еллардагы безнең җәмгыятькә нинди бәя бирә?

5. Ни өчен Гази да, Иргали дә үзләре яшәгән җәмгыять тарафыннан читкә тибәреләләр?

6. М. Хәсәновның бу романына әдәби тәнкыйть нинди бәя бирде?

Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре»), Гурий Тавлинның «Афәт», А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» романнарында тоталитар системаның шәхесне изүе, физик һәм әхлак ягыннан мәсхәрәләве, таптавы темасы җанны тетрәндерерлек дөреслек белән чагылдырылды.

Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал болай дип язган иде:

Большевиклар искелекне җинде,
Яңа юлга чыгып шат булдык,
Яңа юлдан барган идек инде,
Колымага килеп тап булдык.

Бу юлларда әйтелгән язмышка күп кенә татар язучылары да тап булды. Фәтхи Бурнаш, Газиз Гобәйдуллин, Мәхмүд Галәү, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Кәрим, Гомәр Гали, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Нигъмәти, Ләбиб Гыйльми, Гали Рәхим, Садри Җәлал, Фатих Сәйфи-Казанлы, Хәсән Туфан, Шамил Усманов, Сәгыйть Сүнчәләй, Гомәр Толымбай, Мин Шабай, Кави Нәҗми, Сәрвәр Әдһәмова, Галимҗан Мөхәммәтшин, Сөббух Рәфыйков һәм башкалар шәхес культы афәтенә юлыктылар, аларның күбесе һәлак ителде.

Ибраһим Салахов (1911—1998) — шуларның берсе. Аның гомере матур гына башлана. Казахстанның Көкшетау (Күкчәтау) шәһәрендә туган малай шундагы татар мәктәбендә укый. Казан педагогия техникумын тәмамлагач, унтугыз яшьлек егетне 1930 елда балалар һәм яшьләр газетасына эшкә җибәрәләр. Ул «Пионер каләме» журналын нигезләүчеләрнең дә берсе була. Яшь егет илһамланып иҗат итә. Бер-бер артлы пьесасы, шигырь җыентыгы, повесте басылып чыга. Дәртле каләм роман яза башлый. Казан педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты бүлегенең өченче курсында укыган кеше өчен болар аз түгел. Өметле иҗатчы күренекле әдип

Г. Ибраһимовның фатихасын алган, аның белән Ялтада сүз сәнгатебез язмышы турында әңгәмә алып барган көннәрендә үзен күкнең җиденче катында итеп сизә, илһамлануының иге-чиге булмый. Ләкин нәкъ менә шундый гадәти һәм гөнаһсыз очрашуларны ил өстенә кара болытлар ябырылган 30 нчы еллар ахырында бик зур гаеп дип бәялиләр. И. Салаховка унбиш ел ирегеннән аерылырга, тоткынлыкта бер аягын калдырып, гомерлек гариплек алып кайтырга туры килә. Әмма ул бу юлы да көчле рухлылык күрсәтә: кулына яңадан язучылык каләме ала, көн күрерлек дәрт таба. Сәрвәр Әдһәмова әйткәнчә, «бу талантлы язучының иҗаты турында уйлаганда, озак вакытлар авыр ташлар белән бөялеп торганнан соң, ниһаять, юлы ачылып, ургылып ага башлаган чишмә суы күз алдына килә».

Төрмәдән соң ул Казанга кайту турында уйлый да алмый, хәтта аңа туган шәһәре Көкшетауда торырга да рөхсәт итмиләр. Ул комендатура урнашкан Кызыл Яр авылына җибәрелә. Һәр көнне, хакимият вәкилләренә барып, үзенең качып китмәгәнлеген раслап торырга тиеш була. 1956 елда илнең иң югары хөкем коллегиясе, «эш»не яңадан карап, 1938 елгы карарны юкка чыгара һәм гаепсез И. Салаховны тулысынча аклый. Ике дистә ярым елдан соң гына ул башкалар белән бертигез булуына хокук ала, Язучылар берлегенә кабул ителә. Яңа көч белән иҗатын дәвам иттерә. «Дала дулкыннары» исемле шигырьләр җыентыгы, «Күкчәтау далаларында», «Имәннәр тамыр җәйгәндә» романнары басыла.

«Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») — хәзерге татар әдәбиятының горурлыгы. Шәхес культының халыкка алып килгән фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәткән, шул чор турында гаепләү шаһитнамәсе булырлык әсәрләр күп түгел. Автор аны башта «Фаҗига» дип атаган. И. Салахов әсәрне иҗат иреге әле шактый кысынкы елларда, басылуына бөтенләй өмет булмаган бер вакытта язган. Гарәп хәрефләре белән язылган кульязманы Пермь өлкәсенең Барда районында яшәүче Гайшә апа исемле замандашы хәзерге кириллица графикасында машинкада берничә данәдә бастырган. Аның бер данәсен И. Салахов тимер әрҗәгә салып, бакчадагы алмагач төбенә күмеп куйган. Бер данәсен Казанга — сер сыярдай дусларына юллаган. Ниһаять, әсәр 1988 елда «Казан утлары» журналында, 1989 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты һәм 1990 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

«Колыма хикәяләре» — И. Салаховның һәм аның кебек бер гөнаһсызга газапланган меңнәрчә тоткыннарның башыннан узганнарын түкми-чәчми сурәтләгән әсәр. Шундый җәзаларга дучар ителерлек нинди гаепләре булган соң 26 яшьлек егетнең?

1937 елның мартында атаклы язучы Г. Ибраһимовка илле яшь тула. Ләкин газета-журналлар бу турыда берни дә язмыйлар. Яшь каләм әһелләре моңа аеруча гаҗәпләнәләр, бу хәлне ничек аңларга белмиләр. Май аенда исә И. Салаховка Ялтага барып дәваланырга юллама бирәләр. Яшьләр, Ялтада дәваланып ятучы Г. Ибраһимовка, туган көне белән тәбрикләп, Ибраһим артыннан хат биреп җибәрергә карар итәләр. Хатка Ләбиб Гыйльми, Касыйм Шәйхетдинов, Сөббух Рәфыйков, И. Салахов кул куя. Әлбәттә, мондый күңелле һәм изге эшне үтәүне, ягъни әлеге җылы сүзләр язылган хатны өлкән әдипкә тапшыруны, И. Салахов шатланып үз өстенә ала. Әмма шушы игелекле йомышны үтәү аңа бик кыйммәткә төшә. И. Салаховны «халык дошманы» белән элемтә тотуда һәм аңа хәерхаһ булуда гаеплиләр. «Халык дошманы» дип игълан ителүчеләр белән элемтә тоткан дигән сылтау табып, башкаларны да кулга алалар. Репрессия аппараты үзенең кара эшен иге-чиге булмаган киңлекләргә җәелдерә. 30 нчы еллардагы террор дулкыны И. Салаховны тартып алса, 50 нче елларда әзәрлекләүләр Гурий Тавлин (1925—1998), Аяз Гыйләҗевләрне (1928—2002) төрмәгә бөтереп тыга.

Җәмгыятебездә репрессияләр кешеләр өстенә дулкын-дулкын булып өерелеп киләләр, үз юлларында очраган шәхесләрне афәт диңгезенә себереп төшерәләр. Бу — мөстәкыйль уйлаучы фикер ияләреннән котылу чарасы булган. Әлеге язучылар әнә шундый хәлгә юлыкканнар.

«Тайгак кичү» һәм «Афәт» романнарын укучылар бу ике әсәр авторларының язмышында тагын бер уртаклыкка игътибар итәләр. Ул — аларның кулга алынуларына сылтауның Г. Ибраһимов шәхесенә бәйле булуы. Г. Тавлинга килгәндә, эш болай тора. Ул, педагогия институтында әдәбият дәресе тыңлаганда, лекторга менә мондый «баш китәрлек» сорау бирә: «Без, рус әдәбиятын өйрәнгәндә, И. Бунинны, А. Купринны һәм кайбер башка каләм әһелләрен бүгенге көн таләпләреннән чыгып бәялибез. Әмма туган әдәбиятыбызда кайчандыр күренекле урын тоткан татар язучылары турында нигәдер берни дә ишетмибез. Мисалга Г. Ибраһимовны алырга мөмкин. Ул

1905 елдан соңгы кара елларда патша хакимиятенең асылын фаш иткән әсәрләр язган. Аның әсәрләренең барысын да, дегет белән лычкылдатып, бүген бөтенләй телгә дә алмаслыкмыни?»

Бер уйласаң, бик гади нәрсә кебек тә инде. Мөстәкыйль фикерләргә омтылган егет үз башына килгән соравына җавап табарга тели икән, моның ни гаебе бар? Укытучы, сабыр гына тыңлап, аңа я тегеләй, я болай дип җавап биреп узса, яки, бу — катлаулы мәсьәлә, без ул турыда лекциядән соң икәү генә сөйләшеп алырбыз, дип узып китсә, әлеге күренеш шуның белән онытылыр да иде, бәлки. Юк, югары уку йорты укытучысы исемен йөрткән бу бәндә-ханым, студентның сүзен жандармнарга хас тупаслык белән бүлеп, янаулы сүзләр әйтә. «Афәт» романының герое Ирек Кадыйровның (әлеге образның прототибы — язучы үзе) кулга алынуына шушы сорауны бирүе җитә кала.

Әсәр герое өчен фаҗиганең иң зурысы шунда: ул, ата-анасы 37 нче елда юк ителгән малай (большевиклар тарафыннан иң кадерле кешеләреннән мәхрүм ителгән ятим), ил хакимиятенә, аның сәясәтенә бөтен барлыгы белән ышанып яши. Югары оешмаларда эшләүчеләрне дә үзе кебек коммунистларча фикер йөртә дип уйлый. Сорау алучыларга «иптәш» дип тә эндәшә. Фронтларны үткән бу егетнең инануларын төрмә әкренләп юкка чыгара бара. Ләкин рухын сындыра алмый. Канлы куллы сорау алучылар белән ул горур сөйләшә, юлында очраган сатлыкларга карата тиешенчә мөнәсәбәт күрсәтә.

Әлеге образның үз-үзен тотышын, гамәлләрен күзәткәндә, халкыбыз өчен горурланасың. Ирек Кадыйров кебекләр булмаса, бу дөнья күптән инде ерткычлар белән тулыр, намус, әхлаклылык дигән нәрсәләр юкка чыккан булыр иде. Нәкъ менә алар кеше дигән гади затның асылын ачып биләр. Мондый ныклык гаделлек тантанасына ирешү, түбән җанлыларның беркөн килеп җиңелүен күрү өчен кирәк. Шундый ышанычтан башка, җәмгыятьнең сафлануы, кешелекнең киләчәге булмас иде.

Мәхәббәт хисе фаҗигале хәлдәге кешегә аеруча кирәк. Оляның Иреккә булган көчле, әмма җавапсыз мәхәббәте сурәтләнү әсәрнең мавыктыру ягын арттыра. Тик кешеләргә булган ышанычының чәлпәрәмә килүе, бөтенләй уйламаган кешеләрнең үзен сатуы, күрәсең, Ирекнең кемгә дә булса ачылу мөмкинлеген калдырмаган.

«Идел кызы», «Язгы аҗаган», «Тайгак кичү» романнарында нигезсез җәберләнгән кешеләрне яклаучылар табылмавын күреп үткән идек. Әмма «Афәт» әсәрендә Ирек ягыннан сүз кыстырырга батырчылык иткән шәхес тә була. Ул — институтның рус әдәбияты укытучысы Семён Никольский. Аның намуслы һәм кыю кеше икәнлеге күренә. Ул Ирекне фирка җыелышында яклап чыга, Г. Ибраһимовка карата да уңай карашын белдерергә җөрьәт итә. Андыйлар, ни кызганыч, мондый вакытта сирәк була. Әмма югары уку йорты укытучысы Бану Гыйбатовна кебекләр исә, эчтән бертөрле уйлап, теле белән икенче төрле сөйли торган бәндәләр түгел. Ул Г. Ибраһимовны «халык дошманы» дип уйлый да, шулай әйтә дә. Үзе уйларга сәләтле булмаган, югарыдан бирелгән күрсәтмәләрне генә тутый кош сыман кабатлаучыларга, күрәсең, мондый шартларда эш итүе җиңел дә булган. Укучы күрә: фирка җыелышында С. Никольский әлеге Бану исемле хатынга Г. Ибраһимов әсәрләрендә бүгенге яшьләр өчен нинди зарарлы нәрсәләр булуын ачыклап бирергә тәкъдим итә. Ләкин теге хәреф ятлаучының бөтен очраклар өчен яраклы бер калканы бар — «Мин ул буржуаз милләтченең әсәрләре турында сөйләүне үзем өчен түбәнлек саныйм». Бетте-китте, вәссәлам! Баш ватасы да юк, мөһере әзер — буржуаз милләтче! Мескеннең үз фикере юк, моның өчен мөстәкыйль уйлау һәм нәтиҗә ясау сәләтенә ия булырга кирәк. Ә болай күпкә җиңел. Мондый «галимә»ләрдән «белем» алган студентларны кызганырга гына кала. Ирек Кадыйров кебек үзе уйлап, эзләнеп белергә омтылучы яшьләрдә мондый «остазлар» тел-әдәбиятка һәм тарихыбызга карата нәфрәт кенә тәрбияли алалар.

Үз башыннан үткәннәрне әнә шулай бәян итү барышында Ирек байтак башка шәхесләрне дә искә ала, ягъни бу фаҗигаләрнең типиклыгын бирүгә ирешә. Әсәрнең 1970 елда ук язылып тәмамланган булуын исәпкә алсаң (ул «Казан утлары» журналында бары тик 1990—1994 елларда гына басыла алды), авторның тагын бер күркәм сыйфаты ачыла. Ул, димәк, җәмгыятьтә бу хәлләрнең гайре табигый булуын, аларның мәңге дәвам ителмәскә тиешлеген алдан ук үзенең төпле акылы белән исәпләп чыгарган, өстәл тартмасына салып кую өчен генә булса да, кичергән-күргәннәрен язып кую гамәленә керешкән.

Әсәрнең «бәхетле» финалы күңелдә беркадәр җиңеллек тудыра. 50 нче елларның икенче яртысында шәхес культы тәнкыйть ителә, шул ук вакытта Кадыйров кебек имеш-мимешләргә нигезләнеп хөкем ителүчеләр иреккә чыгарыла. Шуңа күрә автор әсәрнең өченче кисәген «Кара болытлар таралгач...» дип атый да. И. Кадыйров фиркагә кайтарыла, институтны тәмамлап, диплом алуга ирешә. Укучы аның яхшы мәгънәдәге үҗәтлегенә, нык ихтыярлы, туры сүзле булуына тиешле бәя бирә. Үзәгең нык булу, әсәрдән күренгәнчә, төрмә шартларында гына түгел, гадәти тормышта да бик кирәк. Ирек Кадыйровка бу сыйфаты һәрвакыт юлдаш була. Аңа очраклы рәвештә бер район газетасында әдәби хезмәткәр булып урнашырга мөмкинлек килеп чыга. Район шартларында журналист булып эшләү җиңел түгел. Чөнки түрәләр, үзәкләрдән ераграк булган саен, үзләрен хөкемдар итеп ныграк сизделәләр. Фирканең җирле башлыклары бигрәк тә шулай иде. Аларның эш рәвешләренә, хакимлек кишәрлекләренә аз гына саксызрак кагылсаң да, дөньяң җимереләсен көт тә тор. Әнә бер мәктәптәге башбаштаклыкны ачып салган өчен, райкомның беренче секретаре журналист И. Кадыйровны мыскыл итүдән дә тартынып тормый. Ул үзе әйткәннәргә каршы килмәүләренә күнегеп беткән. Тик ул бер үк вакытта бик куркак та. Төшемле, мул ризыклы урыныннан алынудан калтырап тора. И. Кадыйровның менә бу сүзләре фирка түрәсен өнсез итә: «Синең (Сезнең дими) тәнкыйтьне кысуың, районны бөлгенлеккә алып баруың, бөтен башбаштаклыкларга күз йомуың һәм башкаларны шуңа өндәвең турында, бүген чыккан шушы газета белән бергә, кичекмәстән Үзәк Комитетка язам».

Райкомның беренче секретаре белән ул елларда шулай сөйләшеп кара әле син. Баш китмәле бит! Секретарь белеп тора: бу кыю һәм тәвәккәл И. Кадыйров әйтеп кенә калмаячак, сүзен җиренә җиткерәчәк. Шуңа күрә әлеге сүзләр секретарьның һавалылыгын тиз шиңдерә. Ул мәкаләдә дөрес тәнкыйтьләнгән кешеләргә фирка җәзасы бирә, И. Кадыйровтан гафу үтенгәндәй кылана.

Әсәрнең 50 нче еллар җәмгыятебездәге хәл-әхвәлләрне өйрәнү өчен дә ярдәме бар. Сугыш каһарманы, Брест ныгытмасын актык мөмкинлекләренә кадәр яклап көрәшкән Пётр Гавриловның әсирлектән кайткач күргәннәрен укып тетрәнәсең. Г. Тавлин шушы күренеш ярдәмендә генә дә ул еллардагы

җәмгыятебезнең шактый тетрәндергеч якларын ачып бирүгә ирешкән.

Дөресен әйткәндә, ул елларның асылын эш башында утырганнар да ахырынача аңлап бетермәде, алар идарәнең билгеле бер урыннарындагы шөрепләре генә иде. Казан шәһәренең бер райком секретаре әйткән сүзләр — моның ачык дәлиле:

— Шайтан да аңламас хәлдә яшибез. Татар мәдәниятенең иң якты йолдызларыннан берсен (Г. Ибраһимов.— *Ф. Г.*), контрреволюцион милләтчелектә гаепләп, таш капчыкта гомерен чиклиләр, ул шәхеснең кемлеген дә анык итеп күз алдына китермәүче икенче берәүне, аның «зарарлы» әсәрләрен өйрәнергә чакыруда гаепләп, төрмәгә тыгалар.

Ул елларның дәһшәтен җәмәгатьчелеккә төшендереп бирүдә А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» романы да (1994) әһәмиятле булды. Булачак язучы рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны-урыны белән җәяүләп, «ристан» хәлендә Свердловск — Петропавел — Карабас — Актас — Волынка — Майкудун — Чиләбе төрмә-лагерьларын әйләнеп чыккан. Ни өчен утыртканнар? Бары тик сталинчыл режимга битараф булганы, халыкны изүнең бу рәвешен хупламаганы, шуны ныгытуга өлеш кертмәве өчен. Егерме ике яшьлек егет яманаты чыккан илле сигезенче маддә буенча гаепләнә. Рәсми хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган шәхескә әверелә. «Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк»,— ди ул.

Бу «мәктәп»тән А. Гыйләҗев менә нинди сабак алып чыга: «Октябрь — дөньяның иң кара сәхифәсе ул. Нәрсә ул пролетариат диктатурасы? Тормыш кануннарын ертып-ертып, алга үткән берәүнең чикләнмәгән власте ул. Ил каршында да, Алла каршында да җавап бирмәячәк явыз шәхеснең өстенлеге».

К. Маркс — җәмгыятьне яңача үзгәртеп коруның иң олы юл күрсәтүчесе — явызлыкта шигърият күрде, «Россиянең татарларны яулап алуы — үтә уңай күренеш» дип язып чыкты. Аның варислары да ул мактаган әлеге рәхимсез ысулларны (азчылык милләтләрне чәнечкеле биләйләр белән кысып тотуны) үзләренә мирас итеп кабул кылдылар. Явыз гамәлләрнең нигезен, шул рәвешле, явыз теория тәшкил итте. А. Гыйләҗев әсәрдә Көнчыгышның бөек фәлсәфәчесе Конфуцийның мондый сүзләрен китерә: «Черек агачтан асыл сурәтләр юнып булмый». Шуның кебек, К. Маркcның талап алу сугышларын

хуплавына корылган теориясе беренче социализм иленең үз эчендәге һәм аның тирәсендәге халыкларга күпме күз яше һәм җәбер китерде.

Кешелекнең яшәү рәвеше, гамәле, фәлсәфәсе — иң затлы тәгълимат — дингә нигезләнергә тиеш. А. Гыйләҗев әнә шундый нәтиҗәгә килә. «Коръән укый башласалар,— ди ул,— тәнемә каз тиресе чыга. Тел музыкасын, Коръән сүзләренең яңгырашын гипнозга тиңлиләр. Коръән аятьләре адәм улларын я кузгаталар, я тынычландыралар. Берәү дә битараф кала алмый». Язучы хаклы: Коръән Кәрим — кеше өчен туры юлның, изгелекнең, саф күңеллелекнең ачкычы, фатиха бирүче, юл күрсәтүче.

А. Гыйләҗев, үзе белән бергә җәбер-золымны, михнәт-хәсрәтләрне бүлешкән кешеләрне искә төшергәннән соң, «күчкәннәр вә калганнар рухына», ягъни үлгәннәр һәм исәннәр намена дога кылырга өнди. Әсәрнең «Йәгез, бер дога!» дип исемләнүенең әнә шулай тирән мәгънәсе бар.

Әйе, мондый кешеләр изге догага лаек, җаннары җәннәттә булсын. Төштә генә күргәндә дә тетрәндерерлек мондый куркыныч хәлләр киләчәктә өндә була күрмәсен. «Кешеләр, сак булыгыз!» — дип әйтергә тели автор. Әсәрнең рухы шушы изге ният белән сугарылган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шәхес культы елларында тоткынлыкка дучар ителгән яки һәлак булган язучыларны атагыз, аларның әсәрләрен искә төшерегез.

2. И. Салаховның тормыш юлы белән танышкач, сез бу шәхесне нинди итеп күз алдына китерәсез?

3. Аның шәхес һәм язучы буларак батырлыгы нәрсәләрдә күренә?

4. Г. Ибраһимовка булган уңай мөнәсәбәтләре И. Салахов һәм Г. Тавлин язмышларында нинди роль уйный?

5. «Афәт» романында чын укытучы итеп сез кемне санар идегез? Ни өчен?

6. Ирек Кадыйров образына хас сыйфатларны дәлилләгез.

7. Кем ул Пётр Гаврилов? Аның турында нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

8. Шәхес культы котырган елларда меңнәрчә гаепсез кешеләрнең төрмә аркылы узулары нинди нәтиҗә бирде?

9. А. Гыйләҗевнең Октябрь инкыйлабы һәм пролетариат диктатурасы турындагы фикерләре белән килешәсезме? Килешсәгез дә, килешмәсәгез дә, үз карашларыгызны дәлилләгез.

10. «Җәмгыять һәм кеше» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

Бу елларда тарихчы галимнәребез И. Таһиров, М. Госманов, Р. Фәхретдинов, С. Алишев, А. Халиков, Ә. Мөхәммәдиев һәм башкалар аеруча нәтиҗәле эшләделәр, татар халкының үткәнен, ниһаять, дөрес итеп күрсәтү өчен, күп көч салдылар. Коммунистлар фиркасенең 1944 ел 9 август карары татар халкының тарихын рәсми идеологиягә, ягъни большевиклар сәясәтенә туры китереп язуны таләп иткән иде. Бу безнең тарихыбызны бозып аңлатуга нигез булып килде. 80 нче еллар ахырында гына ерактагы һәм якындагы үткәнебезне булганынча бәян итү мөмкинлекләре барлыкка килде. Моны тарихчы галимнәребез һәм сүз сәнгате әһелләре дә нәтиҗәле файдаландылар.

Рабит Батулланың (1938) **«Сөембикә» романы** бай мәгълүматлы булуы ягыннан аерылып тора.

Тарихи шәхесләрнең тормышы үз чорының бөтен әһәмиятле вакыйгалары һәм катламнары белән бик нык бәрәккән була. 1516 елда туып, 1552 еллар тирәсендә вафат булган Сөембикә исеме менә ничә гасыр инде телләрдән төшми. Сөембикә образы татар халкының азатлыкка омтылышы билгесе булып килде. Р. Батулла моны тирән аңлап эш итә. Аның сурәтләвендә дә Сөембикә азатлык өчен көрәшкә әйдәүче шәхес буларак кабул ителә. Р. Батулла халкыбызның батыр кызы образын, җанлы итеп, кызыклы һәм катлаулы вакыйгалар эчендә ача.

Р. Батулла Сөембикә турында эзләнүләр алып барган, бик күп мәгълүмат туплаган. Персонажның тууыннан алып һәлакәтенә кадәр булган бик күп сәхифәләрне ачыклаган. Тормышта булган вакыйгаларның язучы хыялы белән баетылуы, үткенләндерелүе әсәрнең җәлеп итү, мавыктыру көчен арттыра. Романның тагын бер кыйммәтле ягы шунда: биредә Казан ханлыгы тормышы үзбаш булып кына түгел, бәлки Нугай, Хаҗитархан, Себер, Кырым ханлыклары, ягъни барлык татар илләре белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә. Мондый киңлек укучыга халкыбызның үткәненә бөтенлекле, булганынча, дөрес итеп карау мөмкинлеген тудыра. Еш кына бу татар

илләренә бердәмлек җитми, кирәк чакта бер-беренә таяныч була алмыйлар. Бу исә авторга үзенең иң әһәмиятле фикерен җиткерү чарасы: татарларның XVI гасыр уртасындагы һәлакәтенең төп сәбәбе — рус дәүләтенең көчәюендә генә түгел, бәлки татар халкының бердәмлеге булмауда да. Әсәрдә менә мондый күренешләр җанны тетрәтә: Кырым җиңелгәндә, Казан, Нугай, Хаҗитархан битараф тора, Казанга куркыныч янаганда — тагын шул ук хәл. Шимал мөселманнарын берләштерүче бер абруйлы зат, үзәк булмавы таркаулыкка китерә. Көчләрне берләштергән очракта, татар дәүләтләрен җиңәрлек көч ул вакытта гомумән дә булыр иде микән?

Язучы халкыбызның бу фаҗигагә килүен эзлекле күрсәтә. Татар илләренең, бигрәк тә Нугай белән Казан ханлыгының үз эчендәге ызгыш-талашларны, хакимият өчен көрәш күренешләрен сурәтли. Нугайда — Исмәгыйль морза, Казанда Булат бәк белән Гәүһәршадлар уздырган сәясәтнең ялгыш булуы, аеруча зур зыян китерүе күрсәтелә. Романнан шундый нәтиҗә ясарга була: Касыймнан китерелгән Җангали белән Шаһгалинең халкыбызны кол иттерүгә китергән эшчәнлекләре никадәр зур булмасын, бу афәтнең төп гаепләләре — Казан ханлыгының үзендә. Ханлык кадәр ханлыкта тәхеткә утыртырлык акыллы кешеләр булмаганмы әллә? Татарны сатучы Касыйм Галиләрен чакырып китереп тәхеткә утырту, бу килмешәкләрнең илгә файдасы булуларына исәп тоту беркатлылык кына түгел, бәлки хыянәт дип бәяләнергә тиеш. Ләкин, нишлисең, хәл шулай булган, тарихны башкача итеп язу мөмкин түгел. Язучы безне бүген һәм киләчәктә шулай эшләүдән сак булырга чакыра. «Сөембикә» әсәренең әһәмияте — анда күтәрелгән мәсьәләләрнең бүгенге көнебез өчен авазда булуында да.

Әсәрнең мавыктыру көче — аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлегендә. Социалистик реализм методы гына хакимлек иткән елларда әдәбият белгечләре Р. Батулланың романында «төп кимчелек» итеп анда романтизм белән реализмның аерым-аерым торуын әйтми калмаслар иде. Чыннан да, Сөембикәнең Сарайдагы, ягъни Нугайдагы тормышы романтик чаралар ярдәмендә сурәтләнгән. Бу аңлашыла да, чөнки яшьлек романтикадан башка булмыйдыр. Бигрәк тә Көнчыгыш төбәкләр тормышы тасвирланганда романтизм буяуларыннан файдаланмаса, әсәр тукымасы бик ярлы булыр

иде. Сөембикәнең ахирәт кызлары белән Исмәгыйль мирзага каршы көрәше күренешләре романтизмнан бигрәк әкиятне хәтерләтә башлый. Сөембикәнең хыялдагы Ирәмбагны эзләп сәфәр чыгуы да шуңа якын. Йосыф мирзаның (соңыннан бәкнең) үз баласына гамәлләрендә ирек кылуы да арттырыбрак җибәрү кебек тоела башлый. Әмма әсәрнең әлеге өлеше бер сулыш белән йотылып укыла икән, димәк, бу — язучының сәнгатьчә осталыгын күрсәтә.

Әсәрдә автор уңышлы кулланган алымнар күп. Милли гореф-гадәтләрне, яшәү рәвешен, кием-салым, сөйләшү үзгәлекләрен оста бирүенә игътибар юнәлә. Шундый уңышлы сәнгатьлелек алымнарыннан берсе — Каракош образын сурәтләве, аңа салынган фикри һәм хисси вазифа. Гомумән, Р. Батулла бу сурәтне уңышлы куллана. Мәсәлән, Г. Тукайга багышланган «Сират күпере» драмасы шагыйрьнең төш күрүе белән башлана. Төштә Г. Тукайның күзен, йөзен Каракош чукый. Каракош — Росия империясенең гәүдәләнеше. Россия дигән галәмәт зур илдә вакытсыз гүр иясе булган Сөембикә заманнарыннан ук бу Каракош бик күп халыкларга янап, күңелләренә шом салып торган. Мәшһүр шагыйрь Мөхәммәдьяр (Казан ханлыгыннан якыннарына — Нугай иленә кунакка килгән) яңа туган Сөембикәне кулына ала. Ул аның күзләренә карый. «Баланың күзләрендә тилгән пәйда була». Шагыйрь күккә карый һәм күктә, биредә мин хуҗа дигәндәй, үз көченә масаеп, Каракош очканын күрә. Шуннан башлап, Каракош шәүләсе Сөембикәне гомере буе эзәрлекли. Көнчыгышның атаклы падишасы Бабур үләсе, Явыз Иван туасы, Сафагәрәй үтереләсе, Кошчак батыр үләсе, 1552 елда Казан канга батырыласы алдыннан да, Сөембикәне афәт хәбәрчесе Каракош сагалый. Каракош — бу очракта гомумиләштерелгән билге, аның куркыныч шәүләсе. Әлбәттә, бер Сөембикә өстендә генә түгел, бөтен татар халкы өстендә шомлы күләгә булып очып йөри. Шул шомның берсе — кешеләрне көчләп чукындыру. Затлы халкыбыз нинди авыр шартларда да үзенең диненнән ваз кичми, аның каһарманнары үз динендә шәһит китүне һәрнәрсәдән өстен күрәләр. Җангали кебек югары катлау кешеләре өчен изге нәрсә — тәхет кенә. Хакимияттә калу яки рәхәт тормышыннан аерылмас өчен, андыйлар теләсә кайсы дингә табына алалар. Казанның соңгы ханы Ядкәр дә — халыкта гына. Р. Батулла әсәреннән килеп чыга торган иң әһәмиятле фикерләрнең берсе шул.

Тарихны белү бүгенгебезгә, киләчәгебезгә дөрес итеп карау, алдагы көннәрдә узгандагы ялгышларны кабатламас өчен кирәк. «Үткәннәрне белеп гыйбрәт ал!» — ди халкыбыз. Г. Афзал әйтмешли:

Тарихын белмәгән халык
Белгәннәрнең колы була.

Тарихи үткәннәрдән дөрес мәгълүматлы булу — милли үзаң тәрбияләүдә мөһим шарт. Бездә теге яки бу хәлиткеч вакыйгаларда татар милләте вәкилләренең үз-үзләрен ничек тотуларын белү дә мөһим. **Флүс Латыйфиның** (1943—2010) **«Хыянәт» романы** (1990) бу яктан шактый кызыклы сәхифәләрне ачып сала. Казан ханлыгының иң укымышлы, абруйлы шәхесе, шагыйрь Колшәриф образы соклану хисе тудыра. 1552 елда Казан рус баскыннарының йөз илле мең сугышчылы чирүе белән камалып алынгач, Ядкәр хан үзенең иң якын киңәшчеләре белән мәслихәтләшү үткәрә. Кайберәүләр, сиздермичә генә Казанны ташлап чыгып, Арча ягына чигенергә тәкъдим итәләр. Колшәрифнең сүзләре хәлиткеч һәм иң дөрес карар кабул итәргә ярдәм итә.

«Мин,— ди ул,— борынгы бабаларыбызның — болгар, сувар, кыпчакларның тарихын өйрәндем, галәм агышында дәһшәтле гарасатларның кабатланып торуын беләм. Без шундый чорга кердек. Изге дисбе шуны раслый. Шунысы хак: халкыбыз киләчәктә дә хөр, азат калсын өчен, безгә түземлек, түземлек һәм тагын бер кәррә түземлек кирәк. Шунда гына җиңүгә ирешә алачакбыз. Кырым, Әстерхан, Нугай берләшә алмады. Җиңсәк, бары тик Казаныбызны бирмичә саклау бәрабәренә генә җиңүгә ирешә алачакбыз. Тар күңеллелек, куркаклык күрсәтеп дошманга бирелсәк, халыкка... бүгенгесенә генә түгел, киләчәгенә хыянәт иткән булырбыз. Юлыбыз бер генә — соңгы сулышка, соңгы тамчы кангача көрәш! Көрәш! Коллыкта яшәгәнче, хөр яугир булып үлүең мең артык!»

Казан ханлыгы халкы 1552 елдагы һөҗүмне нәкъ шулай аңлады. Ләкин туган халкына хыянәт итүчеләр дә табылды. Камай морза шуларның иң күңел кайтаргычы иде. Язучы Ф. Латыйфиның әсәрендә ул шулай күрсәтелә дә. Бу, үзе әйткәнчә, «тамырларында аксөякләр каны ага» торган морза, ханлыкның язмышы кыл өстендә калган бервакытта, үз ихтыяры белән Явыз Иван каршына килеп тезләнә. Алай гына да түгел, камалышта калган татарларның яшәү чыганагы бул-

ган суны кайдан алуларын әйтә. Ханлык ныгытмасына җир астыннан юл казып үтеп керү мөмкин дигән фикер тууга да Камай морза сәбәп була. Күрәбез: бу хыянәт татар халкына бик кыйммәткә төште, аның берничә гасыр буена ирексез яшәвенә китерде.

«Хыянәт» дип аталган әсәрнең исемен тәшкил итүче сүзнең мәгънәсе Камай морзаның сатлык гамәлен ачу өчен генә кулланылмаган. Биредә мәсьәлә шактый катлаулырак. Аксөяк Камайның үз Ватанына хилафлык итүе — бәхәссез нәрсә. Монда икеләнергә урын юк. Әсәрне укучы бу бәндәнең сатлык табигатен бәяләүдә ялгышмый. Аның каравы Углич сәүдәгәре Савелий Кузьмич Булгаковның малайлары Александр белән Василийның ахыр чиктә рус туганнарына арт белән борылуларын бәяләү җиңел эш түгел. Авторның осталыгы шунда: ул әлеге образларның шушы нәтиҗәгә килүләрен уй, хис һәм гамәл хәрәкәтендә күрсәткән. Бу үзгәреш укучы күз алдында, әйтергә кирәк, аның катнашында бара. Шуңа күрә бөтен гомере буена рус мәнфәгатьләре өчен җан атып йөргән Василийның ахыр чиктә Казанны саклаучыларга ярдәм итү юлына басуы зур канәгатьләнү белән каршы алына, гаделлекнең тантана итүе дип бәяләнә.

Әсәрдә сурәтләнгәнчә, әлеге Булгаков фамилияле Углич сәүдәгәре 1535 елда сату-алу эшләре белән Казанга килә.

Аның белән уналты яшьлек Александр исемле улы да була. Александр (Санька) биредә Гөлйөзем исемле кызга гашыйк була, шуның өчен атасыннан аерылып кала. Әтисе, малай суга батып үлгәндер дип, хәсрәтеннән иртә дөнья куя. Александр исә мөселман диненә күчә, шәригать таләп иткән бөтен гамәлләрне үти. Исемен дә Сәет Сәлим улы дип алыштыра. Сәет белән Гөлйөзем Җәгъфәр исемле ул, Галия исемле кыз үстерәләр. Александр-Сәетнең абыйсы (ата бер, аналар башка) Василий, шактый еллардан соң Казанга сәүдә кәсебе белән килгәч, энесен очрата һәм танып ала. Аны рус дәүләте файдасына Казанда шымчылык һәм җимерү эшләре алып барырга өнди. Әмма унҗиде ел буена мөселман дине кануннары буенча яшәгән, дини йола-гадәтләрне төгәл үтәргә күнеккән, татар тормышының сафлыгына-пакьлегенә инанган Александр-Сәеткә абыйсының тәкъдимен капылт кына кабул итү авыр. Татарлар аңа яхшылыктан башка берни дә эшләмәгәннәр. Шул халыкка каршы кул күтәрергә ничек күңел барырга кирәк?

Василий, ничек кенә булмасын, энесе күзенә татарларны начар итеп күрсәтергә тырыша: «Татар ханы Олуг Мөхәммәт Мәскәүне таламадымы? Тагын Устюг каласын, Муромны, Владимирны кем басты? Казанлылар... Тагын саныйммы? Җиттеме?!

— Санама,— ди аңа Александр-Сәет,— мин дә синнән ким белмим. Без дә... казанлылар да саный алабыз. Теләсәң, мин ерагректан да башлый алам. Аннан алдарак кына бер сәбәпсез Болгарны, Казанны, Җүкәтауны, Кирмәнчекне кем харап итте? Шул ук елны Казанга тагын кем җәфа алып килде, халкын кем канга батырды?.. Урысның ун явына татар бер тапкыр җавап биреп килмәдеме?»

Бу — рус милләтеннән булган ике кешенең сөйләшүе. Шушы аңлашудан соң, әлбәттә, Мәскәү белән Казанга татулашырга, татар ханлыгын тынычлыкта калдырырга кирәк иде. Ләкин рус дәүләте Казанга иң дәһшәтле-үтергеч һөҗүм ясый. Василий белән Александр-Сәет бер-берсенә каршы көрәшчеләр ягында калалар, ахыр чиктә берсе икенчесен һәлак кылалар. Әмма Василий, акыллы кеше буларак, үләр алдыннан гына булса да, үз бәйсезлекләрен яклаучы татарларның, алар белән бергә сугышкан Александр-Сәетнең хаклы булуларын төшенә һәм Казан ханына атап язу җибәрә: «Галиҗәнап Казан патшасы! Кирмән астында җир асты юлы казыла, кальганы шартлатырга. Саклана алсагыз — җиңү сезнең якта». Бу — Василий күңелендә барган каршылыкның хәл ителүе, аның икеләнүләренең бетүе, гаделлек ягына басуы. Моны аның рус дәүләтенә хыянәте дип санап булмыйдыр. Чөнки ул намусына, үзенең туганлык хисләренә тугрылыгына хыянәт итми. Бусы — иң мөһиме.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар халкы тарихын дөрес итеп язуның әһәмияте нидә дип уйлыйсыз?

2. Инкыйлабка кадәр дә, аннан соң да татар халкы тарихын булганынча язуга рәсми хакимиятләр ни өчен каршы булган?

3. Татар тарихын дөрес яктырткан үз галимнәребезнең һәм рус галимнәреннән Л. Гумилёв һәм М. Худяков хезмәтләрен табып укырга тырышыгыз.

4. Сез Казан ханбикәсе Сөембикә турында ниләр беләсез?

5. 1552 елда ни өчен рус гаскәренә Казан ханлыгын басып алу мөмкин була?

6. Р. Батулланың язу өслүбенә һәм образлар тудыру үзенчәлегенә игътибар итегез. Шуларны аңлатып сөйләгез.

7. Р. Батулла Каракош образына нинди мәгънә сала?

8. Кем ул Колшәриф? Аның Казан ханлыгында тоткан урынын аңлатып бирегез. Шагыйрь Әхмәт Рәшитовның «Колшәриф» поэмасын укыгыз. Аның буенча фикер алышыгыз. Поэманың соңындагы дога багышлау өлешен ятлагыз («Казан утлары».— 1992.— 1 нче сан.— 3—16 б.).

9. Ф. Латыйфиның «Хыянәт» әсәрендә кемнәрнең үз иленә, халкына хыянәте турында сүз бара? Кемнәр чын хыянәтче, кемнәр аек акылга буйсынып эш итүче буларак тасвирлана?

10. Рус сәүдәгәре Булгаковның улларына сез нинди бәя бирер идегез?

11. Александр мәхәббәте хакына үз халкыннан, диненнән баш тарта. Сез мәхәббәт хисенең шундый көчле булуына ышанасызмы?

12. Камай морза — Казан ханлыгының, Василий рус патшасының серен каршы якка белдерәләр. Сез аларның бу адымнарын ничек бәялисез?

Татар халкы җиңелүгә дучар була. Ләкин рус хакимиятләренә буйсынмый. Басып алучыларга каршы көрәш дулкын-дулкын булып дәвам итә. 1556, 1572, 1582, 1592 елларда аеруча көчле күтәрелешләр була. Татарлар һәм Идел-Урал буе халыклары патша хакимиятенә каршы рус милләтеннән булган кешеләр җитәкчелегендәге көрәшләрдә дә үз азатлыкларын кайгыртып катнашалар. Сүз Иван Болотников (1606—1607), Степан Разин (1670—1671), Кондратий Булавин (1707—1708), Емельян Пугачёв (1773—1775) җитәкчелегендәге күтәрелешләр турында бара.

Татарның күренекле уллары юлбашчылыгындагы күтәрелешләр турындагы истәлекләр, риваятьләр халык хәтерендә бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән. Сәгыйть Ягъфәр улы җитәкчелегендәге «Теләкәй-Сәгыйть явы» (1682), Алдар Исәкәев һәм Теләкәй углы Күчем җитәкчелегендәге «Алдар-Күчем фетнәсе» (1707—1714), Килмәк Норышев һәм Акай Күчемов (Теләкәй батыр оныгы) җитәкчелегендәге «Акай-Килмәк явы» (1735—1736) дип исемләнгән татар-башкорт күтәрелешләре патша хакимиятенә аеруча куркыныч тудыралар.

1755—1756 елларда Батырша (Батыршаһ) кушаматлы Габдулла Гали углы Мәзгыйльдин тарафыннан оештырылган халык аеруча көчле чыгыш ясый. Әлбәттә, бу каһарманнарның һәрберсе турында әле әдәби әсәрләр языйлыр.

Җәмит Рәхимов (1935—1996), «Батырша» исемле роман язып (1992), Габдулла Гали улының шәхесен бүгенге укучыларга танытты. Батырша исеме әлегә кадәр күпчелек җәмәгатьчелек өчен мәгълүм түгел иде. Җ. Рәхимовның оста каләме белән тудырылган әлеге тарихи шәхес образы халкыбызның азатлык өчен көрәшен сәнгатьчә чаралар ярдәмендә көчле итеп ачып бирде. Авторның фәлсәфәче һәм оста бәхәсче булуы да моңа ярдәм иткән. Әсәрнең унҗиденче бүлегендә христиан дине вәкиле белән Батырша арасындагы бәхәс күренеше аеруча нечкәлек белән эшләнгән. Батыршаның салкын канлылыгы, кире каккысыз дәлилләре, сүзгә осталыгы — төп коралы. Үзен хуҗа һәм өстен итеп тотарга теләгән чит дин әһеле бәхәснең үз файдасына бармавын танырга мәҗбүр. Батырша болай ди: «Диннәребезнең аерымлыклары, аларның кайсы яхшы, кайсы яман икәне диндарларның эшкә мөнәсәбәтендә дә бик ачык күренә. Коръәндә хезмәт кешеләргә аларны туендыру, мәгыйшәт-яңарыш өчен бирелә диелә. Шуңа да иҗтиһат итү, сөенеп-очынып, җиң сызганып эшләү, хыянәтсез гадел хезмәт, тир түгү, ни дә булса бар итү — мөселманлыкларыбызның асыл сыйфатларыннандыр. Чөнки җиһанда маңлай тире агызып вә көч сарыф итеп табылган икмәктән дә ләззәтлерәк икмәк улмастыр. Бәнем остазым Габделрахман әйтә торган иде: мәңге яшәрмен дип тырыш, бүген үләрмен дип гамәл кыл! Һәм халаекларыбыз шулай итәргә тырышалар да. Безнең мөселманнарыбыз иҗтиһат итәләр, тырышып эшлиләр».

Бу сүзләрдән үз милләтен яхшы белгән, аны яраткан, аңа ышанган дин әһеленең, үз көрәшенең мәгънәсен тирән аңлаган халык җитәкчесе образын яхшы күрәсең. Ул 1715 елда хәзерге Башкортстанның Балтач районы Карыш исемле татар авылында игенче Гали агай гаиләсендә туган. Сакланып калган хатлары аның зыялылыгын, ачык карашлы булуын күрсәтә. «Үз вакыты өчен шулкадәр матур һәм оста итеп язу куәтен Батырша татар мәдрәсәләрендә тирән белем алу, татар халкы тарихын яхшы үзләштерү һәм тирә-як тормышын үткен күзәтү нигезендә булдырган»,— ди тарих галиме Сәлам Алишев. Батырша Тайсуган, Ташкичү мәдрәсәләрендә укыган. Үз вакытының милләтпәрвәре һәм зур зыялысы булган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар халкы тигезсез көрәштә җиңелә. Ул үзенең ирреге юкка чыгу белән килешәме? Азатлык өчен көрәшнең аеруча нык көчәйгән елларын искә төшерегез.

2. Ул көрәшләргә җитәкчелек иткән күренекле шәхесләр турында сез ниләр беләсез?

3. Кем ул Батырша? Аңа нинди сыйфатлар хас?

4. Татар халкының бәхете өчен көрәшүче хәзерге заман зыялыларыннан һәм милләтпәрвәрләреннән кемнәрне беләсез? Алар белән Батырша арасында уртаклыклар бармы? «Зыялылык» төшенчәсенә тагын нәрсәләр керә?

Язучы **Мәдинә Маликова (1935)** иҗатының төп хасияте турында уйланганда да, әсәрләрендәге зыялылыкка игътибар итәсең. Бүгенге укучы яхшы хәзерлекле, ул әдәби әсәрләрдә тормыштагы төрле хәл-әхвәлләрне күрсәтү белән генә канәгать түгел. Син аңа яшәешнең хикмәтләрен ач, кешенең теге яки бу адымын ясауга китергән сәбәпләрнең тирән фәлсәфәсен шәрехлә, гамәлләренең ахыр нәтиҗәләрен гомумиләштерүләр ярдәмендә күңелгә үткәрерлек итеп яса. Ягъни укучы белән фикердәш бул, аны борчыган сорауларны ачыкларга тырыш, һич югы, шул мәсьәләләрне укучы уйланырлык итеп куя бел. **«Шәфкать» романы** (1983) бу яктан укучы тарафыннан яратып кабул ителде.

Кешенең әхлакый сыйфатлары аның шәхси тормышында, мәхәббәт-гыйшык өлкәсендә генә түгел, хезмәтен башкаруында, андагы кешеләр белән аралашуында да күренә. Эшне аны барыбыз да эшлибез. Әмма аерма шунда: кем ничек эшли? Аны хезмәткә тартып торучы көч нәрсәдә? Бу сорауларга җавап бирү — әнә шул әхлакый йөзне ачып бирү дигән сүз. «Шәфкать» романы уңыш казанган икән, моның сере, барыннан да элек, әсәрдә кеше образларының әхлакый йөзләрен яшәешебезнең әнә шул ике катламын тыгыз үреп сурәтләвендә диясе килә.

Шәфкатьлелек кешенең һөнәренә карамастан һәркем өчен кирәк. Ул — «кешелеклелек» дигән төшенчәнең иң кирәкле бер өлеше. Табиблар өчен бу сыйфат беренче урында торырга тиештер. Авыруга иң якын торган шифаханә хезмәткәрләренең шәфкать туташы дип аталуы очраклы түгелдер. М. Маликова бу әсәрендә менә шуның турында уйлана, бу мәсьәләләргә карашын кешеләрнең гамәлләре ярдәмендә күрсәтеп бирә.

Язучы кискен капма-каршылыклар белән эш итә. Бөтен гомерен, сәләтен кешеләргә бары тик игелек эшләүгә багышлаган профессор Җәмилә Закир кызы барлык тырышлыгын дәрәҗәгә ирешүгә генә биргән доцент Изаил Харисовичка каршы куела. Кулларына әле яңарак кына табиблык шаһәдәтнамәсе алган Зәйтүнә белән Лариса да — нәкъ менә шундый бер-берләренең капма-каршылары.

Әдибә юкка гына әсәрнең беренче битләрендә үк булачак табибларның ант бирү тантанасын сурәтләми. Алар, изге хезмәт юлына аяк басар алдыннан, үз өсләренә әхлакый йөкләмә алалар. Антта менә мондый юллар бар: «Табиблык сәнгатенә өйрәткән кешеләрне атам-анам белән бертигез санармын, авыруларга гаделсезлек кылудан тыелырмын, гомеремне саф һәм керсез үткәрермен». Талантлы язылган әдәби әсәрдә бер сүз дә юкка кулланылмый. М. Маликова да, әсәрнең башында ук әлеге ант сүзләрен китереп, әйтерсең лә болай диярге тели: «Табиблык юлын әнә шундый «бисмилла» белән башлаган кешеләр алга таба ничек эш итәләр икән?» Дөреслеккә хилафлык китермичә, автор, әлбәттә, әлеге антка тугры булып яшәүчеләрнең күпчелекне тәшкил иткәнлеген раслый.

Менә Җәмилә Закировна. Ул, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романындагы Әбүзәр Гәрәевич кебек, бары тик кешеләр бәхете өчен генә яши. Чын табиб иң әүвәл ак халатлы кешеләр ярдәменә мохтаҗлар хакында уйларга тиеш дигән фикер аның өчен яшәү мәгънәсе булып әверелгән. Фәндә ачышлар ясаган икән, бу һич тә хезмәттә нинди дә булса урын яулап алу өчен түгел, бәлки авыруларга уңышлырак ярдәм итәргә теләп эшләнгән. Үзенә яшь алмаш әзерләгәндә, ул аларны кешенең тәнен генә түгел, җанын да дәваларга өйрәткән. Табиблар бер-берләреннән менә шуның белән аерылалар да инде. Яхшылары авыру әгъзаны савыктыру турында уйлашалар, чын осталары авыруның рухын, күңел дөньясын да сәламәтләндерергә тырышалар. Җәмилә ханым үзенә алмашка килүчеләрне соңгылары исәбендә күрергә тели. Зәйтүнә кебек йөзләрчә шәкертләре аның мондый өметен аклыйлар да. Зәйтүнә артыннан: «Минем яшьлек бит бу, минем ныгып, чыныгып кына килгән чагым»,— дип кала икән, бу аңа күңел тынычлыгы, канәгатьлек хисе китерә.

Изаил Харисович исә — үзендә табиб һөнәренә карата тиешенчә караш булдырмаган һәм шуңа омтылышы да булмаган әхлаксыз бер кеше. Аның авыруларны үзе өчен кызыклы яки кызыксыз төркемнәргә бүлүе, остазының урынын яулап алу өчен, төрле мәкерләр оештыруы шул турыда сөйли. Кеше хезмәтен үзләштереп, фәндә җиңел юл белән уңыш казанырга омтылган Лариса образы да шундыйлар рәтенә керә. Бу ике кешенең вакыйгалар барышында уртак тел таба алулары күп нәрсә турында сөйли.

Әсәрнең самимилеген, лириклык көчен тәэмин итүче, барлык сюжет җепләрен бербөтенгә төйнәүче образ — Зәйтүнә. Татар хатын-кызларының сабырлыгын, тыйнаклыгын, уңганлыгын үзендә туплаган Зәйтүнәне укучы ярата, әсәрнең уңышы — шушы образның осталык белән сурәтләнүендә.

М. Маликова әсәрләрендә, аерым очракларны исәпкә алмаганда, гадәттән тыш булуы белән күзгә бәрелеп торган вакыйгалар, холык-фигыльләр белән очрашмыйбыз. Барысы да гадәти кебек. Әнә шул гадилекне кеше күзенә ташланырлык итеп сурәтләү кыен да инде. Биредә язучыга геройларының күңелендә бара торган хис-кичерешләрнең бик сак кына тоемлана торганнарын да сизәргә, әсәр тукымасына көчәнмичә урнаштырырга туры килә. Бу үзеннән-үзе психологик тирәнлеккә китерә. Шуңа күрә без М. Маликова әсәрләрен зыялы-психологик проза дип атыйбыз. Аның татар әдәбиятында тоткан урыны шуның белән аңлатыла да. Моңа инану өчен, М. Маликованың «Басып сайрар талы бар», «Фидая» романнарын, хикәя-повестьларын укып чыгу да җитә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен М. Маликованы зыялы-психологик язучы дибез?

2. «Шәфкать» романында капма-каршылыкны тудыручы образлар турында сөйләгез.

3. Татар хатын-кызларына хас сыйфатларны атагыз. Җәмилә Закировна, Зәйтүнә образларында ул сыйфатларның кайсылары аеруча күзгә бәрелерлек итеп сурәтләнгән?

4. «Табиблык» һәм «шәфкатьлелек» сүзләре синонимнар кебек. М. Маликова әсәреннән шушы бәягә лаек булмаган табиблар турында сөйләгез.

5. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын укып чыгарга тырышыгыз.

Мөсәгыйт Хәбибуллин (1927) да иҗатын үз заманы тормышын яктыртудан башлады. **«Икмәк кадере» повесте** (1968) белән ул җыйнак, тыгыз, кызыклы сюжет төзү осталыгын күрсәтте. Нефтьчеләр белән авыл кешеләре арасында килеп туган киеренке хәлнең сәбәбе, аларны ут һәм су иткән нәрсә — безне туендыра торган җиребезгә булган төрле мөнәсәбәт. «Икмәк бәясе нефть бәясе түгел. Без нефтьне алтынга сатабыз!» — дип күкрәк сугучы Ходайбирдинне туган җиребезнең хуҗасы итеп карап булмый. Авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Сәхаб Кадыйровка исә басукырлар — икмәк үстерү урыны гына түгел, аның кендеге киселгән, камыл араларыннан яланаяк йөгергән, яраткан кызы белән мәхәббәтләрен аңлашкан җир дә. Район үзәгендә үз язмышы хәл ителәсе утырышка да ул иң олы дәлил итеп арыш икмәге алып бара. Бу — игенченең икмәкне зурлавын, аны иң кадерле нәрсә итеп санавын күрсәтә. Әдәбиятта беренче адымнарын ясаганда, М. Хәбибуллин әнә шундый җитди, туган Татарстаныбыз өчен гаять мөһим темага мөрәҗәгать итте.

Шулай да М. Хәбибуллин укучылар арасында «Унсигезенче яз» повестен (1969) бастыргач танылып китте. Аның тормышта яңа гына мөстәкыйль адымнар ясаучы унсигез яшьлек кызның лирик күңел дөньясын осталык белән сурәтләве сокландырды. Кызның сафлыкка, бәхеткә омтылып ясалган гамәлләре теләктәшлек уятты. Язучы тудырган образлар кешелеклелекләре белән көчле. «Тау белән тау очрашмаса да» повестенда (1972) җисми көч-куәт ягыннан өстен булган Ислам нәзберек күңелле, лирик табигатьле Зөлфәткә каршы куелган. Ләкин ахыр чиктә күңел матурлыгы өстенлек итә. «Хәтер ярлары» повестенда, «Сулар үргә акса да...» романында да әхлак мәсьәләләренең күтәелмәгән яклары белән куелуы һәм хәл ителеше әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итте.

«Чоңгыллар» романы (1973) язучының хәзерге заманның мөһим мәсьәләләрен яктыртуга багышланган әсәрләре арасында иң уңышлысы булды. Биредә 1917 елдан соңгы чорда авыл үткән сикәлтәле юлның кешеләр язмышына ясаган тәэсире бөтен катлаулылыгы белән күрсәтелә. Бер якта — авылны күмәкләштерү өчен көрәш алып барган Эюп, икенче якта Совет хакимиятенең юкка чыгуын һәр көнне көтеп яткан Гайзулла, өченче якта — бүгенге күмәк хуҗалык җитәкчесе

Талип Бикмуллиндай, бер үк вакытта үз эшен яхшы белүче, ләкин, үзеннән өстәгеләр күзенә яхшы атлы булып күренү өчен, авыл хуҗалыгы кебек нечкә эшкә хилафлык ясауга бара алучы җитәкче. Алар арасында вакыт чоңгыллары гына түгел, бәлки җәмгыятькә булган карашларында да кискен аермалар ята.

Шул рәвешле, әлеге романда М. Хәбибуллинның тарихи фикерләү, үткәннәрне бүгенге көнебезгә бәйләп бәя бирү сәләте чагылып калды.

Һәм шуннан соң бу язучы халкыбыз үткән юлның гаять катлаулы сәхифәләрен яктырта башлады, хәзерге татар әдәбиятының тарихи романнар язучы күренекле әдибенә әверелде. «Кубрат хан» (1984), «Илчегә үлем юк» (1989), «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1992), «Хан оныгы Хансөяр» (1994) романнары шул турыда сөйли.

Болгар тарихында иң күренекле шәхесләрнең берсе Кубрат хан булган. Шулай да без әлегә кадәр Кубрат ханның килеш-килбәте, холкы-фигыле, акылы-сәләте нинди булганлыгын күз алдына китерә алмый идек. Әлеге роман безгә бу дәүләт эшлеклесен шактый тулы итеп танытты. Моннан мең дә өч йөз ел элек яшәгән кешеләр хәл иткән мәсьәләләрнең катлаулылыгы һәм әһәмияте укучыда искиткеч зур кызыксыну уятты.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар күптармаклы. Ләкин шул катлаулылыкның бер үзәге бар. Ул түбәндәгегә кайтып кала: Кубрат хан, болгарларны берләштереп, көчле дәүләт төзи. Бу берләшмә үз вакыты өчен шактый зур һәм көчле булуы белән күп илләрнең игътибарын җәлеп итә. Ханның бөтен омтылганы — дәүләтне тагын да ныклырак итү, улларының берсенә тәхетне тотрыклы хәлендә тапшырып калдыру. Беренче карашка гади һәм табигый булып күренгән бу нияткә ирешү гаять катлаулы булып чыга. Эчке һәм тышкы каршылыкларның күп икәнлеге мәгълүм була. Шушы шартларда Кубрат ханның акыллы һәм көчле дәүләт эшлеклесе икәнлеге ачыла. Ул гаделлек белән идарә итәргә тырыша. Гаепсез кешеләрне җәберләүгә, кол белән сәүдә итүгә, илдәшләренең шәхси ирекләрен кысуга юл куймаска омтыла. Эш күчмә тормыштан утрак яшәүгә таба бара, шәһәрләр, төрле ныгытма-корылмалар төзелә. Боларның һәммәсендә Кубрат ханның зирәклеге күренә.

Ләкин сәяси җитәкче акылына таянып кына түгел, үз артында торган чын көчне дә исәпкә алып эш итәргә тиешле. Әнә әсәрдә сурәтләнгән Византия императоры — «гаять дәрәҗәдә вакчыл, мин-минлек чире белән балачактан ук» авырый башлаган зат — дәүләтнең хәрби көченә масаеп, күрше илләр белән тавышын бөереннән чыгарып сөйләшә. Бу хәл Кубратка яңа борчулар өсти. Шул ук вакытта ишәеп килгән Ашина ыруы башлыгы Йулыш каһанның гаскәр җыюы да аның күңелен бимазалый.

Мондый шартларда дәүләтне эчтән ныгыту, аның тышкы яктан иминлеген тәэмин итү өчен, ике корал кирәк: беренчесе — иҗтимагый аң сыйфатында дәүләттә урнашкан тәртипләргә бәрабәр килерлек йола, тагын да төгәлрәге — яңа дин. Чөнки, аның уйлавынча: «Болгарда бердәмлек югалып бара, һәр илхан (Кубратның балалары) үз җәйләвен кайгырта». Икенчесе — греклар уйлап тапкан утлы коралны кулга төшерү. Ә нигә кирәк ул аңа? Моңа ул туры җавап бирә: «Грек уты кулыма төшү белән, мин Йулыш каһанны Җир йөзеннән юк итәчәкмен». Ләкин әле моннан Кубрат ханны бүтән илләргә көч белән басып керергә омтылучы җитәкче дип санап булмый. Дөрес, ул яшь чакта яуга күп чапкан. Ләкин соңгы сугышка керергә аны күрше ырулар мәҗбүр итәләр. Бу орыш, ахыр чиктә болгарлар файдасына тәмамланса да, бик зур югалтулар китерә. Кубрат хан үзе һәлак була. Автор моннан бик гыйбрәтле нәтиҗә ясый: «Җиңеп җиңелгән иде Болгар бу орышта». Димәк, сугыш дигән афәт җиңүгә ирешкән якка да күләгәсез генә бәхет китерә алмый.

Тирән фикер йөртүче, олы нәтиҗәләр ясау сәләтенә ия Кубрат хан зур акыл иясе буларак күз алдына килеп баса. Ул бервакытта да ашыгып карар кабул итми, башта нәрсәнең ни икәнлеген төшенергә тырыша. Мәсәлән, нәрсә ул йола, инану, кайсы дин иң дөресе кебек бик катлаулы мәсьәләләр турында баш вата ул. Язмыш белән кешенең кылган гамәлләре арасындагы бәйләнеш нәрсәдән гыйбарәт? Яшәешнең катлаулылыгы аның алдына күптөрле фәлсәфи сораулар китереп куя. Кубрат тар карашлы, кабаланып эш итә торган табигатьле шәхес түгел. Хан буларак, ул бу сорауларга кистереп җавап та бирә алган булыр иде. Ләкин алай итми, күбрәк башкаларны тыңлый, аннан соң гына карар кабул итә. Аның шундый холкын исәпкә алып, дәүләттәге дин башлыгы Ирсан

белән Византиядән килгән фәлсәфәче Фасиан, Кубрат ханга көчлерәк йогынты ясау өчен, үзара көрәш башлыйлар. Әгәр Ирсан, шикләнеп карамыйча, Тәңрегә инанырга кушса, фәлсәфәче кунак Фасиан исә, һәрнәрсә хакында төптән уйлап, үз фикерләреңне булдырырга өнди. Дөрес, ул, болай дигәндә, ханны үз ягына аударуны максат итә, Кубратны христиан диненә тартырга тырыша. Кубратның зирәклеге шунда күренә: ул, Ирсан белән Фасиан сүзләрен чагыштырып карап, дөрес хөкем чыгара. «Мин сабыр итәргә булдым,— ди ул,— дин-йола алыштыру — рух алмаштыру дигән сүз. Рум Болгарга, Болгар Румга игелек кылсын. Игелек итү халыкларны бер-берсенә бәйләр, дуслыкны ныгытыр, дуслык белән йола мәсьәләсе дә хәл ителер». VII гасыр урталары өчен генә түгел, бүгенге көндә дә дәүләт җитәкчеләренә кагыйдә булырлык сүзләр!

Чыннан да әйткәнме мондый фикерне Кубрат хан? Тарихи шәхес турында язганда, авторның сурәтләү өчен җитмәгән нәрсәләрне уйлап чыгарырга хакы бар. А. Толстой, мәсәлән, әдәбиятта беренче адымнарын ясаучы берәүгә язган хатында болай дигән: «Сез, тарихи шәхеснең биографиясенә «үзеңнән өстәргә» мөмкинме, дип сорыйсыз. Мөмкин. Ләкин моны шундый итеп эшләргә кирәк, бу (ягъни уйлап чыгарылган) чынбарлыкта булмаган булса да булырга тиешле итеп бирелсен». Кубрат хан турында, тарихи шәхес буларак, чыганаклар аз булуына карамастан, М. Хәбибуллин, әнә шундый «уйлап чыгарулар ярдәмендә» һәм, әлбәттә, кулланырга мөмкин булган тарихи чыганакларны файдаланып, гаҗәеп үзенчәлекле холык-фигыльле шәхес образын тудыра алды.

Сораулар һәм биремнәр

1. М. Хәбибуллин беренче иҗат адымнарында нинди әсәрләр яза, ул аларда нинди мәсьәләләр күтәрә?

2. «Чоңгыллар» романы М. Хәбибуллин иҗатында кайсы ягы белән әһәмиятле?

3. Сез моңа кадәр Кубрат хан турынданиләр белә идегез?

4. «Кубрат хан» романында төп образ нинди шәхес итеп сурәтләнгән? Романда төп герой нинди мәсьәләләрне хәл итү турында баш вата?

5. Дәүләт эшлеклесе нинди булырга тиеш? Кубрат хан үзенең шәхси сыйфатлары белән бу турыдагы сезнең күзаллауларга туры киләме?

6. Тарихи шәхесләр образларын тудырганда, язучы нинди мөмкинлекләрне файдалана ала?

7. Түбәндәге темаларга докладлар языгыз һәм әлеге әсәр буенча фәнни конференция уздырыгыз:

а) Кубрат хан образын тудыруда язучы кулланган сурәтләү чаралары;

ә) Кубрат хан — безнең борынгы бабабыз;

б) VII гасырда Болгар дәүләте алдында торган бурычларны хәл итүгә Кубрат хан керткән өлеш;

в) «Кубрат хан» романының тел-сурәтләү үзенчәлекләре;

г) «Кубрат хан» әсәрен укып, борынгы болгар әби-бабаларыбыз хакында без ниләр белдек?

Ринат Мөхәммәдиев
(1948)

Ринат Мөхәммәдиев әдәбият мәйданында тәнкыйтьче буларак күренде. Казан университетында укыганда ук, тәнкыйть мәкаләләре яза башлый. «Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары» дигән темага язган диссертациясе белән ул үзенең галим булуын раслады. «Әгәр без янмасак», «Якутлар табыладыр вакыт белән» китапларында аның тәнкыйтьче буларак үзенчәлеге ачылды. Мәсьәләләрне тирәннән, җитди итеп күтәреп, үз фикерен кешеләр зиһененә сеңдерерлек итеп әйтүе — Р. Мөхәммәдиев каләменең төп хасиятләреннән. Тәнкыйтьче бер үк вакытта шигъриятне дә, чәчмә әсәрләрне дә өйрәнә. Аларны ирешелгән эстетик казанышлар югарылыгыннан торып бәяли. Ул Җамал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Габдрахман Кәрам кебек шәхесләрнең тәнкыйть эшчәнлеген ныклап өйрәнде. Аларга хөрмәт белән каравы Р. Мөхәммәдиевнең хезмәтләрендә сизелеп тора.

Бүгенге татар әдәбиятын традицияләр яктылыгында өйрәнү — аның төп кыйбласы. «Сүз бүгенге шигърият турында бара. Ә күңелдә — Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Кандалыйлар... Көр күңелле, азатлык сөючән, көчле рухлы һәм сугышчан поэзиябезнең чишмә башы шулардан булгангамы... Шигъриятебездә яңа дәвер ачкан Тукай рухы исә бөтен сүз сәнгатебезгә — аның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә нур сибеп тора. Шул нур яктылыгында Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм Х. Туфаннар йолдызы балкый. Кайсын гына алма, иҗаты һәм бөтен тормыш юлы белән чын гражданлык үрнәге булып тора...» — дип яза ул. Әйе, мәңгелек тарихлы

татар шигъриятенә гражданлык хисләре хас. Чөнки шигырь безнең өчен күңел ачу чарасы гына түгел, бәлки көрәш коралы да булып килде. Р. Мөхәммәдиев бу традицияләрнең бүгенге шагыйрьләр иҗатында да уңышлы дәвам иттерелүен хуплый.

Талант ияләренең кайсы хакында гына уйланмасын, тәнкыйтьче аның иҗади йөзен билгеләргә тырыша. Чөнки шагыйрь турында шунсыз төпле сүз әйтеп булмый. Мәсәлән, аның мәкаләләреннән Нури Арслановның «классик Көнчыгыш поэзиясе традицияләрен бүгенге шартларда дәвам иткән, аның күп гасырлар буе эшкәртелә, шомара, үсә килгән поэтик һәм идея-эстетик казанышларыннан татар шигырен, стиль төрлелеген баетуда киң файдаланган шагыйрь» икәнен, Илдар Юзеевнең исә «халкыбызның рухы чагылыш тапкан бай музыкаль мирасыбызны тирәнтен өйрәнеп, нечкә сиземләгән һәм шуларны яңа шартларда яңа югарылыкка күтәреп яңгырата алган шагыйрь» булуын аңлыйбыз.

Иҗат индивидуальлеге булмаган «шигырь ясаучылар» турында исә тәнкыйтьченең сүзе кискен. Ул «күңелдән, йөрәктән кат-кат кичерми, тема белән рухланып йокысыз төннәр үткәрми» генә язылган шигырьләрнең шигъриятебез үсешенә зыян китерүен искәртә, әдәбиятыбызның югары дәрәҗәсен саклау турында кайгырта.

Р. Мөхәммәдиев 80 нче елларда үзе дә әдәби әсәрләр иҗат итә башлады. Аның «Беренче умырзая», «Ак кыялар турында хыял» кебек повестьлары укучылар тарафыннан яратып каршыланды. Бүгенге көндә ул — күп кенә хикәяләр, ярты дистәдән артык повесть һәм романнар авторы.

Сәнгатьчә фикерләү тормыш белән тыгыз бәйләнештә булганда гына, әсәр укучыны җәлеп итә ала. Китап сөюче өчен үткәннәрнең сәнгатьчә чагылышы белән очрашу бүген аеруча кызыклы булып әверелде. Дөрес, аны бүгенге хәл-әхвәлләр дә нык җәлеп итә. Аларны укып, ул үз-үзен аңлау дәрәҗәсен камилләштерә, тормыштагы урыны турында җитдирәк уйлана. Шушы җәһәттән караганда, Р. Мөхәммәдиевнең «Чияләнгән төен» китабына тупланган әсәрләр яшьләрдә кызыксыну тудырды. Әсәрләрнең геройлары барысы да — бүгенге көн кешеләре. Аларны сурәтләп, язучы нәрсә хакында уйлана соң? Биредә күтәрелгән мәсьәләләр күп, шуларның аеруча мөһиме түбәндәгегә кайтып кала: тормыш муллыгы, матди һәм рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерүдәге чагыштырмача җитешлек

үзе белән күңел матурлыгы, рухи байлык, юмартлык һәм кешелеклелек сыйфатлары алып килергә тиеш иде. Күпчелек очракларда бу шулай да. Ләкин, Р. Мөхәммәдиев дөрес күрсәткәнчә, муллык дигән җирлек еш кына күңел сукырлыгы авыруын китереп чыгара. «Истәлек өчен, Гыйлемханга...» повестендагы Нәҗип образы — шундый авыруга юлыккан иң гарип рухлы кешеләрнең берсе. Авыл җирендә торып та матурлыкның нәрсә икәнен оныткан, әйберләргә карата бары тик гамәли кирәклек күзлегеннән генә карарга күнеккән бу кеше әйләнә-тирәдәгеләр өчен иҗтимагый зарарлы булып әверелә. Акча барысын да эшли дигән карашны яшәү кагыйдәсе итеп алган Нәҗип һәм «кордаш» дип кенә бирелгән образларның эчке дөньялары никадәр буш, ямьсез һәм яшь буыннар өчен нинди куркыныч.

Тарихка күз салсаң, шул күренә: халык, борынгыдан тормыш өчен кирәкле әйберләрне кулланырга җайлы һәм чыдам итеп ясау белән бергә, аларны матур итәргә дә тырышкан.

Ә менә Гыйлемханның туган авылы кешеләре ул кайтмый торган берничә дистә ел дәвамында гадәти матурлыкны аңлау сәләтләрен сизелерлек җуеп өлгерәләр. Бер-берсеннән уздырып өй җиткерү, машина алу һәм тагын башка ярышлар затлы хисләрнең югала баруына китергән. Гыйлемхан кебек, матурлык иҗат итү — яшәү омтылышы дип исәпләп, кешене аңламаслык дәрәҗәдә рухи зәгыйфь булып баручы Нәҗипләрне, «кордаш»ларны вакытында дәвалап калырга кирәк. Авторны менә шулар борчый. Ул үз уйларын шактый уңышлы итеп, сәнгатьчә дәлилли.

Күрә белгән кешегә тирә-юнебездә өлгергән мәсьәләләр күп. Бүген кешенең әхлакый йөзе — аеруча ныклап, сәнгатьчә өйрәнелергә тиешле әһәмиятле өлкә. Чөнки чорыбыз кешесенең җирдәге яшәешкә тәэсир итү мөмкинлеге гаять зурайды. Р. Мөхәммәдиев тә бу турыда тирән уйлана. Татарстан кешеләре турында башланган сүз тора-бара «Ерактагы якын дуслар», «Чаңны кем дип кагалар?» дигән язмаларында бөтендөнья күләменә барып чыга. Бу очракта укучы ерактагы Куба илен татарстанлы, заман язучысы күзләре ярдәмендә күрә. Авторның әхлаклылык турында фикер йөртүе, шул рәвешле, олы киңлекләрдә яңгырый башлый. Э. Хемингуэй шәхесе турындагы уйланулары аркылы бу фәлсәфәнең бөтенләй яңа яклары ачыла башлый.

«Кенәри — читлек кошы» әсәрендә ул яңадан үз тормышыбызга әйләнеп кайта. Бүгенге көнне әдәби әсәрдә сурәтләп

бирүнең гаҗәеп авыр эш икәне мәгълүм нәрсә. «Үзгәртеп кору» дигән еллар башлангач, бүгенге көн мәүзугының беразга тынып калуы да шуның белән аңлатыла булса кирәк.

70—80 нче еллар тудырган иң ямьсез күренеш ул — безнең җәмгыятебезгә ят булырга тиешле яшәү рәвешенең акрынлап ныгып урнаша баруы. Язучылар да бу турыда уйландылар, борчылдылар. Ниһаять, Р. Мөхәммәдиевнең әлеге романы барлыкка килде. Анда кайбер катламнар тарафыннан җиде кат бик астында тотылган яшерен серләр ачып салынды.

Бу серле дөньяда ниләр бар? Ходавәндә! Анда эш итүче затлар кешеләрне, сары металлны бәяләргә аерган кебек, пробаларга бүлеп йөртәләр икән бит! Кара урман урталарында, табигатьнең күздән ераграк башка гүзәл почмакларында биек койма, усал этләр белән уратылып алынган зиннәтле «мәхәббәт» утрауларында үзләрен күкнең җиденче катында дип исәпләгән бу бәндәләр кәеф-сафа кылуның нинди генә төрләрен уйлап табып яшәмәгәннәр! Инкыйлабка кадәрге азгын байларның кыланышлары боларныкы янында гөнаһсыз гамәл булып кала. Р. Мөхәммәдиев аларны ерткычлар-арысланнар өеренә охшата. Ерткычлар төркемендәге кебек, биредә дә башлык һәм аңа һичсүзсез буйсынучылар бар. Аларның араларына, кем әйтмешли, кыл да сыярлык түгел. Хезмәт урыннарында да кул кулны, ике кул битне юа. Йә, әйтегез, болар кемнәр? Җәмгыятебезне имеп ятучылар. Мондыйлар үз теләкләре белән шушы рәхәт тормышларыннан аерылырлармы? Әлбәттә, юк.

Иң күңел кайтаргычы шунда: бу бәндәләрдә намус, оят юк. Үз даирәләрендә булмаганнарны чүп урынына да санамау дисеңме; чибәр хатын-кызларны күңел ачу уенчыгы итеп карау дисеңме?

Җәмгыятебездәге мондый тискәре күренешләр соңгы унъеллыклар җимеше генә түгеллеге бәхәссез. Автор романда моннан шактый ерак вакытларга күз ташлый. Кешеләрдә бер-беренә ышаныч бетә баруның, алай гына да түгел, әйләнә-тирәдәгеләргә ачу туплану хәрәкәтен әкренләп ачып бирә. Моны ул Фидаил һәм Гыйлем образлары мисалында уңышлы эзли. Гыйлем бәхетсезлегенең сәбәбе утыз җиденче елгы шәхес культы терроры булса, Фидаил — сугыштан соңгы буын вәкиле дә — җитәкчелектәге шул ук административ-бюрократия ысулы корбаны. Бу нәрсә ерак авылларда да тамыр җәйде.

Һәр авылда кешеләрне сүз саен кәнсәләр, төрмә, штраф белән куркытып торучылар бар иде. Әсәрдә сурәтләнгән Нурлы Алан авылында да булган андый бәндә. Куштан Закирны башта авыл Советы йомышчысы, аннан пләвәй (басу сакчысы), бригадир, ахыр килеп колхоз рәисе итеп күрәбез. Шулай куштаннар арасына бер кереп алган мондый адәмнәр авылдашлары өстенә кояш чыгармадылар. Әйтерсең лә мең күзләре бар, бөтенесен белеп, күреп, чагып торалар. Фидаил аларның корбаннары була. Мондый хәл кешеләрнең холкына, психологиясенә, язмышына тискәре йогынты ясый. Әсәрдә болар дәлилле гәүдәләндерелә.

80 нче елларның икенче яртысында Р. Мөхәммәдиев күренекле сәясәтче Мирсәет Солтангалиев язмышы белән кызыксына башлады. Ниһаять, 1992 елда укучыларга «Сират күпере» исемле романын бирде.

Татар дөньясында үз гомерен туган халкының язмышы белән аерылгысыз бәйләгән шәхесләр бик күп. Аларның иң күренеклеләреннән берсе — Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев (1892—1940). Ничә дистә еллар буе бу исем безнең илдә бары тик «милләтче», «халык дошманы», «контрреволюционер» дип кенә әйтеп киленде. Ниһаять, 1990 елның 31 маенда аның өстеннән барлык гаепләр алып ташланды.

М. Солтангалиевнең күп яктан гыйбрәтле тормышы һәм язмышы үзеннән-үзе әсәрдә сурәтләүне сорап тора. Бу эшкә, кыюлык күрсәтеп, Р. Мөхәммәдиев алынды. Сират күпере,— дини тәгълимат буенча, тәмугтагы җәһәннәм өстеннән оҗмахка үтә торган кылдан нечкә, кылычтан үткен күпер. М. Солтангалиев үткән юлны да нәкъ шундый күпердән узу белән генә чагыштырырга мөмкиндер. Бу күренекле шәхес Уфа губернасының Кырмыскалы авылында туа. Казанга килеп, Укытучылар мәктәбен тәмамлый. Совет хакимияте елларында бик зур һәм җаваплы хезмәтләр башкара: Казан губернасының Мөселман комиссариаты рәисе, СССР Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатының коллегия әгъзасы һ.б. Ул татар һәм башка милләтләрнең тигез хокуклылыгы өчен җанатып көрәшә. Шуның өчен аны 1928 елның май аенда кулга алалар, бик озак интектерүләрдән соң, 1940 елның 28 гыйнварында төрмәдә атып үтерәләр.

Әлбәттә, романга, әдәби әсәр буларак, иң әүвәл сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бәя бирергә кирәк. Әсәр документаль нигезгә корылган, шуңа карамастан без авторның Мирсәет

Солтангалиев образына җанлы кешегә хас булган сыйфатлар өрүен күреп торабыз. Шәхси тормышындагы катлаулылыкларны, аерым хәлләрдә, әйтик, Троцкий белән шахмат уйнаганда фикер көрәшен бирүдәге, төрле милли җитәкчеләр белән сөйләшүләрдәге, 1921 елда Идел буенда ачлыкка каршы көрәштәге хәлиткеч кыюлыгын һәм тәвәккәллеген күрсәтүдәге осталыгы бәхәс тудырмый. Бу бөек шәхесне бүгенге укучыга мөмкин булганча тулы канлы кеше буларак ачып бирүе Р. Мөхәммәдиевнең тарихи романнар жанрын да уңышлы үзләштерә баруы турында сөйли.

М. Солтангалиев халкыбызның фаҗигале үткәнен бик яхшы белә, шуңа күрә аның киләчәге турында бөтен барлыгы белән кайгырта. Татар халкы өчен теләгәне шул: ул да башка милләтләр белән тигез дәрәҗәдә булсын. Әмма шовинизм белән агуланган җитәкче даирәләр аны нәкъ менә шуның өчен дошман күрәләр, чөнки татарларны үзләренә тиң күрү аларның максатларына туры килми.

Мирсәет — зур белемле, киң карашлы кеше. Йосыф Акчура, Зәки Вәлиди, Ильяс Алкин һәм башкалар белән әңгәмәләрдә аның бу ягы аеруча көчле ачыла. Большевиклар кебек, ул кешеләрне кызылларга яки акларга гына бүлеп карамый. Шәхесләрне бәяләгәндә, алар эшчәнлегенең асыл тамырына карап эш итү — аның өчен төп кагыйдә. «Ырымбурдагы Рәмиевләрне сыйнфый дошманым дип саный алмыйм»,— ди ул. Зәки Вәлидинең Урта Азиядә Совет хакимиятенә каршы көрәш сафына барып кушылуының төп сәбәпләрен дә Мирсәет яхшы аңлый. Аны бу юлга большевикларның азчылык милләтләргә кимсетеп карау сәясәте китереп бастыра. Менә ни өчен М. Солтангалиев Зәки Вәлидине аңлый һәм күңеленнән сызып ташламый, аны илгә кайтаруның, бу шәхес белән хезмәттәшлек итүнең киләчәктә файдалы гына булачагын дәлилләргә тырыша.

Татар милләтенең киләчәге булуына ышанмаган, аның язмышына битараф караган, Мәскәү күрсәтмәләрен генә сүзсез үтәп баручы С. Сәетгалиев янында сәламәт акыллы, хезмәттәшләрен хөрмәт итүче, кешеләргә ышаныч белән караучы Мирсәет Солтангалиев образы мәһабәт булып балкып тора. М. Солтангалиев — барлык милләтләр өчен тигез хокуклылык, гаделлек таләп итүче, аеруча төрки һәм мөселман халыкларының хокукларын башкалар белән тиң дәрәҗәдә күрергә теләүче җитәкче. Шушындый төп мәсьәләләрдә

ул — большевикларның дөрес булмаган милли сәясәтенә ачыктан-ачык каршы чыгыш ясаган бердәнбер кеше. Сталин репрессияләрендә Солтангалиевнең беренче корбан булуы шуның белән аңлатыла да.

Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романы, беренче карашка, үткәннәребез турында кебек. Юк, бу әсәр бүгенге катлаулы бурычларыбызны аңлау өчен дә бик зарур.

Р. Мөхәммәдиев «Сират күпере» романы өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Р. Мөхәммәдиевнең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйләгез.

2. Р. Мөхәммәдиев әдәби әсәрләрендә үзен һәм җәмгыятьне борчыган нинди мәсьәләләр күтәрә?

3. «Кенәри — читлек кошы» әсәрендә автор нинди күренешләргә каршы чыга?

4. Җәмгыятьтә әхлаксызлык күренешләренең артуы, сезнеңчә, нинди сәбәпләргә бәйләнгән?

5. Кем ул Мирсәет Солтангалиев? Аның шәхесе һәм карашлары турында сөйләгез.

6. Ни өчен М. Солтангалиевне һәлак итәләр?

7. Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романының әһәмияте нәрсәдә? Әсәр җәмәгатьчелек һәм Татарстан дәүләте тарафыннан ничек бәяләнде?

«Ак кыялар турында хыял»

(1984)

Матур әдәбият — кеше турындагы, кешенең җаны-тәне, эчке дөньясы-рухы, кеше белән җәмгыять, кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт хакындагы сәнгать өлкәсе. Шуның белән бергә, кайбер әдәби әсәрләрдә үзәктә кеше генә түгел, җанлы һәм җансыз табигать вәкилләре дә торырга мөмкин. Сез инде беләсез, укучылар, бу бигрәк тә мәсәлләр өчен характерлы.

Әмма әдәбиятның башка жанрларында да — хикәя, повесть, шигырь, поэма, нәсер, хәтта драма әсәрләрендә дә — вакыйгалар үзәгенә хайваннарны кую очраклары бар. Мәсәлән, Джек Лондонның «Ак казык теш» («Белый клык», 1906) исемле мәшһүр повестенда төп персонаж итеп бүре алынган. Мон-

дый очракта авторлар җанлы һәм җансыз табигать вәкиленә кешедәге сыйфатларны бирәләр. Аларны кешечә хис итә белә торган, хәтта уйлау сәләтенә, акыл көченә ия итеп тасвирлыйлар. Автор нияте буенча, андый образлар кешеләр характерындагы, үзара һәм табигатькә яки җәмгыятькә мөнәсәбәтләрендәге үзенчәлекләрне үтемле чагылдыралар. Алар кешеләрдәге аерым сыйфатларны зурлыйлар һәм яклыйлар, кайберләрен кире кагалар.

Ринат Мөхәммәдиев тә «Ак кыялар турында хыял» повестенда шул алымны сайлаган.

Әсәр — язучының беренче зур күләмле әсәрләреннән. Аның төп үзенчәлеге шунда: вакыйгалар үзәгендә кәҗә тәкәсе тора. Ләкин ул кешеләр язмышыннан аерым, үзбашка гына сурәтләнми. Кәҗә белән аерым кешеләр арасында янәшәлек бара, язмышларында охшашлык сизелә. Табигать баласының язмышы ярдәмендә бүгенге кешеләр тормышында тамыр җәйгән афәт күзәтелә. Аның кешеләрне генә түгел, гөнаһсыз хайваннарны да түбәнлеккә өстерәве сурәтләнә. Бу афәт — эчкечелек, инде гомер-бакый тәрбия һәм әхлак учагы булган авылларыбызда да үзенең кара эшен җәелдергән бәла-авыру.

Янәшә сурәтләнгән язмышлар

Вакыйгалар артык катлаулы түгел. Ләкин тышкы гадилек артында тирән мәгънә ята.

...Ерактагы Ак кыялар иленнән тотып алынган һәм авылга кайтарылган кәҗә бәтие шактый вакытлар кешеләргә ияләнә алмыйча иза чигә. Үзен үлепләр дә яраткан авыл малайлары Азат белән Миңлегаязлар аны авыл мохитен кабул итәргә, кешеләргә ышанырга өйрәтәләр. Микәй атлы бу бәти бүре авызына эләгә язып та кала, үсә төшкәч, көндәшләре — башка тәкәләр белән мәрхәмәтсез бәрелешләрне дә уздыра. Кайдадыр аңа кешеләр ярдәмгә килә, я еш кына үзенең табигый көче һәм сәләте булыша. Кешеләр арасында яшәү дәверендә Микәй туган якларын, әнисен һәм туганнарын еш искә төшерә, шул якларга кайту хыялын озак вакытлар саклый. Тик ул төрле мажараларга тара. Әнә ул ничә мәртәбәләр, Ак кыялар иленә кайту өчен, юлга чыга. Әмма бу тәмле, олы хыялы берничек тә тормышка ашмый. Алай гына да түгел, яшәешен ямьләндереп торган хыял кырыс чынбарлыкка бәрелеп челпәрәмә килә. Адәм балаларына ышанган хайван алардагы яман гадәтләргә

дә тизияләнә: тәмәке чәйни һәм тарта башлый, аракы эчәргә өйрәнә, шуның белән гомерен дә фаҗигале тәмамлый.

Димәк, алда әйтелгәнчә, әсәрнең беренче үзенчәлеге — үзәккә кәҗәне кую. Ләкин авторның нияте, әлбәттә, матур һәм йомшак мамыклы тәкә язмышын сурәтләү генә түгел. Шушы гадәти булмаган кызыклы образ ярдәмендә ул кешелек җәмгыяте кереп бара торган тайгак, хәвефле юлның кая алып чыгачагын күрсәтә. Моның өчен янәшә рәвештә берничә кеше язмышын да тасвирлый. Дөрес, ул язмышлар һәрьяклап, киң итеп, эзлекле күрсәтелми, аларны сурәтләүгә фрагментарлык хас. Һәм моны автор махсус шулай эшли.

...Авылга читтән тагын бер җан иясе килә. Монысы — Айсылу — күрше авылның чибәр һәм уңган кызы. Ул монда килен булып төшә. Басынкы табигатьле эшчән Миңлегали белән бергә матур гына тормыш корып җибәрәләр. Ләкин бу гаиләнең гомере кыска булып чыга — таркала. Таркалуның сәбәбе — һаман да шул ук аракы, эчкечелек!

Вакыйгаларның тәрбияви ягы көчле. Намуслы гаиләдә үсеп тәрбияләнгән яшь, таза, булдыклы Миңлегали, аракыга хирыслана баруы аркасында, холкы-фигылендәге уңай сыйфатларын, үз-үзен, хәтта атасы биргән исемен дә югалта. Авылның бер дигән механизаторыннан ындыр табагында капчык хисаплап утыручы бер хөрәсәнгә әйләнә. Болар турында автор саран яза. Без егетнең тайгак юлга баскан беренче адымын һәм, мөгаен, инде чыга да алмаслык тирән упкын төбендә яткан чагын гына күрәбез. (Дөрес, ике арада, кыска-кыска гына итеп, Миңлегалинең исереп җәфалану вакытлары күрсәтелә.) Шулар арасындагы хәлләрне автор башка чаралар белән, иң беренче, Микәй язмышын тәфсилләү ярдәмендә, әмма яшь ирнең түбән тәгәри баруына логик яктан туры килгән янәшәлекләр (параллельләр) яки капма-каршылыклар (контраст) аша бирә. Тормышчан детальләр, уңышлы сурәтләү чаралары, авторның эзлекле позициясе вакыйгаларга актив катнашмаган Миңлегалине һич онытмый. Кешеләр этәрүе белән тайгак юлга кереп баручы Микәйнең язмышы Миңлегалинең эчке халәтен дә бирә сыман. Һәрхәлдә, укучы бу янәшәлекне үзе уздыра. Гөнаһсыз җан иясен харап иткән аракының кешелеккә янавы ачык һәм аңлаешлы төс ала.

Әсәрнең башында ук, күңелгә шом салып, аракы тулы касәләр чыңлый. Хуҗалар кодаларга «юл аягы» тәкъдим итәләр, хатын-кыз, бии-бии, исерекләр җырларын җырлый...

Бу күренешләрне шулкадәр җентекләп сурәтләү юкка түгел. Бу — бәланең башы. Авыл халкы акрынлап упкынга таба атлый. Кибеткә аракы кайткач, әбиләргә хәтле абына-сөртенә чират алырга йөгерә, чөнки шул «шайтан суы»ннан башка бер эш тә майтарып булмый: утыныңны кистерәм дисәң дә, бакчаңны сукалатыйм дисәң дә, каһәр төшкән шешә кирәк. Эшләп торган тракторын калдырып, механизаторлар да ашыга. Менә шунда бит инде әсәрдә укучы чират очында ояла-ояла булса да басып торучы Миңлегалине күрә...

Төп фикерне бирүдә кулланылган чаралар

Повесть башта гел реаль вакыйгалардан гына торыр кебек күренә. Сабыйларның тормышны кабул итүдәге үзенчәлекләре табигый. Кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләре тормышчан. Ләкин тора-бара шартлылык көчәя, хыялда гына туа алырлык хәлләр арта. Монда табигать күренешләре зур әһәмияткә ия. Чөнки әсәрнең төп герое Микәй — табигать баласы. Туганнан алып һәлакәтенә кадәр ул — табигать белән бәйле, табигый инстинктлар колы. Ул гомере буе табигатьтәге матур төскә — аклыкка омтыла. Әсәрнең буеннан-буена ак төс Микәйнең юлдашы булып тора. Лапас кыегына менеп, дөньяга сокланырга ярата ул: «Бөтен әйләнә-тирә ап-ак. Урамнар гел актан. Өй түбәләре, каралты-куралар ап-ак юрган астында. Шул ак түбәләрдән ара-тирә ап-ак төтен чыгып тора. Ул төтен, ак багана булып, ак болытларга барып тоташа. Ак болытларның аръягында да аклык микән...»

Ак төс әйтерсең лә Микәйне бүре авызыннан да коткарып кала: «Кибән янына салган кар, ни хикмәттер, каты булып чыкты — аяклары батмады Микәйнең. Әллә ак төснең аны үз итүе булды — ак кар аны иңнәренә алды. Томырылып килгән җирдән сикерүе булды Микәйнең, буран салган кар өстеннән тырмана-тырмана печән кибәненең түбәсенә менеп тә басты. Артыннан ишелеп калган кар өемнәреннән ул елгыррак булып чыкты.

Куа килгән соры бүре, киресенчә, бата-чума башлады. Әйтерсең лә аның авыр гәүдәсен ак кар күтәрергә теләми иде, баскан саен шыгырдап торган кар убылып-убылып түбән төшеп китә».

Ләкин табигать ак төстән генә тормый. Табигать бай, төсләргә дә мул. Аның башка төсләре дә бар. Һәм менә шулар арасыннан яшел төс аклык белән янәшә куеп бирелә. Микәй, күп төшләр күрә-күрә, төрлечә фикер йөртеп, яшел төсне үзенең гомерлек хыялы булган аклыкка тәңгәл итеп карый башлый. Аңарчы исә ул сөйгәне Шомырткара белән озак кына бәхәсләшә. Аны Ак кыялар иленә, аклык дөньясына китәргә өнди. Тик Шомырткара «яшел хәтфә сыман иңкүлекләр, урман-кырлар, челтерәп аккан шаян инешләр»не артыграк күрә шул. Отышлы алым куллана автор: «Ике ут арасында чарасыз калган Микәй уянып китте. Ишегалдында иртәнге ыгы-зыгы башланган. Өй каршындагы ак каеннарның бөдрә тармакларыннан мөлдерәп торган яшел нурлар коела. Микәй әле генә игътибар итте: җанына аеруча үз булган, аклыклары белән берөзлексез аның карашын иркәләп торган каеннар дөньяга яшел нур чәчә икән бит. Ак төс һәм яшел төс алар бербөтен түгелме соң?.. Ак һәм яшел — Микәй белән Шомырткара дигән сүз. Аларны бер-берсенә каршы куеп, Микәй ялгышкан икән ич...»

Аклыкның, бердән, ышаныч белән, икенчедән, хыял белән янәшә бирелүе, еш кына шуларны алыштырып килүе сәнгатьчә алым булып әверелә һәм фикер йөген җигелеп тарта. Микәй үзе хәзер яшәгән тормышның тискәре якларын ача барган саен, кешеләргә аның ышанычы кимегән саен, ак төс тә сыегая бара. Күз алдында эреп югалган аклык сыман, кәҗә бәтие күңелендәге ак хыяллар да сүрәнләнә, ерагая бара. Әмма аларга алмашка, мондагы яшәүнең матурлыгы булып, яшел төс килә.

Ак һәм яшел төс — безгә иң якын төсләрдән. Алар нур булып чәчелә, яктыра алалар. Кояш нуры төсле. Ай нуры кебек... Кеше күңеленә беренчесе чисталык, пакьлек, өметсафлык нуры булып иңә. Икенчесе — яшәү нуры, яшьлек һәм яңару нуры... Табигать үзе дә бит уяну, тереклеге башланган язда яшелгә күмелә...

Ләкин табигатьтә соры төс тә бар бит әле, ди автор. Монысы инде нурлы була алмый. Монысы инде — яшәүдә эчпошыргыч бертөслелек, гамьсезлек, сүнү төсе. Хәтта әшәкелек төсе. Автор юкка гына бүренең соры булуын ассызыкламый: ак кар күтәрергә теләмәгән «авыр гәүдәле» «соры бүре». Бу төс Микәй тормышындагы матур хыяллар билгесе булган ак

тøскә дә, бүгенге мәгънәле, тереклек яме һәм мәхәббәт белән тулы тормышны гәүдәләндергән яшел төскә дә алмашка килә.

Ә моңа әлеге дә баягы аракы гаепле. Шул бит инде хәзер Микәйне бөтен нәрсәне тутык төсендә күрергә мәҗбүр итә. Аның өчен хәзер балчык та, тимерләр дә, бөтен дөнья да көл төсенә керә... Әйе, эчүчелекнең соңы — соры, күңелсез, фаҗигале...

Шул рәвешле, Ринат Мөхәммәдиев бу повестенда төсләр ярдәмендә җитди фикер уздыра, чаң суга. Хайван булып хайванны да һәлакәт юлына этәргән аракыны, шуңар табынган кешеләрне гаепли һәм шелтәли.

Язучының татар теле байлыгын үзләштергән булуы һәм иркен эш итә белүе дә мөһим. «Әйбәт прозаның нигезендә һәрчак поэзия ята дигән сүзне без бик еш ишетәбез,— дип яза Мәхмүт Хәсәнов «Тәнкыйтьче повесть язган» исемле мәкаләсендә.— Ринат Мөхәммәдиевнең дә теле шигъриятле. Сүзнең тәмен, җөмләнең яңгырашын, сыгылмалылыгын, эчке музыкасын тоеп яза». Повестьта кечкенә геройлар балаларча, авыл малайларынча, олылар үз телләре белән сөйләшәләр. Һәркемнең теле яшенә һәм холкына ятышып тора.

Алда сүз булган һәм автор кулланган башка төрле алымнар һәм чаралар, детальләр әсәрдәге төп фикерне укучыга җиткерүдә зур роль уйныйлар. Әсәрдә баш нәтиҗә, ягъни төп фикер, никадәр тирәнрәк яшерелгән булса, шулкадәр мавыктыргыч. Укучы әйтерсең лә язучы сурәтләгәннәр артыннан барып бу фикергә үзе килә, нәтиҗәне үзе таба. Һәм бу аңарда күңел канәгатьлеге тудыра; димәк, әсәрнең укучыга тәэсир көче арта. Ә эмоциональ тәэсир итү — матур әдәбиятның бер өстенлеге, асыл сыйфатларыннан берсе. Нәкъ менә үтемле ысул-алымнар, уңышлы детальләр автор фикерен төшендерүгә ярдәм итәләр.

Заманыбызның авыр бер мәсьәләсен — кешелекне упкынга сөйрәүче эчкечелек чирен ярып күрсәтүе белән, повесть соңгы еллар татар әдәбиятында яңа бер сүз әйтү булды. Ул уңай бәяләнде. «Күңелсез вакыйгаларга нигезләнгән булса да, «Ак кыялар турында хыял» повесте — яшәү матурлыгын раслый торган якты әсәр,— дип язды танылган балалар язучысы Ләбибә Ихсанова.— Нурлы Алан дигән матур исемне йөрткән бу авылдагы ямьсез гадәтләр әле тиз генә бетмәс тә, бәлки. Чир килгәндә генә тиз килә, килсә, авырлык белән китә дигән сүз бар. Ләкин авылның әле көнне төнгә ялгап эшләүче, салам

җыйнаучы, җир сөрүче, җир тырмалаучы тырыш ирләре бар. Алар артыннан үсеп килүче яшь буын — хыялый малай Азат, дуслыкка тугрылыклы Миңлегаяз, крестьянча төпле фикер йөртә белгән Вакыйфлар бар. Аларның үзәге таза, күңелләре нык. Малайларның киләчәктә авылның алтын баганалары булуына ышанасың».

Сораулар һәм биремнәр

1. «Ак кыялар турында хыял» повестенда уздырылган төп фикерне үз сүзләрегез белән әйтеп бирегез.

2. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендәге төп үзенчәлек дип сез кайсы якны билгеләр идегез?

3. Микәйнең төп ялгышы — кешеләргә артык ышануында дип әйтеп буламы? Болай булганда, кешеләр турында аның әнкәсе каткат кисәткәннәр дөрескә чыга түгелме?

4. Әсәрдәге төсләргә бәйле урыннарны билгеләгез. Аларның һәр очракта нинди вазифа башкаруын аңлатыгыз.

5. Татар әдәбиятында җанлы табигать вәкилен үзәккә куйган әсәрләр тагын бармы? Булса, кем күбрәк хәтерли икәнен ачыклагыз.

6. «Аракы — кешелекнең дошманы» дигән сөйләшү уздырыгыз. Сөйләшүдә күбрәк үзегез белгән мисаллардан, күз алдыгызда булган яки ишеткән хәлләрдән файдаланыгыз.

7. «Ак кыялар турында хыял» повестена таянып, башка әсәрләреннән дә мисаллар китереп, Ринат Мөхәммәдиевнең проза остасы булуын раслагыз.

Әдәбият теориясе. Тормышны, кешене чагылдырганда, язучы дөреслеккә омтыла. Әмма әдәби әсәрләрдә чагылган дөреслек белән чынбарлыктагы дөреслек арасында тәңгәллек юк. Сәнгатьнең башка төрләре кебек үк, әдәбият та — сәнгатьчә дөреслек мәйданы. Әдәби әсәрдә тудырылган тормыш күренешенең гади чынбарлыкка төп-төгәл охшамаган булуы — аның гаебе түгел, ә казанышы. Чөнки, акыл иясе әйткәнчә, сәнгать үз әсәрләрен чынбарлык дип тануны таләп итми. Димәк, сәнгатьнең һәм әдәбиятның үзләренә хас дөреслек категориясе бар. **Сәнгатьчә (художестволы) дөреслек** — һәм әсәр авторы, һәм укучы (яки тамашачы) тарафыннан уртак эзләп табылган дөреслек ул. Ул әдәби әсәрдә тормышчан дөреслек белән язучының эстетик идеалы берберсенә туры килүе нәтиҗәсендә туа. Ә эстетик идеал — җәмгыять төзелешен һәм кешеләрне камил итеп, алардагы матур якларны һәм сыйфатларны алга куеп кабул итү дигән сүз.

Дөреслекне сәнгать төрле алымнар, шул җөмләдән тормышчан булмаган алым-чаралар ярдәмендә дә раслый һәм яклый, мәсәлән, шартлы һәм фантастик-әкияти алымнар, арттырулар ярдәмендә. Шуңа да әдәби әсәрдәге вакыйгалар һәм образлар нәкъ менә тормыштагыча булмаска, алай гына да түгел, бөтенләй дә тормыштагыга охшамаска, аңа ят булырга да мөмкин. Мәсәлән, «Ак кыялар турында хыял» повестенда кәҗә тәкәсе кешечә уйлый, хис итә, ярата һәм нәфрәтләнә, яхшылыклар эшли һәм яман гадәтләргә өйрәнә. Әлбәттә инде, чынлыкта бу алай була алмый. Бу — бары тик художестволы (сәнгатьчә) уйланма ярдәмендә тудырылган шартлы образ. Марк Твен язганча, сәнгатьтә дөреслек, әгәр дә характерлар һәм шартлар шуны таләп итә икән, булуы ихтимал булганнан читкә тайпылырга курыкмый.

Төп хикмәт шунда: сәнгатьчә дөреслек реаль хакыйкатьне ачыграк итеп, үтемлерәк итеп, тәэсирлерәк итеп расларга тиеш. Ринат Мөхәммәдиев повестенда да кешелек җәмгыятенең язмышына янаган аракы турындагы дөреслек шартлы алымнар һәм образлар ярдәмендә ышандырырлык һәм тәэсирле итеп раслана. Бу — әсәрдә сәнгатьчә дөреслек көчле дигән сүз.

ХӘЗЕРГЕ ДРАМАТУРГИЯ

Илдә бара торган кискен вакыйгалар эчендә драматургия төре дә үз урынын табарга, сәхнәне заманча әсәрләр белән тәэмин итәргә омтыла. Драматурглар көн тәртибендә торган мәсьәләләрне аңларга, аларны әсәрләренең үзәгенә куеп хәл итәргә тырышалар. Бу төрдә бүген иҗатка 60—70 нче елларда килгән авторлар Туфан Миңнуллин һәм Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев һәм Шәриф Хөсәенов, Ризван Хәмид, Әхсән Баян, Рабит Батулла, Рөстәм Мингалим, Әхәт Гаффар, Диас Вәлиев, Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин, Ркаил Зәйдулла, Данил Салихов һ.б. актив эшли. Алар янына Зөлфәт Хәким, Мансур Гыйләҗев, Гафур Каюмов, Флорид Бүләков, Фәнәвил Галиев, Рәфис Сәлимҗанов, Аманулла кебек яшьрәкләр килеп кушылды; драматурглар отряды көчәйде.

Сәхнәдә — тормыш

Хәзерге драматургия төрле-төрле мәүзуг-темаларга мөрәҗәгать итә. Алар арасында электән килә торган, ягъни традицион мәүзуглар да, яңалары да бар. Соңгылары заман таләбе белән бүген туган шартлар нигезендә барлыкка килде. Мәсәлән, шундый яңа темаларның берсе итеп милләт язмышы мәсьәләсен күрсәтергә була. Аңың тамырлары үткәнгә барып тоташа.

XX гасыр башында ук, бигрәк тә Г. Исхакый әсәрләрендә татарның киләчәк язмышын, динен саклап калырга көчле омтылышы сурәтләнә («Зөләйха» драмасы). Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары чорында татар язучыларында югалган дәүләтчелегебезне кире кайтару өмете уянды. Алар, шуңа багышлап, күп кенә әсәрләр яздылар. Ләкин бу өмет акланмады. Татар халкына чикләнгән автономия биргән булып, Совет хакимияте башлыклары бу мөстәкыйльлекне кәгазьдә генә калдырдылар. 80 нче елларның ахырында илдә башланган үзгәртеп корулар җиле бу омтылышка яңа рух өрде, яңа кызыклы әсәрләр тууга китерде.

Шуларның берсе — Т. Миңнуллинның «Илгизәр + Вера» драмасы (1992). Татар егете һәм рус кызы арасындагы гөнаһсыз мәхәббәт гаилә кору белән тәмамлана. Ләкин милләтара мондый гамәл ахыр чиктә кечерәк милләткә, бу очракта татар милләтенә зарарсыз узмый: уртак бала инде «олы» милләт баласы булып әверелә. Бу — татар милләтенең сыегаюына, торабара бетүенә таба алып бара. Монда автор кемнедер гаепләү ягында тормый, бу — объектив күренеш. Чөнки, аерым алганда, Вераның да, Илгизәрнең дә эти-әниләре — әйбәт кешеләр. Ләкин милләтара никахлар бигрәк тә бүгенге шартларда, аеруча диннәре башка булса, тулы бәхет бирә алмый. Алар аерым бер милләткә зыян сала.

Хәзерге драматургия үзгәртеп коруларның кеше рухына ясаган тәэсирен аңларга һәм моннан туган драматизмны сурәтләргә омтыла.

Инкыйлаби яңарыш, хәбәрдарлык һәм ачыктан-ачык сөйләү иреге иске тәртипләргә ияләнгән күп кешенең акылын чуалтты. Кемнәр өчендер бу хәтта фаҗигагә әйләнде. Партия һәм совет оешмаларында җитәкче булып эшләгәннәр өчен дә авыр сынаулар башланды. Администраторлык итүгә, боеруәйтеп тору алымына күнеккән, башка эш стилен күз алдына да китермәгән кешеләргә яңача эшләргә өйрәнергә, яңача яшәргә кирәк булды. Моны без Т. Миңнуллинның «Вөҗдан газабы» (икенче исеме «Үткән еллар, көткән юллар») драмасында (1987) күрәбез. Район партия комитетының беренче секретаре Рәшит Тимергазин үзгәрешләр чорына килеп кергәч буталып-югалып кала. Җитәкчелек итү тәртибен, хәтта яшәү принципларын да тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Ә яңа ориентирлар юк, акыл бирүче күренми, барысы да пыран-заран килгән. Намуслы кеше буларак, ул моңа тирән борчыла, җәфалана, эзләнә һәм бәргәләнә. Шуларны сурәтләү ярдәмендә автор «үзгәртеп кору һәркемнең үзеннән башланырга тиеш» булуын әсәрендә төп фикер итеп уздыра.

Т. Миңнуллин драматургиясе соңгы елларда заманга тирәнрәк үтеп керә, зур-зур фикерләр күтәрә. Анда бүгенге яшәешнең, агымдагы тормышның өлгергән мәсьәләләре, төрле яклары чагыла, шул исәптән үкенечле, гыйбрәтле яклары да.

Шуны авторның «Әниләр һәм бәбиләр» драмасы да (1984) раслый.

Кешегә, табигатьнең барлык җан ияләрендәге кебек, үзен саклап калу, алга таба үрчү инстинкты салынган. Ата-ана үз

баласы өчен һәммәсен эшли, авырлыкларга түзә, хәтта үлемгә дә бара. Ләкин кешелек тәраккый иткән, ә әхлак кануннары йомшарган саен, бу изге бурычка хыянәт итү очраклары ешая. «Әниләр һәм бәбиләр» драмасы шуны күрсәтә, чаң суга.

...Бала табу йортының бер бүлмәсендә яңа гына бәби тапкан 4 ана ята. Төрле милләт вәкилләре: 12 бала анасы Гөлфинә һәм яшь Дилемма — татарлар, Алтынчәч — казах, Валентина — рус хатыны.

Шуларның өчесен яңа туган сабыйларына мәхәббәтле караш, дөньяга яңа кеше китерүләренә сөенү һәм горурлану үзара берләштерә, якынайта. Әмма бу яктан Дилемма алардан аерыла. Шул җирлектә драматик конфликт та туа. Яшь ана үз баласын ашатудан баш тарта, аны тәрбияләп үстерергә нияте юк. Уе — баласын шифаханәдә калдырып китү, аннан котылу. Моны эшләү өчен, ул үз-үзен дә, ирен дә әзерләп өлгергән, үзенчә фәлсәфә кора. Аның врачы белән сөйләшкән шушы өзектә шул ачыла:

«Айзарә. Мине сезнең балагызның язмышы борчый.

Дилемма. Нигә сез аңа борчыласыз?

Айзарә. Баланың әнисе борчылмый икән, кемдер борчылырга тиеш ич инде. Мин аңламыйм сезне, Менгличева.

Дилемма. Аңлашылмаслык ни бар? Баланы алмаячакмын. Һәм минем ирем дә, законлы ирем дә, шул ук фикердә.

Айзарә. Ни өчен?

Дилемма. Әлегә безгә бала кирәкми. Ул безгә комачаулый.

Айзарә. Ничек?

Дилемма. Бала карарга безнең вакытыбыз юк. Безгә икебезгә дә укып бетерергә кирәк.

Айзарә. Әниләрегез бармы?

Дилемма. Без аларга бурычлы булырга теләмибез. Икебез дә.

Айзарә. Алайса, нигә балага узарга иде?

Дилемма. Ул безнең ялгышыбыз. (...)

Айзарә. Сез укыган институтка хәбәр итәчәкбез.

Дилемма. Без ул вариантны да уйладык. Без җинаять эшләмибез. Аборт ясатып үтергәнгә хөкем итмиләр, ә моның өчен нигә хөкем итәргә тиешләр? Ни аермасы бар?

Айзарә (*кыза төшеп*). Кем карарга тиеш сезнең балагызны? Уйладыгызмы шул хакта? Кем карарга тиеш?

Дилемма. Кабатлап әйтәм: кемгә кирәк, шул карар. Андыйларны карый торган махсус урыннар бар.

Айзарә. Дәүләт җилкәсенә?

Дилемма. Дәүләтнең җилкәсе юк. Дәүләт үзе кешеләр җилкәсендә утыра. Дәүләткә хезмәт итәргә кешеләр кирәк. Кирәк икән — үстерсен».

Шулкадәр цинизмнан гаҗиз калган врач Дилеммадан «Иманыгыз бармы сезнең?» дип тә, «Бишек җырын беләсезме?» дип тә сорый. Тегесе җавабында «Мин ул сүзне аңламыйм» дип, «Безгә аны өйрәтмәделәр» дип кенә җибәрә.

Бәгырьсез яшь ананың беренче карашка үзенчә нигезле күренгән бу «фәлсәфәсе» драманың бөтен төзелеше, барышы, образлар системасы, сәнгатьчә чаралары ярдәмендә кире кагыла. Җиде ел үз баласы булуны зарыгып көткән Валентина да, үзен бик тә ямьсез санаган Алтынчәч тә, беренче баласын табарга теләмәгән, шуның аркасында гомерлек газапларга дучар булган Исемсез хатын да, турыдан-турымы яки читләтепме, Дилемманы бу адымы өчен гаеплиләр, нәфрәтләнәләр. Балаларның исән-сау дөньяга килүе, әниләренең сәламәт булуы өчен җаваплы табиблар Зәйтүнә Закировна һәм Айзарә Әхәтовна хатын-кыз табигатенә ят булган бу эше өчен Дилемманы кискен тәнкыйтьлиләр.

Үз баласыннан баш тарткан яшь ана вакыйгасы сюжетның үзәген тәшкил итсә дә, драмада төп фикерне уздыруга ярдәм итүче, укучыда һәм тамашачыда үрнәк алу хисе уятучы образ ул — Гөлфинә. Аналарның үз балаларына мәхәббәтен, һәркемне үз итеп, яратып кабул кылуны, тормышка оптимистик карашны олылаучы образ. Кешелекнең өзлексез алга үсешен, буыннар бәйләнешен, дөньяга яңа кешене бүләк итү вазифасын дөрес аңлавын Гөлфинә гади һәм тормышчан итеп, ышандырырлык төстә җиткерә белә. Бу — авторның зур уңышы. Гөлфинәнең — бераз гына беркатлы да, күп сөйләргә яратучы, кыбырсыграк, тиктормас хатынның — җанлы холыкгадәте әсәрдә бик оста бирелгән. Бу хатынның менәзендә иң якты як нәрсәдә дип сораганда, миһербанлылыкта, балаларын, ирен һәм, гомумән, бөтен кешеләрне яратуында дип җавап бирергә мөмкин. Чын кешегә хас мондый сыйфатлары аркасында Гөлфинәнең ир белән хатын арасындагы интим мөнәсәбәтләрне шактый ук ачыктан сөйләве дә гаепкә алынмый, бары тик күңелле елмаю гына уята.

Драманың җанлы һәм кызыклы булып чыгуына бала тирбәтүче ике ананың шартлы образлары, бу аналарның

җырлары (бишек җырлары), өч халыкның бишек җырлары яңгырау да ярдәм итә. Алар төп фикерне җиткерүдә үтемле чаралар булып торалар.

Т. Миңнуллинның соңгы еллар драматургиясендә бүгенге җәмгыятебезнең башка тагын да бик күп өлгергән мәсьәләләре: җанлы табигатькә мөнәсәбәт, аны саклау, аңа һәм кешеләргә миһербанлылык, туган телне югалту куркынычы һәм аның кайбер аяныч нәтиҗәләре һ.б. сәнгатьчә югарылыкта чагылыш таба («Авыл эте Акбай», «Акбай һәм сарык малае», «Гармун белән скрипкә» һ.б.).

Драматургиядә тормыш бөтен тулылыгында һәм төрлелегендә чагылуга башка драматурглар да лаеклы өлеш кертәләр. Һәрберсенең үз иҗат йөзе, дөньяны үзенчә күрү үзенчәлеге бар.

Юныс Әминев белән Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов һәм Юныс Сафиуллин төп игътибарларын халыкның уңай гореф-гадәтләрен яклауга һәм пропагандалауга бирәләр. «Кан кардәшләр», «Баласын җуйган болан эзеннән», «Әни килде», «Сүтәргә билгеләнгән йорт» пьесаларында шуларны күрәбез.

Әхсән Баянов («Алтын кашбау») һәм Әхәт Гаффар («Соңгы сәгать») буыннар бәйләнешен тәэмин иткән якларны һәм билге-сыйфатларны символик һәм метафорик образлар ярдәмендә чагылдыралар.

Рөстәм Мингалим һәм Мансур Гыйләҗев кешенең җәмгыятьтәге урынын, аның билгеләмәсен, бүгенгенең үзәгендә саф күңелле шәхесләр торырга тиешлеген аңларга һәм расларга тырышалар («Дүрт кешелек утыргыч», «Бичура»).

«Ак калфагым төшердем кулдан...» драмасында Илдар Юзеев шәхесләр язмышын сурәтләү ярдәмендә татар милләтенең язмышын чагылдыра. Публицистика алымнары белән баетылган бу әсәр сәяси фикерләрне тамашачыга һәм укучыга тулы җиткерә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәзерге драматургиядә актив иҗат итүче авторларны санагыз. Аларның нинди әсәрләрен укыганыгыз яки сәхнәдән һәм телевизордан күргәнегез бар?

2. Бүген актуаль төс алган нинди темаларны атый аласыз? Аларның кайсын әһәмияте ягыннан алга чыгарыр идегез?

3. Т. Миңнуллинның соңгы елларда язган пьесаларын атагыз. Аларның кайсылары сезгә яхшы таныш?

4. «Илгизәр + Вера» драмасын өйдә укыгыз. Дәрестән тыш җыелышып, бу әсәр буенча фикер алышу оештырыгыз. Бу пьеса милләт язмышының кайсы ягына кагыла? Чын мәхәббәт ике милләт вәкиле арасында кабынганда һәм алар гаилә корганда, уртак баланың кайсы милләткә караган булуы мөһимме? Әллә мондый гаиләнең бәхетле, тигез булуы мөһимрәкме? Шулар турында фикерләрегез белән уртаклашыгыз.

5. Бер укучыга «Хәзерге татар драматургиясе» дигән мәүзугка доклад ясарга кушып, сыйныфта шул докладны тыңлап, тикшерү уздырыгыз.

6. «Мин яраткан драма әсәре» дигән темага сочинение языгыз.

Жанрлар байлыгы һәм форма төрлелеге

Жанрлар ягыннан төрлелек, форма яңалыклары, гомумән, бөтен әдәбият кебек үк, драматургиянең дә өлгергәнлек дәрәҗәсен күрсәтәләр. Төрлесе төрле жанрларны үз күреп, ә кайбер авторлар берничә жанр төрендә дә тормыш дөреслегенә ирешергә омтылалар.

Хәзерге татар драматургиясенең төп үсеш сызыгы реализм юлыннан бара. Ягъни драматурглар тормышның үзенә хас формаларда, үз кануннары җирлегендә иҗат итәләр, чынлыктагы кешеләргә һәм вакыйгаларга охшаш уен тудыралар.

Ш. Хөсәенов «Әни килде» әсәрендә, мәсәлән, нәкъ тормышның үзендәгечә ситуация һәм образлар тудыра. Каты авыру ананың балалары янына шәһәргә килүе, соңгыларының аңа мөнәсәбәтләре — берәүләренең аңа ихлас ярдәм итәргә тырышулары, икенчеләренең аның турында артык пошынмыйча рияланулары, үзләре турында күбрәк кайгыртулары — чын тормыштагыча күрсәтелә.

Ә инде А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» трагедиясендә гел тормышчан гына булу максаты куелмаган. Монда ясалмалыклар да, күчерелмә мәгънә, ягъни метафора белән эш йөртүләр дә бар. Мәсәлән, эшчән-тырыш, байлыкка исе китми торган, атасы йортын ташлап чыгып китә алган Мирвәлинең бераздан атасыннан калган мал-мөлкәт өчен авылдашлары белән пычакка-пычак килүе тормыш логикасына туры килеп бетми, ышандырмый кебек. Ләкин шаблонга сыймаган шушы ситуациядә олы дөреслек, тормыш дөреслеге ачыла. Ул да булса 30 нчы елларда илдә крестьяннарга каршы алып барылган кыерсыту сәясәте, һәркемне ярлы итеп кенә күрәсе

килү теләгенә баш игән, байлыкны кабул итмәү, яратмаска өндәү сәясәте. Шул еллар авылыннан, туган-үскән җиреннән аерылырга мәҗбүр ителгән кешенең авыр һәм газаплы язмышы сәнгатьчә дөрес чагылыш таба.

Әмма бу әсәр дә, асылда, реалистик уен стилен нык саклый. Күпчелек урында һәм күренешләрдә шулай. Ясалмалыклар һәм метафорик алымнар бу стильне баеталар гына.

Икенче төр пьесаларда романтик пафос (рух), шартлылык һәм ясалмалылык өстенлек итә. Тормышны автор үзе күрергә теләгәнчә, образларны беркадәр күтәреп һәм бизәп, кешеләрне матуррак итеп, вакыйгаларны куертып бирү аларны гади реалистик драмалардан аерып тора. Кешеләр характерындагы нинди дә булса бер як алга чыгарылып, төп игътибар шуңар юнәлтеп тасвирлана.

Мәсәлән, Әхәт Гаффар, Ватан сугышының миллионнарга китергән афәт-хәсрәтен үтемле итеп сурәтләү өчен, шундый алымнарга мөрәҗәгать итә. «Язлар моңы» драмасында Фәрдәнә белән Сәгыйдулланың мәхәббәтен һәм гаилә бәхетен җимергән сугыш, кайта-кайта, уенда катнашкан һәр персонаж ярдәмендә каһәрләнә. Барысы да, хәтта кыңгырау чыңы, гармун, кисмәктәге су һ. б. детальләр дә бер үк ноктага бәрә, уенны бер юнәлешкә туплый. Сәхнә күренешләренең еш алышынуы, бу алышынуларда хәтер белән реальлек аралашуы, шуларга яшерелгән символик мәгънә ясалманың, шартлылыкның чынбарлык иллюзиясенә күчеп китүен тәэмин итә. Драмага кертелгән «сугыш җыры» — «сагыш җыры», гомумән, җыр-моң әсәрне буйдан-буйга сугара. Ул юкка гына «Язлар моңы» дип аталмаган. Автор көтелмәгән, кискен хәлләр белән эш йөртергә ярата. Матур мәхәббәткә ия булган Люция белән Хәмитнең туе буласы көнне генә иртән авылның мөхтәрәм кешесе Сәгыйдулла үлеп китә. Ягъни үлем һәм яңа тормыш кара-каршы очрашалар. Шулай башланган драма туйның кызган мәлендә Фәрдәнә карчыкның үлеме белән тәмамлана. Шулай да бу хәл барыбер яшьлек тантанасын, яшәүнең мәңгелеге мәгънәсендәге язлар моңын баса да, каплый да алмый. Кыскасы, татар драматургиясе бүген шартлы-ясалма образларга һәм хәлләргә торган саен иркенрәк һәм уңышлырак мөрәҗәгать итә. Шуның белән сәнгатьчә дөреслекне күбрәк яулый бара.

Яшь драматурглар иҗаты да шуны ук раслый. Мәсәлән, Рәфис Сәлимҗанов «Акъярдагы ахырзаман» исемле комедиясендә шартлы алым-чаралардан уңышлы файдалана.

Кыскача эчтәлек мондый. Ахырзаман киләчәген көтеп яшәп яткан Җиһан карчык бердәнбер көнне Шири дигән сөннәтче картның даруына (яшәртә торган дару, имеш) шулкадәр ышана ки, шуны эчкәч, елдан-ел яшәрә барып, 105 яшендә 16—17 яшьлек кызлар кыяфәтенә керә. Яшьләрчә кыланып яши башлый. Тик эшкә генә урнаша алмый. Паспортында күрсәтелгән туган елы комачаулый чөнки. Тагын да килеп, малае — 80 яшьлек Хөсәен карт — аңар үзе теләгәнчә яшәргә ирек бирми. Бердәнбер көнне Ширинең даруы ялган икәнлеге ачыла. Шунда Җиһанны моңарчы гел яшәртеп килгән эчке ышаныч шартлап сына, һәм ул бер айда үз асыл кыяфәтенә кайта, ягъни яшенә туры килә торган кыяфәтен ала. Шундый фантастик сюжетка корылган пьеса оптимистик фикерне үзенчәлекле итеп раслый: «Һәрнәрсә — кешенең үзендә! Үзенең рухи ныклыгында, ныклы эчке ышанычында!» «Барлык әшәкелек күңел картаюдан килеп чыга,— дип раслый автор.— Күңел яшь булсын!» Бу фикер урынлы һәм дөрес яңгырый.

Драматург Зөлфәт Хәким «Кишер басуы» исемле сатирик комедиясендә фантастик шартлылыкка шулай ук киң урын бирә. Чит планетадан очып килгән, кайчандыр Сергач мишәрләреннән чыккан кунаклар колхозның кишер басуына килеп төшәләр, җирле халык белән якыннан аралашалар. Шул шартлы ситуация авторга бүгенге авылның, бүгенге кешеләрнең, алай гына да түгел, татарның бүгенгесенең кимчелекләреннән мыскыллап та, сыкранып та, сызланып та көләргә мөмкинлек биргән.

Жанр төрләреннән һәм формаларыннан файдалануда, шулай итеп, соңгы еллар драматургиясе шактый уңышларга иреште. Анда бүгенге драманың төрле төрләренә мисаллар табарга була: психологик драма (Т. Миңнуллин «Хушыгыз!»), публицистик драма (Ә. Гаффар «Килер бер көн»), сәяси-фәлсәфи драма (И. Юзеев «Ак калфагым төшердем кулдан...»), иҗтимагый драма (Ф. Бәйрәмова «Безне онытмагыз!»), тарихи-биографик драма (Т. Миңнуллин «Без китәбез, сез каласыз»), иҗтимагый комедия (А. Гыйләҗев «Көттереп искән җил»), лирик комедия (Р. Мингалим «Кунак кызы гел килмәс»), сатирик комедия (Р. Вәлиев «Әй машина, машина...»), музыкаль комедия (М. Гыйләҗев «Казан егетләре»), водевиль (Р. Батулла «Сөйгән ярым ятка кала»), трагикомедия (Зөлфәт Хәким «Җүләрләр йорты»), трагипамфлет (Р. Батулла «Мин Америка ачтым»), детектив комедия (Т. Миңнуллин «Гармун уй-

ный беләсеңме?»), трагедия (А. Гыйләҗев «Өч аршын җир»), шигъри трагедия («Ә. Баян «Каракош») һ.б. Татар драматургиясенең жанр төрләренә бу кадәр үк бай булганы юк иде әле.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәзерге драматургиянең, асылда, реализм юлыннан баруын сез ничек аңлатасыз? Реалистик драмага мисаллар китерегез.

2. Реалистик драманы баетуда шартлылыкның, әкият һәм легенда алымнарының ролен үз сүзләрегез белән аңлатып бирегез. Шартлы-метафорик драмага мисаллар китерегез.

3. Бүгенге драматургиянең жанр төрләренә һәм формаларына бай булуын мисаллар китереп раслагыз.

4. Бүгенге театрлар сәхнәләрендә нинди спектакльләр караганыгыз бар? Аларны кайсы жанр төренә кертеп була?



Рабит Батулла
(1938)

«Сират күпере»
(1986)

Хәзерге драматургиядә тарихи һәм тарихи-биографик жанр төре җанланды. Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, Ә. Баян борынгы дәверләргә, Болгар ханлыгы чорына, Е. Пугачёв заманнарына караган пьесалар яздылар. Татар халкының авыр язмышын А. Гыйләҗев, И. Юзеев драма һәм трагедияләрдә күз алдына китереп бастырдылар. Инкыйлаблар чорлары, Бөек Ватан сугышы еллары тетрәткеч вакыйгалар аша пьесаларда чагылдырылды.

Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулу уңаеннан берничә сәхнә әсәре язылды. Р. Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым», Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз», И. Юзеевнең «Очты дөнья читлегеннән», Ә. Гаффарның «Соңгы сәгать» кебек драмалары һәм трагедияләрендә шагыйрь образын яңача сурәтләргә омтылыш көчле. Болар арасында Р. Батулланың «Сират күпере» драмасы да бар.

Рабит Мөхлис улы Батулла — күп пьесалар авторы. Алар арасында «Өчәү юлга чыктык» (икенче исеме «Ихлас») исемле драма, «Сөйгән ярым ятка кала» дип аталган водевиль, «Кичер мине, әнкәй» дигән мелодрама, памфлет, әкият-пьеса һ.б. бар. Шулай санап чыгу гына да бу авторның драматург буларак та иҗат офыгы (диапазоны) киң икәнен күрсәтә. «Сират күпере» дә шуны раслый.

Тукай образы

Бөек шагыйрь образына язучылар күптәннән мөрәҗәгать итә киләләр. Әле 40—50 нче елларда ук Әхмәт Фәйзи «Тукай» романын, «Тукай», «Тукай Җаекта» пьесаларын, 60 нчы елларда Ибраһим Нуруллин «Тукай Петербургта» драмасын язалар. Боларда шагыйрь образын тарихи фонда ачуга, тарихи, ягъни чынлап та булган фактлар ярдәмендә сурәтләүгә ныклы игътибар бирелә.

Г. Тукайның олы юбилеена атап язган драмасында Риза Ишморат та, асылда, үзәк образны тасвирлауда шушы принципны саклый. Тарихи фактлардан читкә чыкмаска тырыша. Әсәрдә шагыйрь образы белән янәшә үк аның замандашлары һәм дуслары Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Сүнчәләй һ.б., шулай ук аның дошманнары һәм оппонентлары образлары да шактый тулы ачыла.

Ләкин, тарихи фактларга һәм тарихи шәхесләрнең реаль образларына тугрылык саклаганда да, тарихи-биографик әсәр авторы уйланма образларга һәм ситуацияләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Шунсыз мөмкин түгел. Әйтик, Тукай турында күпме генә беләбез дип уйласак та, без аның һәр көне, һәр сәгате, шул ук вакытта кемнәр белән аралашуы, ни-нәрсә турында уйлавы һәм кайгы-хәсрәтләре турында кистереп әйтә алмыйбыз, чөнки белмибез. Ә әсәрдә чынлык, тормышчанлык сакланырга һәм тудырылырга тиешле. Димәк, чынлык иллюзиясе тудыру өчен, язучы үз фантазиясен эшкә җигәргә, вакыйгалар һәм характерлар уйлап табарга тиеш була. Соңгы елларда Г. Тукайга багышлап язылган пьесаларда уйланманың роле арта бара. Төп, чыннан да булган фактларга хыянәт итмичә (мәсәлән, шагыйрь бер елны Петербургка, икенче бер җәйдә Акчуриннар утарына сәяхәт кылган; Казанда «постоялый двор» тибындагы кунакханәдә, бер кечкенә бүлмәдә яшәгән; авыргач, Клячкин шифаханәсендә яткан, шунда вафат булган һ.б.), аларны дөрес, тормыштагыча сурәтләү белән бергә, драматурглар үзләре уйлап чыгарган вакыйгаларны, уйланма образларны да шактый күп кертәләр. Әдәбият белемендә моны **әдәби уйланма** яки **сәнгатьле уйланма** дип атыйлар. Чынлык белән уйланманың кушылмасы никадәр уңышлы булса, әсәр сәнгатьлелек ягыннан шулкадәр ота, укыр өчен кызыклырак, тәэсир итүе көчлерәк була.

«Сират күпере»ндә Тукайның соңгы айлары һәм көннәре сурәтләнә. Ул инде бу вакытка шәхес буларак та, шагыйрь буларак та формалашып җиткән, киң танылган.

Тукайның табигатендәге, холык-фигылендәге безгә истәлекләрдән мәгълүм булган сыйфатлары драмада төрле ситуациядә ачыла. Талантлы һәм горур, туры сүзле, хәтта бәгырьсез дәрәҗәдә туры сүзле, үзенең җирдәге урынын яхшы аңлаган, дусларын яраткан, хатын-кызга кырысрак һәм беркадәр кыюсыз мөнәсәбәтле, киң карашлы, тирән белемле — әсәрдә Тукай шундый шәхес булып күз алдына баса.

Шуның белән бергә, Тукайның олы мәхәббәт хисенә ия булган кеше икәне дә әйбәт күрсәтелгән. Шул ягы белән Р. Батулла драмасы олуг шагыйрьгә багышланган башка әсәрләр арасында уңай якка аерылып тора. Тукайны аз санлы, ләкин бик гүзәл мәхәббәт шигырьләре язарга рухландырган затны автор Туташ дип кенә атый. Аларның очрашу күренеше, берберсенә хисләрен белгертү бик оста эшләнгән. Тукайны без монда олы җанлы, нечкә хисле, көчле тойгыларына баш була белгән, аларны шагыйрьләрчә матур итеп сүзләргә төрә алган, тыйнак та, беркадәр хыялый да мәҗнүн итеп күрәбез.

Һәммәсе өстенә драматург Тукайны көрәшче төсендә тәкъдим итә. Шагыйрь — халкының бәхете өчен көрәшүче, үксезләрне, ятимнәрне, кыерсытылганнарны яклаучы. Шагыйрь — хокуксыз милләтенең вөҗданы, таянычы, ышанычы. Хәтта шәхси бәхетен, олы мәхәббәтен, гаилә тормышын да ул шушы юлда корбан кыла. «Минем өчен түгел андый тормыш,— ди ул дусты Агабәккә.— Мин тулаем халыкныкы! Башым, иҗатым, авыруым белән мин халыкка кире кайтарып алмаска тапшырылган. Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым».

Дөрес, монда Тукай берьяклы уйлый, ялгыша дип тә әйтергә мөмкин. Ләкин бит ул үзенең төзәлә алмаслык авыру икәнен белеп сөйли, чын хәлен шулай хата дип әйтерлек фикерләр артына яшерә.

Үзенең максатын, иҗатының асылын Тукай хәтта дошманыннан да яшерми, ачыктан әйтеп бирә: «Әгәр милләт мине илтифат итеп искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем...» — ди ул Шәүләгә. Аның иң соңгы сүзләре дә шул рухта яңгырый:

Кыйналып-суелып
Бетмәгән
Шигъри динем, исән бул!

Изелеп-кырылып
Үлмәгән
Татар халкым, исән бул!

Шагыйрьне рухландыручы һәм яшәтүче көчләр

Туры һәм кырыс Тукай ялгыз гына түгел. Без һәрвакыт: «Тукай халыкныкы, аны халык үстерде»,— дибез. Шагыйрь үзе дә:

> «Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
> Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем»,—

дип язган («Дошманнар», 1912).

Драмада халыкның шагыйрьгә мөнәсәбәте аерым персонажлар, конкрет шәхесләр образлары ярдәмендә күрсәтелә. Әнә Агабәк — шагыйрьнең күршесендәге бүлмәдә яшәүче җан дусты, акыллы, сабыр, тәҗрибәле кеше. Аның прототибы Фатих Әмирхан булуын укучы тиз аңлый.

Ядкәр Хөрмәтовның чынлыкта революционер Хөсәен Ямашев булуына да ансат төшенергә мөмкин.

Болар — рухи дуслар, көрәштәшләр. Агабәк өчен дә, Ядкәр өчен дә Тукай шагыйрь генә түгел, ул — яхшы иптәш тә, кече күңелле, сабый холыклы, сер сыя торган дус та. Ләкин, әлбәттә, иң элек — шагыйрь, халык улы. Милләте өчен кирәкле, халыкка сүзе үтә торган бөек шәхес.

Сагышлы, Бикчура исемнәре белән аталган персонажлар да Тукайны образ буларак тулырак ачарга ярдәмләшәләр.

Алар һәммәсе шагыйрьнең иҗтимагый тормыштагы урынын ачыкларга, аның әдәбиятка карашын, иҗат кешесенең җәмгыять тормышында биләгән урынын күзаллавына төшенергә, шагыйрьнең гражданин һәм патриот булуын гәүдәләндерергә булыша. Шуның белән бергә, безгә — укучыга һәм тамашачыга — шагыйрьнең рухи дөньясының байлыгын күрсәтә һәм образ буларак җанландыра торган башка якларны белү дә кызыклы һәм мөһим. Сүз аның шәхси тормышы, аның — яшь егетнең — мәхәббәткә һәм гаилә тормышына мөнәсәбәте, бу җәһәттән уңышлары һәм уңышсызлыклары турында бара. Электәрәк язылган әсәрләрдә Тукай берьяклырак сурәтләнә, ул, нигездә, шагыйрь һәм көрәшче буларак кына гәүдәләнә иде. Р. Батулла шагыйрьне кеше буларак тулырак гәүдәләндергән. Моның өчен Туташ һәм Ханым образларын керткән, алар белән шагыйрьнең үзара мөнәсәбәтен шактый җанлы һәм ышандырырлык итеп бирә алган.

Туташка мөнәсәбәтендә Тукай көчле сөю хисенә ия булган, шуңа тугрылыклы, олы җанлы кеше рәвешендә ачыла. Ләкин

сөеклесен тол язмышына дучар итеп авыр хәлдә калдырмас өчен (чөнки үзенең тиздән дөньядан китәчәген ул белә), ул мәхәббәтеннән баш тарта, «сезне сөймим» ди, изге ялганга бара.

Тукайның Туташ белән аңлашу күренеше шигърият белән сугарылган, мәгънәле һәм хисле. Алар чәчәкләр ярдәмендә аңлашалар, берсе зәңгәрсу чәчәкне, икенчесе ак чәчәкне мактап, бер-берсенә күңелләрендә асраган хисләрне белгертәләр, күңелләрен ачалар. Ә аларның күңелләре саф, чиста, гүзәл.

«Тукай. (...) Зәңгәр төс. Зәңгәр чәчәк. Зәңгәрнең дә иң нәфисе — зәңгәрсу төслесе. Бәгыремә, каныма якын иң матур чәчәк бу, Туташ. Бу чәчәккә карасам, авыру чагым булса савыгам. Кайгылы чагым булса, күңелем күтәрелә. Илһамсыз каңгырып йөргәндә, иҗат дәртем уяна. Рәхмәт сиңа, зәңгәрсу чәчәк. (*Чәчәкне Туташның күлмәк якасына кадап куя.*)

Туташ (*салмак кына аягүрә баса, ак чәчәк ала*). Гаҗәп бер гүзәллек! Ак чәчәк — минем сөйгән чәчәгем. Аклык ул — пакьлек галәмәте. Ак чәчәк — иң нәфис, иң саф чәчәк. Чәчәкле җәйне сөйсәм дә, мин ап-ак карлы кышны яратам. Күзләрне камаштырырлык ап-ак, пап-пакь кар өстенә карасаң, эреп югаласың. Бернинди башка төс юк. Берни күренми. Ап-ак бушлык. Ап-ак бушлык мәңгелек кебек тоела башлый. Ап-ак кар яуган кыр өстенә карасаң, вакыт югала, дөньяның матдилеге онытыла. Син хыял дөньясында эреп юк буласың. Бу чәчәк — минем иманым, бу чәчәк — минем саф хисләрем билгесе. (*Чәчәкне Тукайның күкрәгенә кадый.*) Хисләр билгесе итеп адәмнәр сүзләр уйлап чыгарган. Хисләр билгесе итеп шигырь язганнар. Хисләр билгесе итеп музыка, җыр чыгарганнар. Хисләр билгесе итеп кешеләр чәчәк бүләк итүне уйлап тапкан. Япониядә чәчәкләр теле бар икән. Нәфрәтләрен дә, кайгыларын да, мәхәббәтләрен дә алар чәчәк аша әйтәләр икән. Шулай дигәч, минем бер дус кызым: «Нәрсәкәй, әллә аларның теле юкмы?» — дип сорады.

Тукай. Телсез түгел алар. Мәхәббәт аларны телдән калдырган.

Туташ. Сез мине аңладыгыз, Тукай әфәнде».

Күрәбез: хисләр олы, саф, шигъриятле. Тукай Туташ кигән зәңгәрсу күлмәк төсенә ым ясаудан башланган сөйләшү-аңлашу мәхәббәттә аңлашу төсен ала. Болай матур итеп, мәгънәле итеп шагыйрь җанлы егет кенә, аңар торырлык кыз гына аңлаша-сөйләшә ала.

Ә Ханым белән сөйләшү күренешендә без Тукайның горур,

акыллы булуына, хатын-кызны чын күңелдән хөрмәт итүенә тагын да бер кат ышанабыз. Аның дөнья әдәбиятын һәм мәдәниятен яхшы белүен күрәбез. Чөнки тайный советник Әхтәмовның миллионерда кияүдәге кызы Гәүһәршат — югары зыялы, тирән белемле зат. Аның белән сөйләшкәндә, шагыйрь бу Ханым дәрәҗәсендә тора белә. Тукайга читтән торып гашыйк булган, аны милләт өчен сакларга кулын сузган, күңелен ачкан фидакяр җанны үпкәләтмәслек, рухын сындырмаслык итеп кире кага.

Шәүлә образы

Ә менә Шәүлә — Тукайның дошманы. Көчле, мәкерле, акыллы дошманы. Тукайның соңгы айлары һәм сәгатьләре шушы көч белән, ул юлына корган киртәләр белән көрәштә үтә. Вакыйгалар да төрле редакцияләргә, оешмаларга Шәүлә юллаган коткылы телеграммалардан башлана һәм оеша. Драма кануннары ноктасыннан караганда, бу — «Тукай каты авырый» дигән ялган хәбәр — сюжетны оештырып һәм тотып торучы. Шагыйрьнең дуслары, аның таланты алдында баш иючеләр, күп санлы укучылары хафага төшәләр. Яшеренеп йөрүче Ядкәр, телеграммага ышанып, шәһәргә кайта, һәм аны тоталар. Ялган хәбәр Бикчураның фаҗигасен дә тизләтә, Сагышлының рухи газаплары көчәеп китүгә дә сәбәп була.

Шәүлә образы — драматургның зур табышы. Бу кеше жандармериянең астыртынлыгын, мәрхәмәтсезлеген, икейөзлелеген һәм акыл көчен гәүдәләндерә. Мәсәлән, аның шәүлә һәм күләгә турындагы сүзләреннән үзенчәлекле фикер йөртергә сәләтле булуы аңлашыла.

«Ш ә ү л ә. Агачның күләгәсе була. Койманың күләгәсе була. Кешенең дә була күләгәсе. Күләгә ул хуҗасына ияреп йөри. Яки хуҗасы янында тик тора. Ә шәүлә күләгә була алмый. Шәүлә ул — җисемнең үзе. Кояш баеп беткәч, офыкта агачларның күләгәсе түгел, шәүләсе кала. Шул мохиткә берәр кеше килеп керсә, кешенең күләгәсе түгел, шәүләсе күренәчәк. Күләгә куркыныч түгел. Күләгә кояш яктысында гына була ала. Көндез. Ә шәүлә шомлы, шәүлә куркыныч, шәүлә, кеше шәүләсе, һәрвакыт куркыныч җинаятьләр тирәсендә йөри».

Тукай тирәсендә базар хәерчесе кыяфәтендә уралып йөрүче Шәүлә бертуктаусыз җәтмәләр кора, эт шикелле иснәнә, кинаяле сүзләр сөйли, шагыйрьнең бәгыренә үтәрлек хәбәрләр ташый.

Ләкин шул ук вакытта Шәүлә без моңарчы әсәрләрдә күреп өйрәнгән, кап-кара тискәре образ да түгел. Югыйсә без Тукай кебек тарихи шәхесләргә каршы көрәшкән көчләрне берьяклы гына, акылга таманрак, гел этлек эшләп йөрүче, явызлыкны үзендә туплаган схематик образ кыяфәтендә генә күрә идек. Шәүлә андый түгел. Явызлык эшли, ләкин үз эшен дәлилләп күрсәтә белә. Аның фикер йөртүендә, күп кенә сүзләрендә дөреслек тә юк түгел. Мәсәлән, аның революцияләр турындагы фикерләре бик үзгәлекле. Тукайның «Революцияне буучы палач син!» дигәненә каршы ул болай дип җавап бирә:

«Шәүлә. ...Ялгышма, Тукай. Чын революцияне яклаучы мин. Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Интеллигенция бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне асалар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак. Һәр палач, гөнаһсыз башны чапканда, бисмилла урынына: «Яшәсен революция!» — дип акырачак. Менә нәрсә ул әзерлексез революция. Хөрмәтов Ядкәр хыялланган революция ул революция түгел, ул ирексезләү, көчләү хәрәкәте генә булып калачак. Әгәр Ядкәрләр җиңә калса, Россияне «грядущий хам» — тупаслык, әдәпсезлек басачак. Россия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукай. Әнә шундыйлар Россия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәе дип, бөтен көчемне, талантымны биреп көрәшәм».

Әйе, Россиядә булган социалистик инкыйлабның нәтиҗәләре шулай булып чыкты да. Монда Шәүләнең алдан күрә белүчәнлеге сокландырырга да мөмкин.

Шулай да, төрле хәйлә белән, Тукайның ышанычын төрлечә казанып та, соңыннан үзенең кем булуын, максатын ачып салып, шагыйрьне аптыраштта калдырса да, Шәүлә рухи җиңүгә ирешә алмый. Соңгы сүз шагыйрьдә, ягъни хаклык ягында, тарихи киләчәк ягында. Бу — әсәрнең соңгы репликаларында ачык яңгырый.

Көчле һәм мәкерле дошманы өстеннән әхлакый җиңүгә ирешә алган шагыйрь образы тагын да мәгънәлерәк төс ала, үсә, зурая.

Сораулар һәм биремнәр

1. Р. Батулланың драма әсәрләрен атагыз. Алар арасыннан кайсыларын укыганыгыз яки сәхнәдән (телевизордан) күргәнегез бар? Ул кайсы ягы белән исегездә калды?

2. «Сират күпере» драмасында конфликтка кергән көчләрне билгеләгез. Бер якка да кушылмыйча, ике арада торган персонажлар бармы? Күрсәтегез.

3. Тукай образына характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? Аларның кайсы сезгә иң ошаганы? Аның шагыйрьлеген ачкан күренешләрне, диалог яки монологларны күрсәтегез.

4. «Тукай һәм Агабәк», «Тукай һәм Туташ», «Тукай һәм Ханым» дигән мәүзугларда кечкенә чыгышлар әзерләп, фикер алышыгыз. Бу мөнәсәбәтләрдә шагыйрь образының кайсы яклары ачыла?

5. Шәүлә образын бәяләгез. Аңарда патша жандармериясенең кайсы яклары һәм көчләре туплап бирелгән?

6. «Татар драматургиясендә Г. Тукай образы» дигән мәүзугка сочинение языгыз.



Ризван Хәмид

(1941)

«Җиде бажа»

(1988)

Бүгенге драматурглар арасында Ризван Хәмид җитди фикерләргә, кырыс рухлы геройларга ия булган әсәрләре белән аерылып тора.

Р. Хәмид олы сәхнәгә «Синең урыныңа кайттым» исемле драмасы (1977) белән күтәрелде. «Институт елларында ук каләм тибрәтә башлаган Ризван Хәмид берзаман, шифалы җил булып, йокымсыраган күңелләрне дә уятып, татар театрына килеп керде, озакламый аның исеме ил күләмендә яңгырады, пьесалары илебезнең бик күп сәхнәләренә менде»,— дип язды А. Гыйләҗев.

Моннан соң Р. Хәмид «Китәм инде» (1980), «Каен җиле» (1980), «Ике сәгать — бер гомер» (1984), «Майның унбишләрендә» (1984), «Диде кардәш» (1985), «Олы юлның тузаны» (1986), «Актамырлар иле» (1991) һ.б. драмаларын яза. Автор боларда драматик хәлләрне әхлакый яссылыктан әзли. Рухи хәзинәләргә, кешелекле мөнәсәбәтләргә алып килүче катлаулы үзара мөгамәләләрне тасвирларга омтыла. Аның геройларының күпчелеге — үз якташлары, авылдашлары. Шуңар да алар тормышка якын. Тагын да бер үзенчәлек шунда: бу драмалардагы геройлар үзара туганлык мөнәсәбәтендә торалар, алардагы эчке кичерешләр шуңа күрә дә тирән һәм тәэсирле. Югарыда саналган пьесаларның төп юнәлеше — җәмгыятебезгә югары әхлакый кыйммәтләр җитмәүне күрсәтү. Моның

төп сәбәбен автор фәндә һәм техникада алга киткән дәвердә кешелеклелек, миһербанлылык сыйфатларының саегуында күрә. Безгә, иң беренче, рухи атмосфераны торгызырга кирәк, ди бу әсәрләрендә драматург. Безнең тормышыбызның барлык өлкәләре өчен дә мөһим ул. Ахыр чиктә бүгенге проблемаларыбызны уңышлы хәл итү дә шуннан тора. Боларны тамашачыга һәм укучыга үтемле төстә җиткерү нияте белән, автор төрле формаларга мөрәҗәгать итә, эзләнә, еш кына уңай нәтиҗәләргә ирешә. Ул, татар драматургиясендә беренче булып, мәсәлән, бер генә кешелек драма, ягъни монодрама иҗат итте.

«Олы юлның тузаны» исемле драматик хикәядә вакыйга бик җыйнак. Нәүхәбәр карчык, авылдагы гомер сөргән йорты белән саубуллашып, шәһәрдәге улы янына китәргә җыена. Җыена, әмма китми. Менә шул гади һәм гадәти, ләкин бүгенге авыл картларының күбесенең драматик һәм фаҗигале язмышына сәбәпче булган хәлне автор, кешенең туган ил белән, туган-үскән җир белән бәйләнешен, авыр, ләкин сагышлы яшьлек белән саубуллашуын күрсәтү өчен, шактый оста файдаланган. Үткәннәренә, улының тәртибенә, әхлак кагыйдәләренә ревизия ясап, язмышының бүгенгесенә бәя биреп, Нәүхәбәр карчык заманга да, ана буларак үзенә дә яңача күздән карый. Бүген торган саен көчәя барган шәфкатьсезлекне, гамьсезлекне, байлык колы булуны кире кага.

Р. Хәмиднең драматургиясенә хас үзенчәлекле сыйфатлар аның «Җиде баҗа» исемле драмасында да чагылыш таба.

...Колхоз үзәге булган авылда ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Күгәй Гыймазетдиновка һәйкәл ачарга җыеналар. Инде барысы да әзер, ике көннән тантаналар булачак. Күгәйне, хатыны һәм кызы Дая белән бергә, һәйкәл белән танышу өчен чакыралар. Җәймәне ачсалар, постаментта һәйкәл юк, аның урынында ботаклы-чатаклы агач түмәре генә тора. Барысы да пошаманга төшә, һәйкәлне эзләү башлана. Эзләү барышында колхозның үткәне, андагы кыек хәлләр, гаделсезлекләр, кешеләр арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр, аерым фаҗигаләр мәгълүм була. Ахыр чиктә һәйкәл табыла. Аны әтисенең туган авылын бетүгә хөкем итүгә протест йөзеннән Искәндәр алып яшергән икән. Искәндәр ташландык авылны арендага алырга, колхозда бетүгә дучар ителгән яшелчә-җимешчелек тармагын тергезергә карар бирә. Моннан яңа проблемалар туа...

Һәйкәл югалу һәм аны эзләү вакыйгасы — сюжетны тотып торучы һәм үзенчәлекле характерларны ачуда бер сәбәп. Драматург бу вакыйга ярдәмендә авылның бүгенге мәсьәләләрен күтәрә. Шулардан берсе — вак авылларны бетерү, анда яшәүчеләрне бер үзәккә җыю, кешеләрне туган-үскән җирләреннән, ата-баба нигезеннән көчләп аеру сәясәте. Моның хаталыгы, кешеләрнең шул мәгънәсезлеккә каршы торулары күрсәтелә.

Колхозларның уйлагандагыча үсә алмаулары, колхоз рәисләренең алмашынып торуы, эшчән, карусыз, фидакяр Күгәй кебекләрнең дә үзәге черек булган колхозлар хәрәкәтен коткара алмавы — пьесада ачык яңгыраган тагын бер фикер.

Драмада һәр персонажның үз юлы, үз мәсләге, үз язмышы бар. Кайберсенең үз фаҗигасе. Тагын шунысы: әсәрдә баш герой дип әйтерлек образны аерып алып булмый. Һәммәсе бер яссылыкта тора. Уңае яки тискәресе дә юк. Хәтта иң хөрмәтле, иң лаеклы Күгәй дә саф пыяладай түгел. Сабыр, аз сүзле, эшчән ул. Нык ихтыярлы. Нахакка Себергә сөргәндә, төрмәгә эләккәндә дә, андагы каһәрләүләргә дә ыңгырашмаган, үч тә сакламый. Ләкин, бүгенге күзлектән караганда, Күгәй кебек карусыз, ни кушсаң, шуны эшләп йөрүчеләр дә колхозны алга җибәрергә ярдәм итә алмаганнар. Шундыйлар аркасында, аларны юмалап, орден-медальләр биреп, оятсыз һәм намуссыз җитәкчеләр колхозны таларга, ягъни халык байлыгы исәбенә яшәргә мөмкинлек алган. Шуңа күрә дә, гәрчә эш сөймәс һәм ялкау Чуракай авызыннан чыкса да, түбәндәге сүзләрдә хакыйкать тә юк түгел.

«Чуракай. ...Беләсең килсә, дөньҗада минем кебекләр булмаса, тәтеми иде сиңа ул һәйкәл.

Күгәй (*кычкырып көлеп җибәрә*). Ну!

Чуракай (*тыныч*). Кеткелдәмә, кеткелдәмә, зерә кеткелдисең.

Күгәй (*ирония белән*). Ачуланма, һаман да синең үзеңнең миңа тигән ярдәмең аңлашылып җитмәде.

Чуракай. Чөнки минем кебекләр булмаса, калхузның каккан казыгы да калмас иде. Ә хәерче калхузга кем Герой исеме бирсен?

Күгәй. Алаймыни?! Рәхмәт инде, алайса! Без көне-төне җир актардык, ә син шул вакытта эленке-салынкы чутават булып йөрдең. Белмәгән идек: синең аркада җыеп алынган икән ул мул уңышлар. Колхоз шуның аркасында бөлгенлеккә төшми калган икән, мең-мең рәхмәт сиңа!

Чуракай. Чуракайны ике сүз белән сыртына җыгып салдым, дисеңдер инде үзеңчә. Ике сүзнең берендә, мин фәлән иттем, мин тегән иттем дип, күкрәк кагасың. (*Бармагы белән югарыга ымлый.*) Әгәр дә без, синең кебек, аннан төшкән һәр әмерне кабалана-кабалана үтәргә җөгерсәк, әллә кайчан, кулыбызга капчык тотып, хәер сорашырга чыгып китәргә кала иде безгә! Беләсеңме нишләтә идек без ул приказларны? Колак яныннан мима җибәреп тордык. Әнә шуның аркасында сакланып калды калхузның кайбер казыклары! Бер генә пример китерәм, алайса. Калхуз умарталыгын кем бетертте? Соңгы киявең! Ә хәзер карабодай басуына умарта чыгарган өчен калхуз үзе миңа акча түли. Шулай булгач, кемнең заслугасы күбрәк: синекеме, минекеме?»

Р. Хәмид, язмышларның чуалып-чәбәләнеп, үзара аралашып бетүен күрсәтеп, персонажларның менәзен оста ача. Мисалларга мөрәҗәгать итик.

Искәндәрнең кәләше Вилена — колхозның яңа рәисе Дулатның хатыны, алар әле аерылышып өлгермәгәннәр. Мәхәббәте зур булса да, Искәндәр дә бу хатын белән бәхетле була алмаячак. Чөнки хатын шәһәрне ташлап авылга кайтмаячак, Дулат белән килешә алмавы да шуның өчен.

Яки Дая язмышы. Күгәйнең иң кече кызы ул. Дулатка кадәр булган рәис тарафыннан алданган, балага узган, егылып баласын төшергән... Колхоздагы һәм авылдагы гаделсезлекләрне күреп, аның йөрәге әрни, ләкин берни дә эшли алмый. Кырт холыклы, сизгер күңелле, турысын әйтеп сөйләүче бу кыз авылдан качып китеп тә карый, әмма барыбер әйләнеп кайта. Бәхетен таба алырмы ул, юкмы?!

Көбра — үзе бер дөнья, үзенчәлекле шәхес. Ире Күгәйнең киресе буларак, аның эчендәгесе тышында. Иренең шөһрәте, балаларының бәхете өчен ул — иң актив көрәшүче. Гаделсезлеккә түзеп тора алмый. Әүвәлдә укытучы булган бу хатын гаиләсендә дә өйрәтеп тору, җитәкләп йөртү гадәтен ташлый алмый. Ләкин тормышта болай итеп кенә гаделлеккә ирешеп тә, тигезлек урнаштырып та булмый. Үзе дә теләмәстән, ул кече кызы Даяның фаҗигасенә сәбәпчеләрнең берсе булып чыга.

Кызыклы образлардан берсе булган Чуракай — бик каршылыклы характер. Гомере буе колхоз җилкәсендә яшәгән сорыкортларның берсе ул. Гадел һәм эшчән Күгәйнең антиподы. Һаман да аның белән булышып, үчләшеп яши. Шулай да без аны тулаем начарга да чыгара алмыйбыз. Дөресрәге,

ул — колхоз строеның мәхлук корбаны. Кеше буларак, тапкыр, астыртын, акыллы, җор телле. Нәкъ менә шул кеше Күгәй кебекләрнең тырыш хезмәтенең мәгънәсе һәм файдасы бик тар булуын ачып сала. Совет системасының яраксыз якларын күреп-аңлап яшәүче буларак, күрәсең, ул яшәвендә ныклы кыйбла тапмаган. Ләкин гаделсезлекләргә каршы чыгарга җөрьәт итмәгән, астыртын әрепләшеп-үчләшеп гомерен уздыра. Ул бүген дә шул гадәтен ташламый.

Р. Хәмид геройларына хас кырыслык мондагы геройларда да чагыла. Сөйләшүләр каты, мөнәсәбәтләр еш кына киеренке, кайвакытта кеше хакын хаклап тору юк дәрәҗәсендә. Асылда, тормыштагы уңай якларны гәүдәләндергән, дөреслек өчен үзенчә көрәшүче Искәндәр дә шул ук рухта сурәтләнә. Бу аның килен булачак яраткан кешесен әти-әнисенә ничек тәкъдим итүендә үк чагыла. Виленаның кеше хатыны булуын да, балалары булачагын да (үзләре әле өйләнешмәгәннәр) ул турыдан бәреп әйтә. Хәтта, хатынының исеме нәрсә аңлатканын әйткәндә дә, шул рухына туры кала, берникадәр мыскыллы катылык белән сөйли.

Башка персонажлар мөнәсәбәтендә дә шулай. Даяның үзенә гашыйк Сатайдан көлүе дисеңме, Дулатны алдарга маташуымы... Көбра белән булачак килене арасындагы мөнәсәбәтнең беренче адымнардан ук шул эзгә төшүен, Чуракай белән Күгәй мөнәсәбәтләрен әйтеп тә торасы түгел.

Ләкин мондый персонажлар һәм мөнәсәбәтләр артында шулай да әшәкелек ятмый. Ахыр чиктә күпчелек геройлар белән кешелеклелек, яхшыга омтылу, тормыш кыенлыкларын үзгәртү омтылышы идарә итә. Тик боларның чагылышы гына шулай кырыс. Күгәйнең тирәнгә яшерелгән миһербанлылыгы, тыйнаклыгы, Дулатның гаделлеге, аның рухи газапларын китереп чыгарган шәхси тормышыннан өстен булырга тырышуы, Искәндәрнең авыл хуҗалыгын дөрес эзгә төшерү өчен эш башлавы, Даяның мәдәният йорты директоры булып эшләргә белеме дә, теләге дә булмаган парторг хатынына каршы үзенчә көрәшергә омтылуы — болар барысы да кешеләр өчен, авылдашлар өчен, гаделлек хакимлек итсен өчен бара. Димәк, олы кешелек кыйммәтләре өчен көрәшне чагылдыра.

Кыскасы, Р. Хәмид әсәрләре хәзерге катлаулы тормыш шартларында милли драматургиянең үз урынын табарга, иң өлгергән мәсьәләләрне чагылдырырга омтылышын күрсәтә.

Сәхнә әдәбиятында бара торган идея һәм художество эзләнүләре бүгенге кешенең кабатланмас образын эре итеп, җанлы әдәби тип итеп сурәтләүне максат итә. Мондый кешенең халык һәм ил язмышын, туган телебез һәм динебез язмышын үз җилкәсенә алуын күрсәтүдә драматурглар яңа казанышларга омтыла.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Җиде баҗа» драмасының эчтәлеген сөйләү өчен, өйдә план-проспект төзеп килегез.

2. Драмадагы образлар системасын төркемнәргә бүлеп карагыз. Бу бүленештә сез нинди сыйфат-үзенчәлекләргә беренчелекне бирер идегез?

3. Күгәй образын шәрехләгез, бәя бирегез.

4. Дая нинди образ? Ул сезгә ошыймы? Бу кызның кайсы яклары сезгә үрнәк булырлык? Нинди сыйфатларын кире кагасыз?

5. Дулат — Вилена — Искәндәр мәсьәләсенең хәл ителеше сезгә ошадымы? Тормышчанмы?

6. «Җиде баҗа» әсәрен драманың нинди төренә кертер идегез (психологик драма, иҗтимагый драма, тарихи драма, музыкаль драма һ.б.)?

7. Ризван Хәмид драматургиясенә бәя бирегез.

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Татар балалар әдәбиятының барлыкка килүе турында сүз барганда, шуны әйтергә кирәк: ул тумышы белән, һичшиксез, фольклор әсәрләренә барып тоташа. Бишек җырлары, бала уйнату, тәпи йөрергә өйрәтү, йокыдан сыйпап уяту һәм башка тәрбияви гамәлләрдә кулланылган җыр-такмаклар нәниләргә бик көчле тәэсир ясаган. Әлеге такмаклар ярдәмендә сабый күңеленә үзен иҗатучыларның йөрәк җылысы килеп җиткән. Алар шул такмакларны назга төреп җырлаучы әни-әти, әби-бабай, апа һәм абыйларның тавышын, йөзен, җылы күз карашын тойганнар, үз иткәннәр. Милли фольклор, шул рәвешле, баланың рухи дөньясының нигезенә салынган иң затлы катламны тәшкил иткән.

Сүз дә юк, бу такмак-җырларны, аларның төрледән-төрле вариантларын иң әүвәл кемнәрдер уйлап чыгарган. Ләкин күңелләре балага карата мәхәббәт белән тулы ул затлар (бигрәк тә әниләр) авторлыкка вәгъдә кылуны башларына да китермәгәннәр. Бу әсәрләр туганнан туганга, буыннан буынга күчеп, бер милләт кешеләренә таралып киткән. Үсә төшкәч, балаларның тапкырлыгын сынау һәм үстерү өчен, табышмаклар әйтү, аларның төрле уеннар вакытында такмаклар куллануылары шулай ук яшь буынның күңеленә шигъри орлыклар салган. Тора-бара мәкаль-әйтемнәрнең сүз байлыгын үстерүе, аның аһәңлелегенә, төгәллегенә, тапкырлыгына, образлылыгына өстәмә көч бирүче булып әверелүе сөйләмнең иҗадилыгын тәэмин иткән. Менә ни өчен баланың гаиләдә ана теле, милли моңнары ярдәмендә тәрбияләнүе хәлиткеч әһәмияткә ия. Биредә нигезе салынган күркәм тәрбия балалар бакчасында, мәктәптә табигый рәвештә дәвам иттерелергә тиеш.

Балалар өчен язма әдәбиятның башланып китүе дә фольклор белән бәйле. Әйтик, без татар сүз сәнгатенә хас булган бәет жанрын фольклор белән язма әдәбият арасында торган күренеш дип карыйбыз. Чөнки бәетләрнең яшәве, таралуы,

шигъри шомаруы аларның язуда теркәлүе белән турыдан-туры бәйләнгән. Мең еллардан бирле рун, гарәп хәрефле язулар кулланган халкыбыз күңелдә туган шигъри үрнәкләрне дә язмача теркәп куйган. «Сак-Сок бәете» кебек әсәрләрнең балалар күңелен тәрбияләүдә әһәмияте бик зур булган. Бер уйлаганда, балалар әдәбияты әсәрләре булудан шактый ерак торган «Бәдәвам», «Кисекбаш» китаплары да кечкенәләр тарафыннан кызыксыну белән тыңланган һәм укылган. Г. Тукай, мәсәлән, сигез яшенә кадәр үк инде әлеге әсәрләр белән мавыгып танышканлыгын искә ала. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Мөхәммәдьярның «Төхфәи Мәрдән», «Нуры содур», Ә. У.-Кормашиның «Таһир—Зөһрә» һәм башка авторларның әсәрләре хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Алардагы тормыш вакыйгалары, әкияти хәл-әхвәлләр, кеше образларындагы бик үк гадәти булмаган сыйфатлар үзләренә җәлеп итүне нык көчәйткәннәр.

Әлбәттә, балалар өчен махсус әдәби әсәрләр кирәклеге торган саен ныграк сиздерә барган. Моны фәннең, иҗтимагый аңның төрле тармаклары үсешенең алга китүе, яшьләрдә аң-белемгә омтылышның көчәюе, дөньяны танып белүгә булган теләкнең үсүе китереп чыгарган. Шулай да моңа төп сәбәп һәм җирлек — XIX йөз ахыры һәм XX гасыр башында татар әдәбиятының яңа үсеш дәрәҗәсенә күтәрелүе. Борынгыдан килгән шигъриятебезнең колачы, офыгы киңәя, яңа шәкел, өслүб, жанр күренешләренә байый, темалары гаять төрләнә. Иң мөһиме, әдәбият көндәлек тормыш хәлләренә, иҗтимагый вакыйгаларга даими игътибар итә башлый. Ягъни авторлар сурәтләнәсе тормыш материалларын билгесез үткән заманнардан түгел, бәлки бүгенге көннең үзеннән алалар. Бу исә сүз сәнгатенә игътибарны җәлеп итә, аның укучылары тагын да күбәюгә китерә. Болар беренче нәүбәттә, һичсүзсез, балалар әдәбиятына кагыла.

Шушы ихтыяҗны истә тотып, Ф. Әмирхан һәм башка милли зыялыларыбыз тырышлыгы белән 1907 елның гыйнвар — март айларында «Тәрбиятел-этфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле журнал нәшер ителә башлый. Дөрес, ул озын гомерле булмый, нибары биш саны чыгып кала. Әлеге басманың кирәклеген бөтен күңеле белән тойган Г. Тукай, журнал чыгудан туктатылгач, «Югалган ата» дигән ачынулы шигырь яза. 1913—1915 елларда Казанда Ф. Агиев мөхәррирлегендә чыккан «Ак юл» журналында ул инде хезмәттәшлек итә алмый, гомере өзелә.

Габдулла Тукай XX гасыр башында татар балалар әдәбиятын яңа югарылыкка күтәрде. Аның җитмешкә якын әсәре балаларга багышланган. Ул каләм әһеленнән балаларның ни көткәнен яхшы белә, аларның күңел дөньясын тирәнтен аңлый. Бу аның әсәрләренең бала күңеленә барып җитүен тизләтә. «Эш беткәч уйнарга ярый», «Бала белән Күбәләк», «Эшкә өндәү», «Сабыйга», «Туган тел» шигырьләре, «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Су анасы» кебек әкиятләре, алардагы шигъри юллар, строфалар, аерым өзекләр туган телдә тәрбия һәм белем алган һәр татар баласының күңел байлыгына әверелә, гомер буена аларның фикерләү сәләтенә уңай тәэсир ясый.

Г. Тукайдан алдарак һәм аның белән бер чорда иҗат иткән М. Гафури, Дәрдемәнд (Закир Рәмиев), Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, Н. Думави, М. Укмаси, З. Ярмәки, З. Бәшири, С. Сүнчәләй, К. Әмири, Ш. Бабич, Г. Рахманколый һәм башкалар да татар балалар әдәбиятын үстерүгә үз өлешләрен кертгеләр. Аларның һәрберсе диярлек балалар әдәбиятына нинди дә булса яңалык өстәде. Әйтик, Дәрдемәнд табигать күренешләрен сүз ярдәмендә сурәтләүгә, шуның белән кече яшьтәге укучыларның күзәтү сәләтен үстерүгә игътибар итте. Шулай ук кечкенә хикәяләр иҗат итүдә сәнгатьчә югарылыкка ирешә алды. «Бәллү» шигырендә иҗатының фольклорга да таянуы күренде.

М. Гафури исә мәсәл жанрының яңа мөмкинлекләрен тапты. «Гафуриның иҗади тырышлыгы аркасында татар әдәбиятында шигъри мәсәл тулы хокуклы жанр дәрәҗәсенә күтәрелде, татар әдәбиятының үз казанышы булып китте»,— дип язды Г. Халит. «Маймун белән күзлекләр», «Ике чебен», «Тавык белән үрдәк», «Сарыкны кем ашаган?» һәм башка мәсәлләр тирән мәгънәле булулары белән олыларга гына түгел, балаларга да фикер азыгы бирә. Шуны ук аның байтак шигырьләре хакында да әйтергә мөмкин.

1917 елдан соң исә балалар өчен әдәби әсәрләр иҗат итүчеләр арасында без Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Б. Рәхмәт, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, А. Алиш, Х. Туфан, Ә. Бикчәнтәева, Җ. Тәрҗеманов, Г. Афзал, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Җ. Дәрзаманов, Р. Мингалимов, Л. Лерон һәм башка күп кенә каләм әһелләрен күрәбез. Бу иҗади шәхесләрнең балалар әдәбиятын үстерүгә керткән өлешләре төрле-төрле, бу исә

аны бай һәм күп бизәкле итә. Әйтик, Һ. Такташ исемен телгә алуга, шунда ук аның «Ләйлә» исемле шигыре аңда һәм телдә кабатлана башлый.

Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак карга киенгән;
Ләйлә, чанасын өстерәп,
Чыгып китте өеннән...

«Тәүфыйклы песи» шигыре балалар өчен бервакытта да ялыктырмаячак һәм искермәячәк әсәр булып әдәбиятыбыз хәзинәсендә урын алды. Х. Туфанның «Юкмыш бабай малае» әкияте дә балалар тарафыннан яратып укыла. Шунысы үзенчәлекле: Х. Туфан зурлар өчен язган кайбер әсәрләренең төп герое итеп балаларны сурәтләде. «Гөлләр инде яфрак яралар», «Тәрәзәсе гөлле өйнеке» әсәрләре турында шулай әйтергә була.

М. Җәлил «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларын чыгаруы белән генә дә балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертте. «Маэмай», «Сәгать», «Чаңгы шуганда», «Карак песи» шигырьләре үз вакытында киң билгеле иде. М. Җәлилнең хәтта «Моабит дәфтәрләре»ндә дә балалар өчен язылган «Ишек төбендә» дигән шигырь бар. Шаян табигатьле малайның шуклыгы елмаерга мәҗбүр итә.

Ф. Кәримнең шулай ук бу өлкәдә үз урыны бар. Ул — 1933—1937 елларда Татарстан дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе җитәкчесе. Димәк, ул да яшь буыннар өчен сүз сәнгатен үстерүне оештыручыларның берсе була. Шул ук вакытта үзе дә әсәрләр яза. «Күбәләк», «Яз җитә» шигырьләре, «Гармунчы аю белән Җырчы маймыл» әкияте зур уңыш казана. Сугыш вакытында исә «Пионерка Гөлчәчәккә хат» поэмасы иҗат ителде.

Н. Исәнбәтнең балалар әдәбиятын үстерүгә керткән өлешенең мул булуын аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Беренчедән, ул, балалар фольклорын җыеп, аерым китаплар итеп чыгарды. Икенчедән, үзе иҗат иткән әсәрләре белән кечкенәләр күңеленә үтеп керә алды. «Мырауҗан батыр» әкияте — шуларның иң билгелеләреннән. Ул шигырьләрендә һәм мәсәлләрендә дә балалар фольклоры белән аваздашлыгы ягыннан аерылып тора. «Елан патшасы» әкияте, «Мияубикә төше», «Тычканнар җыелышы» мәсәле һәм башка әсәрләрен берләштерүче нигез — фольклор. Аларның төрле жанрларга каравына игътибар ителә. С. Хәким юкка гына аны «халыкның бөтен рухи

байлыгын үзендә туплаган шагыйрь» димәде. Ә. Фәйзи исә «Бал корты» шигыре белән данлыклы.

Чәй эчәбез бал белән,
Бала-чагалар белән.
Бала-чага алты җан:
Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,
Зәйнәп белән Галия,
Иң соңгысы — Асия.

Ә. Исхакның «Минем әтәчем», «Беренче рәхмәт», «Нәфисә» кебек төзек сюжетка корылган шигырьләрендә дә укучыларга рухи азык булырлык яклар бик үтемле итеп бирелгән. Ул бигрәк тә иң кече яшьтәгеләр өчен күп язды.

Ә. Бикчәнтәева шигырьләре берничә буын баланы әдәплелеккә, әхлаклылыкка, дөньяны танып белергә, кешеләр арасында дөрес мөнәсәбәтләр урнаштырырга өйрәтте, аларда кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләде. «Дәү әнием» шигыре — аларның иң талантлы язылганнарыннан берсе.

Өйдә аны һәммәбез
Яратабыз, сөябез.
Син бик кадерле безгә,
Озак яшә, диябез.

Балаларның яраткан шагыйре булып әверелү — иҗат кешесе өчен зур бәхет. Бари Рәхмәт тә — бәхетле шагыйрь. Ул меңләгән укучыларының рәхмәтен тоеп яшәде һәм алар өчен иҗат итте. Ник дигәндә, ул балалар белән алар булып сөйләшә белә, шуңа күрә автор белән аның әсәрен укучы арасында нинди дә булса киртә-фәлән калмый, ягъни Б. Рәхмәт — балалар өчен үз кеше.

Саф һавага чыгып,
Таудан чана шуып,
Кышның салкыннарын
Җибәрәбез куып,—

яки:

Якшәмбе көн бик күңелле,
Ул бәйрәм көн шикелле!
Кичкә хәтле ял итәбез,
Арып бетәм ул көнне,—

кебек отышлы табышлар аның иҗатында бихисап. Шагыйрь, чана шуганда, кышкы салкын көн дә җылынып киткәндәй тоела дигән фикерне балаларга хас тапкырлык һәм җорлык

белән әйтә. Балаларның күңел дөньясына оптимистлык хас дигән нәтиҗә Б. Рәхмәт шигырьләрендә аеруча ачык чагыла. «Сара уңган кыз», «Сара — врач», «Кыш һәм Кеше» шигырьләре ярдәмендә ул кешеләрдәге уңай сыйфатларны зурласа, «Ялкау, Иренчәк һәм Кире турында әкият», «Шундый ялкау ул» әсәрләре исә тискәре холыклыларга карата өнәмәүчән мөнәсәбәт тәрбияли. Әмма шагыйрь турыдан-туры акыл өйрәтү юлыннан китми, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген рәсемләп һәм вакыйгалар барышында күрсәтеп бирә. Бала өчен үзедәй кечкенәләрнең сүзләре, эшләре, алар белән булган эш-хәлләр кызык. Ул аларны үзе белән чагыштырып карый. Менә ни өчен Б. Рәхмәт һәм башка талантлы шагыйрьләр балаларның күмәк сыйфатларын һәм психологияләрен түгел, бәлки аерым бер балага хас үзенчәлекләрне тасвирлауга өстенлек бирәләр. Әнә шулай балалар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләре барлыкка килүен тәэмин итәләр. Бу буын шагыйрьләр, әдәбиятның әлеге өлкәсендә тагын да зуррак үсеш тәэмин итү, татар балалар әдәбиятының халыкара мәйданга танылырлык булып җитлегүе өчен, ныклы җирлек әзерләделәр. Хәзерге балалар әдәбиятының әнә шундый ныклы үсеше, барыннан да элек, Шәүкәт Галиев һәм Роберт Миңнуллин иҗатлары белән бәйле.

Сораулар һәм биремнәр

1. Балалар әдәбияты барлыкка килүдә халык авыз иҗатының урыны нидән гыйбарәт?

2. Фольклор әсәрләренең балаларны тәрбияләүдәге әһәмияте турында сөйләгез.

3. Балалар әдәбияты тууга китергән сәбәпләрне атагыз.

4. Урта гасырлар язма әдәби әсәрләре ни өчен балаларга да рухи азык булды икән? IX сыйныфта өйрәнгән әсәрләргә таянып, шуны ачыклагыз.

5. Балалар өчен хәзер иҗат ителгән әсәрләр белән үткән дәверләрдән килгәннәре арасында нинди аермалыклар бар?

6. Балалар өчен чыгарылган журналлар турында сөйләгез. Бүгенге көн балалары нинди газета-журналлар алдыра алалар?



Шәүкәт Галиев
(1928—2011)

Шагыйрьнең чын исеме — Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин. Ул үзенә псевдонимны Шәүкәт Галиев дип ала. Хәзерге Апас районы Олы Бакырчы авылында 1928 елның 20 ноябрендә туган. Үсмерлек вакыты сугыш елларына туры килә. Ундүрт-унбиш яшьлек үсмер җир сукалау, тырмалау, авыр-авыр капчыклар төяп, дәүләткә ашлык илтү кебек эшләр башкара. Ләкин ыңгырашмый, дошманны җиңү хакына тырыша. Җиде сыйныф белеме булган егетне исәп-хисап эшенә куялар. Ул анда да сынатмый. Ләкин Шәүкәт кечкенәдән үк табигате белән гади малай булмый, күңеле җырга, шигырьгә тартыла. Укучыларның җыр дәфтәре булу — гадәти күренеш. Бишенче сыйныфта укыганда, андый дәфтәрне Шәүкәт тә башлый, тик ул аны ташлый гына алмый, берсе артыннан икенчесен ишеткән, күргән җыр-шигырь белән тутыра бара. Тора-бара үз күңелендә дә шигъри юллар туа башлый. Алар теге дәфтәргә теркәлә баралар. Егерме яшь тулган көннәрдә ул аларның кайберләрен Кайбыч районында чыга торган «Колхоз бригадасы» газетасында бастыра. Шуннан рухланып киткән егет язмаларын Казан басмаларына да җибәрә. Ниһаять, 1949 елда аны район газетасына эшкә күчерәләр, башта җаваплы сәркатип, соңыннан мөхәррир вазифасын башкара. Аның сәләтен тиешенчә бәялиләр: 1953 елда Казанга чакыралар, «Чаян» журналына әдәби хезмәткәр итеп алалар.

Казанда яшәп иҗат итүнең уңай нәтиҗәләре тиз күренә. Бер елдан, ягъни 1954 елда, биредә аның «Яңа көйләр» исемле беренче китабы чыга. Байтак шигырьләр арасыннан бары тик унҗидесен китапның махсус мөхәррире С. Хәким сайлап ала.

Ә. Фәйзи әлеге китапка беренче булып бәяләмә яза. «Аларда,— ди ул,— шигырь өчен иң кирәк ике элемент бар: уй һәм тойгы.

Әле ярый аерылу бар,
Югыйсә шундый шатлыклы
Очрашу булмас иде!

Яхшы әйтелгән! Бу афоризм дәрәҗәсендә кыска итеп әйтелгән уй никадәр юмор катыш нечкә лирика белән җылытылган, җанландырылган! Монда уй һәм тойгы бердәмлеге бар». Олы шагыйрьнең мондый бәясенә лаек булу өчен, чыннан да, талант чаткыларының өметле булуы кирәк. Зыя Мансур да яшь каләм иясенең уңышларына сөенүен белдереп язып чыга. Шуннан соң аның «Кичке утлар», «Әткәйгә хат», «Сиңа әйтер сүзем бар» һәм башка дистәләгән китаплары басылып чыга. Әнә шулай ул, 60 нчы еллардан башлап, хәзерге шигъриятнең иң күп һәм уңышлы иҗат итүче шагыйрьләренең берсе булып әверелде. 1958 елда Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

Ш. Галиев — халык күңелендә урын алган байтак кына җырлар авторы да. Менә аларның кайберләре генә: «Раушанийм, бәгърем», «Утыр әле яннарыма», «Ник яңара сагышлар», «Тамчылар тамар чаклар», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Шомырт чәчәкләре ак кына», «Сөенечкә дисәм» һәм башка бик күпләр.

Көчле лирик булу белән бергә, Ш. Галиевнең таланты юмор һәм сатира өлкәсендә дә ачылды. Аның лирикадагы осталыгын Ә. Фәйзи уй һәм тойгы, хис берлегендә күргәнлеген әйткән иде. Юмор һәм сатира өлкәсендә иҗат итүче каләм әһеленә исә кыюлык, үткен акыл, тормышны һәм яшәешне яхшырту өчен көчле теләк, олы фикерләрне җыйнак кына итеп әйтә белү, нык күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар кирәк. Кешенең юмор хисе булу — акыллылыгы, күңел киңлеге билгесе. Тормышның үзендәге көлү төрле максатларда булырга мөмкин. Әдәбиятта исә көлү бары тик кешелекле максатларда гына булырга тиеш, ул, тискәре күренешләрне тәнкыйть итеп, җәмгыятьне савыктыру, яхшыртуга хезмәт итүне күздә тотсын. Ш. Галиев — көлүгә бик җитди эш итеп караучы шагыйрь.

Тырышыйк, зур өлеш кертик
Без көлү өлкәсенә.
Тик үзебез генә калмыйк,
Әй, адәм көлкесенә...
Көлегез, көлегез,
Файдасы күп, белегез!

Тормыш тәҗрибәсе өстенә 1959—1961 елларда Югары әдәби курсларда уку (Мәскәү) шагыйрьнең иҗат офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрә. 1962 елда чыккан «Камырша» исемле шигырьләр китабы Ш. Галиевнең балалар өчен язылган әсәрләренең беренче тупланмасы булды. Шуннан соң ул кечкенә укучыларына егермедән артык китап бүләк итте. «Шәвәли», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Кызык», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән», «С папой в кабине» дигән китаплары өчен 1972 елда Ш. Галиев Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1982 елда исә «Физзарядка ясый куян» китабы өчен Х.-К. Андерсен исемендәге халыкара Мактау дипломын алды. Бу исә татар шагыйренең талантын халыкара мәйданда тану һәм югары бәяләү иде. 1995 елның 6 июнендә исә аңа «Татарстан Республикасының халык шагыйре» исеме бирелде. Ул «Мактау Билгесе» ордены белән бүләкләнде. 1996 елдан А. Алиш исемендәге бүләк лауреаты.

Олылар өчен язганда, шагыйрьгә зур талант кирәк булса, балалар өчен иҗат итүче кеше ике тапкыр олы осталыкка ия булырга тиеш, диләр. Моның шулай икәнлеге Шәүкәт Галиев иҗаты белән дә раслана. Беренче карашка кеше үз иҗатының башында ук балалар өчен яза башларга тиеш иде кебек. Ләкин Г. Тукай «зурлар» әсәрләре язуда байтак тәҗрибә туплагач кына балалар өчен каләм тибрәтә башлаган кебек, бу юлны Б. Рәхмәт, З. Туфайлова һәм без сүз алып бара торган Ш. Галиев тә үтте. «Камырша» җыентыгында дөнья күргән әсәрләр иҗат ителгәнче, Ш. Галиев бик күп шигырьләр һәм «Әткәйгә хат» поэмасы авторы иде инде. Чөнки баланы алынган мәүзугның отышлы булуы, әсәрнең ниндидер гадәти булмаган оештырылышы, кызыклы тормыш материалы белән генә мавыктырып булмый. Баланың аңына да барып җитәрлек, аны уйландырырлык, тормышның бер ягын ул таң калырлык, сокланырлык, гаҗәпләнерлек, елмаерга мәҗбүр итәрлек итеп сөйләп бирү өчен, аерым сәләт һәм талант кирәк. Әмма һәр балалар язучысының сәләте, сурәтләү үзенчәлеге аерылып торырга тиеш. Шулай булмаганда, бертөрлелек барлыкка килер иде.

Ш. Галиевнең иң яраткан алымнарыннан берсе — әйтәсе фикерен баланың дөнья, яшәеш серләрен әле аңлап бетермәвенә, кечкенә нәрсә хакында да үзенчә, көтелмәгән хикмәтле нәтиҗә чыгаруына нигезләнүе. Мондый «сәер» сүз әйтүче бала укучыга бик сөйкемле булып тоела.

Безнең сыер көн дә кырдан
Чүлмәк-чүлмәк сөт ташый,
Ул бит яшел үлән ашый,
Сөтне ничек ак ясый?

Яки:

Ә салкын боз торган саен эри,
Кыз шуңа тыз-быз чабып йөри;
— Мин аны өйгә алып керәм, ди,
Мич алдына куеп киптерәм, ди,
Җып-җылы иттерәм, ди.

Яки:

Мин үскәч һәйкәл булам,
Батыр булам,
Муса Җәлил янында
Басып торам!

Бала дөньяны күрү, ишетү, сиземләү ярдәмендә өйрәнә. Шулай да танып белүдә сүз, сөйләшү аның өчен аерым әһәмиятле. Аның фикерләве, кешеләр, әйберләр, табигать күренешләре арасында бәйләнешләр урнаштыруы сүз ярдәмендә бара, үсә, камилләшә. Балалар үзләре дә, сүзләрнең аерым үзенчәлекләрен файдаланып, төрле уеннар, сынамышлар уйлап табарга маһир булалар. Аларны башкарганда әйтелә торган такмаклар, кара-каршы әйтешүләр авазларның охшаш яңгырашына яки омонимнарга нигезләнәләр. Мәсәлән:

Тауга мендем, тары таптым,
Аны бирдем тавыкка.
Тавык миңа йомырка салды,
Аны салдым казанга,
Богыр-богыр кайнарга.
Үзем киттем байларга,
Алтын йөзек сайларга.
Ак чук, кара чук,
Монда торма, бар чык!

Балалар такмазаларны тәрбия максатларында файдаланалар. Берәү үзе дә рәтләп белмәгән нәрсә турында «дыр», «бугай»ларны кушып сөйли башлый, аны рифмалы кисәтү белән туктаталар, сөйләгәннәренә бәя бирәләр.

«Дыр» белән «Бугай»
Көрәшкәннәр, ди, бугай.
«Бугай» җиңгән, ди, бугай,
«Бугай»га бүләк биргәннәр, ди, бугай,
«Бугай» мактанган, ди, бугай.

Мондый алымны зур осталык белән Ш. Галиев тә куллана. Гадәттә, андый әсәрләр табышмак сыман булалар.

Без безсез яшәмибез,
Безсез без эшләмибез —
Итекче без өчебез,
Өчебезгә ике без.

(«Безнең безләр»)

Биредә «без» сүзләренең кайсылары кешеләрне, кайсылары эш коралын белдерүләрен бала аерып алырга тиеш була.

Ш. Галиев — сүз уйнатуларның остасы. Бигрәк тә омонимнарны төрле мәгънәләре белән төрләндерүдә бик җиңел эш итә.

— Көтүче сумкасы таптым
Һәм өйгә алып кайттым.
— Көтүчегә бирмәдеңме?
— Юк, сыерга ашаттым!

(«Табышмаклы табыш»)

Сүзләрнең мәгънәләренә игътибар юнәлтү яки аларны мәгънәле кисәкләргә таркатып карау шулай ук кызыклы табышларга юлыктыра.

Шәвәли әйтә:
— Ялгыш сөйлиләр
«Бала-чага» дип,
Бала чакмый бит!
Әйтергә кирәк:
«Бала чаба» дип.

(«Бала чаба»)

Бабай тикмәгә
Таянмый таяк.
«Таяк» эчендә
Бар икән «аяк».

(«Таяк»)

Бигрәк куркыныч
Ул елан чагу —
Күренеп тора:
Эчендә агу.

(«Чагу»)

Халат кигән апалар
Сарык йонын кыркалар.
Мөдир әйтә:

— Ачтык әле
Парикмахерская.
Төзәтеп куя Шәвәли:
— Сарыкмахерская.
(«Сарыкмахерская»)

Шәвәли дигәннән, бу җор сүзле шук малай образы аның йөзгә якын әсәрендә урын алган. Әлеге исемне ишетүгә, балаларның авызы ерыла башлый. Аның белән тагын нинди әкәмәт хәл булды икән, диешәләр. Һәм аларның көткәне аклана да. Беренче карашка Шәвәли аерым бер образ кебек. Ләкин Ш. Галиев аңарда барлык шаян табигатьле малайларның уртак, ягъни типик образын бирә. Аның «мин» исеменнән сүз алып бара торган байтак әсәрләрен дә Шәвәли белән булган маҗаралар дип карарга була. Димәк, алар шагыйрьнең 1965 елда чыгарган «Шәвәли» китабына кергән шаян шигырьләре белән генә чикләнми. Шул рәвешле, автор әлеге образны тулыландыру юнәлешендә утыз елдан артык эшли, Шәвәлинең хисләре, уйлары шагыйрьнең үзе белән бергә үзгәрә, камилләшә, «салмаклана», хис-кичерешләр тирәнлегенә таба хәрәкәт итә.

Шәвәли күлгә бара,
Шикәрен суга сала:
— Ширбәтле су эчсеннәр,
Балыклар тиз үссеннәр!
(«Юмартлык»)

Усал эт күргәч,
Ул болай диде:
— Мин тәмле түгел,
Ашама мине!..
(«Шәвәли хәйләсе»)

— Курыкмагыз, таптатмыйм, ди,
Өйрәнеп киләм инде —
Әти күтәреп утыртса,
Кычкырта беләм инде!
(«Шәвәли һәм мотоцикл»)

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без «Туган тел»дән туганнар,
Без — Тукай оныклары!
(«Без — Тукай оныклары»)

Ш. Галиев иҗаты, шул рәвешле, татар балалар әдәбияты үсешенең аерым бер чорын, җимешле унъеллыкларын тәшкил итә. Соңгы берничә дистә еллар дәвамында ул — балалар әдәбиятын үстерүгә иң зур өлеш керткән язучыларыбызның берсе. «Котбетдин мәргән» («Мәзәкле маҗаралар»), «Хәлим, Сәлим, Мәсәлим», «Филгә итек тектеләр», «Түбәтәйле кыярлар», «Витаминлы хәрефләр» һәм башка бик күп әсәрләр шул турыда сөйли.

Шунысы әһәмиятле: аның шигырьләре композиторларны балалар өчен җырлар язарга да рухландырды. Ш. Галиев шигырьләренә А. Ключарёв «Бикмулла», М. Шәмсетдинова «Күбәләк», «Колын бара каладан», «Үткенлек», «Кыңгыраулы бозау», Илдус Якупов «Бииләр итек, читекләр», «Батыр куян», Анатолий Луппов «Кояш нинди?», Әхмәт Хәйретдинов «Суда шуабыз» дигән матур-матур көйләр яздылар. «Ш. Галиев шигырьләренең шундый популярлык казануының сере,— дип язды Н. Юзиев,— шагыйрьнең балалар дөньясын ачуга бәйле кабатланмас шигъри талант көчендә».

Сораулар һәм биремнәр

1. Ш. Галиевнең шигъри таланты ачылуының аерым баскычларын билгеләгез.

2. Ә. Фәйзи яшь каләмдәше Ш. Галиевнең шагыйрь буларак үзенчәлеген нидә күрә?

3. Юмор-сатира әсәрләре иҗат итүче нинди сыйфатларга ия булырга тиеш дип саныйсыз?

4. Көлә белеп көлүнең әһәмияте нидә икән?

5. Балалар шагыйре буларак, Ш. Галиевнең иҗатта яратып һәм уңышлы кулланган алымнары нидән гыйбарәт?

6. Шагыйрь язган әсәрләрнең балалар фольклоры белән мөнәсәбәтен күрсәтегез.

7. Кем ул Х.-К. Андерсен? Аның кайсы әсәрләрен укыдыгыз? Бу шәхеснең Ш. Галиев белән нинди мөнәсәбәте бар?

Роберт Миңнуллин

_(1948)_



Без Ш. Галиев тарафыннан балалар өчен язылган әсәрләрнең юмор белән өртелгәнлекләрен күрдек. Аларны укыганда, рәсемнәрендәгечә шат елмайган автор шәйләнүе табигый. Чөнки Ш. Галиев көлә икән, тыелгысыз, рәхәтләнеп, кинәнеп көлә, елмая икән, гадилеген бөркеп, иркенләп елмая.

Ә аның яшьрәк каләмдәше Роберт Миңнуллин исә,— шәхес буларак, чак кына башкачарак кеше. Ул — шулай ук мөлаем зат, әмма шул ук вакытта аңарда эчке бер тирән серлелек өстенлек ала кебек. Бу хәл аның әсәрләрендә ачык чагыла. Аның иҗаты турында сүз алып барганда, бигрәк тә 70 нче елларда, Р. Миңнуллин, нигездә, зурлар шагыйреме, әллә балаларныкымы дигән сораулар бирелүе очраклы түгел иде. Хәзер инде ул үзенең иҗади йөзен ачык билгеләде. Роберт Миңнуллин, — барыннан да элек, әлбәттә, балалар шагыйре. Әйе, ул олылар шигърияте дә зур өлеш кертте. Моның шулай икәнлеген аның «Талбишек» исемле шигырьләр җыентыгы (1995) аеруча дәлилле раслады. Көндәлек матбугат битләрендә басылып килүче әсәрләре дә шуны күрсәтә.

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Балкый ул әллә каян.
Авасың бит, Сөембикә —
Әйдә, үземә таян!

Сөембикә — татар халкы дәүләтчелегенең бер билгесе (символы), шуңа күрә бу зат безнең һәрберебез өчен кадер-

ле. Аның исеме белән бәйле манара да һәммәбез тарафыннан изге корылма булып карала. Аның бераз авыш булуы да күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Бу гүзәл бинаның авып төшүе (мәңге басып тора күрсен!) халкыбыз өчен бер зур фаҗига булыр иде. Шагыйрь әнә шул манараның янтайган ягына үз җилкәсен куярга тели. Бу — халкыбызның язмышын кайгыртуга алыну дигән мәгънәне аңлата. Чын шагыйрьләр һәрвакыт халык гамен үзләренеке итеп кабул кылалар. Бу борын-борыннан шулай килгән.

Шагыйрьнең сүз бара торган «Казан. Кремль. Ак диварлар...» шигырендә әйтелгәннәрне, сүз дә юк, өлкән укучылар тирәнрәк кабул итәләр. Шул ук вакытта аларга балаларның да битараф булмаячагы көн кебек ачык.

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Татарның баш дивары.
Син — татарның йөзек кашы...
Син — таш кына нибары...—

дип тәмамланган бу шигырь тирән уйларга төшерә. Әйтергә кирәк, Р. Миңнуллин иҗаты бербөтен. Ул, олыларга язганда, балаларны да күздә тота, кечкенәләр өчен иҗат иткәндә, зурларны уйландырырлык һәм елмайтырлык сүзләр таба ала. Чөнки ул балалар өчен дә җитди итеп яза белә. Ләкин шул җитдилекнең төбендә дөньяны беркатлы, сабыйларча кабул итү ята. Бала өчен ул әйткәннәр, ихтимал, борчылу өчен нигез дә буладыр, зурларда исә алар бөтенләй көтелмәгәнчә әйтелүләре белән елмаю барлыкка китерәләр. Әйтик, бала язны иң беренче нәүбәттә гөрләвекләр белән бәйли. Кар эреп, челтерәп, гөрләвекләр акмаса, яз буламыни? Ә менә шәһәр урамындагы карларны абыйлар, машиналарга төяп, каядыр алып китәләр. Бу хәл бала күңелендә каршылыклы уйлар туугa сәбәп була.

Болай булгач, гөрләвеккә
Карлар да калмас инде.
Гөрләвекләр гөрләмәгәч,
Яз була алмас инде.

Бала хыялының чиге юк. Олылардан аермалы буларак, ул үзе хыялланганга ихлас инана, аларны чын итеп кабул кыла. Кышның салкынлыгы аны туйдыра икән, ул яз күренешләрен рәсем итеп ясый башлый.

Ясадым мин инеш тә,
Ясадым талларын да.
Каз бәбкәләре йөргән
Зур ишегалларын да...

Әнә шулай салкын кыш көнендә ул альбомында яз мохите тудыра. Ул арада чын яз да килеп җиткән икән. Чөнки ел фасылларының алышынуы кемнең дә булса теләге белән бәйләнмәгән, аның үз кануннары бар. Шагыйрь абыйсы ярдәмендә кечкенә укучы әнә шуңа төшенә.

Карасам тәрәзәгә,
Малайлар көлешкәнгә,
Исләрем китте — безгә
Яз килгән дөрестән дә!

(«Яз килгән бит!»)

Үзе ясаган җанвар һәм киек рәсемнәренең бала хыялында терелүе, яшәп китүе Р. Миңнуллин шигырьләрендә тагын да очрый. «Йөгәнсез чаптар» әсәрендә ат, дәфтәр битеннән төшеп, болынга качкан. Бала йөгән кидерелмәгән шушы чаптарның болынны бетереп чабып йөрүенә куана. Аңа чаптарның ирекгә йөрүе күңел рәхәтлеге бирә.

Ярый әле кидертергә
Онытканмын йөгәнен,—

дип куана. Биредә баланың табигате белән ирекле, үзбаш хәрәкәт итәргә омтылуы, эш-хәрәкәтләрендә кемгә дә булса бәйле булырга теләмәве чагыла. Чөнки олыларның тегене болай ит, монысын тегеләй ит дип әйтеп торуларыннан ул үзе дә туеп беткән.

Әтием дә, әнием дә
Мине һәрчак тиргиләр.
Шаярасы килгән чакта,
«Шаяр, улым!» — димиләр.

(«Барыбер»)

Шулай да малай «яратам мин аларны» ди. Чөнки ата-аналарының аңа бары тик яхшылык кына теләүләрен, аның үзенә сөеп карауларын ул нәни күңеле белән барыбер сизә.

Баланың табигате шундый: ул хөрлек ярата, үзенчә эш итәргә омтыла. Олылар исә аңа һаман да бәби, кечкенә итеп

карарга яраталар, аны кирәгеннән артык күзәтәләр, бик еш акыл өйрәтәләр. Алай ук булмаган очракта да, бала өчен бу шулайрак тоела.

Йоклыйсы килмәгән чакта,
«Бар инде, йокла!» — диләр.
Йоклаганда, «Тор инде, тор,
Аунама юкка!» — диләр.

Уйнаганда, «Китап укы,
Уйнап утырма!» — диләр.
Укысам, «Башың авыртыр,
Бик күп укыма!» — диләр.

Әгәр дә өйдә утырсам,
«Бар, урамда йөр!» — диләр.
Ә урамга чыгып китсәм,
«Бик күп йөрмә, кер!» — диләр.

Бала болардан шундый нәтиҗә ясый: «Аңламассың — бу өлкәннәр эшлиләр гел киресен!» Әлеге нәтиҗә, баладан бигрәк, өлкәннәр өчен кирәк.

«Туган тел» шигыре дә шулай дияргә мөмкинлек бирә.

«Туган телем —
Анам теле!» —
Дияр әле балалар.
«Туган телем —
Балам теле!» —
Дияр микән
Аналар?

Әйе, баланың теле «әни», «әти» дип ачылырмы, әллә ул башка телдә сөйләшә башлармы? Аның кулына «Әлифба» тоттырырлармы, әллә башка телдәге хәреф өйрәткечме? Кайсы телне ана теле буларак кабул кылса, димәк, кечкенәләр шул телдә сөйләшүче милләтнең рухын да күңеленә якын итәчәк. Шагыйрь әнә шул турыда гамьләнә. Балаларга туган телебезнең аһәңлелеген, халкыбызга хас яшәү рәвешенең саф нигезен күрсәтеп бирүгә һәм раслауга шагыйрь даими игътибарлы.

Кеше намуслы яшәргә, гадел булырга тиеш. Бу затлы сыйфатларны сүз белән генә түгел, бәлки шуңа хезмәт итүче мохит ярдәмендә дә тәрбияләүгә элек-электән зур әһәмият бирелгән. Шундый мохитләрнең иң тәэсирлесе — Сабантуй. Бу бәйрәм

«көрәш» сүзе белән аерылгысыз бәйләнгән. Гомумән, тормыш, яшәү үзе дә даими көрәшүне күздә тота. Ләкин шунысы бар: тормыш көрәшендә гадел булмаган алымнарның кулланылуы шактый еш очрый. Сабантуйда исә алай түгел, көче, сәләте бар — җиңә, юк икән — үзеңә үпкәлә. Шундый шартларда һәркем үзен сынап карарга тырыша, аңарда гадәти вакытларда йокымсырый торган куәт, ярыш дәрте уяна. Р. Миңнуллин «Сабантуйда» шигырендә моны шактый отышлы итеп сурәтли алган. Малай, кызып китеп, башкалар менә алмаган колга башына үрмәләгән. Күзне кызыктырып торган әтәчне дә алган. Әмма аска таба карагач куркып ук калган. Менүен менгән, ә менә ничек кире төшәргә? Шундый биеклектән карарга ук куркыныч. Шагыйрь шунда кискен борылыш ясый, малайны үз асылына, балалыкка кайтара. Ник дигәндә, ул хәзер куркыныч алдында берүзе кала. Җирдәге кебек, бер-берсен дәртләндереп торучылар монда юк. Ул инде:

Кирәкми әтәчегез,
Кирәкми бүләгегез —
Мине алырга гына
Менегез берәрегез! —

дияргә мәҗбүр. Бу хәл укучыда елмаю уята. Р. Миңнуллинның балалар шагыйре буларак осталыгы да — сүз сөрешен яки вакыйгаларны бер дә көтелмәгән якка борып тәмамлавында, моның көлкеле хәл-әхвәл барлыкка китерүендә. Шул рәвешле, ул шигырьнең финалын аеруча нечкәләп эшли. Әсәрдәге барлык сүз сөреше кинәт яңа ягы белән ачылып китә.

Әйтик, бабасы оныгына болай сөйли: мин һәр көнне кояш чыкканын күрәм, шуңа күрә бәхетле булганмын, ди. Баланың да бәхетле буласы килә икән.

Мин дә бабайга охшаган,
Соң торганым юк минем —
Кояш чыкканын карыйм да
Аннан... тагын йоклыймын!

(«Бабай кебек»)

Кояш чыгуын күрү үзе генә кешегә берни дә бирми. Бабай, шулай иртә торып, көн буена хисапсыз эш башкарырга өлгерә, шуның өчен ул мохтаҗлык күрми, гаиләгә күп файда китерә. Кояш чыгуга яңадан ятып йоклаучы малайның үзен әнә шул хезмәт сөюче бабасы белән тәңгәл куюы көлкеле хәл тудыра.

Нәни укучылар өчен бу кинәтлек кызык тоела. Биредә олы тормыш тәҗрибәсе белән күренешләрне бик самими бәяләүче бала күңеле арасындагы аерманың зур булуы әнә шулай отышлы файдаланыла.

Икенче бер очракта бала үзен иң каты йөгерүче дип саный. Хәтта кояшны узарга уйлый. Ул күк җисемен үзенең берәр иптәше кебек хис итә, аның белән тиз йөгерү буенча ярышка чыга. Әмма, күпме генә йөгерсә дә, кояшны артта калдыра алмый.

Тик кояш
Кызык итте —
Болытка
Кереп китте, —

ди. Шигырь шушы урында өзелеп калса, аның тәэсире әллә ни зур булмас иде. Иң кыйммәтлесе менә бу соңгы строфада әйтелә.

Ә үзе болыт артыннан
Көлгән була, җитмәсә...
Уза идем мин кояшны,
Әгәр кереп китмәсә!

Бу юлларны укыгач, кояш белән узышуны чын-чынлап максат иткән малай күз алдына килеп баса.

Р. Миңнуллин каләменең тагын бер отышлы ягы шунда: ул баланы табигатьнең бер өлеше итеп карый. Кош-кортлар, терлек-туар, кыргый җәнлекләр белән мөнәсәбәтләрдә баланың матур сыйфатларын ача, укучыларда бик гүзәл кешелеклелек хисләре тәрбияли. «Акбай шулай ди...», «Көчек өрергә тиеш», «Әни, мин көчек күрдем», «Кыр кәҗәсе», «Елмаючы бүреләр» һәм башка шигырьләре бу җәһәттән аеруча уңышлылар.

Баланың изге күңеллелеген ачу ягыннан «Әни, мин көчек күрдем» шигыре бик отышлы. Салкын урамда ялгыз калган көчекнең хәлен әнисенә аңлаткандагы тырышлыгы, шул җан иясенең аянычлы хәлен кечкенә йөрәге белән тоюы, аны кызгануы малайның һәр сүзеннән сизелеп тора. Сөйләгән саен, ул көчекнең авыр хәлен күрсәтүгә басымны арттыра бара.

Әни, ул улый иде,
Ул шулай елый иде,

Ул чынлап елый иде,
Ул ныклап елый иде.

Башта көчекнең улавы әйтелә. Әмма малай сизә: улый иде дип әйтү белән генә, әнисенең кызгануына ирешеп булмаячак. «Улый иде» дигәнне ул «елый иде»гә алыштыра. Әнисе ышанмыйдыр дип, «чынлап елый» ди, аннан «ныклап елый» дип өсти. Биредә баланың кечкенә генә булса да үз тәҗрибәсен кулланганлыгы сизелә. Чөнки, үзен кызгандырасы килгәндә, ул да «елаган», «чынлап елаган», «ныклап елаган». Шулай үз дигәненә ирешкән. Бу очракта ул ятим көчекнең язмышы өчен көрәшә, аңа рәхимсезлек күрсәтүчеләрне шелтәләргә дә өлгерә.

Аны, әни, яңгырда
Кемдер ташлап калдырган,
Алдаштырып калдырган,
Адаштырып калдырган...

Без биредә Р. Миңнуллин каләменең җитди, хисчән булуын да күрәбез. Кечкенәләрне кайгыртучанлыкка, үзеннән бүтәннәргә игелек кылырга өйрәтү, моның хупланырга лаек гамәл икәнлеген аңларга ярдәм итү — бу төр әдәбиятның иң изге бурычларыннан берсе. Бала:

Әнием, шул көчекне
Алып керик әле, ә?! —

дип ялвара икән, бу иң югары дәрәҗәдәге кешелеклелек сыйфатының үзен сиздерүе булып аңлашыла. Мондый затлы нигез балаларның һәрберсендә дә була. Нинди мохиттә тәрбияләнүенә карап, аларның балада үсүе яки яралгы хәлендә калуы ихтимал. Шагыйрь, әлбәттә, игелеклелек сыйфатларын максатка юнәлешле рәвештә ныгыту тарафдары, аларда моның даими күңел ихтыяҗы булырга тиешлелеге турында кайгырта. Әлеге малайның көчек турында ихлас кайгыртуы — аның яшендәгеләр өчен үзенә күрә батырлык ул. Югыйсә, «Батырлык эшләр идем...» шигыренең лирик герое кебек, кайберәүләр каһарманлык кылырга җай чыкмауга аптырап йөриләр.

Әрәм ята батырлыгым —
Уйланам шул хакта гына.
Үч иткәндәй, җае чыкмый
Иң-иң батыр чакта гына,—

дип уфтаналар. Башкаларга карата кечкенә генә булса да игелек кылуның әнә шул батырлыкка бәрабәр адым икәнен тиешенчә бәяләргә хәлләреннән килми. Р. Миңнуллин, яшь укучыларын шул турыда уйлануларга этәреп, үзе дә игелек эшли.

Үз-үзен артык ярату, гадәттә, гаиләдә бердәнбер бала булып үскән кешеләргә хас. Эгоист башкалар бәхете яки иминлеге өчен батырлык кылырга сәләтле булмый. Хәзерге вакытта бер балалы гаиләләр саны шактый ишәеп бара. Баланың күңел дөньясы камил булсын дисәң, гаиләдә кимендә ике бала булуы шарт. «Энекәш кирәк миңа!» шигыре әнә шушы хакыйкать, гамь белән сугарылган. Бала үзенең туганы булуын тели.

Бергәләшеп уйнарга
Бер иптәш кирәк миңа —
Берәү генә булса да,
Ямьсез генә булса да,
Елак кына булса да,
Энекәш кирәк миңа!

Бу шигырь,— мөгаен, Р. Миңнуллинның укучылар тарафыннан иң яратып кабул ителгән әсәрләреннән берседер.

Татарстанның халык шагыйре С. Хәким яшь каләмдәше Р. Миңнуллин иҗатының үзенчәлеген кыска гына болай дип билгеләгән иде: «Кыскалык, гадилек, халыкчанлык. Бу — шагыйрь иҗатының төп сызыгы. Роберт шушы сызыктан читкә чыгар дип уйламыйм. Юмор юмор инде ул, барысында да бертөсле дисәләр дә ышанмыйм. Роберт юморы мыек астыннан. Роберт күп сүзле озын шигырьләргә күчсә, атны буразнага тартып төшергән шикелле, шагыйрьне үз буразнасына, Тукайлар, Бари Рәхмәтләр салган буразнага төшерәсе килә».

Әйе, Роберт Миңнуллин шигъриятә үз буразнасына тугрылыклы булып яши. Сибгат ага Хәким, аның иҗатының Х.-К. Андерсен исемендәге халыкара Мактау дипломына лаек булганын, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен алганын күрсә, ничек сөенгән булыр иде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Р. Миңнуллинның балалар шагыйре икәнлеген дәлилләгез. Гомумән, «зурлар» шагыйре «балалар» шагыйреннән ни белән аерыла?

2. Әсәрләрне укучыны да бары тик я балалар өчен язылган әсәрләрне генә яратучы яки зурлар әдәбиятын гына үз күрүче дип аерып карап буламы?

3. Балаларның дөньяны җитди һәм юмор белән кабул итүләренең кушылмасы Р. Миңнуллин иҗатында ничек чагыла?

4. Балалар һәм зурлар арасындагы мөнәсәбәтнең нинди якларын шагыйрь аеруча үткенләндереп тасвирлый?

5. Кечкенә кешенең күңел дөньясы шагыйрь иҗатында ничек чагыла?

6. Кешенең җанлы тереклек ияләренә мөнәсәбәтендә аның иң югары сыйфаты — кешелеклелеге ачыла, диләр. Р. Миңнуллин сурәтләгән геройларда без моны ничек күрәбез?

7. Өлкән шагыйрь С. Хәкимнең яшь каләмдәше Р. Миңнуллинга мөнәсәбәтендә олылар һәм кечеләр арасындагы мөнәсәбәт ничек чагыла?

8. Ш. Галиев һәм Р. Миңнуллин әсәрләрен яттан сәнгатьле итеп уку буенча шигырь кичәсе уздырыгыз.

ӘДӘБИЯТ ДӘРЬЯСЫН КИЧКӘЧ...

(Гомуми йомгак)

Шулай итеп, хөрмәтле укучылар, татар әдәбиятының меңнәрчә елларга сузылган тарихы буенча сезнең сәяхәтегез бүгенге көннәргә дә килеп җитте. Иртәгә инде сез, кулыгызга өлгергәнлек аттестаты тотып, мөстәкыйль тормыш юлыннан атлап китәрсез. Кемнәрдер иген игү хезмәтен сайлар, кешеләрне ипи-сөт белән туендырыр. Кайсыларыгыз, бәлки, төзүче булыр, механизатор, эшче, пароход йөртүче, очучы булыр, бизнес белән шөгыльләнә башлар. Арагыздан югары белемле врачлар, инженерлар, галим һәм укытучылар чыгар...

Күпме еллар матур әдәбият дигән гүзәллек дөньясында гизгән кеше аттестат алгач, ягъни сүз сәнгате буенча төп белемнәрне үзләштерде дигән бәя алгач, бу шөгыленә нокта куя кебек. Кайбер фәннәр буенча ул, ихтимал, шулайдыр да. Әйтик, тарихчы булып киткән кеше өчен химия, биология буенча белем алуына нокта куелу табигый. Ләкин матур әдәбиятны өйрәнүгә карата моны әйтеп булмый. Мәктәпне тәмамлагач та, кеше, һичшиксез, әдәбият белән очрашуын (һич югында кино, театр, телевидение аркылы), әсәрләр укуын, язучылар белән кызыксынуын, яраткан шагыйренең шигырьләрен ятлавын дәвам итәчәк. Бу — матур әдәбиятның үзенчәлеге, асыл бер өстенлеге. Әдәби әсәрләрне академик-биолог та, инженер-химик та, тракторчы-механизатор да, сыер савучы да, министр да зур кызыксыну белән укый. Кыскасы, мәктәптә соңгы көннәрен уздыручы хөрмәтле дустыбыз, матур әдәбият синең гомерең буе юлдашың, рух бирүчең, юанычың булачак.

Ә бүгенгә кадәр алган белемнәрең, укыган әсәрләрең сине бу шөгыльнең дәвам итәргә әзерләделәр. Әдәбиятны гомерең буе яратырлык итеп нигез салдылар. Әдәбият дәресләре үзләренең төп вазифаларын үтәделәр: кызыксынып китап укучы затны бай рухлы шәхес итеп үстерделәр. Алар һәр укучыны төрле жанрдагы яңа әсәрләргә күңел бирергә һәм аларны бәяләргә өйрәттеләр.

Әйе, укучылар, сез инде шактый бай рухлы кешеләр булдыгыз. Чөнки сезнең акыл хәзинәгездә Кол Гали һәм Йосыф — Зөләйхалар, Кандалый һәм Каюм Насыйрилар, Сахибҗәмал һәм Әбүгалисиналар, Тукай һәм Исхакыйлар, Зөләйха һәм Хәятлар, Галиябану һәм Нәфисәләр, Муса Җәлил һәм Әмирхан Еникиләр, Кубрат хан һәм Әлмәндәрләр, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Роберт Миңнуллиннар урын алды. Сезнең күңелегезгә миһербанлык сеңде, әшәкелеккә нәфрәт кабынды, кешеләрне ярату хисе көчәйде. Сез инде ак белән караны аерырга өйрәндегез. Әдәбиятның конкрет тарихи дәверләрдәге бурычы һәм мәгънәсениләрдә булуына төшендегез.

Урта гасырларда татар әдәбияты кешенең дөньядагы урынын, яшәвенең мәгънәсен ислам кануннары яктылыгында тасвирлады. Кешенең Аллаһы Тәгаләгә мөнәсәбәте, әхлак кагыйдәләренең ислам өйрәтүләре җирлегендә саф һәм нык булуы беренче урында торды. XIX йөздә һәм бигрәк тә XX гасыр башында әдәбиятта кешенең гаделлекне, мәрхәмәтлелекне, тигезлекне яклавын тасвирлау алда торган хәлдә, кешелекнең үзенең дә бертөсле генә булмавы күрсәтелде. Әдәбият гади кешене, җәмгыятьнең күпчелеген тәшкил иткән катлау вәкилләрен сурәтләүгә ныклы игътибар бирә башлады. Совет елларында әдәбиятның үзәгенә күмәк коллективка буйсынган, иң әүвәл күпчелек мәнфәгатьләрен яклаган, үз мәнфәгатьләрен шуларга буйсындыра белгән кеше образы бастырылды. Бүгенге әдәбият исә кеше һәм дәүләт, аерым кеше һәм күпчелек-коллектив арасындагы тормыштагыча мөнәсәбәтләрне сурәтләргә, кеше шәхесенең дөрес мәгънәсен һәм билгеләмәсен бирергә тырыша.

Чорлар һәм дәверләр арасында әдәбиятта кешене, аның тормыштагы урынын һәм ролен аңлауда шундый аермалыклар булса да, ул һәр чорда да гомумкешелек кыйммәтләрен яклады һәм саклады. Кайсы

гына чорда язылган әсәр булмасын, анда гаделлек һәм миһербанлылык, хөрлек һәм фидакярлек, мәхәббәт һәм тугрылык, гуманлылык һәм Туган илне, Туган җирне ярату авазлары яңгырый. Явызлык, хыянәт, хөсетлек, алдашу, кансызлык, бәгырьсезлек, таркаулык һәм башкалар кире кагыла, тәнкыйтьләнә. Гомумкешелек кыйммәтләре арасында безнең әдәбиятта аерата берсе һәрчак, һәр дәвер язучыларының игътибар үзәгендә торды. Ул да булса — милләт язмышы темасы. Бу теманың әдәбиятта гел-гел игътибар үзәгендә булуы халкыбызның үз дәүләтчелеген югалтуы, аннан соңгы чорларда үз милләтен, динен һәм денен саклап калу өчен, һәрдаим көрәшергә мәҗбүр ителүе аркасында килеп чыкты.

Сез инде, укучылар, алда әйтелгәнчә, әдәбиятыбызның озын гомерле тарихы белән таныш буларак, андагы күренекле язучыларны, иң яхшы әсәрләрне беләсез. Бу үсеш юлының шома гына булмавыннан да хәбәрдарсыз. Халык һәм милләт язмышына бәйле төстә әдәбият үсеше дә уңышлардан гына тормый, аның югалтулары да байтак булды. XX гасырда ул аерата ачык төс алды. Гасыр тупсасында канатын киң җәя башлаган, зур уңышлар яулаган әдәбият 30 нчы еллардан соң күп кенә язучы-авторларын, гасырлар буе аңа уңышлы хезмәт иткән гарәп графикасын югалтты. Иң мөһиме, әдипләргә иҗатта иркенлек җуелып, алар тар идеология кысаларына кысрыклап кертелде. Әдәби геройны шәхси сыйфатларыннан мәхрүм ителгән, кечкенә бер «шөреп» хәленә төшкән итеп сурәтләү гамәле барлыкка килде, ислам гадәт-йолаларыннан һәм фәлсәфәсеннән көчләп аеруга дучар ителде.

Әдәби иҗат процессында рус фәлсәфәчесе Н. А. Добролюбов ачкан бер канун бар. Аны, гади генә итеп, әдәбиятның үз үсешендә торган саен халыкка, тормышка һәм заманның иҗтимагый проблемаларына якынлаша бару закончалыгы дип әйтергә мөмкин. Урта гасырлар, XVIII һәм XIX йөзләр, XX гасыр башы татар әдәбиятын чагыштырганда, бу закончалык бигрәк тә ачык чагыла. Мәсәлән, урта гасырларның бөек вәкилләре Кол Гали һәм Харәзми әсәрләре белән Тукай һәм Гафури шигырьләрен янәшә куеп карасаң, соңгыларының халык тормышына никадәр якынлыгын күрәсең. Бу якынаю процессы Совет чоры әдәбиятында беркадәр тоткарланды, язучылар

тормышны бизәп-матурлап, хакыйкатьтән шактый читләшеп язарга мәҗбүр ителделәр. Әмма хәзерге әдәбият бу юлда инде үз эзенә төшә бара. Бүгенге әдәби әсәрләрдә тормышчан дөреслек ныгый, көчәя.

Матур әдәбият барлыкка килү белән бер үк вакытта, аның турында белем дә туган. Бу белемнең бер тармагы — әдәби тәнкыйть. «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер[1]»,— дигән Г. Тукай. Чыннан да, әдәбиятның дөрес үсешенә ярдәм итү өчен, аның тәрәккыяте тулы булсын өчен, объектив тәнкыйть һәм теория кирәк. Әдәби тәнкыйть бүген туа торган әсәрләрне анализлый, аларга бәя бирә, әле тәмамланмаган, хәтта киләчәктә булачак (потенциаль) процессларны өйрәнә, агымдагы әдәби үсеш юлларын билгели, прогноз бирә. Әдәби тәнкыйтьче язучы белән укучы арасында арадашлык хезмәтен үти. Чөнки ул укучыга әсәрнең әһәмиятен, автор уздырган төп фикерне, аның максатын, ягъни автор позициясен, әсәрнең сәнгати яңалыгын аңлатып бирә.

Татар әдәби тәнкыйтен һәм әдәбият белемен нигезләүгә һәм үстерүгә Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхреддин кебек галимнәр, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек язучылар зур өлеш кертте. Габдрахман Кәрам, Кәбир Бәкер, соңрак Габдрахман Сәгъди, Гали Рәхим, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали тирән белемле галимнәр һәм үткер күзле, зәвыклы тәнкыйтьчеләр буларак танылдылар. 40—80 нче елларда Гали Халит, Мөхәммәт Гайнуллин, Гази Кашшаф, Хатип Госман, Хәсән Хәйри, Бәян Гыйззәт, Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев шикелле галимнәр әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эстафетаны алга алып киттеләр, милли әдәбиятыбыз тарихының бөтен юлын күзаллаган хезмәтләр яздылар.

Соңгы елларда әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә бер зур төркем әзерлекле галимнәр һәм язучылар эшли. Академиклар, профессорлар, фәннәр кандидатлары. Язучы-тәнкыйтьчеләр. Аларның һәрберсенең яраткан өлкәсе, үзе яхшырак өйрәнгән тармагы бар. Ә билгеле бер тармакта тирәнәю һәм специальлә-

---

[1] *Шәйдер* — нәрсә(дер).

шү — бүгенге фәннең үзенчәлекләреннән берсе. Безнең чор галимнәренә һәм тәнкыйтьчеләренә хас тагын бер үзенчәлекле сыйфат — аларның күпчелеге югары уку йортлары һәм мәктәпләр, лицейлар, училищелар, гимназияләр өчен әдәбият буенча дәреслекләр язуда, хрестоматияләр төзүдә катнашалар. Кайберләре белән танышып үтик.

Академик, профессор **Мансур Хәсәнов** күбрәк татар әдәбиятының теоретик һәм методологик мәсьәләләре белән шөгыльләнде. Аның «Галимҗан Ибраһимов» (1977) һәм «Интернационализмның җанлы традицияләре» (1980) исемле китаплары фикер тирәнлекләре белән аерылып тора. Кайбер хезмәтләрендә ул бүгенге әдәби процессның барышын анализлый, методологик характерда гомумиләштерүләр ясый.

Бүгенге актив тәнкыйтьче галимнәрдән берсе — Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор **Тәлгат Галиуллин** татар поэзиясенең дә, прозасының да уңышларын һәм кимчелекләрен, үзенчәлекле сыйфатларын ачыклап, даими күзәтеп бара. Аның китапларында 30 нчы еллардан алып татар шигърияте узган юл анализлана, хәзерге күренекле шагыйрьләр һәм прозаиклар иҗаты бәяләнә, кайбер жанр төрләре буенча уңышлар барлана («Еллар юлга чакыра», 1975; «Дәвамлылык», 1987).

Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор **Азат Әхмәдуллин**,— асылда, драматургия һәм театр буенча белгеч. Аның китапларында татар сәхнә әдәбияты узган йөз елдан артыкка сузылган юл фәнни анализлана («Татар драматургиясе», рус телендә, 1983). Ул соңгы еллар драматургиясен даими күзәтеп бара, бу өлкәдәге казанышларны һәм кайбер кимчелекләрне билгели, аерым драматургларның иҗат портретларын тудыра («Дөреслеккә ирешү юлында», 1993). Драматургия төренең аерым жанрларын фәнни өйрәнүдә һәм бүгенге авторлар язган пьесаларны бәяләүдә филология фәннәре докторы **Назыйм Ханзафаров** нәтиҗәле эшләде («Татар комедиясе», рус телендә, 1996).

Халкыбызга мирасы кайтарылгач, әсәрләре ныклап өйрәнелә башлаган язучыбыз Гаяз Исхакый турында профессор **Әхмәт Сәхапов** берничә җитди китап язды («Яңарыш хәбәрчесе», 2001, рус һәм татар телләрендә),

олы язучыбыз Аяз Гыйләҗев иҗатына монографик хезмәт багышлады («Аяз Гыйләҗев прозасы», 1995), бүгенге әдәби процесска багышланган мәкаләләр иҗат итә.

Татар прозасының тарихи үткәнен, ирешкән казанышларын, бүгенге хәлен өйрәнүгә һәм бәяләүгә профессорлар **Флүн Мусин** («Чор белән аваздаш», 1983), **Фәрит Хатипов** («Геройның рухи дөньясы», рус телендә, 1981), **Фоат Галимуллин** («Офыкларны алдан күреп», 1995), **Зөфәр Рәмиев, Д. Заһидуллина, Ф. Бәширов, Р. Сверигин, Ф. Яхин, Ф. Ганиева**, филология фәннәре кандидатлары, тәнкыйтьчеләр **Рафаэль Мостафин, Мөдәррис Вәлиев** (Салих Маннапов), **Ринат Мөхәммәдиев, Әлфәт Закирҗанов, Таһир Гыйләҗев** һ. б. лаеклы өлеш кертәләр.

Халык авыз иҗаты һәм урта гасырлар әдәбияты белгечләре — профессорлар **Фатих Урманчеев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов, Резеда Ганиева** — бүгенге әдәби процессны да күз уңында тоталар, әдәбиятның үсеш кануннарын ачыклап, аерым әдәби күренешләргә һәм әсәрләргә бәя бирәләр.

Соңгырак буын вәкилләреннән **Равил Рахмани, Сәгыйть Хафизов, Мансур Вәлиев, Галимҗан Гыйльманов** һәм башкалар, әдәбиятыбызның үсешен күзәтеп, аерым язучылар иҗатларына һәм яңа әсәрләргә бәя биреп, бүгенге иҗади процесска уңай йогынты ясыйлар.

Югарыда исемнәре аталган каләм ияләре — Татарстан Язучылары берлеге әгъзалары.

«Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр»,— дип язган Риза Фәхреддин. Икенче сүзләр белән әйткәндә, матур әдәбият — халык рухының, аның әхлагының чагылышы. Алай гына да түгел, ул — халык рухын, аның әхлагын тәрбияләүче дә. Инде сезнең белүегезчә, хөрмәтле укучылар, бездә «әдәбият» атамасы «әдәп» сүзеннән ясалган. Татар әдәбияты белән якыннан танышкан кеше буларак, сез аның шул сүзгә никадәр тугрылыклы икәнен, иң саф әдәп һәм югары әхлак кагыйдәләрен алга сөрүен күрдегез. Халкыбызның рухи йөзен һәм акыл хәзинәсен саклауга һәм үстерүгә керткән өлеше белән якыннан таныштыгыз. Бүгенге татар әдипләре аның бу изге вазифасын үтәвен лаеклы дәвам иттерәләр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәктәп елларында укыган әсәрләрдән кайсылары сезнең хәтерегезгә сеңеп калды? Исемлек төзегез. Исемлекләрне чагыштырып, кемнең күбрәк әсәр хәтерләвен ачыклагыз. Сезгә иң нык тәэсир иткән әсәрнең кайсы яклары аерата ошады? Кайсы язучыны сез «яраткан язучым» дип атыйсыз?

2. Г. Тукайның «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» дигән сүзләрен шәрехләгез. Әдәби тәнкыйтьнең төп бурычын нидә күрәсез?

3. Татар әдәби тәнкыйте һәм әдәбият белеменнән кайсы авторларның нинди хезмәтләрен һәм әсәрләрен беләсез? Аларның кайсылары сезгә аеруча ошады?

4. Әдәби процесстагы Н. А. Добролюбов ачкан закончалыкны сез ничек аңлыйсыз?

5. Матур әдәбият яклаган һәм кире кага торган гомумкешелек кыйммәтләрен, үзегез аңлаганнарны да өстәп, санап, дәлилләп күрсәтегез.

6. «Матур әдәбият халыкның акыл хәзинәсен һәм рухи йөзен саклаучы һәм үстерүче» дигәнне үз сүзләрегез белән аңлатып бирегез.

ЭЧТӘЛЕК

Башка илләрдә татар әдәбияты. *А. Әхмәдуллин* 3
Гаяз Исхакый. *А. Әхмәдуллин* 5
30 нчы елларда татар әдәбияты. *Т. Галиуллин* 13
Нәкый Исәнбәт. *А. Әхмәдуллин* 30
40—50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы.
Ф. Галимуллин 46
Муса Җәлил. *Н. Юзиев* 65
Фатих Кәрим. *Ф. Галимуллин* 90
Яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында. *Т. Галиуллин* 107
Гомәр Бәширов. *Т. Галиуллин* 122
Хәсән Туфан. *Н. Юзиев* 129
Әмирхан Еники. *Ф. Ганиева* 151
Татар әдәбияты үзгәрешләр чоры алдыннан. *А. Әхмәдуллин* 170
Проза. Гариф Ахунов. *Ф. Ганиева* 172
Нурихан Фәттах. *Ф. Ганиева* 184
Аяз Гыйләҗев. *Ф. Ганиева* 204
Мөхәммәт Мәһдиев. *Т. Галиуллин* 215
Поэзия. Әхсән Баянов. *Т. Галиуллин* 224
Илдар Юзеев. *Т. Галиуллин* 231
Драматургия. Туфан Миңнуллин. *А. Әхмәдуллин* 238
Хәзерге татар әдәбияты. *А. Әхмәдуллин* 256
Шигърият офыклары. *Т. Галиуллин* 262
Равил Фәйзуллин. *Т. Галиуллин* 278
Ренат Харис. *Т. Галиуллин* 286
Мөдәррис Әгъләмов. *Т. Галиуллин* 292
Проза жанрының үсеше. *Ф. Галимуллин* 298
Ринат Мөхәммәдиев. *Ф. Галимуллин, А. Әхмәдуллин* 333
Хәзерге драматургия. *А. Әхмәдуллин* 347
Рабит Батулла. *А. Әхмәдуллин* 356
Ризван Хәмид. *А. Әхмәдуллин* 364
Балалар әдәбияты. *Ф. Галимуллин* 370
Шәүкәт Галиев. *Ф. Галимуллин* 376
Роберт Миңнуллин. *Ф. Галимуллин* 383
Әдәбият дәрьясын кичкәч... *А. Әхмәдуллин* 392

Учебное издание

Ахмадуллин Азат Гильмуллович
Галимуллин Фоат Галимуллович
Галиуллин Талгат Набиевич и др.

ЛИТЕРАТУРА
(Татарская литература в 30—90-х годах XX столетия)

Учебник для 11 класса
средней общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

Издание четвёртое, исправленное

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы
Галимуллин Фоат Галимулла улы
Галиуллин Тәлгат Нәби улы һ. б.

ӘДӘБИЯТ
(XX йөзнең 30—90 нчы елларында әдәбият)

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек

Төзәтелгән дүртенче басма

Мөхәррире *Н. К. Нотфуллина*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректорлары *С. З. Гыймалетдинова, Г. Г. Мөхәммәтҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.08.2011. Форматы 60×90 1/16.
Шартлы басма табагы 25,00 + форз. 0,25.
Тиражы 10 200 д. Заказ Р-1113.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Сәнгать, шул җөмләдән әдәбият та, барыннан да элек битараф калдырмаска тиеш! Сәнгать һәм әдәбият алдамаска, юатмаска, йокымсыратмаска тиеш! Моның өчен, беренче чиратта, авторларның заманны аңлый алулары зарур, заман кешеләрен җитәкли алырлык көчле рухлы булулары зарур!

Аяз Гыйләҗев

9 785298 020725